# НУРИХАН ФАТТАХ

# ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

2

ТОМ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# НУРИХАН ФӘТТАХ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

## 2

## ТОМ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф96

***Редколлегия:***

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,
Т.А.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәттах Нурихан**

Ф96 Сайланма әсәрләр. — 5 томда, 2 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 431 б.

ISBN 5-298-01200-0 © Татарстан китап нәшрияты, 2002



## Заман турында сөйләшү

Язучы дигән абруйлы исемгә тиз генә, мәшәкатьсез генә ирешүчеләр була: аларны укучылар тиз таный, аларның исемнәре әдәбият күзәтүгә багышланган мәкалә-докладларда тиз арада даими урын ала...

Язучы дигән абруйлы исемгә тиз генә, мәшәкатьсез генә ирешеп, беренче каты тәнкыйть сүзе ишетүгә кире чигенүчеләр, язучылык эшен бөтенләй ташлаучылар була; әдәбият тарихы мондыйларны да хәтерли: йөрәк кушуы буенча килмәгәннәр алар әдәбиятка.

Нурихан Фәттах — бүгенге танылган прозаик, драматург һәм публицист — алда саналганнарның берсенә дә туры килми. Үз буыны язучылары арасында ул, ихтимал, акрынлык белән, мәшәкатьле, күпкырлы эшчәнлеге, гадәттән тыш хезмәтчеллеге белән абруйга ирешкән азлардан берседер. Аның турында язуы да җиңел эш түгел: журналларда аның әдәби портреты басылганы юк, филология фәнендә әлегә Нурихан Фәттах иҗатына багышланган диссертацияләр, бүлекләр юк.

Нурихан Фәттахның биографиясе — аның әдәби һәм публицистик хезмәтләрендә. Мин, мәсәлән, аның хикәяләре, романнары, сәхнәдә куелган «Кол Гали» драмасы белән яхшы таныш. Ялкынлы, тирән эчтәлекле, кайчакта бәхәсле дә мәкаләләре белән таныш. Укучылар өчен Нурихан Фәттах әнә шуларда. Китапларын ул еш бастырмый, бер басылган әсәренең икенче басмасын чыгаруны кайгыртып йөрми, аз күренә — күп эшли, нәтиҗәле эшли. Язучылык хезмәтенә ул профессиягә караган кебек карый, әйтик, корыч коючы, җитен үстерүче, руда чыгаручы үз эшенә никадәр җитдилек белән караса, язучылык хезмәтенә Нурихан да әнә шулай җитди карый, аның үткән-сүткәндә генә язып киткән әсәрләре юк. Уңышка ирешсә дә, бары тик зур көч, зур хезмәт нәтиҗәсендә генә ирешә ул, уңышсызлыкка да һич тә әдәби эшкә җиңел караудан түгел, ә Нурихнлыгыннан, әдәбиятка җанытәне белән фанатикларча бирелгәнлегеннән очрый. Үзенә ошамаган, яки үзенә ошап та укучылар күңеленә барып җитә алмаган әсәрләр кайсы гына язучының иҗат биографиясендә булмый соң? Әмма язучының иҗат биографиясен беренче чиратта укучылар күңелен кузгаткан, заман рухын чагылдырган, хәрәкәттәге мирас булырдай әсәрләр билгели. Нуриханда андыйлар исә байтак. Ул, гомумән, тапталмаган юлларны эзли. Әдәбиятта Нурихан чирәм җирләр күтәрүче сыйфатында күренергә ярата. Аның 1953—1954 елларда ук язган хикәяләре бар. Ул хикәяләрнең барысы да бүгенге, танылган Нуриханның иҗат биографиясен бизи, дип әйтүдән ерак торабыз. Әмма прозадагы борылышны беренче сиземләүче, беренче башлап илленче-алтмышынчы еллар әдәбиятындагы яңа сыйфатлардан татар әдәбиятына алып килергә омтылыш ясаучылар арасында Нурихан беренчеләрдән иде. Әсәрләрен кабат бастыру мәшәкате белән йөрү аның табигатендә түгел, дигән идек. Кайберләрен яңа җыентыкларга теркәргә, бастырырга да кирәк иде. 1958 елда ук (моннан 20 ел элек!) язылган «Ялгыз

нарат» хикәясе белән Нурихан Фәттах әдәбиятның бүгенге зур, фәлсәфи темасы — табигать һәм кеше мәсьәләсен күтәрмәдемени? Хезмәт халкының гасырлар буенча буыннан буынга тапшырылып килгән күркәм әхлакый сыйфатларыннан милекчелек хас иде, комагайлык белән бәрелешүен, бу бәрелешүдә табигать һәм кай очракта күркәм әхлакый сыйфатларны яңа буыннарга тапшыручы уңай геройның да имгәнүен, һәлак булуын әдәбиятта хәзер аз язалармы? «Ялгыз нарат» хикәясе — табигать белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне әхлакый-этик проблемалар аспектында караган кыю хикәяләрдән берсе иде.

«Әдәбият — һәрвакыт көрәш ул,— ди СССР Дәүләт премиясе лауреаты, танылган прозаик Федор Абрамов,— әдәбият — Тормыш, Ватан, Заман турында зурдан күтәреп сөйләшү». Тормыш, Ватан, Заман турында меңләгән, миллионлаган укучыларың белән сөйләшү өчен акыл, сәләт, культура кирәк. Ләкин шулар янына әле ихтыяр көче, батырлык, кыюлык та кирәк.

Н.Фәттах әдәбиятта күтәргән темалары буенча һәрвакыт кыю булды. Егерме алты яшендә ул үз буыны әдипләре арасыннан беренче булып роман тәмамлады. Илле өченче-илле дүртенче елларда романнарыбыз аз, бик аз иде әле. Яшь Нурихanның университет студентлары тормышын туган туфракка, яшьләр намусына мөнәсәбәтле киң планда тасвирлаган «Сезнеңчә ничек?» романы илленче еллар татар прозасына заман сулышын биргән әһәмиятле әсәр булды. Студент егет Сәгыйтьнең туган җиренә табигать балаларынча мәхәббәте аның рухи дөньясын, дөньяга карашын баета. Сәгыйть — уйчан, эзләнүчән егет. «Нигә соң туган ил, туган җир төшенчәсе безнең аңда һәрвакыт балачакның кояшлы көннәре белән, яшенле яңгырлары һәм яшел чирәм чемченеп йөргән йомшак мамыклы каз бәбкәләре белән, яланаякка кадала торган арыш камыллары һәм шаулап аккан язгы ташкыннары, карга боткалары белән шулай тыгыз бәйләнгән икән?»— дип уйлана Сәгыйть авылга кайткач. Уйчан егетнең иң кыен вакытта үз намусына турылыклы булырга, принципиаль булырга да көченнән килә.

Заманында Н.Фәттахның «Сезнеңчә ничек?» әсәре, анда тасвирланган югары уку йорты тормышы, намус, принципиальлек мәсьәләләре студент яшьләр арасында күп фикерләр уяткан роман кулдан төшмичә укылган иде. Бүгенге көн әдәбияты дәрәҗәсеннән чыгып караганда, бу романда, ихтимал, бәхәсле дә, примитив та урыннар бардыр, әмма күтәргән темасы ягыннан ул әсәр — яшь язучының кыюлыгы иде.

«Бала күңеле далада» романы (1962) белән дә Н.Фәттах әдәбиятта кыю адым ясады. Илленче елларның уртасы — совет яшьләренең зур хезмәт романтикасы белән рухланып чирәм җирләрне үзләштергән чор. Чирәм җирләрне күтәрүдә Казан югары уку йортларының студентлары, Татарстан яшьләре актив катнаштылар. Яшьлек чоры илленче елларга туры килгән кешеләрнең чирәм җирләрендәге хезмәт пафосы, яшьлек ялкыны белән дөрләгән батырлыгы ул буын вәкилләренең биографияләрендә мәңге сагынып сөйләрлек якты эз булып калды. Чирәм җирләрне үзләштерүчеләр тормышын киң планда эмоциональ-фәлсәфи аспектта яктырту максаты белән Н.Фәттах — инде формалашкан язучы — яңа җир күтәрүчеләр янына китте һәм шунда эшләде. Үз көче белән яңа җирдә иген үстерүдә катнашкан язучы бу теманы әдәбиятка алып килде. Өр-яңа теманы татар әдәбиятына алып килүе һәм роман жанрында моны уңышлы гына башкарып чыгуы аның әдәбиятта шулай ук «Чирәм җир күтәрүе» иде. «Бала күңеле далада» романының ахырында шундый эпизод бар: чирәм

җирләрдә иген үстерүче татар егетләре Һарун белән Барый далада бодай үскәнен карарга килүче казах карты Байболат белән сөйләшәләр.

— Әйдә, әйдә, бабай, рәхим итәсез!— ди Байболат картка Барый.— Синдәй кунакларга без бик шат.

— Кунак түгел — хуҗа!— диде Һарун.

— Ие, ие, конак имәс, куҗамын!— диде Байболат, куанып.

Н.Фәттахның язучылык биографиясенә күз салганда әлеге эпизод искә төшә. Нурихан — чирәм җирләрдә кунак булып, «өйрәнүче» булып кына йөрмәгән кебек, әдәбиятта да, «конак имәс, куҗа». Ул үз темасын алдан бик озаклап сайлап, тормыш материалын тәмам үзләштереп бетергәч кенә язарга тотына. Һәр язучы кайсы формада, нинди жанрда үзен иркенрәк тотса, шул формада, шул жанрда эшләргә тиеш. Н. Фәттах әдәбиятта үзен романчы буларак танытты. Дөрес, аның «Мөдир Саҗидә» повесте, «Ләйлә» хикәясе тормышны иннек-кершәнгә манмыйча хакыйкый тасвирлаулары белән язучының остара, үсә барганын күрсәткәннәр иде. Тормышны якынча, кершәнгә манып, йомшартып язу — әхлаксызлык. Мондый әсәр укучыны адаштыра. Н.Фәттах тормышны тасвирлаганда андагы каршылыкларга күз йоммый, аларга кыю рәвештә анализ ясый. Чөнки язучы буларак үзенең җаваплылыгын яхшы аңлый: хакыйкатьтән башка сәнгать була алмый.

Язучының зур күләмле «Этил суы ака торур» романы озак еллар тарих, этнография, фольклор, тел гыйлеме, фәлсәфә, марксизм-ленинизм әсәрләрен өйрәнү нәтиҗәсе буларак туды. Заманында, бу роман чыккач, бәхәсләшүчеләр булды: тарихи роман жанрына моны кертеп буламы, юкмы? Заманча әсәрме бу, түгелме? Бәхәсләр булдылар да уздылар. Әмма роман калды. Аны күптән инде китап кибетләренең киштәләреннән таба алмыйсың. Тарихи романмы ул? Анысын әдәбият теоретиклары билгеләрләр. Заманчамы? Әйе, заманча. Борынгы Болгар бабаларыбызның моннан мең еллар элеккеге тормышын тасвирлаган булса да — заманча. Әйе, А.Толстойның утызынчы-кырыгынчы елларда язылган «Петр Беренче» романы, М.Җәлилнең Бөек Ватан сугышы алдыннан иҗат ителгән «Алтынчәч» әсәре ничек заманча булса, Н.Фәттахның «Этил суы...» да заманча. Чөнки романның нигезендә яткан халыклар дуслыгын яклау идеясе ул — бүгенге идея дә. Борынгы бабаларыбызның үз кул көче белән көн күрүчеләрнең дә, ил-дәүләт язмышына йогынты ясарлык шәхесләрнең дә чит ил баскыннарына каршы көрәш өчен бер-беренә ярдәм итәргә әзер торулары, үзара дуслык, хезмәттәшлекне яклаулары — заманча.

Бу инде бәхәссез. Әмма әдәби тәнкыйтьтә, кызганычка каршы, үзенчәлекле, киң планлы бу әсәргә әдәби-эстетик анализ әлегә ясалмады, романның сюжет-композиция үзенчәлекләре, поэтикасы ачылмады.

Н.Фәттах иҗаты әдәбият фәнендә гомумән аз өйрәнелгән, аз тикшерелгән. Тәнкыйтьчеләр, күрәсең, аның бер сыйфатын искә алып бетермиләр: Нурихан үз әсәрләренә тәнкыйди күз белән карый белгән кебек, тәнкыйтьчеләр сүзенә дә колак сала, исәпләшә белә. Чөнки дөрес сүз кешене көчәйтә, аның үз-үзенә ышанычын арттыра. Тәнкыйтьтән өреккән язучы — үз позициясенә, үзе язганга ышанычы нык булмаган язучы.

Н.Фәттах әсәрләрен тикшерүчеләр аның тагын бер ягына игътибар итәрләр әле: ул — телнең мөмкинлекләрен армый-талмый эзләүчеләрдән, телгә ифрат дәрәҗәдә сак караучылардан берсе. Саный китсәң, ул буын язучыларыннан аларның саны әллә ни күп түгел. Н.Фәттах, Х.Сарьян һәм... «һәм башкалар» димәкче идем, кыен хәлгә калдым.

Әйе, тел культурасын өйрәнү, телнең мөмкинлекләрен ачу, тел-

не үстерү — язучының үз эшенә һәм укучыларына ихтирамы дигән сүз.

Әдәбиятка килүче кеше үзенең нинди авыр, катлаулы хезмәт юлын сайлап алганын аңларга тиеш.

Чөнки әдәбият — заман турында, тормыш турында миллионнар белән сөйләшү ул.

Нурихан Фәттах миллионнар белән үзенең авыр, катлаулы хезмәт юлын сайлап алганын аңлаган хәлдә сөйләшүче, шул сөйләшүнең бөтен җаваплылыгын тойган, халкына, иленә игелекле язучы ул.

*Мөхәммәт Мәһдиев*
*1977, ноябрь*

# БАЛА КҮҢЕЛЕ ДАЛАДА

*Роман*

**Беренче баб**

**I**

Кысан, тәбәнәк йорт эчендә көчкә тын алып, тирләп-пешеп утырган кешеләр, кинәт буасын ерып киткән су кебек, барысы берьюлы ишеккә ташландылар; иркенгә, салкынча саф һавага килеп чыктылар да рәхәтләнеп тын алдылар; ишектән читкәрәк тарала барып, тирләгән битләрен, маңгайларын сөрткәләделәр, чишелгән төймәләрен каптырдылар, бүрекләрен, яулык-шәлләрен төзәткәләделәр. Элек авыл клубы булган, хәзер исә совхоз конторасы урнашкан яссы түбәле озынча саман йорт алды берничә минут эчендә ыгы-зыгы, шау-шу белән тулды. Берәүләр көлде, икенчеләре сүгенде, өченчесе тамак ярып кемнедер үз янына чакырды. Ә ишектән өсләренә кыска сырма, аякларына авыр итек, ботинкалар кигән яшь егетләр, кызлар һаман чыга тордылар, як-якка тарала тордылар.

Икенче бригаданыкылар, алдан сөйләшеп куйган шикелле, гомуми төркемнән читкәрәк, бер тирәгәрәк җыелдылар.

Кичке аш вакыты инде күптән узган иде, кешеләрнең ашыйсы килә иде, шуңа күрә һәркем тизрәк үзләренә — бригадага кайтып китү турында гына уйлады.

— Бригадир кая соң?— диде кемдер, түземсезләнеп.

— Хәзер анда синең кайгы юк!— диде икенчесе, җавап итеп.

Күп тә үтмәде, иңеләй ачылган киң ишектән чыгып килүче соңгы кешеләр арасында дүрт күз белән көтелгән бригадир Глеб Семеныч Таран күренде.

Ул аю кебек юан, таза бер кеше иде. Аның алгарак чыгып торган ияклӘрен, симез яңакларын, гадәттәгечә, куе кара төк каплаган иде, шунлыктан аның ниндидер йөнтәс җанварга охшашлыгы тагын да ныграк арта

төшкән шикелле иде; ышкылып-кыршылып беткән һәм колакчыннары бәйләнмичә югары кайтарып куелган күн бүреге кыңгыр салынган иде; сарык йоны шикелле укмашкан коңгырт чәчләре, бүрек астыннан чыгып, маңгаена төшеп тора иде; кесә тирәләре каешланган кара сырмасы, шулай ук, гадәттәгечә, җилбәгәй җибәрелгән иде; сырма эченнән исә нинди төр хезмәткәрләрнеке икәнлеген инде аерып булмый торган калай төймәле пинжәге күренеп тора иде.

Бүген ул, күрәсең, җыелыш хөрмәтенә аек баштан килгән һәм шуңа күрә бик кәефсез иде, караңгы чырайлы иде. Хәер, аның кәефсез булуының сәбәбе анда гына да түгел иде.

Ишектән чыккач та ул, як-ягына каранып, үзенекеләрне эзләде. Кызлар, барысы да бертавыштан диярлек:

— Глеб Семеныч, без монда!

— Килегез монда, Глеб Семеныч!— дип кычкырдылар.

Бригадир, аларның анда булуларына, җитмәсә, шул турыда хәбәр биреп кычкырып торуларына ачуы килгән сыман, караңгы чыраена әз генә дә яктылык әсәре чыгармыйча, алпан-тилпән төркем янына атлады.

— Глеб Семеныч, ашыйсы килә!

— Глеб Семеныч, өйгә кайтасы килә!— диештеләр кызлар, шыңшып.

Таран туктады, кыска муенын борып, башта уң ягына карады, аннары сул ягына карады һәм бер-ике адым арттанрак атлап килгән учетчы Димкага кисәк кенә:

— Машина кая?— диде.

Учетчы егетнең нәрсә дип җавап бирәчәген алдан ук белгәндәй, ул ризасыз бер кызулык белән лачт итеп җиргә төкереп куйды.

— Ничә мәртәбә әйттем мин сиңа машина әзер булсын дип!..

Учетчыга үзенең беркайчан да андый сүз әйтмәгәнлеген һәм машинаның әзер булуы-булмавы һич тә аңа бәйле түгеллеген ул бик яхшы белә иде, ләкин шул ук вакытта аңа эчтәге ярсуын ничек булса да чыгарырга, кемгә булса да кычкырырга кирәк иде һәм шулай ук яшьләр алдында кайгыртучан кеше булып күренү дә зыянлы түгел иде.

— Бар, тиз бул!— диде ул Димкага тагын да.— Хәзер үк килеп җитсен, бер минут тормасын, сукин сын!

Бүтәннәрнеке шикелле кыска сырмасы өстеннән биленә әкәмәт киң каеш буып куйган, колгадай озын Димка авыз эченнән нидер мыгырданып алды, ләкин сүз кайтарып тормады; кире борылды да, авыр итекләрен лас-лос өстерәп, машина эзләп китеп барды.

Бригадир кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгарды, учетчының ничек итеп атлап баруына карап торгандай итте дә янә бер төкереп куйды.

— Бер аягын атлаганчы, икенче аягын эт ашый сукин сынның!— диде ул, үзалдына сукранып.

— Бер атласа, бер чакрым атлый ул, Глеб Семеныч!— диде Белугин.

— Бар әле син дә, лыгырдык! Булмас ул җебегәннән,— диде Таран Белугинга.

— Ә, Глеб Семеныч?— диде Белугин, ишетеп җиткермәгән сыман.

— Бар, тизрәк машина алып кил!— дип кычкырды бригадир, чыгырыннан чыгып.— Нәрсә, колагыңа чүбек тыктыңмы әллә?!

— Була! Хәзер!— диде Белугин, җитез генә. Ул, кемнедер чакырган сыман, баш өстенә күтәрелгән кулын бутый-бутый, Димка артыннан йөгерде.

Төркемдәгеләр тынып калдылар. Шыңшу да, көлешү-сөйләшү дә ишетелмәс булды. Бригадир кеше ачулы чакта авыз күтәреп сөйләшеп тору ничектер гаеп эш шикелле тоелды.

## II

Төркем янына Ислам соңгы кеше булып килде. Бригадир аның якынаюын күреп алды да шундук аңа арты белән борылды һәм, кычкырынуыннан, сүгенүеннән туктап, ашыгып-кабаланып, тәмәке пошкыртырга тотынды. Ул Исламга әз генә дә игътибар итмәгән шикелле күренергә тырышты, ләкин ирексездән аның һәрбер сүзенә, һәрбер кыштырдавына колак салып тыңларга мәҗбүр булды.

— Нишләп торасыз монда? Әйдәгез, киттек,— диде Ислам иптәшләренә.

Аның кая китәргә чакыруын беркем дә аңламады. Барысы да, авызларына су капкандай, берни эндәшмичә, күңелсезләнеп бер урында басып тик тордылар.

Ислам никтер тынычсыз күренде, бүтәннәр алдында үз-үзен чак кына чит итеп тоя шикелле күренде. Үзенең тыныч түгеллеген сиздермәс өчен, ул юри кычкырып сөйләште, үз янындагы егетләрнең әле берсе белән, әле икенчесе белән сүз башлап карады, тәмәке кабызды, беркайчан да булмаганча, беренче булып үзе бүтәннәргә папирос тәкъдим итте. Аңа тыелып кына җавап кайтардылар, теләр-теләмәс кенә папиросына үрелделәр.

Ислам алай бик үк ялагайланып та тормады. Тәмәке кабызып бер-ике суыргач та, ялт-йолт каранды да, үзенә

кирәк кемнедер күреп, тиз генә урыныннан кузгалды. Кирәк кешесенең җиңелчә генә җиңеннән тотып, ул аны читкәрәк әйдәде, тавышын әкренәйтеп аңа нидер аңлатырга керешге. Бер-берсенә бик якын килеп, алар берике минут чамасы сөйләнгәләп тордылар.

Шуннан соң Ислам баһадир гәүдәле, ләкин юаш, куркак һәм беркатлырак кыяфәтле Һарун янына килде. Аны да ул үзе белән читкәрәк әйдәде һәм, дусларчарак булырга тырышып:

— Берәр егерме биш сум биреп тор әле, малай?— диде.

Һарун, икеләнеп, борынын тартып куйды. Исламга аның егерме биш сум түгел, егерме биш тиен дә бирәсе килмәде, чөнки Ислам моңарчы да аннан бер мәртәбә илле сум, икенче мәртәбә утыз сум алган иде. Кире кайтарып бирергә вәгъдә иткән вакыты инде күптән узган булса да, аның әле һаман үз бурычын түләгәне юк һәм, күрәсең, түләргә исәбе дә юк иде. Ләкин шул ук вакытта Һарунның кесәсендә хәзер акча бар иде. Аның кесәсендә акча барлыгын Ислам да бик яхшы белә — иртән куен кесәсен актарганда, ул аның кулында иллелекләр күреп калган иде. Шуңа күрә, акча юк, дип ялганларга һич тә мөмкин түгел, ә инде күрәләтә бирми калырга, баш тартырга... Моңа инде аның кыюлыгы җитмәде. Ислам белән бозылышу бер дә уен эш түгел иде.

— Йә, нәрсә куркасың? Бирермен, миндә югалмас!— диде Ислам.— Минем әле болай да сиңа бирәсем бар.

— Бирерсең син!— диде Һарун, мыгырданып.

— Ну, саран да соң син, малай!— диде Ислам, егетне оялтып.— Карун дип юкка гына әйтмиләр икән сиңа...

Тупас йөзле, тупас, эре гәүдәле егет, мондый шелтә сүзләренә хәтере калып, янә борынын тартып куйды. Ислам алдында аның һич тә «саран» булып, «карун» булып күренәсе килмәде. Ислам үпкәләп китеп бара күрмәсен дигән сыман, ул кабаланып куен кесәсен актарырга тотынды. Кесәсеннән, үч иткәндәй, баягы кебек тагын гел иллелекләр генә чыкты. Аның һәрбер кул хәрәкәтен түземсезләнеп, хәтта комсызланып күзәтеп торган Ислам, яшькелт кәгазьне күрде дә, шатланып:

— Иллесе дә ярый безгә... Курыкма!— диде.

— Ыы, ярамый ни!..— диде Һарун.

— Җылак!— диде Ислам, сабырлыгын җуеп. Тузынып ул шулай тиз генә китеп бармакчы булды, ләкин Һарун аның сырма итәгеннән тотып алды.

— Кем җылак?— диде ул, нахак сүзгә кәефе кырылып.

Аны-моны уйлап тормыйча, ул шыгырдап торган кәгазьне Исламга төртте.

— Бер җирдә зәмзәм суы бар, шаулама, үзеңә дә алып кайтырмын,— диде Ислам, акчаны алып учына йомгач, бераз йомшарырга кирәк табып.

Аның үзгәргән, ясалма тавышын ишетеп кинәт Һарунның эчен борып куйды. «Эх, юкка ычкындырдым!» — дип уйлады ул, кирәкмәгән юмартлык күрсәтүе өчен үз-үзен шелтәләп. Ләкин инде эш узган иде, никадәр үкенсәң дә, терсәкне тешләп булмаячак иде. Шуңа күрә, тагын да ахмаграк булып күренмәс өчен, ул бөтенесен эченә йотарга мәҗбүр булды һәм, акча ише юк-бар нәрсәгә әз генә дә исе китмәгән кеше сыман, гомумән, юмарт һәм киң күңелле кеше сыман, эре генә итеп:

— Иртәгә сабанга чыгу хөрмәтенә ярый ул...— диде.

— Менә, менә, шуның өчен дә тырышып йөргәннең эше инде,— диде Ислам.— Күп булмас, шулай да бераз булыр. Хәзер бит аны, үзең беләсең, җылап эзләсәң дә табып булмый.

Аның соңгы сүзләрен ничек итеп әйтүенә карап, Һарун монда ниндидер ялган барлыгын сизенде. Аның тагын эчен борып куйды. «Болай арыш боламыгы булып йөрсәң, ыштансыз калдырырлар монда»,— дип уйлады ул, пошынып, һәм моннан соң Исламга да, ышанычсыз күренгән бүтән кешеләргә дә бер тиен дә ычкындырмаска дип, гомумән, андый акча теләнүче шома егетләрдән читтәрәк йөрергә дип, үз-үзенә сүз биреп куйды.

Чирек сәгатьтән икенче бригада кешеләре янына өсте ябулы машина килеп туктады. Бу машина, «техник ярдәм» машинасы дип аталса да, хәзергә әле беркемгә бернинди техник ярдәм кирәкмәгәнгә, кеше ташучы автобус хезмәтен генә үти иде.

Бригадир «кирәк чакта әллә кайда йөргән» шоферны кыздырып алды да кабинага кереп утырды. Кызлар, егетләр, шаулашып, бер-берсен этеп-төртеп, арткы ишектән кузовка төялделәр.

— Булдымы?— дип кычкырды шофер, кабина ишегеннән башын тыгып.

— Булды, булды!— диештеләр эчтән. Машина, саман йортларны артта калдырып, дала ягына кузгалып китте.

## III

Ислам машинага утырмады, бүтәннәр кылбырдакка килгән арада, шыпырт кына өй артына сызды. Машина

күздән югалганчы, ул кузгалмыйча урынында басып торды.

Контора тирәсендә инде беркем дә калмаган иде. Якындагы промтовар кибете дә, ашханә дә ябык иде. Бары тик кайдадыр авыл уртасында гармун уйнаган тавыш ишетелә дә, кайдадыр тагын шул тирәдә хатын-кызлар кычкырыша иде, аннары Көктугайга яктылык бирә торган «электр станциясендә» дөп-дөп килеп бертуктаусыз двигатель эшләп утыра иде.

Ислам авыл читендәге тәбәнәк яр буенда утырган ялгыз йортка таба юнәлде. Бераздан ул, иске салам, тирес өеме яныннан үтеп, эче-тышы кызыл балчык белән сыланган читән стеналы бер абзар сыман куыш эченә килеп керде. Аның борынына шундук черегән тирес исе, мал исе килеп бәрелде. Ул чыраен сытты, борынын җыерды һәм аяк астындагы юеш, пычрак җиргә салынган ташларга, кирпеч ватыкларына гына басарга тырышып, алгарак узды, капшанып кирәкле ишекне тапты да тотканы тартты. Ул кыздырылган май исе, ит, суган исе бөркелеп торган җылы, якты бер бүлмәгә килеп керде.

Бүлмә бик бәләкәй иде. Ишектән кергәч тә уң якта, стена буенда, бер тимер карават, карават янында — ишек каршында — кечкенә өстәл тора иде. Өстәл турысында — шулай ук ишек каршында — ап-ак пәрдәсе төшерелгән тар гына бер тәрәзә, ә тәрәзә белән өстәлнең сул ягында, озын кирпеч муенын түшәмгә сузып, җыйнак кына, уенчыктай гына плитә-мич утыра иде.

Бүлмәдә Мәрьямнән башка бүтән беркем дә юк иде. Ул, янып-пешеп, кызу ягылган плитә өстендә табада нидер кыздырып азаплана иде. Бөркүлеккә чыдый алмыйча һәм, күрәсең, бүлмәдә үзе генә булудан файдаланып, ул өстендәге калын киемнәрен салып ташлаган һәм яшь, сылу тәненә сыланып торган җиңел генә, юка гына җәйге күлмәк киеп куйган иде.

Сызылып киткән чем-кара кашлы, эчке бер яктылык балкытып торган шомырт кара күзле һәм ак, нәфис битле бу яшь хатын үзенең яшьлеге белән генә түгел, табигый матурлыгы белән дә матур иде. Аның буе-сыны да, гәүдәсе дә, төсе-бите дә — бар җире дә камил, бар җире дә тулы һәм күркәм иде. Шуның өстенә, аның бөтен йөзендә-кыяфәтендә тыйнаклык, йомшаклык нуры һәм дөньяда үзенең бик бәхетле икәнлеген аңлау шатлыгы бөркелеп тора иде. Бары тик өске ирен читендә мыек сыман куерып күренгән кара таплар гына андагы бу гүзәллекне беркадәр киметә шикелле иде.

Ислам килеп кергәч, ул җиңелчә генә сискәнеп китте, ялтырап торган зур пычаклы кулын югары күтәреп, кул аркасы белән маңгай чәчләрен төзәткәләде дә, куаныч та, назлану да белдергән бер шелтә белән:

— Котым калмады... син икәнсең...— диде.

— Мин булса... ник пычак күтәрәсең?— дигән булды Ислам, күшеккән кулларын угалап.

Мәрьям кулындагы аршын буе пычакка карап алды да көлеп җибәрде, кабаланып яңадан плитәгә иелде һәм, бик җитез кыланып, табадагы котлетларны әйләндергәләргә тотынды.

— Беттеме?— диде ул, артына әйләнеп карамыйча гына.

— Көчкә!— диде Ислам.

Ул үзенә яны белән иелеп плитә янында булашкан Мәрьямнең юка күлмәк кигәч тагын да йомрыланып калган сылу гәүдәсенә, селкенгәләп торган күкрәкләренә, җитез кулларына карап торды. Кисәк кенә аның бөтен ихтыяры тоткарланып калган кебек булды. Мәрьямне ул юри шулай җиңелчә генә киенгән дип уйлады. Кайчандыр бик күптән ул аңа бу күлмәгеңне кисәң, син миңа ныграк ошыйсың, дигән иде. «Күрәсең, шуны исенә төшергәндер»,— диде ул үз-үзенә. Аның шундый хәйләсен сизгән өчен, ул үзендә аңа карата ачу тойгысы уятырга тырышты, ләкин үзеннән-үзе калыккан икенче бер теләк ачу тойгысына караганда көчлерәк булып чыкты. «Шәп тә соң, иблис токымы!»— дип уйлап алды ул.

— Уф, пештем! Чыдарлык түгел...— диде Мәрьям, билен турайтып.

Исламның үзенә таба карап торганлыгын һәм нинди уй белән караганлыгын ул сизенде, билгеле; битендәге алсулыгы куера төште, һәм кул аркасы белән ул, малайлар сыман, борын астын сөртеп куйды да, елмаеп:

— Нәрсә?— диде.

Шундый балкып-елмаеп торган килеш, шундый сылу кайнар килеш Ислам аны беренче мәртәбә күргән шикелле булды. Әле һаман ризасыз күренергә тырышып, авызын турсайтып, ул өстендәге кыска пальтосын салып ташлады, Мәрьямне кочагына алды, күкрәгенә кысты да, корышкан телен көчкә кыймылдатып:

— Ташла, синнән башка да пешәр әле,— диде.

— Тукта!.. Үтерәсең!— диде Мәрьям, ычкынмакчы булып.— Боз кебек... җылын әзрәк.

Ислам аның кулындагы пычакны алып өстәлгә ташлады.

— Җылыт... син җылыт,— диде ул, пышылдап.

## IV

— Әллә керми дә китте инде дип торам,— диде Мәрьям бераздан.— Нишләп бик озак?

— Суган саттык,— диде Ислам, теләр-теләмәс кенә.— Китәрсең кермичә! Әнә син нинди! Җылан кебек...

Мәрьям, үзенең җылан кебек булуына куанып, көлеп җибәрде, каты кара чәчле авыр башны йомшак куллары белән кочаклап алды да яратып күкрәгенә кысты.

— Нәрсә турында суган саттыгыз?— диде ул, башланган сүзне дәвам иттерергә теләп.

Исламның хәзер җыелыш турында да, анда сөйләнелгән сүзләр турында да һич тә исенә төшерәсе килмәде. Аның, гомумән, ниндидер дөнья мәшәкатьләре турында, менә шушы кичкенә, җылы, якты бүлмәгә, шушы тыныч рәхәт-ләззәткә кагылышы булмаган ниндидер бүтән нәрсә турында сөйлисе дә, уйлыйсы да килмәде. Шулай да аның үзен менә шулай шашып яраткан, үзе өчен үлеп торган яшь, чибәр хатынның — чынында үз хатынының — күңелен кырырга батырчылыгы җитмәде — кайчагында хәтта аның да күңеле йомшарган чаклары була торган иде.

— Саттык шунда...— диде ул, ялкау гына.— Иртәгә сөрергә чыгарга, диделәр... Моннан соң инде атнасыз да килеп булмас.

— Алайса, син бөтенләйгә китәсең... чынлап?.. Шул далага?..— диде Мәрьям, күңелсезләнгәндәй итеп.

— Китәргә туры килә... хәзергә...

Бу турыда алар арасында инде берничә мәртәбә сүз булып алган иде, ләкин сүз булганда да, алар моны ничектер читләтеп кенә узып китәләр, өстән-өстән генә сөйләшәләр иде һәм, бозылышудан, ике араның суынуыннан куркып, беркайчан да әле күңелләрендәген бөтенләе белән ачыктан-ачык әйтеп бетергәннәре юк иде.

Менә тагын сүз шуңа килеп төртелде — ике арадагы иң төп мәсьәләгә, иң четерекле, иң авыр мәсьәләгә килеп төртелде, һәм алар, бу сөйләшүдә сүзне ничегрәк, кайсы яктанрак башлап җибәрергә кирәклеге турында фикер йөрткән сыман, икесе дә бераз вакытка тынып калдылар.

— Мин синнән башка торалмыйм, торалмыйм!— диде Мәрьям, әчке бер каушау-кабалану белән.

Аның күңеле тулды, күзләренә яшь килде, ләкин Исламның елаганны җене сөймәгәнлеген бик яхшы белгәнгә күрә, күз яшьләрен ул шундук яшерергә тырышты һәм, үз-үзен көчләп, мәҗбүр итеп, ясалма бер елмаю белән елмаеп куйды.

— Әйт инде, нинди тормыш бу? Берең анда, берең монда... Караклар кебек...— диде ул тагын да беркадәр вакыттан соң.

— Бар, әнә котлетың яна!— диде Ислам, күңелсез сөйләшүне туктатырга исәпләп.

Яшь хатын ашарга әзерли башлады: кызу табаны шапылдатып өстәлгә китереп утыртты, икмәген кисте, анысын-монысын әзерләп куйды да, иелеп, карават астыннан тулы бер шешә чыгарды. Ул бер дә ашыкмады, кабаланмады, ләкин шул ук вакытта бик җитез эшләде. Әле генә була язып калган күңелсез сөйләшү турында ул әйтерсең бөтенләй онытты һәм, җилкәсен кашып, ясалма бер кырыслык белән, өстәл башында ашарга көтеп утырган Исламның һәр теләген үтәргә әзер булып, тар, кысан бүлмә эчендә әрле-бирле килде. Кинәт ул каш астыннан гына Исламның үзенә карап утырганлыгын күреп алды.

— Ник карыйсың шулай сөзеп?— диде ул.

— Яратканга карыймдыр,— дигән булды Ислам.

Ә бу минутта ул чыннан да аның нинди уңган, нинди ипле, нинди күркәм хатын булуы турында уйлады. Аның күңелендә бөтенләйгә шушында, шушы бәләкәй генә, җыйнак кына җылы бүлмәдә, шушы уңган, яшь, чибәр хатын янында торып калу теләге туды. Кайдадыр дала уртасында утырган пычрак, салкын вагон белән чагыштырганда, монда аңа оҗмах булып тоелды.

Мәрьям янында булганда, ул һәрвакыт диярлек шулай изрәп-йомшап китә иде. Аны ниндидер авырлык, ялкаулык биләп ала иде. Аның берни эшләмичә, кымшанмыйча шулай тын гына, тыныч кына утырасы, көннәр буе, сәгатьләр буе утырасы килә иде. Ләкин мондый ялкаулык, мондый авырлык минутларыннан соң анда нәрсәдәндер ризасыз булу тойгысы, үртәлү тойгысы калкып чыга иде. Аның үз-үзенә, дөньядагы барлык нәрсәгә ачуы килә, гел шундый җылы, тыныч бүлмәдә, ягымлы, кайгыртучан хатын янында гына яшәргә мөмкин булган бер вакытта каядыр читкә, далага китәргә кирәк булганы өчен, нидер эшләргә, нәрсә беләндер мәшәкатьләнергә кирәк булганы өчен ачуы килә иде.

Хәзер дә ул шундыйрак бернәрсә кичерде һәм тупас кына:

— Буламы инде анда?— диде.

— Булды!— диде Мәрьям.

## V

Исламга бүген һич тә аның белән ачуланышырга ярамый иде.

Мәрьямне үзе белән ияртеп алып килгәндә, ул аңа, хәзер без ир белән хатын кебек, диде, моннан соң безне беркем дә аера алмаячак, диде. Мәрьям берсүзсез ышанды. Барыннан да бигрәк ул үзенең мәхәббәтенә ышанды, үзенең яшьлегенә, матурлыгына ышанды. «Данияне Ислам ямьсез булганы өчен, явыз, холыксыз булганы өчен ташлады. Мин андый түгел. Мине ул беркайчан да ташлый алмаячак!» — дип уйлады ул, тәкәббер горурлык белән.

Шулай итеп, яңа җиргә алар икәүләп килделәр. Килгәч тә алар яңа тормыш башлап җибәрмәкче булдылар. Ләкин көтелгән яңа тормыш тиз генә башланып китмәде. Беренче көннән үк алар көтелмәгән каршылыкларга очрадылар.

Казанда чакта Мәрьям сатучы булып эшли иде. Монда да ул, бернинди мәшәкатьсез диярлек, Көктугайдагы азык-төлек кибетенә эшкә керде. Ул керде, әмма шофер Исламга машина булмады. Шоферлар болай да кирәгеннән артык булып чыкты, һәм Ислам, теләсә дә, теләмәсә дә, икенче бригадага тракторчы булып язылырга мәҗбүр булды. «Кайгырма, мин анда вакытлыча гына!— диде Ислам, яшь хатынны юатып.— Баш-күз алганчы кайда да булса эшләп торырга кирәк ләбаса!»

Шулай итеп, алар бергә торып китә алмадылар. Ислам гомерен үз бригадасында вагонда уздырды. Мәрьям исә өч-дүрт хатын-кыз белән бергәләп саман йорттагы бер бүлмәгә урнашты. Авыл шундый бәләкәй иде, андагы торак йортлар бармак белән генә санарлык иде, һәм барлык йортларны кечкенә бүлмәләргә бүлгәләп бетерсәң дә, иң кирәк кешеләргә дә аерым бүлмәләр җиткерерлек түгел иде. Ислам белән Мәрьям генә түгел, хәтта кайбер балалы, ирле-хатынлы кешеләр дә бер-берсеннән аерым яшәргә мәҗбүр иде.

Мәрьям тора торган йортның бер башында түбәсе җимерелеп беткән ташландык бер куыш бар иде. Бер бүлмәдә яшәүче кыз-хатыннар, үзара киңәштеләр дә, шул куышны рәткә китерергә кирәк дигән карарга килделәр. Дирекция моны хуп күрде, куышны төзәтү, торак бүлмә итеп җайлау эшендә булышу өчен ике-өч кеше бирде, кайбер кирәк-яраклар бирде. Эш дигәннән, монда кар, яңгыр үтмәсен өчен түшәмне, түбәне ныгытып ябасы бар иде дә, ачык тәрәзә куышларына тәрәзәләр куясы бар

иде. Аннары сылыйсы, агартасы, мичләр чыгартасы бар иде.

Ныклап тикшереп карагач, тагын шундый берничә ташландык куыш табылды. Дирекция аларын да торакка әйләндерү чарасын күрде, һәм менә шунда, «яңа йортлар» өлгергән вакытта Мәрьямгә дә кечкенә бер бүлмә эләкте.

«Болай булгач, Исламны далага җибәрү юк инде! Теләсә нинди эшкә керсен, шофер гына им түгел...»— диде ул үз-үзенә. Ләкин Ислам үзенчәрәк уйлады. «Шоферлыктан башка бернинди эшкә кермим!»— диде, кырт кисеп. Аннары әйтте, хәзер инде бригададан алай җиңел генә китеп тә булмаячак, диде, бригаданы таркатырга рөхсәт итмәячәкләр, яңа автомашиналар кайткач, инде алар үзләре үк чакыртып алачаклар, диде.

Мондый җавап ишетеп, Мәрьямнең кәефе кырылды. Шул чагында ул үзенең төзәтеп булмаслык хата ясаганлыгын аңлагандай булды. Ләкин ул хатаның нигезе нәрсәдә иде — Исламга ияреп үзенең монда килүендә идеме, әллә килгәч тә, бернигә карамыйча, бергә тору кирәклеген яклый алмавында идеме, әллә соң бүтәннәр кебек бригадаларга язылмыйча, Көктугайда сатучы булып урнашуында идеме — ул моны һич тә тиешенчә аңлап җитә алмады.

«Алайса, мин синең белән бригадага китәм!»— диде ул. «Прицепщик булыпмы?!— диде Ислам, мыскыл белән.— Синнән башка да җитәрлек анда тузан эчәргә атлыгып торучы патриоткалар! Синең урының — оҗмах. Моннан сиңа беркая кузгалырга ярамый. Җәй урталарындамы, көзгәме — барыбер яңа машиналар кайтачак. Аңынчы килеп-китеп йөрермен».

Бу сүзләрне ул боеручан төстә әйтте, шулай әйтергә хакы барлыгын сиздереп әйтте. Мәрьям каршы килмәде. Һәм алар, бертөрле дә булмыйча, килделе-киттеле яши бирделәр. Ислам көн дә аның янына килеп йөрде, ашап-эчеп йөрде, ләкин килгәндә ул бары кич кенә, караңгы төшкәч кенә килде һәм чит кеше алдында ничек тә үзенең Мәрьям белән нинди дә булса бәйләнеше барлыгын сиздермәскә тырышты. «Син хатын-кыз, бер исемең чыкса, тиз генә җыеп алалмассың»,— диде ул Мәрьямгә.

Хәер, мондый сүзне ул элегрәк тә әйткән иде. Мәрьям моңа баштарак әз генә дә игътибар итмәде һәм үзе дә: «Дөрес, шулай яхшырак булыр»,— дип уйлады. Исламны ул шундый нык яратты, аның сүзләренә шундый нык ышанды, аның хатын-кыз белән чуала торган га-

дәтен белүенә дә карамастан, әз генә дә аны көнләмәде һәм аның бригададагы тормышы белән дә, андагы дуслары-танышлары белән дә бөтенләй диярлек кызыксынмады.

Моңа кадәр шулай булды. Ләкин кичәгенәк ул үзенең балага узганлыгын белде. Ул әйтерсең ут белән су уртасында калды. Бер яктан, бу ят нәрсә аны үзенең яңалыгы белән, үзенең киләчәге белән куандырды. Балалы булу аның яшерен бер хыялы иде, һәм бу турыда белгәч тә, ул үзен кинәт кенә үзгәргән шикелле итеп тойды, ниндидер икенче кешегә, дөньяда үзеннән башка, үзенең мәхәббәтеннән башка берни белән кызыксынмаучы яшь, чибәр кыздан чын-чынлап хатын кешегә әверелгәндәй итеп тойды. Ул көне буе үзалдына елмаеп йөрде. Күңелен яңача җилкенергә, яңача тибрәнергә мәҗбүр иткән яңа, ят шатлык хисеннән кая басканын белми йөрде.

Ләкин, икенче яктан, бу аның котын алды. Әле генә аны куанырга, яшерен ләззәт хисе татырга мәҗбүр иткән нәрсә үзенең бөтен яңалыгы белән, бөтен серлелеге белән котын алды.

Аннан да бигрәк аны: ә ул нәрсә әйтер? дигән уй борчыды. Бит ул Даниянең кызын бер дә яратмаган!

Әйе, ул ни әйтер, ничек тәэсир итәр аңа бу яңалык?

Аны бүген көне буе шул уй газаплады. Шатлык-куаныч хисе, хәтта баштагы табигый курку, шомлану хисе дә юкка чыкты. Күңеленә шик еланы оялагач, ул бары тик начар, күңелсез нәрсә булуы ихтималын гына күз алдына китерде. «Әйтергәме, әйтмәскәме?»— диде ул, икеләнеп. Хәзер ул аны куркытудан курыкты, шул турыда әйткәч тә, аның йөзе кинәт үзгәреп, бозылып китүдән курыкты, әгәр аның йөзе үзгәргәнен күрсә, үзенең дә кинәт аннан күңеле сүрелүе мөмкинлегеннән курыкты — дөньяга үзе турында хәбәр биргән серле җан иясе аңа шундый кадерле булып, шундый мәгънәле, әһәмиятле булып тоелды, һәм ике арадагы сөю, яратышу берниндн үзгәрешсез, берниндн кимчелексез шулай дәвам итсен өчен, ул мөмкин кадәр тыелып торырга, мөмкин кадәр икенче кешене, дөресрәге, өченче кешене күңеле түрендә аннан яшереп саклап торырга мәҗбүр булды.

«Туктале, әйтим, булмаса!— диде ул кинәт, кыюланып.— Белсен үзенең ата икәнлеген...» Ләкин, гаҗәп хәл, кыюлыгы ничек тиз туса, шулай ук тиз арада юкка да чыкты. Ул берни әйтә алмады.

## VI

Үз гомерендә төрле хәлләрне башыннан кичергән Ислам аның әледән-әле үзгәреп торган кыяфәтенә игътибар итми калмады. «Нидер бар монда»,— дип уйлады ул. Яшь хатынның йөзенә, күз карашларына ул җентекләбрәк, сынабрак карады, аның ничек сөйләшүенә, ничегрәк көлүенә игътибар итте. Ул аның бөтен кыланышында, бөтен кыяфәтендә әйтелмәгән нindидер сер, бик зур, бик әһәмиятле сер барлыгын күрде. Бу сернең нинди сер булуын чамалау өчен аңа әллә ни баш ватарга да туры килмәде. Үзе белән мөнәсәбәткә кергән хатын-кызларда моңарчы да аңа шундый ук «серле» кыяфәтләрне күргәләргә туры килгәләгән иде.

«Саграк булырга кирәк моннан соң!»— диде ул, үз-үзенә киңәш иткән сыман. Аңа моннан бүген тыныч кына, тату гына чыгып китәргә кирәк иде, ләкин «сер» чишелә-нитә калса, ул үзенең һич кенә дә тыныч булып кала алмаячагын бик яхшы аңлады.

Мәрьям беренче булып сүз башламасын өчен, «серен» һаман саклап торсын өчен ул, кинәт кенә сүзчәнләнеп:

— Беләсеңме, җыелышта нәрсә турында суган саттылар...— диде.

— Нәрсә турында?— диде Мәрьям, кызыксынып.

— Тәртип юк, дисциплина юк, бригадир эчә...

— Ислам эчә...

— ...Ислам эчә...— диде Ислам, кабатлап.— Юк, Исламга хәзер эчәргә ярамый. Ислам хәзер эчмәскә тиеш!— диде ул аннары, беркадәр серле дә, тантаналы да итеп.

— Авызыңа бал да май!— диде Мәрьям.

— Бал да май!— диде Ислам.— Эчүдән мине берни дә биздерә алмаячак... әгәр үзем теләмәсәм. Телим икән — бүгеннән үк ташлыйм, и гомеремдә дә авызыма да алмаячакмын!

Соңгы сүзләрен ул бераз гына мактанып әйтте, ясалма бер күтәренкелек белән әйтте. Бу аңа ошап куйды, һәм аның тагын да Мәрьям алдында нәрсә белән дә булса мактанасы килде, ләкин хәзер генә мактанырлык бернәрсә дә исенә төшмәде..

— Ләкин ник ташларга аны?— диде ул кинәт, үзенчә бик тирән бер фәлсәфи инану белән.— Әйт, ник ташларга? Аракы да эчмәгәч, хатыннар да кочмагач...— диде ул, шаярткан булып һәм авыр кулын Мәрьямнең иңбашына салды,— ...ник кирәк бу дөнья?

— Хатыннар сезгә шул кочар өчен генә кирәк тә!— диде Мәрьям, үзе дә сизмәстән, әрнүле бер үпкә белән.

— Уйнап әйткәнне дә чынга алмале,— диде Ислам, коры гына.

Сөйләр сүзен оныткандай, беравык ул тынып утырды, аннары яңадан әүвәлге мәсьәләгә кайтты.

— Теттеләр безнең бригадирны!— диде.— Иртәгә сукага чыгарга кирәк, ә бездә бернәрсәнең рәте-чираты юк. Сабан-чәчкеч җитми, культиваторлар җыелып бетмәгән, тырмалар шулай ук... Таранны эттән алып эткә салдылар. И, беләсеңме... бигрәк тә тегене мин теттем!

— Син?! Эчкән өченме?

— Эчкән өчен дә, барысы өчен дә! Теттем генә тегене бөтен җыелыш алдында. Без, мин әйтәм, патриотлар, геройлар, фәлән-төгән... Без шулай да без болай, ләкин безгә тиешле шартлар тудырылмаган, мин әйтәм, без монда Таран сыман эчеп-исереп ятар өчен килмәдек, эшләр өчен килдек, мин әйтәм. Ләкин эшләү урынына безгә, телисеңме-теләмисеңме, эчеп-исереп йөрергә, талашырга, сугышырга туры килә, мин әйтәм, ни өчен дисәң, бригадиры шундый, үзе үрнәк күрсәтә, мин әйтәм, арбаның алды каян тәгәрәсә, арты да шуннан тәгәри, мин әйтәм. Андый «ура» сүзләргә ишәкләр ныграк колак салучан була. Тыңлыйлар авызларын ачып. Шуннан болар шапылдатып кул чаптылар...

— Ни өчен шулай шауладың инде?— диде Мәрьям, тынычсыз бер кызыксыну белән.

— Ни өченме?

Ислам сүзеннән бүленеп калды. Аның да күңеленә шул чакны: әйтергәме, әйтмәскәме? дигән бер сорау килде. Астыртын, мәкерле кешеләргә хас булганча, аның чын уйлары, чын теләк-омтылышлары бик тирәнгә, аска яшеренгән иде, өстә исә астагыларына бөтенләй капма-каршы булган икенче нәрсәләр, икенче теләк-омтылышлар яши иде, һәм мондый хәлгә ул шундый нык күнеккән иде — кайчагында өстәге шул ялган уй-фикерләренең, ялган теләк-омтылышларының ялган икәнлеген ул үзе дә онытып җибәрә иде. Ул бары хатын-кыз янында гына чишелеп китә ала иде, бары тик алар янында гына чын уй-теләкләрен өскә кузгатып чыгара ала иде.

Менә хәзер дә ул чак-чак кына чишелеп китмәде. «Юк, әйтмәскә!»— диде ул үз-үзенә, вакытында исенә килеп.

— Ни өченме?— диде ул, кабатлап.— Таран масая башлады. Аны бик узындырсаң, башыңа менеп атлануы бар. Бригадирлар арасында ул иң тәҗрибәле кеше, иген эшендә күп эшләгән кеше. Бүтәннәр барысы да диярлек шәһәрдән, заводтан. Директорны беләсең, ул үзе дә шундый. Элекке баш инженер. Таран белән Остапенко гына

МТС кешеләре. Шуңа күрә дә борынын чөя башлады. Нишләсәм дә миңа килешә, дип уйлый, сүз әйтә алмаслар, дип уйлый. Килешми торсын! Монда әле без дә бар!

— Юкка бәйләнәсең син шуларга,— диде Мәрьям, кыюсыз гына.— Масайса масаеп тик йөрсен. Аны инде син генә төзәтә алмассың.

Мондый үгет-нәсихәткә Ислам җавап биреп торуны кирәк тапмады. «Синңамы соң андый нәрсәләрне аңлау!» — дип уйлады ул үзалдына. Бу турыда бүтән сөйләшәсе килмәгәнлеген сиздереп, ул сәгатенә күз төшереп алды: бригадага киткән машина инде Көктугайга әйләнеп кайтырга тиеш иде.

— Кузгалырга вакыт,— диде ул, майлы авызын тастымалга сөртеп.

— Китәсеңмени?— диде Мәрьям, сискәнеп.

— Ярамый. Кайтмый калсаң, Таран дөньяның астын өскә китерер. Болай да әле җенләнә торгандыр. Мин бит актив! Актив кешегә соңлап йөрергә ярамый.

Мәрьям әйтерсең аның сүзләрен ишетмәде дә. Ул бары үз кайгысын гына кайгыртты һәм, йөрәк турысында чәнчүле бер хәлсезлек тойган хәлдә, пышылдап диярлек, әкрен генә:

— Кун бүгенгә?!— диде.

Кара каты чәчләре дулкынланып маңгаена төшеп торган, озын, төз гәүдәле, матур кылыч борынлы чибәр иргеткә, үз-үзеннән канәгать, тук, таза егеткә бу минутта ул шундый бер ялыну-ялвару белән, шундый моң-сагыш белән карады — мондый көчле, мондый кызганыч һәм омтылышлы күз карашына кеше түгел, хәтта таш та эрер иде.

Ислам елмайгандай итеп куйды, үпкәләгән баланы юаткан шикелле, өстәлгә яисә урындыкка-нигә кагылган шикелле, аның бөрешеп калган аркасына кагылып алды.

— Кайгырма!— диде ул, җиңелчә мыскыл тонына бирелеп.— Без — патриотлар. Без барысына да түзәргә тиешбез. Бездән партия һәм хөкүмәт шуны таләп итә.

— Сөйләшеп тә булмады... Күргән төсле дә булмадым,— диде Мәрьям, күз яшьләрен сөртеп.

— Карале, бигрәк җеби башладың әле син,— диде Ислам.— Әйтерсең гомерлеккә аерылышабыз! Ярамый, аңлыйсыңмы, ярамый! Бит иртәгә таңнан торып сукага чыгарга кирәк!

— Ә... әйе шул,— диде Мәрьям, чыннан да аның ни сөйләвен аңлап.— Ярамый, әлбәттә.

— Шулай булгач, ник борыныңны салындырдың? Ул

аны дәртсез генә кочып алды, үбеп алды. Мәрьям кинәт анының күкрәгенә башын куйды да чын-чынлап балавыз сыгарга тотынды. «Эх!» — диде Ислам күңеленнән. Җиңел генә ул аны читкә этәргәндәй итте, караваат астына күзе белән ымлап, ашыгып:

— Бармы әле анда? — диде.

— Бар, бар, — диде Мәрьям дә, ашыгып. — Ник сорап торасың — ал, күпме кирәк, шулкадәр ал.

Ул, аның алуын да көтмәстән, иелеп караваат астыннан киндер капчык белән капланган әрҗә тартып чыгарды. Әрҗәнең шакмаклы ояларында башлары сургычлы шешәләр ялтырап утыра иде. Ислам кыска пальтосын киде дә Мәрьям биргән шешәләрне кесәсенә салып куйды.

— Син бит әчмим дигәниең! — диде Мәрьям.

— Үземә түгел! — диде Ислам. — Җегетләргә. Аннары, Таранның авызын томаларга кирәк... артыграк тәнкыйтьләп ташладым мин аны бүген. Акчасын әле алмадым... ул турыда борчылма.

— Сөйләмә юкны! — диде Мәрьям. — Ничек оялмыйсың!

— Бетте, бетте! — диде Ислам, юатып. — Ялгыш кына...

## VII

Яшьләр җыелыштан кайтуга, дөге боткасы суынып, тәмсезләнеп беткән иде, солярка тәме килгән чәй дә шулай ук суынган, тәмсезләнгән иде.

Аларның кайчан кайтыры билгеле булмаса да, шулай да чамалап, һич югы, чәйне яңадан кайнатып җибәрергә мөмкин булган булыр иде, һәм бүре башы кимерердәй ачыгып кайткан кешеләрнең күңелләре күтәрелеп киткән булыр иде. Ләкин ялкау, пыштык Тәзкирә, бер мәртәбә пешергәч, әзерләгәч, шуның белән эшем бетте, дип уйлады. «Йөрмәсеннәр! Гел аларның гына көен көйләмәссең монда!» — диде ул, үзенең ялкаулыгын аклап.

Егетләр, кызлар кайтып ашарга сорый башлагач, өстәл такталарын, табак-савытларны шакылдата, дөбердәтә башлагач, ул, йөзендә әле һаман ахмакларча бер канәгатьләнү белән балкыган елмаюын тыя алмыйча, кабаланып, юргалап, Фәрханә апалар чатырыннан килеп чыкты. Килеп чыкты да, әлерәк кенә батыраюын онытып, шулай да эшлекле, шәфкатьле бер кыяфәттә, уйнаклап, кыланчыкланып, кухняга таба ашыкты. Баштарак ул озак торулары өчен кешеләрне бераз гына кыздырып та алырга уйлаган иде, ләкин түземсез, ачулы тавышлар көчәеп киткәч,

бу уеннан шундук кире кайтты һәм, эчтән тын алып, калай коштабакларга тизрәк ботка бүләргә кереште.

Бер-ике кеше ботка бүлдереп алгач та, өстәл тирәсендә әүвәлгедән дә катырак тавыш купты: никадәр ачыккан булмасыннар, беркемнең дә суык, тәмсез ботканы, Ходайның һәр бирмеш көнендә — иртән дә, көндез дә, кич тә кабатлана торган, күрү белән барлык аппетитларны юкка чыгара торган үзле, ашсыз ботканы ашыйсы килмәде.

Беренче булып усал телле, төпсәдәй кыска буйлы, төпсәдәй таза Илгиз кычкырды.

— Тәзкирә, боткаңны үзең аша! Чәй китер!— диде ул, тәлинкәсен өстәлнең бер башыннан икенче башына шудырып җибәреп.

Бүтәннәр дә ризасызлык белдереп кычкырдылар, сукрандылар, ашамыйча кашыкларын куйдылар, коштабакларын этеп җибәрделәр. Бары тик бер-ике кыз гына, кичке салкыннан бөрешеп, башларын калкытмыйча, теләртеләмәс кенә чәйнәүләрендә булдылар.

— Нәрсә, әллә суынган да?— дигән булды Тәзкирә, бу турыда әле яңа гына ишеткән сыман.

— Чәй китер, чәй!— дип кычкырдылар төрле яктан, бер-берсен уздырырга тырышып.

Тәзкирә, һаман шул ук ахмакларча бер елмаю белән елмайган булып, бер дә кирәкмәгәнгә тагын да ныграк кабаланырга тотынып, боткаларны җыеп алды да, корымланып беткән титаннан яшел кружкаларга чәй агыза башлады.

Илгиз туңган куллары белән кружканы тотып кына карады һәм, шундук тамак ярып:

— Тәзкирә, чәең суык!— дип кычкырып җибәрде.

Шау-шу көчәеп китте. Монысында инде кызлар да кушылды. Бригадада соңгы вакытларда еш кабатланганча, пешекче белән ашаучылар арасында кычкырыш башланды. Тәзкирәне сүктеләр, оялттылар, үчекләделәр, ләкин Тәзкирә аларны уйлап та бирмәде, кызарынып-бүртенеп, ашаучыларның үзләреннән яман шауларга тотынды.

Аның шаулавыннан беркемнең дә тамагы туймады, киресенчә, һәркемнең ачуы гына кабарды. Илгиз дулап бригадир вагонына кереп китте.

Аның анда ни дә булса кыра алуына беркем дә ышанмады, чөнки, беренчедән, кәефсез чагында Таран кеше сүзенә колак салмый иде, кем нинди йомыш белән килсә дә — хаклымы, хаксызмы анда — ул аның үзен тиргәп җибәрә иде. Икенчедән, Таран белән Тәзкирә арасында гыйшык-гашрәт мөнәсәбәтләре барлыгы бригадада теләсә

кемгә билгеле иде, һәм моңа кадәр аштан-судан, дөресрәге, пешекчедән күпме генә зарлансалар да, бригадирның әле беркайчан да Тәзкирәгә каты бәрелгәне юк иде.

Ләкин бүген искиткеч хәл булды. Таран, үз вагоныннан килеп чыкты да, дәһшәтле бер төс белән, аю кебек алпан-тилпән атлап, шау-шулы төркемгә юнәлде. Дөньяның астын өскә китерер дәрәҗәдә кызган-ярсыган яшьләр, ачулы, ач яшьләр, аның якынлашуын күрделәр дә, давыл алдыннан җиргә посып бетә торган кошлар сыман, менә хәзер бик зур тавыш-гауга буласын сизенеп, кисәк кенә тынып калдылар.

— Ни булды? Ник тавышланасыз?— диде Таран, тыелып кына.

— Менә ботка суык, Глеб Семеныч. Ач калдык,— диде Димка, алга чыгып.

Таран, бәйләнчек чебенне куып җибәргәндәй, уртәлеп Димкага кул селтәде, тавыш-гауганың ни дәрәҗәдә нигезле икәнлеген үзе тикшереп карарга теләп, казанның капкачын ачып ташлады: койка сыман булып каткан, утырган суык ботка бөтенләй диярлек башланмаган иде. Берни әйтмичә, ул казан капкачын ябып куйды, аннары титаннан чәй агызды, чәйне авызына китерде, эчеп карады да шундук җиргә түкте.

— Фу, шакшы!— диде.

Шуннан соң ул, дәһшәтле кыяфәтен әз генә дә үзгәртмичә, як-ягына каранып алды һәм, кулларын күкрәгенә кушырган көе, уңайсыз бер көлемсерәү белән көлемсерәп торган Тәзкирәне күрде.

— Ничә мәртәбә әйттем мин сиңа?!— диде Таран, әкрен генә, тышка ургылып чыгарга торган эчке бер ярсу белән.— Ничә мәртәбә сиңа шелтә ясалды? Хайванга да җылы аш ашаталар. Җыештыр, ичмасам, шул пычрак чәчләреңне! Хәзер үк җылыт ботканы, титанны түк, яңа чәй кайнат. Икенче мәртәбә солярка белән ут кабызасы булма! Тапкан җиңел эш... утын киптерәсе килми дә... ялкау!.. Иртәгә үзем тикшереп караячакмын. Кирәгем исә телең белән яла, теләсәң ничек бетер, әмма чәйдән бернинди тәмсез тәм килмәскә тиеш.

Кеше алдында Тараннан беркайчан да үзенә карата шундый хәтер калдыргыч сүзләр ишетмәгән һәм ишетермен дип башына да китереп карамаган Тәзкирә бер елмайды, бер бозылды, елардай булды, нидер аңлатырга, акланырга тырышып, аның сүзен бүлде, түбәнсенеп, кимсенеп «папаша» диде, «Глиб Симәнеч» диде, бригадир исә аны авыз да ачтырмады — беләбез! дигән шикелле, ачу белән кул гына селтәде.

Дөресен әйткәндә, аның күңелендә Тәзкирәгә карата бернинди ачу да юк иде, шулай ук ботканың тәмсез, суык булуында да, чәйнең соляркалы булуында да аның бернинди эше юк иде. Анда бөтенләй ул кайгы түгел иде. Аның, әлбәттә, барыннан да бигрәк, әле генә үзен җыелышта сүгеп кайтаруларына, аннан да яман, Исламның кабахәтлегенә җене котыра иде. Ләкин хәзер ул үзен һич тә шуның өчен ачуланам дип уйламады. Ул, бүтәннәр кебек үк, боткага, чәйгә, Тәзкирәгә ачуланам, дип уйлады һәм, кызган саен, моның шулай икәнлегенә ныграк ышана барды, ныграк ышана барган саен, күңелендә җыелып яткан ачуын-зәһәрен тагын да ярсыбрак түгәргә-сибәргә тотынды. Тора-бара ул кемне сүгүен дә онытты һәм бары тик тиз генә туктый алмаган өчен генә, сүгенүдән, кычкырудан туктаса, кешеләрнең әллә ни уйлаулары бар шикелле тоелган өчен генә сүгенде.

Ниһаять, аның тәмам кәефе кырылды, үз-үзенә, кешеләргә, кичке салкынга — бөтен нәрсәгә ачуы килде, һәм шул ук вакытта сүгенергә кинәт сүз дә бетте, теләге, ярсуы да бетте. Ул, тагын нәрсә генә әйтим икән дигән сыман, аптырап тынып торды да, сүзенең нәрсәдән башлануын исенә төшерде һәм ботканы тизрәк җылытып бирү кирәклеген тагын бер мәртәбә кабатлап, төкеренеп китеп барды.

— Сукин сыннар! Тотып ашарга гына торалар...— диде ул, кемгәдер ачынып.

Гарьлегеннән нишләргә белмәгән Тәзкирә, утка баскан песи кебек кабаланып-карсаланып, каяндыр коры утын алып килде, ташкүмер алып килде, күз ачып йомганчы казан астына ягып та җибәрде һәм кинәт кенә юашланып, юатып:

— Хәзер, хәзер,— диде.— Бераз гына сабыр итегез. Күпкә түзгәнне, әзгә түзәрсез. Сабыр иткән морадына җиткән. Менә хәзер... биш минуттан...

Ләкин инде беркемнең дә ботка җылынганын көтеп торасы килмәде. Барысы да күңелсез генә таралышып беттеләр.

## VIII

Бригадирның нилектән шулай кәефсез булуы болай да бик яхшы аңлашылып торса да, кинәт кенә аның Тәзкирәне пыр туздырып ташлавы шулай да гаҗәбрәк тоелды. Үзләренең чатырларына кайтып, өстәл тирәсен, тимер мич тирәсен каплап алгач та, егетләр, шаулашып, бер-берсен бүлеп, шул турыда гәп сатарга керешеп киттеләр.

— Исламның тәнкыйте үтемле булды. Менә, әйткән иде, диярсез — «папаша» иртәгәдән үк эчүен ташлаячак!— дип кычкырды Белугин, күрәзәлек итеп.

— Уйлап бирә ул синең тәнкыйтеңне! Аракысы беткән. Менә шуңа тилерә,— диде аңа каршы аз сүзле, кырыс холыклы Андронов.

— Юк, күсәкләр, белмисез — аракы өчен генә кеше тилерми. Ислам монда, Ислам!— диде Белугин, сүзен бирергә теләмичә.— Яшәсен Ислам!

— Яшәр әле, яшәр...— диде Андронов, үчекләшеп.— Бер-берсен чәйни башладылар... Яшәрләр әле, яшәрләр...

— Аракы да түгел, Ислам да түгел — Тәзкирә монда!.. Тәзкирә өчен ул!..— дип кычкырды бәләкәй Кәрам, яшелле-зәңгәрле тавышлары белән чәрелдәп.

— Нәрсә акырасың?— диде Белугин һәм өстәл янындагы такта утыргычка менеп баскан Кәрамны сырма итәгеннән тартып идәнгә төшерде.

— Кит моннан, селедка!— диде Кәрам, Белугинга кизәнеп.

— Дөрес әйтә ул, Тәзкирә өчен түгел микән?

— Әйе шул, бөтен бригада алдында хур итеп ташламасые,— диештеләр кайберәүләр.

Үзен яклаучылар табылуына күңеле үсеп киткән Кәрам этеп-төртеп яңадан уртага керде.

— Тәзкирә өчен, Тәзкирә өчен!— дип кычкырды ул тагын, тамак ярып.— Ислам ул астыртын. «Папаша»га ул болай гына дус булып йөри, ә үзе гел Тәзкирә ягын чамалыйдыр әле... ха-ха-ха!.. Шуңа да талашканнар алар.

Баш астына мендәре белән сырмасын бөкләп салган көе, күн итекле кыска аякларын карават башына сузып җибәреп, күкрәге өстенә куйган гармунында ниндидер көй чыгарырга азапланып яткан Илгиз уйнавыннан туктады һәм, гәүдәсен калкыта төшеп:

— Сөйләмәгез әле шул сары албастыны — исемен ишетсәм дә косасым килә башлый!— дип кычкырды.— Катыкка буяп ташласаң, эт яламас нәрсә... Ислам шуның белән пычранып тора ди...

Матур калын иренле, негрныкы сыман очлырак башлы һәм шулай ук негрныкы сыман кара-кучкыл битле, шат, таза чырайлы Мансур, шахмат уйнаган җиреннән бүленде дә:

— Исламның аның Көктугайда фатиры бар, ул шунда йөри. Үзем күрдем,— диде, ап-ак тигез тешләрен елтыратып һәм мин үз сүземне әйттем, калганын үзегез беләсез дигән бер кыяфәттә яңадан шахмат тактасына иелде.

— Аңа фатирлысы да бата, фатирсызы да,— диде Кәрам.

Үзе әйткән сүздән ул беренче булып үзе көләргә тотынды, бүтәннәр дә көлми микән дигәндәй, янындагы кешеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күтәрелеп карады, ләкин аннан беркем дә көлмәде. Белугин исә аның яңадан үзе каршысына килеп басуын күреп, тупас кына аны читкә этеп җибәрде.

Тавышка катнашмыйча, тын гына Мансур белән шахмат уйнап утырган Һарун, нидер исенә төшеп, кисәк кенә башын калкытты.

— Ислам анда эш белән йөри,— диде ул.— Анда кемдәдер аракы бар, ди...

— Шуның өчен синнән акча алдымы?— диде Андронов.

Аның тавышында мыскыллы көлемсерәү шикелле бернәрсә сизелеп китте.

— Ник? Алды шул!— диде Һарун, мактангандай итеп.

Барысы да шундук шахматчыларга әйләнеп карадылар.

— Ничә тәңкә алды, ничә тәңкә?— диде Илгиз, урыныннан торып.

— Илле...— диде Һарун.

— Миннән егерме биш...— диде Кәрам да, көлүеннән туктап.

— Миннән кырыкны!— диде Мансур, елмаеп, мондый нәрсә өчен әз генә дә кәефсезләнмичә.

— Көт, кызыл кар яугач бирер!— диде Илгиз, караватында үрле-кырлы килеп, әчен уа-уа.

— Юлда килгәндә ул миннән дә егерме биш сум алган иде,— диде Андронов.— Сорап карадым, бирмәде. Хәзер инде сорыйсы да килми.

— Мин беркайчан да кешегә акча бирмим. Үзем алсам алам, ләкин үзем бер тиен дә бирмим!— диде Белугин, масаеп.

## IX

Исламның алган акчасын кире кайтарып бирми торган гадәтен бик яхшы белсә дә һәм егетләр әйткән сүзләрнең күбесе хак-дөрес булса да, Һарун бу турыда әле яңа гына ишеткән шикелле булды. Аның кәефе кырылды. Позициясе яхшы булуына да карамастан, ул шахмат тактасындагы фигураларын сыпырып төшерде дә, ике күзе ут булган Мансурның берүзен калдырып, өстәл янынннан ук торып китте.

— Ни булды?!— диде Мансур, исе китеп.
— Син җиңдең. Уйныйсы килми,— диде Һарун, караңгы чырай белән.
Ислам белән ул үзен яхшы мөнәсәбәттә дип, дусларча мөнәсәбәттә дип исәпли иде, һәм аңа бер дә юктан шулкадәр акча чыгарып тоттыруы аянычлы булса да, шуның өчен генә аның белән бозылышырга һич тә исәбе юк иде. Бригада егетләре Ислам үзе юкта шулай шаркылдап көлсәләр дә, төрлечә аның гайбәтен сатсалар да, үзе барда алай бик үк кешни алмыйлар иде. Ә бит аларның күбесе шәһәрнекеләр, барысы да усаллар, чаялар! Һарун кебек авыл егетләре бригадада ике-өч кенә кеше иде, ләкин алар арасында аның бер генә якын дусты да, чынчынлап аркаланырлык, кирәк чакта сыенырлык бер генә кешесе дә юк иде. Шәһәрнекеләрне инде әйтеп торасы да юк — никадәр тырышсаң да, алар белән әлегә ничектер якынаеп, уртак тел табып булмый иде. Аңа исә бик якын бер сердәш кирәк иде, тәҗрибәле дә, кыю да бер иптәш кирәк иде.
Аңа Ислам белән генә түгел, теләсә нинди усал, бәйләнчек кеше белән дә саграк булырга, иптәшләрчәрәк булырга туры килә иде. Бригадада ул үзен шулай тотты да: беркемгә бәйләнмәде, бернигә катнашмады, нәрсә кушсалар, шуны тыңлады, нәрсә сөйләсәләр, шуңа ышанды һәм, баш иеп, барысына риза булып тик йөрде. Хәтта кайберәүләр үзенә хәтер калдыргыч сүзләр ычкындырганда да, хәтта берәр усалрагы кайчагында җәберләп ташлаганда да, ул үзен яклап берни эшләмәде: тавыш та чыгармады, кул да күтәрмәде — бөтенесен кичерә торды, гафу итә торды.
Акча мәсьәләсе аның иң нечкә җире иде. Акчаның җиңел генә кермәгәнлеген, аны табу өчен маңгай тиреңне сыпырып эшләргә кирәклеген ул инде күптән белә иде. Белү генә түгел, бу аның канына сеңгән иде, шуңа күрә ул бер дә юкка акча туздырырга, сораган бер кешегә «Аллаһ әкбәр» өчен иллешәрләп акча чыгарып бирергә күнекмәгән иде. Бүген тагын Ислам кармагына эләгү, җитмәсә, бөтенесе алдында көлкегә калу, аннан да бигрәк, биргән акчаларын кире кайтарып алу мөмкинлеге юклыгына төшенү аның барлык кыюлыгын, барлык усаллыгын кузгатып җибәрде.
— Бирми генә карасын!— диде ул, көлешкән кешеләргә җавап итеп.— Мин аның азау тешен каерып алам!
Чатырдагылар өчен бу үзенә күрә бер яңалык булды. Аның шулай кинәт кенә күтәрелеп бәрелүе егетләрне Таранның бүгенге тузынуыннан ким гаҗәпләндермәде.

Һарунның янау сүзләрен чынга алмыйча, барысы да: кайсы мыскыллап, кайсы үчекләп, кайсы болай гына көләргә керештеләр.

— Нәрсә кешнисез?!— дип кычкырды Һарун, тагын да яманрак итеп.

Шундый яман итеп кычкырды, үз тавышын ишетеп хәтта үзенең дә исе китте. Болай тамак ярып кычкыру аңа ошап куйды. Бу аңа моңарчы кайдадыр тирәндә яшеренеп яткан көч-гайрәт, кыюлык һәм усаллык шулай тышка бәреп чыга шикелле тоелды. Аның күңеленә шундук: «Кара, мин дә алардан ким кычкырмыйм икән!»— дигән бер куанычлы уй килде, һәм бер мәртәбә үз көчен тойгач, аның тагын кемне дә булса куркытасы-өркетәсе килде.

— Бу сүзеңне Ислам ишетә күрмәсен, күсәк,— диде кызыл йөзле Белугин.

Үзенең батырлыгын, кыюлыгын күрсәтергә мөмкинлек чыгуына сөенеп-куанып, үз-үзен белешмәстән, Һарун кинәт Белугинның изүеннән эләктереп алды.

— Бар, әйт! Бар! Курыкмыйм мин аннан! Курыкмыйм!— дип кычкырды ул, тыела алмыйча.

Белугин каушап калды, күзләрен челт-челт йомгалап, кире чигенә башлады.

— Тукта, тукта, күсәк, ни булды?!— диде ул, изүен ычкындырырга тырышып.

Чатыр эче тып-тын калды. Яшь, көчле Мансур шундук ызгышучылар янына килеп җитте; килеп җитте дә муен тамырлары бүртеп чыккан, кызарынган Һарунны кочаклап алды.

— Ташла! Бозма каныңны!— диде ул дусларча. Һарун белән Мансурның караваты янәшә генә иде, һәм, бергә тора башлаганнан бирле, алар ярыйсы гына дуслашып та өлгергәннәр иде.

— Ник акыра ул миңа, ник?!— диде Һарун, калтыранып.

— Ташла!..— диде Мансур.

— Менә... сыер дуласа, аттан яман була...— диде Илгиз, бөтенесенә ишеттерерлек итеп.

Аның бу мыскыллы сүзләре, тиктомалга кызып киткән егеткә салкын су сипкәндәй тәэсир итте. Аның күңелен шундук үзе эшләгән ахмаклык өчен уңайсызлану тойгысы, эх, юкка тавышландым! дигән бер үкенү тойгысы көйдереп алды. Ул, Мансурның сүзенә колак салган бер кыяфәттә, Белугинның изүен ычкындырды.

— Мужик психологиясе. Саранлык,— диде Белугин, үзен ирektә сизгәч.

— Тапканнар талашыр нәрсә! Икенче менә акыл булыр,— дип куйды Андронов.

Аңа каршы икенче почмактан кемдер нәрсәдер кычкырды, аларга тагын бүтәннәр җавап бирде, һәм бераздан сүз төп мәсьәләдән — Һарун белән Белугинның ызгышуы мәсьәләсеннән читләшеп, икенче нәрсәгә күчте.

Һарун аларны тыңламады да, аңламады да. Әле генә бөтен күңелен, бөтен ихтыярын биләп алган тиле гайрәт дулкыны шундук кире чигенде, башына менгән кайнар кан, битен, колакларын кыздырып, аска таба акты. Ул, иптәшләренә күтәрелеп карарга да кыймыйча, кузгалмыйча, кисәк кенә авырайган кулларын кая куярга урын тапмыйча, карават янында басып тик торды.

Үз-үзен чит санап, артык санап беркадәр вакыт ул нишләргә белми шулай катып торды-торды да ятарга әзерләнә башлады.

— Иртә бит әле, әйдә, тагын берәрне уйныйбыз,— диде Мансур, аның янына килеп.

— Юк, ятам инде,— диде Һарун.— Иртәгә иртүк торырга кирәк.

## X

Һарун бер дә йокысызлык авыруы белән азапланмый иде, башын мендәргә терәдеме,— колак төбендә кирәгем исә барабан кагып торсыннар!— шундук гырлап йокыга китә торган иде. Ләкин бүген, үч иткәндәй, әллә ни булды. Аның колак төбендә, билгеле, беркем дә барабан да кагып тормады, аны йоклатмаска теләп, бүтән төрле тавыш-ни дә чыгармады. Бары тик чатыр киндерен тарткалап-чайкалдырып тышта җил шаулады да, эчтә һаман егетләр шаулады. Иптәшләренең кычкырып сөйләшүләрен ишетмәс өчен ул колакларын, хәтта авызын-борынын томалап бетерде, сиртмәле караватын шыгырдатып әледән-әле әйләнгәләп ятты, каяндыр ишетеп калуы буенча, йөзгә, меңгә кадәр санады, тик шулай да тиз генә йокыга китә алмады.

Аның тәмам тынычлыгы югалды. Бер-берсен бүлдереп, күңеленә төрле уйлар килде, кайчандыр булып узган күренешләр, кайчандыр белгән-күргән кешеләр килде, кайчандыр әйтелгән өзек-өзек сүзләр ишетелеп китте. Ул үз-үзе белән, ниндидер кешеләр белән бәхәсләште, нидер аңларга, аңлатырга тырышты һәм шул ук вакытта әлеге уйлар-күренешләр газабыннан котылырга теләде. Беразга ул онытылып киткәндәй булды, ләкин күп тә үтмәде, үзенең яңадан уяу икәнлеген, яңадан йөрәгенең

куркып, сулкылдап типкәнлеген тойды, һәм аны яңадан буталчык, күңелсез уйлар өере биләп алды.

«Күрсәтермен мин сиңа мужикны!» — диде ул күңеленнән, Белугинга янап. Хәзер аңа бу сүзләр бик куркыныч булып, бик дәһшәтле булып тоелды. Шул ук сүзләрне әлерәк кенә — ызгышкан чакта Белугинның үзенә әйтергә башы җитмәвенә ул чын күңелдән үкенеп куйды һәм, икенче мәртәбә Белугин үзен шулай «мужик» дип хурласа, һичшиксез, аңа шулай дип җавап кайтарырга кирәк дигән фикерне күңеленә беркетеп куйды. Белугин белән дә, Илгиз, Андронов белән дә ул бик оста чәкәләште, алар нәрсә генә әйтсәләр дә, аларга каршы мең төрле җаваплар, дөрес, үткен җаваплар тапты һәм бүтән вакытта шундый ук оста, шундый ук шома телле була белмәвенә гаҗәпләнми булдыра алмады.

Ул ызгышның нидән башлануын, ничек булуын, кемнең нәрсә әйтүен, кемнең нинди кыяфәттә булуын — барысын да кат-кат күз алдыннан кичереп чыкты. Хәзерге ызгышуны шулай җентекләп тикшерә торгач, ул кинәт шундый ук икенче бер ызгыш-талашны исенә төшерде. Соңгы ызгышу шундук артка чигенде, төссезләнә, әһәмиятсезләнә барды. Күңеле белән ул еракка, туган якларына әйләнеп кайтты. Бер-бер артлы аның күз алдыннан таныш күренешләр үтте, таныш кешеләр, кырлар-басулар үтте. Тузып беткән яулыгы өстеннән мескен бүрек киеп куйган, һәрвакыт нидер эшләп, нидер кыланып йөргән тавыш-тынсыз әнисе күз алдына килде, һәм уй җепләре үзеннән-үзе... Хәлимәгә барып тоташты.

Хәлимә турында аның инде күптән уйлаганы юк иде һәм, дөресен әйткәндә, бик үк уйлыйсы да килми иде. Ләкин хәзерге минутта, рәнҗетелгән, кыерсытылган күңеле теләсә нинди якынлыкка, теләсә нинди теләктәшлеккә мохтаҗ бер минутта, Хәлимә турындагы уйлар аңа чит-ят җирдә адашып калган юлчыга еректан җемелдәп күренгән өмет уты шикелле булып тоелды.

Хәлимә белән ул ярты ел чамасы йөрде, бик яратып йөрде. Ләкин бу йөрү, бу ярату бер дә ул белгән, ул аңлаган бүтән йөрүләргә, бүтән яратуларга охшамады. Аның белән бәйләнеп киткәч тә, ул әйтерсең ниндидер диванага, ниндидер сырхау кешегә әйләнде.

Хәлимә, кычкырып мактарлык булмаса да, Ташкичүдә чибәр кызлардан санала иде, һәм шуңа күрә ярыйсы гына инде шомарып та өлгергән иде. Егетләр сайларга ул инде күптән остарып беткән иде. Чибәр кызның кирәгеннән артык чуар күңелле икәнлеген белеп алган авылдаш егетләре аның алдында бер дә эреп төшмиләр, киресенчә,

кайчагында читләтеп тә куйгалыйлар иде. Хәлимә исә күбрәк кунак егетләре белән, башка авылныкылар белән чуала иде.

Күрше авылдан Ташкичүгә эшкә килгән тракторчы Һарунга да беренче булып аның күзе төште. Очрашу-күрешүдән соң озак та үтмәде, шома кыз, күзен-башын уйнатып, тәмле телләнеп, елмаеп аның тирәсендә бөтерелә дә башлады.

Үз иптәшләре арасында да, Ташкичү егетләре арасында да Һарун кызлар белән йөрү мәсьәләсендә бик үк тәҗрибәсезләрдән исәпләнелми иде, үзләрендә дә, башка авылларда да аның болай гына «күреп йөргән» кызлары юк түгел иде. Кызлар белән ул гомумән бик тиз танышып китә ала һәм шулай ук тиз арада җиңел генә аерылыша да иде. Ләкин ул танышлар нишләптер аның күңелендә соңыннан искә төшәрлек бернинди җылы хис-тойгылар калдырмыйлар иде, һәм һәртөрле Кәшифәләр, Рәмзияләр, Гөлсинәләр-фәләннәр берничә ай, хәтта берничә көн үтү белән, барысы бергә буталып, шул арада онытылып та бетәләр иде.

Үзенә төбәп караган, үз тирәсендә сырпаланып йөргән Ташкичү чибәрен ул һич тә кире кагарга уйламады. Килеп эшли башлавына атна-ун көн тулмас борын, ул аның белән ныгытып торып танышып та китте, йөри дә, ярата да башлады. Башлавын башлады, ләкин Кәшифәләр, Рәмзияләрне, Гөлсинә-фәләннәрне ташлаган кебек тиз генә ташлый алмады. Әллә чынлап та, карчыклар әйтмешли, сихергә юлыкты, әллә шунда тагын бер-бер хәл булды.

Хәлимә аның өчен ярыйсы гына булып чыкты. Карышмады, ялындырмады һәм кичке уен вакытларында көнчел кызларга, егетләргә, күрәсезме, берегездән дә оялмыйм да, тартынмыйм да, дигән сыман, гел аның тирәсендә булды, иркәләнеп, тавышын үзгәртеп аңа, Һарун, диде, әбә-әү, кулың бигрәк каты, диде. Кичләрен уеннан соң озатып куюларга да, таңга кадәр бүрәнә өсләрендә серләшеп утыруга да, агач төпләрендә кочаклашып-үбешеп торуларга да — берсенә дә каршылык күрсәтмәде. «Яратам» сүзен дә әйтте, «җаным», «бәгырем»не дә әйтте.

Ләкин болай җиңел генә табылган бәхет тора-бара Һарунны туйдыра-җиләтә башлады. Хәлимә белән бергә булганда, еш кына аның эче пошты, сөйләр сүзе бетте, һәм кыз белән якынрак танышкан-белешкән саен, аңа аның ошамаган яклары күбрәк күренә башлады.

Нәкъ шул вакытта Ташкичүгә читтән Шамил дигән берәү кайтып төште. Бик күп акча белән кайтты, баеп, ереләнеп кайтты — аны кайдадыр Донбасс ягында шах-

тада эшли дип сөйлиләр иде. Үзенең ни дәрәҗәдә бай кайтуын күрсәтү өчен, ул бөтен туган-тумачасына, бөтен күрше-тирәләргә бүләкләр өләште. Бүләк дигәч тә, әллә ни искитәрлек нәрсә дә түгел инде — төрле сабындыр-мазардыр шунда, кулъяулык-фәлән, оек-оекбаш... Бүләк димәсәң, хәтере калыр! Авыл халкына җитә калды, Шамил әнә нинди баеп кайткан, әнә нинди мал белән кайткан, диделәр, ах та ух килеп сөйләделәр.

Шамил әйтерсең андый мактау сүзләренә генә дә канәгать булмады. Уллары кайтып төшүнең дүртенчеме, бишенчеме көнендә әти-әни, зурдан кубып, бөтен өй эчен тутырып кунак җыйды. Ташкичүдәге кардәш-ырулары да калмады, башка авылныкылар да калмады. Төп-төгәл бер атна буена Шамилләр йортында гармун кычкырткан, җырлаган тавышлар ишетелеп торды. Үз күзләре белән күргән кешеләр сөйләде, исерек Шамил, имеш, кесәсеннән бер төргәк акча чыгарган да, бөтенесе алдында: «Акчаны мин яфрак урынына да күрмим!»— дип мактанган һәм кулындагы шул бер төргәк акчасын идәнгә чәчеп җибәргән, имеш. Монысы инде ни дәрәҗәдә дөрестер — анысын беркем дә белмәде, әмма бер айдан соң шахтасына кайтып киткәндә, аның юллык акчасы да булмаган, атасына ике сарыкның берсен сатып моңа билетка акча җүнәтеп бирергә туры килгән. Әнисе соңыннан, зарланып, күршеләренә: «Бөлдереп китте, зимагур!»— дип ычкындырган, имеш.

Менә шул Шамил, коры куык, мактанчык Шамил, кунакларны озатып, башы-күзе айный башлагач та, чуар галстуклар таккан булып, көн саен клуб тирәсендә, кызкыркын тирәсендә күренә торган булып китте. Һәр көнне ул кызган баш белән чыкты, бөтенесе ишетсен дигән сыман, кеше арасында юри кычкырып сөйләште. Аннары ул бик бәйләнчек, бик былагай булып чыкты. Егетләрнең әле берсе белән, әле икенчесе белән тавыш-гауга чыгарды, шәһәрчә бик оста, бик яман сүгенде һәм аеруча «каны кызган» чакларда: «Бөтен авылыгызны кырып китәм! Себердә дә суд юк миңа. Мин — шахтер!»— дип күкрәк сукты.

Авыл кешеләре, шаккатып, акча нишләтә кешене, диделәр; аена ул өч-дүрт мең алып эшли икән, дүрәкәй, диделәр. Аннары әйттеләр, Шамил Ташкичүгә кыз алырга дип кайткан икән дә, бер дә үзенә тиң булырлык кыз тапмый икән, диделәр; хәзер инде ышандым, татар кызлары барысы да камыт аяклы, салам сыйраклы икән, кайтам да шахтыма, үземнең Мәрүсәмә өйләнәм, дип әйтеп әйтә икән, диделәр.

Белеп сөйләгәннәрдерме, белми сөйләгәннәрдерме — Һарун, билгеле, аларны тикшереп тормады. Кеше ни сөйләмәс, барысына да ышана китсәң! Ләкин, ни генә булмасын, әлеге шул Шамил — шалкан, он — талкан, Ташкичүгә кайтып, ямьле авылның ямен җибәреп, әчеписереп, акырып-бакырып йөри башлагач та, Хәлимә кинәт кенә үзгәрде дә куйды. Күз алдында үзгәрде, күрәләтә үзгәрде. Ялындыра-нитә башлады, үпкәли, киреләнә башлады.

Һарун баштарак моңа әллә ни игътибар да итмәде, кызларда була торган бер көйсезлек кенәдер, дип уйлады. Ләкин бу көйсезлек торган саен көчәя барды. Ә беркөнне кызый килешенгән вакытка, килешенгән урынга килми калды. Икенче көнне чыбыксыз телефон аша Һарун аның кунак егет тирәсендә чуалганлыгын белде.

Менә шунда аңлады инде ул аның ни өчен шулай көйсезләнгәнлеген! Күңләшүнең ни икәнлеген дә белмәгән егет күңеленә кинәт корт төште. Корт кына да төшмәде, давыл купты! Хәлимә хәзер аңа элеккегә караганда да кадерлерәк, кирәгрәк булып тоелды. Ул аны хәзер элеккегә караганда да ныграк ярата башлагандай булды. Дөресен әйткәндә, бу бер дә ярату да шикелле түгел иде. Бу ниндидер ачу-үртәлү, көнләшү һәм газап иде.

Шул көнне ул бертуктаусыз аның турында уйлады. Үз-үзенә ул, кич булгач та, смена беткәч тә, барып бөтен дөньясын җимерәм, диде, Шамилен дә юк итәм, үзен дә юк итәм — уты-ялкыны бер көнне булыр, диде. Кич булгач, ул чыннан да Хәлимәләр очына китте. Урамда аның энесен очратты да: «Апаң өйдәме?»— дип сорады. «Әле генә кич чыгып китте»,— диде малай. Һарун шундук кире борылды, гадәттә яшьләр уенга җыела торган җиргә — елга буена юнәлде. Хәлимә шунда иде, шулай ук шул тирәдә Шамилнең дә тавышы ишетелә иде. Бәхеткә каршы, берсе бер төркемдә, икенчесе икенче төркемдә иде.

Хәлимәнең ялгызын күреп, ул бик тиз тынычланды. «Кеше сүзе. Гайбәт»,— диде ул чыбыксыз телефон җиткергән сүзләр турында. Ул, берни булмаган кебек, уенга катнашты, гәп сатты, Хәлимә янына баргалап килде. Ләкин таралышыр вакыт җиткәч, ул Хәлимәнең юк булганлыгын шәйләп алды. Коелды да төште. Оятыннан җир тишегенә керердәй булып, карак шикелле сак кына атлап, ул бер-ике мәртәбә кызлар төркемен карап, әйләнеп чыкты. Тапмады, күрмәде һәм агарынып яңадан егетләр янына килде.

— Хәлимә үтүт! Шамил алып сызды!— диде кемдер, авызын ерып.

— Сызармын әле мин аны!— диде ул, үзалдына мыгырданып. Ләкин аның бу көчсез мыгырдануы янау булып та, гайрәтләнү булып та яңгырамады, киресенчә, бик мескен, бик кызганыч бер сыкрау булып ишетелде.

## XI

Икенче көнне тракторчылар җыелышып үзара шушы мәсьәләне тикшерделәр. «Әйдәгез, акылга утыртабыз шул сасы көзәнне!» — диде Расих. Шамил инде һәркемнең канына тоз салып өлгергән иде, тракторчылар да, авыл яшьләре дә аңа инде күптән теш кайрый башлаганнар иде. Һарунның кичәгенәк көлкегә калуы тракторчыларга бер этәргеч булды.

Иптәшләренең үзен якларга әзер торуларын күреп, Һарунның күңеле күтәрелеп китте. «Мин аның сөяген он итәм!» — диде ул, гайрәт орып. Ләкин шахтер егет алай бик тиз бирешә торганнардан түгел иде, ахрысы. Аның болай күкрәк тә киң иде, беләк тә таза иде, җитмәсә, яшькә дә Һарун ишеләрдән олырак иде.

Көн җилле, салкынча булганга, яшьләр ул көнне клубка җыелганнар иде. Ишегалдына килеп туктагач, Һарун:

— Сез керми торыгыз,— диде иптәшләренә.— Мин аны берүзем... Бер кешене өчәүләшеп тукмау егетлек түгел.

Ул бик кызган иде, гайрәтле иде. Аның хәзер Хәлимәне, һичшиксез, Шамил белән бергә күрәсе килде. Ул хәтта аларның бүген дә кичәге кебек аерым булуларыннан, яисә йә берсенең, йә икенчесенең килми калуыннан һәм шуның аркасында «акылга утырту»ның булмый калуы ихтималыннан курыкты.

Яшьләр патефон көенә яңача, шәһәрчә бию өйрәнеп яталар иде. Зал уртасында күпчелек кызлар иде, егетләр исә көлешеп, шаярышып читтә, стена буенда утыралар, шашка, домино уйныйлар иде. Ут бик якты янмаса да, биючеләрнең дә, биемәүчеләрнең дә йөзләрен бик яхшы аерып була иде.

Ләкин Һарун берни күрмәде. Аның күз алдын әйтерсең, нindидер томан, нindидер тузан пәрдәсе каплап алды. Ул түргә узып тормады, ишек төбендә малай-шалайлар арасында гына торып калды һәм томан эчендә, тузан эчендә кайнашкан кешеләр арасында бары тик аларны гына эзләде. Бер урында кузгалмыйча бераз басып торгач, томан пәрдәсе ачыла төшкәндәй булды. Ул әкренләп-әкренләп күрә башлады, һәм аның уттай янган очлы күзләре кызлар янында кайнашкан Шамилне эзләп тапты.

Менә ул, кызлар арасында буталуыннан туктап, ишеккә таба, патефонлы өстәл янына килде; килде дә, әйбәт кенә уйнаган пластинканы алып, икенчене куймакчы булды. Музыка өзелде, бию тукталды. Кызлар, ризасызлык белдереп, мыгырданырга тотындылар.

— Булды, булды... Готово! Пошли. Фокстрот! Трам да ля!..— диде Шамил, яңадан төркем арасына кереп.

Патефон икенче төрле көйгә гыжылдый башлады. Ләкин бию тиз генә җайланып китмәде. Кайберәүләр өстәл янында утырган малайга, ачуланып: «Вальсны куй! Вальсны!»— дип кычкырдылар. Малай «вальс»ны куймады, һәм кылтык шахтер, беркемнең дә сүзен колагына алмыйча, бары тик үзен генә, үзенең яхшы биюче икәнлеген генә күрсәтергә тырышып, нindидер кыз белән пыр туздырып биюендә булды.

Шулай кызып биегәндә ул, әллә урындыкка, әллә берәрсенең аягына абынып, кинәт чайкалып китте. Кызы ычкынды, үзе кемнеңдер өстенә барып капланды. Малай-шалай көләргә тотынды, кызлар исә тагын да яманрак тавыш күтәрделәр. Шамил, ахрысы, үзенә аяк чалдылар дип уйлады — торды да кул астына эләккән беренче кешегә салып та җибәрде. Китте ыгы-зыгы, китте тавыш — бөтен зал аягүрә басты, бөтен зал ду купты.

Ачулы булса да, тиктомалга барып ябышырга Һарун кыймыйчарак торган иде. Хәзер аны әйтерсең кемдер арттан төртеп җибәрде. Гаҗәеп бер җитезлек белән, җиңеллек белән ул, кешеләрне ырып-ерып, уртага барып керде; керде дә ярсып-шатланып, шәп егетнең изүеннән, чуар галстугыннан тотып та алды. Аның инде баядан бирле шул мактанчык галстукка күзе кызып тора иде.

— Әйдәле монда, әйдә!— диде ул, йомшак изү белән йомшак галстукны бергә йомарлап.

— Бир кирәген!

— Сөләгәй! Хулиган!

— Алып чыгыгыз шуны!— диештеләр төрле яктан, аңа көч биреп.

Егетләр, дәррәү кубып, «сөләгәй»нең ике яктан ике кулын тотып алдылар, шаулашып-тарткалашып аны ишеккә таба өстерәделәр.

## XII

Ә соңыннан...

Хәер, соңыннан да әллә ни булмады. Болай үзе бик батыр булып, сугыш чукмары булып йөргән Шамил, егетләр кулына эләккәч, шиңде дә калды. Һарунга кар-

шы ул кыеп бер мәртәбә кул да күтәрә алмады — әллә галстугы муенын буып тыны бетте, әллә чынлап та курка калды.

— Буасың ич... җибәр!— диде ул, өзелеп чыга язган галстугына тотынып.

— Бу, бу! Буып үтер шуны!— диде шунда кемдер. Галстукны ычкындыргач, Шамил батыраеп китте.

— Килмешәк!— диде ул, исен җыеп, мыш-мыш тын алып.— Әләгерсең әле бер... Берүзең генә булсаң, алай әтәчләнмәс идең...

Яшьләр алдында үзенең исемен-дәрәҗәсен саклап калу өчен, Һарунга арыслandaй ыргылырга тиеш булган бервакытта, үзенең батырлыгын тел белән түгел, кул белән күрсәтергә мөмкин булган бервакытта аның шулай янап маташуы бик тә көлке тоелды.

— Әйдә соң, әйдә!— диде Һарун.

Ләкин егетләр койрык булып арттан тагылдылар, һәм алар, бер-берсеннән аерыла алмыйча, бер-берсенә янап, әйткәләшеп шактый урам таптадылар. Иң ахырда авыл яшьләре Шамилне куалап өенә кертеп җибәрделәр. Шушы ызгыштан соң ул беркайчан да кичке уенга чыгарга батырчылык итмәде.

Һарун исә яшьләр күзе алдында кинәт кенә үсте дә китте. Булдыргансың, диделәр, шулай кирәк аңа, диделәр, ныграк төшерәсең калган, Ташкичүгә бүтән кайтмаслык итеп, диделәр...

Тик бер генә кеше — Хәлимә генә аның бу эшен хуп күрмәде. Шамилне түгел, бәлки, Һарунны ул «сугыш чукмары» дип, «яшь әтәч» дип атады.

Шамилне куркытканнар дип, Хәлимә, әлбәттә, өендә бикләнеп ятмады, элеккечә көн саен елга буен, клуб сукмагын таптавында булды. Ләкин шул ук вакытта ул Һарунга да тиз генә якынаеп китмәде: кеше алдында хәтер калдыргыч саксызлык күрсәтте, хәтер калдыргыч сүзләр әйтте һәм кич уеннан кайткан чакта юри гел алдан йөгерде.

Аның шулай качып йөрүенә Һарунның җен ачулары чыкты. Торган саен аның тынычлыгы югала барды. Аны яңадан газап, көнләшү һәм һәртөрле күңелсез уйлар биләп алды. Ул хәзер үзенең аннан җиңел генә котыла алмаячагын аңлады, нәрсәсе беләндер аңа бик нык береккән булуын аңлады.

Әйе, хәзер инде соң иде, ул тәмам буталган, чуалган иде, тәмам «гыйшык баткагына» кереп баткан иде: саескан кебек, койрыгын алса, борыны ябыша, борынын алса, койрыгы ябыша иде. Аңа хәзер, һичшиксез, эшне ныгы-

тып җайлап җибәрергә кирәк иде, шунсыз аңа дөньяда һичнинди тынычлык табып булмаячак иде. Бер дә булмаса, башын алып каядыр олагырга, югалырга кирәк иде. Ул хәзер курка башлады. Шамилдән, Хәлимәдән курка башлады. Шамил аңа Хәлимәне алып китәр шикелле булып, Хәлимә исә берсүзсез риза булыр шикелле булып тоелды.

Ә беркөнне аның күңеленә бер бик шәп уй килде, унҗиде-унсигез яшьлек егетләр күңеленә генә килергә мөмкин булган бер кыю уй килде. «Өйләнәм!» диде ул үз-үзенә.

Хәлимә белән алар инде биш-алты көн күрешмәгәннәр иде. Көпә-көндез ул аның эшләгән җиренә барды. Хәлимә кистереп кенә бер җавап та бирмәде. Һарун белән күрешмәгән өч көн эчендә ул инде Шамил белән якынаеп та өлгергән иде.

— Җәй көне кем өйләнә?! Көтик көзгә кадәр, аннан күз күрер,— диде кыз, җиңел генә, тыныч кына.

Һарун риза булды. Риза булу гына түгел, мондый җылы сүзгә, мондый татулык сүзенә аның яңадан күңеле канатланып китте.

Берничә көннән Шамил китеп барды, һәм ул китеп күп тә узмады, Хәлимә элекке хәленә кайтты. «Кеше сүзенә карап чак-чак кына эшне харап итмәдем»,— дип уйлады егет, сөенеп.

## XIII

Менә көткән вакыт та җитте. Кызу урак өсте башланды. Озакламый урагы да бетте, игеннәр дә җыелып алынды, басулар да бушап калды. Тракторлар туңга сөрә башладылар, ә бераздан җирне бөтенләй туңдырып, катырып җибәрде. Һарун җәйне бик тырышып эшләде, ярыйсы гына ашлык алды. Көннәрдән бер көнне ул әнисенә үзенең өйләнергә исәбе барлыгын белдерде. Әнисе каршы килмәде, өйләнсәң өйләнерсең инде, үзең беләсең, диде; минем өчен кем дә ярый, кулын кушырып, үзүзен кочаклап утыра торганы гына булмасын, диде.

Эшләр шулай җайланып кына барганда, ләгънәт орган Озын Колак Һарунга Хәлимә Шамил белән хат алыша икән, Шамил киләсе җәйгә кайтып алып китәргә итә икән дигән имеш-мимешләр ишеттерде. Үзенчә туйга әзерләнеп яткан җиреннән Һарун шундук Ташкичүгә чапты. «Ни сөйлисең, кем әйтте аны?»— диде Хәлимә, үпкәләп. Ләкин Һарун инде ул кадәр үк беркатлы түгел иде. Ул монда чыннан да нидер барлыгын сизенеп алды.

Ул туйны ашыктырырга булды. Ул хәтта туйга әзерләнеп җиткәнне дә көтмәскә булды. Хәлимәне ул хәзер үк үзләренә алып китмәкче булды. Булуын булды, тик... Хәлимә генә бармады.

Бармады һәм үз-үзен аклар өчен әллә нинди сәбәпләр китереп чыгарды. Без әле яшь, диде; син барыбер җәрингә армиягә китәсең, мин берүзем нишләрмен монда, диде... Аннары тагын, баштагы сүзләрен онытып, бөтенләй икенче төрле сүзләр сөйли башлады. Синең әниеңне бер дә мактамыйлар, килешә алырмын микән мин аның белән, диде. Тагын әйтте, мин сезнең өйне беләм, диде, балчык белән сылаган, салам белән терәгән, көчәнеп бер эттең исә, шундук җимерелергә тора, диде, анда ничек торырбыз, диде.

— Тел тидермә минем әнигә! Сиңа әле җырак аңа җитәргә!— диде Һарун, әнисе өчен хәтере калудан бигрәк үзе өчен хәтере калып.

Шулай ук аның үз йортларын да мыскыллатып торасы килмәде.

— Әти салган йорт ул, беләсең килсә!— диде.— Үз кулы белән салган, хәләл көчен чыгарып салган, синең этиең шикелле колхоз фермасын талап баемаган.

Кинәт Хәлимә дә кызып китте. Аның да үз этисенә тел тидерәсе килмәде, һәм аерылышканда алар бер-берсенә дошман булып аерылыштылар.

— Ни булды? Нишләп чыраең сытылды?— диде әнисе, Һарун кайткач.

— Юк, берни булмады...— диде Һарун. Нидер сизенеп алган әнисе, беркадәр мыскыл катыш көлемсерәү белән:

— Килен нишләп ята? Хәле ничек?— диде.

— Берничек тә түгел!— диде Һарун, үртәлеп.

— Һай Алла, булмаса, тапкансың кайгырыр нәрсә!— диде әнисе, әз генә дә исе китмичә.— Кирәк булса, үзе йөгереп килер әле — хәзер кызлар шундый... Хәерле булсын, бер дә күңел тартмаганые аны. Җилсез агач шауламый: җүнле нәрсә түгел дигәннәрие аны, дөрес икән!

Хәлимәне әнисе тиргәгәч, Һарунга җиңелрәк булып киткәндәй булды. «Дөрес, җүнсез нәрсә!»— диде ул үзүзенә, ләкин күңеле шундук каршы килде: дөрес түгел, әйбәт кыз ул, диде.

Икенче көнне аның Хәлимә турындагы фикере сизелеп үк үзгәрә башлады. Ул аның да бөтенләй үк хаксыз түгеллеген аңлагандай булды. Әнисе алай берничек тә хурларлык булмаса да, өйләре аларның чыннан да иске иде, тәбәнәк иде, чыннан да «балчык белән сылаган, са-

лам белән терәгән» иде. Ул хәтта бөтен авылда иң иске, иң начар йорт иде.

Ләкин каян аласың хәзер генә яхшы, яңа йортны? Шушы йортта Һарунның ике абыйсы, бер апасы туган, Һарун үзе туган, ике сеңелесе туды... Аларның бөтен гомере диярлек шушы иске, черек йортта, тәбәнәк йортта узган, һәм менә шул карт әни, ни өчендер Хәлимә яратмаган ялгыз әни, аларны күкрәк сөтен имезеп үстергән, шушы йортта карап, тәрбияләп үстергән. Әллә ул аны аңламыймы? Әтисе дә, олы абыйсы да сугышта үлеп калган, бөтен михнәт, бөтен кайгы-хәсрәт аның әнисе өстенә, бала-чагалар өстенә һәм менә шул эчтән-тыштан ямалып беткән бичара йорт өстенә төшкән. Балалар ел саен үскәннәр, ел саен аларга көч-куәт кергән, аң кергән — хәзер инде Һарунның башы ул белгән малай вакыттагыча өстәл тактасына гына түгел, түшәмгә тия! Әйе, алар үстеләр... Тик менә шул йорт кына яңармаган да, эшчән, тырыш һәм уңган әниләре генә үсмәгән, аңа гына көч-куәт өстәлмәгән. Алар инде көннән-көн картаялар, көннән-көн җиргә чүгәләр. Каян гына табасың хәзер яхшы йорт та яхшы яшь әни?!

Хәер, картайган әнине яшәртеп булмаса да, искергән йортны яңартып була.

Ләкин ничек итеп, нәрсә белән?

Бу бик авыр мәсьәлә иде, бу һич тә хәл итеп булмастай мәсьәлә иде.

Әйе, ничек итеп, нәрсә белән? Каян акча алырга? Ашлык сатаргамы?

Ул чакта дүртәүләшеп ач калырга кирәк. Бит бөтенесе аның эшләгәненә карап тора! Юк, аның кулыннан килә торган эш түгел бу. Башкарса моны абыйсы Зиннур гына башкара алачак... армиядән кайткач. Ләкин аңа да бит барыбер акча кирәк булачак!

## XIV

Һарунның тәмам башы катты. Аның тиз арада йортлы да буласы килде, кәләшле дә буласы килде. «Яңа, яхшы йорт булганда, Хәлимә карышып та тормас иде»,— дип уйлады ул, балаларча фикер йөртеп. Ул үзенең бик нык оятка калганлыгын күрде, чөнки аның өйләнергә ниятләнеп йөрүе турындагы хәбәр инде Ташкичүгә дә, Уракчыга да таралып өлгергән иде. Аңа хәзер теләсә дә, теләмәсә дә өйләнергә кирәк иде, бары тик ялганчы булып, булдыксыз, җебегән булып калмас өчен генә булса да өйләнергә кирәк иде. Хәлимә белән ачуланышып кына

котыла алмый иде ул бу бәладән. Ләкин өйләнгәндә дә яшь киленне шушы мунчадай йортка түгел, бәлки, биек, иркен яңа йортка алып килергә кирәк иде. Бит әле авыл халкы алдында гына түгел, Хәлимә алдында да үзеңнең Һарун икәнлегеңне, тракторчы Һарун икәнлегеңне күрсәтергә кирәк иде!

Ул төрлечә уйлап карады, әмма, ничек кенә уйласа да, уеның очына чыга алмады. Ул беркем белән дә киңәш итмәде, ул бары үзе генә кайгырды. Вакыт исә узды да узды. Ул арада кыш та җитте.

Ә берничә айдан бөтен ил яшьләрен аякка бастырган яңа кузгалыш башланды. Нindидер чирәм җирләр, яңа җирләр турында сүз китте. Бу сүзләр көн саен, сәгать саен кабатлана торды, телдән телгә күчә торды. Яшь энтузиастлар төялгән беренче эшелоннар кул тимичә, сөрелмичә яткан дала якларына — Казакъстан, Алтай якларына юл тоттылар. Сугышка китүче солдатларны озаткан кебек, төрле шәһәрләрдән ул яшьләрне зур хөрмәтләр белән, изге теләкләр белән озатып калдылар. Аларның һәрбер эшен, һәрбер адымын ерак-ераклардан күзәтеп тордылар, алар турында көн саен газеталарга яза тордылар, сәгать саен радиодан сөйли тордылар.

Һарунның ул чирәм җирләр турында моңарчы да ишеткәне бар иде. Ул турыда чынында былтыр ук сөйли башлаганнар иде. Газетада ул бер тракторчы бригадирның җәй буена егерме центнер бодай, ун мең сум акча эшләп алуы турында укыган иде, һәм ул чакта ук хәбәрне ул үзе өчен түгел, бәлки, нindидер бүтән кешеләр өчен, акыллырак, башлырак кешеләр өчен язылгандыр, дип уйлаган иде, чөнки ул аңа никтер ялгандыр шикелле тоелган иде.

Ул яңадан шуны исенә төшерде. Хәзер аңа анда язылган сүзләр һич тә ялган булып тоелмады. Аның кинәт дәрте кузгалып куйды. «Китәргә кирәк миңа да шул чирәм җирләргә!» — диде ул үз-үзенә. Әгәр анда китсә, беренчедән, күңелен һаман тынычсызлап торган, чынчынлап агулап торган Хәлимәдән, ягъни гыйшык газабыннан котылып торырга була; икенчедән, анда китеп ул бер ел эчендә өйлек акча эшли ала. «Йә өйләнәм, өйле булам, йә бөтенләй шунда торып калам!» — диде ул үзүзенә, ант иткән сыман. Әнисе, сеңелләре өчен кышлык азык бар иде, сыерга печән, ягарга утын әзер иде. Әгәр монда алай-болай авырга килә башласа, тегеннән торып та ярдәм итәргә мөмкин булачак, һәм ул тәвәккәлләргә булды.

Әнисе дулап-тузынып алды. Бар, даласына булмагае,

аннан арысына кит, диде. Шулай да артык киреләнеп тә тормады: ул инде болай да өйдәге хуҗалыкны берүзе алып бара иде, ул инде болай да бөтенесенә берүзе җигелергә күнеккән иде. Аннары, аның бит әле ике кызы үз янында кала. Аннары, улы әйткән сүзләр чынга чыгар булса... нигә ул кадәр карышып торырга?!

Ләкин МТС директоры аны ишетергә дә теләмәде — Һарун МТСта яхшы кадрлардан исәпләнелә иде. Хәер, райком шалтыраткач, директор да берни эшли алмады.

Шулай итеп, ул теләгенә иреште. Иртыш буенда төзелгән «Татарстан» совхозының беренче чатырларын коручыларның берсе ул булды; ялан-япа кыр уртасында, Көктугай читендә, үзе корган чатырда, суыкта-салкында чишенмичә беренче төн уздыручыларның да берсе ул булды, һәм менә монда, далада, беренче буразна салучыларның да берсе ул булачак...

Әйе, менә ул далада, Казакъстанда... чирәм җирләрдә... Килеп бер-ике атна торгач та, авылга мең ярым акча салды, тотмагыз, кассага салыгыз, диде, эшләгәч тагын җибәрермен, диде. Шул ук көнне Хәлимәгә дә хат салды, үзләренең ничек итеп юлда килүләре турында, үзенә бик кызык булып, сәер булып күренгән нәрсәләр турында язды. Аннары язды, кара аны, диде, ятлар белән чуалма, көзгә мин барыбер кайтам, диде.

Хат язганга инде ай тулды, җавап әле һаман юк. Ә бәлки, бөтенләй булмас та, бәлки Хәлимә инде аны онытып та бетергәндер...

Тышта һаман җил шаулый, китереп-китереп чатыр киндеренә суга, усаллана. Эчтә исә әледән-әле сөйләшкән тавышлар ишетелеп куя. Күзләргә һаман йокы керми дә керми...

Шулай да әкренләп аның зиһене томалана, уй-фикерләре чуала башлады. Аның күңеленә соңгы мәртәбә йоклыйм, ахры, дигән бер уй килде.

Шул ук вакытта аның колак төбендә генә аерым ачык булып икенче бер тавыш ишетелде. Бу таныш, кискен тавыш Һарунны кинәт өтеп, чеметеп алгандай булды.

Аның йөрәге кызурак эшләргә тотынды. Йокы качты, бер-берсенә берегә язган күз кабаклары ачылып китте. Чатырга Ислам килеп кергән иде.

## XV

Ислам бригадага кайтып җиткәндә, сәгать унбер тулып килә иде. Вагоннарга якынлашкач та, ул иң элек Таран тәрәзәсенә күз ташлады. Бригадир әле йокламаган иде.

Димка бүлмәдә юк, ишектә йозак эленеп тора иде. Ислам йозакны ипләп кенә ачты да песи кебек сак кына атлап бүлмәгә керде, кечкенә өстәлдәге лампага ут кабызды, аннары, шулай ук тавышланмаска тырышып, кесәләрендәге шешәләрнең берсен тумбочкага, калганнарын сәке астына, почмакка утыртып куйды. Бары шуннан соң гына ул дөбер-шатыр килеп тимер мичкә ягарга кереште.

Беркадәр вакыттан бригадир вагонының ишеге ачылып китте, һәм Ислам ягына агарынган, ач бүредәй ярсыган Таран килеп керде; килеп керде дә, ниндидер бик әһәмиятле, бик җитди сөйләшү булачагын белдергән бер тавыш белән, тантаналы бер дәһшәтлелек белән, кызмыйча гына:

— Керегез әле, сезнең белән сөйләшәсе бар!— диде, ачык калдырылган ишегенә ымлап.

Исламны ул күңеленнән күптән инде гафу иткән иде, дөресрәге, җыелышта булган күңелсез нәрсә белән килешергә мәҗбүр булган иде. Исламның андагы тәнкыйтенә ачуланудан бигрәк, ул хәзер аның юри кайтмый ятуына ачулана башлаган иде, чөнки аның үтереп тә эчәсе килә иде, ә Исламның бүген, һичшиксез, аракы алып кайтачагын ул бик яхшы белеп тора иде.

Ләкин сүзне ул аракы мәсьәләсеннән түгел, бәлки, бөтенләй икенче нәрсәдән — үзе өчен һич тә әһәмияте булмаган нәрсәдән башлады.

— Сез нәрсә... вакытында кайтмыйсыз бригадага?— диде ул, җитди-рәсми бер кырыслык белән.

Күрәсең, бу сүзләрне ул алдан ук уйлап куйган иде. Исламга аның беркайчан да «сез» дип эндәшкәне дә, аның белән мондый рәсми тонда сөйләшкәне дә юк иде. Ул, гомумән, беркем белән дә җитди-әдәпле тонда, акыллы башлыклар тонында сөйләшә белми иде. Исламга бу көлке тоелды, һәм ул авызын кыйшайтып көлемсерәп куйды.

Таран иелә төшкән авыр башын күтәрде дә бар көченә йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

— Мин синнән сорыйм: кайда йөрдең моңа кадәр?— диде ул.— Иртәгә сукага чыгарга кирәк, ә син анда... эт белсен... кайдадыр типтереп йөрисең!..

— Нәрсә, шулай бик сагындыңмыни Исламны?— диде Ислам, әз генә дә тынычлыгын җуймыйча.

— Сагындым! Төкерәм мин сиңа!— дип кычкырды бригадир.— Бригада кешесеме син, түгелме? Бригаданыкы икән, дисциплинага буйсынырга тиешсең.

— Кем дисциплинасына?

— Һәркем өчен дисциплина бер,— диде Таран, ярсуын бераз киметә төшеп.

Шул чакны ул төп мәсьәләдән әле һаман ерак булуын һәм ничек тә тизрәк килешергә, Исламның «берәр нәрсә» алып кайтканмы, юкмы икәнлеген белергә кирәклеген аңлап алды. Ләкин хәзер кинәт кенә шуңа күчү бик кыен, бик авыр булып тоелды. Ул, әйтергә сүз таба алмыйча, Исламны күзе белән ашардай булып, беркадәр тынып торгандай итте. Шуннан соң, үгет-нәсихәт тонында, килешергә теләк белдергән бер тонда, тик шулай да әле тыштан усал, ачулы күренергә тырышып:

— Ничә мәртәбә әйттем мин сиңа...— диде.— Исеңдә тот: икенче болай төнлә йөрүләрне ташла. Соңгысы булсын. Тагын кабатланса, җиде кат тиреңне салдырып алырмын.

— Салдырган диярләр!

— Но, но, телләш тагын! Остарып киттең. Оратор! Мин кем сиңа? Бригадирмы, малай-шалаймы?

— Беттеме?— диде Ислам, кулларын чалбар кесәләренә тыгып.

Таран, аның әле һаман сузарга чамалавын күреп, ачусыз гына сүгенеп куйды. Аның хәлен бик яхшы аңлаган Ислам исә хәтере калган кеше булып кыланды һәм, озын аякларын аерып баскан хәлдә, кинәт кенә Таранның үзенә акыл сатарга керешеп китте.

— Сез нәрсә, иптәш бригадир, тәнкыйтьне яратмыйсызмы?— диде ул, ялган бер күтәренкелек белән.— Тәнкыйтьсез нишләмәкче буласыз сез? Үзегезне тәнкыйтьләгән һәркемгә акыра-бакыра башласагыз...

Ниһаять, Таранның түзәр тәкате калмады.

— Җитәр! Булды!— диде ул, урыныннан торып.— Лыгырдама юк-барны. Андый сүзләр сөйләргә кешесе син түгел. Әйдә, чыгар да...

— Нәрсәне?— диде Ислам, гаҗәпләнеп.

Аның бу гаҗәпләнүе шундый ихлас, шундый ышандыргыч булды. Таранның күзләре шардай ачылып китте.

— Нәрсә-ә?!— диде ул, исе китеп.

## XVI

Тик шулай да алар бик тиз килештеләр. Ислам, үз бәясен арттыру өчен, башта, бер генә шешә алып кайттым, диде. Шатлыгыннан Таран нишләргә белмәде. Шундук ул, Тәзкирәне алып керергә дип, Димканы кызлар вагонына җибәрде. Тәзкирә бригадир янына керүдән баш тартты, башым авырта, диде. Шуннан соң җилләнеп Ислам чыгып китте. «Папаша»га бик нык хәтере калган булса да һәм чыннан да кайгысыннан бераз гына башы

авыртып торса да, алырга дип Ислам үзе кергәч, Тәзкирә күнми булдыра алмады.

Ә бер ун-унбиш минуттан Таран бүлмәсендә төнге күңел ачу башланды. Ярты бушап калгач, Таран белән Ислам арасында ачыктан-ачык сөйләшү булды.

— Минем сиңа үпкәм зур,— диде Таран, тонган күзләрен Исламга текәп.— Тәнкыйтьче, имеш! Оратор! Син аны анда әйтмә, менә монда әйт. Анда начальство, монда — закон-тайга! Монда без үз кешеләр... Шулай бит, Тәзкирә джаным? Син мине яратасыңмы? Мин картлачны-мерзавецны?..

— Шулай, шулай, папаша! Яратам, җаным, яратам. Яратмаган кая ул!— диде Тәзкирә, көлә-көлә.

— Шуның өчен дә бригадир инде ул... тәнкыйтьләр өчен!— диде Ислам, тыныч кына.— Әллә син чын күңелдән сөйләгәндер дип уйлыйсыңмы? Сөйли күрмәсеннәр! Болай гына, форма өчен генә ул. Син миңа ачуланасың ачулануын, ә бит мин сине яклап чыктым, Глеб Семеныч!

— Дөрес, яклап чыкты!— диде Тәзкирә.

— Ничек ул алай?

— Менә ничек... Мин сине тәнкыйтьләдем, ләкин ничек тәнкыйтьләдем? Сылап-сыйпап кына, өстән-өстән генә. Эчә, дидем, бригадага игътибар итми, дидем, иртәгә сабанга чыгарга кирәк, ә безнең әле берни җитеш түгел, дидем. Шулаймы?

— Шулай да булсын. Тагын ни әйтерсең?

— Тагынмы? Тагын менә шуны әйтим, Глеб Семеныч,— дип дәвам итте Ислам, ярарга тырышып.— Син эчәргә яратасың, бригадага игътибар итмисең, кырык җирең кырылып ята — әллә бу турыда бүтәннәр белми дисеңме? Әллә директор, парторг белмиме... агроном?.. Барысы да белә. Җә, әйт, синең турыда мин яңа нәрсә әйттем? Чынында мин сине яклап калдым. Сине мин тәнкыйтьләмәсәм, бүтәннәр сине эт урынына сүгәрләрие. Ә сине анда беркем сүкмәде, минем тәнкыйть белән канәгать булдылар. Менә ул кайда дипломатия!

— Дөрес, папаша җаным!— диде тагын да Тәзкирә, чыр-чыр көлеп.

— План, имеш, сөрү, чәчү, имеш...— диде Ислам, кызганнан-кыза барып.— Кеше турында уйламыйлар, план күптән әзер. Планны аны ат җигеп тартасы түгел — түшәмгә карап бер төкерәсең дә, килә дә төшә өстәл өстенә. Бу чегән тормышында, бу эт тормышында нинди план, нинди сөрү, нинди чәчү булмак кирәк? Көн генә җылынсын, бу җәһәннәм оясында бер генә шакал да кал-

маячак — барысы да качып бетәчәк. Өченче бригададан инде өч кеше качкан, дүртенчедән ике кеше... Харап булган — аны тәнкыйть иткәннәр! Әллә син чыннан да шушында сукыр тычкан шикелле җир тырнап ятмакчы буласыңмы?

— Җир тырнауга килгәндә, аңа мине өйрәтеп торасы юк! Җир тырнап минем күзем чыккан,— диде Таран, бу мәсьәләдә Ислам белән бик үк килешергә теләмичә.— Шулай да хаклы син, сукин сын!

— Исламны әле белмисең син, Глеб Семеныч!— диде Ислам, үсенеп.— Миннән башка ышанычлы кешең дә юк синең монда.

— Юк! Беркемем дә юк. Бары сез генә!— диде Таран, күңеле эреп.

«Ишәк!»— дип уйлады Ислам, үз бүлмәсенә кергәч, бригадирны шулай җиңел генә юмалый алуына күңеле булып.

Сәгать инде төнге беренче китеп бара иде. Ул, йокларга әзерләнеп, өстен-башын чишенә башлады. Ләкин шул вакыт ул үзе бүген акча алган егетләрне исенә төшерде. «Аларның да авызын томаларга кирәк»,— дип уйлады ул, йоклау турындагы уеннан кире кайтып.

Зур чатырда әле кешеләр барысы да йоклап бетмәгәннәр иде. Мансур белән Кәрам, авыр күз кабакларын көчкә ачыштырып, арып-алҗып, шулай да бик бирелеп, шахмат уйнап утыралар иде. Ишек төбендәге почмакта ике егет, пыш-пыш килеп, әледән-әле прх-прх көлешеп, күрәсең, кызлар турында гайбәт саталар иде.

— Эшче халкына сәлам!— диде Ислам, бөтен чатыр эчен яңгыратып.

Аның сәламенә беркем җавап бирмәде: йокыдагылар үз көйләренә тыныч кына тын алдылар — борыннарын сызгырттылар, йокламаганнар үз эшләрендә булдылар. Ислам шахмат уйнаучылар янына килде дә, аларны шаккатырырга исәпләгән бер кыяфәттә, башланмаган шешәне шапылдатып өстәлгә утыртты.

— Ташлагыз әле шул шакмакларыгызны!— диде ул, Мансурга эндәшеп.— Бар әле, стакан алып кил... бәйрәм хөрмәтенә...— бармагы белән ул тамак астына чиертеп алды.

Уен белән мавыккан Мансур, коры гына:

— Нинди бәйрәм?— диде.

— Нинди бәйрәм, имеш!— диде Ислам, үчекләшеп. Олы башын кече итеп, «малай-шалайларны» көтеп утыруына, җитмәсә, беркемнең дә үзенә якты чырай күрсәтмәвенә аның күңеле тырналып куйды.

— Иртәгә сабанга чыгабыз — менә нинди бәйрәм!— диде ул, аңлатырга кирәк табып.— Әйдәгез, тиз булыгыз, вакыт тар.

Аның баягынак кичтән алган акчасын кайтарып бирмәс өчен шулай аракы белән сыйларга исәпләвен Мансур, әлбәттә, шундук аңлап алды, шуңа күрә ул аның җиде төн уртасында «бәйрәм» ясап йөрүен әз генә дә ошатмады.

— Рәхмәт. Үзең эч,— диде ул, яңадан шахмат тактасына иелеп.

— Эт эченә сары май килешми... төсең түгел...— диде Ислам, артык кыстамыйча.

Шулай да, мондый илтифатсызлыкка бик нык хәтере калган кеше сыман, ачуланган булып ул шахмат тактасын кинәт төртеп җибәрде. Такта, үз юлында очраган кашык белән калай коштабакны шудырып барды да, кашыгын-коштабагын, фигураларын җир идәнгә коеп, ярты ягы белән өстәл читендә асылынып калды. Юкка-барга хәтере кала торган, коры салам кебек кабынып китә торган бәләкәй Кәрам сикереп торды һәм кашларын җимереп, әтәчләнеп, чын-чынлап Исламга кизәнеп алды. Ислам тыела алмыйча көлеп җибәрде. Мансурның да кинәт күңеле күтәрелеп китте.

— Нәрсә монда хуҗа булып йөри?!— диде Кәрам, челәеп.— Эчәсең килә икән, эч әнә Таран белән!

Ул арада стакан тотып каяндыр Белугин килеп җитте.

— Кит әле!— диде ул, Кәрамны читкә этәреп.

— Сал Кәрамга. Тынычлансын,— диде Ислам, мәрхәмәтлек күрсәтеп.

— Аңа әрәм итәргә тагын!— диде Белугин.

Хәзер инде Кәрамның Белугинга ачуы килә башлады.

— Селедка! Сөйләнгән була!..— диде ул, Белугинны ашардай булып.

Белугин исә һәркемнән элек үзе авыз итеп карамакчы булды.

— Бир Кәрамга!— диде Ислам, боеручан төстә, иренеп кенә.

Кәрам белән Белугинны сыйлагач, ул Һарун караваты янына килде, аның өстендәге ябынгычын тартып җибәрде дә:

— Әй, авылдаш, тор, килеп җиттек!— диде.

Һарун аларның барлык сүзләрен тыңлап, ишетеп ятты. Исламның шулай стакан төбе ялатып йөрүенә аның җаны үртәлде. Ул Исламның үзенә дә эчәргә тәкъдим

итәчәген көтте һәм алдан ук усалланып, үз-үзенә: «Үтерсә дә эчмим!»— диде. Ислам ябынгычны ачып ташлагач, ул чак-чак кына аңа тибеп җибәрмәде. Аны бары эчке бер курку, шүрләү тойгысы гына тыеп калды, аннары Исламның тавышы ничектер дусларча булып, эчкерсез булып ишетелде.

Карышырга үзендә артык көч тапмыйча, ул урыныннан торды; торды да куллары белән битен сыйпап алды. Ислам, үз кеше итеп, аның иңбашына төртеп җибәрде. Һарун чайкалып китте, ләкин егылмады.

— Ач күзләреңне, аю! Әйттем бит, алып кайтам дип! Тот!

Һарун, берни эндәшмичә, стаканны авызына каплады да Белугин кулыннан бер-ике кабымлык икмәк сындырып алды. Аракы җылысы тәненә китеп өлгергәнче, күңелендә кинәт үкенү, ачыну тойгысы калкып чыкты. «Эх, җебегән, җебегән, җебегән! Ник эчтем? Ник?!»— диде ул, үз-үзен сүгеп. Ләкин инде эш узган иде. Ул кискен бер хәрәкәт белән ябынгычын тартып алды, башыннан бөркәнеп, кире урынына ятты.

— Менә, ичмасам, Һарун — җегет! Бирәләр — эч, бирмиләр — теләнмә!— диде Ислам, мактап.

— Ни әйтсәң дә, мужик! Чыдам халык,— диде Белугин.

## XVII

«Тагын мужик»,— диде Һарун, күңеле әрнеп. Бу сүз аңа пычак белән кадагандай тәэсир итте. «Әллә торып авызын җимерәсе инде шул кызыл битле дуңгызның?»— дип уйлады ул, ярсып. «Тор, тор! Нәрсә үзеңне мыскыл иттереп ятасың шулардан?!»— диде аракы кызуы, аның һаман кытыгын кузҗытып. «Тормый ни, торырсың!.. Торсаң торырсың инде, иллә мәгәр миңа ышанма»,— диде икенче бер тавыш, әнисе булып, «Һи, яшь этәч! Тапкан... кеше белән талашып йөрмәсәң, адәм көлкесе...»— диде өченче берәү, Хәлимә тавышы белән.

«Ә ник алар миңа «мужик» диләр, «аю» диләр, «авылдаш» диләр?»— диде Һарун, үз-үзен яклап. Аның тагын нидер әйтәсе килде, нидер даулыйсы килде, ләкин кинәт кенә ул бик җиңеләеп, каядыр күтәрелеп киткәндәй булды. Ул әйтерсең үзенең тавышыннан, уйлау-фикерләү сәләтеннән генә түгел, хәтта үз-үзеннән мәхрүм булды. Бары тик кайдадыр калын, бик калын стена артында гына кемнәрдер чыш-пыш килеп сөйләшәләр дә, кайдадыр бик якында гына әрнетеп, ачыттырып кемдер сыз-

ланып, зарланып ятты. Шуннан соң ул искәрмәстән тирән, бик тирән чокырга төшеп китте. Чокырга төшкәндә, бик кыска вакытка уйлау-фикерләү сәләте аңа яңадан кайтты, һәм шул чакны аның күңелендә яшен чаткысыдай гөлт итеп, үләм! дигән бер кискен, куркыныч уй ялтырап китте. Бераздан яшен чаткысыдай ялтырап киткән уй да, курку да, чокыр да — барысы да каядыр юк булды. Ул йокыга чумды.

Бик озак булып тоелган күпмедер вакыттан соң, аны нидер тынычсызлый шикелле тоелды. Ул, мондый тынычсызлый торган нәрсәдән котылмакчы булып, йомшак, тирән рәхәтлеккә тагын да ныграк чуммакчы булып, күзләрен катырак йомды. Ләкин ул барыбер онытылып китә алмады. Ни йокылы, ни уяу көе шулай үз-үзе белән тарткалашып ята торгач, йөрәге еш-еш типкән хәлдә, нәрсәдәндер коты алынып, ул кисәк кенә уянып китте һәм, авыр күзләрен ачып җибәрсә, чатыр эченең инде яктырып беткәнлеген күрде. Ул моның төшме, өнме икәнлеген аера алмаган сыман, чатырның, иртәнге сыек, салкын яктылык белән тулы түшәменә текәлеп калды.

Чатыр эчендә бик тын иде, ифрат дәрәҗәдә тын иде. Юк, төш булырга мөмкин түгел иде бу, бу өн иде.

Аның куркуы арта төште. Күңеленә шундук: «Мине уятмый китеп барганнар»,— дигән бер шикле уй килде. Атылып ул урыныннан торды, караватаствннан кәкре муенын сузып утырган кирза итеген эләктерде дә, баш астындагы кыска сырмасын, бүреген тартып алды һәм бер-берсенә бик якын китереп куелган ике караватарасыннан чыгып, аннан-моннан киенә-киенә, ишеккә ташланды.

Инде шулай чыгып китим дигәндә генә, ул зур чатырның ике ягына тезелгән тимер караватларда кайсы бик нык сузылып, кайсы, киресенчә, салкыннан урталай бөгелеп, башларын ябынгыч астына яшереп яисә кулларын салындырып — төрлесе төрле рәвештә йоклап яткан иптәшләрен күреп алды һәм, нәрсә уйларга да белмичә, туктап калды. Йөрәк тибеше әкренәйгәндәй булды, чатнап башы авыртып куйды, тик шулай да күңелендәге икеләнү бетеп җитмәде. «Ни булды соң әле бу?» — диде ул үз-үзенә, аптырап. Үзе яктырган... Әллә соң бөтен чатыр белән... бөтен бригада белән йоклап калганнармы... исереп?..

Аның үзенең сәгате юк иде, Мансур исә сәгатен төнлә баш астына куеп ята иде, һәм сәгать карау өчен генә аны уятып азаплану уңайсызрак иде. Һарун чатырның киндер ишеген күтәреп куйды да тышка чыкты.

Инде таң атып беткән иде, Иртыш аръягындагы бер болытсыз күк читенә сыек алсулык йөгергән иде һәм чатырлар, вагоннар арасында һәркемнән иртәрәк уяна торган тынгысыз җил — көчсез, әмма шулай да үзәкләргә үтә торган зәһәр дала җиле әрле-бирле сугылып йөри иде.

Әйе, эш кешесе өчен хәзер йоклап ята торган вакыт түгел иде. «Бу әле беренче көнне шулай, соңга табарак ничек булыр бу?»— дип уйлады Һарун, эче пошып. Ничек эшләрсең бу шәһәр ялкаулары белән? Сәгатьле эшкә өйрәнгәннәр дә, монда да шулай сыртларын кояш кыздырганчы йоклап ятарга исәплиләр микәнни?

Кояшның зәгыйфь, салкын нурларын көчсез генә чагылдырып, буйсынучан бер төс белән йокымсырап, боегып утырган корыч машиналар арасында ул үз тракторын күреп алды да шунда таба атлады. Бер дә юктан, болай гына тракторның капотын ачып карады, тегесен-монысын тикшерде, кичә көндез генә җыеп куелган сабан төрәннәренә типкәләп алды, калай савыттагы ачкычларны-ниләрне барлап чыкты. Барысы да үз урынында, хәзер утырып чыгып китеп барсаң да була иде.

«Туктале, яхшылап киенеп чыгыйм да кабызып җибәрим, бөтенесенең котын алып. Бик тиз уяныррлар шуннан соң!»— дип уйлады ул, дуамалланып, һәм салкыннан бөрешә башлаган ялангач тәнен сырма итәкләре белән каплаттырып, кире чатыр ягына йөгерде.

Башына яулык өстеннән ниндидер күн бүрек, кыска сырма өстеннән плащ киеп куйган, ләкин шулай булуга да карамастан туңган, агарынган һәм йончылган кыяфәтле Тәзкирә, поход кухнясы алдына чүгәләгән көе, казан астына ут кабызырга азапланып ята иде.

— Һарун! Һарункаем, кил әле монда,— диде ул, үзе яныннан йөгереп барган егетне туктатып.

— Нәрсә?— диде Һарун.

— Мәхәббәтсез, карама шулай күзеңнең агы белән!— дигән булды Тәзкирә, кыланчыкланып. Аннары янында яткан калай банка кисәген сузды да, төчеләнеп-ялынып: — Бар әле, Һарункаем, шушы җамаяк белән солярка гына китереп бир?— диде.— Бер үбәрмен шуның өчен үзеңне.

«Синнән генә үптерәсем килеп торадырые менә монда!»— дип уйлады Һарун, Тәзкирәнең кыяфәтеннән җирәнеп.

— Таран сиңа әйттеме кичә?— диде ул.— Нәрсә дип әйтте, солярка сибәргә куштымы?

Таран исемен ишетү белән, Тәзкирә кинәт үзгәреп китте.

— Исем киткәние бер аның әйтүенә!— диде ул, пыранлап.— Бетмәс андый карт алашалар!

— Карт алаша булса да, бригадир алаша бит әле ул,— диде Һарун, аның шулай Таранны хурлавын кызыкка күреп.

— Бригадир! Андый черекбаш!— диде Тәзкирә, ачуы кабарып.— Ничә әйттем, кухняга бирәр нәрсә корамаларга, дип... Теләсә, тактасын да табарые, бүрәнәсен дә... Төкереп тә бирми. Монысы тагын бер тамчы соляркасын кызганган була, карун! Мужик! Белугин белеп әйтә сине.

«Тагын!»— диде кемдер, Һарунның колак төбендә генә пышылдап. Ул тагын да ныграк бөрешеп, йомарланып калгандай булды. Аның шундук Тәзкирәнең яңагына китереп кундырасы килде, кухнясы-ние белән тибеп очырасы килде. «Нәрсә болар барысы да миңа каныкканнар?— диде ул үз-үзенә.— Туктале, күрсәтермен әле мин сезгә «мужик»ны! Мин әле...»

Тәзкирәнең мондый сүзенә карата күңеленнән ярсыса да, теле белән ул аңа бер сүз дә әйтә алмады.

— Нәрсә карап каттың? Бар, бар, юлыңны кара!— диде Тәзкирә, үртәлеп.

Әйтергә теләгән сүзе Һарунның, ниһаять, тел очына килде, һәм ул, бик усал сүз әйтәм дип уйлап:

— Иртәрәк торалар аны казан астына ягасы булгач,— диде.

Тәзкирә инде унсигез-унтугыз яшәр кыз түгел иде. Үз гомерендә инде ул ярыйсы гына күргән дә, ишеткән дә иде, һәм Һарунныкыише «тәнкыйть» сүзләренә аның күптән колагы каешланып беткән иде. Ләкин төнге күңел ачудан соң бик әз йоклаганга, бүген аның бөтенләй кәефе юк иде.

— Йөрмәле монда күз көеге булып... катыншаланып!— диде ул кинәт.— Синнән башка да өйрәтүчеләр җитәрлек монда.

«Моның теленә эләксәң... күрсәтер бу күрмәгәненне!»— дип уйлады Һарун һәм, Тәзкирә чынлап торып дуларга тотынганчы, моннан тизрәк сыпыру ягын карады.

## XVIII

Чатырда әле һаман беркем тормаган иде. Бүтән көннәрне иртүк кереп идәнне, өстәл өстен себереп-җыештырып чыга торган Фәрханә апа да бүген нишләптер соңгарак калган иде. «Шушындый көнне... күптән көтеп алган беренче көнне!.. Барысы да юри сүз берләшеп куйганнар диярсең! Ә үзләре кичәгенәк җыелышта нәрсә генә сөй-

ләнмәделәр дә, нәрсә генә вәгъдә итмәделәр!»— дип уйлады Һарун, йоклап ятучыларга мыскыллы караш ташлап.

«Һи, мужик, авылдаш! Нәрсә катыншаланып йөрисең юкка!»— диде Тәзкирә, Һарунга җавап итеп. Егет ачудан тешләрен кысып куйды, идәндә яткан калай коштабак белән тимер кашыкны тиз генә иелеп алды да, үртәлеп, үчләшеп, ачулы бер дәрт белән, җилкенү белән барабан кагарга тотынды.

— Торыгыз, то-ор! Ялкаулар, торыгыз!

Йоклап ятучылар, мондый гаҗәп шау-шу ишетеп, берән-сәрән кыймылдашып куйдылар, ни булган бу дигән сыман, аптырашлы бер кыяфәт белән башларын калкыттылар. Мансур тиз генә сикереп торды да күз ачып йомган арада күлмәк-чалбарын киде, аягына җиңел ботинкасын элдерде һәм, берни эндәшмичә, берни сорашмыйча, тышка чыгып йөгерде. Ул көн дә дала юлыннан ике-өч чакрым җир йөгереп кайта иде, кайткач гимнастика ясый, тимер-томыр күтәрә, бил тиңентен суда коена иде.

Мансурдан соң Андронов кузгалды. Ябынгычын өстеннән алып ташлады да күзенә төшкән озын чәчләрен артка таба сыпырыштырды һәм, бөтенләй торыргамы-юкмы дигәндәй икеләнеп, шәрә килеш беравык тын гына утырып торды. Аннары киерелеп-сузылып, авызын бик нык ачып исни-исни, караватб башындагы киемнәренә үрелде.

Һарун, үзе чыгарган тавышка үзе дәртләнеп-җилкенеп, бертуктаусыз шакылдатуында булды.

— Торыгыз! То-ор!— дип кычкырды ул бар тавышына.

Йокысы туймаган һәм күз кабаклары шешенеп беткән Белугин, башын мендәрдән калкыткандай итте дә:

— Котырдыңмы әллә, күсәк?! Тукта хәзер!— дип кычкырды һәм, колакларын томалап, икенче ягына әйләнеп ятты.

Аның ачуланып кычкыруы Һарунның бары тик кирелеген генә арттырды. Үч итеп, ачу итеп, ул юри аның баш очына килеп шакырга кереште. Андронов икенче яктан карават аша үрелде һәм Белугинның өстендәге ябынгычын тартып алды да колак төбендә генә:

— То-ор!— дип кычкырып җибәрде.

Белугин шундук сикереп торды, торды да мендәрен Андронов ягына тондырды. Андронов башын иеп калды һәм, күршесе караватына килеп төшкән мендәрне алып, Белугинның үзенә атып бәрде. Ул арада бүтәннәр дә уяндылар, һәм бер-ике минут эчендә чатыр эче иртәнге ыгы-зыгы белән, шау-шу белән тулды.

Белугин, мендәрен баш астына салып, яңадан ятмакчы булды, ләкин шундук икенче яктан Илгиз килеп

өлгерде һәм шәрә тәнле Белугинның шәл кебек итеп төренгән ябынгычын иңбашыннан тартып алды.

— Күсәкләр! Туң башлар! Кешегә карата бернинди ихтирам юк сездә,— диде Белугин, еларга җитешеп.— Ташла калаеңны, дурак!

— Ә-ә, шулаймы, Ташбаш Кушбашев!— диде Һарун, усал бер шатлык белән авызын ерып.— Кичәгенәк иртәрәк яталар аны. То-ор, то-ор!

Кешеләрнең үзенә, үзе чыгарган тавышка буйсынуларын күреп, Белугиннан башкаларның моңа һич тә ачуланмауларын күреп, аның күңеле үсеп китте. Аның шакылдаткан саен шакылдатасы килде, үз иптәшләрен генә түгел, бөтен бригаданы уятасы килде. «Туктале, чыгып чаң кагыйм әле!»— дип уйлады ул һәм шундук тышка чыгып йөгерде.

Башта ул кызлар вагоны янына барды.

— Торыгыз, то-ор!— дип кычкырды ул, тәрәзә каршысына килеп.

Тышта тәлинкә каккан тавыш ишетеп кызлар да хәрәкәткә килделәр. Тәрәзәдә Фәридә күренеп китте. Ул, күрәсең, кисәк кенә сикереп торган иде — аның йокылы-уяулы йөзендә бераз гына курку билгесе бар иде, һәрвакыт моңсу карый торган зәңгәр күзләре зур ачылган иде. Ап-ак шәрә муены, муен асты күренеп торган чандыр ялангач тәненә ул иске соргылт шәлен япкан иде. Һарунны күргәч ул, уңайсызланып, шәлен югарырак, муен турысынарак күтәрә төште. Тиз генә тәрәзәдән читкә тайпылды да, күренмичә генә:

— Нәрсә булды, нәрсә булды, Һарун? Нинди тавыш ул?— диде.

— Юк, юк, берни юк! Торыгыз! Торырга!— дип кычкырды Һарун, тавышланудан туктап.

— Хәзер, хәзер!— диде Фәридә.

Вагон стенасы аша Һарунның колагына кызларның үзара көлешкән тавышлары чалынып калды. «Прицепщигын уятырга килгән!»— диде кемдер, кычкырып. «Бичара, түзмәгән икән!»— диде икенчесе. Фәридә үпкәләп нидер җавап кайтарды, кызлар яңадан шаркылдап көләргә тотындылар.

Һарунның никтер кәефе кырылды. Аның хәзер бригадир вагонына да, Фәрханә апалар ягына да барып торасы килмәде. Кулындагы кашыгы, тәлинкәсе кинәт бик авыр булып, кирәксез, мәгънәсез булып тоелды. Аттай башы белән балалар сыман тәлинкә шакылдатып йөрүе өчен ул үз-үзен сүгеп ташлады һәм, кем дә булса күреп көлә-нитә күрмәсен дигән шикелле, тизрәк үзләренә ашыкты.

## Икенче баб

### I

Беренче булып тракторын Һарун кабызды. Вагон тәрәзәләрен калтыратып, колакларны тондырып, каты чиста тавыш белән мотор пытырдарга тотынды. Кешеләрнең тәне буенча тыелгысыз бер дерелдек йөгереп узды, кыяфәтләр үзеннән-үзе җитдиләнеп киткәндәй булды. Үзен биләп алган күтәренкелек тойгысын яшерә алмыйча, Мансур, ап-ак тешләрен елтыратып, елмаеп җибәрде. Бәләкәй Кәрам, «ура» кычкырып, тракторлар арасында чабып йөрде.

Һаруннан соң Илгиз кабызды, Ислам кабызды. Бер-бер артлы пускачлар, дизельләр эшли башлады. Күп тә үтмәде, барлык тракторлар, җирне-күкне дер селкетеп, бер-берсен уздыра-уздыра, шатланып-дәртләнеп җырларга-гүләргә тотындылар.

Иртән бераз гына якты йөзен күрсәтеп алган дала кояшы бик түбәннән агылып торган болытлар арасына кереп югалган иде. Көн ямьсез, үзәкләргә үтеп көчле, тыгыз җил исә иде.

Тракторлар хәрәкәткә килгәч, әйтерсең җил дә туктады, көн дә ачылып китте — җилгә дә, салкынга да хәзер беркем игътибар итмәде. Җиңелчә генә дулкынлану белән, бары тик бәйрәм вакытларында гына, бары тик гадәттән тыш тамаша вакытларында гына була торган бер сабырсызлык белән, кызыксыну белән барысы да кузгалып китү минутын көттеләр.

Яшьләр, ашыгып, бер-берсеннән калышмаска тырышып, соңгы хәзерлек күрделәр, тыз-быз килеп, әле вагонга, әле чатырга кереп киттеләр, нидер алып чыктылар, нидер кертеп куйдылар, «ягулык склады» янына — яртылаш җиргә күмеп куелган зур-зур мичкәләр янына барып әйләнделәр.

Бөтенесе дә әзерләнеп беткәч, Таран биек «С-80» кабинасына — Ислам янына менеп утырды. Куәтле зур трактор кисәк кенә урыныннан тартылып куйды, һәм кырлы киң табаннарын шыгырдатып-калтыратып, бөтен җир өстен селкетеп, җитез генә шуышып китте.

Һарун, Исламның ничек итеп кузгалып китүен күзәтеп торды да, үзалдына: «Шофер, имеш! Трактор да йөртә белми!» — дип уйлап алды. Аны шулай күңеленнән мыскыллый алуы өчен ул үзендә масаю, горурлык шикелле нәрсә тойды. Үзенең нинди оста тракторчы икәнлеген күрсәтмәкче булып, аның шундук тормозны ычкындыра-

сы килде, Исламнан бер адым калмый барасы, аны хәтта узып китәсе килде. Ләкин ул китмәде, кабина ишеген ачты да, артына борылып, башын тыгып, кемгәдер кул болгады.

Ияк астын каплап, башына шәлен бәйләп куйган, өстенә яңа кыска сырма, зәңгәр чалбар, аякларына исә куныччы кайтарылулы яңа итекләр киеп куйган ак чырайлы Фәридә, зур брезент бияләйләре белән тимер штурвалга җайсыз гына тотынып, купшаеп-кабарып, сабан утыргычында утырып тора иде. Ирләр киеме аның чандыр гәүдәсен зур итеп, табигый төсен-битен күрер күзгә ят һәм тупас итеп, хәтта бераз гына көлке итеп күрсәтә иде.

Һарунның чакыруын күреп, ул бик авырлык белән генә урыныннан төште, кабина янына килде дә, аның сүзләрен ныграк ишетергә теләп, бияләен колак турысына күтәрде.

— Нәрсә, нәрсә?

— Кил, утыр! Кабинага!— дип кычкырды Һарун, үз яныннан урын күрсәтеп.

— Юк, юк! Мин сабанда!..— диде Фәридә, башын чайкап.— Миңа анда күңеллерәк. Анда миңа күңелле-рә-әк!

Трактор кузгалып киткәнче утырып калыйм дигән сыман, ул ашыгып сабан янына китеп барды. «Утырмасаң әллә!»— диде Һарун, чак-чак кына хәтере калып. Үзсүзле, тәкәббер шәһәр кызын күңеленнән ул хәтта яманлап куйды. Әле хәзер тыңламый әйткәнне, эшли башлагач, теңкәң корып бетәр моның белән!

Ул, ниһаять, кузгалып китмәкче булды. Ләкин шул ук секундта каршысына йөгергәләп, елмаеп Тәзкирә килеп чыкты. Килеп чыкты да, сорап-нитеп тормыйча, гусеница өстенә ябышып менде һәм кабаланып кабина ишегенә тотынды.

— Нәрсә, трактор астында каласың киләмени?!— дип кычкырды Һарун, ачу белән.

— Калса әллә, бер калганнан... Һарункаем!— диде Тәзкирә, тәмле телләнеп.— Мәхәббәтсез, карама шулай күзеңнең агы белән! Нәни генә утырып барырмын да төшеп калырмын... Ничекләр итеп түзмәк кирәк — бигрәкләр күңелле бит, җаным Һарун! Көнләшеп куйдым. Шул казанга бәйләнеп гомерем узар инде!

Аның тәтелдәвенә әз генә дә колак салмыйча, Һарун, бөтен игътибарын тракторга күчереп, тормозны ычкындырды да җай гына, салмак кына кузгалып китте. Шатлыгыннан нишләргә белмәгән Тәзкирә, курыккан булып, чыркылдап җибәрде; кычкыруның гына әллә ни тәэси-

ре юклыгын күреп, ике куллап Һарунның каты беләгенә тотынды, ләкин моңа гына да канәгать булмыйча, кабина ишеген ачты да бер читтәрәк биленә таянып торган Фәрханә апага кул болгап алды, нидер кычкырды һәм, куанып-сөенеп, чырылдап көләргә тотынды.

## II

Бригада урнашкан җирдә кайчандыр бер-ике бөртек саман йорт булган. Анда көтүчеләр торган. Ә бик күптән йортлар янында түгәрәк күл ялтырап яткан. Күл инде кипкән, юкка чыккан, һәм аның урынында вак-төяк түмгәкләр дә камыш куаклыклары һәм камыш сыман биек, каты үләннәр генә торып калган. Күл кипкәч тә, әле кеше бу урынны ташлап китмәгән: кое казып һаман шунда тереклек итеп яткан. Ләкин йөзәр, меңәр баш хайванга кое суы гына җитеп бетмәгән, һәм көннәрдән бер көнне сыер, сарык көтүләре, тузан туздырып, тын даланы тояк тавышы белән күмеп, әкрен генә Иртыш буйларына юл тоткан. Кое, саман йортлар шул көенчә утырып калган, вакыт үтү белән ишелгән, җимерелгән, һәм тирәякта җил-буран да кояш хакимлек итеп калган.

Моннан ике-өч көн элек килеп утырган вагоннарны, чатырларны исәпкә алмаганда, камыш куаклары янындагы әлеге шул саман йорт хәрабәләре тирә-якта бердәнбер билге булып, күз карашы төртелердәй бердәнбер корама булып тора. Күптән инде түбәсе убылып төшкән, өстенә алабута, әрем үскән балчык-тирес хәрабәләргә басып, кайсы гына якка күз салсаң да, беркайчан да адәм кулы тимәгән карт дала сузылып ята. Дала диңгезе уртасында адашып калган шушы ташландык утраудан — элекке көтүчеләр утравыннан Көктугайга таба — көнбатыштан көнчыгыш юнәлештә — бормаланып тар гына иске юл үтә. Хәер, бригада белән Көктугай арасында тракторлар, машиналар йөри башлагач, бу тар юлның эзе дә калмады.

Менә шушы юл буенча көнчыгышка — Иртыш ягына карап китсәң, Көктугайга барып чыгасың. Көнбатышка карап китсәң, кая барып чыгасың?— Бу турыда бригадада беркем дә белми, чөнки ул якка бернинди атлар да, машиналар да йөрми. Ул якка таба иске тар юл гына сузыла. Шулай ук төньяк белән көньякта нинди авыллар барлыгы, анда кемнәр, нинди кешеләр яшәве турында да беркемнең дә хәбәре юк. Бригада авылын өч яктан да ниндидер билгесезлек — иксез-чиксез киңлек һәм әйтерсең ниндидер төпсез бушлык әйләндереп алган, әйтер-

сеӊ ул якта бөтенләй икенче бер дөнья, икенче ил, икенче тормыш иде.

Тракторлар иске тар юл буенча көнбатышка таба — билгесез дала ягына таба юнәлделәр. Кайбер урыннарда әле кипшереп тә өлгермәгән йомшак чирәмне сырлап-издереп ике-өч чакрым чамасы җир киткәч тә, алдагы трактор кырт кына көньякка борылды һәм, юлдан беркадәр алга чыгып, шунда туктап калды. Беренче басу шушыннан башлана иде, һәм, алдан билгеләнгәнчә, беренче буразна да шушы төштән ярылырга тиеш иде.

Бригада авылы ягыннан бер-бер артлы тезелеп, юл буенча озын койрык булып, шау-шулы яшьләр белән тракторлар килә торды; «С-80» тракторы янына җиткәч, кабиналардан, сабаннардан кызлар, егетләр төшә тордылар, җыела тордылар һәм бу даланы, бу киӊлекне үз гомерләрендә беренче мәртәбә күргән шикелле, бик еракта — соргылт күксел томан эчендә булырга тиешле ниндидер нәрсәне җентекләп күзәтергә тотындылар. Ләкин никадәр генә карасаӊ да, никадәр генә күзәтсәӊ дә, даладан башка анда берни дә юк иде.

Ун-унбиш минуттан барлык тракторлар да бер тирәгәрәк җыелып беттеләр. Әлерәк кенә җир-күк селкетеп килгән металл чыӊы, мотор тавышлары ишетелмәс булды, һәм җанлы корыч машиналарга утырып, әллә каян килеп чыккан кешеләрнеӊ — төсләре-битләре белән дә, кыланышлары белән дә мондагыларга охшамаган ниндидер ят кешеләрнеӊ, яшь күӊелле, шат күӊелле кешеләрнеӊ монда килеп инде ничәмә көн хуҗаларча нидер эшләүләрен, нәрсәгәдер бик тырышып әзерләнүләрен сагаеп-пошынып тыӊлап, күзәтеп яткан киӊ дала, болар тагын нишләмәкче була инде дигән сыман, тын да алмый тынып калды.

— Берни күрмим,— диде Таран, каядыр еракка карап.

— Монда түгелдер ул, Глеб Семеныч,— диде Ислам.

— Нишләп монда булмасын! Шушында!— диде учетчы.— Нәкъ менә шушыннан башлап киттек. Әнә тегендәрәк, калкурак җир өстендә булырга тиеш.

Эзләгән нәрсәнеӊ «кайда» булырга тиешлеген аӊлатмакчы булып, ул кулы белән каядыр бушлыкка төртеп күрсәтте, ләкин аныӊ кай төшне күрсәтергә теләвен, билгеле, беркем дә аера алмады. Аннары ул, читкәрәк китеп, җир өстеннән нәрсәдер эзләргә тотынды.

— Таптым!— дип кычкырды ул кинәт.— Менә монда мин күн итек белән тырнап куйганыем. Менә монда, Глеб Семеныч.

Таран мыгырданып анының янына килде һәм чыннан да җир өстендә итек үкчәсе белән тырналган бер эз күрде. Берни әйтмичә, ул яңадан дала ягына карарга тотынды.

Моннан бер атна чамасы элек басу бүлеп йөргәндә, буразна яру өчен уңай булсын дип, маяклар кадап куелган иде. Ләкин юл буенда маяк юк иде — нишләптер аны бөтенләй кадап куярга ук онытканнар иде, ә юлдан эчкәрәк кадалган беренче маякны әллә җил аударган, әллә инде җәпәй йоткан иде.

— Ярар, эзләмәгез!— диде Таран, кулын селтәп.— Димка, бар, сукин сын, йөгер! Икенче маяк күренгәч тә тукта. Менә шушы үкчә эзеннән башлап китәрбез.

— Әнә Галимулла килә!— диде шулчак Димка. Ул моны шундый итеп әйтте, гүя бөтен өмет-ышаныч бары Галимуллада гына иде.

Барысы да юл ягына әйләнеп карадылар. Кышкы ябагасы коелып бетмәгән кола биясен әкрен генә атлатып, Фәрханә апаның ире Галимулла тракторчылар янына якынлашып килә иде.

— Тизрәк кил, тизрәк!— дип кычкырды Һарун, кул болгап.

— Тизрәк! Тизрәк!— дип кычкырдылар бүтәннәр дә, ашыктырып.

Үзенә кычкыруларын ишетеп, ул атын кызулата төште. Кола бия, зур башын чайкап, койрыгын болгап, бераз гына юыртты да, ни булды тагын? болай да барып җитәрбез әле дигән сыман, бер дә исе китмичә, әкренли башлады. Галимулла, анының шулай кинәт кенә әкренләвенә үзен гаепли күрмәсеннәр тагын дигән шикелле, тезген очы белән бер-ике мәртәбә селтәнеп алды. Ләкин анын үзенең дә бик үк кызулыйсы килмәгәнлеге, ат өстендә яхшы утырмаганлыгы әллә кайдан күренеп тора иде — атка атланып йөрүне, күрәсең, ул инде күптән онытып бетергән иде.

Галимулла килеп туктагач та, аңа мәсьәләне аңлатып бирделәр. Ул да Димка әйткәнне раслады: дөрес, диде, шушы төштән башлап киттек, диде. Дала кешесенекенә охшаш кысыграк күзләрен тагын да ныграк кыса төшеп, ул да еракка карарга тотынды, ләкин берни күрә алмады.

— Туктагыз әле, җегетләр... баш белән уйлап карaганда... җил аударгандыр аны,— диде ул, тамагын кыргалап.— Ат белән үзем тиз генә эзләп килим әле.

— Бар инде, бар!— диештеләр төрле яктан, ашыктырып.

Галимулла, үзенә шундый зур эш йөкләтүләренә күңе-

ле үсеп, бераз тагын сөйләнеп алмакчы булды, ләкин аңа сөйләнергә ирек бирмәделәр — атын куркытып куалап җибәрделәр.

Галимулла юлдан ераклашканчы һәм кечерәя-кечерәя офык читендә кара тап булып калганчы, шактый вакыт узды. Монда торып калган кешеләр, барлык сабырлыкларын бергә туплап, аның тизрәк югалган маякны табуын, йә булмаса маяк булып үзенең берәр җирдә туктап калуын көттеләр. Ләкин Галимулла һаман туктамады. Ул маяк кадап куелган төшне бик яхшы хәтерлим дип исәпләде һәм, үзенең ялгышмаячагына әз генә дә шикләнмичә, барды да барды. Күпмедер вакыттан соң ул еракта нечкә генә булып, бәләкәй генә булып җир өстеннән калкып утырган бер таяк күреп алды. «Шунда микәнни?»— дип уйлады ул, исе китеп. Туктады да артына әйләнеп карады — тракторлар бик еракта торып калган иде. «Ай-һай!»— диде Галимулла. Шулай да ул әлеге таякны барып карамакчы булды һәм әледән-әле артына борылып карый-карый, ары китте.

Көтеп торучыларның түземлекләре соңгы чиккә җитте.

— Булмый бу болай!— диде Һарун, сабырлыгын җуеп.

— Кайтып йоклап килик, булмаса,— диде Белугин, һич тә күңелен төшермичә.

Менә бервакыт җир астыннан калкып чыккан кебек, офык читендә яңадан Галимулла күренде. Күренде дә туктап калды һәм бер урында кузгалмыйча тора башлады. Аны шундук аңлап алдылар, кыймылдашып куйдылар.

— Башлады-ык!— дип кычкырды Таран, тамак ярып. Ислам үз тракторы янына йөгерде, кабинага менеп утырды.

— Китегез, кит!— дип кычкырды Таран, трактор алдындагы кешеләрне читкә куалап.

Аның күңелендә, бик кыска вакытка булса да, игенче хисе уянды. Кузгалып киткәнче, ул сабаннарны, беркетү-тоташтыру тимерләрен карап чыкты, аннары ерылган авызын җыя алмыйча елмаеп сабанда утырган Кәрамга төшәргә кушты, утыргычка үзе менеп утырды да, әйдә, дигән сыман, Исламга кул болгады.

Көчле тракторның гусеница табаннары тартылып, калтырап куйды, һәм трактор, өй кадәрле гәүдәсен бик җиңел күтәреп, шакы-шокы килеп, кузгалып та китте. Пычак кебек үткер төрәннәр үлән тамырлары белән челтәрләнгән йомшак җирне кисеп керделәр, билгеле бер тирәнлеккә төштеләр дә, карга канатыдай кара, елкылдавык дымлы туфрак катламының астын өскә әйләнде-

реп ишә-ишә, алга таба шуыша башладылар. Тирә-якка газлы төтен исен, машина исен күмеп, яңа сөрелгән җир исе — исерткеч ис таралды. Арттан, сырлы кара юрган булып, сөрелгән җир күпереп калды.

Кешеләр көлешеп, дымлы туфракны кулларына алдылар, бармак араларында әвәләп, иснәп карадылар, берберсен узып әле трактор алдына, әле сабан артына йөгереп чыктылар, буразнага басып бардылар һәм, кинәт туган эчке бер күтәренкелек хисенә, тантана хисенә биреләп, бүрекләрен, бияләйләрен чөйделәр.

Эш башланды. Инде хәзер бу далада беркайчан да туктап-тынып тормаячак эш башланды.

## III

Башлануын башланды, ләкин көтмәгәндә трактор туктап калды һәм бик каты үкереп, сырлы тимерләре белән йомшак җирне издерергә, бер урында таптанырга тотынды. Җире әле тиешенчә кипмәгән иде, һәм «С-80» тракторы никадәр куәтле булмасын, бишәр төрәнле ике сабанны өстерәү аның да хәленнән килерлек түгел иде.

Таран сабаннан төште дә җилләнеп трактор янына килде.

— Саерак сөрергә кирәк, Глеб Семеныч,— диде Ислам, киңәш итеп.

— Өс төрәннәрне алып ташларга кирәк,— диде Белугин.

Таран аларның берсен дә тыңларга теләмәде, тракторны як-яктан карап әйләнде дә, тәгәрмәчләргә уралган балчыкны чистартырга кушты, калай тартмадан ачкычлар алып, арт сабанның бер төрәнен сүтәргә кереште. Үз гомерендә аның мондый гына хәлләргә юлыкканы бар иде, әлбәттә, һәм мондый чакта нәрсә эшләргә кирәклеген дә ул бүтәннәргә караганда яхшырак белә иде. Кулына ачкыч алып эшкә тотынгач та, ул шундук сүгенүеннән дә, юкка-барга үртәлүеннән дә туктады, куллары да калтыранмады, киресенчә, соллы, төгәл хәрәкәтләнде һәм шулай ук шешенке кыяфәте дә кисәк кенә үзгәреп киткәндәй булды.

— Тартырга тиеш! Менә моны алып ташласаң, йөгертеп тартырга тиеш!— диде ул, үзалдына сөйләнгәләп.

Төрәнне алгач, трактор чыннан да кузгалып китте. Әмма соңгы көченә улап, көчәнеп беркадәр җир киткәч тә, янә йомшак, юеш балчык издерергә тотынды.

— Безгә, Глеб Семеныч, бөтенләй төрәнсез генә сөрергә кирәк,— диде Белугин.

— Сезнең ише киңәшчеләр... ораторлар!— диде Таран, тузынмыйча гына.

— Башта бер генә сабанны тарттырып карарга кирәк,— диде Һарун.

«Дөрес!»— дип уйлады Таран, ләкин мондый фикер иң әүвәл үз күңеленә килмәгәнгә һәм аны икенче кеше тәкъдим иткәнгә күрә, аның Һарун белән дә килешәсе килмәде. Ул, гомумән, эш вакытында үзенә ни дә булса күрсәтүләрен, өйрәтүләрен бик үк килештереп бетерми иде, ул бары үзенчә генә, үзе белгәнчә генә эшләргә ярата һәм шулай үзенчә эшләүне иң дөрес юл дип исәпли иде.

— Бер сабанны аны кем дә ташлап калдыра,— дип куйды ул үзалдына.— Сабан ташлап калдыру җиңел эш ул, син менә ике сабан белән сөреп кара, алай бик оста булсаң.

Икенче төрәнне дә алгач, трактор кузгалып китте. Арттан сузылып килгән кара җир күзгә күренеп тарайды, ләкин шул ук вакытта тракторга сизелерлек дәрәҗәдә җиңеләя башлавы.

— Булды, булды! Киттек!— диештеләр арттан ияреп килгән кешеләр, куанып.

Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, алар тагын иртәрәк сөенгәннәр булып чыкты. Трактор өченче мәртәбә тукталады, өченче мәртәбә кузгала алмыйча, көчәнеп уларга, үкерергә тотынды.

— Юк, булмый бу болай!— диде Һарун, тәмам сабырлыгын җуеп.

Таран тагын сабаннан сикереп төште, тирә-якта өелешеп торган кешеләргә никтер кычкырып алды, тракторны, сабан төрәннәрен яхшырак чистартырга кушты да, киреләнеп, үзсүзләнеп, өченче төрәнне сүтәргә кереште.

Шулай азапланып ятканда, якында гына автомобиль тавышы ишетелде. Таран башын калкытып карады һәм сөрелмәгән җир буенча турыга яшел «газик» якынлашып килгәнен күрде. «Көтеп кенә тора идем менә монда!»— дип уйлап алды ул үзалдына.

Кабинадан, беренче булып, кош тоткан сыман көлепелмаеп, Тәзкирә килеп чыкты. Директор машинасына утырып килүе белән масаюы аның күзгә бәрелеп тора иде. Аның һәркемгә, сез мине тиргисез дә тиргәвен, ә менә мин директорның үзе янына утырып кына йөрим! дип әйтәсе килә шикелле иде.

— Аш пеште! Ник кайтмыйсыз? Көтәм, көтәм...— диде ул, кычкырып, һәм, түшен киереп, бригада кешеләренең әле берсенә, әле икенчесенә карап алды.

Бүтән чакта шундый озак көтеп алына торган ашның

бүген шундый иртә пешүе һәм, гомумән, Тәзкирәнең вакытыннан элек өлгерә алуы кешеләргә бик гаҗәп булып тоелды, һәркем шундук сәгатенә күз төшереп алды. Сәгать инде төшке икенчегә китеп бара иде! Бу инде һич тә иртә түгел иде, бүтән көннәр белән чагыштырганда, бу хәтта бик соң иде. Бераз вакытка кешеләрнең ашыйсылары килеп киткәндәй булды, әмма ныклап торып эшкә тотынуны, чын-чынлап сөрә башлауны көтеп тору, ашкыну тойгысы һәм шул ук вакытта бөтен нәрсәнең гел аркылы килеп торуына пошыну, үртәлү тойгысы ашыйсы килүдән көчлерәк иде. Тәзкирәгә беркем җавап бирмәде.

## IV

Машина белән директор һәм баш агроном килгән иде. Ачык, тыныч йөзле, урта яшьләрдәге директор Горшков Игорь Андреич, җиргә аяк басу белән, яшьләргә сәлам бирде, аннары башын калкытмыйча мыш-мыш килеп һаман үз эшендә булган Таран янына килде, аңа да шулай ук сәлам бирде. Ләкин аның бригадир белән исәнләшүе корырак, рәсмирәк булды. Таранның бозылган кыяфәтен күреп алгач та, ул, ачу белән, үзалдына: «Тагын исерек, ахры!»— дип уйлап куйды.

Ул, Тараннан бер-ике адым читләште дә, сөрелгән җиргә күз төшереп алды, аннары юл буенда туктап калган тракторларга, монда җыелып, күңелсезләнеп торган яшьләргә карап алды. Мәсьәләгә төшенү өчен шул җитте. Шулай да ул күңеленә килгән бөтен нәрсәсен берьюлы чыгарып салырга ашыкмады.

— Ничек, сөреп буламы?— диде ул, тыныч кына, Таранга түгел, бәлки, яшьләргә эндәшеп.

— Була...— диештеләр, төрле яктан теләр-теләмәс кенә.

Кулына бер уч дымлы туфрак тотып, төркем янына баш агроном Остапенко килеп туктады — ул, читкәрәк китеп, сөрелгән җирне караштырган иде. Өстенә ул итәкләре тез башына кадәр генә җитеп торган яшел брезент плащ, аягына аучылар итегенә охшаш озын куныччлы итек кигән иде. Ул болай да бик зур, авыр гәүдәле кеше иде, ә инде җилдән куркып плащының өчлы башлыгын да күтәреп куйгач, бигрәк тә зур булып, озын булып күренә иде. Аның кайчандыр симез, тулы йөзе хәзер беркадәр сулыккан һәм бушап, салынып төшкән иде.

— Менә, юеш әле...— диде ул, учындагы балчыгын күрсәтеп.

Якташы Остапенконың сүзләрен Таран үзен яклау

дип аңлады һәм эшен ташлап билен язды да сөйләшүчеләргә якынрак килде: әйтмә дә инде, Кирилл Яковлевич!.. Шулай була торып та, менә монда иза чигәргә туры килә бит әле дигән сыман, эре генә төкереп куйды, аннары, җирнең әле юеш булуы-булмавы, ягъни сөрә башларга әле иртәме-түгелме мәсьәләсендә күңеленнән һич тә баш агроном яклы булмаса да, бары тик сөйкемсез директорга каршы килү өчен генә:

— Юеш шул! Нишләп юеш булмасын!— диде.— Кар суы да китеп бетмәс борын... Галимнәр, имеш, ораторлар-профессорлар! Югарыдан торып кем дә боерык биреп ятарга белә — менә монда эшләп карасыннар алар, алай бик оста булгач.

— Әйе, иртәрәк әле, Игорь Андреич, иртәрәк,— дип куйды Ислам да, каршы якларны бер-берсе белән килештерергә тырышкан сыман.

— Иген эшен китаптан укып өйрәнгән кешеләр һәрвакыт шулай инде ул,— диде Таран, күрәләтә Горшковка төрттерергә исәпләп.— Югарыдан план килеп төштеме, шундук ашыктырырга тотыналар: тизрәк тә тизрәк! Үз башы белән уйларга аның акылы юк. Ул сиңа ышанмый, кәгазьгә ышана. Кадрлардан аерылу дип атала менә бу, беләсегез килсә! Профессорлар, имеш, галим халык!..

Директор, беркемне бүлдермичә, тыныч кына тыңлап торды. Монда совхозга җибәрелгәнче, ул Казан заводларының берсендә баш инженер булып эшләде. Ул тумыштан ук шәһәр кешесе иде, һәм авыл хуҗалыгы аңа, Таран әйтмешли, «китаптан укып» кына таныш иде. Бу мәсьәләдә тәҗрибәсе әз булганга, ул, иген игү эшенә кагылышлы нинди генә сүз булмасын, һәрвакыт игътибар белән тыңлый, һәркемнең сүзенә колак салырга тырыша иде. Аның мондый ягын яхшы белгәнгә, Таран да, баш агроном да, аңа ни сөйләсәң дә бата, дип исәпләргә гадәтләнгәннәр иде.

— Димәк, иртәрәк чыкканбыз?— диде ул, Таран сөйләп бетергәч, баш агрономга карап. Аннары яшьләргә карап алды.— Ә сез ничегрәк уйлыйсыз?

— Иртә түгел, Игорь Андреич!— дип кычкырды Һарун, ашыгып, буталып.— Үзем беләм. Без сөрдек! Без һәр елны шулай сөрәбез...

Ул инде баядан бирле нәрсәдер әйтергә укталып торды, әледән-әле директорның күзенә карап алды һәм бары тик ачу китергеч кыюсызлык кына аны тыелырга мәҗбүр итеп торды.

— Дөрес әйтәсез, иртә түгел,— диде директор, Һарунның сүзләрен куәтләп.— Мин сезне тәҗрибәле бригадир

дип исәплим, Глеб Семеныч, шуңа күрә дә иң элек беренче белән өченче бригадага киттем. Алар инде кояш чыкканчы торып тотынганнар. Сәгать алтыдан. Ә сез?

— Бездә бит кояш икенче яктан чыга, Игорь Андреевич,— диде Белугин, директорның күзләренә туры карап.

— Күреп торам, сезнең кояш әле булса чыгып өлгермәгән,— диде директор.— Беренче бригадада, беләсезме, нишләгәннәр? Менә болай төрән сүтеп вакыт әрәм итеп маташканчы, «С-80»нең бер сабанын ычкындырып калдырганнар.

— Мин дә әйттем!— диде Һарун.

Кемдер аның кабыргасына төртеп алды, һәм ул, болай да инде чамадан тыш күп сөйләп ташлавын, җитмәсә, мактана башлавын шәйләп, туктарга мәҗбүр булды.

— Хәзергә шулай да ярап торыр,— дип дәвам итте директор.— Алар бездән икенче мәртәбә әйләнеп калдылар. Шулай ич, Кирилл Яковлевич?

— Шулай,— диде баш агроном, шулаен шулай да, ә бәлки, шулай да түгелдер, кем белә аны дигән сыман икеләнү белән.

— Бер сабанны мин аны үзем дә тартам,— диде Белугин, гамьсез генә папирос пошкыртып.

Тирә-якта көлешеп алдылар, әмма директорның тыныч-җитди йөзе, хәтта кырыс йөзе әз генә дә үзгәрмәде.

— Алай да була. Безнең өчен ул бер дә яңалык түгел,— диде Таран, бирешергә һич тә исәбе юк икәнлеген белдереп.— Ә норманы кая куясың? Норма бит бер сабанга яисә анда ике-өч төрәнгә бирелмәгән. Ягулык та ике мәртәбә артыграк китә. Менә ул кайда математика!

— Норма!— диде Горшков, кинәт тавышын көчәйтеп.— Ә менә болай утыру, сезнеңчә, нормамы? Кыскасы шул: хәзер үк ычкындырыгыз арт сабанны, кузгалыгыз! Ә «ДТ»лар өч төрәнне җиңел тарталар.

— Беренче бригадада шулай иткәннәр,— диде баш агроном, аның сүзен дөресләп.

## V

Бер сабанны «С-80» тракторы җилтерәтеп кенә алып китте. Мондый хәлне күреп, сабанда утырып барган Кәрам куанычыннан кычкырып ук җибәрде. Әле генә шундый мәкерле булып, берничек тә бирешмәслек булып тоелган киң даланы урталай ярып барган тракторга кешеләр исләре китеп карап тордылар.

Беренче буразна ярылгач, шуңа карап икенчесен яру инде авыр эш түгел иде. Төрән сүтеп вакыт әрәм итмәс

өчен, Һарун «С-80» тракторыннан ычкындырып калдырылган өч төрәнле сабанны үз тракторына такты. Ул арада озын аяклы Димка беренче буразна башыннан уңга таба йөз адым санады да күн итеге белән тырнап куйды, Һарун тракторын Димка билгеләп куйган җиргә китерде һәм Ислам китеп барган якка борылды. Ул арада Димка беренче трактор артыннан йөгерде. Ярты чакрым чамасы ул трактор артыннан ияреп барды, аннары буразнадан башлап тагын уңга таба йөз адым санады да, Һарун өчен маяк булып, шунда дала уртасында туктап калды.

Ерактагы «маяк»тан күзен алмыйча, Һарун әкрен генә кузгалып китте.

Күз алдында җәелеп яткан киң дала, җайкын дала аңа аңлаешсыз булып, серле булып тоелды. Уракчыда, Ташкичүдә һәм шулай ук үзе эшләгән бүтән күрше-тирә авылларда аңа һәрбер басу биш бармагы кебек таныш иде, шуңа күрә кайда ничек эшләячәген ул алдан ук белеп тора иде. Ләкин шундый таныш булган һәм һәр елны икешәр-өчәр мәртәбә тракторы белән аркылыга-буйга йөреп чыккан, сөреп, чәчеп, урып чыккан шул җирләрдә дә әле бөтенләй көтелмәгән урыннар очрап куя торган иде: йә бик ташлы, каты урынга, йә, киресенчә, бик йомшак, дымлы урынга килеп эләгә торган иде, ә кайбер урман буйларын кайчакта бер җәй эчендә вак каен, усак үрентеләре күмеп китә торган иде. Никадәр азапланырга туры килә иде аңа андагы тигезле-тигезсез ала-кола басуларда, чокыр-чакыр буйларында, урман куеннарында!

Ә монда? Монда җир өсте тигез, ачык. Ләкин ул бит монда беренче мәртәбә, үз гомерендә беренче мәртәбә! Ул, нинди дә булса берәр көтелмәгән хәлгә юлыкмыйм тагын дигән сыман, баштарак бик сакланып кына, алдынартын карап кына эшләргә булды. Кузгалып киткәч тә, ул беренче тизлек белән генә барды, аннары икенчегә күчте. Мотор бик әйбәт, бик көйле эшләде. Бары тик сабанга артык авыр урыннарда гына яисә тәгәрмәч араларына, төрәннәргә үзле балчык катыш иске чүп-чар калдыклары күп уралганда гына, йөреш сизелерлек булып әкренәя төште, һәм шундук мотор икенче бер калын тавыш белән көчәнеп үкерергә тотынды. Андый чакта Һарунның бөтен тәне пружинадай кысылып-җыерылып калды, куллары үзеннән-үзе идарә рычагларын кысыбрак тотты, аяклары тимергә ныграк терәлде, һәм ул, бөтен гәүдәсе белән алгарак иелгән көе, барлык игътибарын бергә туплап, сагаеп, мотор тавышына колак салды. Авыр урынны узгач та трактор, ниндидер капкыннан ычкынган сыман, кисәк кенә җиңеләеп китте; күңелләнеп-шат-

ланып, мотор ачыграк тавыш белән гөрләргә тотынды. Һарун исә, өстеннән авыр йөк төшкән сыман, иркенәеп калды, әйтерсең ул бөтен җаны-тәне белән, бөтен нервлары, мускуллары белән шушы корыч машинага береккән иде, әйтерсең ул мотор белән бергә җигелеп, бөтен шушы механизмны хәрәкәткә китерә һәм артка тагылган авыр сабанны да, сабандагы Фәридәне дә үзе тартып-өстерәп алып бара иде.

Димка турысына барып җиткәч, аңа туктарга һәм, учетчы егет алга китеп маяк булып басканчы, тагын бер урында көтеп торырга туры килде. Көткән арада ул кулына көрәк алды, кырды, чистартты, даланы, Димканы күзәтте һәм бер генә мәртәбә дә Фәридә ягына әйләнеп карамады. Аның янында ул үзен бик уңайсыз итеп, хәтта чит-ят итеп тойды һәм, никадәр генә үз-үзен иркен, гади тотарга тырышмасын, һәрбер сүзе, һәрбер кыланышы,— теләсә дә, теләмәсә дә,— ясалма булып, ямьсез, тупас булып чыкты. Ул моны үзе дә сизде; моны сизгән саен, аның үз-үзенә, үзенең шундый авыр, тупас булуына, кыюсыз булуына ачуы килде.

Менә Димка, күпмедер җир киткәч, Ислам бураznасыннан уңга таба тиешле адымнарын санады да, калкусыман булып күренгән бер төштә каккан баганадай катып калды. Янында чит кеше барлыгын сизеп уңайсызлану һәм аның белән икәүдән-икәү генә булганга, аның белән ни дә булса сөйләшергә кирәклеген дә, шул ук вакытта берни сөйләшеп булмаганлыгын да аңлау, сизүтою нәтиҗәсендә барлыкка килгән әчке бер киеренкелек юкка чыкты. Чит кешене генә түгел, хәтта ул үзүзен дә онытты; еракта бары тик карачкыдай караеп Димка гына торып калды да йөрәк тибешенә кушылып көчәйгән мотор тавышы гына торып калды. Ә бераздан артта тагын да кап-кара булып, елкылдап, сырлы тасма сузыла башлады.

## VI

Ислам бөтенләй диярлек күренмәде, тик кайчакта гына ул кисәк кенә кайдадыр офык сызыгында калкып чыкты. Һарунга җирнең кырые нәкъ шул трактор янындадыр, нәкъ шул калкулык артындадыр шикелле булып тоелды.

Тумыштан ук авыл кешесе, игенче кеше буларак, дала эченә үтеп керә барган саен, ул мондый иксез-чиксез җирләрдә никадәр күп иген игәргә, никадәр күп ашлык алырга мөмкинлеген ныграк аңлагандай булды. «Нинди

киңлек! Нинди шәп җирләр! Нишләп әрәм булып яткан бу дала моңарчы?»— диде ул әледән-әле, сокланып, исе китеп.

Беркадәр вакыттан ул тирә-якка күнегә башлады. Хәзер инде баштагы сагаю-икеләнү дә кими төште. Хәзергә әле бернинди ташлыклар да, әрләнлән балчыклары да һәм монда килгәч ишетергә туры килгән баткак урыннар да очрамады. Бары тик кайбер урыннарда гына бергә укмашып, җиргә сыланып үскән вак куак сыман үләннәр очраштыргалады да, көтмәгәндә төлке-бүре базлары килеп чыкты. Аннары трактор алдында яисә артта — сөрелгән җир өстендә — ояларыннан куркытып чыгарылган тычканнар, йомраннар чабышып йөрде, йә булмаса, искәрмәстән каршыда өтәләнгән, төсе уңган кызгылт-сары төлке пәйда булды; трактор узып киткәнче, үлән арасында посып ятты да елкылдап, сәер ис аңкытып калган кара җир янына килде, очлы борыны белән яңа, ят туфракны исни-исни, як-ягына карана-карана, сакланып кына буразна эченә керде; керде дә кинәт исеакылы китеп бик озаклап карап торды; аңгыраеп шулай бер-ике минут чамасы утыргач, пумала койрыгын өстерәп, куркып, кабаланып, өйрәнелгән таныш далага чапты. Төлкеләр, йомраннар даласына төзәлмәслек тирән яра салып узган киң буразна исә, ерактагы күксел болытларга барып тоташырга тырышкандай, берөзлексез сузылды да сузылды.

Берзаман артына борылып караса, Һарун уң яктарак икенче бер трактор күреп алды. Анысы Илгиз булырга тиеш иде. Димканың яңа урынга барып җитүен көтеп торган арада, алар хәтта бер-берсенә якынаеп та куйдылар. Ләкин кузгалып киткәч, ара тагын ераклашты, һәм Илгиз дә, алдагы Ислам шикелле үк, дала дулкыннары арасында югалып калды. Үзенең алдында да, артында да кешеләр барлыгын, аларның да үзе кебек үк тракторлар белән бертуктаусыз алга, дала «иленә» үтеп керә барганлыкларын аңлау анда күтәренкелек тойгысы тудырды. Бу минутта ул үзен бик кирәкле кеше итеп, бик әһәмиятле кеше итеп тойды.

«Кайда мин, нинди җирдә?»— диде ул, үз-үзенә сорау биреп. Бит мондый даланы, мондый күк йөзен, мондый төлке-йомраннарны аның төшендә дә күргәне булмады. Бит аның туган җире, туган авылы кайдадыр еракта ята. Ник килгән ул монда, нинди язмыш алып килгән аны бу ят җирләргә, бу ят кырларга? Нинди гаҗәп — каяндыр читтән — ерактан кил дә, имеш, хуҗа булып, ия булып нидер эшләп, нидер кырып йөр, имеш! Һәм

шул чакны бөтен дала, бөтен күк йөзе, төлкеләр, йомраннар, бөркетләр, тилгәннәр — һәр барчасы сокланып, таң калып сиңа карап торсыннар, имеш тә, кыймыйча, синең алда сүзсез генә баш исеннәр, сиңа юл бирсеннәр, имеш...

Әйе, монда хәзер ул хуҗа, ул хаким. Ләкин ни дәрәҗәдә зур да, ни дәрәҗәдә киң соң бу дала? Бармы аның чиге-чамасы һәм кая да булса барып чыгу өчен әле күпме барырга кирәк?

Әгәр менә шушы вакытта аның янында, янәшәдә Хәлимә булса, ул ни әйтер иде икән? Гаҗәпләнер иде микән, әллә бер дә исе китмәс иде микән? Юк, хәтта ул да гаҗәпләнер иде. И Һарун, нинди котсыз җир икән бу, дияр иде, беркайчан да минем шулкадәр күп төлке күргәнем югые, дияр иде...

Менә шулай трактордан төшмичә барасы да барасы иде, көн-төн барасы иде, атналар-айлар барасы иде. Икәүдән-икәү генә. Бернинди Исламнар да, Илгизләр дә, Белугиннар да булмасын иде, елга буе, карт тирәк булсын иде, елга өстеннән салкынча томан күтәрелсен иде, һәм, якында гына йокымсырап, бер-берсенә тавыш биреп, бакалар кычкырышсын иде... Аннан соң кояш чыксын иде, һәрвакыт шулай якты, җылы булып торсын, беркайчан да җил дә, болыт та булмасын иде...

Дала аңа башта гына шулай ямьсез булып, котсыз булып күренер иде. Башта ул һәркемгә шулай тоела. Ә соңыннан ул да күнегеп китәр иде, хәтта ярата да башлар иде. Мин синең белән калам, Һарун, дияр иде, син кайда — мин шунда, дияр иде, җүнле кеше бер-берсеннән аерылып торамыни, болай да инде синсез саргаеп беттем, карар йөзләрем дә калмады, дияр иде. Ә Шамил турында, ул дөрес түгел, сиңа юри сөйләгәннәр, дияр иде... Шамил турында...

«Каян килеп керде соң әле монда Шамил?» — диде ул кинәт үз-үзенә.

Хыялый гүзәллек шундук юк булды, күз алдында дала калкып чыкты, түбәннән генә агылучы, каядыр ашыгучы болытлар калкып чыкты. Никтер бик күңелсез булып китте.

Күз алдына килгән хыялый күренешләрнең хәзерге чынбарлыкка бернинди бәйләнеше юклыгын аңлау нәтиҗәсендә туган бу күңелсезлектән, бу күңел кайтудан соң чирек минут чамасы вакыт узмады, кисәк кенә аны бөтенләй икенче бер нәрсә тетрәндереп җибәрде. Алда ул җир өстендә бөгәрләнеп яткан нindидер кара нәрсә күреп алды. Ул кара нәрсәнең «нәрсә» икәнлеген шәйләүдән элек ул тракторны туктатырга, шундук, шул ук

секундта ук туктатырга кирәклеген аңлады һәм тиз генә тормозга басты. Шунда нидер ышкылып, шыгырдап куйды, чинап куйды, һәм шактый җитез барган трактор, бөтен авырлыгы белән кинәт алга таба сөрлегеп киткәндәй туктап калды.

## VII

Һарун тиз генә җиргә сикереп төште һәм трактор каршында, корыч гусеницадан бер метр чамасы алдарак бөгәрләнеп яткан Димканы күреп алды. Ул, күрәсең, йоклап киткән булган, ләкин хәзер уянган да, бу ни булды дигән сыман, аптырап-куркып, аягына басарга азаплана иде.

— Нәрсә? Нишләдең?— диде Һарун, иелеп.

— Нишләдең?! Берни юк. Арыткан.

Һарун, батыраеп һәм батыраерга, акыл өйрәтергә үзен хаклы санап, учетчы егеткә бераз кычкырынгалап алды.

— Утырып кына баргач та... сиңа рәхәт!— диде Димка, үртәлеп.— Эт кебек йөгерәсең дә йөгерәсең, аяк атлар хәл калмады.

Алар янына шундук Фәридә килеп җитте.

— Нәрсә, нәрсә? Ни булды?— диде ул, әле Һарунга, әле Димкага карап.

Аңа җавап бирүче булмады. Димка да, Һарун да, мәсьәләгә инде күптән төшенеп алган булсалар да, әле һаман берни аңламагандай, әле һаман нидер ачыкларга, нидер хәл итәргә кирәк шикелле, сүзсез генә бер-берсенә карашып тордылар.

Фәридә, артык сорашып тормыйча, шундук сабан янына китеп барды; кулына көрәген алды да, авыр гына, кыен гына кыланып, төрәннәрне чистартырга кереште.

Димка яңадан кузгалып китте.

Һарун Фәридәнең шак-шок килүен ишетеп торды һәм: «Монысында булышмыйм. Үзе генә чистартсын»,— дип уйлады. Эшсез тормас өчен, ул моторның теге-бу нәрсәсен караштырган булды, ләкин моторда берни юк иде, механизмнар дөрес, төгәл эшли иде.

Шуннан соң ул трактор алдына чыкты һәм, җилдән ышыкланып, папирос кабызды. Үз-үзеннән уңайсызлану, нәрсәдәндер ризасызлык, канәгатьсезлек тойгысы барыбер бетмәде. «Юк, болай ярамый»,— дип куйды ул, ышык урыннан чыгып.

— Каяле, үзем...— диде ул, тупас кына.

Фәридә көрәген бирде дә, читкәрәк китеп, әкрен генә, ашыкмыйча гына чәчләрен, шәлен-яулыгын рәтләргә кереште.

«Ялкау!»— дип уйлады Һарун. Кызның шулай үз эшеннән тиз генә, җиңел генә баш тартуына да, берни эндәшмәвенә дә, үпкәләгән сыман читкә карап торуына да — барысына да аның саруы кайнады. Икеләнү, кыенлык тойгысы кул белән алгандай юк булды, беләкләренә көч-куәт өстәлде, һәм ул, үз-үзен кинәт ничектер бик җиңел сизеп, җитез генә селтәнеп, төрәннәр алдындагы авыр туфракны чәчкәләп ташлады; төрән тимерләрен, шабалаларны көзгедәй ялтыратып, тәгәрмәчләргә тотынды. Аның һәрбер хәрәкәте кызның күңеленә авыр шелтә булып төште.

Эшен бетергәч, ул көрәген каккалап-суккалап кызга тоттырды.

— Карабрак бар,— диде ул.

Шуннан соң ул яңадан радиаторга барып сөялде һәм Димканың кая да булса барып җитүен, туктап калуын көтә башлады.

Шул чакны алда, сул якта бик ачык булып трактор тавышы ишетелде. Озакламый трактор үзе дә күренде. Ислам кире кайтып килә иде.

Һарун турысына җиткәч, Ислам, Таран, Кәрам өчәүләшеп җиргә төштеләр, Һарун янына килделәр. Бригадир Һарунның ничек эшләве белән кызыксынды, тегесен-монысын сораштырды һәм, әйткәнгә генә ышанмаган шикелле, иртәнгегә караганда турырак басып, тракторны, сабанны әйләнеп чыкты. Аннары ул тракторга үзе менеп утырды, тракторның ничек тартканлыгын белмәкче булып, бераз җир сөреп карады.

— Яхшы,— диде ул, әллә тракторны, әллә сөрелгән җирне мактап.— Бүтәннәр күренмәдеме?

— Илгиз күренә, Глеб Семеныч,— диде Фәридә, Һарун өчен җавап биреп.

Үзе белән генә булган чакта кызның берни эндәшмәве, хәзер исә беренче булып сүз башлавы Һарунның мин-минлеген кытыклап куйды. Аңа кинәт моңарчы Фәридә бары тик аны санга сукмаган өчен генә сөйләшмәгәндер шикелле тоелды.

— Җир башына кадәр күпме әле?— диде ул, Исламга эндәшеп һәм шул ук вакытта киеренке бер игътибар белән, Фәридә тагын ни дә булса әйтмәсме, дип көтте.

— Кайтып җитәргә күпме?— диде Ислам. Аның йөзе чытык, күңелсез иде. Аның даладан да, беренче буразналардан да зуррак, әһәмиятлерәк икенче төрле кайгысы бар шикелле иде.

— Әллә шулай бик кайтып җитәсегез килә, Ислам абый?— диде Фәридә һәм тиктомалга көлеп куйды.

Ул шундый шат тавыш белән, шундый яңгыравык тавыш белән көлде, әллә инде аның бер дә көлгәненелмайганын күреп гадәтләнмәгәнгә, әллә монда бернинди көлке нәрсә юклыгы үзеннән-үзе аңлашылып торганга, Һарун, соң дәрәҗәдә исе китеп, шундук аның ягына борылып карады. Карагач ул тагын да ныграк гаҗәпкә калды. Бу һич тә әлерәк кенә маңгай чәчен төзәткәләп, авызын күпертеп торган Фәридә түгел иде, бу бөтенләй яңа, икенче Фәридә иде. Аның гадәттәге эрелеге каядыр юк булган иде. Аның йөзе дә, күзләре дә — бөтен кыяфәте балкып, нур чәчеп тора иде.

Һарунның күңелен тагын нидер өтеп алды. «Тапкан көләр нәрсә! Кулына кош төшкәнмени!»— дип уйлады ул, кызга ачуланудан бигрәк, Исламга карата көнләшү хисе тоеп.

— Кайтып җитәмме инде, Фәридә җаным, әллә шушында туфрак буламмы,— диде Ислам, үз-үзен кызгандырган булып.— Минем табигатемә ярый торган эш түгел бу, Фәридә җаным. Барасың, барасың кырмыска кебек, ташбака кебек... кая барып чыгарыңны үзең дә белмисең. Ә машинада! Бер утырдыңмы, җилдәй очасың гына! Кепкаң гына төшеп калмасын. Менә ул кайда шәп тормыш!

— Юк, юк, монда да күңелле!— диде Фәридә, бәхәсләшеп.— Ой, без төлкеләр күрдек, төлкеләр! Берсе чак-чак кына трактор астына кермәде.

— Безнең ише берәр җүләр төлке булгандыр ул,— диде Ислам, көлеп.

— Ә мин йомраннар үтердем!— диде Кәрам.— Көрәк белән генә бәрәм дә әйләндерәм дә салам!

— Саласың!— диде Ислам, мыскыллап һәм илтифатсыз, саксыз бер өстенлек белән яшь егетнең кепкасын күзенә батырып куйды.— Берне үтерде дә, шапырыныр хәзер.

Кәрам, кызарынып, кепкасын маңгаена күтәрде һәм, ярсуыннан нишләргә белмичә, Исламга әтәчләнеп алды.

— Нәрсә гел кулыңны сузасың?!— диде ул, чиләеп.— Кулың бик озын булса, тиз кыскартырлар!

Тәмам хәтере калып, хурланып, Кәрам үз тракторлары янына китеп барды.

— Менә шул юлбасарлар белән ничек эшләмәк кирәк?!— диде Ислам, зарланган булып.

— Ә нәрсә ул йомран, Ислам абый? Теге зур тычканнармы?— диде Фәридә.

Хәзер инде Ислам аның үзеннән көләргә тотынды.

— Юк, юк, тычканнар кебек түгел, күселәр кебек!— диде Фәридә.

— Ник, аларның тычкан кебекләре дә була,— диде Ислам.

— Чынлапмы?— диде Фәридә.

— Җә, кузгалырга вакыт,— диде Һарун, аларның сүзен бүлеп.— Йомраннар, тычканнар турында сүз бетмәс анда.

— Оһо, синең начальник бик усал икән!— диде Ислам, Фәридәгә күз кысып.

— Юк, юк, нишләп усал булсын!— диде кыз. Һарун аларның соңгы сүзләрен ишетмәде. Берничә секундтан ул рычагларга тотынды, газны ыграк ачты, һәм мотор, тракторның корыч күкрәген ватып чыгарга җыенгандай, тагын ярсып гүелдәргә кереште.

## VIII

Кичке смена алышынган вакытта төлкеләр-йомраннар турында бераз гына сүз булып алды да шуннан соң бүтән берницди кычкыру да, көлешү дә ишетелмәде. Бу тынлык, бу җитдилек аш вакытында да дәвам итте — кешеләр әйтерсең бер көн эчендә кисәк кенә үсеп, олыгаеп киттеләр. Алда торган зур эш янында, карлы таудай булып торган бурыч янында юк-бар нәрсә сөйләп күңел кытыклаулар да, Тәзкирә белән әйтешүләр дә бик кечкенә булып, бик әһәмиятсез булып калды.

Яшьләрнең бу җитдилеген, бу тынлыгын Тәзкирә үзенчә юрады. «Туннарын тыгардай булып кайтканнар, убырлар!»— дип уйлады ул күңеленнән. Тыштан исә искиткеч шат, ягымлы булды һәм бик җитез кыланып, ихахайлап, йөгергәләп, тиз-тиз генә һәркемгә аш бүлә башлады. Беренче коштабакны ул, гадәттәгечә, Илгиз алдына китереп утыртты.

Әллә бик нык ачыкканга, әллә берәр башка сәбәптән, аш Илгизгә бик тәмле булып, шикләнерлек дәрәҗәдә тәмле булып тоелды.

— Тәзкирә, нинди аш пешердең?— дип кычкырды ул шундук.

— Ни булды, Илгизкәем? Тәмсезме әллә?— диде Тәзкирә, аның янына килеп.

— Нәрсә бу — әллә итле аш?— диде Илгиз, сорау алгандагы сыман.

— Ашале, аша! Ашагач белерсең,— дигән булды Тәзкирә, серле итеп.

Илгиз, ышанып җитмәгәндәй, ашны бер кабып карады, бер болгатып карады, ләкин аш чыннан да итле иде.

Азык-төлек мәсьәләсе бригадада гына түгел, гомумән,

бөтен совхозда, бөтен районда бик четерекле мәсьәлә иде. Кешеләр инде итле ашны гына түгел, хәтта бәрәңгене дә күптән онытып бетергәннәр иде. Шуңа күрә Тәзкирәнең бүген итле аш пешерүе бригада өчен чын-чынлап бер яңалык булды.

— Тагын бир!— диде Илгиз, беренче коштабакны бетергәч.

— Һай, әллә ошап куйды, Илгизкәем?— дигән булды Тәзкирә.

Бер генә коштабак бүтәннәргә дә әз булып тоелды. Алар да икенче мәртәбә сорап алдылар, мактау сүзләренә һич тә саранланмыйча, ашны мактадылар. Тәзкирәне мактадылар. Тәзкирә әйтерсең бер карыш үсеп китте, әллә шатлыктан, әллә казан кызуыннан йөзе алсуланды. Бер дә юктан ул кычкырып көлгән булды, сөйләнгән булды һәм, барысының да теләген үтәргә әзер кеше шикелле, кая басканын да белмичә, әрле-бирле йөгереп йөрүендә булды.

— Нәрсә... итне күп китергәннәрме?— диде Таран, ашап туйгач.

Бүген ул да бригада белән бер табынга утырган иде.

— Китерделәр!— диде Тәзкирә, эре генә.— Китерерләр алар көтеп ятсаң! Якаларына ябышсаң да әле тиз генә китереп тоттырмыйлар. Сукага төшкән көн дип, шул сез убырларга бер яхшы аш ашатыйм, дидем. Тотып ашардай булып торасыз бит. Көн йокламыйм, төн йокламыйм — алай да кадерем юк. Утыны чи, яндыра алмый бер теңкәң корый, суы шакшы, анысы белән тагын җаның кыела... Бармы, юкмы — сораучы юк, «давай!» дияргә генә беләсез.

— Тәнкыйть сиңа килешкән!— дип куйды Илгиз.

— Килешкән менә, килешми ни! Ыжлап бирәм бер сезнең тәнкыйтегезгә!— диде Тәзкирә, ни әйтсәм дә, миңа барыбер ачулана алмаячаклар, дигән бер чамасыз кыюлык белән.

— Шулай да каян алдың соң?— диде Таран.

— Директор машинасына утырып Көктугайга бардым. Бирәсеңме ит, юкмы, мин әйтәм, бирмисең икән, бригадага кайтмыйм, аш пешермим, мин әйтәм, кирәгем исә ачка кырылып бетсеннәр патриотларың, мин әйтәм. Буа торгач бирде, бер сарык салып җибәрде, җанкисәгем! Сорый белсәң, табалар, итен дә табалар, маен да, шикәрен дә...

— Икенчегә, алайса, майлы ботка?— диде Илгиз болай гына, Тәзкирәне үчекләү өчен генә.

— Телең бик озын, сиңа юк!— диде Тәзкирә.

— Нәрсә юк?

— Коймак!

— Коймак?!

Тәзкирә шундук кухня янындагы кечкенә яшел чатырга кереп китте, анда бераз вакыт югалып торды да, табага өеп, җылы коймак алып чыкты. Алып чыкты да, үзенең шәплеген, уңганлыгын аңлау шатлыгыннан, масаюдан кая басар урын тапмыйча һәм ерылырга гына торган иреннәрен бөрештереп кыскан көе, өстәл өстендәге коштабакларга чәнечке белән коймак өләшә башлады.

— Тәнкыйть килешкән, килешкән!— диде Илгиз, бер үк сүзне кабатлап.

— Болай булгач, сине гел тәнкыйтьләп кенә торырга туры килер инде,— диде Һарун да, сүзгә катышып.

— Тәнкыйтьләсәгез тәнкыйтьләрсез инде. Сезнең өчен дип тырышканның эше...— диде Тәзкирә, киң күңеллелек күрсәтеп.

Ул инде үз-үзеннән дә, бүтәннәрдән дә тулысынча канәгать иде, аңа инде бернинди мактау да, хурлау да үтәрлек түгел иде. Горурлануның, масаюның инде ул чигенә җиткән иде. Шуңа күрә, әледән-әле явып торган мактау сүзләре ишетеп, көтмәгәндә аның күңелендә үкенү шикелле бернәрсә кузгалып куйды. Итне ул һич тә директордан «буып» алмаганлыгын, бәлки, ит турында беренче булып Горшков әйткәнлеген, хәтта «тизрәк барып алырга кирәк, кооператорларга ышанып булмый, берәр ничек юкка чыгарып куюлары бар» дип кисәткәнлеген һәм шулай ук коймакны да үзе генә түгел, бәлки, Фәрханә апа белән икәүләп пешергәнлеген исенә төшерми булдыра алмады. Ләкин, ялганчы булып калмау өчен, бу турыда инде әйтергә ярамый иде.

— Синең әле чәең дә баллыдыр?— диде Илгиз, Тәзкирәне тагын да үчекләмәкче булып.

— Солярка урынына әллә бал биреп җибәргәннәр?— диде Кәрам.

Соляркаdebу искә төшерү Тәзкирәнең бөтен кәефен үзгәртеп җибәрде.

— Баллысын Алладан сорарсыз!— диде ул, коры гына.

— Баллы чәй! Баллы чәй бир, Тәзкирә!— дип кычкырды Илгиз, кружкасы белән өстәл шакылдатып.

— Кирәк булса, үзегез дә агызып алырсыз инде, җанкисәкләрем!— диде Тәзкирә, киреләнеп.— Минем монда кырык кулым юк сезгә!

Өстәл кырыенда утырган Фәридә кинәт урыныннан торды.

— Кая... үзем...— диде ул, сүз тыңлаучан бер җитезлек белән, Илгизгә якынаеп.

— Миңа да!— дип кычкырды Кәрам өстәлнең икенче башыннан.

Фәридә, бик өлгер кыланып, башта Илгизгә, аннары Кәрамга чәй агызып бирде. Аның мондый яхшы эшен хуп күреп, бүтәннәр дә, миңа да миңа дип, кружкаларын суздылар.

— Миңа балын күбрәк сал,— диде Ислам, кызның күзләренә карап.

— Балын?..

— Балын, балын!— диде Ислам.

Фәридә аңлап алды, никтер көлә башлады. Көлә-көлә ул Исламга чәй агызды, көлә-көлә китерде һәм кружканы кире хуҗасына сузганда, тагын нәрсәдер исенә төште дә, тәмам тәкатьсез калып, кисәк кенә бөгелде дә сул кулы белән күкрәгенә тотынды. Аның шулай, бертуктаусыз кытыкланып торган сыман, тыела алмый көлүе күпчелеккә бик гаҗәп, бик сәер тоелды.

Аның әле беркайчан да аш янында бүгенге шикелле шат күңелле дә булганы юк иде, кемнең дә булса йомышын үтәп йөргәне дә юк иде. Гадәттә ул, бер урынга килеп утырдымы, шуннан кузгалмыйча, беркемгә катышмыйча, алдына килгәнне ашый да шундук торып та китә торган иде.

Ул һәрвакыт өйдәгечә чиста, пөхтә киенеп йөрергә тырыша, киенгәндә дә бер киемен көне буе кими, бәлки, иртә-кич әле бер нәрсәсен, әле икенче нәрсәсен алыштырып кия иде, һәм шунлыктан ул кайберәүләргә бертуктаусыз төзәнергә-бизәнергә яратучан купшы кыз булып, хәтта аксөяк, иркә кыз булып күренә иде. Аның турында болай дип уйларга тагын икенче бер сәбәп тә бар иде. Үзенең бер-ике ахирәтеннән башка ул бүтән беркем белән диярлек аралашмый иде; бүтәннәр шикелле бер дә юктан көлми дә, шаярмый да һәм, кайчан гына булмасын, минем сездә эшем юк, сезнең дә миндә эшегез булмасын дигән сыман, уйчан-моңсу кыяфәт белән, хәтта горур-тәкәббер кыяфәт белән үз көенчә йөри бирә иде.

Аның күңелендә ниләр ятканлыгын бригадада беркем диярлек белмәде, һәм эрелеге, тәкәбберлеге өчен аңа егетләр дә, кызлар да гел кырын күз беләнрәк карадылар, ә кайберәүләр еш кына аны өтеп алудан да тартынмадылар. Бригада кешеләренең мондый карашы аның эрелеген, горурлыгын көчәйтә генә төште һәм аны тагын да ныграк үз эченә бикләнергә мәҗбүр итте.

Бүген әнә ул кинәт ачылып китте. Кара, нинди, хәтта ул да көлә белә икән!

Күпчелек аның турында шулайрак уйлады, һәм һәркем үзенчә җавап эзләде: нәрсә булган аңа?

— Бик эчәсең килгән икән... Ислам абый...— диде Фәридә.

— Килгән, килми ни!— диде усал телле Илгиз.— Ислам безнең Йосыф пәйгамбәр кебек — аңа кызларның бер күзе төштеме, йә бармакларын кисәләр, йә чәйләрен түгәләр!

— Йосыф пәйгамбәр булсам, белерием мин сезне нишләтергә!— дип куйды Ислам.

— Син инде болай да Ислам-пәйгамбәр!— дип кычкырды Кәрам, элеп алып.

— Пәйгамбәр!— диде Илгиз, үзенә-үзе каршы килеп.— Нинди пәйгамбәр булсын ул. Ислам-иблис диген!

Өстәл тирәсен көчле көлү тавышы яңгыратып җибәрде.

— Ну, ишәк!— диде Ислам, күзләрен акайтып.— Күрсәтермен әле мин сиңа иблисне!

Бүтән вакытта аның бу янавы Илгизгә, ихтимал, әзме-күпме тәэсир дә иткән булыр иде, ләкин иптәшләре арасында булгач, үз-үзен беркем кулы җитмәслек сак астында исәпләп, моңа ул бөтенләй игътибар итмәде һәм, батыраеп, Фәридәгә кычкырынгалап алды.

— Һарун калды ич, Һарун!— диде ул, кыз утырган якка каерылып.— Син алай үз начальнигыңны онытма, кирәк булыр!

Фәридә яңадан урыныннан торды, бер дә авырсынмыйча, җиңел генә шундук Һарун янына килеп җитте һәм, үз-үзен елмаерга мәҗбүр итеп:

— Чыннан да! Каяле, баллырагын китереп бирим,— диде.

Һарун аңа берни эндәшмәде: ал да димәде, алма да димәде. Аңа кинәт кыздан ниндидер хуш ис, җиңел ис килеп бәрелгәндәй булды, һәм берничә секундка аның зиһене чуалып китте, теле тотлыкты. Хәтта Фәридә шапылдатып каршысына чәй китереп утырткач та, аның авыр теле тиз генә чишелеп китә алмады. Бары тик бер-ике минуттан соң гына, өстәл янында сүз бөтенләй икенче нәрсәгә күчкәч кенә һәм кайберәүләр туеп урыннарыннан кузгалгач кына, ул үз-үзен тынычрак, иркенрәк тоя башлады.

«Эх, нинди җебегән мин!»— дип уйлады ул, ачынып.

## IX

Нилектән шулай кинәт кенә күңеле күтәрелеп киткәнлеген, нилектән бертуктаусыз шулай көләсе, шаярасы килгәнлеген Фәридә үзе дә аңламады. Дөресрәге, бу турыда ул баш ватып та тормады һәм күңеленнән, мин үземне гадәттәгечә тотам, дип уйлады. Шуңа күрә ул егетләрнең

төрттереп әйткән сүзләренә дә, кызларның мәгънәле генә карашып алуларына да бөтенләй диярлек игътибар итмәде.

Ләкин аштан соң ул бүген гадәттәгечә әкрен генә кыймылдап, боек, төче кыяфәт белән үз вагонына юнәлмәде. Бүген аның анда һич тә кирәсе килмәде. Керде исә, никтер бик моңсу, бик күңелсез булыр шикелле булып, дөнья кинәт тараеп, кысынкыланып калыр шикелле булып тоелды. Аның әле һаман тышта, саф һавада йөрисе килде, кемнедер күрәсе, сөйләшәсе килде.

Җир өстен корыткач та җилсезрәк, җылырак кичләрне егетләр тышта төрле уеннар белән, көрәшләр, көч сынашу кебек нәрсәләр белән мавыга башлаганнар иде, ә кайчакта алар юл буенча йөгерешеп-узышып та килгәлиләр иде. Гадәттә боларның барысын да комсорг Мансур башлап җибәрә иде. Спортны яраткан өчен дә аны бригада оешуның беренче көннәреннән үк комсорг итеп сайлап куйганнар иде.

Бүген дә ул кичке аштан соң берничә иптәшен «спорт мәйданчыгына» ияртеп алып китте. Анда алар, кулларын төкереклән, бер-бер артлы «штанга» күтәрергә тотындылар. «Штанганың» бер башына Көктугайдан алып килгән иске сабан тәгәрмәче, икенче башына берничә төрән тимере тагылган иде.

Фәридә, спорт белән бик үк кызыксынмаса да, иптәш кызы Зәкияне «спорт мәйданчыгы»на әйдәде.

— Арыдым, йокы килә,— диде Зәкия.

— Нинди йокы бу вакытта!— диде Фәридә, исе китеп.— Әйдә, карап торабыз! Бездә шундый күңелсез: укыйм дисәң, китабы юк, гәзит-журнал юк. Кайт та мич каршында җылынып утыр, җылын да төренеп ят! Кирәкми! Туйдым, күңелсез...

Алар якынрак килделәр һәм, кызыксынып, соклану белдереп, Мансурның җиңел генә, көчәнмичә генә тимер-томыр күтәрүен карап тордылар. Үз эше белән мавыгып, Мансур аларны бөтенләй күрмәде. Хәле бетеп штангасын җиргә ташлаган иде, янында гына кызларның мактау сүзләрен ишетте дә артына борылып карады.

— Мансур җиңде, Мансур!— диде Фәридә, кул чабып.

— Монда әле судьялар да бар икән!— дигән булды Мансур, ап-ак тешләрен елтыратып.

— Андый судьялар!— диде Илгиз һәм үзеннән алда өлгергән Димканы тупас кына төртеп җибәрде.

Кызу-кызу кыланып, ул шундук күтәрә дә башлады. Фәридә, көлә-көлә, буташтырып санап торды.

— Кем чакырган боларны монда?— диде Илгиз, кычкырынып.

Ачу белән ул тимерләрен җиргә орды. Аның шулай оруы булды, штангага Фәридә килеп тотынды.

— Китегез әле, чуалмагыз аяк астында! Әллә таптალып үләрсез,— диде Илгиз, яңадан уртага чыгып.

— Һи, шушы Илгизне!— диде Фәридә, үпкәләмәкче булып, ләкин үпкәли алмады, көлеп җибәрде.

— Әле генә күтәрдең ич!— диде Мансур, Илгизгә аркылы төшеп.

— Күтәрсә, анда синең ни эшең бар?— диде Илгиз. Егетләр чак-чак кына ызгышып китмәделәр. Ләкин шунда арага Зәкия керде.

— Их, туплы уйнарга!— диде ул бер дә юктан.

— Әнә комсоргтан сорагыз тупны, кая куйган?— диде Илгиз, бәйләнчекләнеп.

— Беркая да куймаган — тишек, ямарга кирәк,— диде Мансур.

— Әйдәгез, гармунга җырлатам, биетәм үзегезне!— диде Илгиз кызларга.

— Әйдәгез, сикерәбез!— диде Мансур.

— Сикерәбез, сикерәбез!— диде Фәридә, чәбәкәй чабып.

Аның сүзенә беркем дә каршы килмәде. Егетләр, ике вагон арасына Фәрханә апаның кер элә торган бавын тарттырып бәйләп куйдылар да, бер-берсен уздырмакчы булып, бау аша сикерергә тотындылар. Ул арада Фәридә белән Зәкия авыр өс киемнәрен алыштырып чыктылар. Мансур бауның бер очын чишеп алды, биеклекне кызлар өчен җайлады да, читкәрәк китеп торган Фәридәгә команда бирде:

— Әйдә!— дип кычкырды.

Фәридә бауга таба йөгереп китте. Ул һәркемнең үзенә таба карап торуын тойды, аның тагын никтер көләсе килде, кинәт кенә читкә борыласы, йә булмаса, бер-бер хикмәт эшләп ташлыйсы килде. Шулай да ул үз-үзен тыеп калды, исән-имин бау янына барып җитте дә, каты җиргә бер ныгытып басты да, бөтен гәүдәсе белән бергә укмашып, сеңер туптай югары атылды һәм күз ачып йомган арада бауның икенче ягына килеп тә төште.

Аны коточкыч шатлык хисе биләп алды. Ул тиз генә кире борылды, Мансурга кычкырып:

— Күтәр, күтәр, тагын сикерәм!— диде. Ул тагын да бауга таба ыргылды. Монысында Мансур бауны чак-чак кына югары күтәрде. Фәридә, җиңеләеп, ашкынып, тагын югары омтылды һәм әйтерсең бернинди көчәнүсез, бернинди кыенлыксыз икенче якка атылып чыкты.

— Оһо!— диде Мансур, чын күңелдән гаҗәпләнеп.—

Карале, син бит юкка әрәм булып яткансың. Синнән менә дигән спортсмен чыгачак, валлаһи менә!

Фәридә шатлыктан ни әйтергә дә белмәде. Үзенең чыннан да «менә дигән спортсмен» була алуын исбат итү өчен аның тагын да биегрәк, тагын да яхшырак сикерәсе килде, бөтенесенең исен китәрерлек итеп сикерәсе, очасы килде.

— Кая инде...— дигән булды ул, кызарынып.

— Чын-чын, валлаһи менә!— диде Мансур.

## X

«Җебегән мин, җебегән!»— диде Һарун үз-үзенә, кабатлап. Ашап туйгач, Мансур аны да уенга кыстап карады, ләкин ул баш тартты.

— Арытты әле,— диде ул, иренеп кенә.

Ә чынында аның үзе генә каласы килде. Хәзер аңа Мансур да, Илгиз дә, Кәрам да — берсе дә кирәкмәде. Хәзер аның үзалдына нидер уйлыйсы, нидер хәл итәсе, тынычланасы килде. Ул әкрен генә, авыр гына атлап «өйгә» кереп китте, авыр, керле киемнәрен караватасты на салып ташлады да, башыннан бөркәнеп, үз урынына сузылып ятты.

Баштарак ул берни уйламады — күңеленә, ичмасам, бер генә уй-фикер дә килмәде. Шулай ук ул үзен тиешенчә тыныч та сизмәде. Йөрәккәме, башкамы әйтерсең ниндидер чит нәрсә килеп кысылган иде, һәм шул чит нәрсә әйтерсең канга, уй-фикергә үз көенчә агарга ирек бирмичә, күзгә күренмәгән ниндидер көпшәләрне, кан юлларын тоткарлап, томалап тора иде.

«Эх, җебегән!»— диде ул тагын да, көрсенеп.

Ләкин шул ук вакытта үзе турында «җебегән» дип әйтү аңа нигезсез булып яңгырады. «Ни өчен җебегән?»— диде ул, үз-үзенә сорау биреп.

Нишләде әле ул җебегән булып? Беренче буразна салынды, басуны әйләнеп кайтты — тагын ни кирәк аңа? Беренче көнне шулайрак булыр инде. Алай булганына да шөкер. Кайберәүләрнең бит әле әнә анысы да юк. Алар әле яңа буразна ярып яталардыр. Якты күздә өлгерерләрме алар? Өлгермәсәләр нишләрләр? Караңгыда бит маяклар күренмәячәк. Ут яндырырлар микәнни? Алай, бәлки, кызыграк та булыр. Ух, бик кызык булыр ул алай!

Шулай итеп, сиздермичә генә уй юллары, кан юллары ачылып китте. Кинәт аның колагына тыштан өзек-өзек тавышлар ишетелеп китте. Өзек-өзек тавышлар моңарчы да бер минутка да тынып тормадылар, ләкин

әлегәчә ул аларны ишетмәде, ишетсә дә аермады, аңламады. Хәзер исә аермачык булып, үчекләп, Фәридәнең көлгән тавышы ишетелде.

Әмма бу көлү тавышы хәзер анда әз генә дә куаныч тойгысы тудыра алмады. Ул үзе — турыдан-туры аның «начальнигы» булган кеше — шушында, ябынгыч астында бөркәнеп яткан бервакытта, аның шулай берни уйламыйча, пошынмыйча, ниндидер Илгизләр, Димкалар арасында көлеп-шаярып йөрүе ничектер бик сәер булып, бөтенләй килешмәгән нәрсә булып тоелды. «Начальник» күңелендә кисәк кенә көнләшү шикелле бер нәрсә калкып чыкты.

«Ник көлә ул? Нәрсә булган аңа?» — диде ул үз-үзенә. Аның бит беркайчан да болай көлгәне, тилергәне юк иде. Бит ул бары бүген генә көлә башлады. Бүген генә... тегендә буразнада очрашкач кына... Ислам «абыйсы» белән очрашкач кына. Әйе, әйе, аның белән очрашкач кына! Аңарчы ул, көлү түгел, рәтләп сөйләшмәде дә. Ә бит сөйләшергә, көлешергә аңарчы да җае булгалады. Нәрсә дигән сүз бу? Нәрсә бу шулай да?!

Никадәр баш ватмасын, шулай да ул моңа җавап таба алмады, дөресрәге, аның тапкан җавапларының берсе дә аны тулысынча ышандыра алмады. Көндез ул, билгеле, Ислам «абыйсы»на көлде. Кичке аш вакытында да аңа көлде, ул булганга көлде. Ләкин әнә ул тагын Илгизләр, Мансурлар янында да көлеп йөри! Хәзер анда Ислам юк. Булса, аның тавышы күптән инде ишетелгән булыр иде. Шулай булгач, кемгә көлә соң ул?

Исламнан башка анда... тегендә Кәрам да бар иде. Ләкин Һарун аны санга да тыкмады. Шулай ук монда Илгизнең дә, Мансурның да сәбәпче булуы мөмкин түгел. Шулай булгач, кем кала соң тагын? Кем? Чынлап та ул үзе микәнни? Әйе... ул үзе микәнни?..

Ул аякларын сузып җибәрде дә чалкан әйләнде һәм күңелендәге каршылыклы уйларның, тойгыларның төбенә төшүдән гаҗиз калып, таштай каткан бер караңгы чырай белән тын гына ята бирде.

Шул рәвешчә ул шактый озак ятты.

Шулай да нәрсә булды соң әле аңа? Көлсә ни, көлеп тик йөрсен... авызын тыя алмагач... Анда аның ни эше бар, көлмәгәе, әллә нишләсен! Юк, андый коткыларга бирелергә һич тә ярамый, аның ише ерык авызлар күп булыр дөньяда. Эшләргә кирәк, эшләргә! Ник килде ул монда? Шуның өченме? Ул бит Исламнар, Белугиннар түгел. Ул чыннан да мужик, кара халык. Андый шәһәр чибәрләренә аның әле буе җитеп бетми. Теләсә нишлә-

сеннәр. Тегендә, авылда, аны дүрт күз белән көтеп торалар, аңа ышанып торалар.

Кемнәр көтә? Хәлимә?

Ләкин Хәлимә хәзер аңа кайчандыр төштә күргән бер танышы гына булып тоелды. Бераз вакытка аның хыял дәрьясы тагын туктап-тоткарланып калган сыман булды. Шуннан соң ул үзенең әле генә, бүген генә Хәлимә турында хыялланып уйлавын, аны да үзе янында тракторда итеп күрәсе килүен хәтерләде. Күңеле белән ул яңадан далага, даланың да Хәлимә турында уйлаган төшенә әйләнеп кайтты.

«Көненә ничә мәртәбә әйләнергә булыр икән?» — диде ул үз-үзенә. Бу аңа бик мөһим, бик авыр мәсьәлә булып тоелды, һәм ул тырышып-тырышып уйларга кереште.

Әйтүләренә караганда, беренче басуның озынлыгы сигез чакрым чамасы булырга тиеш иде.

Сигез чакрым! Сызгыра беләсеңме, абзыкай! Тегендә, туган якларда, иң озын дип исәпләнелгән җирләр дә икеөч чакрымнан артмый иде, андый җирне сөрүче тракторчы үзен дөньяда иң бәхетле кеше итеп саный иде. Аларга исә күбесенчә тар, кыска җирләрдә азапланырга туры килә торган иде. Ә монда... Ул сигез чакрым җирне төгәл генә күз алдына китерүе дә кыен — шундый ят, шундый сәер бу! Уракчы белән Ташкичү арасы җиде чакрым, шулай да әле нинди ерак булып тоела торган иде!

Бүген ул көч-хәл белән берне әйләнде. Иртән-иртүк тотынган булсалар, бәлки, икене дә әйләнгән булыр иде. Өч төрән белән сөргәндә, күпме була соң әле ул?..

Шулай уйланып һәм уйланган саен мавыгып ята торгач, ул тәмам тынычлангандай булды. Хәзер инде нәрсә турында уйласа да, кемне генә, нәрсәне генә исенә төшерсә дә, күңеле барыбер үз урыныннан кузгалмас һәм бар нәрсәгә дә тыныч, битараф көе калыр шикелле тоелды.

Вакыт инде соң иде, чын-чынлап йокыга киткәндә дә ярый иде. Ләкин ул йокыга китәргә өлгермәде, шул чакны аның янына Мансур килеп җитте.

— Бик арыдыңмы?— диде Мансур.

— Нәрсә?— диде Һарун, аның ни турыда сораганын аңлап җитмичә.

— Бүген бик арыгансың, ахрысы, һаман тормыйсың,— диде Мансур.

— Әллә... арыганмын бугай шул,— диде Һарун, иренеп кенә.

— Мин тамчы да арымадым, валлаһи менә!— диде Мансур, бәхәсләшергә җыенгандай. Әйтерсең аның арымаганлыгына кем дә булса ышанмаска исәпли иде. Ул,

гомумән, үзенең таза, нык булуы белән бераз гына мактанырга ярата иде.— Нәрсә ул сабанга утырып йөрү? Мин көне буе, төне буе ашамый-эчми йөри алам, чын, валлаһи менә!

«Әле бер көн эшләмәгән, авырын-җиңелен белә дә башлаган. Эшләп кара әле син, аннан мактанырсың»,— дип уйлады Һарун, Мансурның болай сөйләнүен бик үк килештермичә.

— Юкка без бергә булмаганбыз, Һарун,— диде Мансур, тавышын әкренәйтә төшеп.— Илгиз сүгенә дә сүгенә, үзе җүнләп берни өйрәтми. Китәм мин аннан.

— Шулаймыни?

— Әллә нинди ул,— диде Мансур, зарланып.— Һич аңламассың. Әллә берәр комсомол җыелышында кыздырып аласы инде үзен.

Һарун берни әйтмәде, үзалдына көлемсерәп кенә куйды.

— Карале, ал әле мине үзеңә?— диде кинәт Мансур.

Һарун аптырап калды, борынын тартты, күзен читкә борды. Аның бер дә прицепщигын алыштырасы килеп тормый иде, ләкин шул ук вакытта ул нишләптер Мансурга кире җавап та бирә алмады.

— Мин каршы түгел дә түгелен...— диде ул, көттеребрәк.— Ләкин минем бит Фәридә бар!

Шулай диде дә, үзе дә сизмәстән, кызарынып китте. Фәридә турында «минем» дигәч, ул үзен ниндидер гаеп эштә тоткан сыман булды. Фәридә исемен ишетү белән, шулай ук Мансурның да шат кыяфәте үзгәреп китте — ул аны, күрәсең, бөтенләй исенә дә алмаган иде.

— Карале, Һарун, ошыймы ул сиңа?— диде ул, серле бер пышылдауга күчеп.

— Кем?— диде Һарун.

— Фәридә соң...

— Әллә...— диде Һарун, мөңгерәүгә охшаш бер аваз чыгарып.

«Сизенде микәнни?»— дип уйлады ул Мансур турында. Нишләптер кисәк кенә аның кул-аягы хәлсезләнеп калган сыман булды.

— Нәрсәсе ошасын инде аның...— диде ул.— Көлә дә көлә... тиле кебек...

— Шулай шул,— диде Мансур.

Ләкин үзе ни өчендер көрсенеп куйды.

— Уйлап карарга кирәк,— диде Һарун, борынын тарткалап.

— Мин, алайса, Таран белән сөйләшәм!— диде Мансур, җитез генә.

— Сөйләш...— диде Һарун.

## XI

Ислам да аш яныннан төшенке күңел белән китеп барды һәм үзләре вагонына кайткач, бераз ял итеп алмакчы булып, сәкегә сузылып ятты. Шулай ята торгач, аның күз алдына бер-бер артлы үткән көннәр килеп басты.

Ул Казанның кызыл ярлы чокыр-чакырлар белән ергаланып беткән бер ягында, иске шпаллардан корыштырылган бер куышта туды. Курку-өркүле, кысынкы бала вакыты аның ике тәрәзәле шул куышта һәм кызыл ярлы чокыр-чакыр араларында, чүплек башларында үтте.

Сугыш елларында әтисе аның тимер юлда әллә вагоннар караучы булып йөрде, әллә нindидер кара эштә эшләде. Күрәсең, шуңа күрәдер аны армиягә алмадылар. Кайчакларда аңа нindидер төнге кунаклар ияреп килде. Алар, кыш көннәрендә ишекне иңеләй ачып, мышнап-кызарып, өй эченә нindидер авыр-авыр төргәкләр, әрҗәләр алып керделәр, пышын-пышын гына сөйләштеләр һәм еш кына очракта, өйдәгеләргә йокы мазасы бирмичә, төне буе эчеп утырдылар, кычкырдылар, сүгенделәр.

Берзаман, күзгә төртсәң күренмәслек бер төнне, әтисе тузынып-җенләнеп кайтты. Кайтты да, әшәке сүзләр кычкырып, әнисен кыйнарга керешге. Бүтән вакытларда да ул аны хәлдән тайганчы кыйнап чыгып киткәли торган иде, ләкин аның әле беркайчан да ул кадәр шашынганы юк иде. Әнисе чырылдап караватка посты, үзе чытырдатып балаларын кочаклап алды. Балалар, елашып, котлары алынып, әниләренә елыштылар.

«Үтерәм! Берегезне дә калдырмыйм!»— дип кычкырды әтиләре, ямьсез күзләрен акайтып.

Әнисе бернинди каршылык күрсәтә алмады. Ул бары куллары белән битен-башын капларга гына тырышты да, авыр куллардан ычкынып, ишеккә ташланмакчы гына булды. Ике күзен кара кан баскан ерткыч ата шундук аның юлына аркылы төште, кинәт аны идән уртасына егып салды да, нindидер җансыз нәрсәне таптаган сыман, хайвани бер кансызлык, рәхимсезлек белән таптарга, изәргә тотынды. Әнисенең тавышы бетте, авызыннан, борыныннан кара кан атылып чыкты.

«Дөмектеңме? Шул кирәк сиңа! Икенче әләкләшеп йөрмәссең...»— диде ата кеше, гырылдап, пычрак куллары белән авыз читен сөрткәләп.

Шуннан соң ул бүлмә эченә ялт-йолт каранды да ишеккә тибеп җибәрде. Тышка чыгар алдыннан чоланда нидер кузгатып, нидер актарып маташты, ә бераздан аның бакча коймасының черек такталарын сындырып,

чокыр-чакыр ягына сикереп чыкканлыгы ишетелде. Балалар, елашып, әниләре янына килделәр. Аның күзләре йомык иде, тузгыган сыек чәчләре кан белән укмашкан иде. Ул әле үлмәгән иде, ул әле ыңгыраша, кыймылдый иде һәм шул хәлендә дә балаларына үрелергә азаплана иде.

Ислам ислерәк иде — яланаяк, яланөс көе ул тышка чыгып йөгерде, күршеләре Фатиха апаларның тәрәзәләре каршысына килде дә: «Әни үлде... әни үлде»,— дип шыңшыды. Тәрәзә шакырга аның акылы җитмәде. Елаушыңшу тавышына Фатиха апа килеп чыкты, тол килене чыкты, һәм алар, куркуыннан рәтләп берни аңлата алмаган малайны җитәкләп, күршеләренә йөгерделәр.

Өйгә килеп керсәләр, өй эче ниндидер ят кешеләр белән, милиционерлар белән тулган иде. Бөтен җирнең астын өскә китереп алар нәрсәдер эзләп яталар иде.

Ә бер ярты сәгатьтән соң, тышта өй турысына машина килеп туктаганлыгы ишетелде. Ят кешеләр өстәл янына утырып чыш-пыш сөйләштеләр дә, нәрсәдер яздылар да, әниләрен машинага салып, каядыр алып киттеләр.

Ул чагында Ислам күп нәрсәне аңлап та җитмәде. Боларның барысы да аңа ничектер бик томанлы булып, төштәге шикелле генә булып тоелды. Әтисенең вагон талап, урланган мал белән эш итүе турында, әнисенең исә, көн-төн ызгыш-талашка һәм мондый шикле, хәтәр нәрсәләргә түзә алмыйча, кайдадыр кемгәдер әйтүе турында ул бары соңыннан гына белде.

Ярты айдан әнисе савыгып өйгә кайтты. Ләкин ул барыбер элеккечә тазарып, аруланып китә алмады. Ашауэчү ягыннан да, кием-салым ягыннан да моңарчы алар бернинди мохтаҗлык күрмәделәр. Шуңа күрә һәм шулай ук әтисе рөхсәт итмәгәнгә, әнисе беркайда да эшләмәде — йорт саклап өйдә генә ятты. Өчәүләшеп ачтан үлмәс өчен, аңа хәзер эшкә керергә туры килде. Мең төрле газап белән һәм төрле таныш-белешләр аркылы, бигрәк тә Фатиха апалар ярдәмендә, ул якындагы икмәк заводына капчык кырып торучы булып урнашты. Эше дә авыр булмады, тамагы да шунда үтте, җитмәсә, куенына кыстырып, балаларына да алып кайткалады.

Әкренләп-әкренләп алар шулай аякка бастылар. Әтиләрен беркем беркайчан исенә төшермәде. Алар бары аның көтмәгәндә кайтып керүеннән генә, шундый авырлык белән җайланган тормышны яңадан туздырып ташлавыннан гына курыктылар. Ләкин ата кеше кайтмады. Ул качкан иде. Белгән-күргән кешеләр соңыннан аның тотылуы турында, унмы, унбишме елга төрмәгә утыртылуы һәм кайдадыр тайгада качарга иткән чагында атып

үтерелүе турында сөйләделәр. Бу хәбәрне ишетеп беркем дә күз яше түкмәде, беркем дә кайгыга сабышмады. Шулай да ике-өч көн буена әнисе рәтләп берни сөйләшмәде-эндәшмәде, ә төннәрен йоклый алмыйча уфылдап чыкты. Яшь чагында алар икесе дә матур булганнар, икесе дә бер-берсен үләрдәй булып яратып торганнар. Ләкин бергә торуның икенче елында ук әтисе хатын-кыз белән чуала, эчә башлаган. Аннары тимер юлга эшкә кергән, һәм шулай итеп тормышлары бозыла башлаган...

Бозыла башлаган... бозылды... һәм аны инде беркем дә, берни дә төзәтә алмады. Иртән әниләре эшкә китте, энесе күршеләргә керде, ә ул — Ислам — мәктәпкә йөгерде. Мәктәптә өч-дүрт сәгать булды да, ашыгып, энесе янына кайтты. Салкын өйдә алар, туңып-бөрешеп, булса, каткан икмәк кимереп, булмаса, ач көе әниләрен көтеп утырдылар.

Ачка кибегеп, япа-ялгыз өй саклап яту тора-бара аларны туйдыра-җиләтә башлады. Аларның тышка, урамга чыгасылары килде, уйныйсылары килде. Урамда алар үзләрен иркенрәк сизделәр. Малайларга ияреп күршеләргә керделәр, җылындылар, туендылар, ә яз җиткәч, көннәр җылынгач, өйләренә кайтып керәселәре дә килмәде.

Чокыр-чакыр арасында ут ягып җылынып ятарлык, тегенди-мондый шуклык ясарлык тын, аулак урыннар җитәрлек иде. Җәй урталарында бакчаларда бәрәңге өлгерде, яшелчә өлгерде. Бәрәңге, яшелчә янына көннәрдән бер көнне йолкынган тавык-чебешләр дә өстәлде. Һәм, шулай итеп, малайлар әкренләп-әкренләп җиңел кәсепкә өйрәнеп киттеләр.

Әнисе бик кайгырды, тиргәде, үгетләде, алай да үтмәгәч, елап алды, авыр тормыштан һәм үзенең сәламәтлеге начар булудан зарланды. Көн саен диярлек укытучылар килде, шулай ук тиргәделәр, үгетләделәр, әмма малайларга бернәрсә дә тәэсир итмәде. Ә бераз вакыттан иске шпаллардан теркәп салынган мунча сыман куышка пыр тузып күршеләр керә башлады, усал, кырыс чырайлы милиционерлар килә башлады. Берсенең төнлә, сарай ишеген ватып, тавыкларын алып чыкканнар, икенчесенең баудагы керләрен урлап киткәннәр, өченчесенең утынлыктагы балтасы югалган яисә алмагачын ботарлап чыкканнар... Болай да тынгысыз чокыр-чакыр арасы ыгы-зыгы килде. Барысын да алардан күрделәр, «ут күз» Исламнан күрделәр. «Атагыз үтерә алмады, хәзер инде сез үтерәсез»,— диде әниләре, кайгысыннан, оятыннан нишләргә белмичә.

Шулай җәй үтте, көз үтте. Берничә мәртәбә аларны милициягә чакырдылар, куркыттылар-өркеттеләр, хәтта ябып та яткырдылар, ләкин тотучы да, күрүче дә булмагач, берни эшләтә алмадылар. «ФЗӨгә кер ичмасам, тамагың да туяр, киеме-салымы да булыр»,— диде әнисе, елап. Кыстый торгач, теңкәсенә тия торгач, Ислам риза булды. Әнесе берүзе калды. Ләкин ул абыйсыннан да уздырып җибәрде. Бик яшь булуына да карамастан, ниндидер шома малайларны ияртеп, бөтен чокыр-чакырның астын өскә китерде, атналар буе күзгә-башка күренми башлады.

ФЗӨдән Ислам заводка керде, токарь булып эшли башлады. «Ярый әле, монысы юлга салынды»,— диде әнисе, куанып. Ләкин аның юлга салынуы озакка бармады. Сигез сәгать буена станок янында басып тору аңа дөньяда иң авыр газапларның берсе булып тоелды. Үз эшенә ул җирәнеп карады. Юк, алай яшәргә мөмкин түгел иде, ничектер икенче төрлерәк итеп яшәргә кирәк иде, көч түкмичә генә, бил бөкмичә генә яшәргә кирәк иде. Аның күз алдына чокыр-чакыр маҗаралары, тәмле төтен исе, пешкән бәрәңге, пешкән тавык исләре килде. Кайчан гына булып узган шул күңелле чакларны ул уфтанып сагынып куйды. Шулай да андый тормышка инде яңадан кире кайту мөмкин түгел шикелле тоелды.

Җиңел кәсеп юллары, әлбәттә, монда да бар иде. Һәм, җае туры килгәндә, ул аптырап, куркып тормады. Ләкин аны тоттылар. «Әллә бер мин генә? Барысы да урлаша»,— диде ул, үз-үзен акламакчы булып. Аның эшен зурга җибәреп тормадылар, кызганып, бары эшеннән генә чыгардылар.

Берничә айдан аны армиягә алдылар. Анда ул шоферлыкка өйрәнде. Бу эш аңа ошыйрак төште, һәм, яңадан Казанга кайткач, ул токарь булып түгел, бәлки, шофер булып урнашты. Ул тимер юл буендагы бер сәүдә базасыннан товар ташый башлады.

Армиядән кайтып бераз вакыт торгач та, әнисе үлде. Камил төрмәдә иде. Шпаллардан теркәлгән мунча сыман куышта ул бердәнбер хуҗа булып калды. Машинасы белән кайткан саен, ул машина төбенә әле аннан, әле моннан тактадыр-мазардыр салып кайткалады һәм озакламый ике тәрәзәле мунчаны зурайтып җибәрде, киңәйтеп җибәрде, тирә-ягын биек койма белән тотып алды. Кайчандыр чокыр-чакыр араларында, чүплек башларында ач-ялангач каңгырап йөргән Ислам менә дигән иттереп яши башлады.

## XII

Әйе, бик шәп яшәде Ислам, бик иркен яшәде, үзе теләгәнчә типтереп, дөньяның артына тибеп яшәде.

Тик менә өйләнгәч кенә эшләре гел кирегә тәгәри башлады. Дания баштарак бик күндәм, буйсынучан булып күренсә дә, бергә торып киткәч, бик усал, бик явыз булып чыкты. Көнләште, юк-бар гаеп такты. Анысы гына җитмәгән, эшләгән урынга барып әләкләшеп йөрде, табышланып йөрде, ә инде берәр хатын-кыз белән бергә булганын ишетә-нитә калса, ду кубып тиргәшергә, талашырга тотынды. Андый чакта ул аңа әллә ни каршылык күрсәтмәде, әмма инде эчеп-исереп кайттымы, барысы өчен үч алмакчы булып, озын телле усал хатынын үтергәнче тукмап ташлады. Мондый ызгыш-талаштан соң, гадәттә, өй эчендә беркадәр вакытка тынлык-иминлек урнашты, ләкин ике-өч көннән соң җил-давыл, өермә-гарасат көтмәгәндә тагын да ныграк көч белән, тагын да ныграк усаллык белән калкып чыга торган булды.

Хәзер инде ул машина белән үз йортына бик сирәк кайтты, тегеләй-болай кулга кергән нәрсәләрен Даниягә түгел, бәлки, бүтәннәргә ташыды. «Барысын да барып әйтәм, билләһи газим, бөтен караклыгыңны барып әйтәм!» — дип янады Дания, аеруча нык тилергән чакларында. «Әйтер бу аждаһа, әйтер... Мине дә эти кебек итәрләр болар»,— дип уйлады Ислам, чын-чынлап куркуга төшеп.

Баладан соң Дания бөтенләй ябыгып, ямьсезләнеп калды; битенә, маңгаена ниндидер таплар чыкты. Баланы Ислам яратмады, бала анасы Данияне тәмам күралмас дәрәҗәгә җитте. Йортыннан, хатыныннан ул торган саен ныграк суынды, торган саен ныграк читләште, атнасына хәтта икешәр-өчәр көн кайтмаган чаклары булды. Елап, баласын күтәреп Дания анда барды, монда барды, акча бирми, диде, аерылышам, судка бирәм, диде.

Аннан-моннан кергән нәрсәләрне итәк астыннан шудырып ятучы Сәхибә көтмәгәндә милициягә эләкте. Җеп очының берсе Сәхибәдән Исламга да килеп тоташа иде. Тишә-нитә күрмәсен дип, агай-эне кайгыга калды. Тәвәккәлләү өчен бу бик уңай сәбәп булды. Башы исән чакта аңа ничек тә Казаннан таю ягын карарга кирәк иде. Һәм көтмәгәндә моның җае да чыкты. Ул патриот булып язылды.

Аның теләгенә беркем каршы килмәде, киресенчә, аның «патриотлыгын» барысы да хуплап каршы алдылар — кайбер олы абзыйлар аны анда бик үк яратып

җиткермиләр иде. Хәтта Дания дә бу хәбәргә сөенеп бетә алмады: бик шәп, диде, башкайларым котыла икән син зимагурдан, диде. Алтаена түгел, Каф тау артына олак, диде, эзеңә көл сибеп калырмын, хәер биреп калырмын, диде. Ләкин китәр вакыт җиткәч, Ислам чемоданнарын күтәреп ишеккә юнәлгәч, кинәт чәчен-башын тырнап еларга, иренең муенына, беләгенә сарылып еларга тотынды. Ислам аны ачу белән төртеп җибәрде дә, ишекне шапылдатып чыгып йөгерде.

Вокзалда аны елмаеп Мәрьям каршы алды.

Яңа җирдә алар яңа тормыш корып җибәрмәкче булдылар. Ләкин кая соң ул яңа тормыш? Кая ул көтелгән, вәгъдә ителгән яңа тормыш, шәп тормыш? Шушы суык, пычрак вагонмы әллә? Көне буе эт урынына җигелеп йөрүме? Ул бит моның өчен килмәде. Ул ниндидер бүтән төрле тормышны күз алдына китерде, Казандагы кебек үк майлы, төшемле тормышны, әмма Казандагыга караганда да иркенрәк, күңеллерәк тормышны күз алдына китерде. Юк, юк, Мәрьям белән бергә булуны гына ул яңа тормыш, шәп тормыш дип уйламады!

Монда килеп бер-ике төн кунгач та, ул үзенең бик нык алданганлыгын, ахмакларча алданганлыгын аңлады. Ул инде моннан да тизрәк ычкыну турында, кая да булса бүтән җиргә — йортлар, кешеләр булган җиргә китеп урнашу турында уйлаштыра башлады. Ләкин шул ук вакытта аны нидер җибәрми торгандай булды. Нәрсә ул «нидер»? Әлбәттә, Мәрьям! Дөресен әйткәндә, ул алып килмәдемени аны монда? Әйе, ул алып килде... аның өчен килергә туры килде. Ул Дания түгел. Аның белән тәмугта да күңелсез булмаячак.

«Чынлап та, әллә китәргә инде аның янына?»— дип уйлады Ислам. Ни пычагыма шушы как тактада аунап ята соң әле ул? Ни пычагыма үз-үзен шулкадәр газаплый? Үзенә күрә бүлмәсе бар, йомшак урыны бар, ашарга-эчәргә әзер. Шуннан башка ни кирәк аңа тагын?! Автомашиналар кайтканчы, мастерскойга урнашып торырга була. Кайда да кеше кирәк. Таран җибәрер, Таран җибәргәч, директор да каршы килмәс, әле эш ныклап башланмаган да. Ә Мәрьям сөенеп бетә алмас. Дания белән чагыштырганда, ул беренче сорт, экстра! Шундый хатының була торып, дуңгыз кебек пычрак вагонда аунап яту үзе оят. Туктале, әллә соң хәзер үк китәргәме?

Ул урыныннан кузгалып куйды, озын аякларын сәкедән идәнгә төшерде дә, бик сирәк очракларда гына була торган бер күңел йомшаклыгына бирелеп, уйлана-уйлана торып утырды. Далага күченеп килгәннән бирле,

аның әле беркайчан да Мәрьям турында болай уйланганы да, аны шулай сагынганы да юк иде бугай.

Ләкин озаграк уйлана торгач, ул Мәрьямнең кечәге кыланышларын күз алдына китерде.

«Берсеннән котылдым, икенчесенә тотыласым юк!» — диде ул аннары, күңел йомшаклыгын тәмам кысрыклап. Әлерәк кенә кызганып, яратып уйлаган хатынга карата бу минутта ул читләшү хисе, хәтта дошманлык хисе тойды. Мондый читләшү хисе, дошманлык хисе бераздан икенче нәрсәгә, зуррак, киңрәк нәрсәгә күчте, үзен алдаган, үзен шулай җайлы-майлы эшен ташлап китәргә, менә шулай салкын вагонда аунап ятарга мәҗбүр иткән бөтенләй икенче кешеләргә, икенче сәбәпләргә күчте, һәм ул күренмәгән шул ниндидер бик күп дошманнарына янап, юк, бер мәртәбә алдадыгыз, икенче мәртәбә алдый алмассыз! диде.

## XIII

Шунда ул янә икенче бер нәрсәне исенә төшерде. Кулларын кесәсенә тыккан килеш, ул идән уртасында туктап калды. Ачулы-уйчан кыяфәте шундук үзгәрде, йөзенә омтылыш һәм тәвәккәллек галәмәте бәреп чыкты. Күп уйлап тормыйча, ул бүлмәдән үк чыгып китте.

Рация буенча Таран кем беләндер сөйләшеп утыра иде.

— Башланды! Отчет сорыйлар. Әле рәтләп эшкә дә тотынмаган, инде җанны да кыя башладылар,— диде Таран, трубканы аппаратка куеп.

Ислам, өстәлнең бер башында нидер язып-сызып утырган Димкага карады да:

— Әллә үлчәмәдең?— диде.

— Үлчәдем!— диде Димка, сизелеп торган бер кирелек белән.

— Көне буе чабып йөрде бит ул,— дип куйды Таран, учетчыны яклап.

— Йөрмәсение! Беткәнмени бүтән кеше.

— Беренче көнне була инде ул. Ярар, эшләсен,— диде Таран, һаман шул ук яклаучан-килешүчән бер йомшаклык белән.

— Кем отчет сорый?— диде Ислам.

— Районнан сорыйлар, имеш. Янәсе, беренче көнне күпме сөрелгән — шуны беләселәре килә. Районнан өлкә сорый, өлкәдән Алма-Ата, Алма-Атадан Мәскәү... Менә шулай бер-берсен кыздыралар, ә таякның юан башы менә безгә төшә. Җә, исәпләп бетердеңме инде, писер?

— Нәрсәсен исәплисең инде аның?— диде Димка. Ул бөтенләй икенче нәрсә белән мавыгып утыра иде, ахры-

сы.— Ислам да Һарун, аннары Илгиз беркадәр... Күп булса, ун гектар булыр барысы.

— Ун гектар икән ун гектар!— диде Таран, шелтә белән.— Нәрсә аны баядан бирле башымны катырып утырасың? Исәпләнмәгән әле, янәсе. Ярый, без аны егерме гектар итәрбез. Аларга сан кирәк, сан! Калганына алар төкереп тә бирми.

— Ничек инде ул алай, Глеб Семеныч?— диде Димка, башын калкытып.— Егерме түгел, ун да юк әле анда, үлчәп карасаң. Каян алып язармын мин аны соңыннан?

— Әнә күрәсеңме?— диде Ислам, түшәмгә ымлап.— Шунда кара да яз, кара да яз!

— Бик дөрес,— диде Таран.— Нәрсә шыңшып утырасың әле син? Ни кушалар, шуны яза бир. Кем кушты? Таран кушты! Җавап сиңа әзер. Ә мин инде җавабын табармын, кайгырма.

— Нинди җавап ул, Глеб Семеныч!— диде Ислам, гаҗәпләнгән булып.— Кем килеп тикшереп йөрсен аны?!

— Егерме! Егерме!— дип кычкырды Таран трубкага.— Төнге смена эшли. Эшли, дим! Хәзер үзем барам. Яннарына барам хәзер. Эшлиләр, барысы да эшлиләр.

Ислам, бригадирның Горшков белән сөйләшүен аңлап алды да, колагына пышылдап:

— Әйт шуңа икенче авыз ачмаслык итеп! Нәрсә юкка төпченә...— диде.

Сөйләшеп туктагач, Таран, күрәсең, Ислам коткысына бирелеп, директорны сүгәргә тотынды.

— Инженер, имеш! Төгәллекне ярата, имеш! Монда сиңа завод түгел, сәгатьле эш түгел. Бик җиңел генә уйлый: аңа хәзер менә чыгар да сал, әйт тә бир! Юк, булмый ул алай! Кайчан телибез, шунда эшлибез, шулай да үз эшебезне белеп эшлибез. Сезнең ише инженерларны күп күргән инде без.

Көндез директор белән булган очрашуны, аның алдында үзенең җиңелергә мәҗбүр булу хурлыгын ул инде онытып бетергән иде, ләкин «инженер»ны сүгә башлагач, аның күңел ярасы яңадан кузгалды. Ул лачт иттереп идәнгә бер төкерде дә, усалланып, кашларын җыерып урыныннан торды һәм тамак төбеннән буылып, кысылып чыккан гыжылдавык тавыш белән:

— Бармы?— диде.

— Юк шул, бер тамчы да калмады, Глеб Семеныч,— дигән булды Ислам.

— Алдыйсың, сукин сын!— диде Таран.— Атаң өчен бер тамчы да калдырмагач, ни пычагыма кирәк син!

— Валлаһи, Глеб Семеныч,— диде Ислам, ант итеп.

Икесе дә, бер-берсен сынаган сыман, тавыш-тынсыз гына карашып тордылар.

— Тегендә бар да соң...— диде Ислам, ниһаять, көрсенеп.

— Чынмы?!

— Чын булгач та, монда түгел бит.

— Ах, сукин сын! Ах, оратор! Ах, профессор!— диде Таран, Исламны кочаклап.— Хәзер машина чакырабыз. Авария! Ашыгыч ярдәм кирәк! Утыр да кит. Шофер үзебезнеке... Нәрсә, акча кирәкме? Акча бездә бер капчык!

Бригадирның мондый тәкъдименә Ислам карышкан булып, ык-мык итеп утырган булды, ләкин Таран аның сүз белән әйтелгән ризалыгын сорап та тормады — шундук аппаратка тотынды һәм, чыннан да, бик ашыгыч эше бар кеше сыман, трубкага кычкырырга тотынды.

Ә бер ярты сәгатьтән бригадага техник ярдәм машинасы килеп җитте.

## XIV

Караңгы күк читенең иң әүвәл Иртыш ягы ачылды. Күзгә күренмичә, әмма искиткеч бер өлгерлек-җитезлек белән, каяндыр, бик еррактан, әйтерсең бик тирән җир астыннан чатнап торган сыек-салкын яктылык күтәрелә башлады. Яктылык көчәйгәннән-көчәя барды, өскә, югарыга күтәрелә барды, як-якка җәелә барды һәм берзаман бөтен шәрекъ ягын биләп алды. Күп тә үтмәде, күк йөзенә, җир йөзенә җан биреп, ямь биреп, сыек-салкын аксыллыкка кызгылт-алсу нурлар кушылды.

Көн туды. Далада яңа көн туды.

Көн туганын хәбәр итеп, яшел үлән керфекләрен тирбәлдереп, җир өстеннән йомшак кына, көчсез генә җил йөгереп үтте. Җил артыннан кошлар уянды, җәнлекләр-җанварлар уянды. Уянды һәм шундук һәркем үзе эшенә тотынды. Таңны мактап, кояш-нурны мактап, югарыда тургайлар сайрады, аста, җир өстендә, чыр-чу килеп шат чыпчыклар базар ачып җибәрделәр.

Көн туды. Далада яңа эш көне туды.

Һарун йокыдан кичәгегә караганда күтәренкерәк күңел белән торды, бөтен тәнендә ашкынучан көч-дәрт ташып торганлыгын тойган хәлдә торды. Кичәгенәк әле алда нindидер билгесезлек ята иде, бүген исә аның өчен бөтенесе ачык, аңлаешлы иде, бөтенесе үз урынында иде.

Тәзкирә, төне буе Таран вагонында «мәҗлестә» булса да, нишләптер ашны бүген вакытында өлгертте. Көндезге сменага китәсе кешеләр ашап туюга, даладан бер-бер артлы тракторлар кайта башлады. Шундук сораштыру

китте, төпчену китте. Күп тә үтмәде, даладагы төнге яңалыклар бөтен бригадага мәгълүм булды.

Бары тик бер генә нәрсәне беркем дә белә алмады. Беренче трактор кайтып җитүгә инде шактый вакыт узып киткән булса да, нишләптер Белугин һаман күренмәде. Һарунның сабырлыгы кимегәннән-кими барды. Әледән-әле ул басу ягына карап алды, төнлә эшләгән кешеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә барды, бер үк сорауларны кабатлады: соңгы мәртәбә аны кайчан күрдегез, диде, кайда күрдегез, диде; бер-бер җирдә батып-нитеп ятмый микән, диде. Ләкин беркем дә ачык кына җавап бирә алмады.

Һарун нәрсә уйларга да белмәде. Башкаларның инде әзерләнеп бетүләрен, ә үзенең әле һаман селкенеп йөрергә мәҗбүр булуын күреп, аның эче пошты. Күңеленнән ул Белугинны сүкте, үз-үзен сүкте. Трактор аныкы иде, аңа беркетелгән иде. Белугин эшләргә тиешле трактор исә моннан ике йөз чакрым чамасы ераклыктагы Аксу станциясенә йомыш белән киткән иде. Һарунның алмашчысы Вәгыйзь дә шунда станциядә иде. Алар аннан кайтып җиткәнче, Һарунга Белугин белән эшләргә туры киләчәк иде. «Аны бөтенләй тракторга якын китерәсе калмаган»,— дип уйлады ул, үкенеп.

Белугинның кайтмавына бүтәннәр дә хафалана башладылар.

— Эчмәгән дә иде бит, исереп, алай-болай булган дисәң...— диде Тәзкирә.

— Таранга әйтергә кирәк,— диде кемдер.

— Таран исерек,— диде Димка.

— Исерек?!

— Тагын да!

— Каян ала ул аракыны?

— Менә сиңа бригадир! Әйтәм күренми...— диештеләр яшьләр, ризасызлык белән.

— Йоклап калгандыр әле берәр җирдә андый черек баш,— диде Ислам.

— Бүре ашагандыр!— диде Илгиз, хихылдап.

— Төне буе бергә эшлә дә, тракторы-ние белән кеше хәтле кеше югалтып кайт, имеш!— диде Тәзкирә.

— Ул далада кеше түгел, әллә нәрсәң югалыр,— диде Андронов.

Менә техник карау да бетте, тракторлар, хәл алып, көч җыеп, яңадан басу ягына кузгала башладылар.

— Әйдәгез, утырыгыз да... киттек!— дип кычкырды Ислам, бик эшлекле кеше сыман, ашыгып.— Монда лыгырдап эш чыкмас, барып карарга кирәк.

Аның шулай катгый төстә сөйләнүе, Белугинның кайтмый калуына кемнәрдер мондагылар — «лыгырдаучылар» гаепледер сыман итеп сөйләнүе Һарунның җенен котыртып куйды, ләкин шул ук вакытта ул Исламның хаклы икәнлеген дә танымый булдыра алмады. Монда көтеп торуда, әлбәттә, мәгънә юк иде, тизрәк басуга китәргә, югалган кешеләрне, югалган тракторны эзләп табарга кирәк иде.

Илгиз тракторын кабызгач та, ул, сорап-нитеп тормыйча, аның янына кабинага менеп утырды.

«Ә Фәридә?»— диде ул кинәт үз-үзенә. Иртәнге ыгы-зыгыда, трактор өчен, Белугин өчен борчылган-пошынган арада ул ничектер аны исеннән үк чыгарып ташлаган иде. Хәер, эш монда истән чыгаруда гына да түгел иде, Фәридә нишләптер аның күзенә дә чалынмаган иде. Ул, Фәридәне эзләп, тәрәзә аша тирә-якка күз йөртеп чыкты, аннары артына каерылып карады. Шул чакны ул «С-80» тракторы янында үзенең прицепщигын күреп алды. Ул күргәндә, Фәридә, кирәкми дигән сыман, баш чайкый иде, Ислам исә, аны үз янына чакырып, кабинадан кул суза иде.

Һарунның болай да караңгы йөзе тагын да ныграк караңгыланып китте. Белугинга карата булган ачуга, гомуми кәефсезлеккә тагын икенче бер кәефсезлек өстәлде. «Аңа шул ихахай да михахай гына булсын! Эш турында уйлап та бирми, ялкау!»— дип уйлады ул, кызга карата бу минутта нәфрәт шикелле бер нәрсә тоеп.

Ислам алданрак китте. Һарун гына түгел, Илгиз дә, Мансур да, бүтәннәр дә Фәридәнең киң, биек кабинада утырып барганлыгын, «Ислам абыйсы» белән нәрсә турындадыр көлешеп, куанышып барганлыгын күреп калдылар. Илгиз, башын салындырып, моңаеп утырган Һарунга күз ташлап алды да, авызын ерып көләргә тотынды.

— Пешмәгән син, Һарун!— дип кычкырды ул аның колак төбендә генә.— Күрдеңме, «Победа»га утырып баралармыни Казан урамнарыннан! Шундый кызым була торып, шуны Исламга биреп тораммы соң? Юк, пешмәгән син!..

— Син бик пешкән инде!

— Минме? Миңа эләксә, уч төбендә биетәм мин аны!

— Мактанчык син!— диде Һарун, кырт кисеп. Илгизнең шундук авызы капланды. Ул хәтта җавап кайтарырга да аптырабрак калды һәм беркадәр вакыт берни эндәшми барды.

— Карале, әйдә, алышабыз?— диде ул кинәт, дусларча

тонга күчеп.— Мин синнән болай да көнләшеп йөрим, шундый шәп кыз!.. Бер дә күршегә кереп торасы юк, кабинаңа утырт та, кочаклашып, үбешеп тик йөр!

Һарунның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Күршесенең оятсыз йөзенә кундырудан ул үз-үзен чак-чак тыеп калды. «Дуңгыз!»— дип уйлады ул, тешләрен кысып.

— Чынлап, әйдә, алышабыз!— диде Илгиз.

— Синең күңелдә гел шул гына!— диде Һарун, нәрсә әйтергә дә белмичә.

— Синең күңелдә нәрсә соң?

— Трактор!— диде Һарун, үзе дә сизмәстән. Илгиз бөгелеп-сыгылып, әллә нинди тавышлар чыгарып көләргә кереште.

— Бигрәк беркатлы син... трактор!.. Уф... Ха-ха! Тракторга гашыйк!

— Синең кебек катлаулы булып булмады инде,— диде Һарун, оятыннан җир тишегенә керердәй булып.

— Җә, килештекме?— диде Илгиз, көлүеннән туктап.— Мансур сиңа, Фәридә миңа!

«Мансур белән сүз берләшеп куйганнар,— дип уйлады Һарун.— Миннән көлмәкче булалар. Юк инде, күп көлдегез!»

— Булдымы?— диде Илгиз, бәйләнчекләнеп.

— Ник аның турында минем белән сөйләшәсең?— диде Һарун.— Башта син аның үзе белән сөйләш... алай бик батыр булгач!

## XV

Кичә төнлә Белугинның бөтенләй диярлек йокысы туймады. Шуның өстенә тагын көннең-көнозын далада булырга туры килде. Төштән соң бераз йоклап ял итеп алырга тырышып караса да, булдыра алмады: баш очында әле берсе, әле икенчесе шауларга тотынды; анысы гына җитмәгән, былагайланып өстеннән юрганын тартып ачтылар; йокларга тырышып-тырышып та берни барып чыкмагач, соңыннан үзе дә кул селтәде, «ярар, бер төнгә йокламыйча да үлмәм әле» диде.

Җылы кабинада йомшак урында тирбәлеп бару баштарак аңа бик күңелле, бик рәхәт булып тоелды. «Сөрү дә сөрү диләр, ни авырлыгы бар соң моның!»— дип уйлады ул, исе китеп. Беркадәр вакыт ул шулай күтәренке күңел белән барды. Ләкин бертуктаусыз гүелдәгән мотор тавышыннан, җиңелчә газ исеннән, аякларга бәреп торган тимер җылысыннан сиздермичә генә аның тәне

ойый башлады, күз кабаклары йомылып-йомылып китте; идарә тимерләрен кысып тоткан куллар искәрмәстән бушап-бушап калды, һәм трактор, дилбегәне йомшартуны көтеп кенә барган көйсез айгыр кебек, шундук уңгасулга каерылды.

Ә берзаман күз йомылу, куллар йомшау, күрәсең, берничә секунд кына түгел, бәлки, берничә минут дәвам иткән иде — шулай ничектер онытылып киткәннән соң кисәк кенә күзләрен ачып караса, ул үзенең бөтенләй ят җирдән, буразнасыз-нисез җирдән сөреп барганлыгын шәйләп алды. Тракторын туктатты да, сикереп җиргә төште, күзләрен угалаштыргалап прицепщигы янына килде. Ни күзе белән күрсен, прицепщик Коля да, штурвалын кочаклап, гыр-гыр йоклап утыра иде!

Белугин сүгенеп, тарткалап Коляны уятты да югалган буразнасын эзләргә тотынды. Ары сугылды, бире сугылды, ләкин каты җирдән башка, күн итекләренә йомшак кына булып сугылучы, уралучы кылганнардан башка аяк астында бүтән берни таймады. Курыкканга куш күренә дигәндәй, аның күңеленә кинәт шом төште. «Кай төш соң бу?— дип уйлады ул, аптырап.— Әллә адаштыммы?» Күңеленә шундый шикле уй килгәч, аңа чыннан да шулайдыр шикелле булып, чыннан да ул адашкандыр шикелле булып тоелды.

Үзенең кайдалыгын ачыграк аңларга тырышып, ул, тирә-яктагы караңгылыкка, берни әйтми-сөйләми торган шомлы, мәкерле караңгылыкка текәлгән көе, бераз вакытка тынып калды.

Нәкъ шул чакны якында гына ниндидер ят, ямьсез тавышлар ишетелгәндәй булды. Аннары караңгыда, берүзе гөрелдәп утырган трактор ягында, фаралардан төшкән ут яктысында кинәт ялт-йолт итеп ниндидер яшькелт нокталар күренеп китте. Мондый парлы-парлы яшькелт утларны Белугин баягынак та күргән сымак булган иде, ләкин ул чакта алар аңа йокы баскан күзгә генә шулай күренәдер шикелле тоелган иде. Хәзер исә аның йокысы качкан иде, күзләре ачык иде, монда инде бернинди күзгә күренү дә булырга мөмкин түгел иде. Белугинның йөрәге жу итеп китте, аяклары үзеннән-үзе атламас булды һәм яшен тизлегендә аның күңеленә «Бүреләр! Бүреләр чолгап алган!» дигән бер коточкыч уй килде. Караңгы, тын даланы яңгыратып, ул, бар көченә:

— Коля-а!— дип кычкырып җибәрде.

— Нәрсә-ә?— диде йокымсыраган Коля, иренеп кенә.

Белугин, камалуда үзе генә түгеллеген аңлап, тизрәк прицепщигы янына ашыкты.

— Бүреләрне күрдеңме? Тирә-якта бүреләр йөри!— диде ул, тыны бетеп.

— Пүреләр?— диде чуваш егете, беркадәр кызыксыну билгесе күрсәтеп.

Ул әле һаман йокысыннан арынып җитә алмаган иде.

— Син күрмәдеңмени, күсәк? Әле генә ут яктысында тешләрен ыржайтып торалар иде,— диде Белугин, ялганлаганын үзе дә сизмәстән.— Караңгыда берсе чакчак кына миңа орынып китмәде.

— Пулмас ла,— диде Коля, шикләнеп.— Күзләре яшел уттай янамы?

— Әйе, әйе!— диде Белугин.— Фонарь кебек, трактор фаралары кебек!

— Төлкеләр ич алар,— диде Коля, гамьсез генә.

— Төлкеләр? Төлкенең күзе яшел буламыни?

— Төнлә шулай яшел пулып күренә ул... Ут яктысында. Мин инде әллә ничәне күрдем, арттан да килеп чыгалар, яннан да...

Мондый сүз ишетеп, Белугин тынычлангандай булды, ләкин аның хәзер һич тә Коля алдында куркак булып, төлке белән бүрене дә аера белмәүче надан булып каласы килмәде, һәм ул, үзенең ялган сөйләгәнлеген белгәнгә күрә, үзенең хаклыгына тагын да ныграк ышанган бер кирелек белән:

— Юк, мин күргәне төлке түгел, бүре!— диде.— Бүре белән төлкене дә аермаска мин!..

— Пүресе дә пулыр, арысланы да,— диде Коля, сүз көрәштереп тормыйча.

Аның чын күңелдән ышануын күреп, Белугинның тәмам күңеле күтәрелеп китте.

— Әйдә, мен минем янга, туңгансыңдыр,— диде ул Коляга.

Коля карышып тормады — ул инде чыннан да шактый күшеккән иде. Бер кабинада икәү булгач, аларның икесенә дә күңеллерәк булып китте. Икесе дә тәмәке кабыздылар да кузгалып киттеләр, уңга борылдылар һәм, бер илле метр чамасы җир киткәч, үзләре бураznасына барып чыктылар. Белугинның күңеле тәмам үз урынына утырды. Трактор, күңелле үкереп, тирбәлә-тирбәлә, бураzна читеннән алга шуышты.

— Ваня, синең урынга утырып парыйм әле?— диде Коля.

— Монда утыру өчен минем кебек курс бетерергә кирәк,— диде Белугин, эре генә.

Коля бүтән сорамады. «Ярамый икән, ярамый. Анысы ярамаса, монысы ярыйдыр»,— дип уйлады ул һәм

башын кабина почмагына терәде дә, шундук гырылдарга да тотынды. Белугин баштa бер сүз дә әйтмәде, әмма янында гына йоклап барган кеше тәэсирендә бераз вакыттан аның да күз кабаклары йомыла башлады.

— Тор, күсәк. Нәрсә эш вакытында йоклап ятасың?— диде ул, Коляны уятып.

— Нишләргә соң?— диде Коля, йокы аралаш мыгырданып.

— Нишләргә? Бар, сабаныңны кара!

— Туктат,— диде Коля.

Белугин тракторны туктатты, сабан карарга дип, Коля артыннан үзе дә төште. Салкында, каты җирдә бераз селкенгәләп алгач, аның тәне җиңеләеп киткәндәй булды. Алар тагын тракторга менеп утырдылар, тагын кузгалып киттеләр. Ә берничә минуттан соң Белугинны яңадан йокы газаплый башлады, һәм ул, түзәр тәкате калмыйча: «Барыбер черем итеп алмый булмас»,— дип уйлады.

— Кил, утыр,— диде ул, ниһаять, үз урынын Коляга биреп.— Мин ял итеп алам. Булмый... Кара аны, күсәк, күзеңне дә йомма!

Белугин кебек «курс бетермәсә» дә, шулай да Коляның трактор гына йөртерлек чамасы бар иде. Тракторны ул тиешле эздән дөрес, туры алып барды. Утырган урынында ул хәтта кымшанырга да курыкты һәм бер генә секундка да күз карашын буразнадан, буразна читеннән барган гусеница тимерләреннән читкә юнәлтмәде.

Шулай бара торгач, ул берзаман сәгатенә күз төшереп алды: Белугин йокыга киткәнгә инде бер сәгать чамасы вакыт узып бара иде. Ул Белугинны уятмаска булды. Шуннан соң ул тракторын туктатты да, артык шауламаска, тавышланмаска тырышып, җиргә төште, төрәннәрне чистартты, яңадан үз урынына менеп утырды һәм беркем ярдәменнән башка, беркем күзәтүеннән башка эшли алуына, шулкадәр көчле-куәтле машинаны дала ярып, төн карасын ярып каядыр алып бара алуына әйтеп бетермәслек горурлык хисе тоеп, яңадан кузгалып китте.

«Таңга кадәр сөрим дә сөрим. Уянып киткәч, исе китсен. Анда инде сүксә дә перни түгел»,— дип уйлады ул үзалдына.

Һәм ул һаман сөрүендә булды.

Буразна башына ул бөтенләй искәрмәстән барып чыкты. Бервакыт күзләрен ныграк ачып җибәргән иде, алда бернинди буразна юклыгын, бары тик сөрелмәгән җир кисәге генә булуын күреп алды. Ул гаҗәпләнеп китте

һәм Белугин шикелле бураздны югалттым, ахрысы, дип уйлады. Ләкин шунда ул үзенә кадәр сөргән Һарунның әйләнеш ясап борылган эзен күреп алды. Ул үзендә җиңү шатлыгы шикелле бер җиңеллек тойды. Ипләп кенә корыч машинаны уңга борды. Аның иң курыкканы шушы борылыш иде, кисәк кенә борып, сабанны каплатмасам ярар иде, дип, ул инде баядан бирле баш ватып килә иде. Исән-имин борылып, икенче як бураздага кергәч, аның куанычы тагын да арта төште.

Хәзер инде сөрә торган җир таныш иде, хәзер инде тракторны ни өчендер үзеннән-үзе дә кайта алыр шикелле иде.

Һәм бер-ике чакрым чамасы җир китеп, күзенә мендәр чүбе керә башлагач та, ул, күп уйлап тормастан, тормозга басты, тракторны туктатты, газны кысып куйды һәм инде шулкадәр күп җир сөргәч, үз-үзен ял итәргә хаклы санап: «Хәзер менә черем итеп алырга да пула!»— дип уйлады.

## XVI

Колак төбендә генә ниндидер ят тавыш ишетеп, Белугин да, Коля да кинәт уянып киттеләр һәм, күрәсең, кайда икәнлекләрен онытып, тиз генә сикереп тормакчы булдылар. Берсенең түбә капкачы бәрелде, берсенең маңгае бәрелде, һәм икесенең дә күзләре шар булды: инде төн узган иде, тимер кабина эче ләхет кебек тар, кысан иде, ә каршыда, трактор янында, аждаһадай булып Һарун басып тора иде!

Алар аны-моны искәреп өлгергәнче, Һарун кабина ишеген ачып та җибәрде, тиле бер көчкә буйсынып, иртәннән бирле күңелен ярсыткан үртәлүгә бирелеп, Белугинны сырмасыннан эләктереп тә алды; эләктереп алды да, җилтерәтеп, капчык кебек итеп җиргә сөйрәп тә төшерде. Коля, эшнең болайга китүен күреп, тизрәк читкә тайпылды.

— Шулай сөрәсеңме син?!— дип кычкырды Һарун.— Сине анда көтеп яталар...

Белугин өчен бу шундый көтелмәгән нәрсә булды, ул әйтерсең кинәт телсез калды: үзен аклап ни дә булса әйтә дә алмады, каршылык та күрсәтә алмады.

— Нәрсә, күсәк... Ник дулыйсың?— диде ул, ниһаять, исен-акылын җыеп.

— Дулармын мин сиңа!— дип кычкырды Һарун, торган саен батырая барып.— Икенче якын киләсе булма трактор янына, ялкау шамбы! Синең аркада никадәр вакыт әрәм булды...

Ул шулай тузынды-тузынды да, дөбер-шатыр килеп,

тракторын карарга тотынды. Тракторын исән-сау күргәч, ул әкренләп сүрелә башлады.

Нәкъ шул чакта ул тракторга якын килергә курыккандай бер читтәрәк басып торган Фәридәне күреп алды. Басылып җитмәгән ярсуы кинәт гөлт итеп кабынып китте һәм шул ук секундта аңа бөтенесенә дә бары ул гына — Фәридә генә гаепледер шикелле тоелды.

— Нәрсә катып калдың?— диде ул, тупас кына, кызга эндәшеп.— Әллә аю биетәләрме? Әйдә, чистарт сабанны...

Фәриданең чыннан да курку катыш аптырау һәм кыюсызлык белдергән кыяфәте шундук үзгәреп китте. Күз карашы томанланып, мескенләнеп калды, тагын берәр катырак сүз әйттең исә, шул күзләрдән мөлдерәп яшь тамчылары агып чыгар төсле тоелды. Урыныннан кузгалырга йөрәге җитә алмагандай, ул беравык тын гына басып торды да, тамагына килгән күз яшьләрен йотып, иреннәрен тешләде һәм соргылт җылы шәл белән кысып, уратып бәйләнгән матур башын кисәк кенә югары күтәрде, Һарунга карата, аның барлык дулау-тузынуларына карата ачыктан-ачык нәфрәт сиздереп торган бер горурлык белән күзләрен кыса төште, сабанга якынрак килде, берни эндәшмичә көрәгенә тотынды һәм әкрен генә, салмак кына кыланып, төрән шабалаларын чистартырга кереште.

Бакта әле ягулык күп, радиаторда су җитәрлек иде, кимендә төшкә кадәр тыныч кына эшләргә була иде. Һарун, тиешле техник карауны да үткәреп тормыйча, кузгалып китәргә булды.

Белугин белән Коля, бераз җир арттан ияреп килделәр дә, күрәсең, давыл тынды, ахрысы, дип уйлап, Фәридә янына сабанга утырмакчы булдылар. Ләкин давыл әле бөтенләй үк тынып җитмәгән булып чыкты. Һарун тракторын туктатты да, ишектән башын тыгып:

— Утырма! Ачкыч белән тондырам!— дип кычкырды.

Белугин да, Коля да сабаннан читкә тайпылырга мәҗбүр булдылар.

— Кызган әзрәк, күсәк,— диде Белугин.

— Кайтырсыз әле, йокыгыз туйган!— диде Һарун.

— Котырган! Тиле! Шакал!— диде Белугин, сүгенеп.

«Тагын нәрсә әйтер икән?»— дип көтте Һарун күңеленнән, әмма Белугин ул көткән, ул уйлаган сүзләрне әйтмәде һәм шулай ук артык бәйләнчекләнеп торырга да батырчылык итмәде.

Алар буразна буенда басып калдылар. Нишләргә дә белмичә, бераз вакыт трактор артыннан карап тордылар-тордылар да, оятлы башларын иеп, теләр-теләмәс кенә дала уртасыннан «авылга» таба юл алдылар.

## XVII

Һарун көне буе кәефсез булды. Фәридә ягына ул хәтта әйләнеп карарга да курыкты. Аның алдында талашуы өчен, җитмәсә, бер дә юкка, нахакка аңа кычкыруы өчен ул хәзер үкенеп бетә алмады. Хәзер менә Белугиннар кайтып җиткәннәрдер дә, очраган бер кешегә аның турында, аның тилелеге турында көлешеп сөйлиләрдер шикелле, барысы да бары тик аны гына гаеплиләрдер, аны гына тиргиләрдер шикелле булып тоелды, ә Фәридә, моннан соң беркайчан да аның белән сөйләшмәскә, беркайчан да аның белән алыш-бирешкә кермәскә дип, үз-үзенә сүз беркетеп куйгандыр шикелле булып тоелды.

«Эх, боздым эшне, боздым! Харап иттем...» — диде ул үзалдына, әледән-әле көрсенеп. Фәридә аны болай да бик үк яратып җиткерми, гел аңа өстән торып, түбәнсетеп карый, хәзер инде бөтенләй яратмас. Кая ул ярату! Прицепщиклыктан китәргә үзе үк сорамаса әле... Сорар да шул! Барыр да әйтер Таранга Мансур кебек: Һарун белән эшләп булмый, дияр; үзе рәтләп берни әйтми, өйрәтми, акыра да бакыра, дияр; алыгыз мине аннан, теләсә кемгә беркетегез, аның белән эшлисем килми, дияр. Нинди хурлык булыр кеше алдында!

Ник ул гына шундый холыксыз, алама кеше булды икән, ник ул гына беркем белән дә тыныша алмый икән? Өченче көн ызгышуы җитмәгән, менә тагын... Ни өчен диген — трактор өчен! Тимер ич ул, җансыз, салкын тимер! Бүтәннәр әнә кычкырышсалар да, аракы өчен, хатын-кыз өчен, тегесе-монысы өчен кычкырышалар, ә ул трактор өчен, юк, трактор өчен дә түгел, бер сәгать эшкә соңга калган өчен! Адәм көлкесе! Бер сәгать тә түгел әле... Бит аңа чынында вакытын да бушка әрәм итәргә туры килмәде, утырды да китте дә барды. Менә хәзер бүтәннәр кебек үк сөреп бара. Тракторга да, далага да, буразнага да берни булмаган. Алайса, ни өчен талашты соң ул?..

Шулай үз-үзен шелтәләп бара торгач, ул юл буена килеп җиткәнлеген сизми дә калды. Вакытның бүген шундый тиз үтүенә ул чын күңелдән гаҗәпләнеп куйды. Тагын да гаҗәбрәге шул булды — кай арададыр төш җиткән иде, һәм Галимулла белән Тәзкирә, үгезләр җигеп, ашарга алып килгәннәр иде.

Һарун, юлны аркылы чыгып, икенче якка борылды да, сабанны чистартырга җиңелрәк булсын өчен, тракторны артка чигереп куйды.

— Бар, ашый тор... Сабанны үзем карармын,— диде ул Фәридәгә.

— Юк, юк, нишләп... Мин үзем. Бар, син аша,— диде Фәридә, шундук эшкә керешеп.

Иртәннән бирле бу аларның беренче сөйләшүләре булды. Һарун күңеленнән кызның үзенә карата нинди дә булса кырыслык эшләвен көткән иде. Ләкин Фәридәнең тавышында әз генә дә үпкә дә, хәтер калу да сизелмәде, әйтерсең алар арасында берни дә булмаган иде, һичюгы, ул инде бөтенесен оныткан, бөтенесен кичергән иде, яисә иртәнге күңелсезлеккә Һарун уйлаган кадәр үк игътибар итмәгән иде. Туктале, әллә соң чыннан да берни дә булмадымы, әллә соң ул үзе генә шулай күңеленнән юкбар нәрсә уйлыймы?

Фәридә алдында аңа бик-бик уңайсыз булып китте. Ләкин шул ук вакытта ул үзендә искиткеч бер җиңеллек тойды, ниндидер авыр газаптан, ниндидер хаксызлык, ахмаклык газабыннан котылу шатлыгы тойды. Шулай да ул Фәридәгә берни сиздермәскә тырышты — борынын тарткалап, йөткеренгәләп, тракторы янында булашуын-да булды. Бак бушап килә иде, кичкә чаклы сөрергә ягулык җитмәячәк иде. «Кайтып килми булмас»,— дип уйлады ул һәм, төшке ашны ашап тормыйча, тиз генә бригадага кайтып килү нияте белән, сабанны ычкындыра башлады. Аның хәзер һич тә ашаучылар янына барып, алар күзенә күренеп торасы килмәде.

Ләкин аның кузгалып китүе булды, кулын болгап, нидер кычкырынып, каршысына Тәзкирә килеп җитте.

— Кая барасың? Аш суына. Әйдә, аша,— диде ул, чәрелдәп.

— Кайтып килергә кирәк. Килгәч ашармын,— диде Һарун.

— Кайтырсың әле ашагач! Синең өчен бөтен көнемне монда уздырыр хәлем юк,— диде пешекче, чарага куймыйча.

Үзе турында тагын кире фикер тумасын өчен, инде хәзер Тәзкирәдән дә ләгънәт-шелтә ишетмәс өчен, Һарун килешергә мәҗбүр булды.

Ул арба янына килгәндә, ашаучылар, көлешеп-елмаешып, үзара ниндидер кызык нәрсә турында сөйләшәләр иде. Аларның ничек елмаюларына карап, өзек-өзек сүзләренә һәм үзен ничек каршылауларына карап, Һарун сүзнең нәкъ үзе турында, иртәнге хәл турында булганлыгын сизенеп алды. Ул сагая калды, йөзе караңгыланды, адымы үзеннән-үзе әкренәя төште. Килеп җиткәч, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, калай тәлинкәгә аш бүлдереп алды да төркемнән читкәрәк китеп утырды.

Аның турында сөйләнәсе сүз әллә инде сөйләнеп бет-

кән иде, әллә иптәшләре үзе барда сөйләүне урынсыз дип исәплиләр иде — ул килеп ашарга утыргач та, табын янындагылар тынып калдылар.

Шулай да Тәзкирә түзмәде, беренче булып:

— Нишләп ятадырые соң ул?— диде.

— Йоклап,— диде Һарун, каты гына, аның кем турында сораганлыгын бик яхшы аңлап.

— Йоклап? Шул заманга тикләме?— дигән булды Тәзкирә, исе китеп.

— Әллә үзеңнең йоклаганың юкмы шул заманга тикле?— диде Һарун.

— Мәхәббәтсез!— дигән булды Тәзкирә. Аннары ачусыз гына ялгап алып китте: — Кайтып керделәр икәүләп. Кайда йөрдегез болай, җанкисәкләрем, димен. Аш юк, бетте! Вакытында кайталар аны, димен. «Пүре куып җүрдек»,— ди Колясы. Ташбашы сүгенергә тотынды. Китәм, ди, күрдем инде далаларын да, ди, сөреп тә карадым, тырмалап та карадым, ди, берни үсми, китәм, ди. Ни булды, сөйлә әле җүнләп, мин әйтәм. Трактор ватылды, ди. Трактор урынына җигелеп сабан тарттым, ди. Көлеп эчем катып бетте. Бүтән чакта сырланып, анысын яратмыйм, монысын яратмыйм дип утырган Нәдим Сәлимеч... һәй, тамагы җотыгып кайткач, җанкисәгем, казан төбеннән кырып биргән көйгән ботканы да ялт итеп кенә куйдылар. Шәп булган инде, көн дә шулай сабанга җигелеп йөрсәгез, җанкисәкләрем, мин әйтәм, моннан соң бер дә тавышланып утырмассыз аш янында, мин әйтәм...

Тәзкирәгә беркем берни эндәшмәде. Ул шулай сөйләнде-сөйләнде дә, көлүеннән туктап:

— Нык кыйнадыңмыни соң син аны?— дип сорап куйды.— Әнә врачка китте, справка алам, судка бирәм, ди...

Һарун җавап кайтармады. Ул Тәзкирәнең үзеннән көлгәнлеген бик яхшы аңлады, ләкин мыскыллап көләме, шаяртып көләме икәнлеген әлегә аера алмады. Сүзгә егетләр дә кушылды, һәм барысы да көлешергә, Һарунны төрлечә үчекләргә тотындылар.

— Син әле аның бер генә тешен сындыргансың, мин аның бер тешен дә калдырмасыем,— диде Илгиз, Һарунны мактаган булып.

Һарун тагын эндәшмәде. «Көлегез әйдә, көл!»— диде ул үзалдына. Аның хәзер үз-үзен яклыйсы да, тавышланасы да килмәде.

— Шулай кирәк аңа! Икенче йоклап йөрмәс,— диде кинәт Фәридә, ачыктан-ачык яклау, хуплау белдергән бер күтәренкелек белән.

## XVIII

Һарунның иелгән башы шундук югары күтәрелде. Ул хәзер иптәшләренең сүзен бөтенләй икенче бер киеренкелек белән, бөтенләй икенче бер өмет-теләк белән тыңлый башлады. Хәзер аңа беркем дә аннан көлми дә, беркем дә аны мыскылламый да шикелле булып тоелды, киресенчә, барысы да Белугин белән Колядан гына көлә, аны исә барысы да яклыйлар, мактыйлар шикелле иде. Ә Фәридә шундый шат иде, шундый ачык, ягымлы иде, күрәсең, аның баягы тупаслыгын ул чыннан да оныткан иде. Карале, нинди эчкерсез, нинди әйбәт кыз икән бу Фәридә!

Кызның искәрмәстән ачылып китүен Һарун үзенчә аңлады, үз файдасына аңлады. Бүген Белугин белән булган нәрсә өчен хәзер ул үзен батыр итеп, җиңүче итеп сизә башлады. «Шулай булыр әле ул! Белерсез әле Һарунның кем икәнлеген»,— дип уйлады ул, горур бер масаю белән.

Төштән соң аның күңеле аеруча күтәренке булды. Аңа тагын, гадәттәгечә, туктарга һәм тракторын, сабанын чистартырга туры килде. Туктаган саен, ул Фәридә белән бик ачылып, иркенләп сөйләште, көлде, шаярды, хәтта җаен туры китереп, бер мәртәбә болай гына, ялгыш кына кызның иңбашына орынып алды. Аның мондый ачыклыгына, мондый орынып алуына Фәридә үзе дә бик канәгать шикелле күренде — ачуланмады, үпкәләмәде һәм, гомумән, үз-үзен бик иркен, тыныч тотты. Кош булып очарга Һарунга гүя канат кына җитмәде. «Юк, сиңа бирмибез әле без аны!»— дип уйлады ул, күңеленнән Илгиз белән бәхәсләшеп.

Хәзер ул Фәридәне бөтенләй диярлек эшләтмәде, аның өчен сабанын да чистартты, тракторын да чистартты. Кызны ул үзе янына кабинага чакырды: ял ит, арыгансыңдыр, диде, дала тигез, сабанга берни булмас, диде. Ләкин Фәридә риза булмады. Һарунның моңа әз генә кәефе кырылгандай булды. «Төнге сменага күчик әле! Салкын җил сөякләреңә үтә башлагач, бер дә туң тимер өстендә шыкаеп утырасың килмәс»,— диде ул, үз-үзен юатып.

«Ә ник төнге сменага күчкәнне көтәргә?»— диде ул бераздан. Дөрес, атна алышынганны көтәсе дә юк. Белугинны тракторга утыртмыйм, дип әйткәнсең икән, сүзең сүз булырга тиеш. Белугин эшләмәгән өчен генә трактор да эшләми тормас ич! Шулай булгач, телисеңме, теләмисеңме, төнлә дә үзеңә сөрергә туры килә түгелме соң әле, иптәшкәем?

Ул әле бу турыда уйлап җиткермәгән иде. Уйлап, уеның очына барып чыккач, аның күңел күтәренкелеге җитдилек белән, хәтта беркадәр пошыну-борчылу белән алышынды. Сәламәтлеге начар булуга беркайчан да зарланмаса да һәм авылда чакта кайбер вакытларда тәүлегенә дүртәр-бишәр сәгать кенә йоклаган чаклары булган булса да, көнен-төнен бертуктамый җир сөрүнең никадәр авыр, никадәр йончыткыч икәнлеген ул инде бик яхшы белә иде.

## XVIII

Менә кич тә булды. Үзе кебек үк озын аяклы үлчәү таягы күтәреп, Димка килеп җитте һәм, өчпочмаклы сажинны алмаш-тилмәш атлатып, сөрелгән җир башларын үлчәп чыкты.

— Күпме?— диде Һарун, учетчы егет үз турысына җиткәч.

— Дүрт тә кырык,— диде Димка һәм, артык берни өстәп тормыйча, күршеләргә таба атлады.

Дүрт тә кырык, димәк, норма тулмаган, тулу түгел, якын да килмәгән. Бик үк шәп түгел. Шулай да әллә ни зарланырлык та түгел. Өч төрәнгә җиткән. Башта шулайрак була инде ул. Менә җир тагын да ныграк кипшерә төшсен дә сыланмый башласын, аннары инде күрсәтергә була күрмәгәннәрен!

Үз-үзен дәртләндереп ул шулай уйланды, ләкин чынында ул моңа һич тә дәртләнә алмады. Җир эшендә ул беренче көннән үк беркемгә ал бирмичә, гел алдын булып барырга күнеккән иде — бер көн артта калсаң, биш көндә дә куып җитә алмассың, дигән мәкальнең мәгънәсен ул бик яхшы аңлый иде. Монда да ул шулай беренче көннән үк норманы тутырып барырмын, арттырып барырмын дип исәп тоткан иде, ләкин нихәл итәсең...

Бригадага кайткач, ул иң әүвәл иптәшләренең күпме сөрүе белән кызыксынды. Башкаларның да кычкырып мактарлык түгел иде, барысыныкы да бер чамарак иде, бары тик Исламның гына нормасы тула язган иде. Биш төрән белән! «С-80» өчен тулы норма! Бу ничектер шиклерәк иде. «Булмас дип тә булмый, ул бит гел дүртенче тизлек белән генә чаптыра»,— дип уйлады Һарун, үзенең шикләнүенә үзе үк каршы килеп.

Йокысы тәмам туйган, йөзендәге кызыллыгы бераз шиңә төшкән Белугин, кичке техник карау башлангач та, юаш кына, мыштым гына атлап һәм бүтән вакытлар-

дагыча бик үк кычкырынмыйча, Һарун янына чыкты; чыкты да, бертуктаусыз папирос төтәтеп, берни эндәшмичә, читтәрәк басып торды. Ул, күрәсең, сүзне каян башлап җибәрергә белми азаплана иде.

— Тынычландыңмы инде, күсәк?— диде ул, ниһаять, теле ачылып.

— Нәрсә?— диде Һарун, ишетеп җиткермәгән сыман. Белугинның үзе янында басып торуын бик яхшы сизеп торса да, ул аны бөтенләй күрмәмешкә салышты.

— Тынычландыңмы инде?— диде Белугин, кабатлап.

— Мин болай да тыныч,— диде Һарун.— Ә тракторга мин сине барыбер утыртмыйм.

— Утыртмыйсың? Ничек инде ул алай утыртмыйсың?— диде Белугин, әле һаман ышанып җитмичә.

Ул, ясалма бер искитмәүчәнлек белән, көлгәндәй итеп куйды да нидер эзләп кесәсенә тыгылды.

— Утыртмыйм булгач утыртмыйм!— диде Һарун, нык итеп.— Сиңа ышанып трактор кырдырыр хәлем юк.

— Ярар алайса, без киттек! Контора ябык, кабул итү сәгате тәмам,— диде Белугин, үзенчә тантаналы булырга тырышып.

— Бар, бар, китә бир! Алдыңнан артың!..

Ләкин Һарунның бу үзсүзлелеге Фәридәгә бик үк ошап җитмәде.

— Ә кем өчен әзерләнәбез соң без?— диде ул, аптырап.

— Кем өчен булсын, үзебез өчен!

Күңеленнән инде бу турыда күптән бер карарга килгәнгә күрә, Һарун моны ничектер катгый төстә әйтте, бернинди икеләнү калдырмый торган итеп әйтте.

— Әллә төнгә дә без барабыз?— диде Фәридә, күрәләтә ризасызлык белдереп.

— Тракторны тик торгызып булмый ич инде,— диде Һарун, тыныч кына.

— Тормаса тормас... Ике смена эшләргә монда! Машина түгел...— диде Фәридә.

Мондый җавап ишетеп, Һарун хәтта эшеннән туктады һәм кызга таба әйләнде дә, чынлап әйтәме бу, юри генә әйтәме дигән шикелле, сораулы бер караш белән тынып калды.

Фәридә исә чынлап әйткән иде.

Әйе, барысы да уйланылган, исәпләнелгән иде, тик менә бу турыда гына уйланылмаган иде. Бу турыда уйларга Һарунның башына да килмәгән иде.

Әйтерсең кызның йөзенә кинәт кенә каяндыр көчле яктылык төште, һәм шул чакны Һарун аның моңа кадәр шундый матур булып, нәфис, гүзәл булып күренгән би-

тендә, маңгаенда, бит очларында нindидер яшерен кимчелекләр барлыгын күрде. Күз ачып йомган арада алсу, чибәр кыз сурәте сулыгып-ямьсезләнеп калды.

Шигырьләрдә мактала торган үтә кызыл гашыйклар сыман, Һарун кызларны аларның эшчәнлегенә, булдыклылыгына карап кына яратырга һәм, кызлар турында фикер йөрткәндә, иң элек аларның эштә алдынгымы, түгелме икәнлеге белән кызыксынырга гадәтләнмәгән иде. Ләкин хәзер менә үзе өчен шундый кыен бервакытта, төнге сменага барырга риза булу-булмау мәсьәләсе кызның эшкә-хезмәткә карата гына түгел, бәлки, эшкә дәшүченең үзенә карата да нинди мөнәсәбәттә икәнлеген күрсәткән бервакытта, үз прицепщигына ул нәкъ шул күзлектән — эшчәнлек, булдыклылык күзлегеннән карарга мәҗбүр булды, һәм ул шундук аңа үзенчә бәя дә бирде. Аңа карата ул хәзер бернинди ташлама ясамады, аның өчен бернинди акланырлык нәрсә эзләмәде. Аның хөкеме кыска булды, һәм ул, мөмкин кадәр шәфкатьсезрәк булырга тырышып: «Хәлимәдән кай җире артык соң моның?— диде.— Бер җире дә артык түгел. Төсебите икенче дә, тәкәбберлеге икенче... Юк, безнең тиң түгел бу. Белугиннар сыңары... ялкау!»

— Бармасаң, мин сине көчләмим,— диде ул кызга, тыелып кына, коры гына.— Берүзем китәрмен. Кирәк икән, иртәгә көндез дә эшләрмен. Мин эшләп өйрәнгән. Минем җилкә нык. Шәһәр чибәрләренеке кебек камырдан әвәләнмәгән. Өч мең чакрым җирдән мин монда кызык эзләп килмәгән, ихахай да михахай килеп йөрер өчен... и шулай ук буразнада йоклап ятар өчен дә! Теләмисең икән, үзеңә кара.

Фәридә үзен хаклымын дип уйлады. Ул инде болай да үләрдәй булып арыган, алҗыган иде, аның инде җеп өзәр хәле дә калмаган иде, һәм ул хәзер сменасын тизрәк тапшырып, җылы вагонга кайту турында гына, авыр өс киемнәрен салып ташлау турында гына уйлый иде. Шуңа күрә Һарунның йөзгә бәреп әйткән авыр сүзләрен ул һич тә аңлый алмады, ләкин шул сүзләрнең бөтен ачысы, бөтен зәһәре, агу булып, шундук аның йөрәгенә кадалды. Көтмәгәндә шундый әр-хур ишетүе өчен аның кинәт күңеле тулды, күзенә яшь килде, һәм ул, Һарун белән кычкырыша башлаудан, елап җибәрүдән, йә булмаса, тагын да хурлыклырак сүзләр ишетүдән куркып, хәтере калып, икенче якка борылды: борылды да, башын горур тотарга тырышып, әкрен генә үзләре вагонына китеп барды.

Ул китеп озак та тормады, кызыксынучан, серле бер кыяфәт белән Мансур килеп җитте

— Нәрсә... Ни булды?— диде ул, пышылдап.

— Берни булмады,— диде Һарун, көттереп, теләмичә генә.

Ул аңа борылып та карамады. «Нәрсә кирәк тагын моңа?»— дип уйлады ул, кирәкмәгән чакта аның килеп кысылуын һич тә яратмыйча.

— Әллә баш тартты?— диде Мансур, төпченеп.— Эштән баш тарттымыни?

Ул, күрәсең, Һарун белән Фәридә арасындагы сөйләшүне ишетеп торган иде.

— Әйе,— диде Һарун һәм кинәт аңа таба борылды да:
— Барасыңмы минем белән төнге сменага?— диде.

— Барам! Була!— диде Мансур, шундук риза булып.

— Әйдә алайса, әзерлән,— диде Һарун, җиңел сулап.— Ләкин Илгизгә әйт. Болай гына ярамас.

— Ярар, әйтермен,— диде Мансур.

## XIX

Вагонга килеп кергәч, Фәридә авыр, тупас күн итекләрен, авыр, тупас сырмаларын ишек төбендәге буш урынга салып ташлады да, тәне белән җиңеләеп, әмма күңелендә һаман әрнеткеч бер авырлык тойган хәлдә, үзләре бүлмәсенә узды. Бүлмәдә беркем юк иде, кызларның барысы да тышта тракторлар янында иде. Теләр-теләмәс кенә, бик авырлык белән генә ул өстен-башын алыштыра башлады; иң әүвәл майга-ләпеккә буялып беткән авыр чалбарын салып ташлады; тәрәзә турысында икәнлеген шәйләп, читкәрәк китте дә, чемоданыннан икенче җиңел, чиста чалбар алды, тәненә сыланып торган җылы йон свитерын алды. Ләкин аның хәзер бу киемнәрен дә киясе килмәде. Аның хәзер, гомумән, берни эшлисе килмәде. Аның бары үз урынына сузылып ятасы, башыннан томаланып ятасы һәм, күз яшьләренә тулы ирек биреп, елыйсы, үксеп-үксеп елыйсы килде.

Ләкин әле тракторлар кузгалып китмәгәннәр, бөтен бригада тышта ыгы-зыгы килә иде, берәрсенең аны эзләп килеп керүе бар иде, аннары, гомумән, ятып кына беркемнән дә, бернидән дә качып котылып булмаячак иде. Күпмедер вакыт ул бер урында тын гына утырып торды. Шулай утыра торгач, үз-үзен кызганып, күз яшьләре агызды, мине эзләп килмиләр микән дип, әледән-әле тәрәзәгә карап алды. Күрәсең, барысының да эшләре бик ашыгыч иде яисә беркемнең дә анда эше юк иде — аны эзләп тә килмәделәр, кызганып та килмәделәр. Аның тагы да ныграк күңеле тулды, тагын ул күз яшьләре агызды һәм әле

генә кигән свитерын кире салып куйды да, урынын рәтләп, бөтен дөньясына үч итеп, юрган астына чумды.

Әмма юрган астында да ул тиз генә тынычлана алмады. Бераздан ул кире торды һәм буталган фикерләрен барларга, бергә тупларга теләгән сыман, юрган итәге белән капланган аякларын салындырып, бер ноктага текәлеп калды. Кичке эңгер-меңгердә елтырап, керфек очларын чылатып, күз төпләреннән янә кайнар яшьләр агып чыкты һәм матур алсу иреннәре әледән-әле дерелдәп алды.

Чынында аның хәзер һич тә елап, күз яшьләре түгеп утырасы килмәде. Аның хәзер иркәләнәсе килде, кемнәндер җылы, яхшы сүз, юату, ярату сүзе ишетәсе килде.

Ә соң көне буе шул турыда уйламадымыни, шул турыда хыялланмадымыни ул? Шуны теләмәдемени ул? Ул инде теләп кенә дә калмаган иде, ул инде ышанган да иде — шундый яхшы сүзнең, шундый җылы, ягымлы сүзнең әйтеләчәгенә һәм кайчан да булса бүтән көнне түгел, бәлки, нәкъ менә бүген әйтеләчәгенә бөтен күңеле белән ышанган иде.

Ә нинди сүз әйттеләр аңа? Аны сүгеп җибәрделәр, куалап җибәрделәр!

Үзенә иң кыен вакытларда ул, гадәттә, әнисе турында уйлый торган иде, һәм тагын да ул шундый ягымлы, шундый әйбәт әнисен — алтын бәясенә торырлык кадерле әнисен исенә төшерде. Әмма бу да күпкә бармады....

Әйтәсе дә түгел, аңа бик авыр иде, бик кыен иде, ләкин бу авырлык менә бүген генә, хәзер генә сизелгән авырлык-кыенлык түгел иде. Бу инде күптән, монда килеп тора башлауның беренче көненнән үк килә иде. Ул һич тә мондый тормышка күнекмәгән иде, күнегү түгел, мондый тормышны ул нәрсә дип тә белми иде. Аның хәтта авыл җирендә дә атнадан, айдан артык булганы юк иде, ул бөтенләе белән, башы-аягы белән шәһәр кешесе иде.

Шулай булуга да карамастан дала турында, чирәм җирләр турында ул шәһәрдә чакта ни өчендер бөтенләй икенче төрле итеп уйлаган иде. Аннары дала турында, чирәм җирләр турында газеталарда шундый мактап, шундый ис китеп язалар иде, радиодан шундый тантана белән, шундый күтәренкелек белән сөйлиләр иде, Казанда чагында аңа ул «далалар», ул «чирәм җирләр» ниндидер хуш исле болынлыклар булып — Агыйделдә пароходта барганда тәрәзә аша күренеп-күренеп калган болынлыклар, таллыклар шикелле ниндидер гүзәллек тулы сихри урыннар булып тоелган иде. Шуңа күрә ул монда шундый ашкынып, хыялый-романтик уйлар белән дәртләнеп килгән иде.

Килгәч тә ул монда бернинди болынлыклар да күрмәде, сихри гүзәллекләр дә күрмәде. Ул бары тик шәрә, туң дала күрде дә, җан өшеткеч, күңел шомландыргач иксез-чиксез бушлык күрде һәм усал телле кешеләр белән очрашты. Шулай да Көктугайда торганда әле үзеңне кешечә хис итәргә була иде, барыйм дисәң, киносы, тыңлыйм дисәң, радиосы бар иде, кайчагында хәтта танцылар да булгалый иде.

Әйе, анда әле әзме-күпме кызык бар иде. Монда килгәч исә алары да юкка чыкты. Кайчандыр күңел түрендә йөргән романтика, батырлык, гүзәллек көн дә торып авыр, тупас күн итекләрне, авыр, тупас сырма-чалбарларны кию белән, тәмсез, туклыксыз тары боткасы, дөге боткасы чәйнәү белән алышынды. Ул ниндидер механизмга, ниндидер автоматка әверелде, һәм мондый автоматик тормыш аны һич тә кызыктыра да, мавыктыра да алмады. Ул монда бернинди батырлык та, гүзәллек тә күрә алмады. Мондагы тимер-томыр, балчык эшенә аның берничек тә күңеле ятмады. Ул бары тешен кысып кына эшләде, бүтәннәр эшләгән өчен генә эшләде һәм ничек кенә булса да сынатмаска, ничек кенә булса да йомшак булып, булдыксыз булып күренмәскә тырышты. Ләкин никадәр көч, никадәр чыдамлык куярга туры килде аңа моның өчен!

Әйе, ул беркемгә зарланмады, шыңшымады. Зарланмаска, шыңшымаска аңа горурлыгы ярдәм итте... Аннары моңа кадәр барлыгы-юклыгы да беленмәгән һәм күңелендә кинәт кенә барлыкка килгән икенче бер дәрт-теләк, икенче бер көч-куәт аңа канат бирде.

## XX

Ә менә ул канатны көтмәгәндә сугып сындырдылар, җиргә салып таптадылар, һәм шул чакны ул үзенең кинәт кенә ятимләнеп калганлыгын күрде. Горурлык югалды, чыдамлык, түземлек бетте; әле бер-ике көн төшендә генә ямьләнә башлаган, таллы-болынлы Агыйдел буйлары сыман яшәрә башлаган дала, кешеләр — барысы да яңадан ямьсезләнеп, котсызланып калды.

Әйе, бу дала да, мондагы тормыш та, тракторлар-сабаннар да аның өчен түгел, кемнәрдер бүтәннәр өчен, Һаруннар, Илгизләр өчен. Көчлеләр, кырыс күңеллеләр өчен, җилкәләре тимердәй нык булган кешеләр өчен. Чыннан да, монда ул нишли ала? Утырса, шул сабанга утырып йөри ала да беләге талганчы төрән чистарта ала. Ә бит монда ул гына җитми. Монда эшләү, монда яшәү

өчен батыр йөрәкле булу кирәк, борлыкмый торган шат күңелле булу кирәк. Әгәр ул трактор кабинасына менеп утырса, йә булмаса, сабанда утырып баруның гомумән кирәге булмаса, ул бөтенләй юкка чыгачак, аның монда бернинди әһәмияте калмаячак. Әгәр, мәсәлән, Тәзкирә кебек ул аш пешерүче булса, Фәрханә апа кебек керләр юса, ул чагында ул үзен, бәлки, чыннан да кирәкле кеше, чын кеше итеп, батыр, эшчән кеше итеп сизәр иде. Яисә менә шушында тегү мастерское ачылып, кешеләргә ул шунда кием тексә...

Ләкин бер дә алай түгел шул. Аш пешерүче дә түгел ул, кер юучы да, тегүче дә түгел. Ул бары сабанга утырып йөрүче генә, төрән чистартучы, тәгәрмәч майлаучы гына, үзеннән көчлерәк, батыррак кешеләргә ачкычтыр, гайка-фәләндер биреп торучы гына һәм эш дип атарлык бернинди эше булмаса да, барысыннан да ныграк аручы, алҗучы гына... Нинди мескен хәлдә ул!

Аның тормышы гомумән әллә ничек кенә булды. Ул һәрвакыт кешегә ияреп йөрде, кешегә ияреп эшләде, кешегә ияреп уйлады һәм беркайчан да үз-үзеннән тулысынча канәгать булмады. Бүтәннәр тормышта үзләрен хуҗаларча тоттылар, батыр, кыю тоттылар һәм киләчәктә кем булу турында, нишләү турында алдан ук хыял йөрттеләр, үз-үзләренә, үз көчләренә нык ышанып фикер йөрттеләр. Ә ул беркайчан да киләчәктә үзенең кем булырын, нәрсә эшләрен алдан белә алмады, дөресрәге, кем дә булса булу турында үз көченә, үз сәләтенә, үзенең теләк-омтылышларына таянып хыяллана алмады һәм, бүтәннәргә — көчлерәк, ихтыярлырак иптәшләренә ияреп нәрсә турында гына хыялланмасын, хыяллана торган нәрсәләренең берсенә дә ныклап торып күңеле ятмады; берни дә аны чын-чынлап мавыктыра да, җилкендерә дә алмады.

Былтыр ул, унны бетергәч, классташ кызларының күбесе «биолог» булырга исәпләгән өчен һәм бигрәк тә дусты Наиләдән калышмаска теләп, университетның биология факультетына гариза бирде. Чынында аның һич тә «биолог» буласы килмәде, алай гына да түгел, укыганда биологияне, ботаника, зоологияләрне ул бөтенләй яратмады. Шуңа да карамастан ятып калганчы, ул атып калмакчы булды, ләкин, кызганычка каршы, төбәгән җиргә тидерә алмады.

Конкурстан үтмәве турында белгәч, ул өенә кайтты да китабына капланып еларга тотынды. Аның өчен бөтен нәрсә бетте, җимерелде... Моңарчы һәрвакытта таяныч булып, юлдаш булып килгән иптәшләре икенче юлдан

китте, бернинди ярдәмчесез көе ул үзе генә торып калды, һәм киләчәк аңа ниндидер караңгылык эченә, томан эченә кереп буталгандай булды.

Иптәшләре аңа күңелен төшермәскә киңәш иттеләр: быел булмаса, җәрингә булыр, диделәр; кыш буе әзерләнде киләсе көзгә тагын бер бәхетеңне сынап карарсың, диделәр. Ул яңадан кулына дәреслекләр алды. Яңадан теорияләр, формулалар, ят сүзләр ятларга тотынды. Бөтен нәрсә аның өчен шул теория-формулаларга, ят сүзләргә бәйләнгән шикелле булып, әгәр шул теория-формулаларны үзләштерә алмаса, дөньяда яшәргә дә кирәк булмаячак шикелле булып тоелды.

Ләкин әнисе әйтте, кызым, диде, бер ел буе шулай корыны бушка әйләндереп, кырыкмаса-кырык мәртәбә укыган китапларыңны кырык беренче мәртәбә укып гомер уздырырсың микәнни, диде, ичмасам, үзеңә күлмәклек булса да акча булыр, эшкә кер, диде.

Китапларын аның болай да күрәсе килми иде. Әнисенең сүзләре аңа бик урынлы тоелды. Ул тегү мастерскоена эшкә керде. Тегү эше аңа ошап китте, чын-чынлап ошап китте. Үз гомерендә бу аңа иң нык ошаган нәрсә булды.

Әйе, тегүчелек эше аңа бик тә, бик тә ошады. Ләкин аңа барыбер тегүче булырга туры килмәде. Тормыш аны көтмәгәндә тагын үзе теләгән якка борып җибәрде. Тегүчеләрдән берничә кыз көннәрдән бер көнне чирәм җирләргә китү турында котырынып йөри башладылар; шундый нык котырындылар, баштарак ул «чирәм җирләр», «дала җирләр» турында ишетергә дә теләмәгән Фәридәне дә котыртып җиткерделәр, башын әйләндерделәр, һәм ул, яраткан эшен, ияләшкән иптәшләрен ташлап, әтисен, әнисен ташлап, менә монда килде. Җилкенеп, атлыгып килде, яшерен бер куаныч-усаллык белән килде, элекке сабакташ кызларыннан үзенчә үч алмакчы булып, үзенең дә алардан ким түгеллеген күрсәтмәкче булып килде.

Килүен килде, әмма ул, күрәсең, беркайчан да аларның исен дә китәрә алмаячак, үз-үзен батыр кеше, көчле ихтыярлы кеше итеп тә күрсәтә алмаячак. Ул, гомумән, беркем дә булмаячак. Ник соң унны бетергән һәрбер кеше, һичшиксез, биолог булырга, медик, агроном булырга яисә артист яки галим булырга тиеш икән? Нигә, әйтик, кеше гомер буена аш пешерүче яисә тегүче булмаска тиеш икән? Ә бит иптәшләре алдында оят булмаса, ихтимал, ул беркайчан да үзенең тегүчелек эшен ташламаган булыр иде, аннары, ул хәтта бары тик аш-су пешереп торырга

гына да риза булыр иде. Өйдә бит һәрвакыт әтисе ул пешергән ашны мактап ашый...

Туктале, әллә соң Тәзкирәгә әйтеп карарга мы — урыннарны алышырга риза булмас микән? Юк, булмас. Булыр сиңа! Ул инде җаен белеп алган. Күтәрсәң аннан! Аның теленә егылып үләрсең...

Хәер, монда башкалар да шундый: тиргәшәләр, талашалар. Рәхмәт юк, яхшы сүз юк, ялкау да фәлән, камыр җилкә. Ничек түзеп йөргәнне белми, хәлең ничек, дип, арыдыңмы, дип сорамый — төнге сменага чыгабыз! Юату, иркәләү урынына...

## XXI

Үзалдына шулай уйланып, дөньясы җимерелгәндәй кайгыга бирелеп утырганда, ул вагон ишегенең әкрен генә ачылганлыгын ишетмичәрәк калды. Бүлмәгә килеп кергән кешенең үзенә таба якынлашуын күреп алгач, дөресрәге, эчке бер тойгы ярдәмендә сизеп алгач кына, ул кинәт сискәнеп китте; кискен бер хәрәкәт белән кулларын югары күтәрде дә ашык-пошык күз яшьләрен сөртергә тотынды; ләкин сөртеп бетерә алмады, керүченең кем икәнлеген таныды да шул көе, ике кулын дога кылган сыман югары күтәргән көе, яшьле күзләрен зур ачкан көе, утырган урынында катты да калды.

Керүче кеше Ислам иде, вагон түшәменә тиярлек булып, бөтен тәрәзәне киң гәүдәсе белән каплап, дәһшәтле елмаеп, сүзсез-нисез аның каршысында басып тора иде. Алар бер-берсенә карашып алдылар. Фәридә күзләрен читкә борды, нәрсәсендер рәтләмәкче булды, нинди дер хәрәкәт ясамакчы булды, ләкин берни эшли алмады — каршысына бүре килеп чыккан бәрән сыман, куркыпкалтыранып тик утырды.

Менә ул иелде, якынрак килде, идәнгә тезләнде, чөнки югарыдан аска карап тору аңа, күрәсең, уңайсыз иде, аннары пычрак кием белән чиста урынга утыру да бик үк килешеп бетми иде. Тезләнде дә, серле, магнитлы күзләрен тутырып, аның яшь белән чыланган күзләренә карап тора башлады.

Фәридәнең чәчләре тузгыган иде, күз төпләре кызарынган, юешләнгән иде; бит очларында исә кибеп өлгермәгән яшь эзләре беленеп тора иде; өстенә каплаган юрганы, бер як иңбашыннан ычкынып, идәнгә шуышып төшкән иде, шуңа күрә муены, иңбашы, шәрәләнеп, ачылып калган иде. Бу минутта аның бөтен җирендә тәртипсезлек һәм үз-үзенә карата игътибарсызлык бил-

гесе күренеп тора иде. Ләкин нинди сылу, нинди чибәр иде ул шушы килеш!

Ислам кинәт аны шул тузгыган чәчләре белән, бер итәге идәнгә шуышып төшкән юрганы-ние белән кочаклап күкрәгенә кысты һәм онытылып, пышылдап:

— Фәридә!— диде.— Ни булды? Ник елыйсың, Фәридәм?

Фәридә берни әйтмәде. Аның теле бәйләнде. Каты, нык куллар богавында ул үзен ниндидер тоткында шикелле итеп, ниндидер читлектә шикелле итеп сизде. Әмма аның һич тә бу тоткыннан, бу читлектән качасы килмәде, киресенчә, бу читлекнең ул тагын да ныграк кысылуын теләде, үзенең тәмам шунда юкка чыгуын теләде.

— Кем тиде? Һарунмы?— диде Ислам, бала-чаганы юаткан сыман.

Читлектәге кош кинәт җан әсәре сиздерде, талпынатыпырчына башлады һәм, телгә килеп:

— Җибәр, Ислам абый, җибәр!— диде.— Кеше килеп керер. Мин күлмәкчән генә... Ислам абый!..

— Матур син, Фәридә!— диде Ислам абыйсы.— Сиңа сокланмаган кеше юк. Бик авыр булыр сиңа монда. Һаруннар, Илгизләр сине кыерсытырга гына торалар.

Фәридәгә аның тавышы төштәгедәй булып, каяндыр күктәнме, җир астыннанмы килгәндәй булып тоелды. Ул аның нәрсә әйткәнлеген дә аңламады. Бары тик ул аның нәкъ менә үзе өмет иткән юату сүзләре, иркәләү, ярату сүзләре әйткәнлеген генә белде, шуны гына тойды, һәм аңа шуннан башка хәзер бүтән берни дә кирәкмәде. Аның күңеле яңадан канатланып китте, яңадан җилкенә башлады. Дөньяның яме кире кайтты, шундый көчле булып, ташкын булып кайтты — бөтенләе белән аны үзенә төрепчорнап алды, күмеп ташлады һәм тирбәлдереп, иркәләп каядыр еракка, каядыр читкә — билгесезлеккә алып китте.

Кинәт аның дымлы иреннәрен нидер яндырып алды. Искәрмәстән ул утлы ялкын эчендә калды, күбәләктәй шунда янды, юкка чыкты һәм бары тик колак төбендә генә ниндидер бер нәрсә — беркайчан да янмый да, югалмый да торган нәрсә:

— Торыйк бергә, Фәридәм... чибәрем, матурым!..— диде әкрен генә, шыпырт кына.

Кайдадыр бик якында гына яңгырап киткән икенче бер тавыш — әлеге сихри пышылдауга һич тә охшамаган ят, чит тавыш аны тәмам югалып бетүдән коткарып калды. Шундый ачык, аермачык рәвештә ул Тәзкирәнең тавышын ишетте, тутыккан калай шыгырдаткандагы төсле тешкә тия торган әшәке, җирәнгеч тавышын ишет-

те. Ялкын кинәт бозга әйләнде, һәм ул үзенә сарылган авыр нәрсәне, трактор исе, тәмәке исе аңкыткан нәрсәне коты алынып, бар көченә этеп җибәрде.

— Ашарга... аш суына... И-и, белмәдем... Куркытмаган булырыем, хи-хи!..— диде Тәзкирә, хихылдый-хихылдый артына чигенеп.

Агарынып, шашынып Ислам аягына басты. Тәзкирәне ул тышта, вагон ишеге төбендә куып җитте.

— Тыныңны чыгарасы булма!— диде ул, ыжгырыппышылдап.

Фәридә ашарга чыкмады. Кызлар кайтып кергәнче дип, юрганына бөркәнде дә сузылып урынына ятты. Төне буена ул бизгәк тоткандагы шикелле бер янды, бер туңды. Иртә белән исә бик озак уяна алмый ятты. Уянып киткән иде, бик нык башы авыртканлыгын, бөтен тәненең кыйнап ташлагандай хәлсезләнеп калганлыгын тойды. Кызлар аңа тормаска куштылар, эшкә бару турында уйлап та карама, диделәр. Ул риза булды һәм, үз-үзен чыннан да авыру дип уйлап, урынында кузгалмыйча ята бирде.

## XXII

Усалланып Һарун төнлә әз генә дә черем итмәде. Йокы турында Мансур сүз кузгаткаласа да, Белугин белән булган хәлне исендә тотып, яшь егетнең киңәшен ул ишетергә дә теләмәде. Бер күзеңне йомсаң, йокыга баш булырмын дип кем әйтә ала? Белугинны гына түгел, әллә кемеңне дә борып сала ул! Аңа башта ук бирешмәскә кирәк, аның үзеннән дә усалрак, черкәнрәк булырга кирәк. Ул чакта ул җиңә алмый... юк, җиңә алмый...

Һәм ул җиңдермәде. Хәтта Мансур да, үзенең көче белән мактанырга ярата торган батыр Мансур да, сабанында утырган килеш, бер-ике мәртәбә калгып китте. Туктаган арада, аның шулай оеп утыруын күреп, үзен бераз ачуланып алырга да туры килде.

Әйе, хәтта Мансур да җиңелде, көчле, батыр Мансур да бөгелеп-сыгылып төште. Ә ул җиңелмәде! Күз кабаклары йомылды; аяк-куллары ташка-агачка әйләнде, берни тоймас-сизмәс булды; ике як иңбашларына ниндидер авыр капчыклар бастырып куйган шикелле булды.

«Шушыны гына әйләнәм дә, борылышка гына җитәм дә йоклыйм!»— диде ул кайчакта, бирелә башлап. Аның өчен буразна башы ниндидер оҗмах булып, барлык михнәтләрдән, барлык кыенлыклардан котылу урыны булып тоелды.

Менә җир башы да күренде, буразна да бетте, һәм

шундук күңелендә, йокламаска кирәклеген исенә төшереп, сакчы фикер калкып чыкты. «Юк инде, булмый бу болай,— диде ул, кем беләндер бәхәсләшкән сыман.— Юк инде, юк. Алай ярамый, иптәшкәем. Кеше күзенә ничек күренербез? Юк, булмый бу болай...»

Куркыныч урынны шулай хәвеф-хәтәрсез генә узып киткәч, яңадан аның зиһене томалана башлады, һәм ул, ком чүлендә бер тамчы су турында хыялланган юлчы сыман, яңадан да бераз гына черем итеп алу турында, буразна башына җиткәч тә — монысында инде һичшиксез!— йоклап алу турында хыялланырга тотынды.

Күпмедер вакыттан соң янә тагын җир башы күренде, буразна бетте, ләкин тагын сакчы фикер, аның теләгенә каршы төшеп, юк инде, юк! диде.

Төне буе шулай дәвам итте.

Төнге саф, салкынча һавада мотор бик яхшы эшләде. Кайбер урыннарда ул хәтта өченче тизлек белән дә алдырды. Ул бөтенесе дүрт мәртәбә әйләнде. Дүрт мәртәбә! Дүрт әйләнү була дүрт метр. Дүрт тә ике була сигез. Сигез метр да сигез мең метр... Сигез дә сигез күпме була соң әле ул? Нормага тулды микән? Тулгандыр, тулмый булмас. Сигез дә сигез. Менә башы да эшләми башлаган. Сигез сигезең — алтмыш дүрт! Алты гектар да кырык. Норма. Нормадан артык!

Ул үзендә искиткеч бер канәгатьләнү тойды, күтәренкелек тойды. Кайтыр юлга борылгач та, ул үз урынына Мансурны утыртты һәм кабина почмагына башын терәп, елмаеп, шундук йокыга китте.

Ләкин йокы аралаш аның күңеленә кинәт, ә бит тагын үземә китәргә туры киләчәк! дигән бер коточкыч уй килде. Өченче сменага! Йокламыйча! Вәгыйзь кайтып җитмәсә, тагын төнгә, дүртенче сменага! Булдыра алырмы?

Ул кисәк кенә күзләрен ачты, күнегелгән бер хәрәкәт белән Мансур ягына үрелде.

— Йокла, йокла, үзем уятырмын!— дип кычкырды Мансур аның колагына.

Һарун аңа үзенең кайгысын әйтеп бирде.

— Мин риза. Миңа ышана аласың,— диде шат күңелле Мансур, сер сынатасы килмичә.

«Ризасын риза...»— дип уйлады Һарун, ләкин уй җебенең очына чыга алмады, яңадан борынын сызгырта башлады.

Бригадага алар соңгы кеше булып кайттылар. Алар кайтып җиткәндә, инде техник карау тәмамланган иде. Мансур тракторны читкәрәк, иркенгәрәк туктатты да тарткалап Һарунны уятты.

Җиргә баскач, Һарунның аяклары сөрлегеп китте. Аның хәзер элеккегә караганда да яманрак башы авырта, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә иде, ә аякларында аның шундый хәлсезлек, шундый көчсезлек иде — андый хәлсезлекне аның бары тик бала вакытында бик каты чирдән савыгып килгәндә генә кичергәне бар иде.

— Шулай... Мансур... кайтып та җиттек,— диде ул, телен көчкә әйләндереп.

Ләкин тракторлар тирәсендә кайнашкан иптәшләрен күреп алгач, аңа кинәт үзеннән-үзе яңа көч-куәт өстәлгәндәй булды. Аяклары турайды, башы күтәрелде, һәм ул йончылганлыгы, ябыкканлыгы үзенә дә сизелеп торган йөзенә ныклык, чыдамлык билгесе чыгарырга тырышты. Белугиннар, Исламнар каршында, Фәридә каршында өтәләнгән булып, хәлсез булып күренергә мөмкинме соң. Авызыңда кара кан булса да, алар алдында төкерергә ярамый.

Үзләрен күреп аңа барысы да чиктән тыш гаҗәпләнерләр шикелле тоелды. Күңеленнән ул шулай булуын теләде, барысының да үзенә, Мансурга игътибар итүләрен теләде. Ярым йомык күзләре белән ул кешеләр арасыннан Фәридәне эзләде, Илгизне, Белугинны, Исламны эзләде; аларның исләре китеп елмаюларын күрәсе килде, ни дә булса әйтеп эндәшүләрен көтте, хәтта бераз гына үчекләшеп, төрттереп алсалар да, бу минутта һич тә үпкәләмәскә булды. Ә Таран аңа тракторны тик торгызмаган өчен, ике смена рәттән эшләп, шундый батырлык күрсәткәне өчен рәхмәт әйтер, мактар шикелле тоелды.

Аларның кайтканлыгын, әлбәттә, күреп алдылар, ләкин беркем дә моңа әз генә дә гаҗәпләнү белдермәде. Һәркем үз эшендә булды.

Һарунга бик кыен, бик авыр булып китте. Ул үзен ялгыз итеп, кирәксез итеп сизде. Төне буе үз-үзе белән тартышып, үз-үзен мәҗбүр итеп шулкадәр азаплануы да, үз-үзеннән бик тә канәгать булуы да, норма тутыруы да — барысы да бик күңелсез булып, вак һәм әһәмиятсез булып калды. «Ярар, монысында инде буразна уртасына җитеп туктыйм да рәхәтләнеп йоклыйм!»— дип уйлады ул, кемгәдер үч иткән сыман.

## XXIII

Юынып ятканда, алар янына Илгиз килеп туктады.

— Әйдә киттек!— диде ул Мансурга, боеручан төстә.

— Кая? Мин бит әле генә кайттым,— диде Мансур, берни аңламыйча.

— Кая! Абзар артына! Үз эшеңне оныттыңмыни?— диде Илгиз.

— Юк инде, булмый бу болай,— диде Һарун, сүзгә катышып.— Үзең алышыйк дидең — алыштык... Фәридә сиңа, Мансур миңа. Вәссәлам!

— Фәридә! Аның ише үләмәт. Чирләп ята әнә. Үзеңә булсын!— дип кычкырды Илгиз, чукрак кешеләр белән сөйләшкән төсле.

— Чирләп?!

— Чирләп, имеш! Кичәдән бирле тормаган. Тапкан! Хатын-кыз белән булашамы соң җүнле кеше.

Болай да карар җире калмаган Һарунның тәмам төсе качты.

— Авызыңны үлчәп ач, мин аңа бармак белән дә чиертмәдем,— диде ул, әкрен генә, әмма нык итеп.— Серкәсе су күтәрми торган кеше икән, анысына мин гаепле түгел.

— Нәрсә миңа акырасың?— дип кычкырды Илгиз. Үзенең туктаусыз кычкырынуы аңа, күрәсең, бүтән кеше тавышы булып ишетелә иде.— Мин генә әйтмим, әнә бөтен бригада сөйли.

Ул шулай тузынды-тузынды да, берни барып чыкмаячагын аңлап, үз юлы белән китеп барды.

— Гел шундый ул,— диде Мансур, күңелсез тынлыктан соң.— Әллә нинди шунда... Бер дә җегетләргә охшамаган, валлаһи менә. Берзаман бертөрле сөйли, икенче заман икенче төрле сөйли. Алама хатын-кызлар кебек.

Һарун эндәшмәде. Ул Илгиз әйткән сүзләр турында, Фәридә турында уйлады. Беренчедән, Фәридәнең чирләп китүенә чын күңелдән эче сызланса, икенчедән, аның чирләве турыдан-туры үзенә, үзенең кичәге дорфалыгына бәйле булуы аның йөрәген әрнетте. Ул кадәр аяктан егарлык сүз дә әйтмәгән иде югыйсә, шулай да әнә нишләгән!..

Юынгач, алар Мансур белән ашарга киттеләр. Һарун хәзер һәркемнең үзенә Илгиз кебек берәр каты, авыр сүз әйтүен көтте. Бәхеткә каршы, өстәл янындагыларның барысы да төнлә эшләп кайтучылар иде. Алар әле Фәридәнең чирләве турында берни белми булырга тиешләр иде. Тик Тәзкирә генә...

Ләкин, гаҗәп хәл, Һарун белән Мансурны күргәч, пешекче елмаеп җибәрде.

— Ә-ә, сез дә бар икән әле дөньяда!— диде дә, биепсикергәләп, шундук ашарга әзерли башлады.

— Бик авыр булгандыр инде, җанкисәкләрем. Күзләре генә утырып калган бичаракайларның!— диде ул аннары, Һарун белән Мансурны кызганып.

Аның авызыннан шундый сүз ишеткәч, Һарунга ничектер җиңелрәк булып киткән шикелле булды. «Шулай да начар кеше түгел бу Тәзкирә, керделе-чыктылы»,— дип уйлады ул.

Өстәл янында бернинди шау-шу, сөйләшү ишетелмәде. Бары тик Тәзкирә генә, күрәсең, мондый тынлыкны бик үк ошатмыйча, Һарун белән Мансур каршысына, озын такта утыргычка килеп утырды да, биленә буып куйган керле алъяпкыч итәген сыпырыштыргалап, үзалдына сөйләнгән сыман гына әйтеп куйды:

— Белми генә йөргәнбез икән, Һарун җаным, бигрәкләр уңгансың икән син,— диде.— Беркөнне ике кешене аяктан җыктың, ә үзең, ташка үлчим, мунча пәрие күк тап-таза.

Майсыз ботка Һарунның тамагына утырды. Тәзкирәгә каршы ул бер генә сүз дә әйтә алмады. Мондый гайбәткә, мондый... мондый кешегә, гомумән, нәрсә дә булса әйтүе дә мөмкин түгел иде. «Нинди оятсыз, нинди кабахәт кеше бу Тәзкирә!»— дип уйлады ул, әле генә аның турында бөтенләй икенче төрле фикердә булуын онытып.

— Ике кеше түгел, бер генә. Фәридә генә!— дип кычкырды Белугин, өстәлнең икенче башыннан тавыш биреп.— Миңа берни булмады, күсәкләр. Наташа белән без бүген йөз гектар сөреп кайттык.

— Әллә йөздән биш кенә микән соң?— диде Наташа, көлемсерәп.

— Йөздән биш тә, йөздән бер дә җитә безгә,— диде Белугин.— Без комсыз түгел. Минем әти беркайчан да аерым хуҗалык булмаган. Миндә тамчы да мужик каны юк.

Бу сүзләрнең кемгә төбәп әйтелгәнлеген Һарун, әлбәттә, бик яхшы аңлады. Ләкин хәзер аның моңа әз генә дә хәтере калмады. Аның күңелендә кинәт яңа бер тойгы уянды, үз-үзенә, үзенең хаклыгына ышаныч тойгысы уянды. Ул үзенең Фәридәгә карата да, Исламга, Белугинга карата да хаклы булуына һәм ике смена эшләп кайтып, менә хәзер өченчесенә китәргә җыенуының дөрес икәнлегенә элеккегә караганда да ныграк ышанды. Шундый нык ышанды, Белугиннар, Тәзкирәләр хәзер нәрсә генә әйтсәләр дә, нинди генә гаеп ташласалар да, аның өчен барыбер иде, андагы ышанычны инде берни дә, беркем дә какшата алмаячак иде. Ул хәзер андый вак-төяк гайбәтләрдән, вак-төяк чәйнәшүләрдән өстен иде, көчле иде.

— Монда менә синең кебекләр кирәкми дә инде,— диде Андронов беркадәр тынлыктан соң, Белугин

сүзләренә җавап итеп.— Беләсең килсә, Карп Налимович, монда менә нәкъ мужик канлы кешеләр кирәк. Иген эшенә күңеле ята торган кешеләр кирәк. Мужиклыктан җәяүләп качкан синеңише Акула-Белугаларның монда поты бер тиен!

— Син үзең дә әллә ниткән игенче түгел,— диде Белугин, балык исемнәрен төрләндерүгә соң дәрәҗәдә хәтере калып. Аның чын исеме Карп иде, һәм үзенең исемен дә, фамилиясен дә ул сөйми иде.

— Әйе, мин дә тумыштан игенче түгел. Әни дә, эти дә игенче булмаган,— диде Андронов, әкрен генә, салмак кына.— Тик шулай да мин син түгел, син мин түгел. Мин мужик һөнәренә, игенче һөнәренә чын күңелдән өйрәнергә тырышам, ә син аңа төкереп качасың.

— Тотынды!— диде Белугин, кулын селтәп, бурлаттай кызарынып.— Син ул лекцияңне комсомол җыелышында сөйлә. Мин инде андый лекцияләрне күп тыңлаган. Идейно чыныккан кеше мин. Эш мәсьәләсенә килгәндә, мәгълүм булсын, чебешне көз саныйлар, ә көз әле җитмәгән, яңа яз башы, шулай булгач, иртәрәк сайрамыйсың микән?

— Иртәрәк сайраган булсам, һич тә үкенмәм,— диде Андронов, тыныч кына.

— Минемчә, беренче булып монда Ваня кычкырды,— диде Наташа, ике арадагы әйтешүне бүлдереп.

— Дөрес, мин! Бирелӛм, Натка!— диде Белугин, ике кулын күтәреп.

«Минем өчен барыбер... барыбер...»— дип уйлады Һарун, утырган килеш йокымсырый башлап.

## XXIV

Иптәш кызлары чыгу белән, Фәридә йокыга китте. Ул бик каты йоклады. Ләкин күпмедер вакыттан соң ул искәрмәстән уянып китте, һәм баш авыртудан да, гомуми хәлсезлектән дә көчлерәк булып, ачырак булып шунда аны бер уй тетрәндереп җибәрде. Аның өчен бу бик үк күтелмәгән нәрсә дә булмады булуын; аның өчен бу һәртөрле газапларның, һәртөрле каршылыклы уй-тойгыларның, бер ноктага җыелып, яшен чаткысыдай ялтырап китүе булды. Ул үзенең ниндидер ярамаган эш эшләве турында уйлады; бернинди акланугa, бернинди гафу итүгә лаек булмаган тотнаксыз, җилбәзәк кеше булуы турында уйлады. Ул хәзер үзенә, үзенең кичәге кыланышларына бары гаепләү, хәтта җирәнү, чиркану күзлегеннән генә карады, һәм аның чын-чынлап коты алын-

ды. Аңлап та, аңлатып та булмаган, бөтен аңны-зиһенне томалап, албастыдай изеп торган бу курку тойгысыннан аның йөрәге сулкылдап тибәргә тотынды; маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. «Аһ, нишләдем мин, нишләдем!»— диде ул үз-үзенә, өзгәләнеп.

Шактый вакыт ул шундый газаплы уйларыннан котыла алмый ятты. Әмма шулай да озакламый бу аны алҗыта башлады, һәм шунда ук үзенең чамадан тыш бетеренгәнлеген, булып үткән «җинаятькә» чамадан тыш әһәмият биргәнлеген аңлап алды. Күз алдына Ислам килде... Ислам абыйсы килде, аның серле, дәһшәтле пышылдаулары ишетелеп китте. Аннан да аянычлырагы шул булды — оят, гарьлек тойгысының зәһәрен йомшартып, сиздермичә генә күңеленә татлы нәрсә өстәлгәндәй булды. «Аһ, нишләдем мин, нишләдем!»— диде ул тагын да үз-үзенә. Ләкин монысында инде ул аһылдау авазлары дәртсезрәк, көчсезрәк булып чыкты.

Шул ук вакытта диярлек ул Һарун турында уйлады. Ул хәзер Һарунга әз генә дә үпкәли дә, ачулана да алмады, киресенчә, аның алдында ул үзен бик-бик гаепле итеп, бурычлы итеп сизде. Бит ул аны ташлап китте, иң кыен вакытта ташлап китте! Нишләде икән ул? Сөрде микән төнлә? Берүзе ничек сөрде икән? «Аһ, нишләдем мин, нишләдем!»— диде ул өченче кат, ихлас бер үкенү белән.

Ул бары юынгычка чыгып битен-күзен генә юды; эш киемнәрен генә киенде дә, ашап та тормастан, хәтта ул турыда исенә дә кертеп карамыйча, басуга китеп барды.

Үзенчә ул бик ашыгып барды, йөгерә-йөгерә барды. Ләкин чынында ул бик үк йөгерә дә алмады — авыр эш киеме һәм гомуми хәлсезлек тиз арада үзен сиздерә башлады. Шулай да ул бернигә игътибар итмәде, тыны бетеп, абынып-сөртенеп, кызу-кызу һаман баруында булды. «Тизрәк, тизрәк!»— диде кемдер, арттан куалап. «Тизрәк, тизрәк!»— дип кабатлады ул күңеленнән, алга — басу, буразналар ягына ашкынып.

«Шундый вакытта... шул башың белән... ничек чирләп ятмак кирәк?— дип уйлады ул, үз-үзен шелтәләп.— Нинди йөз белән чирләп ятмак кирәк хәзер? Нинди чир ди ул! Ул авыру түгел, ул тап-таза. Кызлар сүзенә ышанып... иркәләнеп... Бөтенесе эшләгәндә, бөтенесе кырда, басуда булганда... нинди оят, нинди хурлык! Һарун хаклы, йөз мәртәбә, мең мәртәбә хаклы. Хәзер инде үпкәләү юк... бернинди үпкәләү, ачулану юк аңа. Аның да җаны бар. Ул әнә үпкәләп тә, иркәләнеп тә тормады. Сөрде микән, нишләде икән? Кайда икән хәзер? Ни генә

булмасын, тизрәк аны табарга кирәк, күрергә, гафу үтенергә кирәк».

Күңеленә аның шундый уйлар килде. Үз уйларына бирелеп, ул тирә-якка бөтенләй диярлек күз салмады. Ләкин берзаман башын күтәребрәк караган иде, үзеннән алда, еракта юл буенча китеп барган тракторны күреп алды. «Әле яңа баралар икән, соңга калмаганмын икән»,— дип уйлады ул, сөенеп.

Берничә минуттан ул тракторны куып җитте, кулын болгый-болгый, кычкыра-кычкыра алга чыкты. Аны шундук күреп алдылар, туктап калдылар. Үз каршысында Һарун белән Мансурны күреп, Фәридә, ни әйтергә белми, телсез-өнсез калды. Егетләр дә шулай ук аптырап киттеләр.

— Фәридә?!— диде Мансур, исе китеп.

— Фәридә?!— диде Һарун, күзләрен зур ачып. Фәридә бары еш-еш тын алды да, әледән-әле куллары белән күкрәгенә тотынды.

Сөйләшкән сүз ачыграк ишетелсен өчен, Мансур газны кыса төште.

— Нәрсә... ни булды?— диде ул, кабинадан башын сузып.

— Юк, юк! Берни булмады. Йоклап калганмын... Белугин кебек...

Һарун белән булачак сөйләшү турында Фәридә бөтенләй уйламаган иде. Йоклап калу турындагы сүзләр ничектер үзеннән-үзе ычкынды.

— Сине бит авырый диделәр. Терелдеңмени?— диде Һарун.

— Терелдем инде... мин озак чирләмим,— диде Фәридә.

— Әйдә, утыр алайса!— диде Һарун.

Кызга ул кулын сузды, аннары аңа кабинага менәргә булышты. Фәридә Мансур янына кереп утырды. Һарун аның сул ягына урнашты, кабина ишеген шартлатып япты да, кинәт сүзсезләнеп калган Мансурга ым кагып:

— Әйдә, тарттыр!— дип кычкырды. Җир башына җитеп, тракторны буразнага боргач, Мансур кызга борылып карады да:

— Сиңа, Фәридә, Илгизгә китәргә туры килер,— диде.

— Илгизгә?— диде Фәридә, аптырап.

Аның көләч йөзе шундук сүрелеп калды. Мансурның хуҗаларча Һарун янында утырып килүенә аның инде башта ук күңеле тырналып куйган иде; ул инде башта ук нидер сизенгән иде, ләкин, ни генә булмасын, һич тә мондый тәкъдим көтмәгән иде. Шулаймы дигән

сыман, ул Һарунга карап алды, аның кыяфәтеннән «шулай» икәнлеген аңлады һәм күрсенгәндәй итте дә, көттереп, әкрен генә:

— Ярар,— диде.

Аннары, телен йоткан төсле, кисәк кенә тынып калды, шәл очын бөтергәләде дә, карлыкканрак бер тавыш белән:

— Кая соң ул Илгиз?— диде.

— Ул бездән алда китте,— диде Мансур.— Без аны хәзер куып җитәрбез!

Мансур җиргә төште, һәм трактор, ашыгып, ачулы үкереп, бразна буйлап бара башлады.

## Өченче баб

### I

Язгы кыр эше, бер башланып киткәч, тукталмыйча берөзлексез һаман дәвам итте. Беренче кайгы-шатлыклар да, беренче курку-өркүләр дә — барысы да сизелмичә артта кала барды, истән чыга барды. Алары урынына икенче шатлыклар, икенче кайгылар туды, икенчеләре урынына өченчеләре туды, һәм бер-бер артлы алышынып торган шатлык-кайгылар белән, борчу-пошынулар белән көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте.

Дала күзгә күренеп үзгәрде. Кызулыгын көн дә арттыра барып, күктән якты кояш елмайды; елмайган кояштан мөмкин кадәр күбрәк нур алып, көч алып калырга, тизрәк буйга үсеп җитәргә ашыгып, җир өстеннән югарыга үләннәр үрләде. Баш өстендә исә көне буе көмеш тургайлар чыңы яңгырап торды.

Даладагы язның бозлы җилләрен дә, көн эчендә алышынып торган карын, яңгырын да татыган кешеләр, әле күптән түгел генә салкын чатыр-вагоннарда өс-башларын чишенмичә йоклап азапланган кешеләр, җылы, матур көннәр башлануга куанып бетә алмадылар. Ә аннан да куанычлырагы шул булды: туфрак көннән-көн саркый барды, ныгый барды һәм баштарак очраштырган уйдык-уйдык баткаклыклар, йомшак, юеш җирләр тәмам юкка чыкты. Җир өсте ныгу белән, тракторларга да җиңеләя төште. Әйе, бер башланып киткән эш туктал-мыйча берөзлексез дәвам итте. Ләкин шулай да бу зур эштә, бу җаваплы эштә көндәлек җитәкчелек сизелмәде, әйдәүче, рухландыручы көч сизелмәде. Бу, барыннан да бигрәк, бригадирга кайтып калды. Таран өчен әйтерсең дала да юк, яз да, тугайлар да юк һәм шулай ук тракторлар да, план да, эшчеләр дә юк иде. Эшкә керешүнең беренче көненнән соң ул сөрүчеләр янына бары ике-өч мәртәбә генә барып кайтты да бүтән анда күзгә-башка да күренмәде; иртә-кич смена алышынганда, техник карауга чыкса чыкты, чыкмаса чыкмады; таң аттымы, тегебу йомыш табып, Көктугайга китте; китеп, аннан йә исереп кайтты, йә үртәлеп, карасына орынып кайтты. Аның кайда булуы, нишләп йөрүе белән беркем диярлек кызыксынмады — аның кайда йөрүе, нишләп йөрүе инде болай да билгеле иде.

Бигрәк тә тәҗрибәсез яшьләргә кыенга туры килде. Җитмәсә, бригадир ярдәмчесе булып исәпләнелгән Касыйм Садретдинов та, инде апрель башларында ук ре-

монтта кулын сындырып, шәһәр больницасына озатылган иде.

Менә шундыйрак бервакытта бригадага директор белән баш агроном килеп төште. Хәер, моңарчы да алар монда әледән-әле килеп киткәлиләр иде, ләкин ул килүләрендә әле бригадада «шундыйрак вакыт» икәнлеге бик үк күзгә ташланып тормый шикелле иде.

Алар килеп төшкәндә, бригадир өйдә юк иде.

— Нәрсә, басуга киттемени?— дип сорады директор Тәзкирәдән.

— Киткән, пычагым! Көктугайдадыр,— диде Тәзкирә, кулын селтәп.

Таранны Горшков Көктугайда очратмаган иде. «Күрәсең, туп-туры район үзәгенә сыпыргандыр»,— дип уйлады ул бригадир турында. Шоферга ул басу ягына борылырга кушты.

Беренче басу инде сөрелеп беткән. Тракторлар, яңа буразна ярып, икенче басуны сөреп яталар. «Димәк, бүген төнлә сөреп бетергәннәр»,— дип уйлады Горшков.

Беренче басуның бүген төнлә сөрелеп бетүе һәм тракторларның яңа басуга тотынулары никтер аңа ошамады. Аның күңелендә ниндидер ризасызлык, ниндидер канәгатьсезлек тойгысы туды, әйтерсең бригадада эшнең тукталып тормыйча, көннән-көн алга китүе начар нәрсә, ярамаган нәрсә иде.

Күрәсең, Таранга булган ачу тәэсирендә туган бу ризасызлык, канәгатьсезлек тойгысына шулай да ул үсәргә ирек бирмәде. Аның үзе өчен үзе булдырган ныклы бер кагыйдәсе бар иде: беркайчан да ул эш кешесе алдында юкка-барга кәефсез булып, ачулы булып күренергә тырышмый иде, чөнки үзендәге караңгы чырайның, кәефсезлекнең бүтәннәрнең дә күңелен төшергәнлеген, алай гына да түгел, караңгы чырайлы кешенең үзенә карата бары тик кире тойгы, начар фикер генә туарга мөмкин икәнлеген ул бик яхшы белә иде.

Тракторлар сөреп, бозып бетергән юл буенча беркадәр баргач, ул машинаны туктатты да җиргә төште. Аның артыннан баш агроном да төште, һәм алар сөрелгән җир буйлап җәяүләп кенә киттеләр. Горшков, гадәтенчә, сөрелгән җирнең сыйфаты белән кызыксынды, кесәсендәге җыелма метрны алды да, юлдан чыгып, туфракның тирәнлеген үлчәп карау белән генә канәгатьләнмичә, һаман эчкәрәк керде һәм әледән-әле иелеп, йомшак туфракка метрын батырып-батырып алды. Шулай бер иелеп, бер тураеп сөрелгән җир өстеннән яңа буразналарга таба атлады. Аның артыннан, берничә адым арткарак калып,

шулай ук әле кулында балчык әвәләп, әле үлчәштергәләп, эче пошкан күңелсез кыяфәттә Остапенко атлады.

Кая гына бармасын, директор һәрвакыт диярлек баш агроном белән бергә йөри иде. Моның үзенә күрә бер сере бар иде. Иген игү һөнәренең барлык серләрен, барлык нечкәлекләрен белми торып, төп юнәлеше игенчелек булган шундый зур хуҗалыкка дөрес, оста җитәкчелек итү мөмкин түгеллеген ул, әлбәттә, бик яхшы аңлый иде. Аның бөтен нәрсәне үз күзе белән күрәсе, үз кулы белән тотып карыйсы, кыскасы, үзенә таныш булмаган һөнәрнең серенә төшенәсе килә иде. Ә инде моның өчен махсус агротехника, агрономия дәреслекләре укырга вакыты булмаганга һәм күбрәк вакытын совхозның һәртөрле хуҗалык эшләре белән, көндәлек вак-төяк мәшәкатьләре белән уздырырга туры килгәнгә, фән сүзе, тәҗрибәле практик сүзе ишетмәкче булып юлга чыкканда, бигрәк тә бригадаларга барган чакта, ул үзе белән әлеге шул Остапенконы ияртә иде.

Артык күп сөйләшми торган, күңелендә ниндидер уйфикерләре, зур планнары бар кеше сыман, һәрвакыт пошынган, уфтанган кыяфәттә йөри торган, тиешле кабинетка, тиешле өстәл янына утыртып куйсаң, теләсә нинди түрәдән, теләсә нинди министрдан ким утырмаячак эре, дәрәҗәле баш агрономга ул баштарак бик матур өметләр баглады. Ләкин Остапенко белән күбрәк бергә булган саен, теге-бу нәрсә турында аның киңәшләрен күбрәк ишеткән саен, аның агрономнан күңеле кайта барды. Ул аның бик гади шикелле тоелган нәрсәдә дә буталып, тотлыгып калганлыгын күрде һәм, никадәр гаҗәп булмасын, үзен кызыксындырган нәрсәләргә кайчандыр институт бетергән, диплом алган, алай гына да түгел, монда килер алдыннан Украинада чөгендер үстерү белән шөгыльләнгән бер зур гына селекция станциясендә ун-унбиш ел буена директор булып утырган Остапенкодан түгел, бәлки, совхоз эшчеләре арасындагы кайбер тракторчылардан, элекке авыл яшьләреннән өйрәнде һәм, үзе дә сизмәстән, Остапенкога түгел, бәлки, алар сүзенә колак сала башлады.

Сөрелгән җир буйлап барганда, директор чи калган урынга килеп чыкты. Кемдер буразнасын тәмамлаганда кайбер төштә чирек метр, кайбер төштә хәтта ярты метр киңлегендәге тар гына соргылт тасма калдырып узган иде.

— Карагыз әле, Кирилл Яковлевич, нәрсә бу?— диде Горшков, баш агрономны көтеп алып.

Остапенко аның бу соравын, күрәсең, агрономиядән

бирелә торган гади бер сорау дип аңлады һәм, дәртсез генә мыгырданып:

— Бу, Игорь Андреич, чи калган җир дип атала,— диде.

Горшков Остапенкога утлы күз карашы ташлап алды.

— Чи калган җир икәнлеген мин үзем дә беләм,— диде ул, кызмаска тырышып.— Ләкин бу бит турыдан-туры сезнең эшегез, Кирилл Яковлевич!

— Яңадан сөрдертергә кирәк булыр,— диде баш агроном, шул ук күңелсез, дәртсез бер битарафлык белән.

«Бүкән! Күзле бүкән!»— дип уйлады директор үзенең баш агрономы турында.

— Сөрдерергә кирәклеген дә беләм!— диде ул, каты гына итеп.— Кем сөрдерергә тиеш? Нәрсә, һәркемне директор җитәкләп йөртергә тиешмени?

— Барысына да каян җитешәсең, Игорь Андреич. Бригадир бар...— диде Остапенко, мыгырданып.

— Без менә шул бригадирларга ышанып ятабыз да! Чынында беркем дә җавап бирми,— диде Горшков, чынчынлап кыза башлап.

Шулай дигәч, ул тагын Таранны исенә төшерде, тагын аңа ачуы килеп куйды. «Күрәсең, талашмый булмас болар белән»,— дип уйлады ул, кәефе кырылганнан-кырыла барып. Остапенко белән аның артык сүз озайтып торасы килмәде. Берни әйтмичә, ул яңадан кузгалып китте.

Ә берничә адым атлагач, аңа аяк астындагы сөрелгән җир бүтән урыннардагы төсле үк батып тормый шикелле тоелды. Ул метрын җиргә батырып карады. Тирәнлек нибарысы унбиш-уналты сантиметр чамасы гына иде. Үз-үзенә ышанмыйча, ул тагын тикшереп карады, ләкин сай сөрелгән җир шактый киң булып чыкты. Директор, машинаны туктатырга кушып, шоферга кул болгады.

— Бу җирне билгеләп куярга кирәк булыр,— диде ул, беркемгә дә карамыйча, әмма чынында Остапенкога ишарәләп.

Шофер машина артына кыстырылган көрәген алды да чи калган җир турысына, юл буена тирән генә итеп чокыр казып куйды.

## II

Алар шулай эш белән мәшгуль булып ятканда, юлга таба бер-ике трактор якынлашып килгәне күренде. Горшков белән Остапенко, машинага утырып тормыйча, тракторларга каршы юнәлделәр.

Юлга беренче булып Илгиз килеп чыкты һәм, күрәсең,

башлыклар яныннан болай гына узып китүне уңайсыз санап, әйткәнне дә көтмәстән, машинасын туктатты да җиргә сикереп төште. Ул арада икенче трактор да буразна башына якынлашты. Монысы Белугин иде. Аксу станциясендәге трактор, Һарун рәттән өченче сменага киткән теге көнне, запчастьлар, тырма-фәләннәр төялгән арба өстерәп, бригадага кайтып төшкән иде. Һәм Белугин хәзер үз тракторында эшли иде.

Күп тә үтмәде, бик каты үкереп, дөнья бетереп «С-80» тракторы да җир башына килеп җитте. Бер-ике минуттан директор машинасы янында кечкенә бер төркем барлыкка килде.

Горшков, үзенең ачулы икәнлеген белгәнгә күрә, гадәттәгегә караганда да сабыррак, тынычрак булырга тырышып, җайлап кына, ашыкмыйча гына башта кешеләрнең хәл-әхвәлләрен сорашты, аннары шулай ук җайлап кына, ашыкмыйча гына сөрүгә кагылышлы теге-бу мәсьәләгә күчте. Ике арада шундук якынлык урнашты. Директор Таран турында сораштырды, киләме, карыймы, диде, сөргән җирләрегезне ничек кабул итәләр, диде, яхшы сөрәсезме, чи калдырмыйсызмы, диде.

Таран турында сүз чыккач та, Илгиз, беренче булып:

— Без инде ул Таранны онытып бетердек,— диде.— Ишетсәк шул кичләрен исерек тавышын гына ишетәбез.

Әллә аның артык кычкырып сөйләвен, әллә бригадирны яманлавын ошатмыйча, Белугин шыпырт кына Илгизгә төртеп алды. Директор аның бу кыланышын күрде һәм елмайгандай итеп куйды да:

— Әллә дөрес түгел?— диде Белугинга.

— Мин, Игорь Андреич, аның өчен түгел... Мин аның өстендәге тузанын гына кагып алдым,— дип ялганлады Белугин, күзгә карап.

— Нишләп дөрес булмасын!— диде Ислам, ялган сөйләп торуы өчен Белугинга ачуланган булып.— Бригадир түгел, чүпрәк баш ул, Игорь Андреич! Эшкә тотынганчы ничек мактанды: мин, имеш, фәлән дә төгән, минем, имеш, иген эшендә күзем чыккан!.. Миннән башка беркем дә сөрә дә белми, чәчә дә белми, имеш. Белгәч, ул менә монда килеп өйрәтсен, күрсәтсен. Без бит бу эштә, Игорь Андреич, сабый балалар белән бер. Бигрәк тә яшьләр. Әнә анда юлдан эчтәрәк берәү чи калдырып киткән, еландай сузылып ята...

Ислам авызыннан мондый сүз ишетеп, директор аңа сынабрак, җентекләбрәк карады. Исламны ул моңарчы да беркадәр беләә иде, тик аның турында билгеле бер карашы гына юк иде.

Ислам исә директор белән Остапенконың сөрелгән җир өстендә каранып йөрүләрен, ә шофер егетнең чи калган җир турысына чокыр казып куюын ерактан ук күреп килгән иде, чөнки аның буразнасы беренче басу янында гына иде. Нишләп йөрерләр алар анда? Билгеле, җиләк җыймаганнардыр! Аннары сөрелгән җирне ничек кабул итүләре турында да юкка гына сораштырып тормас.

— Алайса, еландай сузылып ята?— диде Горшков, Исламга эндәшеп.— Алай эшләсәк, егетләр, беркем безнең баштан сыйпамаячак. Барыннан да бигрәк, җир үзе бездән үч алыр.

Үзенең сүзләрен дөресләүне көткән сыман, директор Остапенко ягына карап алды. Баш агроном исә берни аңлатмый торган бер мыгырдану авазы чыгарды да буш, мәгънәсез күз карашын читкә борды, тирләгән такыр маңгаен учы белән сөртеп алды.

— Дөрес әйтәсез, анда чи калдырган җир бар, шулай ук сай да сөрелгән,— дип дәвам итте Горшков.— Гаепле кешесен табарга, яңадан сөрдертергә туры килер. Ә бөтен өстәмә чыгымны гаепле кешедән түләтәчәкбез! Күңелле эш түгел...

— Шулай,— диештеләр егетләр, сүлпән генә.

— Шулай булса, монысы соңгысы булсын!— диде директор, нык итеп.— Норма тутыру бик яхшы, арттырып үтәү тагын да яхшырак. Нормагызны арттырып үтәмәсәгез — хәтта бөтенләй үтәми калсагыз да!— беркем сезне җавапка тарттырмаячак. Инде җирне бозасыз икән, килделе-киттеле генә эшлисез икән, ул чагында сүз икенче төрле булыр!

Ул, йодрыгын йомарлап, утын яргандагы сыман, берике мәртәбә селтәнеп алды. Бу аның бик нык ачулы икәнлеген күрсәтә иде. Егетләргә уңайсыз булып китте, һәркем эченнән, шүрләп: «Минем җир түгел микән?»— дип уйлады.

— Яхшылап тикшерергә кирәк, Кирилл Яковлевич,— диде директор Остапенкога.— Андый җирләр әле, бәлки, тагын бардыр.

— Монда, Игорь Андреич, яшьләр генә гаепле түгел, бригадир да, учетчы да гаепле,— диде Ислам, бик борчылган бер кыяфәттә һәм шул ук вакытта бөтен гаепне нindидер «яшьләр»гә аударып:— Начар сөргән икән, кабул итмәскә тиеш! Ни өчен бригадир ул!

— Аны инде күптән типкәләп төшерәсе бар бригадирлыктан!— диде Илгиз.

Горшков эндәшмәде, бары тик кашларын гына җыерып куйды.

— Төнге сменада эшләүчеләрнекедер ул,— диде Кәрам.

— Дөрес, Игорь Андреич. Бездә кайберәүләр комсызланып төнлә дә, көндез дә сөрәләр,— диде Белугин.

— Ярый, эшләгез,— диде директор, беркемгә дә җавап кайтармыйча.

Ул тракторчылар белән саубуллашты да машинага кереп утырды. Яшел «газик», тракторлар сырлап бетергән тигезсез юлда як-якка тирбәлеп, әүмәкләп, Көктугай ягына китеп барды.

Машина шактый ераклашып өлгергәч, Белугинның кинәт нидер исенә төште.

— Әх, күсәкләр!— диде ул, үкенеп.— Сорарга оныткanбыз: иртәгә бит Беренче Май! Бәйрәмне ничек үткәрәбез? Тамак чылатырга шулай ук бернәрсә дә булмас микәнни? Әллә артларыннан йөгерергәме? Эһе-ей!..

— Акырма!— диде Ислам, кырт кисеп.— Ишетмәдеңмени нәрсә дигәнен? Язгы чәчү бетмичә торып, бернинди ял да, бәйрәм дә булмаячак дип кисәттеләрме? Шулай булгач, бәйрәмне без менә монда — буразнада ясаячакбыз... йомраннар, төлкеләр белән...

— Ничек ул алай?— диде Кәрам, төркем уртасынарак тартылып.— Минем андый сүз ишеткәнем юк. Ял иттерми эшләтергә аларның нинди хакы бар?

— Хак! Сиңа тагын хак!— диде Ислам, мыскыл белән.— Монда сиңа хак та юк, закон да юк. «Закон— тайга» монда. Тели икән, җәй буена ял иттерми эшләтә ала... колхоздагыча... Анда да бит мужиклар җәй көне тәүлегенә утыз алты сәгать эшлиләр. Алар ялның нәрсә икәнлеген дә белмиләр, аннары кыш буе йоклыйлар карга күмелеп, аю кебек... Шулай. Чөнки үзегез теләп килдегез, гариза биреп... Шыңшырга хакыгыз юк!

— Юк инде, ял иттерми, бәйрәм иттерми эшләтә торган закон юк,— диде Кәрам, үзсүзләнеп.

— Кит әле моннан!— диде Белугин, гадәтенчә Кәрамны төртеп җибәреп.

— Нәрсә-ә, Селедка!— диде Кәрам. Былагайланучы егетләргә Ислам олыларча кычкырынып алды.

— Җитте, ишәкләр!— диде һәм, эшкә тотынырга вакыт икәнлеген аңлатып, шундук урыныннан кузгалып куйды.

Төркем теләр-теләмәс кенә таралыша башлады. Белугин белән Ислам бергә киттеләр һәм бәйрәм турында бераз кычкырынып бардылар да кинәт пышылдауга күчтеләр — аларның, ахрысы, ниндидер уртак серләре бар иде. Аларның бу серле сүзләре трактор янына килеп

җиткәч тә бетмәде. Трактордан читкәрәк туктап, алар тагын ике-өч минут чамасы гәпләшеп тордылар. Ислам янышнан аерылып киткәндә, Белугинның кызыл йөзендә әле яңарак кына бөтенләй булмаган тантана һәм яшерен бер шатлык нуры балкый иде.

## III

Беренче Май бәйрәме быел якшәмбе көнгә туры килә иде. Бүген исә шимбә көн иде. Һәрбер бәйрәм алдыннан булганча, һәрбер җирдә булганча, монда да кичә кичтән үк аеруча бер җанлылык, күтәренкелек сизелә башлады. Кызларның вакытлары булганнары кер юдылар, барлык кием-салымнарын, төзәнү-бизәнү әйберләрен барлап куйдылар, бәйрәм көнендә нинди күлмәк, нинди кофта кию турында киңәшеп алдылар, былтыр язны туган якларында уздырган бәйрәмнәрне, ул чактагы күңеллелекләрне исләренә төшерделәр.

Бәйрәм рухы кичен тагын да ныграк сизелде. Арадан кемдер берәү, иртәгә, имеш, бәйрәм хөрмәтенә ял бирәләр икән, буфетка бер ящик ак аракы, бер ящик кызыл аракы кайта икән, дигән сүз таратып өлгерде. Бу сүзнең дөресме-түгелме икәнлеген беркем дә тикшереп тормады. Белугиннар, Илгизләр, Кәрамнар, төкерекләрен чәчеп, теләсә кем алдында шул турыда сүз куерттылар, булачак аракыларны хәтта үзара бүлешеп тә куйдылар: агы егетләргә, кызылы кызларга, диделәр, ләкин кызлар күп эчми, шуңа күрә кызылның яртысы да безгә булыр, диделәр.

Шулай шаулашып утырганда, буфетка машина белән азык-төлек алып кайттылар. Егетләр, дәррәү кубып, җиргә казып ясалган һәм түбәсе туфрак белән капланган баз янына ташландылар. Андроновның хатыны буфетчы Ира бүген чыннан да бик баеп кайткан иде, шунлыктан аның күңеле бик күтәренке иде.

— Аракы бармы, аракы?— дип кычкырды Кәрам, тамак ярып.

— Анысы иртәгә,— диде Ира.

Бу сүзләрне ул болай гына әйтте, андый сорауга бүтән төрле җавап биреп булмаган өчен генә әйтте. Беркатлы Кәрам исә аның бу сүзләрен чынга алды.

— Иртәгә була!— диде ул, куанып.

— Иртәгә? Була диме? Бик шәп!— диде Белугин.— Бүген эш көне, ярамый.

Бөтен дөньясын онытып, үз эше белән генә мәшгуль булган Ира бүтәннәргә дә, иртәгә, иртәгә, дип кенә җавап бирде, һәм алар да моны чынга алды.

Бүген Ира ике капчык шикәр, егерме биш кило май, печенье, конфет, кипкән балык һәм шырпы-папирос ише нәрсәләр алып кайткан иде.

Егетләр капчыкларны, әрҗәләрне кулга да тидермәделәр берничә минут эчендә барысын да баз эченә өеп ташладылар. Машина бушатылгач, әйберләр ничек кирәк алай урнаштырылгач, шундук сату-алу башланып китте. Барысы да, яктыны каплап, ишегалдына өелделәр, кычкырдылар, шаулаштылар, шикәр алдылар, май алдылар.

Шундый бәйрәмчә ыгы-зыгы шартларында бүген смена алышыну бүтән көннәрдәгегә караганда бер сәгать чамасы соңга калды. Кешеләр, үзләре дә сизмәстән, чыгырдан чыктылар һәм үзләренең төп эшләрен, төп бурычларын онытып җибәрделәр. Кайберәүләр хәтта, бүген төнге сменага бармаганда да яхшы булыр иде, дигән сүзләр дә сөйләштергәли башладылар.

## IV

Эңгер-меңгердә, бензовозга утырып, бригадага Таран кайтып төште.

Көндез ул, чыннан да, Көктугайда озак буталып йөрмичә, район үзәгенә китте. Район үзәгенә ул Ира белән, рабкооп председателе Галимов белән барды, дөресрәге, райпотребсоюздан азык-төлек алырга баручы машинага утырып, юлчы булып барды. Ул анда, билгеле, бераз төшереп алды. Кире Көктугайга кайткан чакта ул инде шактый кызмача иде.

Көктугайда ул бригада өчен азык-төлек һәм һәртөрле вак-төяк товар алды да, машина белән Ираның үзен генә кайтарып җибәрде. Үзе шунда торып калды. Галимовтан ул бүген шәһәргә дә бер машина киткәнлеген һәм ул машинаның бәйрәм хөрмәтенә дип беркадәр «ак баш» алып кайтуы ихтималын белде. Мондый хәбәр ишетеп аның тамагы шундук әтәч булып кычкыра башлады, һәм ул, төн уртасына чаклы булса да, шул машинаның кайтканын көтеп торырга булды.

Көткән машина кайтты. Көткән машина белән көтелгән «ак баш» та кайтты. Аны шундук тиз-тиз генә складка ташыдылар да бикләп куйдылар. Аракы алай бик күп түгел, кибеткә чыгарып тормасаң да була иде. Шуңа күрә, ачыктан-ачык сату-сатмау мәсьәләсен хәл иткәнче, хәзергә бу турыда теләсә кемгә шауламаска булдылар. Галимов белән әшнә булганга, Таран алай бик үк коры калмады: садакадан тигән ике яртының берсен

кесәсенә салды, икенчесен шунда ук бер-ике дусы белән аударып та куйды.

Нәкъ шул чагында, караңгы төшеп килгәндә, ул Горшковка юлыкты.

— Әйдәгез әле минем белән,— диде Горшков, үз артыннан аңа конторага барырга кушып.

Директорның коры гына, кырыс кына эндәшүенә, артык берни сөйләшмичә, туп-туры үз юлы белән китеп баруына карап, Таран аның хәзер аеруча кәефсез икәнлеген һәм хәзер менә бик тә күңелсез, бик тә яман сөйләшү булачагын сизенеп алды. Бик сирәк очракта гына булганча, кинәт аның култык астында, сул ягында нидер сызланып, чымырдап куйды.

Үз кабинетына кергәч, Горшков, өстендәге күн пальтосын салып тормыйча, туп-туры түргә узды. Утырды, йодрыкланган ике кулын өстәлдәге пыялага шапылдатып куйды һәм ачу китергеч дәрәҗәдә коры, рәсми бер тынычлык белән:

— Бригадада көненә ничә мәртәбә буласыз, Глеб Семеныч?— диде.

Таран һич тә мондый сорау көтмәгән иде, ул никтер аны эчкән өчен тирги башлар дип, «каты шелтә» белән, эштән куып чыгару белән куркыта башлар дип көткән иде.

— Ничек ничә мәртәбә?— диде ул, берни аңламыйча.— Мин бригадада торам, шулай булгач...

— Юк, мин ул турыда әйтмим,— диде Горшков.— Кырда, басуда... тракторлар янында ничә мәртәбә буласыз?

Таран шундук аңлап алды. Аңлау гына түгел, артыгы белән аңлады. Билгесезлек бетте, һәм билгесезлек бетү белән, газап та, шүрләү-курку да бетте. Үз-үзен ул кыюрак, ышанычлырак сизә башлады.

— Кайчан ничек туры килә бит!— диде ул, кара төк баскан ияк очларын сыпыргалап.— Кайсы көнне ике-өч мәртәбә буласың, кайсы көнне бөтенләй өлгереп булмый.

— Ягъни айнып булмый?— диде Горшков, аның сүзләрен үзенчә төзәтеп.

— Алай да булгалый: нәрсә яшереп торырга, Игорь Андреич!— диде Таран, сүзне тиз арада дусларча гәпләшүгә бормакчы булып.

Ләкин директорның кырыс, киеренке йөзендә бер генә җепсел дә кымшанмады. Ул, нык кысылган йодрыкларына таянган килеш, күкрәге белән бераз алга табарак авышты, ашардай булып, күзен дә чытмыйча, Таранга текәлеп карады. Бүлмәдә әз генә вакытка уңайсыз бер тынлык урнашты.

— Сез анда көненә бер генә мәртәбә дә булмыйсыз, Глеб Семеныч,— диде ул, ышандыргыч итеп.

Сөрүчеләр янында көненә бер мәртәбә дә булмаганлыгын Таран үзе дә бик яхшы белә иде, ләкин бу турыда директор авызыннан ишетү аның өчен хәтер калдыргыч булып тоелды. Ул каршы килде, дөрес түгел, диде, кабинетта утырып сез каян беләсез минем анда көненә ничә мәртәбә булуымны, диде. Директор исә үзенекен сөйләде, нindидер чи калдырылган, сай сөрелгән җирләр турында, игътибарсызлык, җавапсызлык турында сөйләде. Алар шулай әйткәләшеп яткан чакта, парторг белән Остапенко килеп керде. Якташын күреп Таран тагы да кыюлана төште.

Остапенко сүзгә катышмады. Горшков белән парторг аңа икәүләп акыл өйрәттеләр, куркыттылар, янадылар. Таран да алай бик аптырап тормады, беткән баш беткән диде дә, уңны-сулны карамыйча, селтәнергә-кизәнергә тотынды. Сез ораторлар, диде, сез эшләмисез, мин эшлим, диде, минем утыз еллык, кырык еллык стажым бар, сезнең ниегез бар, диде. Соңыннан эш хәтта шуңа барып җитте, беркем берни аңламады, беркем берни тыңламады. Тик шул чакны директорның: «Мин сезне бүгеннән куалап чыгарам!»— дигән сүзләре генә Таранның чамадан ашкан кайнарлыгын сүрелдерә төште һәм авыр таш булып туп-туры йөрәгенә барып утырды.

— Син китермәдең мине монда! Мине партия җибәрде!— диде ул, күкрәк сугып.

— Бар, ычкын! Айнып кил, шунда сөйләшербез,— диде директор, ишеккә күрсәтеп.

## V

Горшковның, мин сине бригадирлыктан куып чыгарам, дигән сүзләре торган саен Таранның ачуын кузгатты. Никтер ул хәзер бу дәһшәтле сүзләрдән әз генә дә курыкмады, аның өчен хәзер барыбер шикелле булып тоелды, тик аның хәзер үч аласы гына килде, шундый каты, шундый ачы сүзләр әйткән өчен директордан, парторгтан, барлык «начальстводан» үч аласы килде. «Туктале, миннән алда үзең куыла күрмә!— дип уйлады ул, Горшков белән бәхәсләшеп.— Мин кайда да югала торган кеше түгел, алтын бәясенә йөри торган кеше мин!»

Юл буенча ул шулай үзалдына дулап кайтты. Ләкин үз-үзенең күңелен күтәрмәкче булып никадәр дуламасын, янап әйтелгән куркыныч сүзләр һич кенә дә исеннән чыкмады. Ул кайткач та үз янына Ислам белән Димка-

ны чакырып алды. Аларның шат кыяфәтләрен күреп, аның яңадан ачуы кабарды. «Аларга рәхәт. Көләләр, шаяралар, сукин сыннар! Ә мин анда...»— дип уйлады ул, үзалдына сукранып.

— Ничә мәртәбә әйттем мин сиңа!— дип кычкырды ул Димкага.— Сөргән һәрбер җирне карап-тикшереп кабул ит, дип ничә әйттем мин сиңа! Кем чи калдырган, кем сай сөргән анда?

— Кем булсын — Белугин!— диде Димка, әз генә дә исе китмичә.— Әйтәсең, әйтәсең, тыңламый.

— Белугин?! Бар әле чакыр монда!— диде Таран, боерып.

Димка, җиңел генә кубып, сызгырынып, егетләр чатырына йөгерде.

— Нәрсә син, сукин сын, минем йөзгә кызыллык китермәкче буласыңмыни?— диде Таран Димка белән килеп кергән Белугинга.

Бригадирның ни өчен чакырганлыгын Белугин инде белә иде.

— Мин аны, Глеб Семеныч, кичә сменадан кайтканда ук яңадан сөреп чыктым... казып куйган чокырларыниләре белән!— диде ул.

— Аңлатыбрак сөйлә!— диде Таран. Аңа чыннан да барысын да аңлатып бирергә туры килде. Мәсьәләгә төшенгәч, ул беркадәр йомшый төште.

— Сөреп куюың яхшы булган,— диде ул.— Ләкин икенче мәртәбә бу эшеңне ишетәсе булмыйм! Җиде кат тиреңне тунап алырмын. Сезнең аркада менә миңа эләгә. Тикшерәчәкмен, комиссия җибәрәчәкмен, ди. И җибәрер дә!

— Җибәрсен! Берне түгел, бишне җибәрсен,— диде Ислам.

— Монысы тагын ни дигән сүз була? Ул сезгә гаеп ташлаган, икенче бригаданыкылар чи калдыралар, сай сөрәләр, дигән. Ә сез, имеш, шуны да күрмисез! Килсеннәр, карасыннар, ул чи калган җирнең хәзер әнә эзе дә юк. Җилләр искән! Кем хаклы да кем гаепле? Дөресме?

— Дөресен дөрес тә...— диде Таран, бик үк килешәсе килмичә.— Шулай да килмәүләре яхшырак. Бәйләним дисә, тырнак астында кер җитәрлек.

Ислам белән Белугинга, Димкага ул бүгенге очрашу турында сөйләп бирде. Аның үз-үзен яклауны, үзенә карата нинди дә булса җылы сүз ишетүне өмет итүен күреп, Ислам да, Белугин да, билгеле, директорны эттән алып эткә салдылар. Бигрәк тә Ислам тырышты. Синең әле аңа тагын да ныграк әйтәсең калган, диде, мин булсам,

әйтер идем аңа тиешлесен, диде. Мондый сүзләр ишетеп, Таранга җиңелрәк, күңеллерәк булып китте. Инде көтмәгәндә вагонга ихахайлап Тәзкирә килеп кергәч, аның тәмам күңеле күтәрелеп китте.

— Аракы кайттымы?— диде Белугин, үзен кызыксындырган төп мәсьәләгә күчеп.

— Кайтуын кайтты, саттырмаячаклар.

— Ник? Ә бәйрәм?

— Ниткән бәйрәм ул тагын?!— диде Таран, гаҗәпләнеп.

— Беренче Май бәйрәме, Глеб Семеныч!

— Кем әйтте сезгә аны бәйрәм булачак дип, сукин сыннар? Әле сөйләп торам ич, талашып кайттым, дип!..

— Бөтен бригат шаулый, папаша җаным!— диде Тәзкирә Белугин өчен җавап биреп.— Баядан бирле инде колак итемне ашыйлар — бәйрәмгә нәрсә пешерәсең дә нәрсә пешерәсең, диләр. Ит кайтамы, ит буламы, диләр. Каян алыйм мин ул итне, папаша җаным?

— Алайса, ял да, бәйрәм дә булмаячак?— диде Белугин.— Безне алдаганнар алайса? Бу бит коммунизмга каршы килә, күсәкләр! Башыгыз бармы сезнең шуны уйларга?!

Таран сораулы караш белән әле Исламга, әле Белугинга карап: «Бөтен бригада сөйли, бөтен бригада тели,— дип уйлап алды ул шундук.— Менә бу шәп булыр иде, Игорь Андреич! Бөтен бригада белән сөйләшеп кара син! Чынлап та, бәйрәм вакытында ял иттермәскә кемнең хакы бар? Бу колхоз түгел, совхоз бу! Юк андый закон! Менә шуннан соң сөйләшеп кара инде син бөтен бригада белән, хөрмәтле Игорь Андреич!»

— Алайса, бөтен бригада сорый, бәйрәм сорый?— диде ул, ничектер серле итеп.

— Бөтен бригат, папаша җаным!— диде Тәзкирә.

— Кичәдән бирле шаулашалар инде, Глеб Семеныч,— диде Димка да, сүзгә катышып.

— Май бәйрәмендә дә эшләргә дисәләр, иманнары булмас,— диде Ислам.— Нәрсә баш ватарга, Глеб Семеныч? Без алардан сорап та тормыйбыз, тотабыз да үзебез бәйрәм итәбез.

— Шула-ай...— диде Таран, мыгырданып.— Шулай, иртәгә ял, иртәгә бәйрәм!

## VI

Җыелышларда булсын, үзара сөйләшкәндә булсын, баш кешеләр әйтә килделәр, язгы кыр эшләрен мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә тәмамларга кирәк, диделәр, монда никадәр иртә чәчсәң, шулкадәр отасың, диделәр,

шуңа күрә сөрү-чәчү вакытында бернинди авырлыкларга карамыйча эшләргә туры киләчәк, диделәр. Мондый сүзләр сөрүгә төшкәнче әйтелде. Моңа беркем каршы килмәде, кирәк икән, эшлибез, диделәр, без монда курортка килмәгән, диделәр һәм, әйткәннәре буш сүз булып тоелмасын өчен, шунда ук зур-зур йөкләмәләр дә алдылар, берсен-берсе ярышка, узышка да чакырдылар.

Җыелышлар узып китте, тантаналы, кайнар сүзләр онытылды, сүз урынына йөкләмәләр, ярышлар һәм һәртөрле лозунглар урынына чын эш вакыты килеп җитте. Һәм шул чакны кайберәүләр бу чын эшнең җыелышларда җиңел генә әйтелгән җиңел сүзләр белән чагыштырганда һич тә җиңел түгел икәнлеген күрделәр. Кайберсенең эштән бик тиз күңеле кайтты, кайберләре ничек тә түзәргә тырыштылар, арада хәтта ачыктан-ачык шыңшучылар, сыкранучылар да табылды. Кыскасы, берничә көнгә сузылган авыр, киеренке эш вакытында һәркем инде ярыйсы гына йончылырга да өлгерде, һәрбер яңа эш башында, һәрбер өйрәнелмәгән эш башында була торган иң авыр чор — сынау чоры иде бу. Шуңа күрә Беренче Май көнен ял итәргә бригадирның рөхсәт итүе турындагы хәбәрне күпчелек шатланып каршы алды.

Җыелышларда зал яңгыратып, теләсә кемне таң калдырып матур сүзләр сөйли ала торган кешеләргә Һарун һәрвакыт кызыгып, көнләшеп карый торган иде, чөнки ул үзе андый кешеләр кебек шома итеп, матур итеп сөйли дә белми, хәтта аларча итеп уйлый да белми иде кебек. Ул бары эшли генә белә иде. Эш — аның бердәнбер таланты, бердәнбер осталыгы иде.

Бәйрәм турындагы, ял турындагы сүзләр аны кичәгенәк үк сагаерга мәҗбүр итте. Бу аңа бер дә ошамады. Ял итәсе, бәйрәм итәсе килмәгән өчен түгел, бәлки, бөтенләй икенче төрле сәбәпләр буенча ошамады.

Беренчедән, моңа кадәр һәр елны ул — һич югы, колхоз эшенә йөри башлаганнан бирле — Беренче Май бәйрәмен мәктәп балалары сыман урамда демонстрациядә яисә кырда-болында түгел, бәлки, кырда-басуда — эш өстендә каршылады. Авылда, колхозда бу бик табигый саналды, һәм беркем дә моңа каршы да килмәде, ризасызлык та белдермәде. Киресенчә, Беренче Май җитәр алдыннан һәм бәйрәм көнне аларны бигрәк тә нык кыздырдылар, бигрәк тә нык җилкендерделәр, «Май бәйрәмен хезмәттә яңа уңышлар белән каршылыйк!», «Бер генә сәгатьне дә бушка әрәм итмәскә!» кебегрәк өндәмәләр әйткәләделәр, бәйрәм көнне кемнең ничек эшләвенә, күпме эшләвенә аеруча игътибар иттеләр. Кыскасы, Беренче Май бәйрәме

аның аңында бүтән бәйрәмнәрдәге төсле эчеп исерү, урам буенча гармунга акырып йөрү көне булып түгел, бәлки, икеләтә тырышып эшләү көне булып, икеләтә киеренке, икеләтә җаваплы көн булып сеңеп калган иде.

Юк, ничек кенә әйтсәң дә, бер дә күңеле тартмады аның бу ял дигән, бәйрәм дигән нәрсәләргә!

Иртән басудан кайтып, тракторын заправка урынына китереп туктаткач та, ул иң элек кешеләрнең нәрсә сөйләвенә колак салды. Беренче шатлык-куаныч шаукымы инде узган иде, кешеләр кичәгегә караганда тынычрак күренәләр иде, әмма үз-үзләрен кичәгегә караганда иркенрәк, бәйрәмчәрәк тоталар иде, һәм ике сүзнең берендә: «Беренче Май», «бәйрәм» сүзләре кабатланыла иде.

Андый сүзләрне Һарун пошынып, хәтта ачуы килеп тыңлады. «Үзем генә булса да китәм!»— диде ул, кискен бер карарга килеп. Бу турыда инде ул моңарчы да уйлаган иде, тик әлегә тәвәккәллеге генә җитеп бетми иде. Ә хәзер, «бәйрәмчеләр» белән тагын күзгә-күзгә очрашкач, тагын аларның эчне тырный торган сүзләрен ишеткәч, ул усалланып куйды. «Китәм, теләсә нишләсеннәр!»— диде ул, кабатлап.

Белугин белән ызгышып алганнан соң, Вәгыйзь кайтканчы көн-төн ял итми эшләгәннән соң, ул элеккегә караганда да тынып-басылып калды, элеккегә караганда да үз эченә йомылып калды. Мансурдан башка, Вәгыйзьдән башка ул беркем белән рәтләп сөйләшмәде, аралашмады, һәркем алдында ул үзен бик киеренке итеп һәм ни өчендер гаепле итеп сизде. Күпчелек аны аңламады, Исламнар, Белугиннар сүзен кабатлады, комсыз, диделәр, карун, диделәр, кулыннан килсә, бөтен даланы берүзе сөреп бетерер иде, диделәр. Үзенә карата булган бу кире фикер аңа шундый нык тәэсир итте, кайчагында ул үзе дә үзенең хаклы булганлыгына шикләнеп куйды, һәм теге вакытта Белугинга эшләргә ирек бирмәвенә аңа чын күңелдән үкенергә дә туры килгәләде.

Ярый, анысы инде узды, бетте... Ләкин менә тагын аңа күпчелек фикеренә каршы килергә туры килә. Тагын! Берсе әле ныклап торып онытылып җитмәс борын!

«Туктале, әллә ашыкмаскамы соң?»— дип уйлады ул кинәт, икеләнгәндәй итеп. Әйе шул, төптән уйлап караганда, нигә кычытына әле ул? Чыпчык дулап киртә җимерә алмый. Ялкау икән, ялкау инде алар, хәзер инде аларны барыбер төзәтеп булмаячак. Көненә сигез сәгать эшләп, атна саен ял итеп өйрәнгәннәр дә монда да шуны куалар. Үзләренчә алар да хаклы. Бер ул гына совхоз эшен бетерә алмас. Бары тик аның үзеннән генә көләр-

ләр — юк, көлеп кенә дә калмаслар, иң беткән кешегә, иң начар кешегә саный башларлар, күз кырыена да чыгармаслар... битеңә төкерерләр, валлаһи төкерерләр! Шулай, иптәшкәем, кеше ял иткәндә, ял итәргә, кеше эшләгәндә эшләргә — беркем бер сүз әйтә алмас, беркем бер шелтә ясый алмас. Үз-үзеңне бел дә тик йөр. Вәссәлам!

Ул шулай уйлады. Бу инде аның өчен иң соңгы карар булды. Күңеле тынычланып ук җитмәсә дә, мәсьәлә беркадәр ачыклана төште.

## VII

Һарун белән Мансурның кайтканын күреп, чатырдан Вәгыйзь килеп чыкты.

Битенә сипкел сыман бөртек-бөртек тут сибелгән, җирәнсу чәчле һәм тыныч холыклы Вәгыйзь яше буенча Һарун белән бер чамадарак иде. Ул да төбе авыл егете иде, ләкин монда авылдан түгел, бәлки, заводтан, слесарьлыкка өйрәнчек булып эшләгән җиреннән килгән иде. Һарун белән алар бик дус, тату эшлиләр һәм нинди генә мәсьәләдә булмасын, үзара уртак сүз таба алалар иде, уртак сүз тапмаган очракта да, беркайчан да алар арасында тәмсезләнү булмый иде.

Өстенә Вәгыйзь эш киеме кигән иде, ләкин шулай да анда гадәттә булмаган җиңеллек, күтәренкелек сизелә иде. Ныклап торып, җиң сызганып эшләргә уйламыйча, аның болай гына, үз чиратын уздыру өчен генә чыкканлыгы әллә каян күренеп тора иде. «Әллә салып алырга да өлгергән инде?»— дип уйлады Һарун, аның мондый җиңеллеген һич тә ошатмыйча.

— Нәрсә, аракы кайтканмы әллә?— диде Мансур, күңелле елмаеп.

Ул да, күрәсең, Вәгыйзьне кызмача дип уйлады.

— Кая? Мондамы?— диде Вәгыйзь.— Складта бар, ди, саттырмаска итәләр, ди. Таран бүген бөтен бригада белән барып склад басмакчы була.

— Алайса, безнең өчен дә тырышырсыз инде,— диде Мансур.

— Нишләп алай? Бергәләп басарбыз складны!

— Таран белән бергәләп склад басасы гына калганые менә монда!— диде Һарун, караңгы чырай белән.

— Нәрсә, әллә сез бармаска уйлыйсыз?

— Кая?

— Бөтен бригада, машинага төялеп, Иртыш буена барырга җыена. Шунда юл өстендә склад басмакчылар. Аракы булачак.

— Колагымны тондырдылар инде шул аракылары белән!— диде Һарун, үртәлеп.

— Аракысыз бәйрәм бәйрәм түгел инде ул,— диде Вәгыйзь, Белугин сүзләрен кабатлап.

— Ә без бәйрәм итмибез!— диде Мансур. Вәгыйзьнең көләч йөзе шундук сүрелеп калды. Ул инде Һарунның холкын белеп өлгергән иде, шуңа күрә Мансурны ул һич тә шаяртып сөйлидер дип уйламады. Дөресме дигән сыман, ул Һарунга карап алды да, хәтер калдырудан курыккандай, иплəп кенә, сакланып кына:

— Килешмәс бит, малай,— диде.— Тагын чәйни башларлар... үзегез беләсез...

— Белмим әле,— диде Һарун, көттеребрәк.— Менә синең белән дә киңәшергә уйлаганыем. Килешмәс дисең алайса?

— Нәрсә килешми, нәрсә килешми?— диде Мансур, кычкырып.— Ислам белән Белугин сүзенә карасаң! Барабыз! Көне дә ямьсез әнә, бер дә бәйрәм көне түгел.

Аның нык торуы Һарунга да тәэсир итте.

— Килешмәсә килешмәс!— диде ул, күңелендәге икеләнүен җиңеп.— Алар чәйнәвеннән куркып... чәйни бирсеннәр! Барабыз! Вәссәлам! Иртыш буенда исереп йөрүгә караганда, бураздада булу мең артык.

— Анысы шулай да шулаен...— диде Вәгыйзь, бирелә башлап.

— Шулай булгач, тагын сиңа ни кирәк?— диде Мансур.— Бүген без көндез дә эшләргә тиеш. Син шуңа каршы түгелме? Түгел! Ислам-иблисләрнең каршы булуында безнең эшебез юк. Каршы килеп кенә карасын!

— Минем дә анда бер дә аягым тартмый,— диде Вәгыйзь, тәмам бирелергә мәҗбүр булып.— Китик, булмаса, өчәүләп! Берүзем нишләп ятыйм мин монда?

## VIII

Һарун белән Мансур тиз-тиз генә эшләрен бетерделәр дә, усал телләр күзенә эләккәнче, алданрак ашап алырга булдылар. Ләкин алар соңгарак калдылар: өстәл янына килеп аш бүлдереп алулары булды, шундук берән-сәрән бүтәннәр дә җыела башлады.

— Көндез бригатта беркем калмый, теләсәгез нишләгез — сезнең өчен генә пешеренер хәлем юк,— диде Тәзкирә, Һарун белән Мансурның далага китәргә исәпләвен белгәч.— Минем дә кеше кебек ял итәсем килә, теләсәгез нишләгез, җанкисәкләрем!

Башкалар эшләгәнне эшләмичә, үзләре теләгәнчә

эшләргә исәпләүләре өчен һәм, шуңа күрә бүтәннәр күзе алдында үзләренең кисәк кенә дәрәҗәләре күтәрелергә тиеш дип исәпләп, өстәл янында Мансур үзен кинәт кенә кыю итеп, батыр итеп сизә башлады. Үзләренең сөрергә китәргә ниятләүләре турында инде бөтен бригада диярлек белеп өлгергән булса да, нишләптер хәзер менә шул хакта Тәзкирәдән башка беркемнең дә сүз кузгатмавы, бармагыз дип, сез дә ял итегез, дип үгетләмәве, һич булмаса, башта көтелгәнчә, чәйнәргә, кычкырынырга тотынмавы яшь егетнең күңелен тырнап куйгандай булды. Бөтен игътибарны аның үзләренә юнәлтәсе килде, һәм ул, мыштым гына кузгалып китәсе урында, Тәзкирәнең кытыгына төртелә торган сүзләр ычкындырырга тотынды.

— Сине бит төне буе ял иткән диләр — нигә көндез сиңа ял?— диде ул, мыскыллы елмаеп.

— Миндә эшегез булмасын!— диде Тәзкирә, пыраннап.— Әйткән сүзем сүз: пешермим булгач пешермим! Китүчеләр Көктугайда ашар, монда калучылар теләсә нишләсен. Бүген миңа да ял! Казанга бәйләнеп ятар хәлем юк.

— Пешермәсәң әллә, бик кирәгең барые!— диде Мансур, аның мондый тузынуына әз генә дә исе китмичә.— Казанга бәйләнеп ятасың килмәсә, әнә сабанга утырып йөре безнең кебек — анда бик җиңел.

Мансурның шулай дип әйтүе булды, кызуы җиткән Тәзкирә шырпыдай кабынды да китте. Сез генә эшлисез инде, диде, бигрәк борыныгызны күтәрә башладыгыз, диде, бары да шул Һарун аркасында, аның коткысы белән йөрисең, диде.

Мансурның телен тыймавына Һарун үртәлеп куйды, эндәшмә дигән сыман, аның кабыргасына төртеп алды да, кырмыска оясы чынлап торып кузгалганчы, тизрәк ычкыну ягын чамалый башлады. Ләкин кырмыска оясы инде кузгалган иде. Һәм аны инде берничек тә тыептуктатып булырлык түгел иде. Бөтен бригада ял итәргә атлыгып торганда һәм моның һич тә начар нәрсә, зарарлы нәрсә түгеллеге көн кебек ачык булганда, бары тик Һарун белән Мансурның гына, коллектив ихтыярына буйсынмыйча, үзләренчә мөгез чыгарырга исәпләүләре һәркемгә бик сәер булып тоелды, сәер генә түгел, хәтта яман нәрсә булып, индивидуализм булып, «капитализм калдыгы» булып тоелды.

Тәзкирәгә ияреп шундук аларны «тәнкыйтьләргә» тотындылар. Нәрсә бу, диделәр, әллә сез генә патриотмы, диделәр, юк, бу һич тә патриотлык түгел, коллективтан,

иптәшләреңнән аерылу бу, диделәр, эшне артка сөйрәү бу, демагогия бу, диделәр. Хәер, эшлиселәре килә икән, эшләсеннәр, аларны беркем тотмый, диделәр, тик шулай да ялгыз берни кыра алмаячаклар, диделәр. Ә Белугин мәсьәләгә бөтенләй үзенчә бәя бирде.

— Эх, күсәкләр, шуны да аңламыйсыз!— диде.— Акча котырта монда, акча! Бәйрәм итсәң, аракыга акча чыга, эшләсәң — керә! Беләбез мужик психологиясен!

Һарун, бер кызарып, бер агарып, өрә-өрә кружкасыннан кайнар чәй чөмерде. «Эх, тагын харап булдым!» — дип уйлады ул, үкенеп бетә алмыйча.

Ул аларның сүзләрен аермачык ишетә дә, аңлый да алмады. Ул аларның сүзен, аларның шелтәсен бары тойды гына — бөтен күңеле белән, бөтен әгъзалары белән тойды. Ул үзен кызган табада утырган кебек хис итте, ниндидер камалышта-чолганышта калгандай хис итте. Һәм иң яманы шул булды — арада аларны яклардай беркем дә юк иде. Ул да Мансур, Мансур да ул! Бүтән чакта төпле генә фикер йөртә торган Андронов та күренми — кайдадыр хатыны янында йөри. Вәгыйзь юаш, аннан яклау сүзе ишетү мөмкин дә түгел, якласа, аның үзенә ташланачаклар, Илгиз аумакай, сатлык җан... Туктале, әллә соң Таранга кереп әйтергәме? Нәрсә дип? Кыерсыталар дипме?! Киресенчә, ул үзе күргәнче-белгәнче башны алып олагырга кирәк моннан.

Һарун, шулай үзалдына уйланып, урыныннан торды да, әйдә, дигән сыман, Мансурның иңбашына сугып алды.

Алар кузгалып кына киткәннәр иде, ашыкмыйча гына атлап килгән Ислам күренде. Кичәгенәк Таран бүлмәсендә шактый озак утырганга һәм, иртәгә барыбер ял бит әле, диебрәк соңлап ятканга, аның йокысы туймаган иде, кәефе бик үк шәптән түгел иде.

Аның кухня янына килеп җитүе булды, Тәзкирә яңадан чәрелдәргә тотынды. Һаруннын кирелеген, үзсүзлелеген ул һич тә кичерә алмады. «Туктале, монда әле син генә түгел, җанкисәгем!» — дип уйлады ул, Исламны күрүгә сөенеп.

— Җибәрмәскә кирәк! Бригаттан узып беркая баралмас!— дип кычкырды ул Һарун артыннан.

## IX

Алдан ук Ислам бүген бернәрсәгә катышмаска, артык шауламаска дип, тәртипле, җайлы булып, бүтәннәр нишләсә, шуңа риза булып күренергә дип, үз-үзенә сүз биреп куйган иде. Аның исәпләвенчә, бүген нидер бу-

лырга, нидер җимерелергә-кырылырга тиеш иде. Ә мондый чакта читтәрәк калу аның өчен иң яхшысы иде. Таран әле гырлап, ыңгырашып йоклап ята. Хәер, әйткән сүзен кире алып, бригаданы эшкә кушарга исәпләсә дә, инде эш узган иде. Смена алышына торган вакыт узган, һәркемдә бары ял-бәйрәм кайгысы иде. Аларны инде Таран түгел, хәтта Горшков үзе дә тракторга утырырга мәҗбүр итә алмас иде. Шулай да Горшков үзе килеп чыкканда шәп булыр иде! Юк, бүген барыбер нидер булырга тиеш, барыбер дөньяның асты өскә әйләнергә тиеш!

Ләкин Һарунның далага китәргә җыенуы турында ишеткәч, ул кинәт үзгәреп китте. Ничек кыюлыгы җиткән аның?! Димәк, бөтен бригада булмаячак, димәк, каршы килүчеләр дә бар! Юк, аны болай узындыру килешмәс. Бер мәртәбә узынды, киреләнде, әмма монысында инде булмас! Бүген хәлиткеч көн. Белугин түгел бу, Фәридә түгел бу, Ислам бу! Ул инде болай да җитәрлек канга тоз салды.

Ислам өстәл янындагыларга ялт-йолт күз йөртеп чыкты. Һарун юк иде, ул инде Мансур белән икәүләп үз тракторы тирәсендә булаша иде. Ислам, ашыкмыйча, берни эндәшмичә, тракторлар янына китеп барды.

— Җибәрмәскә кирәк, җибәрмәскә!— дип кычкырды Белугин, Тәзкирә сүзләрен кабатлап.

Ул хәтта кычкыру белән генә дә канәгатьләнмәде, алдындагы чәен дә эчеп бетермичә, кабаланып, Ислам артыннан кузгалды. Аңа Кәрам иярде, һәм алар барысы да килеп тә җиттеләр, «баш күтәргән» тракторны уратып та алдылар.

— Нишлисең син монда, бозау?— диде Ислам, сүзләрен теш арасыннан чыгарып.

Һарун артына борылып карады, гаҗәпләнеп китте, шулай да коелып төшмәде.

— Минем нишләвемдә синең ни эшең бар?— диде ул, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.

— Минә нинди эшем бар!— диде Ислам һәм үзеннән-үзе күтәрелергә генә торган авыр йодрыгын селтәп тә җибәрде.

Һарун нәрсә булганлыгын төшенеп өлгергәнче, аның авыз-яңак тирәсенә тагын бер-бер артлы таштай авыр йодрык килеп кунды. Уттай янган иреннәрендә ул кинәт ниндидер юеш, тозлы нәрсә тойды. Ул, моның нәрсә икәнлеген ачыкламак булган сыман, кул аркасы белән авыз читен сыпырып алды. Кулында кан күрү әйтерсең аны котыртып җибәрде, һәм, аны-моны уйлап тормыйча, ул үзенең дошманына ыргылды.

Күпмедер секундка Мансур аннан өлгеррәк булып чыкты. Туптай атылып ул иптәше янына килеп тә җитте һәм, бокс алымы кулланып, Исламның уң як култык астына бер-икене тондырып та алды. Ислам өчен бу һич тә көтелмәгән нәрсә булды. Ул хәтта ыңгырашып куйды, Һарунны бер читтә калдырды да, яраланган ерткыч сыман чинап, үкереп, Мансурга ташланды. Шул ук вакытта ул җирдә аунап яткан автол чиләген эләктереп алды.

Ләкин Мансурга төбәлгән чиләк шулай да ычкына алмый калды. Исламның югары күтәрелгән беләген каяндыр килеп чыккан Андронов тотып алды. Чиләк кулдан төшеп китте. Андронов аны күн итеге белән тибеп очырды, һәм шул ук вакытта Мансур котырган Исламның икенче як беләгенә килеп асылынды.

Шулай итеп, сугыш бик тиз бетте. Белугиннар, Илгизләр, юатып, этеп-төртеп, Исламны читкә алып киттеләр.

— Әйдә... сөрт тә, киттек!— диде Мансур иптәшенә, кесәсеннән кулъяулык чыгарып.

Ләкин Һарунның әле ярсуы басылып җитмәгән иде.

— Мин әле... мин әле күрсәтермен аңа... күрмәгәнен!— дип сөйләнде ул, әледән-әле авыз читләрен сөрткәләп.

Мансур, җибәрмәскә итеп, аны беләгеннән тотты.

— Бәйләнмә,— диде Вәгыйзь дә, Һарунның юлына аркылы төшеп.— Хәзер кабызам, китәбез. Нинди бәйрәм булсын монда болар белән!

Ул, тиз-тиз кыланып, тракторның пускачын кузгатып җибәрде, ә бераздан тирә-яктагы чыр-чуны күмеп, көчле дөпелдәп, трактор моторы җанланып китте. Бу таныш дөпелдек тавышы һәркемне айнытып җибәргәндәй булды. Һаруннарның кузгалып китүләренә беркем диярлек игътибар итмәде. Трактор ераклашып өлгергәч, ярсыган кызгылт-сары Тәзкирә генә, йодрыкларын селкеп:

— Карун! Комсыз!— дип кычкырды.— Бөтен бригатны болгатып тик йөри, туймас тамак! Синнән дә калыр әле, дала киң... Башың аягың астына килгере!

## X

Яшьләр, бу күңелсезлек өчен кемне гаепләргә дә белмичә, әкрен генә таралышып беттеләр. Төнге эштән кайткан кайберәүләр, беркая барып йөрмәскә, хәзер үк ятып йокларга булдылар. Төнлә ял итүчеләрдә дә инде хәзер бәйрәм кайгысы калмады. Бер ярты сәгать чамасы шулай пошынып, зарланып үтте. Ләкин Көктугайдан ма-

шина килеп җиткәч, кәефләр яңадан күтәрелде. Шундук барысы да тыз-быз килеп юлга әзерләнә башладылар.

Барасы кешеләрнең барысы да машинага төялеп беткәч кенә һәм инде кузгалып китәргә дип шофер ашыктыра башлагач кына, кемдер Таранны исенә төшерде. Бер-ике кеше шаулашып бригадир вагонына йөгерде. Алар ишек шакыганда, Таран инде уянган иде.

— Глеб Семеныч! Глеб Семеныч! Тизрәк, тизрәк!— диделәр аңа, ашыктырып.

— Хәзер, егетләр, хәзер чыгам!— диде Таран, җавап итеп.

Бригадирның юынганын, капкалап алганын көтеп тордылар да кузгалып та киттеләр. Кызлар җыр башлап җибәрде, һәм барысы да юл буенча ду китереп җырлап бардылар. Күпчелек бу ялны, бу бәйрәмне дирекция тарафыннан рөхсәт ителгән дип, бүтән бригадалар да җыелышып Көктугайгамы, Иртыш буенамы баралардыр дип уйлады. Аларга хәзер Көктугайда йорт алларында, урамнарда халык кайнашадыр, демонстрация узадыр, музыка уйныйдыр шикелле булып, анда хәзер шундый ямьледер, күңелледер шикелле булып тоелды. Алар тизрәк шул күңелле шау-шуны күрергә, чуар киемле халык төркеменә кушылырга ашыгып бардылар.

Менә машина Көктугайга якынлашты һәм выжылдап тәбәнәк саман йортлар арасына барып керде. Ләкин «урамнарда», йорт алларында, тирес өеме тирәләрендә бернинди халык төркеме дә, бернинди ыгы-зыгы да күренмәде. Бернинди демонстрация дә юк иде, бернинди трибуна да, кызыл байраклар да, чәчәк бәйләмнәре дә юк иде. Урамда өтәләнгән бер-ике дала эте селкенеп йөри дә бер йорт каршында яшь бала күтәреп яшьрәк кенә бер хатын басып тора иде. Аннары тузанлы юлдан ашыгып кара киемле ике кеше китеп бара иде. Шулай да, бәйрәм икәнлеген белдереп, контора урнашкан йорт янында, телефон баганасында моңсу гына кызыл әләм салынып тора һәм радиоузел вагоны ягыннан, эчне пошырып, күңелләрдәге бушлыкны арттырып, бәйрәм музыкасы уйный иде.

— Менә сиңа бәйрәм!

— Эх, юкка килеп йөргәнбез!

— Кая булып беткән халык?!— диештеләр кешеләр, исләре китеп.

Мондый хәлне күреп хәтта Таранның да кәефе үзгәрде. Ул инде юл буенча Горшков белән булачак очрашу, сөйләшү турында уйлап килгән иде, шул очрашу-сөйләшүдә үзен ничегрәк тотарга кирәклеген исәпләп, үз-үзен дәртләндереп, батырайтып килгән иде.

Машина гадәттә туктый торган урынга — контора белән ашханә урнашкан йорт каршысына килеп туктады. Контора бикле, ашханә эшләми иде. Берничә кеше җыелышып кибеткә йөгерде. Таран Ислам белән Белугинны гына ияртте дә склад ягына китте. Үч иткәндәй, монда да беркем очрамады. Алар Галимов тора торган йортка юнәлделәр. Бәхеткә каршы, анысы өйдә булып чыкты. Беркадәр тарткалашкач, ы-мы итеп торгач, Галимов бригада өчен бер ящик бирергә риза булды.

Бәйрәм болай әйбәт үтте. Аракы җитәрлек булды, ашауэчүгә шулай ук мохтаҗлык сизелмәде. Аннан да яхшырагы, исереп бер-берсенә бәйләнүчеләр бөтенләй булмады. Ләкин һәркемнең үзалдына эче пошты, нидер җитми шикелле булып, нидер ким булып тоелды. Кичкә таба кайту ягына борылгач исә, килгәндәге кебек күңелле чырчу да, җыр тавышы да ишетелмәде.

Күңелләре дөрес сизенгән булып чыкты: Иртыш үзәнлеген артта калдырып, Көктугай авылы урнашкан тәбәнәк калкулык өстенә килеп менгәч тә, кабинадагылар алда, контора тирәсендә торган ят машиналарны күреп алдылар. Ят машиналар тирәсендә ниндидер ят кешеләр — зур дәрәҗә кешеләре дә бар иде. Шунда ук совхоз директоры да, бөкрәеп йөри торган чандыр парторг та, юан корсаклы Остапенко да күренә иде. Таран шоферга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды. Ләкин шул ук вакытта ят машиналар янындагы төркемнән аерылып, каршыга таба йөгереп килүче Горшков күренде. Ул ачу белән шоферга йодрык болгады һәм карышырга бернинди урын калдырмый торган кискен бер хәрәкәт белән ишарәләп, контора ягына борылырга кушты.

## XI

Һарунның йөзенә карарлык та түгел иде; сул як күз төбе шешеп, күгәреп чыккан, ирен читләре шулай ук күпкән, канаган иде; күпкән, канаган урыннар сул як чигәсендә дә күренеп тора иде, ике як яңагы, колак төпләре — бөтен башы-күзе уттай яна, сызлый; ә кәефе чамадан тыш яман иде.

Юл буенча ул берни эндәшмәде. Нәрсә генә сөйләсәң дә, беренче сүз иң әүвәл әлеге шул нәрсәгә барып төртеләчәк, ә ул нәрсә күңелдә шундый яңа, шундый ачы иде — кузгатмыйча да ул кузгалырга гына тора иде.

Алар шулай берни сөйләшмичә буразна башына барып җиттеләр, буразнага керделәр.

— Син ял ит, үзем сөрермен,— диде Вәгыйзь Һарунга.— Көртлек әйткәндәй, көрткә чумсак та бер... көнгә чыдарбыз әле.

— Юк,— диде Һарун, суелган, кителгән калын иреннәрен көчкә аерып.— Мин сөрәм... аннан син...

Вәгыйзь кабинаның сул ягынарак күчеп утырды һәм үз күңелен үзе күтәрергә тырышып, «Башмагым»нан бер көй шыңшырга тотынды. Ул шулай җырлар-көйләр шыңшырга ярата иде.

Таныш буразна буенча беркадәр җир киткәч тә, күз алдында таныш дала, таныш табигать җәймәсе җәелә башлагач та, тракторның корыч йөрәгеннән беләкләренә, аяк-балтырларына таныш җылы, таныш дерелдек йөгергәч тә, Һарун үзенең онытыла, тынычлана барганлыгын тойгандай булды; күңел җәрәхәте дә, тән җәрәхәте дә әкренләп-әкренләп бетә башлагандай булды. Дөресрәге, ул үзенең кыйналу хурлыгыннан, үзенең барлык газаплы, авыр уйларыннан аерылгандай булды. Аны хәзер бөтенләй икенче дөнья, икенче тормыш җәлеп итте, бөтенләй икенче дөнья, бөтенләй икенче тормыш үз эченә, үз кочагына алды.

Күңеленнән ул кошларга, кәрлә куакларга эндәште, тыз-быз чабышкан йомраннар белән, эледән-әле күренгәләп калган төлкеләр белән әйткәләшеп алды һәм бертуктаусыз дала белән, шундый якын, шундый таныш, кадерле киң дала белән, күктәге болытлар белән әңгәмә алып барды. Ул аларга үзенең кайгысы турында сөйләде, җиңелүе, кыйналуы турында, бөтенесе алдында хурга калуы турында сөйләде. Чыпчыклар көлде, йомраннар берни аңламаган булып кыландылар, астыртын төлкеләр, вак тешләрен елтыратып, борын очларын җыергалап, арттан хихылдап калдылар.

Бары тик күктәге болытлар гына аның барлык кайгы-хәсрәтләрен тын гына, тыныч кына тыңлап бардылар, аннары акыллы, киң күңелле карт дала гына барысын да аңлап-белеп ятты.

«Мин нинди киң, мин нинди зур!— диде дала, әкрен генә аның колагына пыш-пыш килеп. Үз гомеремдә мин күпне күрдем, күп кичердем, диде; ничә айлар, ничә көннәр туңып-өшеп кар астында яттым, ничә айлар, ничә көннәр эсселектән яндым-көйдем, шәрәләндем, котсызландым, диде; ә кайчакта ком-бураннар мине күмеп китте, диде. Әйе, дустым, мин күп күрдем, күп кичердем баштан, диде; берсе килде — таптап-мәсхәрәләп китте, икенчесе килде — ут-ялкынга тотты мине, диде; ә син килдең — тимер белән, очлы төрән белән актарырга кере-

шеп киттең, диде... Шулай да мин кайгырмыймын, мин һаман да тыныч, һаман бөек, горур»,— диде.

«Дала мәңге, дала бөек, дала горур!»— диде җил дә, яшел үлән сабакларын тарап.

«Кара миңа,— диде дала тыныч кына, ипләп кенә, елмайгандай итеп.— Мине берни ямьсезләтә, боза алмый. Кайгы фани, тормыш мәңге, дөнья мәңге!»— диде.

«Әйе, әйе, кайгы фани, кайгы бетә, тормыш мәңге!»— диештеләр ак болытлар әкрен генә, моңсу гына.

«Тапкансың пошыныр нәрсә! Курыкма, бирешмә, бул кыю, бул горур!»— диде бөркет, канатларын күктә салмак җилпеп.

«Юк, без әле бирешмибез! Күрсәтербез әле без аларга күрмәгәннәрен!»— диде кемдер аның колак төбендә.

## XII

— Кара, буразнага төштең!— дип кычкырды Вәгыйзь якында гына.

Һарун күзләрен ныграк ачып җибәрде. Шул чакны ул уң як табаннарның чыннан да буразнадан баруын күреп алды.

— Ярый, мин утырыйм инде, әнә кулларың да тыңламый,— диде Вәгыйзь.

Һарун, телдән язган кеше сыман, берни җавап кайтармады — пыяла аша алга, зәңгәрсу офык ягына төбәлгән килеш, кымшанмыйча-кузгалмыйча, урынында утырып тик барды.

«Куллар да тыңламый башлады шул»,— дип уйлады ул, күңеленнән Вәгыйзь белән сөйләшеп. Ник кеше арый икән? Булырга иде һәрвакыт уяу, барырга иде һәрвакыт шулай... болытлар белән, җилләр белән сөйләшеп...

Карарга иде бертуктамый шушы киң дөньяга, шушы киң далага... Сөрергә иде иңләп-буйлап...

Монысында Вәгыйзь үз сүзендә нык торды — көчләп диярлек тракторны туктаттырды да урыныннан күчеп утырды. Җирне бер мәртәбә әйләнеп чыкканчы, ул Һарун белән Мансурның икесен дә ял иттереп алырга исәпләде. Юлга кире әйләнеп килгәч, ул бригадага кайтып китмәкче булды. Бүген аның берничә хатка җавап язасы, Фәрханә апага керле киемнәрен юарга бирәсе бар иде. Аннары бит аңа бүген төнгегә чыгарга кирәк! Ни генә булмасын, ул монда көне буена кала алмый иде.

Вәгыйзьнең шулай килеп булышуы Һарун белән Мансурга ярыйсы гына файда булды.

— Рәхмәт,— диде Һарун, юл буена килеп җиткәч.

— Нәрсәсенә рәхмәт инде аның,— дигән булды Вәгыйзь, тыйнаклык күрсәтеп.

— Беләсезме, әйдәгез, бүтән вакытта да шулай итәбез?— диде Мансур.— Мондый көнне генә түгел, һәрвакыт... төнлә дә, көндез дә? Көндез ашарга туктагач никадәр вакыт әрәм була! Берең ашаганда икенчең сөреп торса, шәп булачак, валлаһи менә!

— Шулай шул,— диде Һарун, бөтенләй икенче нәрсә турында уйланып.

— Чынлап, әйдәгез, шулай итәбез,— диде Мансур.

— Мин каршы түгел,— диде Вәгыйзь.— Ләкин бүгенгә минем эшләр барые, кайтып кына килим инде.

— Китмә, ашап кит. Төш җиткән,— диде Һарун, киңәш итеп.

— Юк инде, сезнең өлешкә керергә монда...

— Нишләп безнең өлеш кенә булсын? Бездә биш кешелек азык бар!— диде Мансур.— Анда әллә Тәзкирә пешереп куйган дисеңме сиңа?

— Әйдәгез әле, без дә бер бәйрәм итеп алыйк!— диде Һарун, җанлангандай итеп.

«Бәйрәм» сүзе чыгу белән, иртәнге хәлне искә төшереп, өчесе дә берьюлы елмаешып алдылар. Хәзер инде алар тыныч иде, көлсәң дә хәтер калырлык, күңел тырналырлык түгел иде.

— Шулай да шәп бирдем үзенә!— диде Мансур, мактанып.

— Кара, нинди шешкән!— диде Һарун, күмәчтәй кабарган күз тирәсен сыйпаштыргалап.

— Бетәр әле, бәйрәмдә ансыз гына булмый инде ул,— диде Вәгыйзь һәм, кинәт кенә күңеле күтәрелеп, «Наемщик»тан дәртле бер көй башлап җибәрде.

Иртәннән бирле алар беренче мәртәбә өчәүләшеп көләргә, мыскыллашырга тотынып киттеләр. Шулай кинәт кенә ачылып китеп, сөрелмәгән җиргә утырдылар да Мансурның төенчеген чишеп җибәрделәр. Төенчектә чыннан да азык мул иде. Кичә кич алып куйган бер кило кипкән балыгын Мансур бөтенләе белән алып килгән иде, шуның өстенә тагын ике балык консервысы, ярты кадак май, шикәр, бер бөтен икмәк һәм дүрт шешә алма суы бар иде.

— Агы беткән, менә сезгә кызылы!— диде Мансур, шешәләрне берәм-берәм уртага куеп.

Егетләр янә көлешеп алдылар, газета өстенә таудай өеп ташланган балыкка үрелделәр, шатыр-шотыр китереп, кипкән балык сырты кимерергә тотындылар.

Бер ун-унбиш минуттан төшке аш тәмам булды. Һарун

алданрак туйды, алма суын шешә авызыннан гына авыз итеп карады да, җәһәт кенә кыланып, аягына торып басты. Шундук Мансур да кузгалды. Газета өстендәге нәрсәләрнең барысын да Вәгыйзьнең үзенә калдырдылар да тегү машинасы кебек җиңел генә келтердәп утырган тракторлары янына килделәр.

— Безнең бәйрәм күңеллерәк булды,— диде Мансур, өстендәге балык тәңкәләрен сыпыргалап.

Нәкъ шул чакта түбә өстендә самолет тавышы ишетелде. Өчесе дә берьюлы күккә карадылар. Төн ягыннан аларга таба ике канатлы «чикерткә» очып килә иде.

## XIII

Бригада турысыннан бүтән вакытта да берән-сәрән самолетлар очкалап тора иде, ләкин алар барысы да биектән очалар иде. Бу исә бик түбәннән генә очып килә иде.

Егетләр, дөньяларын онытып, самолетның үзләре турысына килеп җиткәнен көтеп тора башладылар. Озак көтәргә дә туры килмәде — бик каты пытырдап һәм кояшлы көндәге су өстен хәтерләткән яшькелт корсагын, аскы канатындагы кара саннарын, язуларын күрсәтеп, самолет баш өстеннән генә очып китте дә, кинәт бөтен гәүдәсе белән янтаеп, сөрелгән басу ягына борылды; аннары ерактан, офык читеннән, бер әйләнеп килгәч, тракторга якын гына бер җиргә килде дә төште.

Җирдәге кешеләр, нәрсә уйларга да белмичә, авызларын ачтылар да калдылар.

— Менә кызык!— диде Мансур.— Әйдәгез, янына барабыз.

— Ашыкма,— диде Вәгыйзь, ни өчендер шикләнеп.

— Адашты микәнни? Әллә бензины беткәнме?— дип куйды Һарун да.

Самолет, тракторга таба беркадәр йөгереп килгәч, туктап калды. Кабинадан башта мех итекле, күн киемле очучы төште, аннары, фюзеляждагы махсус уемнарга басып, уртачарак буйлы юан гына бер ир кеше төште. Башына ул яшькелт фуражка, өстенә көрән төстәге яхшы җиңел пальто, аякларына исә юан, кыска балтырларын кысып торган яхшы күн итек кигән иде. Битендә аның бераз гына шадрасы бар сыман иде. Кыяфәте җитдикырыс иде. Җиргә төшкәч тә ул як-ягына карангалап алды да, җирнең катылыгын-йомшаклыгын тикшереп карагандай, ничектер иплəп кенә, йомшак кына атлап, тракторчы егетләр янына килә башлады.

Егетләр, бер-берсенә елышкан көе, кайсы кулын биленә таянып, кайсы кесәсенә тыгып һәм мөмкин кадәр эре, җитди күренергә тырышып, шулай да билгесез бер сагаю белән, ят кешенең үзләре янына килеп җитүен көтеп тордылар. Күктән төшкән кеше, дүрт-биш адым җитми туктап калды да, ничектер теләр-теләмәс кенә, коры гына:

— Исәнмесез,— диде.

— Исәнмесез,— диде Мансур, шулай ук тыелып кына.

Бераз вакыт алар бер-берсенә карашып тордылар, аннары юан кеше, чатырлар ягына ымлап күрсәтте дә:

— Сезнең тораклармы анда?— диде.

— Безнеке,— диде Мансур.

— Кайсы совхоз җирләре бу? Әллә колхозмы?— диде кеше.

— «Татарстан» совхозы бу, колхоз түгел,— диде Мансур.

Ят кешегә ул бригаданың номерын да әйтте, бригадирның, совхоз башлыкларының исем-фамилияләрен дә әйтте. Аларын белгәч, күктән төшкән кеше бригадада ничә кеше, ничә трактор, нинди тракторлар булуы белән кызыксына башлады. Мондый сораулар комсорг Мансурны сагаерга мәҗбүр итте, һәм ул кисәк кенә тынып калды.

— Нәрсә, үзегездә ничә кеше, ничә трактор барлыгын да белмисезмени?— диде кеше, үчекләшкән сыман.

— Ник белмәскә! Беләбез!— диде Мансур.— Белүен беләбез — әйтергә ярамый.

Ят кешенең кырыс йөзе йомшарып, яктырып киткәндәй булды. Ул хәтта елмайган сыман күренде, тик елмайганда ул йөзе белән түгел, бәлки, күзләре белән генә, күз карашы белән генә елмайды.

— Нәрсә, сермени?— диде ул, Һарун белән Вәгыйзьгә мөрәҗәгать итеп.

— Сер шул!— диде Мансур.

Бер читтәрәк басып торган очучы көлемсерәп куйды. Ят кеше, юан муенын борып, аның ягына карап алды да, яңадан Мансурга эндәшеп:

— Нишләп бөтен бригададан бары сез генә монда, басуда? Бәлки, анысы да сердер?— диде.

— Бүтәннәр бәйрәм итә!— диде Мансур, һич тә кирәкмәгән бер горурлык белән, мактану белән.

— Ә сез ник бәйрәм итмисез?

— Итәсебез килми...— диде Мансур, буталып. Үз-үзен ничек тотарга кирәклеген ул онытып җибәрде. Вәгыйзь-

нең колак төбендә нидер пышылдап торуы, ә үзенең шул серле пышылдауга бирелеп, кинәт кенә шиккә төшүе аңа бөтенләй нигезсез булып тоелды.

— Димәк, сезнең ял итәсегез килми?— диде кеше, беркадәр тынып торганнан соң.

Ул пальто кесәсеннән ниндидер зур каплы папирос чыгарды. Катыргы савытны ачып, юан, озын бер папиросны авызына алып капты да, тартасызмы дигән кебек, егетләргә тәкъдим итеп чыкты.

— Ник тартмаска... Тартабыз аны!— диде Мансур, елмаеп.

Аның артыннан папироска Һарун үрелде, Һаруннан соң Вәгыйзь үрелде, һәм алар керле бармакларын хуш ис аңкытып торган ак тартмага тидереп, берәр папирос алдылар да җилгә арты белән борылып шырпы сызып җибәргән ят кеше кулындагы утка иелделәр, кабыздылар һәм кәгазь көпшәдән тырышып-тырышып тәмле, җиңел төтен суырырга тотындылар. Мондый хуш исле папиросны аларның әле төшләрендә дә күргәннәре юк иде. Барысы да бергәләп төтен суыра башлагач, ике арада эчке бер якынлык барлыкка килде.

— Ә сез кем буласыз соң?— диде Мансур.

— Сер!— диде кеше, хәйләкәр елмаеп.

Ул, күрәсең, җавап бирергә түгел, сорау бирергә генә күнеккән иде. Үзе турында ул шуннан башка бүтән берни әйтмәде, шулай ук Мансур да төпченеп тормады. Аның җиңелчә җил кискән симез, тулы йөзе яңадан җитди төс алды, һәм ул, өзелгән сүзен ялгап җибәреп:

— Алайса, сезнең бәйрәм итәсегез килмәде инде?— диде.— Ә шулай да сез инде бәйрәм итеп алгансыз.

Күз кырые белән генә ул Һарунга, аның җимерелгән авыз-борынына ымлап алды. Һарун, күпкән ямьсез ирен-нәрен бер-берсеннән аерып, елмайгандай итеп куйды:

— Булды инде...— диде ул, үзалдына мыгырданып.

— Сез, алайса, сугыша да беләсез?— диде ят кеше, төпченүен дәвам итеп.

— Ник сугышмаска!— диде Мансур.— Кирәк булгач, сугышасың да, талашасың да.

— Шулай укмыни?!— диде кеше, гаҗәпләнгән булып.

— Шулайрак шул,— диде Мансур, аның үзе кебек үчекләшү тонында.

Ул аңа иртәнге хәлне сөйләп бирде. Күктән төшкән кеше, аның сүзләренә ышаныргамы, ышанмаскамы дигән сыман, эндәшмичәрәк торды да, кыска гына итеп:

— Яхшы иткәнсез... сугышып!— дип куйды. Аннары юан бармаклары белән үзенең авыз читенә, күз төплә-

ренә кагылгалап алды һәм бөтенләй күңелләләнеп китеп: — Ә болар төзәлер!— диде.— Туйга кадәр эзе дә калмас.

Һарунга күңелле булып, җиңел булып китте. Ят кеше авызыннан — һичшиксез, зур кеше булырга тиешле кеше авызыннан — чыккан мондый сирәк гына мактау сүзләре аны кинәт дәртләндереп җибәргәндәй булды.

«Нинди кеше икән соң бу?— дип уйлады ул, торган саен ныграк кызыксынып.— Районнандыр дисәң, ник самолет белән килгән? Өлкә шәһәреннән микәнни? Әллә соң Алма-Атадан укмы?»

— Ярый, хушыгыз,— диде кеше, китәргә җыенып.— Армый эшләгез. Авыз күбүдән дә, күз төбе күгәрүдән дә курыкмагыз — үзегез әйткәнчә, кирәк икән, сугышыгыз да, талашыгыз да! Әйе, сугышыгыз, талашыгыз... һәрбер исерек башлар белән, сволочьлар, паразитлар белән!.. Ләкин үз сүзегездә нык торыгыз.

Ул ашыкмыйча гына самолетка таба юнәлде.

Шул чакны Һарун үзенең тракторын исенә төшерде. Ул Мансурга карады да әйдә! дигән шикелле кискен бер хәрәкәт ясады.

Трактор самолеттан элегрәк кузгалып китте. Һарුннар беркадәр ераклашып өлгергәч тә, яшькелт-соры дала белән күк чите тоташкан турыда, чатырлар-вагоннар ягында, юл буенча ашыгып килүче машина күренде. Бу, һичшиксез, директор машинасы булырга тиеш иде.

— Туктагыз әле, туктагыз!— диде Вәгыйзь, күктән төшкән кешеләргә кычкырып.— Әнә безнең директор килә.

Ят кешеләр туктап калдылар һәм көтә башладылар.

## XIV

Бер биш-алты минуттан «ГАЗ-69» машинасы килеп тә җитте. Кабинадан Горшков белән райком секретаре Нурсәетов һәм Остапенко чыкты. Алар ашыгып самолетка таба атладылар.

— Исәнмесез, иптәшләр!— диде күктән төшкән олы кеше.

Райком секретаре белән Горшковка, Остапенкога ул бер-бер артлы кул биреп чыкты.

— Петряев Иван Гаврилович,— диде ул, үзенең кем икәнлеген белдереп,— партиянең Үзәк Комитетыннан. Сезнең өлкә буенча вәкил.

— Беләбез, иптәш Петряев,— диде Нурсәетов.

— Белүен беләсездер дә, ләкин һич тә бүген үзегезгә кунакка килеп төшәр дип көтмәгәнсездер,— диде вәкил.

— Дөрес, көтмәдек,— диде Горшков.

— Бүген Беренче Май, самолетлар да очмый, беркем дә эшләми, дидегез инде, ә?

— Алай ук дип уйламадык та, иптәш Петряев,— диде Нурсәетов.— Дала киң, күк йөзе аннан да киңрәк — самолетлар да тыз да быз очып кына торалар.

Вәкил аңа сынабрак карады, баягыча кесәсеннән папирос чыгарды, аннары тартырга тәкъдим итте дә үзара әңгәмәне башлап җибәрде. Дөресрәге, ул сораулар бирде, совхоз директоры җавап кайтарды, башкалар әдәпле генә тыңлап тордылар. Горшков, ашыкмыйча, шулай да беркадәр дулкынланып, «Татарстан» совхозы турында, эштәге кимчелекләр-фәләннәр турында, кыр эшләренең бүгенге торышы турында сөйләде.

— Чәчә башладыгызмы әле?— диде кинәт вәкил. Бу сорауны ул шундый итеп бирде — Горшков, әйтәсе сүзен онытып, тотлыгып калды. Шунда ул әле генә үзе сөйләгәннәрнең вәкил өчен бөтенләй диярлек әһәмияте юклыгын һәм барыннан да элек аны нәкъ менә шул мәсьәлә — «чәчә башладыгызмы әле?» мәсьәләсе кызыксындырганлыгын аңлап алды.

— Юк әле, иптәш Петряев,— диде ул, сүлпән генә.

— Ник, әллә бәйрәм комачаулады?

— Юк, башка бригадалар эшлиләр,— диде ул, «бәйрәм» сүзенә үзенчә ачыклык кертергә тырышып.— Икенче бригада гына «бәйрәм» итә. Аның да яртысы гына...

Таранның ярты бригаданы ияртеп Иртыш буена китеп баруын директор белә иде инде.

— Калган яртысы әнә шул трактор да өч егетме?— диде вәкил, ераклашып баручы тракторга күрсәтеп.

Күңеленнән аның ярсыганлыгы, тузынганлыгы һәм үз-үзен бары тик көчләп кенә тыеп торганлыгы әллә кайдан сизелеп тора иде. Директор тынып калырга мәҗбүр булды. Дөресен әйткәндә, мондагы хәлне ул әле рәтләп белми дә иде, бригаданың яртысы Таран белән бергә булгач, яртысы, күрәсең, эшлидер дип уйлый иде.

— Бригадирдан уңмадык... исерек баш... Төшерергә туры килер,— диде ул, уңайсыз хәлдән котылмакчы булып.

Ләкин үзенең һаман ни өчендер акланырга, бар гаепне бары бүтәннәргә генә аударырга азаплануы өчен кинәт аның үз-үзенә ачуы килеп куйды. Нәрсә монда төчеләнеп торырга? Вәкил дигәч тә, ул да бит күктән төшкән Газраил түгел! Бүтәннәр шикелле үк ике аяклы, ике куллы. Мондагы авырлыкларны белергә тиеш. Дөньяга бүген килмәгәндер, шулай ук далага да... Нәрсә аңа юк-бар сөйләп торырга? Әйтергә дә салырга барысын да!

— Эшләр һич тә мактанырлык түгел, иптәш Петряев,— диде ул, ниһаять, көрсенеп.— Әле анысы җитми, әле монысы җитми. Яисә көтмәгәндә берәр төрле этлек килеп чыга. Аннары хәзергә әле тәҗрибә дә җитеп бетми.

— Аңлашылды. Ә кайчан чәчә башлыйсыз?— диде вәкил.

— Көннәр шушылай торса... шушы көннәрдә...— диде Горшков һәм дөрес әйттемме дигән кебек, Нурсәетов белән баш агрономга карап алды.

Бу мәсьәләдә аның төпле генә бер фикере дә юк иде. Югарыдан инде күптән күрсәтмә килгән иде, вакыт җитү белән шундук чәчә башларга, диелгән иде. Бер генә көнне дә, бер генә сәгатьне дә әрәм итмәскә дип һаман тукып торалар иде. Нурсәетов та бүген нәкъ менә шул мәсьәләне кузгаткан иде, һәм монда килергә чыгар алдыннан алар арасында әлеге шикеллерәк сүз дә булып алган иде. Ул үзе дә кирәк урында бик шәп итеп сөйли белә иде, һәм, вакытны кулдан ычкындырмыйк тагын дип, аның инде болай да күңеле сызлап йөри иде. Ләкин аннан ни файда? Үзең чын игенче, тәҗрибәле игенче булмагач, ул вакытының кайчан килеп җиткәнлеген ничек итеп дөрес кенә белә аласың? Моңарчы бу якларда иген игү белән бик үк шөгыльләнмәгәч, район кешеләре дә, хәтта менә Нурсәетов үзе дә бу мәсьәләдә кистереп кенә берни әйтә алмый. Аннары бер урында җир иртәрәк кибә, икенче урында соңгарак кала. Бер үк совхозда түгел, хәтта бер үк бригадада да җир бер үк төсле булмаска мөмкин. Ә моны үз вакытында чамалау өчен аеруча осталык, аеруча тәҗрибә кирәк. Монда инде Остапенкога гына ышанып булмый.

— Ә ник «шушы көннәрдә» генә?— диде вәкил.

— Җир юеш. Сылана, чәчкеч тәгәрмәчләре бата,— диде баш агроном, директорны үзенең авторитетлы сүзе белән коткарып калырга исәпләп.

— Сылаша? Тәгәрмәч бата?— диде вәкил, сынаучан-усал күз карашын Остапенкога күчереп.— Һәм шушы сүзне агроном кеше әйтәме? Сезнең гади такта кисәге күргәнегез бармы? Бардыр, булмый калмас. Булса, алай-са, һәрбер «рационализатор» уйлап таба торган гап-гади бер «яңалык» турында да ишеткәнегез бардыр? Чәчкеч тәгәрмәчләренә такта кисәкләре беркетәләр дә, бернинди батудан, сылашудан курыкмыйча чәчә бирәләр! Ә менә сезнең күрше районда такта урынына камыш көлтәләреннән файдаланалар. Монысы яңалык. Тырышкач табалар.

Күптән инде тартылып беткән папиросын ул җиргә атып бәрде дә, зур-зур атлап, әле генә кайтарылып калган буразна янына килде һәм хром итекләренең пычрануыннан да курыкмыйча, сөрелгән җир өстенә керде. Йомшак туфрак аның итек табаны астында батып-батып калды.

— Карагыз, күпме бата? Тездәнме, әллә бот төбеннәнме?— диде ул, кешеләргә борылып.

— Ярый әле, егетләр тиешле тирәнлектә генә сөргәннәр, югыйсә бәлале булыр идек,— диде райком секретаре, шаяртып.

Вәкил, җәһәт кенә иелеп, бер уч туфрак алды, аны камыр кебек әвәләп карады да, укмашып җитмәгән балчыкны җиргә томырды һәм шуннан соң, пычранган кулларын бер-берсенә бәргәләп:

— Беләсезме, иптәш Нурсәетов,— диде райком секретарена беркадәр тантана белән,— күрше районда инде өченче көн чәчәләр!— Бераздан тынычрак тонга күчеп, әмма шулай да катгыйлыгын, таләпчәнлеген әз генә дә йомшартмыйча: — Юк, иптәшләр, һич тә кояш киптергәнне көтеп ятарга ярамый. Бүген үк, хәзер үк тырмалый башларга, чәчә башларга кирәк,— диде.— Монда Татарстан да түгел, Мәскәү өлкәсе дә түгел. Монда корылыклы як. Табигать монда бик кырыс. Кояш та киптерер, җил дә җилләтер — авызыбызны ачып та калырбыз. Хәзер үк, бүген үк бер сәгатьне, бер минутны әрәм итми тотынырга кирәк! Чирәм җирләрдә мул уңыш алу, барыннан да элек, вакытында чәчеп калуга бәйле. Монда дым бик кадерле нәрсә. Кулдан ычкындырдыңмы — бетте, харап эш! Мин үзем Алтайда туып үскән кеше, дала миңа таныш. Хәер, иптәш Нурсәетовка сөйләп торасы да юк...

— Дөрес, иптәш Петряев,— диде райком секретаре.

— Ни әйтсәң дә, әлеге дә баягы шул тәҗрибә җитми,— дип куйды Горшков.

— Шулай,— диде вәкил, аның белән килешеп.— Ләкин тәҗрибә җитми дип, ярты юлда тукталып калыргамы безгә? Юк, без монда аның өчен килмәдек... Безнең кулда көчле техника бар, менә шундый кыю егетләр бар!..

Ул, төркем янына килергә бик үк кыймыйча, бер читтәрәк басып торган Вәгыйзь ягына ымлап алды. Барысы да Вәгыйзьгә әйләнеп карадылар. Аларның үзе турында сөйләшүләрен аңлап, тракторчы егет башын иде, читкә борылды.

Горшковны бу көннәрдә тагылма инвентарь мәсьәләсе борчый иде.

— Сабаннар, чәчкечләр җитми,— диде ул бераздан, зарланып.

— Ә бензовозлар җитәме?

— Бензовозлар җитә. Без бит кыштан ук үзәк поселокка дүрт цистерна китереп утырттык. Нефтебаза безнең үзебездә. Аннары һәрбер бригаданың кечерәк үз цистернасы бар. Ул яктан безнең кайгы юк.

— Алайса, сез байларча яшисез, иптәш Горшков!— диде Үзәк Комитет вәкиле.— Сезнең хәлләр начар түгел. Кайбер совхозларда менә тракторларга ягулык ташып өлгертә алмыйлар, шуның аркасында тракторлар тик торырга мәҗбүр. Сез, алайса, көн-төн чәчә аласыз. Көнтөн. Бер минут туктап тормыйча!

— Шулай итәчәкбез, иптәш Петряев,— диде директор, ышанычлы итеп.

— Ә тагылма инвентарь мәсьәләсенә килгәндә, мондый хәл бер сездә генә түгел, иптәшләр. Бу турыда без бик яхшы беләбез. Хәзер инде чарасы да күрелә башлады. Озакламый яңа сабаннар да килеп җитәр, чәчкечләр дә килеп җитәр. Ул мәсьәлә тулысынча хәл ителәчәк. Хәзер безнең бурыч — көтеп яту түгел, бәлки, булган кадәресе белән планны үтәп чыгу, чөнки безнең башка мөмкинлегебез юк. Карагыз әнә кояшка — хәзер ул нинди ягымлы, ә берничә атнадан, хәтта берничә көннән аның усаллана башлавы мөмкин!

Тагын беркадәр сөйләшкәч-гәпләшкәч, вәкил урыныннан кузгалып куйды.

— Ярый, иптәшләр, безгә китәргә вакыт,— диде ул, саубуллаша башлап.

Бер-ике минуттан пропеллер калтыранып, ялт-йолт килеп әйләнергә тотынды. Тирә-якны мотор тавышы күмде, үләннәрне сыпырып, җир өстеннән каты җил исте. Самолет җиңел генә күтәрелеп китте, һәм, тиз арада кечерәя барып, көнбатышка таба юл алды.

## XV

Никадәр күп эчмәсен, Таран бүген исерек түгел иде. Гадәттә ул үз-үзен оныта алган чакта гына, искәрмәстән генә исерә иде. Аның мондый онытылуы исә йә бик шатлыклы чагында, йә бик гамьсез чагында була торган иде. Ә бүген ул шат та була алмады, гамьсез дә була алмады. Ул бүген бик тынычсыз булды. Тыштан никадәр гайрәт ормасын, эчтән никадәр хәтере калган кеше булып кыланмасын һәм никадәр тотнаксыз, башсыз булмасын, шулай да ул үзенең бик үк килешеп җитмәгән эш эшл-

әвен аңламый булдыра алмады. Ул барысын да аңлады. Вакытның бик кадерле икәнлеген дә, мондый чакта бернинди яллар-бәйрәмнәр булырга мөмкин түгел икәнлеген дә бик яхшы аңлады. Ләкин аңласа да аңламамышка салынды, күңеленнән хәтта, мин аңласам да, бүтәннәр аңлап җитми, дип уйлады. Шулай булгач, диде ул, миңа артык бәйләнүче дә табылмас, диде, бәйләнәләр икән, бөтен дөнья пролетариат бәйрәмен тыярга сезнең хакыгыз юк, дип әйтермен, диде. Үз-үзен ул шулай тынычландырмакчы булды, ләкин көне буе аны бертуктаусыз үкенү корты кимерде. Кортны ул хәтта аракы белән дә үртәп чыгара алмады. Күрәсең, андый кортка аракының гына көче җитәрлек түгел иде.

Контора алдындагы тамашаны күргәч, Таран күңелендәге корт яңадан кымырҗый башлады. «Ну, Таран, нык тор!»— диде ул үз-үзенә. Машина туктап, кешеләр җиргә коелгач, шул ук сүзләрне ул Исламга да әйтте.

— Нык торырга!— диде.— Монда ниндидер козгыннар җыелган, чукып ташлаулары бар.

— Нәрсә котың алынды?— диде Ислам.— Әллә күрмәгән козгыннармы? Курыкма, бездән узып берни эшли алмаслар.

Аның мондый сүзләрен ишетеп, Таран беркадәр тынычлангандай булды, һәм ул, контора алдындагыларга якынлашкач та, үз-үзен бик иркен, хәтта чамадан тыш иркен, әрсез тотып, елмайган булып, башта райком секретаре Нурсәетов белән, аннары Горшков һәм бүтән ваграк башлыклар белән кул биреп күрешмәкче булды. Ияк очларын, авыз читләрен матур кара төк уратып алган озын матур сынлы Нурсәетов сузган кулны кире какмады. Горшков исә Таранны бөтенләй күрмәмешкә салынды. Директор шулай ук яшьләр белән дә каты гына, коры гына исәнләште.

Ә бер ун-унбиш минуттан контора йортында җыелыш башланды. Монда барлык бригадирлар, совхоз җитәкчеләре, район вәкилләре һәм совхозның һәртөрле җаваплы кешеләре килгән иде. Ләкин шулар арасында икенче бригаданыкылар күпчелек иде, шуңа күрә бу җыелыш гомуми совхоз җыелышы булып түгел, бәлки, бары тик икенче бригада өчен генә, аның да әле Иртыш буеннан кайтып килүчеләре өчен генә, ягъни аларны кыздыру өчен генә җыелган җыелыш булып аңлашыла иде.

Алма-Атадагы шәп фатирыннан фатирсыз далага күченеп килгәч тә, тазалыкка мантымаган, хәлсез, чирләшкә кыяфәтле парторг җыелышны ачып, көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — ул да булса, язгы кыр эшләренең бары-

шы һәм язгы чәчү, дип аңлатты. Шуннан соң ул Горшковка сүз бирде.

Директор, үз алдындагы нәрсәнедер төйгән сыман, авыр йодрыкларын бертуктаусыз селти-селти сөйләде, гадәттәгегә караганда кызып, дулкынланып, хәтта ачуланып сөйләде.

Таран аның бер генә сүзен дә аңламады. Ул, башын иеп утырган килеш, каш астыннан гына аның усал-салкын йөзенә карады, сәгать теле кебек гел аслы-өсле селкенеп торган ачу китергеч йодрыкларына, әледән-әле ачылып ябылган авызына карады һәм үзалдына үртәлеп-тынычсызланып: «Кайчан күчә инде төп мәсьәләгә?» — дип уйлады. Ә төп мәсьәлә аның өчен хәзер совхозның бүгенге көндә ничек эшләве мәсьәләсе дә, чәчү мәсьәләсе дә түгел иде, аның өчен төп мәсьәлә хәзер бары тик үзенә кагылган нәрсә генә булырга мөмкин иде.

Менә аның колагы кинәт үрә торды. Ул хәтта авыр башын күтәреп җибәрде. Бертуктаусыз селкенгән-чайкалган йодрык та, усал-салкын кыяфәтле кеше дә каядыр юк булды, бары тик күз алдында шул кешенең нык ачылган авызы гына күренде дә яңгыравык тавышы гына ишетелде. Горшков Үзәк Комитет вәкиле белән булган очрашу турында сөйләде. «Әһә, менә ни өчен корт чаккандай тыз-быз киләләр икән!» — дип уйлап алды Таран, үзенчә бер яңалык ачып. Директорның сүзләрен ул хәзер игътибар беләнрәк тыңлады. Көтмәгәндә, ниһаять, аның исеме дә телгә алынды.

— ...Таран... безнең ышанычны акламады! — дип кычкырды Горшков, дөнья яңгыратып.

Без аңа күп түзеп килдек, әйтеп тә карадык, киңәш тә иттек, ләкин безнең әйтү бернинди уңай нәтиҗәләр бирмәде, диде. Аның эшкә җавапсыз каравы, төкереп каравы аркасында иkенче бригада бүген эшне өзде, диде. Беркемнән сорамыйча, беркемгә әйтмичә, үз белдеге белән, диде, башбаштаклык, диде... Шушындый вакытта, иптәшләр, диде, җавапсызлык кына түгел бу, җинаять бу, диде... Моның өчен, диде...

Таранга бик-бик кызу булып китте. Бүлмәдә кеше утырмаган, кеше басмаган бер генә буш урын да булмаса да, контора эче ничектер бушап, тынып калгандай булды, һәм шушы котсыз буш бүлмәдә, тын бүлмәдә Горшковның сүзләре аеруча көчле булып яңгырады. Ни өчендер аңа директорның үзе турында әйткән сүзләре түгел, бәлки, шул сүзләрне шулай кычкырып әйтүе, хәтта урамдагыларга да ишетерлек итеп әйтүе куркыныч булып тоелды. Чит кеше тыңлап-нитеп тора күрмәсен та-

гын дигән сыман, ул тәрәзә ягына кырын күзен төшереп алды. Өй эчендә һава бөркү булганга, тәрәзәләрнең икесе дә бөтенләй ачып куелган иде, тышта чыннан даниндидер кешеләрнең тыңлап торулары күренә иде. «Бетте баш!»— дип уйлады Таран, күңеле төшкәннән-төшә барып.

— ...Без аның күп еллык стажы булуына карап тора алмыйбыз... Иртәгәдән совхоз чәчүгә керешә, шундый җаваплы чорда без аңа ышана алмыйбыз!..— дип янады директор, шул ук колак тондыргыч рәхимсез бер тавыш белән.

— Бик дөрес!— дип кычкырды кемдер арттан. Таранга бу якында гына, колак төбендә генә мылтыктан аткан кебек тәэсир итте. «Әһә, минем көчекләр өрә!»— дип уйлады ул, сискәнеп, ләкин кайсы «көчек» өргәнлеген аера алмады. Аның башы тагын да ныграк күтәрелә төште, сыек, нурсыз күзләрендә нәфрәт һәм явызлык чаткысы елтырап китте.

Ләкин шул ук секундта ул: «Тукта, бер көчек өрү белән генә... Бит әле бригада үз сүзен әйтмәде,— дип уйлады.— Бит әле Исламнар, Белугиннар бар!»

Күп тә үтмәде, ул көткән, ул өмет баглаган кеше үзе сүз сорады.

## XVI

Моннан бер атна-ун көн элек Исламның күңеленә бер тынгысыз уй төште. Бу уй кисәк кенә туды һәм бөтенләе белән аның барлык уй-хисләрен, барлык теләкләрен биләп алды.

Таран урынына ул бригадир булып калу турында хыялланды.

Бу турыда ныграк баш вата башлаган саен, бу эш аңа бик мөмкин шикелле булып, хәтта бик җиңел булып тоелды. Үз планын ул башта Мәрьямгә әйтте. «Тракторны аны камыт киеп тартасы түгел, аны ишәкләр тарта. Миңа бары кәгазьләргә кул куясы да, җыелышлар җыеп, ялкауларны кыздырасы гына кала,— дип шапырынды ул аңа.— Начармыни? Ни генә булмасын, сукыр тычкан кебек җир тырнау түгел. Сине үз яныма алам. Икенче көнне үк! Димканы куалап чыгарам. Яшибез икебез генә бер вагонны биләп! Теләсәң эшлисең, теләмәсәң — түшәмгә төкереп ятасың!»

Бераздан, читләтеп булса да, бу турыда ул Белугинга да сиздерергә кирәк тапты, чөнки бу эштә аның кебек сердәшнең бик тә кирәк булуы мөмкин иде. Белугин

моны хуп күрде: дөрес, диде, синнән башка монда бригадирлыкка ярарлык беркем юк, Таранны аны болай да алачаклар, директор аңа күптән инде теш кайрый, диде.

Горшковны Ислам тын да алмый тыңлады. Бу инде хыял гына түгел иде, бу инде хыялның тормышка ашуы дигән сүз иде... шул хыялның тормышка ашуына берике адым гына калды дигән сүз иде. Бу инде тимернең нәкъ кызган чагы иде! Һәм ул сугарга булды. Ул тагын да үзенең бер мәртәбә инде сыналган алымын кулланырга исәпләде — арттан килеп үз «дустына» пычак кадамакчы булды.

Директор сүзен бетерер-бетермәс борын ук, җыелышны алып баручы, кем сөйләргә тели, дип әйтеп бетерер-бетермәс борын ук, атылып ул урыныннан торды. Йөгерешкә китәсе кешенеке сыман аның йөрәге дөп-дөп типте, һәм шуңа күрә баштарак аның сүзләре бик тәэсирле булып, чын күңелдән сөйләнгән шикелле булып яңгырады. Сүзне ул бик шома, бик оста башлап җибәрде.

— Таран сүзенә ышанып, аңа ияреп без хата ясадык,— диде ул, турыдан-туры директорга мөрәҗәгать итеп.— Җаны бар кеше бүгенге көндә бәйрәм ясап, эчеп-исереп йөрмәс — соң булса да, без моны хәзер барыбыз да аңладык. Рәхмәт сезгә, Игорь Андреич, шундый шәп итеп аңлатып бирдегез! Әгәр мин үз иптәшләрем исеменнән әйтәм дисәм, һич тә ялгышмам дип уйлыйм...— диде ул, суларга тын җитмәгәндәй беравык тынып торганнан соң, һәм шул ук вакытта як-яктагы иптәшләренә тиз генә күз йөртеп алды.— Без бу хатабызны төзәтәчәкбез, Игорь Андреич... Икенче бригада моннан соң дирекция һәм партком йөзенә кызыллык китермәс! Бик каты сабак булды бу безнең өчен. Ә, Глеб Семеныч, сез инде ачуланмагыз. Без дә сезгә әйтә килдек, хәтта талашкан чаклар да булды. Тыңламыйсыз. Тыңлаудан узгансыз. Эштә түгел сезнең күңел... нәрсә аны яшереп торырга!

— Дөрес!— дип кычкырды тагын баягы тавыш.

— Сволочь!— диде Таран, пышылдап.

Шулай да аның тавышын ишетеп алдылар, ләкин бу сүзне ул Исламга карата әйткән идеме, «дөрес!» дип кычкырган кешегә әйткән идеме — беркем аңлый алмады. Аннары хәзер аның күңелен җилкендергән хис-тойгылар белән бик үк кызыксынмыйлар да иде. Аның гаебе чамадан тыш зур, һәм аны яклау, аңа теләктәшлек күрсәтү бу минутта мөмкин дә түгел иде. Таранның йөрәк

түреннән атылып чыккан нәфрәт ялкыны, гомуми тынлыкка, салкын битарафлыкка бәрелеп, шундук юкка чыкты.

...Исламнан соң бүтән бригаданыкылар сөйләделәр, совхоз, район башлыклары сөйләде, һәм көн тәртибендә төп мәсьәлә язгы чәчү мәсьәләсе булса да, сүз үзеннән-үзе Таран турында гына, аның эчүе, эшкә бармак аша каравы турында гына барды. Шуңа бәйләп аның барлык гөнаһларын, барлык хаталарын искә алдылар. Таранның беркайчан да тарак теше күрмәгән һәм укмашып беткән чәч араларыннан, күкрәгеннән салкын тир бәреп чыкты. Әледән-әле аңа учы белән маңгаен, муенын, колак артларын сыпыргалап алырга туры килде. «Чәйнәгез, чәйнә... Батырыгыз, батканны батыру җиңел ул!» — дип уйлады ул үзалдына. Шуннан башка ул җыелышка хәтта күңеленнән дә берни әйтә алмады. Ул бары бер генә нәрсә турында: калдырырлармы, юкмы, дигән нәрсә турында гына уйлады. Өченче бригада бригадиры Скребкин дигән дуңгыз аның урынына ниндидер Барый Рамазанов дигән кешене тәкъдим иткәч, калдыру-калдырмау мәсьәләсендәге икеләнү шундук юкка чыкты, һәм монда җыелып утыручыларның, сөйләүчеләрнең һич тә юри кыланмаганлыкларына ул инде ышанырга мәҗбүр була язды.

— Юк,— диде Белугин, Скребкин тәкъдим иткән кандидатурага каршы килеп,— безгә чит кешеләр кирәкми, безнең үз кешеләребез дә бар...

Аның бу сүзләре шундый кисәк кенә, шундый көтелмәгәндә әйтелде, шундый ашыгычлык белән, малайларча кабалану һәм хәтта беркадәр үпкә белән әйтелде — барысы да диярлек аның ягына борылып карадылар, елмайдылар, көлеп җибәрделәр.

— Чынлап!— диде Белугин, кызарынып һәм, иптәшләре белән бәхәсләшкәндәге шикелле, баш өстендә кулларын бутап алды.— Нигә безгә белмәгән кеше? Тагын әллә кемне китереп куярсыз да, тагын безне сүгә башларсыз. Куегыз әнә Ислам Мусинны! Кай җире белән бригадир булмаслык? Эштә алдынгы, үзе чибәр, үзе башлы.

Соңгы сүзләрен ул көлдермәкче булып әйтте. Чыннан да кайберәүләр пырхылдап алдылар, әмма шулай да җыелыш, баштагы олылыгын, җитдилеген саклап, тыныч көе калды.

Таранны бригадирлыктан алу мәсьәләсендә Горшков әз генә дә икеләнми иде. Ләкин Таран урынына кемне кую хакында аның әле төпле генә фикере юк иде. Ул инде парторг белән дә, бүтәннәр белән дә киңәшеп караган иде, ләкин алар да әлегә ачык кына берни дә әйтә

алмаганнар иде. Ә бит тизрәк табарга кирәк иде ул кешене, яшь, эшчән, булдыклы кешене!

Ислам Мусин?.. Әйе шул, Мусин... Болай үзе төпле генә күренә, фикерләре дөрес, алдынгы да... Тик шулай да нәрсәседер җитми кебек. Нәрсәсе җитми? Белмим. Шулай да ярамаслык түгел шикелле. Уйларга кирәк. Ә теге егетләр артык яшьләр. Кыюсызлар. Аннары ул бит аларның берсен генә күрде.

Туктале, нишләп соң бу Мусин дигәннәре Таран белән бергә эчеп йөри дә, ә тегендәгеләр, үз-үзләрен кыйнатып булса да, эшкә китәләр? Кем кыйнаган аларны? Бу турыда бит беркем берни әйтмәде! Кыйнашканнармы? Кыйнашканнар! Бетте-китте. Хәер, аңа карап кына кешегә дөрес бәя биреп тә булмый. Бригада фикерен белергә кирәк. Ә Барый Рамазанов? Анысы болай эшчән, булдыклы... Ләкин бит бригадир булу өчен ул гына җитми. Менә ул кешеләрне якыннан белмәү бәласе! Юк, беленә башладылар инде... Соңга табарак әле барысы да биш бармак кебек билгеле булыр.

Горшков икеләнгән чагында ашык-пошык карар кабул итәргә гадәтләнмәгән иде. Монда да ул ашыкмаска булды. Ләкин шул чакны Остапенко сүз сорады.

— Минемчә, иптәшләр.... ике тәкъдим булды...— диде ул, авыз эчендә ботка кайнатып.— Иптәш Белугин хаклы: бригадага белгән кешене куярга кирәк, ягъни бригада кешеләре үзләре яхшы белгән, ышанган кешене... Иптәш Мусин начар егет түгел. Бригада ышана икән, тәкъдим итә икән... Ә Таран... Глеб Семеныч мәсьәләсендә... шулай ук мин дә кушылам...

Баш агрономның сүзләре бүтәннәргә дә тәэсир итте. Хуплап, яклап әйткән сүзләр ишетелгәләде. Һәркем Ислам турында, шундый яхшы итеп сөйли белә икән, һичшиксез, эштә дә начар булмас, дип уйлады. Барый Рамазанов дигән кеше җыелышта юк иде, шуңа күрә аның кемлеген мондагыларның күпчелеге ныклап белми дә иде.

— Карагыз әле, Игорь Андреич,— диде Нурсәетов, урыныннан тормыйча гына,— бу бит икенче бригада җыелышы түгел — совхозның ачык партия җыелышы! Тикшерә торган төп мәсьәлә Таран урынына яңа бригадир сайлау түгел — язгы чәчү мәсьәләсе. Яңа бригадир турында, Таран турында икенче урында яхшылап сөйләшергә була, мәсәлән, бригаданың үзендә! Калганнар ни әйтә бит әле! Монда бригаданың яртысы гына, алары да «бәйрәмчеләр». Белгән кеше, имеш, үз кешебез, имеш! Без барыбыз да «үз кешебез». Безгә «белгән» кеше генә

кирәкми, безгә булдыклы, эшлекле кеше кирәк, икенче бригаданы үз артыннан алып барырдай кеше кирәк... Иртыш буена качып-посып аракы эчәргә алып барырдай кеше түгел,囡эштә... язгы чәчүдә, иген игүдә үз артыннан алып барырдай яхшы җитәкче кирәк! Болай бутамыйк әле без мәсьәләне. Төп мәсьәлә турында сөйләшик, бүгенге көндә иң төп мәсьәлә турында!

— Хәзергә без моны калдырып торыйк,— диде парторг, урыныннан торып.— Иртәгәдән чәчүгә тотынырга дип Таранны мәҗбүр итәргә кирәк. Вакытлыча ул үз эшен дәвам итәргә тиеш. Яңа бригадир турында без бригаданың үзе белән сөйләшербез. Ризамы, иптәшләр?

«Иптәшләр» риза булды. Таранга әйтерсең кинәт сур өрделәр. Аның тыны озаеп, күз аллары яктырып китте. «Таранннан башка эшегез барамы соң сезнең! Куркыттылар, янәсе! Таптылар куркытыр кеше!»— дип уйлады ул, батыраеп һәм моннан соң беркайчан да эчмәскә дип, шул ук минутта үз-үзенә ант итеп куйды.

## XVII

Икенче көнне иртән, әле дала уяныр-уянмас борын, бригада «авылы»ның нәкъ уртасында түземсезләнеп кычкырткан сигнал тавышы ишетелде.

Һарун өстендәге ябынгычын атып бәрде дә, яланаякларына кирза итекләрен элдереп, җылы тәненә кыска сырмасын каплап, тизрәк тышка ашыкты. Чатыр янында гына бер йөк машинасы тора иде, машинага капчыклап орлык төялгән иде.

— Нәрсә, үлеп беттегезме әллә?— диде шофер, Һарунны күреп.

— Юк әле,— диде Һарун.

— Бодай алып килдем, тизрәк бушатырга кирәк. Уят кешеләрне,— диде шофер.

— Мин бригадир булгач килерсең,— диде Һарун, бер дә исе китмичә.

— Анархия сездә — менә нәрсә!— диде шофер, сүгенеп.

Йокылы күзләрен көчкә ачыштырып, вагоннан Таран килеп чыкты. Ул ничектер үз-үзенә ышанып җитмәгән сыман гына, теләр-теләмәс кенә шофер белән исәнләште дә, тегесен-монысын сорашты да, үзенең әле бөтенләй үк бригадирлыктан төшерелмәгәнлеген, әле һаман хуҗа кеше икәнлеген күрсәтергә тырышкан шикелле, гадәт буенча гына мыгырданып, «начальствоны» әрләп алды, орлыкны аны алданрак ташып куярга кирәк

иде, диде. Шуннан соң гына ул шоферга машинаны кая илтеп туктатырга кирәклеген әйтте һәм ашыкмыйча гына олы чатырга юнәлде.

Кайчандыр көтүчеләр яшәгән һәм хәзер җимерелеп беткән саман кураның бер почмагы беркадәр сакланып калган иде. Сөрүгә тотынганчы бригада кешеләре сакланып калган шул почмакны чүп-чардан, салам-тирестән чистартып, түбә яптылар, өстәмә стеналар корамаладылар. Орлык саклау өчен үзенә күрә бу амбар хезмәтен үтәргә тиеш иде. Чатырдан Таран ияртеп чыккан егетләр машинадагы бодайны тиз арада шунда бушатып куйдылар.

Камыт аяклары белән алпан-тилпән атлап, тамагын кыргалап, «амбар» янына Галимулла килеп җитте. Беркемгә берни әйтмичә, ул иң элек капчыкларны санарга кереште. Санга кергән һәрбер капчыкка уң кулы белән кагылып-кагылып алды һәм шул ук вакытта сул кул бармакларын бөгә барды. Санап бетерде дә:

— Менә миңа тагын эш артты,— дип куйды. Аның бу сүзләренә беркем бер сүз әйтмәде. Күрәсең, мондый игътибарсызлыкны ошатып җиткермичә, Галимулла, шулай ук бармакларын бөгә-бөгә, үзенең эшләрен саный башлады.

— Ат караучы да мин, үгез караучы да мин...— диде ул, зарлангандай итеп.

— Сыер савучы да мин!— диде Һарун, елмаеп. Галимулла, ялгышып, санавыннан туктап калды һәм шаяртуны бик үк аңлап җитмичә:

— Ни сөйлисең, Һарун? Сыер юк лабаса безнең,— диде, ихлас бер гаҗәпләнү белән.

— Булыр әле,— диде Һарун.— Сыерлар булгач та без сине, Галимулла абзый, сыер фермасы мөдире итеп куярбыз.

— Туктале син, Һарун,— дигән булды Галимулла, мондый сүзгә ачыктан-ачык кәефе килеп һәм яңадан санарга керешеп китте: — ...үгез караучы да мин, утын кисүче дә мин, су ташучы да мин, хатынга су кайнатучы да мин... кайчакта. Тагын нәрсә бар әле? Басуга аш илтүче дә мин! Менә хәзер килеп, амбар каравылчысы да мин. Эш арта да арта, ә эш хакы һаман шул көе.

— Сора — арттырсыннар,— диде Мансур, киңәш итеп.

— Сорадым инде — сиңа әле болай да күп түлибез, диләр.

— Ныграк сора син, Галимулла абзый. Кирәк икән, талаш та, сугыш та!— диде Һарун.

Егетләрнең үзенә теләктәшлек итүләрен күреп, Гали-

муллаңың күңеле үсеп китте, һәм моннан соң, һичшиксез, үз дәрәҗәсен белеп эш итәргә ниятләгән кеше төсле ул:

— Ташлыйм мин бу кырыкмаса-кырык эшне!— диде.— Тапсыннар икенче кеше. Баш белән уйлап караганда, минем кай җирем сездән ким? Тракторына өйрәнми булмый болай булгач.

— Сиңа башта сабанга өйрәнергә туры килер, Галимулла абзый,— диде Мансур.

— Сабанына да ярый, кайсына да ярый. Аена сез икешәр меӊ алып эшләгәндә, ир башыма алты йөз белән йөрү оят! Ул алты йөз миңа монда балык консервысына да җитми. Ташлыйм. Булды.

Ул шулай тик торганда гына үзалдына дулап алды да, чыннан да амбар каравылчылыгыннан тизрәк таярга ниятләгән шикелле, үз чатырына кайтып китмәкче булды.

Ләкин шул чакны йөгерешеп кызлар килеп җитте.

— Бодай китергәннәрме, бодаймы?— диде Фәридә, егетләрнеӊ әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Бодай түгел, борай!— диде Мансур.

— Нәрсә соң ул борай?— диде Фәридә.— Күрсәтегез әле, нинди була икән ул борай? Борайны минем гомеремдә күргәнем юк.

Аларның көлешеп сөйләшүләренә эче пошып, Һарун читкә китеп барды.

— Син түгел, минем дә күргән юк инде ул борайны, Фәридә,— диде Галимулла, капчыклар янына кире килеп.— Ап-ак борай күмәчләрен, борай коймакларын хәзер төштә генә күрергә туры килә инде. Баш белән уйлап караганда, карабодае да шулай, тарысы да шулай... Чәчмиләр хәзер. Борчак, ясмык, арпа ишеләрне дә чәчмиләр. Бөтен басуны арыш, бодай иңләп алды. Хәзер әнә кукырус дигән нәрсә чәчә башладылар.

— Күрсәт әле борайны, Галимулла абзый?— диде Фәридә, аның сүзен тыңламыйча.

Мансур тиз генә шундагы бер капчыкны чишеп җибәрде дә, кулын капчыкка батырып, бер уч кызгылт бодай алды, икенче кулы белән исә шундук капчык авызын җыеп тотты.

— Менә ул борай!— диде ул, учланган кулын югары күтәреп.

Кызлар чыркылдашып аның кулына үрелделәр, капчык авызына ябырылдылар. Фәридә, Мансурның кулын тотмакчы булып, сикереп-сикереп алды. Мансур йомарланган кулын кинәт кызларның борын төбендә генә ачып җибәрде дә көлеп:

— Кара, нинди эре!— диде.

— Һи-и, бодай ич бу!— диде Фәридә, алдануы өчен кәефе кырылгандай булып.— Кыш көне без чистарткан бодай ич бу!

— Син аны ашап кара, ашап!— диде Мансур.— Аның тәме икенче.

Фәридә кечкенә учына берничә бөртек бодай алды да, Мансур сүзенә ышанып, каты орлыкларны чәйнәп карамакчы булды.

— Ашама, агуланган!— диде Мансур, кинәт аның беләгеннән тотып.

Фәридә коты алынып, орлыкларны җиргә ташлады. Мансур көләргә тотынды. Шул ук вакытта кемдер икенче капчык авызын ачты, һәм шыбырдап җиргә бодай коелганы ишетелде.

— Түгә дә башладылар!— диде Галимулла, ачуланып.— Бала-чага түгелсез ләбаса ашлык белән уйнарга! Барыгыз әле, ычкыныгыз моннан! Берегез дә якын килмәгез. Баш белән уйлап караганда, бу хәзер миңа тапшырылган.

Ул яшьләрне амбардан куалап чыгарды да капчык авызларын яхшылап бәйләп куйды. Шул чакны якында гына Таран күренде.

— Кил әле монда,— диде ул, Һарунны үз янына чакырып.

Һарун теләмичәрәк кенә аның янына барды.

— Беләсеңдер, бүген чәчә башлыйбыз,— диде Таран, үзенә тиң кеше белән сөйләшкән сыман, җитди, эшлекле бер тонда.— Син барачаксың чәчәргә. Хәзер үк чәчкечләреңне карап куй... смена кайтканчы.

Алдан билгеләнгән буенча, чәчү агрегатын беренче булып Ислам алып чыгарга тиеш иде, шуңа күрә Һарун, ни әйтергә белмичә, аптырабрак калды.

— Мин? Ә Ислам?..

— Нәрсә Ислам?— диде Таран, йөзен җыерып.— Әйткәннәр икән, тыңла!

— Тыңлыйм, Глиб Симоныч!— диде Һарун, куанып.— Мин болай гына.

— «С-80» сөрәчәк,— диде Таран, аңлатырга кирәк табып.— Өч чәчкечне аңа тагып булмый, беләсеңдер.

— Ә яңа чәчкечләр кайткач?

— Икенче агрегат җибәрәчәкбез,— диде Таран, нык итеп.

— Болай булгач, миңа бит кешеләр дә кирәк булачак, Глиб Симоныч.

— Әнә сиңа Мансур, әнә Фәридә, тагын берәр кызны

алырсың... Рәшидәме анда...— диде Таран һәм шуның белән сүзне беткәнгә санап, үз юлы белән китеп тә барды.

## XVIII

Таранның иң җаваплы, иң мөһим эшне үзенә ышанып тапшыруы Һарунны кинәт кенә җилкендереп җибәрде. «Нишләп болай булды соң әле бу?»— дип уйлады ул үзалдына. Исламга үч итеп кенә микән, әллә соң барысыннан да аны артыграк күргәнгә микән, ягъни барысына караганда да аңа ныграк ышанганга микән? Туктале, шулай булыр әле ул! Кемнең кем икәнлеген белерсең әле! Исламнар, Белугиннар алар эчкәндә генә кирәк, Һаруннар, Мансурлар һәрвакыт кирәк.

Әйе, башлап ул чәчәчәк. Ислам түгел, Һарун чәчәчәк! Аның алдында хәзер бик зур, бик җаваплы эш ята, биш мең биш йөз гектар җир ята. Биш мең биш йөз! Агрономнар биш көн эчендә чәчеп бетерергә кушалар. Дөресе шулай диләр. Алар сүзен тотканда, тәүлегенә мең дә бер йөз гектар чәчәргә кирәк булачак. Өч чәчкечле бер агрегат сменага алтмыш-җитмеш гектар чәчә. Биш көндә! Юк, беркайчан да алай булмый ул. Алар бер елны сигез көндә тәмамладылар язгы чәчүне. Шулай да әле бөтен район шаулады. Гадәттә ул ун, унбиш көнгә, хәтта егерме көнгә сузыла. Ун көндә, унике-унөч көндә тәмамласаң, ул инде менә дигән була. Яңа чәчкечләр кайтмыйча торып, тагын бер-ике агрегат җибәрмичә торып, берни барып чыкмаячак. Биш мең биш йөз гектар бит ул! Ә шулай да шуны чәчәргә кирәк, вакытында чәчәргә кирәк.

Үзалдына Һарун шулай уйлады. Ул бүген үзен бар нәрсәдән риза, канәгать итеп тойды, шат, бәхетле итеп тойды. Кинәт кенә хәтеренә үткән күңелсез көннәр төшсә дә, хәтта андый күңелсез нәрсәләр дә аңа һич тә күңелсез булып, кәеф җибәрә торган нәрсәләр булып тоелмады, киресенчә, шул ямьсез, күңелсез нәрсәләрне дә ул хәзер бөтенләй икенче яктан, матур яктан гына күргәндәй булды.

Кабинада үз янында Рәшидә белән бергәләп утырып барган Фәридә никтер кычкырып көлеп куйды.

«Ник көлә икән?— дип уйлады Һарун, кызыксынып.— Ә нинди матур көлә!» Фәридәнең көлүе дә, аның көлүе турындагы фикере дә аның күңелендә хәзер бернинди әрнү-үкенү дә, көнләшү, сагышлану да тудырмады. Аның күңелендә бары шатлык тойгысы гына уянды. Ләкин бу минутта Фәридә түгел, бәлки, Рәшидә көлгән булса да, аның көлүенә карата да ул барыбер шундый ук хис-тойгы кичергән булыр иде.

«Теге вакытта нишләп мин аның шундый ягымлы, эчкерсез икәнлеген белмәдем икән?» — диде ул үз-үзенә, Фәридә турында уйлануын дәвам итеп. Ничек итеп ачуланыша алды икән соң ул аның белән? Ник, ни өчен? Сүз тыңламаган өченме? Төнлә эшкә чыгудан баш тарткан өченме? Әллә соң бүтән нәрсәгәме? Ныклап уйлап карaганда, бер дә аның эштән баш тартуы өчен түгел бит. Дөресе, Исламга таба елышкан өчен, аның янында көлгән, шаярган өчен. Тапкан дулар нәрсә!

Бер җаен туры китереп сөйләшергә кирәк әле аның белән барысы турында да. Ачыктан-ачык! Тик менә һаман да җай дигән нәрсә генә чыкмый. Моңарчы чыкмады, хәзер инде чыгачак. Хәзер инде ул аның кулында... Аның карамагында. Ул һәрвакыт аның белән бергә булачак. Хәзер инде Илгизләргә бирү юк! Ислам-иблис тә читтә булачак. Башта җайлап кына сөйләргә кирәк, мин сине һич тә рәнҗетергә уйламадым, диярге, ул теге әллә ничек кенә килеп чыкты, көтмәгәндә генә, диярге, мин бит сине кыерсытасы килгәннән түгел, диярге... Шунда Ислам турында да ычкындырып җибәрергә булыр.

«Ник!» — диде ул үз-үзенә шундук. Юк, анысы инде булмас! Анысы инде гайбәт булачак, әшәкелек булачак. Аның бит үз күзе, үз колагы бар — барысын да күрә, барысын да ишетеп тора. Аннары, дөресен әйткәндә, Исламны да ул кадәр хурлап булмый. Холкы гына алама. Эштә ул ялкау түгел, бригадада беренче булып бара! Кайчан карама, кызыл тактада аның исеме турысына 150 дә 160, 170 процент! Исең китәр. Ә Һарун гел икенче урында. Мәсьәләнең шул ягы да бар бит әле, иптәшкәем. Ләкин ул аны барыбер узарга тиеш. Сөрүдә булмады, чәчүдә булырга тиеш! Кызлар кинәт икесе дә берьюлы:

— Җиттек!— дип кычкырып җибәрделәр.— Туктат, туктат, җиттек!

Беренче басу башында, юл кырыенда тырма таккан трактор туктап тора иде. Таран, агрегат уртасындагы бер тырма өстенә иелеп, нидер рәтләп маташа иде. Шунда ук, кулларын салындырып, Наташа басып тора иде. «Әнә шулай булыр әле ул! Беренче адымыңнан ук каршылык чыгып тора»,— дип уйлады Һарун. Ул, нәрсә булганын белмәкче булып, җиргә төште, тырмачылар янына килде. Таран башын калкытып карады да:

— Бар, бар, кит тизрәк!— диде Наташага, кулын болгап.

Өстенә әкәмәт зур комбинезон кигән һәм шунлыктан ямьсез булып, авыр сөякле булып күренгән Наташа елмаеп Һарунга нидер кычкырган булды һәм йөгергән сы-

ман кыланып тракторы янына китеп барды. Трактор кара төтен ургытып, каты гына такылдап алды да кинәт тартылып куйды һәм җир өстенә капланып яткан очлы тешле тырмаларны өстерәп, шалдыр-шолдыр кузгалып та китте. Телен йоткан шикелле тәмам сүзсезләнеп, йомылып-басылып калган Таран, Наташаның тракторны шулай йолкып алгандай кузгатуына түзмәде, гадәтенчә сүгенеп куйды.

— Дипломлы тракторчы! Әнә шулай кырдырып бетерәләр техниканы.

Бер-берсенә янәшә китереп тагылган тырмалар, очлы тешләре белән кылган үскән каты җир өстен тырнап бардылар да, сөрелгән җиргә җитеп, кинәт кенә йомшак кара туфракка чумдылар. Буй-буй буразналар белән дулкынланып яткан җир өсте тырмалар артыннан күпереп, тигезләнеп калды. Яшькелт далага һәм сөрелгән сырлы җиргә күнеккән күзләргә вак-вак тырма эзләре белән челтәрләнгән туфрак җәймәсе яңа булып, күңелле-күркәм булып күренде.

Таран, тырма артыннан бераз гына ияреп барды да, кире борылып, чәчүчеләр янына килде, чәчкечләр белән, тегесе-монысы белән кызыксынды, тотып-тотып карады, боргалап-суккалап карады. Һарунга ул бер дә юкка төпченә шикелле тоелды.

— Киттекме?— диде ул, сабырлыгын җуеп.

— Әйдә, кузгалып карыйк,— диде Таран, ашыкмыйча гына.

Һарун, үз урыннарына басарга кушып, чәчүчеләргә кул болгады, тракторына менеп утырды да, кабинаның арткы тәрәзәсе аша борылып карый-карый, әкрен генә кузгалып китте. Сүз тыңлаучан корыч машина, ике якта тасма булып уралган киң табаннарына басабаса, иплэп кенә, сакланып кына йомшак җир өстенә килеп керде. Калай тәлинкәләрен чыңлатып, чылбырларын шалтыратып, чәчкечләр ашыкмыйча гына арттан иярделәр.

Таран башта Мансур чәчкечен көйләп җибәрде. Чәчкечнең ничек эшләвен күзәтеп, ул беркадәр җир утырып барды, аннары Фәридә янына, Рәшидә янына күчте. Шыбырдап, сикереп, киң көпшәләр буенча эре каты бөртекләр коелды; бөртекләр, калай тәлинкәгә тиеп, чыңлап-чыңлап киттеләр; йомшак җиргә барып төшкәч бөтенләй тынып, юашланып калдылар, бер-бер артлы тезелеп-сузылып җир куенына ята бардылар.

Җир әле йомшак иде, дымлы иде. Трактор, бик каты үкереп, көчәнеп, авыр гына алга үрмәләде.

Илле-алтмыш метр чамасы китеп өлгермәделәр, Таран ашыгып трактор янына килде, туктатырга кушты. Һарун, нәрсә булды икән дигән шикелле, шомланып, бригадирга сораулы күз карашы ташлады.

— Авыр түгелме, тартамы?— диде Таран. «Күзең чыкканмы әллә?!»— дип уйлады Һарун һәм, җавап биреп тормыйча, яңадан кузгалып китте.

— Ярый, әйдә!— дигән булды Таран, соң булса да китәргә «рөхсәт» биреп.

— Чәчәбез, ура!— дип кычкырды Мансур, кызларга кул болгап.

## Дүртенче баб

### I

Икенче бригада директорның бертуктаусыз эчен тырнап торды. Таранга ул әз генә дә ышаныч баглый алмады: үчлекләшеп йә бөтенләй чәчүгә чыкмый калыр, йә булмаса, бер-бер этлек эшләп ташлар дип шикләнде. Хәзер иң мөһиме, әлбәттә, ничек кенә булса да чәчүне башлап җибәрү иде, шуңа күрә яңа бригадир мәсьәләсен ул беркадәр вакытка исеннән чыгарып торырга мәҗбүр булды. Иртән-иртүк ул рация буенча икенче бригаданың хәлен белешмәкче булып карады, ләкин аңа бригададан җавап-фәлән бирүче булмады. Аның шиге тагын да арта төште, һәм ул бүген барыннан да элек икенче бригадага барып әйләнергә дигән карарга килде.

Ул килеп җиткәндә, бригада күптән инде кырда эштә иде, һәм вагоннардан бер читтәрәк кер юып яткан Фәрханә ападан башка «урамда» беркем дә күренми иде. Горшков туктап аннан чәчүгә чыгу-чыкмау турында сорашты.

— Киттеләр, барысы да китте,— диде Фәрханә апа.— Чәчәргә киттеләр. Галимулла да шунда — бодай ташый.

Мондый хәбәр ишетеп, директорның күңеле беркадәр үз урынына утыргандай булды. Юлда ул басу ягыннан кайтып килүче яшьләрне очратты. Алар да: «Чәчәләр»,— диделәр. Директорның тәмам кәефе күтәрелде. «Күптән шулай итәсе калган аны!»— дип уйлады ул Таран турында. Кем белә, бәлки, төзәлеп тә китәр. Бер-ике көн тагын сынап карарга да ярый. Бер-ике көн түгел, хәтта чәчү беткәнче... яхшы эшләсә, әлбәттә. Ни әйтсәң дә, кадр бит, тәҗрибәле кадр. Тагын чыгымчылый башлый икән, анда инде ике төрле уйлап торасы да булмас. Вакыты нинди хәзер, вакыты! Шундый җаваплы бервакытта бригадир алыштыру да килешеп бетми. Ярый ла яңасы бик булдыклы кеше булса. Каш ясыйм дип, күз чыгарып куюың да бар бит әле. Ә ул Ислам Мусин дигәннәре һич тә күңелгә ошамый.

Беренче басу башына барып җиткәч, Горшков шоферына туктарга кушты. Юл өстенә такыр җиргә тигез булып бөртекләр коелып калган иде. Шунда ук, бер читтәрәк, ап-ак булып берничә юан капчык аунап ята иде. Күренеп тора, чәчәләр, чәчеп үткәннәр. Ләкин чәчүчеләр инде шактый ераклашып өлгергәннәр иде, ахрысы — якында гына кешеләр дә күренми, трактор тавышы да ишетелми иде.

— Әллә артларыннан киттекме, Игорь Андреич?— диде шофер.

— Ашыкмыйк, үзләре килсен,— диде ул.— Ә хәзергә әйдәле, тегендәрәк барып карыйк.

Тигезсез юлдан як-якка чайкалгалап бара торгач, Горшков тагын туктарга кушты, машинадан төште дә, сөрелгән җиргә эчкәрәк керде, нидер күрмәкче булып, як-ягына карангалап торды, аннары әкрен генә атлап кире килде дә юл буенча бара башлады.

— Теге мин казып калдырган чокырны эзлисезме, Игорь Андреич?— диде шофер.

— Кайда соң әле ул? Шушы тирәдә генә булырга тиеш иде бит,— диде директор.

— Юк, бераз гына алдарактыр әле,— диде шофер. Горшков бәхәсләшеп тормады, һәм алар тагын кузгалып киттеләр, ләкин, никадәр генә барсалар да, эзләгән нәрсәләрен таба алмадылар.

— Димәк, кемдер сөреп ташлаган,— диде Горшков, каранудан туктап.— Чокырны да, чи калган җирне дә сөреп ташлаганнар. Остапенко тикшерергә әле «өлгермәгән», кемнәрдер мондагылар әнә өлгергән...

— Нишләп «кемнәрдер» булсын, ул көнне анда булганнарның мин барысын да беләм,— диде шофер.

— Ярар, хәзергә калып торсын,— диде директор, бу турыда артык сөйләшәсе килмәгәнлеген сиздереп.— Ихтимал, Таран үзе үк сөрдерткәндер.

## II

Сөрүчеләр янында булгач, директор яңадан беренче басу ягына борылырга кушты. Юл буендагы капчыклар янына җитеп, беркадәр көтеп торгач, еракта болайга таба кыймылдаучы бер трактор күренде. «Газик» тракторга каршы кузгалып китте. Ләкин бу әле чәчүчеләр булып чыкмады, бу әле Наташа гына иде. Чәчүчеләр белән ул бары бер чакрым чамасы киткәч кенә очрашты. Таран белән күрешү, исәнләшү салкын гына, коры гына булды.

— Ничек, барамы эшләр?— диде Горшков, беркемгә дә төбәп кенә әйтмичә.

— Баруын бара да, авыррак бара,— диде Таран, көттеребрәк.

Ул да шулай ук директорга карамыйча гына, каядыр читтәге кешегә — Һарунгамы, Мансургамы җавап биргән шикелле генә итеп әйтте һәм, күрәсең, «начальство» алдында үз-үзен ничек тотарга кирәклеген белмичә, чәчкеч капкачын ачып, бодай актарырга керешкән булды.

— Сылана, дискларга балчык сылана, Игорь Андреич,— диде Мансур.— Сабанда җиңелрәк.

— Өстәл янында тагын да җиңелрәк,— диде Таран, җиңелчә шелтә белән.

— Орлыкны китереп җиткерәләрме?— диде директор, тагын кемгәдер бөтенләй чит кешегә мөрәҗәгать иткәндәй.

— Җиткерә алмый шул, көтеп торырга туры килде,— диде Таран.

— Машина кирәк, Игорь Андреич,— диде Мансур.

— Сезнең машинагыз бар. Сезгә бер машина беркетелгән,— диде директор.

— Ныклап тотынсак, машинасыз булмый,— дип куйды Таран да, эндәшми калуны уңайсызга санап.

— Нәрсә, сез әле ныклап тотынмадыгызмыни?

Таран мондый «бәйләнчек» сорауны ишетмәмешкә салынды. Директор, аның җавабын көткән кебек, беравык тынып торды. Шулай тынып торган арада аның күз карашы Һарунга төште. «Монысы тагын ни була инде?»— дип уйлады ул, ризасызлык белән. Ләкин шундук анда кызыксыну чаткысы кабынып китте.

— Күз төбең нишләде, егет, әллә күбрәк йокладың?— диде ул, берни белмәгәндәй.

Үзенең җимерелгән кыяфәте турында Һарун инде онытып бетергән иде, онытып ук бетермәсә дә, ул турыда артык пошынмый башлаган иде. Директорның соравыннан соң аңа уңайсыз булып китте.

— Сволочь Ислам эше! Аның һөнәре!— диде Таран.

Таранның сүзләрен директор тыштан бөтенләй игътибарсыз калдырган шикелле күренде, ләкин күңеленнән шундук уйлап алды: «Ислам? Ислам Мусинмы?»— диде. Димәк, икесе сугышканнар! Аңлашыла, барысы да аңлашыла.

Горшков Һарунга бүтән бернинди сорау-фәлән биреп тормады, киресенчә, шундый күңелсез нәрсәне искә төшереп, аны уңайсыз хәлгә куюы өчен гафу үтенгән сыман, мөмкин кадәр йомшак, ягымлы итеп:

— Ничегрәк соң, ерып чыга алырбызмы?— диде.

— Ник чыкмаска!— диде Һарун, тотлыгыбрак.— Орлык булса, яңгыр яумаса...

— Итле аш пешсә,— дип өстәп куйды Мансур.

— Ул ашны авызга китереп каптыручы булса...— диде директор, елмаеп.

Бер дә кирәкмәгән чакта «итле аш» турында, инде чәйнәп чүбеккә әйләнгән нәрсә турында сүз кузгатуы өчен Һарун күңеленнән Мансурга ачуланып куйды һәм:

«Тапкан сүз! Тыңламагыз юк-бар нәрсәне!» — дигәндәй, директорга бер күтәрелеп карады да, кыюланып, хәтта бераз усалланып:

— Эш бездән тормас,— диде.— Без тырышырбыз. Без бит аңлыйбыз... иптәш директор. Бер минут туктамый эшләргә була, трактор яхшы тарта... Орлык булса, яңгыр яумаса, ягулык булса...

— Иртән сезгә машина килдеме? Менә шул сезнең машина. Кулдан килгән кадәр ярдәм итәчәкбез, хәтта... ит мәсьәләсендә дә!

— Болай булгач, ныклап тотынырбыз инде,— дип куйды Таран.

— Ничегрәк була инде ул «болай булгач»?

— «Болай булгач»мы, Игорь Андреич!— диде Таран, тавышын күтәрә төшеп һәм «начальство» белән килешергә, татулашырга ниятләвен сиздереп.— Болай булгач... чәчеп була торган булгач... бөтен нәрсәне шуңа җигәчәкбез! Машина бирәсез? Рәхмәт. Шоферы әйтмәде, сукин сын, тизрәк ычкынган. Ә ягулык мәсьәләсендә... кирәк икән, китертербез... үгезләр белән... Көн-төн чәчәчәкбез. Тик менә тагын икенче агрегат җибәрәсе иде. Чәчкеч җитми, чәчкеч!

— Ярый, шулай да булсын,— дип куйды директор, тыелып кына.

Аның бу сүзләрен Таран үзе белән килешү дип аңлады, шулай дип аңламаса да, шулай булуын теләде һәм, ниһаять, ачылып китеп, аның алдында үзенең планнарын җәеп салмакчы булды.

— Беренче басу биш йөз гектар, шулай булгач, ничә көндә...

— Биш йөз гектар?— диде кинәт директор, аның сүзен бүлдереп.

— Биш йөз гектар...— дип кабатлады Таран, директорның үзгәргән кыяфәтенә әз генә дә игътибар итмичә.— Тәүлегенә бер трактор кимендә йөзне чәчкәндә...

— Нинди йөз?!— диде Һарун.— Сменага алтмыш-җитмешне чәчәргә була.

— Димәк, 130—140?

— Хәзер оятлы итәрләр, сукин сыннар!— диде Таран, кәефле генә сүгенеп.— Бик шәп, ләкин беренче көннәрне алай алдырып булмас. Булдырсаң — молодец! Ике агрегат җибәрсәк, Игорь Андреич, тәүлегенә 250— 300 гектар чәчәчәкбез.

Таран вәгъдәсенә генә ышанып җитмәгән сыман, Горшков яшьләргә карап алды.

— Яшьләр ничек уйлый, комсомоллар?— диде ул.

— Булыр, тырышырбыз,— диде Һарун.

— Карагыз аны, сүзегездә торасы булыгыз!— диде директор, ярым шаярту, ярым кисәтү тонында.

— Без сүздә тора беләбез!— диде Мансур, дәртләнеп.

«Шимбә көнне менә ни өчен эч пошкан икән!»— дип уйлады Горшков, чәчүчеләр яныннан аерылып, үз машинасына таба атлаганда. Биш йөз гектар. Нишләп шул чакта ук башына килмәде икән? Әлбәттә, биш йөз гектар. Шимбә көн сөреп бетерделәр. Туктале, Таран, койрыгыңа басарбыз әле без синең! Шундый иттереп басарбыз...

Көктугайга кайткач та ул икенче бригаданың җир сөрү турындагы барлык мәгълүматларын яңадан тикшертеп карамакчы булды.

## III

Таран чыннан да акылга утырды: кычкырмады, сүгенмәде һәм, аннан да бигрәге, авызына бер тамчы аракы алмады. Исламнардан, Белугиннардан аерылгач, дөресрәге, читләшкәч, ерагайгач, кинәт ул үзен бөтен бригадада чит-ят итеп, ялгыз итеп сизә башлады. Тәзкирәне ул кешегә дә санамады һәм моңарчы да, хәзер дә аның белән эч серләрен уртаклашмады. Аның өчен хәзер иң газаплысы менә шул ялгызлык булды, тагын да газаплырагы — утырган урынының ныклыгына ышанып җитмәү булды. Шулай да ул нәрсәдер көтеп, кул кушырып утырмады һәм элеккегә караганда тырышыбрак, күңел биребрәк эшли башлады. Кайчандыр бик күптән булганча, яшьрәк чакларында булганча, ул бары тик эштә генә, эш турында бертуктаусыз кайгы-борчылуларда гына үз-үзенә күңел тынычлыгы таба алды, бары шунда гына үзенең икеле-микеле хәлен онытып тора алды.

Әйе, бригадирлыктан аны икенче көнне дә алмадылар, өченче көнне дә алмадылар. Бу турыда хәтта искә төшерүче дә булмады. Ләкин Таран өчен эшләр шулай җайланып кына барганда, бригадада кинәт көтелмәгән хәлләр килеп чыкты.

Бригадир вагонының тышкы ягына аркылы-торкылы сызыклар сызылган кызыл такта кадаклап куелган иде. Димка һәр көнне иртә-кич, җирләрне үлчәп кайткач, иңбашына эленгән кара сумкасыннан акбур белән дәфтәр алып, һәркемнең исем-фамилиясе турысына саннар, процентлар язып куя иде. Аның язганын күрделәрме, шундук такта янына кеше җыела иде.

Сөрүгә төшкәннән бирле иң зур процентлар бары берничә фамилия турысында гына булды. Бу берничә фамилия эчендә Ислам белән Һарун фамилиясе дә, Андро-

нов та, Белугин да бар иде. Алар, «социалистик йөкләмә» алып ярышмасалар да, күңелләреннән үзара ярышып, бер-берсен узарга тырышып эшлиләр иде, шуңа күрә беренчелек, икенчелек еш кына алышынып та куйгалый иде: иң алга йә Ислам, йә Андронов чыга, алардан кала йә Һарун, йә Белугин була иде. Ә бер мәртәбә Һарун икенче урынга да күтәрелеп куйды. Кызыл тактада беренчеләр рәтендә һәр көнне гел бер үк кешеләрне күрү үзеннән-үзе бер гадәткә кереп китте, һәм беркем дә моңа гаҗәпләнмәде дә, ихтимал, көнләшеп тә карамады. Бары тик Белугинга гына ышанып җитмәделәр. Аның уңышлары нишләптер нигезсез булып, күктән төшкән шикелле генә булып тоелды. Хәер, бер күнеккәч, анысы да онытылды. Аннары кызу эш вакытында бу турыда әллә ни баш та ватмадылар.

Көтелмәгән хәлнең берсе бүген иртән булды. Димка көндәгечә кызыл тактага яңа саннар яза башлагач та, яшьләр, туры юлларын кыегайтып, вагон ягына каерылдылар. Башта берсе килде, аннары икенчесе килде, һәм күз ачып йомган арада вагон янында бөтен бер төркем җыелып өлгерде.

Бүген монда бик зур яңалык бар иде. Ислам белән Белугинның процентлары 160 тан, 170 тән кисәк кенә 102 гә, 100 гә егылып төшкән иде, ә иң беренче урынга Һарун, Һарун янына Вәгыйзь менеп утырган иде.

Такта янында җыелып торучылар, Вәгыйзьнең югары үрләвенә гаҗәпләнүдән бигрәк, Ислам белән Белугинның түбән төшүенә гаҗәпләнделәр.

— Нәрсә булган?

— Нишләп алай кисәк кенә?

— Бригадир булырга гына торганда!..— диештеләр яшьләр, бер аптырап, бер мыскыллы көлү белән.

Күп кешегә бу чыннан да аңлаешсыз булып, серле булып тоелды, ләкин Ислам белән Белугинның үзләре өчен монда бернинди сер дә юк иде. Нәрсә булганлыгын алар бик яхшы аңладылар, сизелер-сизелмәс кенә агарынып киттеләр, тотлыктылар һәм бүтәннәр шикелле берни аңламаган булып кыландылар, ялгыштыр, яңадан үлчәтербез, диделәр.

Ислам Димканың үзен генә туры китерде дә шундук аңа ташланды.

— Син нәрсә, ишәк, үз башыңа җилкенәсеңме?!— диде ул, ажгырып.

— Таранга әйт, мин берни белмим,— диде Димка, китәргә җыенып.— Ул бригадир. Ул нәрсә куша, мин шуны эшлим.

Ислам аның юлына аркылы төште.

— Күрсәтермен мин сиңа Таранны!— диде ул, янап.— Синең үз башың кая? Кисәк кенә төшергәч, барысы да сизеләчәк. Әкренләп төшергән булсаң, беркем белмәс иде. Ну, хәзер бел аны, үзеңә җавап бирергә туры киләчәк! Сизенә калсалар, төпченә башласалар, Таран әйтер, учетчы үлчи, мин белмим, дияр, мин әйтермен, әнә шул ишәк эше ул, шул бутагандыр, минем анда эшем юк, диярмен, и бетте-китте! Әгәр син әйтсәң, миңа шулай куштылар, дисәң, әйтерләр, синең үз башың кая диярләр, комсомол намусың, патриотизмың кайда диярләр.

Димка үзенең ялгышуын бары шунда гына аңлап алды. Чыннан да, бу эшнең чие чыга-нитә калса, барыннан да элек аңа җавап бирергә туры киләчәк бит! Ул чакта инде, үлчи белмәгәнмен, бутаганмын, дип кенә котыла алмассың. Бер-ике мәртәбә ялгышырга мөмкин, ләкин көн дә ялгышканга, Ислам белән Белугин җирендә генә ялгышканга беркем ышанмаячак. Ник син унны бетердең, диярләр, чыннан да, ни өчен комсомол булып йөрисең, диярләр. Әгәр сине алдау юлына этәргәннәр икән, ник шундый коткыга бирелдең, ни өчен Исламнарны, Тараннарны фаш итмәдең, диярләр. Итәрсең аларны фаш! Икенче көнне үк муеныңны артка таба каратып куярлар. «Иртыш» совхозында шулай учетчыны чәнчеп ташламаганнармыни! Нишләргә соң шулай да? Менә капты, менә эләкте кармакка!

Димка шулайрак уйлады һәм, ул-бу булганчы, тактадагы саннарны төзәтеп кермәкче булды.

— Нинди аңгыра син шулай да!— диде Ислам, чын күңелдән ачынып.— Ник укып йөргәнсеңдер ун ел буена икмәк черетеп! Төзәтмә, калсын шул көе. Хәзер инде эш узган. Артык төпченә башласалар, төнлә икебез дә йоклап калганбыз, диярбез. Ләкин иртәгә, бел аны!

## IV

Төшкә таба көтелмәгән хәлнең икенчесе булды. Үз янына Остапенконы, бухгалтериядагы бер-ике кешене утыртып, бригадага директор килеп төште. Аның җил кискән һәм соңгы көннәрдә ябыга төшкән йөзе — гадәттә тыныч, җитди йөзе бүген бик кырыс, ачулы иде.

Машинадан төшкәч тә ул, бүтән бер җиргә сугылып тормыйча, туры Таран вагонына барып керде. «Әле генә даладан арып» кайтканга, бераз ял итеп алмакчы булып Таран урынга яткан иде һәм, гөнаһ шомлыгына каршы, гырылдап йокыга да киткән иде. Аның шулай көпә-

көндез йоклап ятуын күреп, Горшковның ярсуы чак-чак кына тышка бәреп чыкмады. Ул аны тәкәллефсез генә, төрткәләп кенә уятты да үзенең ни өчен килгәнлеген аңлатып бирде.

Аларның кычкырып сөйләшкәнен ике такта ишек аша ишетеп торган Димканың йөрәге жу итеп китте. Директор сөрелгән җирләрне яңадан үлчәп-тикшереп карау өчен махсус комиссия алып килгән иде. Коты алынган егетнең күз алдына шул чакны шомлы нәрсәләр килеп басты. Ул тиз генә урыныннан торды, бүлмә сасытып йоклап яткан Исламның баш очына килде дә ашыгып аны уятырга тотынды. Бу минутта аңа бары Ислам гына ярдәм итә ала иде, бары ул гына дөрес киңәш бирә ала иде.

Аның кабаланып, пышылдап сөйләвеннән Ислам берни аңлый алмады, тиктомалга уятуы өчен ачуланып бер мыгырданды да яңадан күзләрен йоммакчы булды. Ләкин Димка аңа барыбер йокларга ирек бирмәде. Ислам, ниһаять, мәсьәләгә төшенеп алды, башын калкытты, утырды һәм, йонлач, шәрә ботларын кочаклап, бераз уйга калгандай булды.

— Тиз бул, тиз, хәзер монда керәләр!— дип пышылдады Димка, өтәләнеп.

— Эшләр хөрт синең, ишәк баласы ишәк,— диде Ислам, әкрен генә.— Мин болай ук булыр дип уйламаганыем...

— Нишләргә соң, нишләргә?

— Нишләргә? Монда инде берни эшләп булмый. Бригадир кушты дип әйтә алмыйсың. «Ник кушты?» «Кемгә яздың?» Кемгә язуың турында мин аларга түгел, атаңаанаңа әйтергә дә киңәш итмим,— диде Ислам, дәһшәтле итеп.— Ялгышканмын, гафу итегез, и бетте-китте! Сине алар берни эшләтә алмаслар.

— Шуннан, шуннан?— диде Димка, әледән-әле ишек ягына каранып.

— Нәрсә тагын «шуннан»? Бел: Таранны гаепләмә. Таранга болай да эләгәчәк. Син яшь, тәҗрибәсез, и беттекитте. Алсалар шул, сине эшеңнән алырлар. Бәлкем, алмаслар да... Ә Таранга капут! Беләсеңме, капут! Кара аны, бутый-нитә күрмә, югыйсә үпкәләштән булмасын.

Димка, күрше бүлмәдән Таран белән Горшковның чыгып килгәнлеген ишетеп, яңадан үз өстәле янына барып утырды. Кисәк кенә ишек ачылып та китте, йөзе җимерелгән Таран, башын тыгып:

— Димка, сукин сын, кая дөмектең?— дип кычкырып җибәрде.— Чык әле монда хөкем каршына!

Ишектән башын тыккан арада ул Димканың куркынган күз карашы белән очрашты һәм шул вакыт эчендә ул да аңа, тавышсыз гына янап: «Кара аны, мине бутый күрмә, югыйсә үпкәләштән булмасын!»— диде. Димка, яза торган нәрсәләрен ташлап, урыныннан торды.

— Курыкма, нык тор!— диде Ислам, аны юатып. Директорның сизенүе дөрес булып чыкты. Документларда үткән шимбә көнгә икенче бригада буенча 550 гектар чамасы җир сөрелгән булып күренә иде, димәк, илле гектар чамасы җир артык язылган булырга тиеш. Бүлгәләп үлчәгәч, бөтен бер басуның төп-төгәл 500 гектар булып чыкмыйча, йә бераз артыграк, йә бераз кимрәк чыгуы да ихтимал. Аннары шимбә көнге сводкага икенче басудагы җирләр дә кертеп язылган булырга мөмкин. Әмма, ни генә булмасын, илле гектар бәләкәй сан түгел, ул кадәр аерма гади төгәлсезлек аркасында гына килеп чыкмаска тиеш. Горшков шикләнде һәм, бер тотынгач, барысын да ачыкламакчы булды.

Кичкә таба сөрелгән җирләр үлчәнеп бетте. Комиссия үзенең соңгы сүзен әйтте. Сводкадагы мәгълүматлар белән чагыштырганда, кырык сигез гектар ким чыкты. Ике-өч урында сай сөрелгән җирләр табылды. Икенче бригада бригадиры белән учетчы өстеннән акт төзелде, актка кул куелды.

Шул ук кичне шушы уңай белән совхоз конторасында берничә кешелек җыелыш җыелды. Җыелышта Таран дипломатларга гына хас чыдамлык, тапкырлык күрсәтте. Ислам турында да, Белугин турында да ләммим эндәшмәде. Аларны чагу аңа берничек тә ярдәм итмәячәк иде, бары тик мәсьәләне генә буташтырачак һәм болай да исеме чыккан Таранның тагын да ныграк абруен гына төшерәчәк иде. Ул моны бик яхшы сизенде һәм, баштагыча, бөтен гаепне үзенең учетчысына аударды.

Димка да шулай ук чыдамлык күрсәтте: бөтенесен үз өстенә алды, моңарчы беркайчан да мондый эштә эшләгәнем булмагач, күрәсең, ялгышканмындыр, диде, гафу итегез, икенче мәртәбә игътибарлырак булырмын, диде.

Ләкин Таранны Димка гына коткарып кала алмады. Аны бригадирлыктан төшерергә дип, шундук карар чыгардылар. Сай сөрелгән җирне яңадан сөрергә, диделәр, барлык өстәмә чыгымны һәм кырык сигез гектар өчен язылган акчаны Таран белән Димкадан түләтергә, диделәр. Кызыл тактадагы үзгәреш турында комиссия кешеләреннән беркем берни белмәде, һәм бу шул көенчә торып калды.

Бу бәладән шундый җиңел котылуы өчен сөенеп, җыелыштан соң Димка тизрәк бригадага ашыкты.

Таран бригадага кайтмады, кайгысыннан Галимовларга эчәргә китте.

## V

Таран бригадирлыктан алынуын алынды, ләкин аның урынына тагын беркем билгеләнмәде. Тикшерелә торган мәсьәлә белән мавыгып, моңа тагын тиешле игътибар җитеп бетмәде. Аннары бу мәсьәләдә директорның инде үз фикере бар иде һәм ул аны монда кузгатып торуны бик үк кирәк тә санамады. Ул әле бригадир булачак кешенең үзе белән ныклап торып сөйләшмәгән иде.

Смена алышынуга кайтып җиткән Димка, барыннан да элек, Исламны эзләп тапты; эзләп тапты да аңа барысын да сөйләп бирде. Шатлыктан Исламның хәтта тез буыннары йомшаргандай булды. Күңеле нечкәреп, ул чак-чак кына Димканы кочаклап алмады, ләкин тиз арада тыелып калды: үзенә буйсынган кешеләр алдында бригадирның дәрәҗәле, кырыс булырга тиешлеген ул вакытында исенә төшереп өлгерде.

Алар янына ашыгып, нидер сизенеп, Белугин белән Кәрам килеп җитте. Шатлыклы хәбәр турында аларга да әйтелде. Күп сөйләнеп тормыйча, Белугин шундук кухня ягына йөгерде, якындагы бер буш мичкә өстенә менеп басты да, кулларын болгап, тиләләнеп:

— Тыңлагыз, тыңлагыз!— дип кычкырды.— Яңалык! Бик зур яңалык! Коралсыз баш күтәрү нәтиҗәсендә, тиран Таран диктатурасы бәреп төшерелде, «Татарстан» совхозының икенче бригада республикасында ультракызыл-яшел демократия власте урнаштырылды. Тыңлагыз, тыңлагыз! Шушы минуттан алып безнең республика бригадиры — Ислам Мусин. Яшәсен яңа президент Ислам Беренче!

Барысы да «яңа президентны» күрмәкче булып, яккакка күз ташладылар. Ислам буфет тирәсендә әле булса Димка белән ни турындадыр «дәүләткүләм әһәмиятле» сөйләшүләр алып бара иде. Менә алар кузгалдылар һәм икесе бергә янәшә атлап, үзләре вагонына кереп киттеләр. Белугинның үзе турында әйткән сүзләрен ишетә торып та, шуны юкка чыгармавы һәм бигрәк тә вагонга учетчы белән бергә кереп китүе кешеләргә ышандыргыч тәэсир ясады.

Төрле яктан яуган сорауларга Белугин бик авторитетлы итеп бер үк сүзне әйтте: «Таранны төшергәннәр, Та-

ран инде юк,— диде.— Димка әле генә Көктугайдан кайтты, ышанмасагыз үзеннән сорарсыз»,— диде. Ул, билгеле, Исламны бригадир итеп куйганнар, дип кистереп әйтә алмады, ул бары: «Бригадир булып Ислам кала»,— дип кенә әйтте. Күпчелек моны үзенчә аңлады, бу мәсьәлә инде хәл кылынгандыр, дип, Исламны чыннан да бригадир итеп куйганнардыр, дип аңлады. Бригадада инде ике-өч көннән бирле шул турыда имеш-мимешләр йөргәнгә, кешеләр өчен бу әллә ни яңалык та булмады.

Илгиз хихылдап көлеп куйды, Тәзкирә куанып елмаеп җибәрде, кайсыберсе мыгырданып алды. Андронов, барысына да ишетелерлек итеп:

— Тапканнар бригадир!— диде.— Берсеннән-берсе яхшы. Бригада фикерен сорау юк, нитү юк... Мәсәлән, мин каршы.

— Мин дә!— диде Һарун.— Кирәге юк андый бригадирның!

— Мин дә!— диде шулай ук Мансур да.

— Тагын кемнәр каршы?— дип кычкырды Белугин, төркемгә карап.

Каршылар бүтән табылмады. Күпчелек эндәшмәде. Дөресен әйткәндә, алар өчен барыбер иде. Кем белә аны, бәлки, ул чыннан да менә дигән бригадир булып чыгар! Үзе яшь, көчле, сүзен тыңлата ала. Ике-өч кеше яратмаган өчен генә аны бөтенләй юкка чыгарып та булмый бит. Ни генә булмасын, Тараннан начар булмаячак.

— Теләмәсәгез, үзегезгә аерым бригат төзегез!— дип кычкырды Тәзкирә, чәрелдәп.— Сезнең эше мөгезсезләр кайда да шул булыр инде. Күп болгаттыгыз, җитәр!

— Тәзкирә!— дип кычкырды Белугин, тәртип урнаштырмакчы булып.— Бездә хәзер демократия: үзара талашу-кычкырышулар катгый рәвештә тыела. Яңа фикерләрегез, тәкъдимнәрегез булса, кәгазьгә язып үземә тапшырыгыз. Яңа «президентның» боерыгы шундый.

— Төш аннан! Йә сугып төшерермен,— диде Андронов ачу белән.— Президент ялчысы!

Яшьләр сүлпән генә таралышып беттеләр.

## VI

Бригада белән идарәне Ислам икеләнмичә үз кулына алды. Бу турыда ул берни белдермәде, беркемнән рөхсәтфәлән сорап тормады. Аның өчен бөтенесен Белугин башкарды, һәм Исламга бу бик файдалы булып чыкты. Шулай итеп, кисәк кенә бригадир булды да куйды. Ләкин үз-үзеңне бригадир итеп аңлау белән генә, билгеле, бер-

ни кырып булмый иде. Моны бүтәннәр дә аңларга тиеш иде, һәм бүтәннәр дә аңласын өчен нәрсәдер эшләргә кирәк иде.

Барыннан да элек ул киң күңеллелек күрсәтергә кирәк тапты һәм, үзенә шатлыклы хәбәр алып кайткан Димканы куандырмакчы булып, аның штрафының яртысын үзе түләргә вәгъдә итте. Шуннан соң ул бераз гына Белугинны кыздырып алырга булды.

— Кара аны, икенче мәртәбә сай сөрәсе булсаң... бел аны!— диде.— Менә синең аркада Димкага штраф түләргә туры килә.

— Беләбез, беләбез!— диде Белугин, куанып.— Мине әллә аңсыз элемент дип белдеңме? Без хәзер Таран диктатурасы өчен түгел, үзебез өчен, халык өчен эшлибез. Без — демократия!

— Ташлале шул юк-бар нәрсә лыгырдавыңны!— диде Ислам, эре генә.— Димканың штрафының яртысын мин түлим, әйдәле, яртысын син түлә! Менә булыр сиңа демократия!

— Дөрес,— диде Димка, мондый тәкъдимгә чиктән тыш куанып.— Болай гаделрәк булыр. Ул җир бозып йөрсен дә, аның өчен мин монда...

— Кара аны... бел: мин сиңа ике сөйләмәм,— диде Ислам, нык итеп.— Яртысын син, яртысын мин! И бетте-китте. Дөресе аның бөтенләй синнән булырга тиеш тә, ярый инде, сүз биргәч...

— Бетте! Бирелəм!— диде Белугин, шундук риза булып.

«Төнге сменага барасы бар бит әле»,— дип уйлады Ислам. Әллә бармаскамы соң? Барса, бригадир кешегә гади тракторчы кебек эшләп йөрү килешмәс кебек тоелды, бармаса, шулай ук моның эш ташлау, эштән баш тарту булып аңлашылуыннан курыкты. Бригадир итеп билгеләнү турында директорның боерыгы булмыйча торып, үз теләге белән, үз белдеге белән шундый зур җаваплылыкны үз өстенә алуның нинди четерекле эш икәнлеген ул, әлбәттә, бик яхшы аңлады.

Ул китмәкче булды, ләкин киткәндә дә кирәкле кешеләргә кайбер күрсәтмәләр бирергә, тегесен-монысын барлап куярга, сораштырырга кирәк тапты. Димкага ул тиз генә Тәзкирәне алып керергә кушты. Димка шундук йөгереп чыгып китте һәм тиз арада пешекчене алып та керде. Яңа бригадир иртәгә нинди аш пешереләчәк дигән мәсьәлә белән кызыксынды.

— Ничек тә яхшырак берәр нәрсә әзерләргә кирәк,— диде ул.

Ләкин Тәзкирә, тары ярмасы белән дөгедән башка бүтән берни юк, диде, аннары ялындырып булса да өстәп куйды:

— Коймак пешерергә була да соң,— диде.— Ирада абрикос джемы бар бугай, джемлап бик тәмле була ул. Пешерик әле булмаса шул җотларга-убырларга!

— Нинди җот, нинди убыр?!— диде Ислам, кырыс кына.— Моннан соң андый сүзләреңне ташла. Кара аны... бел, үпкәләштән булмасын!

— Абау, мәхәббәтсез!— дигән булды Тәзкирә.— Бигрәк! Убыр дими, нәрсә дисең аларга? Убыр гына түгел, гуҗ бине гоныклар!

— Ярый, мин сиңа ике сөйләмәм,— диде Ислам, үз-үзен дәрәҗәле тотарга тырышып. Шулай да түзмәде, гади генә ыжгырып алды: — Хәзергә ярамый, аңлыйсыңмы, ярамый! Тәртип кирәк, тәртип! Башлап син тәртип бозасың, әйтерләр...

— Әйтсәләр, ыжлап бирәм бик!— диде Тәзкирә, күзен-башын уйнатып.— Әйтеп тик торсыннар. Бер колагымнан керә, икенчесеннән чыга. Ярар, мәхәббәтсез, синең өчен генә... Карале, үзем генә өлгермәсәм... коймак пешерергә Фәрханә апага да әйтсәк?

— Әйт, Ислам кушты, диген.

— Әйтәм, әйтәм, җаным. Карама шулай күзеңнең агы белән, мәхәббәтсез!

— Кара аны... төн уртасында торыгыз. Смена алышынуга бөтен нәрсә әзер булсын. Бел: үпкәләштән булмасын!

— Белдем, белдем! Белмәгәннәр кая инде ул!— диде Тәзкирә, ерылган авызын тыя алмыйча.

— Бар. Хәзер Ираны җибәр минем янга,— диде Ислам, коры гына.

Бармак очларына эленгән ачкычларын чылтыратып, бер-ике минуттан Ира килеп керде. Ислам аннан буфет хәлләрен белеште, фәлән нәрсә бармы, фәлән нәрсә җитәрлекме, диде, нәрсәләр кирәк, диде. Ира теләр-теләмәс кенә җавап бирде. Сораштырып бетергәч Ислам аңа бүген үк Тәзкирәгә абрикос джемы бирергә кушты.

— Мин аны син кушмасаң да бирәм,— диде Ира.

— Бик әйбәт,— диде Ислам, аның мондый тупаслыгына әз генә дә игътибар итмичә.— Бар, хәзергә шул.

Ира ишекне шапылдатып япты да кызулап чыгып китте.

Шул рәвешчә, яңа «президент» патшалык итә башлады.

## VII

Ә икенче көнне иртән-иртүк бригадага таныш машина килеп туктады. Җиргә бер-бер артлы өч ир кеше төште. Аларның берсе шофер, икенчесе Горшков, өченчесе ниндидер ят бер кеше иде. Өстенә ул бераз керләнә төшкән яшькелт солдат сырмасы кигән иде. Яшел галифе чалбары да, таза кирза итекләре дә, гимнастеркасы да шулай ук солдатныкы иде. Ләкин башында шакмаклы кепка иде һәм, башында шул шакмаклы кепкасы булмаса, аннары, иңбашларындагы погоннары алынмаган булса, һичшиксез, аны солдат дип уйларга мөмкин булыр иде.

Гәүдәгә ул бик үк калку да, бик үк тәбәнәк тә түгел, уртача гына иде, ләкин солдатча таза, нык күренә иде. Аның йөзе җитди-киеренке, хәтта бераз гына борчулы-ризасыз иде. Бер-берсенә ябышып кысылган иреннәренә, бер нәрсәгә дә төбәп кенә карамый торган һәм каядыр эчкә, кашлары, керфекләре арасына кереп яшеренгән коры, ачулы күзләренә карап аны монда һич тә үзе теләп килгәндер дип әйтерлек түгел иде. Ул үзенең кайдалыгына да, кемнәр янында икәнлегенә дә бик үк игътибар итеп җиткерми шикелле иде. Күңеле аның кайдадыр читтә, икенче җирдә иде һәм монда аны әйтерсең беркем дә, берни дә кызыксындырмый да, кызыксындыра да алмый иде.

— Менә сиңа икенче батальон!— диде Горшков, солдат киемендәге кешегә эндәшеп.

— Әйберләр машинада калып торсын, Игорь Андреич,— диде солдат, аның сүзләрен бөтенләй ишетмәгән сыман.

— Калсын, калсын, кирәк булгач килеп алырсың,— диде директор.

Бригада инде уянган иде, көндезге сменага китәсе кешеләр юынып-нитеп йөриләр иде. Кухня ягыннан табада кыздырылган май исе, коймак исе килә — Тәзкирә белән Фәрханә апа, табак-савыт шалтыратып, аш-су әзерләп йөриләр иде.

Горшков, юлдашларын ияртеп, шунда таба юнәлде. Исәнлек-саулык сораштылар да, өстәл янындагы утыргычның бер кырыенарак килеп утырдылар.

Директорны күреп Тәзкирә шундук чытык йөзенә елмаю билгесе чыгарды һәм учак янында бераз маташты да, майларын чәчрәтә-чәчрәтә чыжлап торган кайнар табаны пычрак чүпрәк белән ике куллап тоткан килеш, Горшков алдына коймак китереп утыртты. Аннары ул

коймак янына калай банкадан кашык белән каерып абрикос джемы салды. Шул ук минутта ул, утка баскан песидәй кабаланып, титаннан кайнар чәй дә агызып алды.

— Игер Әндрич, авыз итеп кенә карагыз әле бер!— диде, әледән-әле сөйләнгәләп.

Шулай тыз-быз чабып йөргән арада ул шоферга да, ят кешегә дә, ичмасам, бер генә мәртәбә дә күтәрелеп карамады. Шофер егет аның мондый гадәтен, күрәсең, инде белә инде, шуңа күрә ул да Тәзкирәгә бернинди игътибар билгесе күрсәтмәде. Әмма яңа кешенең моңа сизелеп үк хәтере калгандай булды: җил кискән кара-кучкыл йөзе тагын да ныграк караңгыланып, кырысланып калды, очкынланып торган коры күзләре тагын да ныграк эчкә батты. Тәзкирәнең директор алдында ялагайлануына, күзенә кереп торган пычрак, саргылт чәчләренә, керле алъяпкычына һәм, гомумән, бөтен кыяфәтенә, күңел кайтаргыч бөтен килеш-килбәтенә каш астыннан гына карап утырды-утырды да: «Мин хәзер килермен»,— дип, каядыр торып китте.

Горшков иртән ашарга өлгерә алмаган иде, шуңа күрә ул пешекченең йөзенә карап тормады, шундук кайнар коймакка үрелде һәм тәмләп, яратып ашарга да тотынды. Бер-ике коймак капкач, шоферына эндәшеп:

— Әйдә, җитеш син дә,— диде. Шофер әдәпле генә баш тартты.

— Ничегрәк булган, Игер Әндрич, ашарлыкмы?— дигән булды Тәзкирә, үзен мактатасы килеп.

— Бик тәмле, бик шәп,— диде Горшков, чын күңелдән мактап.— Нәрсә, көн дә шулай коймак пешерәсезме сез? Болай булгач, бер дә зарланырлык түгел.

— Көн дә булмаса да, пешерәбез инде, Игер Әндрич. Кайчакта көн аралаш, кайчакта һәр көнне... ничек туры килә, Игер Әндрич,— дип сөйләнде Тәзкирә, Горшков белән шофер каршысына утырып.— Аларга бит ничек пешерсәң дә ошамый, Игер Әндрич. Кырык мир бит алар. Бөтенесенә дә ничек ярап бетәсең. Берсе тары боткасы яратмый, икенчесе токмачлы аш яратмый. Итле ашны барысы да ярата да — юк! Күлеңә күрә чумасың инде, Игер Әндрич, кулыңнан килгәнчә тырышасың, тамаклары туйсын дип. Тырышмый ярамый. Черем итеп алырга да өлгермисең, гел аяк өстендә дә аяк өстендә. Шулар өчен дип тырышасың инде, Игер Әндрич... Каягыз, тагын китерим? Теләсәгез, дөге боткасы салып бирәм. Әллә чәй кирәкме? Джем?

— Юк, булды, рәхмәт,— диде Горшков, майлы кулын Тәзкирә биргән чүпрәккә сөртеп.

Ашагач аның кәефе тагын да күтәрелеп китте.

— Шәп, шәп,— диде ул, Тәзкирәне мактап.— Мондый коймак миңа өйдә аена бер мәртәбә генә эләгә.

Тәзкирәнең масаюдан түбәсе күккә тиде.

— Тырышабыз инде, Игер Әндрич, тырышабыз,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Шул уб... патриотлар өчен дип тырышкан көнең инде...

## VIII

Берничә минуттан өстәл тирәсенә яшьләр җыела башлады. Шул ук вакытта еракта тракторлар кайтканы ишетелде, һәм, күп тә үтмәде, бригада «авылы» иртәнге шаушу белән тулды.

Директорның иртән үк килеп җитүе, бер караганда, әллә ни яңалык та түгел иде, «начальство»дай ул бригадага иң еш килүчеләрдән иде, һәм аңа монда инде күнегеп беткәннәр иде. Ләкин шулай булуына да карамастан бүген аның монда килүенә беркем дә игътибарсыз кала алмады. Горшков баш күтәреп караганда, аның тирә-ягы яшьләр белән тулы иде.

— Нәрсә, башлыйбызмы, иптәшләр?— диде ул, урыныннан торып.

— Нәрсә башларга? Без инде башладык, әйдәгез, сез дә тотыныгыз,— диештеләр егетләр, үзләре алдындагы тәлинкәләргә күрсәтеп.

— Ә? Сезгә әйтмәделәрмени?— диде Горшков.

Аңа ул әлерәк кенә кемгәдер кешеләрне чакырып килергә кушкан шикелле тоелган иде. Үзенең ялгышуын күреп, ул үз-үзеннән көләргә кереште.

— Хата миндә,— диде ул.— Ашагыз, ашагыз, соңыннан сөйләшербез.

Ләкин түземсез яшьләрнең ашап туйганны көтеп торасылары килмәде. Төрле яктан шундук:

— Башлагыз, Игорь Андреич!

— Вакыт тар. Колак тыңлар, авыз ашар!— диештеләр.

— Басудагылар кайтып җиттеме? Ярар, алайса, башлыйк,— диде директор, ашаучыларга күз йөртеп.— Шулай итеп, икенче бригаданың гомуми җыелышын ачык дип игълан итәбез? Берәрегез тиз генә вагоннарны карап әйләнегез — килмәгәннәр булса килсеннәр.

Әлерәк кенә эштән кайткан һәм шуңа күрә юынырга, чистарынырга өлгермәгән кара киемле, арыган, йончыган егетләр, кулларына кружка тотып, шикәр суыра-суыра, аяк өсте чәй эчеп торган кызлар, өстәл янында ашап утыручылар, поход кухнясы тирәсендә чуалучылар —

барысы да тынып калдылар, барысы да бер ноктага — таушалган кара күн пальто төймәләрен ычкындырып җибәргән көе, фуражкасын кулына тотып, өстәл башында басып торган директорга төбәлделәр.

Горшков, гадәтенчә, ашыкмыйча гына, тыныч кына сөйләде, ләкин аның көр, яңгыравык тавышы һәркемне үзенә җәлеп итте, һәркемне тыңларга, игътибарын бер тирәгә тупларга мәҗбүр итте.

— Мин сезне озак тотмам, иптәшләр,— диде ул,— үзегез дә беләсез, сезнең бригадирыгыз булдыксыз, ышанычсыз кеше булып чыкты. Аның шундый ышанычсыз, булдыксыз булуы аркасында, аракыдан айный алмавы аркасында икенче бригада күп кенә хаталар ясады. Эш хәтта җинаятькә кадәр барып җитте. Нинди җинаять турында сүз барганлыгын аңлыйсыздыр, иптәшләр. Моны башкача атап булмый. Күз буяу, җитәкчелекне алдау, дәүләтне алдау — иң яман җинаятьләрнең берсе ул. Таякның юан башы монда, билгеле, сезнең учетчыга да төшә. Яшьлеген, тәҗрибәсезлеген искә алып, бу юлы без аны кичерергә булдык. Аңа бары штраф кына салынды. Ә Таранны дирекция һәм партоешма эшеннән үк алырга кирәк тапты.

— Бик дөрес! Яхшы булган!

— Күптән кирәгие!— диештеләр яшьләр.

— Алайса, яхшы булган? Ике як та риза,— диде Горшков, сүзен дәвам итеп.— Хәзер, иптәшләр, безгә яңа бригадир сайларга кирәк...

Ул сүзеннән туктап калды, беравык тынып, көтеп торды.

Беренче булып гадәттәгечә Белугин тавышы ишетелде.

— Ә бит безнең яңа бригадир бар!— дип кычкырды ул каяндыр арттан.

— Бар? Кем соң ул?— диде директор, шаккатып.

— Ислам! Ислам Мусин!— диде Белугин.— Кичәдән бирле безнең бригадир — Мусин!

— Кичәдән бирле? Мин тагын сезгә бригадир эзлиэзли аптырап беттем. Беркемнең киләсе килми. Чынлап!— диде Горшков, кинәт гап-гади сөйләм теленә күчеп.

— Килмәсәләр килмәсләр,— диде Белугин,— безнең үз бригадирыбыз бар, безгә беркем кирәкми! Боерык языгыз да, эше дә бетте шуның белән.

— Дөрес, безгә бүтән кеше кирәкми!— дип кычкырды Кәрам да.

— Ярый, алайса... үзегездә табылгач... Ләкин кем соң әле ул Ислам Мусин — никтер онытып җибәргәнмен,—

дигән булды директор, төркем арасына күз йөртеп.— Каяле, күренегез инде бер...

Исламны төрткәләп кемнәрдер уртагарак чыгардылар. Хәер, Ислам аларның төрткәләвен дә көтеп тормады — көлке-җитди бер кыяфәт белән кыю гына кыланып, шундук Горшков каршысына килеп басты.

— Бу мин булам инде, Игорь Андреич,— диде ул, майлы чүпрәген бер кулыннан икенче кулына күчергәләп.

— Ә-ә! Беләм, сез икәнсез!— диде директор, «хәтеренә төшереп».— Димәк, кичә кичтән бирле? Ә үзегез төнге сменага бардыгызмы?

— Бармый ни... кеше юк бит. Ярамый, Игорь Андреич,— диде Ислам, тыйнак кына.

Горшков, бернинди карарга килергә дә белмәгән сыман, беркадәр уйлангандай итеп торды.

— Бик шәп,— диде ул, ниһаять.— Алай үзегез сайлап куйгач, мин каршы түгел. Сайлап куйгансыздыр ич? Үзегез теләп?

— Сайлап куйдык, сайлап!— диде Белугин, барысы өчен дә җавап биреп.

— Сайладык, Игер Әндрич,— диде Тәзкирә дә. Шуннан башка бүтән бернинди тавыш ишетелмәде. Исламның бригадир итеп куелуын дирекция тарафыннан эшләнелгән эш дип уйлаучы кешеләр, хакыйкатьне белеп, гаҗәпләнеп тынып калдылар.

Шулай да тынлык озакка бармады. Монысында инде Белугин түгел, бәлки, Мансур кычкырды.

— Исламны, Игорь Андреич, беркем сайламады,— диде ул.

— Сайламады? Ничек сайламадыгыз?

— Шулай, сайламадык,— дип кычкырды Һарун. Кешеләр гөжләп куйдылар.

— Күргән дә юк, белгән дә юк!— диде Ира, ачкычларын чылтыратып.

— Кирәкми безгә андый бригадир!— дип кычкырды тагын Һарун.

— Ник?— диде Горшков, аңа таба борылып. Һарун тотлыгып калды, күрәсең, ул мондый сорау көтмәгән иде.

— Тыңламагыз аның сүзен, Игорь Андреич!— диде Белугин, яңадан тавыш биреп.— Бер-берсен алар яратып җиткермиләр. Дипломатик мөнәсәбәтләр начар — шуның өчен бәйләнә ул.

— Ник алай дисез?— диде Горшков, бу мәсьәләгә бөтенләй битараф кеше сыман.— Шиге бар икән, әйтсен.

— Ник әйтмәскә, әйтермен!— диде Һарун, гайрәтләнеп.— Ни өченме? Беренчедән, эчәргә ярата. Таран да

эчте... Таран үзе генә эчмәде... Исламнар, Белугиннар белән бергә эчте. Икенчедән, кырык сигез гектарга аның да катнашы булырга тиеш. Шулай ук Белугинның да! Карагыз әнә күрсәткеч тактага! Димка аларга артык язган булган...

Исламның Таран белән бергәләп эчүе турында бригада кешеләре, әлбәттә, бик яхшы беләләр иде. Һарунның бу хактагы сүзләрендә бернинди яңалык юк иде. Ләкин артык чыккан кырык сигез гектар мәсьәләсенә килгәндә, күпчелек монда бары Димканы гына гаепли иде. Аннары бу турыда сүз куерып өлгермәгән иде һәм кайберәүләр әле берни белмиләр иде.

Барысы да сагая төштеләр һәм бу авыл малае тагын ниндирәк шаккатыргыч сүз әйтер икән дигән шикелле, кызыксынып, Һарун авызына текәлеп калдылар.

Һарун бүтән берни әйтмәде, уттай янган тынгысыз күзләрен як-якка юнәлтеп, борынын тартып, баскан урынында таптанып тик торды. Кинәт агарынып киткән Ислам, зәһәрен чәчеп:

— Авызыңны үлчәп ач! Үкенергә туры килмәсен!— диде.

— Үкенмәбез!— диде Һарун, аның үзеннән дә яманрак усалланып.— Ул кырык сигез гектарны Димка кемгә язган? Миңа язмады, Вәгыйзьгә дә... Нишләп кичәгенәк 100 процентка төштең? Шулай ук Белугин да...

— Чынлап та! Дөрес шул!— диештеләр як-якта.

— Һарун белеп сөйли, Игорь Андреич,— диде Андронов.— Ислам белән без бер тракторда эшлибез. Көн дә карыйм мин моның сөргән җирен: ничектер минекеннән артык күренми. Кайтып кызыл тактага карасам — аныкы барысыныкыннан да күбрәк! Күптән шикләнеп йөри идем, ярый әле, менә Һарун әйтте.

— Кирәкми Ислам!— дип кычкырды тагын Мансур. Барысы да шауларга, бер-берсен бүлеп нидер сөйләргә тотындылар.

Горшков, шауламагыз дигән сыман, кулын күтәрде дә, коры гына:

— Аңлашылды,— диде.— Алайса, сез Мусин кандидатурасына каршы?

— Каршы, каршы! Кирәкми!— диештеләр, тагын да ныграк шаулашып.

— Булды. Ризамын. Андый шигегез булгач... Ярый, монысы калып торсын. Ә хәзер мин алып килгән бригадирны карап карыйк.

Барысы да, кемне әйтә икән бу дигән кебек, өстәл тирәсенә, директор ягына карадылар, ләкин анда шофер-

дан башка бүтән бернинди чит кеше күренмәде. Горшков та алар кебек үк як-ягына каранды, кешеләр башы аша үрелеп, читкәрәк тә күз ташлап алды.

— Бар әле, табып китер монда,— диде ул аннары шоферга.

Бригадир булып сайланырга тиешле солдат кеше берүзе директор машинасында боегып утыра иде. Төркем янына ул тартынып кына, кыюсыз гына килде, күрәсең, үзенең шул тартынуы, кыюсызлануы өчен үз-үзенә ачуы килеп, әледән-әле башын түбән иде, кашларын җыерып, каядыр читкә карап-карап алды. Килеп җиткәч, ул авыр башын чак кына күтәргәндәй итте дә, беркемгә дә туры гына карамыйча:

— Исәнмесез...— диде һәм, тамак төбенә нидер утырып, уч төбенә йөткереп куйды.

— Менә сезгә мин алып килгән яңа бригадир иптәш Барый Рамазанов,— диде директор, аны җыелышка тәкъдим итеп.— Элекке танкист. Моторны яхшы белә. Моңа кадәр дүртенче бригадада бригадир ярдәмчесе булып эшләде. Яхшы эшләде. Тырыш.

— Эчми-тартмый, хатын-кыз белән йөрми. Кыскасы, монах!— диде Белугин, ачыктан-ачык мыскыл белән.

Илгиз хихылдап көлеп җибәрде.

— Дөрес, эчми-тартмый, хатын-кыз белән йөрми, чөнки үз хатыны бар. Шулай ич? Әллә юкмы соң? Ярый, анысын соңыннан ачыкларбыз,— диде Горшков һәм, дөресме дигән сыман, Барый Рамазановка карап алды.— Шуның өстәвенә яхшы спортсмен. Ничек, ризамы?

— Әнә кызлар әйтсен. Хатыны булгач, белмим, риза булырлар микән,— дип куйды тагын Белугин.

Горшков аның сүзләрен игътибарсыз калдырды. Кызлар исә ачуланып шундук Белугинны өтеп алдылар. Эре, нык сөякле, кырыс чырайлы, әмма акыллы, төпле күренгән бу чибәр солдат аларга беренче караштан ук ошады, һәм алар инде аның турында үзара гайбәт сатып алырга да өлгерделәр.

— Риза, риза, Игорь Андреич! Без сезгә ышанабыз!— дип кычкырдылар кызлар, кыйгаклап.

Соңлап булса да, кызларга егетләр дә кушылды. Риза, диделәр, белми алып килмәгәнсездер әле, диделәр. Белугин тагын нидер кычкырмакчы булды, ләкин бик тиз аның авызын томаладылар. Директор, эшне озакка сузмыйча, кесәсеннән язылган бер бит кәгазь чыгарды да, аны кулында тоткан килеш:

— Шулай итеп, иптәш Рамазановны икенче бригада бригадиры итеп сайладык,— диде, «сайладык» сүзенә

аеруча басым ясап.— Хәзер инде чынлап та сез үзегез сайладыгыз. Иптәшләр, бүгенге көндә без бөек эшләр башкарабыз. Безнең эшебез авыр, тормышыбыз шулай ук җиңелдән түгел. Ләкин шуңа да карамастан язгы чәчүне без вакытында башкарып чыгарга тиешбез. Бу безнең иң беренче бурычыбыз. Менә шундый бервакытта сезнең арада аеруча нык тәртип булырга тиеш. Иптәш Рамазанов сезнең кебек үк яшь кеше, күп кенә нәрсә буенча тәҗрибәсез кеше. Иптәшләрчә, дусларча сез аңа һәрвакыт булышып, ярдәм итеп торыгыз...

Директор, оятыннан, ачуыннан үз-үзен кая куярга белмичә, иреннәрен кысып, башын иеп бер читтәрәк басып торган Исламга һәм чамадан тыш кызарынган Белугинга таба борылды.

— Бигрәк тә мин моны сезгә карата әйтәм,— диде ул.— Чөнки бригадада сез иң өлкәннәрдән, иң тәҗрибәлеләрдән исәпләнәсез...

Ислам директорның тел төбе кая барганлыгын инде күптән сизенеп алган иде. Җыелыш башыннан ук ул аның ягымлы-килешүчән тавышына, елмаюлы ачык йөзенә шикләнебрәк караган иде. «Салам кыстырмакчы буласыңмы? Кыстыр әйдә, кыстыр!— диде ул, күңеленнән Горшков белән чәкәләшеп.— Син төлке булсаң, мин бүре булырмын әле! Бугазларын чәйнәп өзми туктамам».

— Тату яшәгәндә, килешеп эшләгәндә, бу кадәр көч белән, бу кадәр бердәмлек белән безгә тау-таш җимерергә була! Шулай бит, иптәшләр?— диде Горшков, сүзен тәмамлап.

— Шулай!— дип кычкырдылар яшьләр, һава яңгыратып.

Шуннан соң директор, үз исеменнән язылган боерыкны укып чыкты да, яңа бригадирга ымлап, аны үз янынарак чакырды.

— Мин килешле итеп сөйли белмим,— диде Рамазанов, карлыкканрак тавыш белән, йөткеренгәләп.— Бригадир итеп куйдыгыз... сайладыгыз... Рәхмәт ышануыгыз өчен... Менә шул, чәчү беткәнче безнең безгә дә тынгылык булмаячак. Чәчү буенча сезнең... безнең бригада артта түгел. Ә менә булмаган кырык сигез гектарны сызып ташлагач, сөрү буенча без өченче урынга төштек. Безгә кимендә икенче урынга, хәтта беренче урынга чыгарга кирәк! Менә шул. Минем сүзем бетте. Ә хәзер...— ул тотлыккандай итте дә, киңәш, рөхсәт сорагандай, Горшков ягына карап алды.— Хәзер җыелыш тәмам. Эшкә тотынырга вакыт, һәркем үз эшенә бара.

## IX

Машина янына килгәч, Горшков арткы утыргычтагы кызгылт яңа чемодан белән яшел солдат капчыгына күрсәтте дә:

— Хәзер инде боларны алырсыңдыр?— диде.

— Алырга туры килә,— диде яңа бригадир.

Кабина ишеген ачып, ул әйберләрен берәм-берәм җиргә алып куйды.

Үз-үзен әле чын-чынлап хуҗа итеп сизмәгәнгә, ул, кая урнашырга да белмичә, икеләнгәндәйрәк итеп калды. Таранның үзе югында аның бүлмәсенә керәсе килмәде, шулай ук Димка белән Ислам янына да күңеле тартмады.

Аның шулай аптырабрак торуын күреп, машина янына егетләр килеп җитте.

— Әйдәгез безгә,— диделәр алар.

— Бездә иркен, буш караватта бар.

— Әйдәгез алайса,— диде Барый, риза булып.

Егетләр, аның әйберләрен күтәреп, чатырга юнәлделәр. Рамазанов директор белән саубуллашты да егетләр артыннан иярде.

Монда аңа бернәрсә дә ошамады. Чатырның да, чатыр уртасындагы тимер мичнең дә, озын такта өстәлнең дә, тимер караватларның да тегендәге, дүртенче бригададагы чатырдан, андагы тимер мичләрдән, агач өстәлләрдән, тимер караватлардан бернинди аермасы юк иде. Монда да шундый ук җир идән иде, шундый ук тупас тумбочкалар иде, карават асларында трактор исе аңкыткан шундый ук керле киемнәр, теләсә кая ташланган чолгаулар, кирза итекләр ята иде. Тегендә дә, монда да солдат чатырларындагы чисталык кебек чисталык, пөхтәлек юк иде. Тик монда ул тәртипсезлек ныграк күзгә ташланып тора иде. Аннары, чатырның югарыдагы төнлеге ачылмаганга, һава тынчу, сасы иде.

Барый чатырга килеп кергәндә, берничә егет ни өчендер үзара тарткалашып, былагайланып яталар иде. Илгиз, пычрак киеме белән караватына сузылып яткан көе, күкрәгендәге бозау хәтле гармунын акырта, Белугин, күн итекле озын аякларын карават башыннан сузып җибәреп, папирос пошкырта иде.

Үзара тарткалашучылар, яңа бригадирны күрү белән, бер-берсеннән аерылып читкә киттеләр. Илгиз, гармун кычкыртудан туктап, караватына торып утырды. Белугин исә күз кырые белән генә ишек ягына карап алды да, илтифатсыз-игътибарсыз бер кыяфәттә, һаман үз эшендә булды.

Барый, беркемгә бер сүз әйтмичә, ниндидер авыр, кыен

бер тойгы белән, түргә узды, өстәл янына килеп утырды. Бу минутта аның тел очына, ичмасам, бер генә сүз дә килмәде, күңеленә, ичмасам, бер генә уй-фикер дә килмәде, һәм ул шулай үзен кысып, буып торган ниндидер нәрсәдән котыла алмыйча, газапланып, авыр башын аска иеп, күпмедер вакыт тын гына утыруында булды. Егетләр, күрәсең, беренче булып аның сүз башлавын көттеләр һәм шулай ук берни эндәшмәделәр.

— Яле, бригадир, сөйләп җибәр, ник боектың?— диде кинәт Белугин, тәмәке тартуыннан туктап.

Ул моны ничектер бик җиңел генә әйтте, Кәрамга яисә бүтән берәр малай-шалайга эндәшкән кебек кенә әйтте. Яңа кешегә бу шундук тәэсир итте. Үзен кысып-буып торган ниндидер нык, тыгыз нәрсәне ул әйтерсең кинәт өзеп ташлады. Ул, йөрәгенең ашкынып тибә башлаганын тойган хәлдә, әкрен генә башын калкытты да:

— Ал аягыңны!— диде, кычкырмыйча гына, дәһшәтле итеп.

Аның каш астына кереп яшеренгән усал күзләрендә кискенлек һәм ихтыяр көче чагылып китте. Егетләр тып-тын калдылар. Белугинның исә тәне буйлап кинәт электр чаткысы узгандай булды — мондый көчкә, мондый боеруга буйсынмый калу мөмкин түгел иде. Ул, солдат киемендәге бу яңа кешенең сүзен тыңларга мәҗбүр булуы өчен бернинди хәтер калу шикелле нәрсә белдермәгән гамьсез бер җитезлек белән, ике аягын берьюлы күтәреп, җир идәнгә басты, торып утырды һәм кулындагы папиросын күрсәтеп:

— Моны да ташларгамы, бригадир?— диде.

«Нәрсә бу, юри кыланамы, әллә үзе шундый күңелле кешеме?»— дип уйлады Барый. Ул, артык каты орынмыйча гына:

— Ташла,— диде.

Белугин, һич тә аңа каршы килергә нияте юклыгын күрсәтмәкче булып, утлы папиросына төкерде дә, караватында утырган килеш, төпчекне ишеккә таба ыргытты. Төпчек, ишек төбенә барып җитмичә, читтәге бер караватка барып төште. Белугинның һәрбер хәрәкәтен, һәрбер сүзен йотлыгып күзәтеп-тыңлап торган Кәрам көлеп җибәрде. Бүтәннәр тыелып кына елмаеп куйдылар. Монда әллә ни көләрлек нәрсә булмаса да, киресенчә, ачуланырга кирәк булса да, Барыйның да инде күңелендә тыгылып торган боз кисәге эреп юкка чыккандай булды. «Үзе алып ташлар микән?»— дип уйлады ул, каш астыннан гына Белугинны күзәтеп.

— Менә дуслаштык та, бригадир,— диде Белугин, ятарга әзерләнеп.— Хәзер инде бәү-бәү итәргә буладыр ич?

— Юк,— диде бригадир, күтәребрәк.— Башта төпчегеңне алып ташла, аннары йокларсың.

Белугинның гамьсез йөзенә гаҗәпләнү билгесе чыкты.

— Ятсын әйдә,— диде ул, илтифатсыз гына.— Аңа кем тия? Миңа кирәкми. Кирәк булса алып тарт син аны, бригадир.

Аның соңгы сүзләре инде шаяру булып түгел, бәлки, көлү булып, оятсыз мыскыл булып яңгырады. Бригадирның калын кашлары бер-берсенә тагын да ныграк якын килде.

— Кем бүген дежур?— диде ул, егетләргә күз йөртеп.

— Бездә дежур юк.

— Фәрханә апа җыештыра безнең чүп-чарларны,— диделәр егетләр.

— Староста да юкмы?

— Юк.

— Соң сез ничек торасыз... бу ат абзарында?!— диде Барый, шаккатып.

— Торабыз инде. Кайтып йоклыйбыз да чыгып китәбез, тагын кайтып йоклыйбыз,— диде Илгиз.

— Шундый тап-таза егетләр... әз генә дә оялмыйсызмы үз торагыгызны хатын-кыздан тазарттырырга?

— Юк, нишләп оялыйк!— диде Белугин, яңадан сүзгә катышып.

— Менә нәрсә,— диде Барый, аның сүзен тыңламыйча.— Бүгеннән башлап андый иркәләнүләргә чик куелачак. Аналарыгыз куеныннан чыккансыз, имчәк баласы түгелсез. Бүгеннән башлап үз арагыздан дежур билгеләгез. Дежур идән себерә, гомуми чисталыкны күзәтә, өстәлне чистарта, төнлекне ачып, һаваны алыштыра. Караватларга аяк киеме белән яткырмый. Урын-җирне яхшылап җыештырта. Кыскасы, торак урыны ялт итеп торырга тиеш.

— Солдаттагыча!— дип куйды Белугин.

— Шулай, солдаттагыча,— диде Барый.— Мондагыдай шакшыга кеше түгел, дуңгыз да түзмәс!

— Мунча кирәк, мунча кергән юк күптән,— диештеләр егетләр, җитдиләнеп.— Кем дә чисталыкны ярата. Мөмкинлегең булмагач...

— Булыр, карарбыз,— диде яңа бригадир.— Тагын нинди сораулар бар?

— Хәзергә юк. Йокы килә. Бар инде, чыгып кит, бригадир,— диде Белугин.

— Булмаса шул: дежур итеп бүгенгә Белугинны билгелим,— диде бригадир.— Старостаны үзегез сайларсыз, исемлек төзегез. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды!— диделәр чатырдагылар беравыздан

һәм шундук чатыр киндерләрен дер селкетеп көләргә тотындылар.

Белугин кулларын бутап нидер әйтмәкче булды, ләкин аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр — көлделәр, кычкырдылар, тизрәк аның идәнне, өстәл өстен себереп-чистартып алуын таләп иттеләр. Ыгы-зыгыдан файдаланырга, шау-шу арасында үзенчә гайрәтләнеп, батыраеп калырга ярата торган Кәрам йөгереп килеп аның ябынгычына тотынды; Илгиз, тыңламасаң икмәк шүрлегеңә менеп төшәрмен, дип янады һәм шулай эткәләп-төрткәләп, кычкыртып-куркытып Карп-Ваняны урыныннан торгыздылар. Белугин сүгенде, кулларын бутады, аягы белән селтәнде, ләкин егетләр аңа барыбер тынгылык бирмәделәр. Үзен чиктән тыш җәфалый башлагач, Белугин, ярдәм сорап, бригадирга кычкырды.

— Бригадир, үтерәләр!— диде, юләрләнеп.— Коткар, үтерәләр! Күсәкләр, кансызлар!

Шундый күңелле егетләр каршында бик коры булып күренмәслек дәрәҗәдә генә, шулай ук артык куштанланмыйча да, бүтәннәргә кушылып Барый бер көлеп-елмаеп алды да, соңыннан кереп тикшерермен дип, ишеккә таба кузгалып китте.

## X

Ул ишеккә җитәр-җитмәс борын, коймак исе аңкытып торган өсте каплаулы авыр коштабак күтәреп, юрга тайдай юргалап, ихахайлап Тәзкирә килеп керде.

— И, иптәш бригадир, монда икәнсез ләбаса!— дигән булды, тәмле телләнеп, түргә узып.— Иртән әле ашамагансыздыр, тамак ялгап алыгыз менә. Әле яңа гына табадан төшкән, кулны пешерә. Алай ашамый йөрсәң, бик тиз кибегерсең монда, җанкисәгем... иптәш бригадир. Кая куйыйм? Шунда гына утырып ашыйсыңмы, әллә кухняга барыпмы?

Яңа бригадирның чыннан да бик ашыйсы килә иде, ә чыжлап, майда лычкылдап торган коймакка ул баягынак та ымсынып куйган иде. Ләкин хәзер Тәзкирәнең шундый җирәнгеч-ялагай кыяфәтен, ярарга тырышып шундый тәмле теллеләнүен күргәч, аның ашыйсы килүе үзеннән-үзе юкка чыкты.

— Ярар, хәзер кухняга барырмын,— диде ул коры гына, һәм ишектән беренче булып чыгып та китте.

Тәзкирә, коштабакны ике куллап тоткан көе, йөгергәләп аның артыннан иярде. Юлда аларга Димка очрады. Ул да лас-лос атлап алар артыннан тагылды.

Барый бая утырган урынына — өстәл башына килеп утырды да, ашның тәмен бозмас өчен, Тәзкирәнең керле киеменә, маңгаена төшеп торган мунчаладай саргылт чәчләренә карамаска тырышып, алдына куйган коймакны көчәнеп кенә ашарга кереште.

Ул бер-ике коймак кабарга да өлгермәде, кулындагы ачкыч бәйләмен чылтыратып, сулыга төшкән аксыл, ябык йөзле һәм, яшь булуына да карамастан, җәелә, юаная башлаган авыр гәүдәле бер хатын килеп җитте.

— Иптәш бригадир,— диде Ира, Барый каршысында туктап калып.

Бу сүзләрне ул үзенең күптәнге таныш кешесенә әйткән кебек итеп, шулай үзара сөйләшергә гадәтләнгән кешесенә әйткән кебек итеп, ничектер үпкәләп-ачуланып әйтте, ләкин үз күреп, якын күреп әйтте. Бу бер дә Белугинның яисә Тәзкирәнең «иптәш бригадиры» түгел иде, бу аны чын-чынлап олылауны, хөрмәт итүне һәм тулысынча бригадир итеп тануны аңлаткан «иптәш бригадир» иде. Барый моны бөтен күңеле белән аңлады һәм, чак-чак кына кәефе күтәрелгәндәй булып:

— Нәрсә булды?— диде.

— Сез өйләнгән кешеме?— диде Ира.

— Шуннан?— диде бригадир, үзендә кинәт сәер бер сагаю тоеп.

Ира, бик үк урынлы булмаган сорау бирүен аңлап, үзеннән-үзе көлеп куйды.

— Өйләнгән булсагыз, әйтегез әле,— диде ул, яңадан җитди-ачулы булып күренергә тырышып,— өйләнгән кешеләр бергә торырга тиешме, әллә аерыммы?

— Кызык,— диде Барый.— Үзегез ничек уйлыйсыз?

— Мин бик дөрес уйлыйм, иптәш бригадир — иргә чыкканмын икән, ирем белән бергә торырга тиешмен!

— Торыгыз, сезгә кем комачаулый?— диде бригадир, берни аңламыйча.

— Комачаулыйлар икән шул, иптәш бригадир!— диде Ира.— Менә бу авызын җырып утырган Димка белән Ислам комачаулый. Алар ике буйдак бер бүлмәдә торалар, ә без, өйләнгән булып та, бер-беребездән аерым яшибез. Тигезлекме бу?

— Кайда торалар? Ирегез кем соң сезнең? Рәтләп кенә аңлатып бирегез әле,— диде Барый.

Эшнең болайга китүен күреп, сүзгә шунда Димка кушылды, ләкин Ираның бары үзе генә сөйлисе килде.

— Берегез генә сөйләгез!— диде бригадир.

Ниһаять, ул мәсьәләгә төшенеп алды. Ислам белән очрашу, сөйләшү яисә аның белән бәрелешкә керү түгел,

хәзер әле аның бу турыда уйлыйсы да килмәде. Ислам турында ул әлек тә бераз гына ишетеп белә иде. Бүген аңа тагын кайбер нәрсәләр күрергә, ишетергә туры килде һәм шуңа күрә Исламның «бер төнлек» бригадирлыктан төшерелүе белән һич тә килешергә теләмәячәген, ике арада ачыктан-ачык дошманлык барлыкка килмәгән очракта да, аның барыбер яңа бригадирны тиз генә үз итә алмаячагын Барый бик яхшы сизенде. Ул әле монда нибарысы бер сәгать чамасы булды, ул әле монда бик күп нәрсәне төшенеп тә җитмәде, күп кешенең холкын-фигылен түгел, исемнәрен дә белмәде, ләкин күргән-белгән кадәресе дә аңа дус белән дошманны аерырга гына җитәрлек иде.

Ирага ул тиз генә җавап кайтармады. Ләкин җавап бирмичә дә булмый иде.

— Менә нәрсә,— диде ул, уйчан гына,— минем әле башым керсә, аягым кермәгән, аягым керсә, башым кермәгән. Бригада хәлләрен мин белмим. Менә бераз бергәләп эшлик, иләшик, аннары күз күрер. Шулаймы?

— Шулаен шулай да...— диде Ира. Аның, күрәсең, хәзер үк үз теләгенә ирешәсе килә иде.— Таран да шулай диде, ярар, күз күрер, ашыкмыйк, диде. Ныклап әйтә башлагач, бүлмәсеннән үк куалап чыгарды. Менә бу Димка белән Ислам якын да килмәделәр. Игорь Андреичка да әйтергә уйлаганыем, Леша рөхсәт итмәде. Ислам белән болай да пычакка-пычак килеп торалар... әләкләшеп йөрмә, диде... Ярар, рәхмәт, иптәш бригадир!

Ира, иңбашларын мыскыллы сикерткәләп, ачкычларын чылтыратып кузгалып та китте.

— Мин хәзер үк күченеп чыгам,— диде Димка, ашыгып.— Егетләр янында буш урыннар бар.

Ира туктарга кирәк тапты һәм, бригадирның соңгы сүзен ишетү нияте белән, көтеп тора башлады. Болай булгач, инде хәзер буш вәгъдә белән генә котылып булмаячак иде. Беренче адымнан ук ихтыярсыз булып күренмәс өчен, нинди дә булса билгеле бер карарга килергә кирәк иде һәм, яхшымы, начармы, ул карар катгый булырга тиеш иде.

— Ярар, әйдәгез, алайса,— диде бригадир, ашавыннан туктап.

Ул, нык-нык басып, Таран вагонына юнәлде.

— Ислам өйдә юк, Көктугайга китте,— диде Димка.

Барый туктап калды.

— Менә нәрсә,— диде ул тагын да, баштагы фикерен үзгәртеп.— Алайса, син, Димка, хәзер үк егетләр янына күчен. Булдымы? Ә без Ира белән Исламның кайтканын

күтәрбез. Үзе юкта кешенең урынын туздыру ярамый. Шулаймы?

— Шулай инде, шулай,— диде Ира, килешергә мәҗбүр булып.

## XI

Үзе генә калгач, Барый җиңеләеп көрсенеп куйды. Дөрес эшләдеме ул, юкмы? Әйе, дөрес. Аның урынында булган һәркем шулай итәр иде. Ләкин Ислам белән очрашасы бар бит әле! Әгәр дә ул Белугин сыман киреләнеп торса, чыкмаса? Нишләргә, җыелышка куяргамы?.. Ярый ла, үзе аңлап чыгып китсә. Ярар, күз күрер әле.

Бу четерекле мәсьәләдән вакытлыча котылып, инде нишләргә, кая барырга, эшне кай җиреннән тотынып башларга кирәклеген белмичәрәк торганда, тамагын кыргалап, ничектер кыюсызланган шикелле әкрен генә атлап, аның янына кәкре аяклы, калку яңаклы бер ир кеше килеп туктады. Галимулланың йөзенә карагач та, бригадир аның да ниндидер бик әһәмиятле йомыш белән килгәнлеген сизенеп алды. «Менә башланды да!» — дип уйлап алды ул үзалдына.

— Галимулла абзый бит әле сез?— диде ул.— Менә нәрсә, Галимулла абзый, Фәрханә апага әйт — моннан соң егетләр чатырын себермәсен дә, чистартмасын да. Үзләре җыештырсыннар.

— Ә синекен?

— Минекен дә... булгач. Хәзергә әле минем торыр җирем дә юк.

— Ничек соң... алай булгач, баш белән уйлап караганда... акча ягы ничек соң?

— Анысын уйлашырбыз. Ким-хур булмас. Ул турыда кайгырма. Керләрен юа — анысы бик әйбәт, ләкин идән себерү, өстәл җыештыру — аларның үз эше.

— Шулай инде, Барый, баш белән уйлап караганда...— диде Галимулла, мондый тәкъдимне хуп күреп.— Ни... минем дә сиңа бер сүзем бар бит әле... Барый дип әйтимме, иптәш бригадир.

— Сез олы кеше... ничек әйтсәгез дә ярый,— диде Рамазанов.

Ашыкмыйча гына Галимулла үзенең йомышын аңлатып бирде.

— Нәрсә мин, җир сөрмәслек кешеме?— диде ул.— Кирәк булгач, йөрим, бернинди каршылыгым юк. Бөтенесенә дә йөрим, ә акчасы һаман шул көе: биш-алты йөз. Бүтәннәр икешәр мең эшләгәндә, хурлык бит бу ир

кеше өчен, Барый. Үгезгә утырып йөргәнче, сабанга утырып йөрим мин.

Яңа бригадир Галимуллага да тиз генә җавап таба алмады. «Башланды!» — диде ул тагын да үзалдына. Башланды. Менә инде аны һәртөрле сораулар-үтенечләр белән күмеп тә ташладылар. Алар аның мондый мәсьәләдә бөтенләй диярлек тәҗрибәсез булуын да, бригада белән җитәкчелек итү шикелле зур эшне ничек итеп башкара алырмын, дип, эчтән хәтта шүрләвен дә белмиләр. Алар бары үзләрен генә беләләр, үзләренең таләпләрен генә куялар, үз теләкләрен генә әйтәләр. Ничек итеп аклар ул шушы ышаныч-өметләрне, ничек итеп бөтен эшне дөрес кенә, туры гына алып бара алыр? Алып бара алырмы, юкмы?

Яшь бригадир өчен әлегә бу ниндидер томанлы, аңлаешсыз нәрсә иде. Дүртенче бригадада эшләгәндә аңа мондый мәсьәләләрне хәл итәргә туры килмәде, ул бары тәҗрибәсезрәк, яшьрәк тракторчыларга теге-бу нәрсәдә генә ярдәм итте, өйрәтте-күрсәтте, аннары бригадирның кайбер йомышларын үтәштерде. Анда ул күбрәк тракторлар өчен җавап бирде. Ә монда — кешеләр...

— Ярар, Галимулла абзый,— диде ул, куен дәфтәрен чыгарып.— Бухгалтериядә белешермен, сөйләшермен. Бу бит, үзең беләсең, мин генә хәл итә торган нәрсә түгел. Бер дә булмый, дисәләр, директор белән киңәшербез. Ничек тә җае чыгар. Синсез бригадада эш бармаячак. Алай димә син. Бригаданың тоткасы син! Шулаймы?

— Тоткасы инде, тоткасы, Барый туган,— диде Галимулла, күңеле күтәрелеп.— Бөтен эш минем кулда, баш белән уйлап караганда...

— Безнең ат ничегрәк, йөрерлекме?— диде Барый, сүзне икенчегә борып.

— Менә дигән! Биеп кенә тора.

— Син аны, алайса, иярләп кенә куй әле. Мин хәзер басуга эшчеләр янына китәм.

— Була ул!— диде Галимулла, күтәренкелек белән.

Берничә минуттан Барый өстендәге авыр сырмасын үзенең әйберләре янына салып куйды да, гимнастеркадан гына калып, бил каешын, якаларын төзәткәләп, Галимулла янына китте. Галимулла әле генә кола бияне даладан алып килгән, иярләп куйган иде. Бригадир каеш тезгенне кулына алды, аелларның ничек каптырылуын, иярнең ат сыртында ничек ятып торуын үз кулы белән тотып-капшап карады һәм шуннан соң җиңел генә сикереп атка атланды.

— Сорасалар, әйтерсең,— диде ул Галимуллага, күз-галып киткәч.

— Әйтермен, Барый туган, әйтермен,— диде Галимулла.

## XII

Ислам вагонга килеп кергән теге кичтән алып Фәридә өчен ниндидер тынгысыз, борчулы һәм киеренке тормыш башланды. Ислам абыйсы аның күңеленә серле, дәһшәтле ут салып калдырды. Ул бер янды, бер сүнде — көчле ялкын булып күккә ашты, йә булмаса, әкрен генә пыскырга тотынды. Үз-үзен тыярга, янудан-көюдән тотып калырга аның хәзер бернинди әмәле булмады. Ул үзенең нишләгәнен дә, кая басканын, кайда йөргәнен дә тоймас, сизмәс булды. Ул хәтта төсләрне, исләрне һәм шуныңише гап-гади, гадәти нәрсәләрне буташтыра башлады. Аның барлык күрү сәләтен, тою, сизү сәләтен бары бер генә нәрсә биләде, бары бер генә нәрсә томалап торды. Ул моның яхшымы, начармы икәнлеген дә белмәде, акмы, карамы икәнлеген дә белмәде. Ул бары аңа гына омтылды, ул бары аны гына теләде.

Баштарак бу аның котын алды. Ләкин шулай да бу куркып кире чигенү түгел иде. Бу кот алынуда аңа таба — серле, куркыныч ялганга таба ашкыну һәм шуннан бәхет, ләззәт эзләү шикеллерәк нәрсә бар иде. Аның өчен бу һәлакәт иде, ләкин бу һәлакәттә шулай ук яшерен бер мәгънә бар иде һәм әгәр дә мәгәр шул яшерен мәгънәнең төбенә төшмәсәң, беркайчан да үзеңә тулы тынычлык та, бәхет-куаныч та таба алмассың шикелле иде.

Шул кичтән соң алар бары кеше алдында гына очраштылар. Хәер, бу алай очрашу да булмады, бу бары бер-береңне күрү генә булды, һәм Ислам абыйсының үзәккә үтеп керә торган күз карашын күрдеме, шундук ул башын түбән иде, битенә шундук алсулык йөгерде һәм сандугачтай кечкенә йөрәге шундук күкрәк читлегендә ашкынып канат кагарга тотынды.

Ул шулай берничә көн әйле-шәйле йөрде. Беренче Май көнне Иртыш буенда, әрәмәдә алар тагын бергә булдылар. Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, бергә атлап Иртыш яр буена барып чыктылар һәм, көлеп-шаярышып, яр буенда саргылт тал пипиләре өзделәр. Беренче бал кортлары гүләп торган, беренче бал исе, яшел тереклек исе аңкыткан тал янында Ислам абыйсы аны тагын кочагына алды, үпте һәм тагын шул ук сүзләрне кабатлады, торыйк бергә, Фәридә, аппагым, былбылым,

диде... Халык монда усал, диде, мин хәзер сине теләсә кемнән көнли башладым, диде.

Ул көнне дә ул аңа берни җавап кайтармады. Кайтара алмады — алар янына тагын көтмәгәндә албасты Тәзкирә килеп чыкты! Мунча пәрие, сары шайтан Тәзкирә килеп чыкты...

Әмма аны инде Тәзкирә генә өркетерлек түгел иде. Аны хәзер беркем дә, берни дә өркетә дә, куркыта да алмаячак. Ул көчле иде, беркайчан да булмаганча көчле һәм бәхетле иде. Аның хәзер ныклы таянычы, яклаучысы бар иде.

Тик шулай да бу бәхет тә чамадан тыш кыска гомерле булып чыкты. Иртыш буендагы очрашудан соң алар бер генә мәртәбә дә ныклап торып сөйләшә алмадылар. Күңелдәге ялкын һаман үзалдына яши бирде — кинәт-кинәт кабынып китте һәм тагын да искәрмәстән сүнеп калды. Кызу эш вакытында икәүдән-икәү генә очрашуларның бик үк мөмкин түгеллеген ул, билгеле, аңламый булдыра алмады. Ләкин күңел аңга буйсынмады, ул үзенекен даулады, үзенекен таләп итте һәм сүнгән күмеркөл астында һәрвакытта өмет чаткылары пыскып ятты.

Әйе, кайчан да булса бер аның белән барысын да ачыктан-ачык сөйләшәчәгенә, барысын да аңлашачагына ул әз генә дә шикләнмәде.

Ләкин аның күңелендә бүген сәер бер үзгәреш барлыкка килде. Бу үзгәреш бөтенләй көтмәгәндә, уйламаганда булды. Аның кинәт күзе ачылып китте! Аның кинәт колагы ишетә башлады! Һәм әле кайчан гына башаяк килеп күренгән кешеләр, әйберләр, дала, күк йөзе — барысы да тиз арада җиңел генә үз хәленә кайтты, һәм ул үзе дә әйтерсең каяндыр күктән җиргә килеп төште. Бик каты төште, шап итеп төште, авыртынып куйды, чайкалып куйды, әмма шулай да егылмады — аягында торып калды.

Җыелыш вакытында ул Исламның тупаслыгын күрде, аның тупас сүзләрен ишетте. Беренче мәртәбә күрде, беренче мәртәбә ишетте. Аннан да бигрәк, ул аның ялганчы икәнлеген, намуссыз икәнлеген аңлагандай булды. Һарунның кырык сигез гектар турында әйткән сүзләренә ул һәркемнән элегрәк ышанды, бернинди шикләнүсез, бернинди икеләнүсез ышанды. Менә шушы нәрсә андагы барлык томанлы нәрсәләрне туздырды да ташлады.

Шул ук вакытта ул ачык күзләре белән, берни капламаган саф, дәртле күзләре белән икенче бер кешене, көчле, кырыс кешене күрде. Күрде, һәм яшь кызның сизгер күңелендә хөрмәттән дә олырак бер яңа хис калкып чыкты.

## XIII

Бодай ташучы машинага утырып, Ислам чыннан да Көктугайга китте. Бригадада ул хәзер бер минут тора алмады. Монда аңа дөнья тараеп, кысылып калды, монда аңа суларга һава җитмәде. Нәрсә булганлыгын ул әле тулысынча аңлый да, ачыклый да алмады, чөнки бу шундый тиз булды, шундый көтмәгәндә булды. Ул үзен искәрмәстән ниндидер капкынга эләккәндәй, ниндидер базга барып төшкәндәй хис итте. Аның мондый хәлдән котыласы килде, капкынын ватып, йолкып ташлыйсы килде, капкын куючының, аяк астына чокыр-баз казучының бугазын чәйнәп өзәсе килде. Ләкин моннан берничек тә котылу мөмкин түгеллеген ул бөтен күңеле белән сизде. Шуны ныграк сизгән саен, аның котылу теләге, тоткынлыкны юкка чыгару теләге һәм кемнәрдәндер үч алу, кемнәр беләндер исәп-хисап ясау теләге көчәйгәннән-көчәя генә барды. Аның уттай кызган миендә мең төрле план кайнады; үзенең хурлыкка төшүен җуеп ташлау өчен, һичшиксез, өскә, югарыга калкып чыгу өчен ул үзенчә мең төрле юллар, мең төрле ысуллар эзләде һәм үз теләгенә ирешүдә хәзер бер генә нәрсәдән дә тайчанмастай булды.

Шофер белән юл буенча ул берни сөйләшмәде. Бөтенләе белән үз-үзенә, үз зәһәренә укмашып, йомарланып калды, һәм караңгы бер чырай белән, җансыз таш сындай утыргычта тирбәлеп тик барды.

Көктугайга җитәрәк, икенче бригада ягыннан килә торган юлны аркылы кисеп олы юл үтә иде. Юллар кисешкән турыга җиткәч, Ислам шоферга туктарга кушты, кабинадан төште дә, артына борылып та карамыйча, турыдан, юлсыз җирдән китеп барды. Әле эш вакыты иде, Мәрьям кибеттә булырга тиеш иде. Ул шунда ашыкты. Аның өчен хәзер дөньяда бары ул гына, Мәрьям генә калган иде.

Аның агарынган, төсе качкан йөзен күреп, Мәрьям чакчак кына кычкырып җибәрмәде. Ләкин кибеттә кешеләр бар иде, һәм үз-үзен ул тыеп калырга мәҗбүр булды.

Алар, гадәттәгечә, күз карашы белән генә исәнләштеләр, күз карашы белән генә бер-берсенә сораулар-җаваплар бирделәр. Ислам, бер читкәрәк, тәрәзә янынарак килде дә шунда сөялеп туктап калды.

Ярма үлчәгән арада Мәрьям, куркып-борчылып, әледән-әле аңа күз төшереп алды, ялгышты, ярмасын койды, акчасын төшереп җибәрде. Товар алучы беткәч, ул шундук кибетен япмакчы булды. Кулларына төенчекләр тоткан һәм бер-берсеннән һич тә аерылыша алмыйча, үзара

гайбәт сатып торган ике хатын, аның җыенуын күреп, әкрен генә ишеккә юнәлде. Иң соңгы кеше булып өстебашы акбурга буялып беткән бер эшче кыз чыкты.

Алар ишектән чыгып бетүгә, кибет каршысына атка атланган бер казакъ карты килеп туктады. Ул, бүтән хатын-кыз белән бергәләп ак халатлы сатучының да чыгып килүен күрде дә, атын баганага бәйләп тә тормыйча, ашыгып баскычка менде. Өстенә ул иске генә сырма, башына кызыл төлке тотылган озын колакчынлы бүрек, аякларына җиңел күн итек кигән иде.

— Япмале, кызым, тора тор,— диде ул, Мәрьямгә кычкырып.— Чай керегиде, чаең бармы?

Шулай сөйләнә-сөйләнә ул кибеткә кермәкче булды, ләкин шул чакны аның юлында Ислам калкып чыкты.

— Бетмәс монда чәйләр!— диде ул, картның күкрәгенә төртеп.

Карт чайкалып китте, инде егылдым дигәндә генә бер кулы белән ишек яңагына тотынып калды. Ул берни аңламады. Үз-үзен хаклы санап ул һаман кибеткә кермәкче булды, ой-бой, диде, бо калай болады бо, диде.

Ислам җилтерәтеп аны беләгеннән тотып алды, Димканы яисә Кәрамны төрткәләгән кебек төрткәләп, көчләп ишектән үк чыгарып җибәрде.

— Кая тыкшынасың?!— диде ул, җикеренеп.— Әйткәннәр сиңа ябык дип!

Арага шундук Мәрьям керде. Карт кешегә карата тупас кылануы өчен, ул Исламны җиңелчә генә шелтәләп алды, шулай да картның теләген үтәргә дә батырчылык итмәде.

— Мин хәзер киләм, бабай, көтеп тор,— диде ул, ишегенә йозак салып.— Чәй бар, көтеп тор.

Карт, үзалдына сукранып, атының тезгененнән тотып алды, яшьләрчә җиңел генә сикереп ияргә атланды. Аның бик нык хәтере калды. Ул Мәрьямнең сүзен тыңлап та тормады — атының корсагына бер тибеп алды да юырттырып каядыр китеп тә барды.

— Кодай орган адамдар! Келеп толды кагырган адамдар... Өз илеңдә өзеңә бостандыгың җок. Эттең балалары!— диде ул, ярсып.

## XIV

Мәрьям Исламнан бернәрсә турында да сораштырмады. Аның хәзер кәефе чамадан тыш начар икәнлеген сораштырмыйча да аңларга була иде. Ул аны бары яратып, үз итеп шелтәләп кенә алды, и җүләр, диде, и тиле, диде.

Аның ягымлы шелтә сүзләренә колак салгандай итеп, Ислам әкрен генә арттан атлады. Хәзер ул гайбәттән дә курыкмады, бернәрсәдән дә курыкмады. Аңа хәзер Мәрьям кирәк иде, бары ул гына кирәк иде.

Өйгә кайткач, Мәрьям аны бала-чага кебек итеп урындыкка утыртты, өстен-башын салдырды, аннары плитә өстендәге сулы чәйнекне алды да, сөйләнә-сөйләнә, гөрелди-гөрелди, олы сабыйның битен юдырды, чиста ак сөлге белән колак артларын, авыз тирәләрен сөрткәләде. Аның һәрбер сүзенә, һәрбер хәрәкәтенә буйсынып, Ислам кымшанмыйча тик кенә утыруында булды.

— Атнасына бер киләсең, анда да кашың-күзең җимерелгән була. Харап буласыңмы инде син болай... миннән башка...— диде Мәрьям, сөйләнүеннән туктамыйча.

«Әһә, кая бора!»— дип уйлады Ислам үзалдына, ачусыз гына.

— Ник теге көнне килмәдең?— диде Мәрьям.— Мин сине төн уртасына кадәр көттем.

— Булмады.

— Шулайдыр инде. Харап буласыңмы инде син шушы эчүләрең белән.

— Эчмәдем,— диде Ислам, тыйнак кына. Усал, кырыс Исламны шундый юаш, көлке кыяфәттә күреп, Мәрьямнең тәмам күңеле эреде. Аның аннан көләсе килде, аны иркәлисе, сөясе килде. Сул кулы белән аның башын йомшак күкрәгенә кысты, уң кулы белән яратып кына аркасына чәбәкләп алды.

— Җүләрем, диванам,— диде ул, сөйләнеп.

«Нинди яхшы хатын!»— дип уйлады Ислам, аның шулай сөйләнүенә, иркәләвенә рәхәтләнеп. Битендә ул аның йомшак йон киемен тойды, аның җиңелчә хуш исен сулады һәм ун-унбиш минут вакыт узмады, үз-үзен тәмам терелеп, яңарып киткәндәй хис итте.

Эшкә киткәндә Мәрьям аның өстеннән бикләп китте. Кичке сигезләргә чаклы Ислам берни белми йоклады.

Ул күзләрен ачып җибәргәндә, кечкенә бүлмәдә балкып ут яна иде, Мәрьям исә, җәйге җиңел күлмәген киеп, өстәл өстенә иелгән көе, нидер тегепме, ямапмы утыра иде. Аның нәрсә эшләгәнлеген белмәкче булып, Ислам күзләрен ныграк ачты һәм көчәнеп, үз-үзен мәҗбүр итеп аның кулларына карап ята башлады, ләкин, никадәр караса да, берни аера алмады.

— Сәгать ничә?— диде ул, кайдадыр текелдәгән сәгать тавышы ишетеп.

— Иртә әле, иртә,— диде Мәрьям, көлемсерәп. Уянгач та Ислам түшәмдә балкып янган утка ничектер игътибар итеп җиткермәгән иде. Якты лампочканы ул әле яңа гына күргән кебек булды, һәм шундук аның күңеленә: «Сменага соңга калганмын!»— дигән бер уй килде. Ләкин ул моңа әз генә дә хафаланмады. Бүген иртән ул бригадага кайтмаска дип үз-үзенә сүз биргән иде, ихтимал, бөтенләй Көктугайда торып калырмын, дип тә уйлаган иде. Хәер, мондый теләк әле ныгып, күңелендә берегеп тә өлгермәгән иде, бу әлегә ярсыган миендә бербер артлы туган йөзләрчә теләк-планнарның бере генә иде.

— Ай-һай, йоклыйсың да соң!— диде Мәрьям, эшеннән аерылмыйча гына.

— Йокласа ни булган? Көндез йоклыйм, төнлә эшлим.

— Соңга калдың шул инде эшеңә,— диде Мәрьям, үкенгәндәй итеп.— Уятам, уятам — юк! Мәет тә мәет, ул да мәет. Мин сиңа әйттем, сменаңа өлгермисең, дидем, йокы аралаш мине куып җибәрдең. Ни дип җавап бирерсең инде кайткач?

— Аларга тагын җавап биреп торырга!

— Нәрсә булды соң шулкадәр — ник сөйләмисең?— диде Мәрьям.

— Сөйлисе килми әле,— диде Ислам, ялкау гына иснәнеп.— Сөйләрлек тә түгел. Эшләр хана.

— Нәрсә, сугыш чыкканмы әллә?

— Аннан да яманрак.

— Шулай да?

Ислам үзенең нинди хәлгә таруын сөйләп бирде. Мәрьямнең моңа, ичмасам, керфеге дә селкенмәде. Үз кайгысына карата, үз теләкләренең җимерелүенә, гомумән, үз шәхесенә карата аның шундый илтифатсызлыгын күреп, Исламның чын-чынлап хәтере калды.

— Алайса, бригадир булып булмады?— диде Мәрьям, бик гади, әһәмиятсез нәрсә турында сөйләгән сыман.— Кирәге юк. Булма да! Урак өстендә яңа машиналар кайтачак. Инде күп тә калмады. Бер-ике... өч ай ничек тә түзәрбез әле...

Ислам кашларын гына җыерып куйды.

— Туктале, нәрсә ямыйсың соң син анда?— диде ул кинәт.

Мәрьям кулындагы ак чүпрәк аңа бик сәер булып күренде. Бу аны аңлаешсыз бер шиккә төшерде. Хатын исә, үз эше белән мавыгып, аның ягына әйләнеп тә карамады. Курчакныкы шикелле бәләкәй генә, нәни генә күлмәкне, ике җиңеннән ике куллап тоткан көе, югары

күтәрде дә, караватта сузылып яткан кешенең исен китәрмәкче булып:

— Менә нәрсә ямыйм!— диде.

Үзенең балага узуы турында ул әле һаман әйтмәгән иде. Ләкин ике арада бу хакта сүз булмаса да, ни өчендер аңа Ислам инде барысын да беләдер шикелле булып, белмәве мөмкин түгел шикелле булып тоела башлаган иде. Һәм бу турыда Исламга әйтү хәзер һич тә кыен булмас шикелле иде. Ул хәзер беркемнән дә курыкмый да, оялмый да иде, ул бары бер генә нәрсә турында уйлый, бер генә нәрсә турында борчыла иде. Бу бер генә нәрсә, әлбәттә, «ул» иде, каяндыр, нишләптер барлыкка килгән һәм үзенең барлыкка килүе турында көннән-көн ныграк сиздерә торган өченче җан иясе иде. Хәзер аның күңелен моңарчы беркайчан да булмаган яңа бер куаныч, яңа бер өмет-теләк биләп алган иде. Бу яңа куаныч, бу яңа өмет-теләк андагы барлык иске, таныш хис-тойгыларны күмеп киткән, юкка чыгарган иде һәм булачак ана кеше кайда гына булмасын, нәрсә генә эшләмәсен, һәрвакыт үзен сиздереп тора иде.

Ислам мәсьәләгә төшенеп алды һәм тагын да ныграк гаҗәпләнеп:

— Кемгә соң ул?— диде.

— Кемгә булсын — үзебезнең улыбызга!— диде Мәрьям, гаҗәеп бер тынычлык белән.

Ислам моңа ачуланырга да, ачуланмаска да белмичә, икеләнгәндәй итеп калды. Анда әле чын-чынлап тавыш куптарырлык ачу да, зәһәр дә юк иде. Шул ук вакытта бу эшне болай гына да калдырырга ярамый иде. Ачуланмасаң, тавышланмасаң, Мәрьямнең чынлап та аны бу хәбәргә сөенде дип, һич югы, килеште, риза булды дип уйлавы мөмкин иде. Аңа исә һич тә андый мөмкинлеккә урын калдырырга ярамый иде. Баланың һәм балалы хатыннарның нәрсә икәнлеген ул инде белә иде. Менә сиңа кирәк булса, авыртмас башка тимер тарак! Мәрьям — балалы хатын, Мәрьям — бала анасы! Юк, мөмкин түгел бу!

Ул беркадәр вакыт берни эндәшми ятты. Кинәт аңа бөтен нәрсәнең асты өскә әйләнгән шикелле булды. Ягымлы, юмарт, чибәр Мәрьям каядыр юк булды, аның урынына усал телле, ябык, ямьсез Дания, явыз, хәшәрәт Дания торып калды, һәм Дания күз алдына килү белән, аның күкрәк читлегендә йокымсырап яткан шәфкатьсез ерткыч шундук кыймылдап-кузгалып куйды.

— Ничә ай?— диде ул, урыныннан торып.

— Дүртенче ай инде, атасы!— диде Мәрьям, елмаеп.—

Малай! Карале менә тотып. Нәкъ синең төсле: кара чәчле, кылыч борынлы, үзе шундый ус-са-ал! Күрше малайлары белән сугышырга гына тора, атасыннан урлап тәмәке тарта башлаган, имансыз! Нәрсә кушарбыз икән инде? Исламгәрәй? Исламҗан, Исламбай, Исламгул, Исламетдин? Ислам... Мин инде әллә никадәр исем эзләп таптым. Кайчакта шулай искә төшә дә, исем эзләргә тотынам. Ә кыз булса? Кыз булса, син аны яратырсыңмы? Кызлар исеме дә эзләп куярга кирәк. Исламия... Илһамия... Икълимә...

Эшеннән туктап, ул Исламга күтәрелеп карады.

— Ник син шундый күңелсез?— диде ул, исе китеп.— Әллә кыз булса дигәнем ошамый? Мин үзем дә малай булыр, димен ич! Ирләрнең малай яратканлыкларын әллә белми дисеңме? Аны гына беләбез! Данияңне син кыз бала тапкан өчен яратмагансың да... Туктале, әллә малай да кирәкми?

— Юк, кирәкми,— диде Ислам, җан өшеткеч бер салкынлык белән.

— Кирәкми?! Малай да кирәкми, кыз да кирәкми — кем генә кирәк соң сиңа? Кыз-тәкә булмас лабаса ул!

— Берсе дә кирәкми!

— Берсе дә кирәкмәгәч, кая куярбыз соң без аны?— диде Мәрьям, әллә чынлап, әллә юри үчекләшеп.

— Төшерт. Әле соң түгел.

Мәрьям, олы сабыйның баягынак караватта юашланып, буйсынып утыруыннан көлгән сыман, чын күңелдән көлеп куйды.

— Җүләр!— диде ул, яратып, үпкәләп.— Нинди акылсыз әле син!

Аның үз-үзен шундый тыныч тотуы, куанычы-шатлыгы Исламга да тәэсир итте, һәм ул һич кенә дә дулаптузынып китә алмады.

— Көлмә, соңыннан җыларга туры килмәсен,— диде ул.— Шушы эт оясында ничек итеп бала карамакчы буласың? Әллә шушында төпләнеп калырга уйлыйсыңмы?

— Син кайда, мин шунда,— диде хатын, җитди итеп. Аның нәкъ менә шушы сүзләре Исламга кирәкле тәэсирне ясады. Ата булачак кешегә бу элеккечә чиксез ярату, чиксез бирелгәнлек сүзләре булып түгел, бәлки, бала белән муенга тагылырга теләү булып, усаллык, явызлык булып ишетелде.

— Ә мин ияртмәсәм?— диде ул, әкрен генә.

— Ияртмә...— диде Мәрьям, кинәт күңеле төшеп, кызганыч, сынык бер тавыш белән.— Иярер дип курыксаң... Юк, курыкма! Алай курка торган булгач, иярмәм.

Ул һаман да үзенең тынычлыгын, шат күңеллелеген саклап калырга, һич югы, елап җибәрмәскә тырышты, ләкин ихтыярсыздан тамак төбенә шунда каты төер булып кайнар яшь тамчысы килеп тыгылды. Бите буенча агып төшкән бер-ике бөртек яшен ул авызына йотты да, чын-чынлап елап җибәрүдән куркып, беравык тынып утырды. Каты төер, ниһаять, кире төшеп китте.

— Төшерттерү турында уйлама да!— диде ул, башын калкыткандай итеп.— Теләмисең икән, синеке булмас, үземнеке генә булыр.

Гадәттә юаш, күндәм хатын авызыннан чыккан мондый нык, каты сүзләр Исламның тагын да ныграк кытыгын кузгатып куйды.

— Теләсәң нишлә!— диде ул, кырт кисеп.— Мин сиңа яхшылап әйттем... бел: соңыннан үпкәләштән булмасын!

Аның бу сүзләреннән соң Мәрьям туңып, бөрешеп калгандай булды. Шул ук вакытта ул үзенең хәзер бер нәрсә турында да сөйләшәсе килмәгәнлеген, сөйләшсә дә, баягыча тыныч кына сөйләшә алмаячагын аңлады.

Әле генә шундый җылы булып, күңелле булып тоелган бүлмә Исламга кабердән дә тар булып, суык, шыксыз булып күренде. Аның тизрәк моннан чыгып китәсе килде. Ләкин кая китәргә? Бригадагамы? Анда исә мондагыдан да күңелсезрәк, мондагыдан да чиркәндергечрәк.

Аның күңеле бушап, коргаксып калды. Анда хәзер бернинди теләк тә, өмет тә, бернинди ярату да, җылылык та юк иде. Көтмәгәндә аның елыйсы килде, кемгәдер зарланасы, барлы-юклы эч серләрен түгәсе килде, кемнәндер җылы эзлисе, элеккечә ягымлы иркәләү сүзләре ишетәсе килде.

Әйе, хәзер инде Мәрьям белән бөтенесе бетте, ул хәзер бөтенләй чит-ят булып әверелде. Аңа хәзер карыйсы да килми. Кемгә таянырга, кемгә сыгынырга хәзер, кем алдына килеп башыңны салырга? Мондый эч пошу, мондый әрнү-сыкрануларны аның элек тә кичергәне бар иде, ләкин хәзергесе аңа бигрәк тә яман, бигрәк тә авыр булып тоелды.

Шул чакны ул Фәридә турында уйлады. Аның сынган күңеле талпынып куйды. «Хәзер инде мине эт белән эзләсәң дә таба алмассың!— диде ул, күңеленнән Мәрьямгә эндәшеп.— Үзеңә үпкәләрсең. Бу бала бик яхшы сылтау булды әле. Үзеңә үпкәләрсең...»

Ул кисәк кенә торды да киенә башлады. Мәрьям, аның барлыгына-юклыгына әз генә дә игътибар итмәгән сыман, тавыш-тынсыз һаман үз эшендә булды.

— Ярый, хуш,— диде Ислам, киенеп беткәч.

— Сау бул,— диде Мәрьям, авызын көчкә кыймылдатып.

Ислам ишекне тартып җибәрде, шапылдатып кире япты да, ашыгып, бәреләсугыла китеп тә барды.

Бу аларның беренче мәртәбә чын-чынлап ачуланышулары булды.

## XV

Икенче бригадага бригадир булып килгәнче Барый тегендә үз эшен яратып эшләде һәм шуннан да зуррак, шуннан да җаваплырак эшкә үрләү турында беркайчан да уйлап та карамады. Таран урынына бригадир итеп кую турында сүз кузгалгач, ул моңа бары көлеп кенә карады. «Аның кебек бригадир булу өчен аның кебек үк эчәргә кирәк, ә мин алай ук эчә алмыйм»,— диде ул, шаяртып. Ләкин чынлап торып кыстарга тотынгач, ул пошаманга калды. Ул үзенчә каршы килде, минем җитәрлек тәҗрибәм юк, диде, җитәрлек белемем юк, диде. Ләкин аның сүзен ишетергә дә теләмәделәр.

Ул Сергач якларындагы бер мишәр авылында туды. Аңа унөч-ундүрт яшь чагында әтисе, йортын-илен сатып, Казанга күченеп килде. Барый сигез класстан ары укымады, әтисе янына такта яру заводына эшкә керде. Армиягә дә ул шуннан алынды. Берничә ел хәрби хезмәттән соң, ул, кече сержант погоннары тагып, яңадан Казанга кайтып төште, яңадан элекке урынына урнашты. Ләкин кайтып өч-дүрт ай чамасы эшләмәде, җилләр аны менә монда, казакъ далаларына китереп ташлады. Аның бөтен тормыш юлы, бөтен биографиясе шуннан гыйбарәт иде.

Ул әле чынында армия тормышыннан аерылып та җитмәгән иде. Әллә шуңа, әллә бүтән сәбәптән, мондагы тормыш аңа кайсыдыр ягы белән нәкъ менә шул армия тормышын хәтерләтте. Кече сержанттан кисәк кенә капитан, йә булмаса, майор дәрәҗәсенә күтәрелү акылга сыймаган нәрсә булган кебек, көтмәгәндә бригадир булып кую да аңа шундыйрак бер акылсызлык булып тоелды. Дөрес, монда бераз башкачарак иде, бригадир ярдәмчесе белән бригадир арасында кече сержант белән капитан йә майор арасындагы кебек үк аерма юк иде, әмма шулай да башкарган эшләре буенча бригадир ярдәмчесе кече сержантка тиң булса, бригадир чын-чынлап рота командирына, хәтта батальон командирына тиң иде.

Горшков белән сөйләшкәндә ул үзенең шундыйрак чагыштыруларын ычкындырып җибәрде. Директорга бу ошап куйды.

— Ә синең сугыш вакытындагы хәлләрне укыганың, ишеткәнең юкмыни?— диде ул.— Кирәк булгач, кайчагында сержантлар түгел, хәтта солдатлар да взвод белән, рота, батальон белән командалык иттеләр! Монда да шул ук сугыш түгелмени? Ягъни икмәк өчен көрәш, дала белән, кыргый табигать белән сугыш — көрәш түгелмени? Нәкъ менә сугышның иң кызган чагында, иң җаваплы бер урында безнең бер командирыбыз яраксыз булып чыкты. Син яшь кеше, көчле кеше, шул булдыксыз командирны алыштырып, ротаны, батальонны үз артыңнан ияртергә тиешсең, шул көрәштә җиңеп чыгарга тиешсең! Нәрсә, авыр булыр дип куркасыңмыни? Әйт дөресен генә.

— Юк, куркуын курыкмыйм,— диде Барый.— Мин бит монда җиңел булыр дип килмәдем.

— Соң, шулай булгач?!— диде Горшков.— Алай кисәк кенә майор буласың килмәсә, әйдә, хәзергә үзеңне лейтенант итеп кенә хис ит!

Шулай итеп, килешергә туры килде.

Хәер, үзе теләмәсә, аны, әлбәттә, беркем дә мәҗбүр итә алмас иде. Теләдеме соң ул бригадир булып килергә? Кешеләргә, үз-үзенә ул: «Теләмим,— диде,— аягым тартмый, күңелем тартмый»,— диде. Әмма күңеленнән, яшертен генә, сиздермичә генә ул инде күптән риза иде.

Үзенә күрә моның бер сере бар иде. Бу чыннан да сер иде, хәтта аның үзе өчен дә сер шикеллерәк иде — шундый тирәнгә, шундый еракка яшеренгән иде ул! Көктугайда бер кыз бар иде, бүтән беркайда да булмаган һәм булуы да мөмкин булмаган бердәнбер кыз бар иде. Менә нәрсәгә барып тоташкан иде ул сернең очы!

Ул инде аның белән бер-ике мәртәбә сөйләшеп тә алган иде, ләкин бер-ике мәртәбә сөйләшү генә ул әле танышу да, бер-береңә якынаю да түгел иде. Бу бары сөйләшү генә иде. Сөйләшүне бер-ике мәртәбәдән арттыру өчен, ныклап торып танышу өчен аның вакыты да, мөмкинлеге дә булмады. Дүртенче бригада Көктугайдан әллә кайда еракта ята, буш вакытларда авылга килеп китү турында хәзер уйларга да туры килми иде, чөнки, беренчедән, бригада өчен кирәк йомыш белән, гадәттә, бригадир үзе йөри, икенчедән, аңа, гомумән, бер генә минутка да тракторлардан аерылып торырга ярамый иде. Ни генә булмасын, Көктугайдагы кыз турында аңа бары уйлау-хыяллану белән генә канәгатьләнергә туры килде. Хәер, анысы да әле онытканда бер генә, бик иркен, бик тыныч вакытларда гына була иде.

Ә бит шулай читтән генә кызыгып йөрсәң, беркайчан да аның белән чын-чынлап таныша алмавың да мөмкин!

Хәзер, кызу эш вакытында, кем белә, бәлки, атналар, айлар буена бригададан чыкмый ятарга туры килер. Ул арада, кем белә, кыздан инде җилләр искән булыр, ягъни, кем белә, әллә кияүгә-нигә чыгып куяр, әллә бүтән берәрсенә гашыйк булыр... кем белә аларны!

Ә бригадир булгач? Ул чагында инде бөтенесе аның үз кулында булачак! Теләсәң дә, теләмәсәң дә көн саен Көктугайга кибеткә-нигә барырга, тегесе-монысы артыннан чабарга кирәк булачак. Аннары икенче бригада Көктугайга якынрак та. Димәк, кызга да якынрак...

Бүген иртән ул юри кибеткә сугылып узды. Вакыт әле иртәрәк иде. Кибет бикле иде. Бикле булса да, ишек янында, баскычта аңа ул күренгәндәй булды. Медиклар кебек ап-ак халатын кигән, кыска чәчләрен чыгарып, ап-ак башлыгын киеп куйган — Казан гастрономнарында сатамыни! Ник, ул бит болай да Казанныкы. Шулай булырга тиеш тә. Казанча чиста, пөхтә, Казанча әдәпле, тыйнак, матур... Ул чынлап та әдәпле, тыйнак. Сабыр холыклы. Аңа менә нәкъ шундый сабыр холыклылар ошый да... Әле берсе кычкыра, әле икенчесе кычкыра, берәр исерeге, җитмәсә, чиратсыз кермәкче була. Арттан этешәләр-төртешәләр яисә кинәт кенә шикәре-фәләне бетеп куя. Барысына да сатучы гаепле! Ник аңа чиратсыз бирәсең? Ник аңа шикәрне өч кило үлчәдең?— барысы да аның өстенә ява.

Ә ул бер дә үртәлми дә, кычкырмый да. Кыска гына итеп һәркемгә җавап бирә, иплән кенә берәрсен шелтәләп ала, үзе тагын бер дә кабаланмыйча, шулай да тиз-тиз генә, җитез генә үзенең эшен эшли бирә.— Ягез, сезгә нәрсә?— Әнә теге селедканы...— Күпме?— Берне, берне! Җиткән, әллә сасып беткәндер ул...— Сасымаган. Тагын нәрсә?— Берәр кило тары ярмасы бирерсең дә ике консерва. Треска...— Аракы юк. Егерме тиен вагыгыз бармы?..

Үзе шулай сөйләнә, сорый, җавап кайтара, бер кулы белән ярма үлчи, икенче кулы белән папирос-фәлән, шырпы-фәлән алып бирә, счет төймәләрен шалт-шолт китерә. Беркемне тоткарлап, вакыт уздырып тормый. Өлгер, җитез... ә йөзендә нурлар уйный...

Тик менә кибеттә эшләве генә ничектер күңелгә ятып бетми кебек. Кибет халкының инде аның күптән даны чыккан. Аларның бармак бераз кәкрерәк, диләр. Хәер, һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре. Аларның барысы турында да шулай дип уйлау, бәлки, дөрес тә түгелдер, кем белә аны... шулай да... Кем белә аларны!

Кайчан барырга соң? Бүген булмый. Ярамый. Бүген

әле эшләр күп. Нишләргә тиеш соң ул? Тракторлар сөрә, чәчү хәзергә тоткарлыксыз бара. Тиешле кешеләр далада, тиешле кешеләр ял итә.

«Ә Ислам? Ул да бит ял итә,— диде ул үз-үзенә, күңелле уйларыннан бүленеп.— Кайтты микән? Кайгысыннан, ачуыннан китеп барды микәнни? Яңа бригадир белән күзгә-күз очрашмас өчен? Кем белә аны, шуңа күрәдер...»

Бераз вакытка бу аңа ничектер көлке булып тоелды. «Шулкадәр бригадир булырга тырышкан кешеләр дә булыр икән!»— дип уйлады ул, беркатлы бер гаҗәпләнү белән. Ләкин аның бу гаҗәпләнүе озакка бармады. Шундук иртәнге җыелыш күз алдына килде, Белугинның «Кирәкми!» дигән сүзләрен һәм ничек итеп аның «бригадир» Исламны яклап алып калырга тырышуын хәтерләде. Аннары ул Исламның нәфрәт белән, ерткычларча дошманлык белән янган күз карашын күргәндәй булды.

Юк, монда һич тә мәсьәләгә алай өстән генә карарга ярамый. Киресенчә, монда минут саен, сәгать саен сакуяу булырга кирәк, андый-мондый нәрсә була калганда да, тиешенчә җавап бирергә әзер булырга кирәк.

«Кайтты микән?»— дип уйлады ул тагын да, тынычсызлангандай итеп. Ул атын куа төште һәм бригада «авылы»на кайтып җиткәнче юырттырудан туктамады.

## XVI

Ул кайтып кергәндә, егетләрнең күбесе гырылдап йоклап яталар иде, ләкин кайберәүләр инде торып юынырга һәм төшке ашны ашап алырга да өлгергәннәр иде. Өстәл өстендә, идәндә-нидә баягыча чүп-чар, калдык-постык нәрсәләр күренми — үзенә кушканны Белугин әзме-күпме үтәп чыккан иде. «Хәзергә ярый»,— дип уйлады Барый.

Йоклаучыларны уятмас өчен ул, мөмкин кадәр саграк кыланырга тырышып, буш карават өстендәге үз әйберләрен әвеш-түеш китерде дә, бераз ял итеп алу нияте белән, астына сырмасын җәйде һәм болай гына, артык кызыксынмаган шикелле генә:

— Ислам кайтмаган, ахрысы,— дип куйды.

Егетләр аңа Исламның Көктугайда кем беләндер сугышуы турында әйттеләр. Бу турыда аларга бодай ташучы шофер җиткергән иде, бодай ташучы шоферга исә бүген иртән Исламның казакъ картын кибеттән төрткәләп чыгаруын күреп калган бер хатын әйткән иде. Егетләргә сөйләгәндә шофер бераз үзеннән дә өстәгән иде. Егетләр Барыйга сөйләгәндә шулай ук бераз гына арттырып,

шыттырып җибәрделәр, һәм, аларча, Ислам анда ниндидер коточкыч эш эшләгән кебегрәк булып аңлашылды.

— Кайтмас инде ул — милиция алып киткәндер!— диештеләр егетләр, үзләренчә фараз кылып.

Аларның мондый имеш-мимешләре Барыйның тынычсызлыгын гына арттырды. Бүтән вакыт булса, ихтимал, ул андый «коточкыч» эшләрне уйлап та бирмәс иде, ләкин ул хәзер бригадир кеше иде, җаваплы кеше иде, кыйнашкан-сугышкан кеше аның кешесе иде, аның шәхси дошманы булса да, аның бер солдаты иде! Ә бит ул-бу була калса, барыннан да элек аңа сүз ишетергә, аңа җавап бирергә туры киләчәк.

Менә ул нәрсә икән бригадир булу! Нишләргә? Артыннан эзли китәргәме, әллә үзе кайтканны көтеп торыргамы?

«Тегендә, ичмасам, ике кулыма бер эш иде. Юкка килештем,— дип уйлады ул үзалдына.— Менә монда иреклe башыңнан ирексез булып, ниндидер Исламнар, ниндидер башкисәрләр турында кайгырып ят икән! Юк, бармаска! Бала түгел, теләсә нишләсен».

Ул яткан җиреннән сикереп торды да тышка чыгып китте. Аның инде ятып, ял итеп торасы килмәде. Төшкелекне ашап алды да бригада хуҗалыгы белән, язу-сызулар белән таныша башлады.

Беренче трактор кайтып җитү белән, ул шундук заправка урынына чыкты, сорашты, тегесен-монысын тикшереп карады. Беренче трактордан соң икенчесе, өченчесе кайтты. Бригадир алар янына да барды, сорашты, тикшерде, җиң сызганып тракторчыларга булышты һәм эшләгән арада әледән-әле Көктугай ягына карап алды. Үзен ул кеше алдында бик тыныч тотты, Ислам турында бөтенләй уйламаган-кайгырмаган шикелле итеп тотты.

— Болай булгач, төнге сменага үземә китәргә туры килер инде,— диде Андронов.

— Син ял ит, үзем китәрмен,— диде бригадир.

— Ничек алай?— диде Андронов.— Бригадир кешегә тиеш түгел.

Барыйның киеренке, көчәнүле тынычлыгы шундук юкка чыкты.

— Кем әйтте сиңа аны бригадир кеше эшләргә тиеш түгел дип?— диде ул кинәт, тавышын күтәреп.

— Эшләргә тиеш түгел димим... Сменага чыгу... Сезнең бит үз эшегез дә...— дип мыгырданды Андронов.

— Барыбер түгелмени?— диде бригадир.— Моннан соң андый карашларны ташларга кирәк булыр. Өйрәнеп беткәннәр: анысы тиеш түгел, монысы тиеш түгел! Барышнялармыни! Кирәкмәгән чакта икешәр смена рәттән

эшләү бер дә батырлык түгел. Батырлыгыңны күрсәтәсең килсә, үз сменаңда күрсәт. Синең әле иртәгә дә эшлисең бар. Булдымы? Кабинада йоклап йөргәнче, бар, чатырга кереп йокла.

Андронов шундук телен тешләргә мәҗбүр булды. Бригадирга шулай кинәт кенә кызып китәргә сәбәп булырлык әллә ни әйтмәгәнлеген һәм Рамазановның бу очракта бик үк хаклы түгеллеген аңласа да, никтер ул аңа ачулана алмады. Киресенчә, яңа бригадирның каты-каты сүзләреннән соң аңа хәтта күңеллерәк тә булып китте. «Бу инде Таран түгел, тешле күренә. Капкан җирдән өзми куймас»,— дип уйлады ул.

Алар шулай әйткәләшеп яткан чакта, сиздермичә генә Галимулла килеп җитте, беравык аларның эшләренә карап торгандай итте дә, кыяр-кыймас кына:

— Карале, Барый туган, сиңа тагын бер йомыш бары,— диде.

— Сөйлә, Галимулла абзый,— диде Барый, йөзендәге ачуын юкка чыгарып, ә күңеленнән уйлап куйды: «Монысы тагын эш күплектән зарланмакчы була микәнни?»— диде.

— Минем хәзер төнлә эшем юк, Барый туган,— диде Галимулла.

— Төнлә эшлисеңме син, эшләмисеңме — анысы миңа караңгы!— диде Барый, кинәт кенә күңеле күтәрелеп.

Галимулла шаяртканны аңламады, бригадирның сүзе бетүен ихтирам белән көтеп торды да ашыкмыйча гына яңадан ялгап алып китте.

— Ни... Барый туган, бодайны хәзер машина ташый чәчүчеләр янына. Миңа эш бетте. Үгезләр дә, ат та беркая китмәс...

— Аңлашылды!— диде Барый, аның сүзен бүлдереп.— Син төнге сменага чыгарга телисеңме? Рәхмәт, Галимулла абзый. Ләкин сиңа бик авыр булмасмы?

— Һи-һи, Барый туган,— диде Галимулла, йөзе яктырып.— Җиңел эш кайда гына соң ул?!

— Алайса, бар киенеп чык,— диде бригадир.— Үзем белән барырсың.

— Хәзер, Барый туган!— диде Галимулла, сөенеп, кабаланып.

## XVII

Ислам бригадага төнге уникеләрдә генә кайтып төште. Яңа бригадирны ул Таран бүлмәсендәдер дип уйлады. Үзенең кайтканлыгын белдерү өчен, аны uyату һәм уят-

кач икәүдән-икәү генә очрашу, сөйләшү нияте белән, ул ишекләрне юри дөбердәтеп ачты, тамак кырды, сеңгерende: бүлмәгә кергәч, авыр итекләре белән әле тимер мичкә, әле сәкегә орынып китте, идәнгә каты-каты басып куйды, ләкин күрше бүлмәдә бернинди уяну галәмәте сизелмәде.

Үзе юк чакта бригадада ниләр булганлыгын, яңа бригадирның ниләр сөйләгәнлеген белмәкче булып, ул Димканы тарткалап торгызырга исәпләде. Ләкин Димка урынында как тактадан башка бүтән берни юклыгын тоеп, ул тагын да аптырап калды. Ул шырпы сызып лампа кабызды. Бүлмәдә беркем юк иде. Аскы сәкедә, җыештырылмаган урын-җир өстендә, аның үзенең мендәрләре, керле сөлгеләре генә аунап ята иде.

«Әһә, Таран бүлмәсе ошамаган, шуңа күрә бу якка урнашмакчы булган,— дип уйлады ул, үзенчә мәсьәләгә төшенеп.— Димка ишәкне куалап чыгарган... Аңа шул кирәк тә! Минекен чыгарып ташларга кыюлыгы җитмәгән. Чыгармый тор!»

Үз бүлмәсенә күз йөртеп алгач, ул лампасын тотып күрше бүлмә ягына чыкты, ишеккә якынрак килде. Таран ишегендә йозак эленеп тора иде.

«Кайда булыр соң бу?»— дип уйлады ул, гаҗәпләнеп. Яңадан үз бүлмәсенә керде дә идән уртасында туктап калды. Аның ятасы килмәде. Аңа бу тын, буш бүлмәдә кинәт бик моңсу булып китте. Аңа бүген, һичшиксез, аны күрергә иде; күрергә, сөйләшергә кирәк, шулай булды, болай булды, гаеп миндә, фәлән-төгән дип аңлатып бирергә кирәк. Хәзер һич тә ансыз ярамый, хәзер аның бары сырт буеннан гына сыйпарга кирәк. Югыйсә бөтен эшнең харап булуы мөмкин. Менә ул юк. Ничек кенә бөгелергә исәпләмә, ничек кенә баш орырга исәпләмә — юк булгач, юк! Кая гына олакты икән соң ул?

Ул егетләр янына юнәлде. Ашыкмыйча гына атлап барганда, кемдер арттан килеп, тавыш-тынсыз аның кулына тотынды. Ул туктады, артына борылды. Бу Тәзкирә иде.

— Кая киттең болай?— диде Тәзкирә, пышылдавык тавыш белән.

— Абзар артына!— диде Ислам.

Тәзкирәне култыклап, ул кире вагонга борылды. «Нәрсә анда күренеп йөрергә!— дип уйлады ул.— Бу пумала баштан да яхшырак итеп беркем сөйли алмаячак».

Ислам култыгына эләккәч тә, Тәзкирә, куанычын яшерә алмыйча, бер юктан көлеп-хихылдап җибәрде, туң-

ган булып, иңбашларын җыерды, җылы эзләп Исламга сыенган сымаграк итте.

— Кара, безнең «папаша» кая икән?— диде ул, вагонга кергәч, беренче сүзе итеп.

— Нәрсә, бик кирәк булдымыни?— диде Ислам.

— Кирәге барые бик! Болай гына... үлгән кешене искә төшерәсең ич шулай кайчагында,— диде Тәзкирә, тимер мич янына килеп.— У-у, бигрәк суык монда, ягып җибәрик әле.

— Як.

Ислам, озын гәүдәсе белән урталай бөгелеп, сәкегә җайлап утырды да, Тәзкирәгә каш астыннан гына караган килеш, тынып калды.

— Синдә бер ярты булырга тиеш,— диде ул Тәзкирәгә.

— «Папаша» бүлмәсендә калды бит ул,— дигән булды Тәзкирә, күзләрен майландырып.

— Эх, карга! Шунда калдыралармы?— диде Ислам, шелтә белән.

Ул каяндыр бер кадак табып алды да Таран бүлмәсен ачып эчкә керде. Аның артыннан Тәзкирә дә керде. Кирәкле нәрсәне алар икәүләп эзләделәр. Караңгыда Исламның әле кулына, әле битенә полтыранган дымлы чәч бөртекләре тиеп китте. Аның ачуы килде, әледән-әле үзенә орынып киткән сөйкемсез хатынны төртеп җибәрүдән ул үз-үзен чак кына тыеп калды. Ниһаять, өске сәке почмагында, ниндидер пычрак керләр арасында эзләнгән нәрсә килеп чыкты.

— Бар, ашарга алып кил,— диде Ислам.— Каранып йөре, кызларны уятма.

Тәзкирә кухняга чыгып йөгерде һәм бер-ике минуттан ачылмаган бер консерва белән кипкән балык, икмәкфәлән күтәреп керде.

Ислам ишекне бикләде дә яңадан үз урынына сәкегә килеп утырды.

— Җә, сөйлә барысын да... ниләр булды мин юкта?..

Тәзкирә үзе белгәннең барысын да төкми-чәчми сөйләп бирде. Аның сөйләгән сүзләрендә Ислам көткән куркыныч хәбәрләр булмаса да, минут саен ул үзендә тыелгысыз бер ярсу дулкыны күтәрелә барганлыгын тойды.

## XVIII

Кичтән авызына аракы алдымы, Тәзкирәнең иртән тора алмый азаплана торган бер яман гадәте бар иде. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, бүген дә нәкъ шулай булды. Ул йоклап калды, үзләре вагонында гына да түгел —

Ислам вагонында йоклап калды. Ул чепи күзләрен ачыштырып җибәргәндә, тәрәзәдән бөркелеп, бүлмәгә якты кояш нуры тулган иде, тышта кемнәрдер мыгыр-мыгыр сөйләнеп йөриләр иде. Бик тиз арада ул үзенең кайдалыгын абайлап алды, атылып урыныннан торды, кабаланып-калтыранып ерык изүләрен каптырды һәм әвәләнгән күлмәк итәген аска сыпыргалап төшерде дә тиз-тиз генә аягына киенеп куйды. Аннары ул шулай ук кабаланып өстенә киенде, идәндә аунап яткан яулыгын башына алып бәйләде һәм шулай таушалган-борчылган өс-баш киеме белән, йокылы, куркынган кыяфәт белән тышка йөгереп чыкты.

Аның Ислам вагоныннан чыгуын беркем күрмәде. Бер читтәрәк гимнастика ясап яткан Мансур, үз эше белән мавыгып, аңа бөтенләй игътибар итмәде. Тәзкирә башта поход кухнясына, аннары титанга ут кабызып җибәрде, тыз-быз чабып тегесен-монысын әзерләргә кереште. Әмма никадәр ашыкмасын, никадәр куырмасын, барыбер өлгерә алмады. Көндезге эшкә китәчәк кешеләр ашарга тиешле вакытка казандагы су да кайнап чыкмады. Булачак тавыш-гауганы күз алдына китереп, коты алынган Тәзкирә нишләргә дә белмәде.

Шулай итеп, аш өлгермәде. «Убырлар» исә, торып аякларына басу белән, бер-бер артлы өстәл янына килеп тә утырдылар; килеп утырдылар да, хәзергә әле бик үк тавышланмыйча, шулай да шомлы бер тынлык саклап, көтә башладылар.

— Хәзер, хәзер, җанкисәкләрем! Бер генә минут, биш кенә минут. Хәзер кайнап чыга... Кайнап чыккач инде ул, җанкисәкләрем, бер-ике минуттан пешеп тә чыга. Хәзер, хәзер...— дип сөйләнде ул, ары чабып, бире чабып.

Ләкин якынлашып килгән җил-давылны туктату инде аның көченнән генә килерлек түгел иде. Ә җил-давыл килде, бары далада гына булганча, бик тиз килде һәм бөтен нәрсәнең астын өскә әйләндерде дә ташлады.

Төнге сменадан арып-алҗып кайтып төшкән Барыйны яшьләр ризасыз шау-шу белән каршыладылар. Аларның бозык кыяфәтләрен күреп, бригадирның үз-үзеннән канәгать йөзе шундук үзгәреп китте, нindидер яман нәрсә булганлыгын сизенеп, йөрәге кысылып куйды: «Тагын! Монысы нәрсә икән инде?»— диде ул үз-үзенә.

— Ни булды?— диде ул, тыелып кына.

Егетләр аңа аңлатып бирделәр. «Кичәгенәк коймаклар пешергән иде... Ислам кебек аяк чалмакчы була микәнни?»— дип уйлап алды бригадир кеше.

— Чыгарып ташларга кирәк шул шакшыны!
— Чыгарабыз, кирәге юк!— диештеләр яшьләр.
Аларның бу шаулашуында, бер яктан, Тәзкирәгә карата ачу булса, икенче яктан, яңа бригадирга сыгыну, аннан ярдәм көтү, аңа ышаныч баглау ишетелде.
Барый шул чакны вагоннан чыгып килүче Исламны күреп алды. «Кайткан бит, кайткан!— диде ул үзалдына, куану шикелле бер нәрсә тоеп.— Милициягә дә эләкмәгән, кул-аягы да исән, башы да исән».
Ул аны чын-чынлап кайтмас дип, хурлыгыннан, йә булмаса, үчлекләшеп бөтенләй бригаданы ташлап китәр, дип, тагын әллә нәрсәләр дип уйлап бетергән иде. Мондый чакта кеше качырып яту, әлбәттә, күңелле нәрсә булмас иде. Бит ул бер дә алай начар кеше күренми, кем белә, бәлки, чыннан да аның белән бергәләп эшләп китәргә булыр. Бераздан, күнегә, өйрәнә төшкәч, ярдәмче итеп билгеләргә булыр. Начальство булырга ярата икән, әйдә, була бирсен! Ләкин шул ук вакытта аны бары бригададан качмаган өчен генә башыннан да сыйпап булмый. Аның белән хәзер бик күңелсез сөйләшү, котылгысыз сөйләшү булырга тиеш. Икәүдән-икәү генә сөйләшергәме, әллә?.. Юк, ул Тәзкирә түгел, аның белән кыенрак булыр. Аны... шулай ук менә бу ялкау Тәзкирәне, күрәсең, бары бергәләп кенә, бөтен бригада белән генә акылга утыртырга мөмкиндер.
Көн салкынча, җилле булганга, җыелышны олы чатырда ясарга булдылар. Кызлар-егетләр озын өстәлнең ике ягындагы озын утыргычларга, тимер караватларга тезелешеп, кысылышып утырдылар, һәркемнең өстендә эш киеме иде, һәркемнең кыяфәте түземсез, ачулы иде. Соңгы кеше булып Галимулла белән Фәрханә апа кергәч тә, өстәлнең түрге башында басып торган Барый җыелышны ачып җибәрде.
— Ярар, башладык,— диде ул, беренче сүз итеп.— Бригадир булуыма әле бер тәүлек тә булмады — менә инде икенче җыелыш. Эш вакытында сүздән ботка кайнату килешми. Шулаймы? Шулай булса, менә шул: чәчү беткәнче бу икенче һәм соңгы җыелыш булсын! Иптәш Мусин! Басыгыз, сөйләгез — көн тәртибе буенча иң элек сезнең мәсьәләне тикшерәбез. Мөмкин кадәр кыска сөйләгез.
Башын күтәрмичә тын гына утырган Ислам кыймылдап куйды, ләкин торырга ашыкмады. Бригадир белән килешү теләге, аннан гафу үтенү, һич булмаса, аңа барысын да сөйләп бирү теләге — Барыйның үзен күргәч тә, эчтән генә тантана итә шикелле тоелган Һаруннарны,

Андроновларны күргәч тә — барысы да анда хәзер кирелек белән, ярсырга, дуларга торган бер нәфрәт белән алышынды.

— Нәрсә сөйләтмәкче буласыз миннән?— диде ул, чакчак кына үртәлгәндәй итеп.— Мин артист түгел, шулай ук кәмитче дә түгел.

Аның янында утырган Кәрам, озын сырма җиңе белән авызын каплап, пырхылдап көлеп алды.

— Ислам Мусинның кәмитче түгел икәнлеген мин дә раслый алам!— дип кычкырды Белугин.

Якындагы кызлар Кәрам белән Белугинга ачулы пышылдап алдылар.

Бригадир, бөтен чатырны яңгыратып, боеручан тавыш белән кинәт:

— Торыгыз!— дип кычкырды.

Ислам чак-чак кына калтыранып китте. Ул торырга кирәк тапты һәм, бригадирга сөзеп караган килеш, нәрсәдер көтә башлады.

— Алдан кисәтеп куям: юк-бар сөйләп вакытны алмагыз,— диде Барый.— Качышлы уйный торган чак түгел. Ник кичәгенәк сменага кайтып җитмәдегез?

Артык киреләнеп, үзсүзләнеп торуның хәтәр икәнлеген Ислам бик тиз аңлап алды. Ачуын, ярсуын тыеп булса да, ул бераздан сүзгә кереште; түбәнсенмичә генә, мескенләнмичә генә һәм шулай ук бүтәннәрнең күңелен кытыкларлык дәрәҗәдә кыланмыйча, чак-чак кына бәйсез, чак-чак кына күндәм, килешүчән кыяфәттә, кичәгенәк үзенең нишләве, ни өчен соңга калуы турында сөйләргә керește.

Кайтырга машина көтеп торганда, диде, биш ел күрешмәгән бер иптәшемне очраттым, диде; шәһәрдән кайтып килә, кайдадыр бездән ары бер совхозда эшли икән, диде; очрашкач, билгеле, бик куаныштык, диде, ул мине үзе янына кабинага утыртты да үзләренә алып китте, диде; күптән күрешмәгән дус булгач, мин үзем дә карышмадым, аннары ул мине кичтән үк бригадага китереп куярга сүз бирде, чөнки ул үзе шофер, машина үз кулында, диде; аларга баргач бераз салырга туры килде, бик арыган булганга, мин боларда йокыга киткәнмен, уянып китсәм, кичке сигез булган, диде; соң булса да, ул мине бригадага китереп куйды, менә шулай итеп туры килде инде, диде.

Аның тавышында әз генә дә борчылу-пошыну да, үкенү дә сизелмәде, ул ничектер үзенә бөтенләй чит нәрсә турында сөйләгән кебек сөйләде. Ләкин шул ук вакытта аңа бәйләнергә дә мөмкин түгел кебек иде. Кыска гына

сөйлә, юк-бар сөйләмә, диделәр. Менә ул мөмкин кадәр кыска итеп, сөзеп-сыгып кына сөйләде дә бирде. Тагын нәрсә әйтергә?

Ул беркадәр вакыт уйланып торгандай итте дә, күрәсең, болай гына котылып булмаячагын үзе дә аңлап:

— Мондый нәрсәнең яхшы түгеллеген үзем дә аңлыйм,— диде.— Үз хатамны төзәтү өчен, бүген көндез берәрсе белән прицепщик булып барам, төнлә — сменага...

— Молодец, төзәлә башлагансың!— диде Белугин.

— Кем нәрсә әйтә?— диде Барый, утырган кешеләргә карап.

— Тагын нәрсә әйтәсең инде — җиткән! Төзәлергә сүз бирде ич,— дип кычкырды Илгиз.

— Җиткән, җиткән! Ашыйсы килә, бетерик инде!— диде Кәрам да.

— Җитмирәк торсын әле,— диде Андронов, урыныннан торып.— Бик җиңел генә икән: иптәшен очраткан, эчкән, исергән, йоклап калган... Кем кушкан аңа анда эчеп йөрергә? Җитәр, күп эчтегез Таран белән! Минемчә, болай гына калдырырга ярамый моны. Эшләргә теләми икән, әнә барыр юлы! Иң дөресе аның шул булыр.

Ислам өчен түгел, хәтта бригадир өчен дә бу көтелмәгәнрәк тәкъдим булды. Кешеләр җиңелчә генә шаулашып алдылар. Яңадан урынына утырган Ислам туптай атылып караваттан торды да, күзләрен шардай итеп, бөтен гәүдәсе белән Андронов ягына тартылып куйды.

— Кем сиңа эшләргә теләмим дип әйтте!— диде ул, бүртенеп. Аннары шундук Барый ягына борылды.— Алыгыз шуны миннән, йә булмаса, мине икенче тракторга куегыз. Күп канымны бозды инде... әллә бугазын чәйнәп ташлармын ачу килгәндә!

— Мин дә бик синең белән эшләргә атлыгып тормыйм,— диде Андронов.— Башта үзең җибәрмәдең бит.

— Ал мине!— диде Белугин Исламга.

— Анысын әле без карап карарбыз,— диде бригадир, тыныч кына.— Хәзер без ул турыда сөйләшмибез, сезнең турыда сөйләшәбез, иптәш Мусин.

— Нәрсә барыгыз да миңа ябырылдыгыз?— диде Ислам, бер кызудан Барыйга да кычкырынып.— Чыгарыгыз! Әллә бик исе китте дип белдегезме? Дала киң, совхозлар җитәрлек. Төкерәм бригадагызга!

Бу сүзләрне ул бераз гына үпкәләп әйтте, үзенең сүзен кирегә борып, үзенә бөтенләй икенче гаеп ташларга ниятләүләре өчен ачынып әйтте һәм, бригададан китәсе килмәгәнгә күрә дә, китү белән куркытмакчы булып

әйтте. Ләкин ул чак-чак кына эшне бозып ташламады. Аның соңгы сүзләре иң тыныч, иң пошмас кешеләрне дә кузгатып җибәрде. Юк, монысы инде чамадан тыш иде, монысы инде һич тә ярый торган нәрсә түгел иде.

— Алай төкерә торган булгач, тотмаска кирәк!— дип кычкырды Мансур.

— Бар, китә бир! Эзеңә көл сибеп калырбыз,— диде Һарун.

Ислам, аларның да авызларын томаламакчы булып, тагын бер мәртәбә урыныннан ыргылып алды, ләкин шундук арттан, алдан, уң яктан, сул яктан — төрле яктан аңа каршы бүтәннәр кычкырды, кызлар, егетләр кычкырды. Кирәкмәгәнне ычкындыруын Ислам бары шунда гына аңлап алды. Ул беркемгә дә җавап та кайтара алмады, беркемнең дә авызын да томалый алмады, киресенчә, аның үзенә хәзер тешен кысып, башын иеп утырырга туры килде.

Иң азактан Галимулла сүз сорады. Гадәттә беркем эшенә катышмый торган кешенең нидер әйтергә җыенуын күреп, Ислам үзалдына мыскыллы гына көлемсерәп куйды. Ләкин, гаҗәпкә каршы, Галимулланың сүзе бүтәннәрнекенә караганда да үткенрәк булып чыкты.

Галимулла, ишек төбендәге карават кырыена, җир идәнгә чүгәләп утырган җиреннән ашыкмыйча гына торды да, тамагын кыргалап, уртага, өстәл янына килде һәм, никтер Барыйдан күзләрен алмыйча, тыныч кына сөйләргә кереште.

— Баш белән уйлап караганда, дөрес, иптәшләр,— диде ул.— Андронов белән эшлисем килми дип, ни алай, Ислам туган... Минә минем дә үгезләр белән тарткалашып йөрисем килми дә бит — кушкач, нишлисең... кирәк булгач... Андронов белән эшлисең килмәсә, әйдә, ал минем үгезләрне, алышабыз.

Мондый алыш-бирешне ул һич тә шаяртып кына тәкъдим итмәде, ахрысы, шулай ук аның Исламнан көләргә дә исәбе юк иде шикелле. Ләкин шунда бөтен чатыр эче тетрәп, дер селкенеп китте — барысы да кинәт бушанып, тыела алмыйча көләргә тотындылар.

— Ике үгезгә бер трактор әзрәк булмасмы?

— Өстәвенә нәрсә сорыйсың?— диделәр егетләр, шаркылдашып.

Үзенең сүзен көлкегә алган өчен кәефе кырыла язган Галимулла, сабыр гына көтеп торды да:

— Чынлап әйтәм,— диде.— Ата-баба күрмәгән үгез... Бүген минә Барый белән сөреп кайттык, күңелләр күтәрелеп китте.

— Булдымы, Галимулла абзый?— диде Барый, аның сүзен бүлеп.— Үзең беләсең, вакыт тар. Соңгы сүзеңне әйт тә...

— Соңгы сүзме, Барый туган? Соңгы сүз менә шул...— диде Галимулла, бригадирның ашыктыруын бик үк ошатмыйча.— Туктагыз әле, ник сез миннән соңгы сүз әйттерәсез? Әйтсен Ислам, гаепле икән, әйтсен. Алай гына булмый бит ул, иптәшләр. Баш белән уйлап караганда, егет кеше эше түгел бу, дезертир эше! Шул минем соңгы сүз.

Ул сөйләп бетерде дә, кәефләнеп, тыныч кына яңадан үз урынына утырды. Ислам турында аның «дезертир» дип әйтүе, Андронов сүзләре шикелле тагы да көтелмәгәнчәрәк булып, кисkenрәк булып яңгырады. Бригада тып-тын калды, һәркем үзалдына: «Шулайрак микәнни? Тагын кем нәрсә әйтер икән?»— кебегрәк сорау бирде һәм барысы да, кем дә булса башлап җибәрсә, йә аны якларга, йә аңа каршы чыгарга кирәклеген аңлап, сагаеп, тынычсызланып көтүендә булды.

Бригадирның һич тә сүзне озайтып торасы килмәде. Ислам турында ул җитәрлек әйтелде дип, үткәзеп әйтелде, тиешенчә әйтелде дип исәпләде, һәрнәрсәнең чамасын белергә кирәк булган кебек, монда да, билгеле, чама дигән нәрсәне онытып җибәрергә кирәкми иде. Төрле яман исемнәр белән атап кына, сүгеп-тиргәп кенә Исламны, әлбәттә, төзәтеп тә, акылга утыртып та булмаячак иде. Моның хәтта кире нәтиҗәгә китерүе дә мөмкин иде. Бригадирлык итүенең беренче адымыннан ук ул андый күсәк күтәрү юлына басмаска булды һәм, артык сүзләргә урын калдырмыйча:

— Ярый, бу турыда хәзергә җитәр,— диде, кискен генә итеп.— Галимулла абзыйча әйткәндә, егет кеше эше түгел бу! Шулаймы? Шулай булса, менә шул: үз гаебен чын күңелдән тануын, калдырган бер смена өчен бүген прицепщик булып эшләргә теләвен исәпкә алып, иптәш Мусинны бу юлы гафу итәбез. Икенче кабатламасын дип, сабак булсын дип, фәлән-төгән дип әйтеп тормыйбыз. Акылсыз кеше түгел — кирәген үзе аңлар. Каршылар юкмы?

— Юк,— диделәр, тыелып кына.

— Бертавыштан кабул ителде.

## XIX

Барый баштарак, Ислам яклылар күбрәк була күрмәсен тагын дип, бераз гына шүрләп тә куйган иде. Күпчелекнең үзе яклы икәнлеген күреп, аның күңеле

үсеп, тыны озаеп китте. Әле кичә генә шундый ят булып тоелган, әмма менә бүгеннән, шушы минуттан кинәт якынаеп киткән кешеләр арасында — күбесенең әле исем-фамилияләрен дә белеп бетермәгән, йөзләрен дә әле ныгытып хәтердә калдырмаган кешеләр арасында ул үзенә ышаныч ноктасы тапты һәм менә шул ышаныч ноктасына таянып эш иткәнгә күрә дә шундый җиңүгә иреште. Ислам белән икәүдән-икәү генә сөйләшсә, ихтимал, бернәрсә дә барып чыкмаган булыр иде. Әйе, кем белә аны...

— Тагын шуны да әйтәсем калган икән,— диде ул аннары, бөтенләй вак нәрсә турында сөйләнгән шикелле.— Бүген үк егетләр чатырына күченегез. Берүзегезгә бер бүлмә биләү бик үк ярап бетмәс. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды...— диде Ислам.

— Монысы бетте. Тәмам!— диде Барый, кулын күтәреп.— Хәзер аш пешерүче турында...

Бригадир кыска гына итеп бу мәсьәләнең ни өчен җыелышка куелуын аңлатып бирде. Әле генә без иптәш Мусинны тәнкыйть иттек, диде; ни өчен тәнкыйтьләгәнебез аңлашылып тора, диде, чөнки ул эшкә аяк чалды, диде. Ә менә аш пешерүче Тәзкирә Садриханова, әйтүегезгә караганда, көн дә эшкә аяк чала, диде; бүген менә тагын ул үз эшенә соңга калган, диде; бөтен бригаданы ач тота, бөтен бригаданың эшенә аяк чала, диде; кайберәүләр аны эшеннән үк алырга кирәк, диләр, мин яңа кеше, берни әйтә алмыйм, үзегез карагыз, сез нәрсә әйтсәгез, мин шуңа риза, диде.

Бу мәсьәләдә күп сүз булмады. Җыелыш бик коры тотты, Тәзкирәне эшеннән алырга һәм прицепщик итеп куярга дип бертавыштан карар чыгарды.

— Ләкин кемне куябыз соң?— диде Барый, җыелышка карап.— Шуны да онытмыйк — аш пешерү бик авыр эш, җаваплы эш. Бөтен бригаданың яхшы эшләве, барыннан да элек, аш пешерүченең тырышлыгына бәйләнгән. Тамагың ач булса, эшлисең дә килми, күңелең дә төшенке була. Шулаймы? Бәлки, бу авыр, җаваплы эшне үзләре теләп алучылар булыр?

Бригадир хатын-кыз халкына сораулы күз карашы ташлап алды.

— Иң яхшысы монда Фәрханә апа булыр,— диде Илгиз.— Хатын-кызлардан монда аннан да тырыш, аннан да чиста кеше юк.

— Мин дә шундыйрак фикердә,— диде Барый, бераз гына ашыгычлык күрсәтеп.

— Юк, Барый туган, туктале син,— диде кинәт Гали-

мулла, тавыш биреп.— Фәрханә апагызның эше бар. Җиткән. Баш белән уйлап караганда, ике эшне бергә алып бара алмас ул. Үзең дә әйтеп торасың, авыр, дисең, җаваплы, дисең. Монда яшь кеше кирәк, өлгер кеше.

— Кая соң әле ул үзе?— диде Барый, Фәрханә апаны күрмәкче булып.— Үзе нәрсә әйтә бит!

Фәрханә апа әлерәк кенә чыгып киткән иде. Ул Тәзкирә пешереп өлгертмәгән ботканы пешерә иде.

— Ул, Барый туган, мин нәрсә әйтсәм, шуны әйтер,— диде Галимулла, чүгәләп утырган урыныннан кымшангандай итеп.

Халык күңелле генә гөрелдәп алды.

— Менә ул капитализм калдыгы!— дип кычкырды Белугин, шау-шу арасында.

— Карале, Галимулла абзый, син әле шундыйрак икәнсең!— дигән булдылар кызлар, Галимулланы оялтмакчы булып.

Галимулла аларның шаяртуына бөтенләй игътибар итмәде, ышанмасагыз, үзеннән сорарсыз алайса, диде.

Шулай күңелле генә шаулашкан чагында, ишек төбендәге караватларның берсенә кысылышып утырган берәү кулын күтәрде.

— Мине куегыз,— диде ул.

Нинди батыр кеше икән ул дигән шикелле, барысы да аның ягына борылып карадылар.

— Фәридә?!— диде Илгиз, чатыр эчен яңгыратып.— Табылып тора соң кешесе дә! Барысы да тынып калдылар.

— Ничек, ышанасызмы, булдыра алырмы?— диде бригадир, җыелышка эндәшеп.

Беркем дә туры гына җавап бирә алмады. Кайсылары: кем белә аны, дигән төсле иңбашларын җыерып куйдылар, кашларын сикерттеләр, авызларын кыйшайттылар; кайсыберсе үзара пышылдашып алырга да өлгерде. Чыннан да, кем белә аны? Эштә әллә ни куандырмый, ләкин шул ук вакытта ялкау да түгел бугай.

Беркем дә яклап сөйләмәгәч, ничектер уңайсыз була башлады.

— Минемчә, булдырыр,— диде Зәкия, беренче булып.

— Булдырыр, ник булдырмасын,— диде Наташа да, тыелып кына.

— Сез нәрсә беләсез соң!— дип кычкырды Илгиз кызларга.— Әнә Һарун әйтсә дә ярый, ичмасам!

— Юк, Ислам әйтсен, Ислам!— дип кычкырды кемдер почмактан.

Һарун, һәркемнең үзенә төбәлгән елмаюлы күз кара-

шын тоеп, кинәт кызарынып китте. Аның Фәридә турында ни дә булса әйтүен алар чынлап телиләрме, әллә болай гына шаярталармы? Әйтсәң, нәрсә әйтергә? Кара, ничек итеп чеметтереп алды! Туктале, аның чеметтерүенең монда ни катнашы бар? Фәридә бит аның белән эшли, шулай булгач, чыннан да, ул аны яхшырак белә.

Ул торып басты да, буталып, тотлыккандай итеп:

— Минемчә дә... булдырыр...— диде.— Ул кыз кеше. Чәчүдә аңа авыр. Монда да авыр инде... Аш пешерү аның эше инде... Үзе теләгәч... булдырыр, тырышыр инде...

Аннан беркем дә көлмәде, аны бик игътибар белән тыңлап тордылар, һәм бөтенләй көтмәгәндә аның сүзе бу мәсьәләдә хәлиткеч булып чыкты — аш пешерүче итеп Тәзкирә урынына Фәридәне куйдылар.

Шул чакны чатырга Фәрханә апа килеп керде.

— Ашарга өлгерде, оланнар,— диде ул һәм сәхнәдәге конферансье шикелле шундук кире чыгып та китте.

## Бишенче баб

### I

Чит кешегә дала никадәр киң, иркен булып, буш, ташландык булып тоелмасын, чынында ул иясез җир түгел, җансыз-өнсез сахра түгел.

Еллар, гасырлар буена ул шулай тарау булып җәелеп яткан; еллар, гасырлар буена ул шулай берни үсми торган, беркем тормый торган сихри бер патшалык булып тоелган. Әмма еллар, гасырлар буена монда кеше гомер иткән.

Әйе, гомер иткән. Ләкин алар монда беркайчан да иген дә икмәгәннәр, җимеш-бакчалар да үстермәгәннәр, агач-таштан гүзәл итеп зур-зур калалар да салып калдырмаганнар.

Ничек гомер иткәннәр соң алар, нәрсә белән көн күргәннәр, дөнья көткәннәр?

Еллар, гасырлар буена алар монда көтү көткәннәр, сыер, сарык асраганнар, ат-җылкы тотканнар. Шуның белән алар тамак туйдырганнар, шуның белән киенгәннәр, җылынганнар, һәм аларга шуннан башкача туенырга, киенергә дә, башкача гомер итәргә дә мөмкин түгелдер шикелле тоелган.

Көтүченең бөтен гомере шушы киң далада үткән, күл буенда, су буенда мал-туар арасында үткән. Бәрән, бозау белән, колын белән бергә туган; сыер, сарык белән, ат-җылкы белән бергә үлгән.

Бөтен илгә уртак булган олы үзгәрешләрне исәпкә алмаганда, хәтта егерменче гасыр уртасына хәтле монда тормыш өчен төп чыганак шул көенчә торып калган: беркем берәү җир сөрмәгән, беркем берәү иген икмәгән. Шул ук иркен дала калган, көтүлекләр, мал-туарлар калган, тик хәзер ул көтүләрнең хуҗалары фәлән хан да, фәлән биләр-бәкләр түгел, бәлки, фәлән колхоз, фәлән совхоз булган.

Еллар, гасырлар буена Казакъ даласында тормыш шулай дәвам иткән.

Ләкин тын даланы корыч чыңы, мотор шавы белән күмеп, киң табанлы чаналарга утыртылган кызыл вагоннар һәм әкәмәт зур цистерналар тагып, кар-көрт ерып, көтмәгәндә фәлән елны монда көчле тракторлар килеп чыкты; килеп чыктылар да, буран уйнап торган дала уртасыннан бертуктамый көн-төн алга үрләделәр. Авылларга җиткәч, тракторлар буран күмеп киткән саман йортлар каршысында туктап калдылар. Вагоннардан сикерешеп яшьләр төште; яшьләр белән бергә чемоданнар,

капчык-тѳенчеклəр тѳште, чатырлар һəм караватлар тѳште.

Алар бик күп иде, алар хəтта бѳтен Кѳктугай халкыннан да күбрəк иде.

Туңмасыннар ѳчен, ерак юлдан арып килгəч ял итсеннəр ѳчен, киң күңелле дала халкы кунакларны үз ѳенə кертте, җылы урынын бирде, ашын-чəен бирде. Болай да бик кысан йортлар тагын да кысанланып, кечерəеп калды. Лəкин беркем шыңшымады, зарланмады — шулай кирəк булгач, ничек тə түзəргə, сер бирмəскə тырыштылар.

Əмма ерак җирдəн килгəн бу кешелəр кѳннəрдəн бер кѳнне, без, дилелəр, монда гомерлеккə килдек — киң даланы сѳреп иген игү ѳчен, яңа тормыш кору ѳчен килдек, дилелəр.

Əйе, шулай дилелəр. Озакламый Кѳктугайга күченергə туры килде. Далаларын ташлап, туган-торган урыннарын ташлап кѳктугайлар алыстагы Камыскүлгə юнəлделəр. Дѳрес, аларга əйттелəр, безгə эшчелəр бик кирəк, калыгыз үз авылыгызда, җолдастар, бергə-бергə иген игəрбез, дилелəр. Лəкин «иген игү», «дала сѳрү» турында беркемнең дə ишетəсе дə килмəде. Шулай итеп, Кѳктугай күченде.

Атлар, дѳялəр җигелгəн чаналарга барлык җиһазларын, барлык кием-салымнарын, азык-тѳлеклəрен тѳялелəр дə, сыерларын, сарыкларын арттан куып, əкрен генə, шыгыр-шагыр Камыскүлгə сəфəр чыктылар. Дѳрес, совхоз аларга торып калган йортлар ѳчен тиешле акчасын түлəде, күченергə машиналар бирде, ярдəм итеп эшчелəрен бирде. Шуның ѳстəвенə совхоз янындагы тѳзелеш оешмасы Камыскүлдə яңа йортлар җиткерүдə күченүчелəргə тегесе-монысы белəн булышуны үз ѳстенə алды. Лəкин картлар əйтте, дала бетə, җир бетə, дилелəр; кысылдык, дилелəр, ул даланы сѳрəбез дип əйтүлəре чынга чыкса, кѳтүлеклəр, болынлыклар харап була гой, кайда кѳтү кѳтəрбез дə ничек итеп мал-туар асрарбыз, дилелəр. Кайбер башлыраклар əйтте, юк сүз ул, булмас, дилелəр, шушы яшькə җитеп əле беркемнең дə, далада иген игеп була икəн, дигəн сүзен ишеткəнем юк, дилелəр; менə күрерсез, бидайлары тишелеп тə чыкмас, шундук кояш кѳйдереп ташлар, дилелəр; берəр җəй азапланырлар да, берни булдыра алмагач, үзлəреннəн-үзлəре таралышып бетəрлəр, дилелəр. Тѳрлесе тѳрлечə юрады, тѳрлесе тѳрлечə кайгырды.

Бер-бер артлы Камыскүлгə килə тордылар, кеше ѳстенə кереп, ничек кирəк алай урнаша тордылар.

Язлар җитеп җир ачылгач, Камыскүлнең бер читендә тип-тигез бер яңа урам барлыкка килде. Хәер, бу әле урам ук түгел иде, бу бары тик булачак урамның сызыклары, билгеләре генә иде. Бу булачак авыл иде — Көктугайга да, Камыскүлгә дә охшамаган тигез, төзү авыл иде.

Озакламый Көктугайдан вәгъдә ителгән бер машина килде, төзү эше осталары килде. Килделәр дә, күп сөйләшеп, сатулашып тормаенча, эшкә тотындылар. Хәзер инде аларга беркем дә кырын күз белән карамады, ләгънәт тә укымады, киресенчә, уңган, оста бу яшьләрне авыл халкы тиз арада яратып та өлгерде.

Әкренләп-әкренләп тормыш шулай үз җаена керде. Маллар көтүгә чыкты, абзарлар бушап калды, сыер савучылар, терлек караучылар далага — ерактагы утарларга — фермаларга күченделәр. Зурайтылган «Җамбыл» колхозының көтүләре күзгә күренеп артты, ишәйде. Ләкин, гаҗәп хәл, көтүләр никадәр күп, ишле булмасыннар, көтүлекләр беркемгә дә тар, кысан булып күренмәде. Ни әйтсәң дә, монда да туган дала иде, монда да шул ук Иртыш буйлары, шул ук болыннар-тугайлар иде. Юк, дала әле һаман киң иде, һаман әле иксез-чиксез иде. Нишләтсәң дә, аны берничек тә кысып, тарайтып булырлык түгел иде.

## II

Көктугайдан Байболат карт иң соңгы кеше булып күченде. Камыскүлдә беренче төнне ул бөтенләй диярлек аяк өсте уздырды. Монда аның бер генә нәрсәгә дә күңеле ятмады, бер нәрсәгә дә кулы бармады. Бүтәннәр шикелле ул яңа җирдә яңа йорт өчен урын да сайлап йөрмәде, яңа йортны ничек итеп җиткерербез икән дип тә хафаланмады. Шулай бер-ике көн каңгырап, башын иеп йөрде-йөрде дә, фермага маллар янына китте. Ул көтүче иде, бер еллык, ике еллык кына да түгел, тумыштан ук, туганчы ук көтүче иде. Көтүгә чыгарга, әлбәттә, бик иртә иде әле, фермада да эшчеләр җитәрлек иде. Ләкин ул барыбер фермага китте, бөтен вакытын шунда мал-туар арасында уздырды, бөтен кайгысын шунда онытмакчы булды. Чынында ул бары шунда гына үзен тыныч, иркен сизде, ләкин эче-тышы бала-чага белән, хатын-кыз белән тулы кысан өйгә кайттымы, беркайчан да булмаганча, әле анысын кырды, әле монысын кырды, бер дә юкка хатынына бәйләнде, балаларына бәйләнде.

Бары тик Сәлим белән генә ул тынычрак сөйләште дә

аның хатынына гына каты орынмады. Сәлим аның беренче хатыныннан туган кече улы иде. Көктугайда чакта Сәлим өйләнгәч тә әкәсеннән башкаланып чыккан иде, ләкин монда кеше өстендә алар бөтенесе бергә торалар иде.

Сәлимне ул тирги дә, кыздыра да алмады, шулай ук аңа акыл да өйрәтә алмады. Киресенчә, әкә кешенең үзенә аннан еш кына каты-каты сүзләр ишетергә туры килгәли иде. Сәлим әйтте, аңсыз адам син, әкәм, диде; ашлыкны безгә элек читтән китерәләр иде, хәзер менә үзебезнең бидаебыз булачак, диде; син әйтәсең, дала бетә, җир бетә, дип әйтәсең, диде; нишләп бетсен, кая булсын, диде; дала беркая да китми, шунда кала, диде, әллә соң акылың юкмы шуны аңларга, диде; җәйге кояш кыздыра башлагач та корып-саргаеп бетә торган кылган, әрем урынына анда шаулап иген үсәчәк, диде; синең әле беркайчан да иген басуларын, шаулап утырган бидай, арыш басуларын күргәнең юк, ә мин күрдем, шуңа күрә һич тә курыкмыйм да, борчылмыйм да, диде.

Камыскүлдә тора башлавының беренче көненнән үк үзен монда ул бөтенләй үз кеше итеп тотты: көн дә иртән каядыр чыгып китте, кемнәр беләндер дуслашып-аралашып алды, тегесе турында, монысы турында кайгыртты һәм шулай азапланып йөри торгач, Камыскүлнең ватылып эштән чыккан двигательләрен рәтләп бирде, электр утлары кабызды, тирән кое насосларын эшкә җибәрде. Әйтәсе дә түгел, үзе уңган, үзе оста — нигә генә барып тотынмасын, коя да куя, ясый да куя. Ул ягына берни әйтеп булмый. Кем улы — аның улы! дигәндә үзе ни тора.

Ләкин хәзер аның хәтта уңганлыгы да картның ачуын гына китерде. Бигрәк тә аның шуңа эче пошты: гомергә шушында торган сыман, үзенең туган авылын, туган болыннарын Сәлим исенә дә кертеп чыгармады, кайгырмады, уфтанмады һәм кайгыручы-уфтанучы адам-дарга әз генә дә теләктәшлек белдермәде. Ихтимал, ул да эченнән генә сызгандыр, әмма ләкин Байболат карт берни сизенмәде. Ул яшьләрнең барысы да шулай, әйтерсең аларга инде дала да кирәкми, җир дә, болыннар да кирәкми, хәтта мал-туар да кирәкми. Аларга шул машина да трактор булсын, электр да радио булсын. Бүтәне турында алар исләренә дә кертеп карамыйлар. Эх, бозылды заманалар, бозылды дөньялар!

Тора-бара Байболат та ил кайгысы белән килешә башлагандай булды, бик үк килешмәсә дә, сирәгрәк көрсенә башлады. Килешми нишлисең? Кая барасың? Кире Көкту-

гайга кайтып китмәссең бит! Ярый ла, акыллы башларның сүзе дөрескә чыгып, бернәрсә дә булдыра алмыйча, үзләреннән-үзләре таралышып бетсәләр!.. Бетмәсләр микәнни?.. Исең китәр, казакъ гомергә шул далада яшәп тә иген игә белмәгән. Орыс, нугай килде дә бидай чәчә, янәсе. Алай җиңел генә булса, казакъ күптән инде игенче булган булыр иде. «Юк, үлгәнче кайтам әле мин Көктугайга... үз болыннарыма!»— дип уйлады ул үзалдына, гайрәтләнеп.

Әйе, ул инде күнегә дә башлаган кебек булган иде, күнекмәсә дә, ул кадәр үк бетеренми иде. Ләкин тыныч кына шундый бервакытта юлдан язган Сәлим коточкыч бер яңа хәбәр алып кайтты. Әкәм, диде, без дә быел дала сөреп бидай игәчәкбез, диде; совхоз гына түгел, безнең «Җамбыл» колхозы да ашлык үстерәчәк, диде. Үз гомеребездә беренче мәртәбә җир сөрәчәкбез. МТСтан безгә тракторлар килә, кешеләр килә, шуны белдем бүген, әкәм, диде.

Мондый сүзне ишетеп, Байболат карт телсез-өнсез калды; көрәктәй зур куллары белән сул як күкрәген кысып тотты да, хәлсезләнеп, «лып» итеп сандык өстенә утырды. Улына ул берни эндәшмәде. Ни дә булса әйтергә һәм нәфрәт, ләгънәт белдерергә аның хәзер көче-тәкате җитмәде.

Шулай итеп, чыннан да бетә... Моңарчы әле: дала бетә диеп сөйләнгәндә дә, күңеленең яшерен бер җирендә аның беркайчан да бетмәячәгенә, аның зурлыгына, киңлегенә ныклы бер инану бар иде. Кайчагында ул да нәкъ Сәлим шикелле уйлап куя иде һәм күңеленнән, үз-үзен юатып, берничә совхоз гына ул даланы барыбер сөреп бетерәчәк түгел, дидер иде. Иртыш буенда әле авыллар, колхозлар бар иде һәм барлык колхозларны совхозга әйләндереп тә, барлык авылларны далага күчереп тә булмаячак, дидер иде; кайда авыл — шунда казакъ, кайда казакъ — шунда дала, мал-туар, көтү булачак, дидер иде.

Ләкин әнә алай түгел икән шул. Алайса, колхозлар да совхозга әйләнәчәк, авыллар да бетәчәк, ягъни малтуарны юкка чыгарып, һәммә җирдә иген игәргә тотыначаклар! Болай булгач, чыннан да, бетә, бетә... Бернигә өмет юк.

Байболат карт хәзер тәмам телдән язды. Бер-ике көн эчендә ул күзгә күренеп ябыгып калды.

Ерактагы фермаларның кайбереннән маллар кыш көне дә кайтарылмый иде. Кышкы фермаларның берсе Иртыш буена, элекке «Кызыл ту» колхозы болыннарына якын бер җиргә урнашкан иде. Уйланды-уйланды да Бай-

болат карт бөтен гаиләсе белән шунда күченеп китмәкче булды. Ичмасам, күзем күрмәс, диде; тигез даланы бозсалар да, таллыкларга, чытыр-чатырларга керә алмаслар — тешләре үтмәс, диде. Камыскүлгә әйләнеп тә бакмамын, кирәгем исә җир упсын үзен, диде.

Колхоз идарәсе аның теләгенә каршы килмәде: бик яхшы булыр, синдәй тәҗрибәле, оста малчылар анда бик кирәк, Байболат әкә, диделәр.

Беркөнне карт иртән-иртүк фермадан ике дөя җигеп алып кайтты да, чытырлы арбага үзенең барлык сандыкларын, төргәкләрен, капчыкларын чыгарып төяде. Мендәрләр, ястыклар өстенә иң әүвәл карт энисе менеп утырды, аның артыннан хатыны менеп утырды, алары янына тагын кечкенә улы белән кечкенә кызы менеп утырды.

— Син нишлисең, минем белән китәсеңме, монда торып каласыңмы?— диде Байболат Сәлимгә.

Ул, билгеле, һич тә аның үзе белән тагылып йөрүен теләмәде. Ул моны болай гына, гадәт буенча гына сорады.

— Мин анда нишләрмен?— диде Сәлим.— Син көтүче — көтү көтәрсең. Минем күңел икенче нәрсәдә, әкәм, үзең беләсең. Ә Гөлбиби...

— Гөлбиби минем белән китә!— диде карт.

— Син башта аның үзеннән сора, бәлки, аның монда каласы киләдер.

— Сорыйсы юк!— диде карт, ачу белән.— Үзең каласың икән кал, кадалып кит! Әмма ләкин Гөлбиби минем белән китә.

Гөлбиби Сәлимнең туган сеңелесе иде. Абыйсын ул этисеннән дә, үги энисеннән дә, хәтта әбисеннән дә якынрак күрә иде. Каядыр кешеләрдән читкә, урман арасындагы ялгыз фермага күченеп китәргә аның һич тә күңеле тартмады. Кыен булса да, кысынкы булса да, аңа монда абыйсы янында, яшьләр арасында, үз тиңнәре арасында рәхәтрәк тә, күңеллерәк тә иде. Ләкин шул ук вакытта аның этисенә каршы килергә дә кыюлыгы җитмәде.

Чытырлы арбага, таудай итеп төялгән кием-салымнар, ястык-мендәрләр өстенә соңгы кеше булып яшь кенә бер кыз менеп утырды, һәм озын сыйраклы, озын муенлы дөяләр, ластыр-лостыр атлап, җиңел генә кузгалып та киттеләр.

Иртыш буендагы ялгыз фермада, мал-туар абзарларыннан һәм шуныңише каралты-курадан башка тагын көтүчеләр, сыер савучылар, мал караучылар өчен салын-

ган зур гына бер-ике саман йорт та бар иде. Байболат карт хатыннары, бала-чагалары белән шул йортларның берсенә урнашты.

«Камыскүлегезгә әйләнеп тә бакмам, кирәгем исә җир упсын шунда!» — диде ул, бер үк сүзне кабатлап. Монда ул гомергә, мәңгегә төпләнеп калмакчы булды.

## III

Ислам кибеттән төрткәләп чыгаргач, Байболатка тәмам дөнья җимерелгәндәй булды. Ул бик хурланды, үз гомерендә әле беркайчан да хурланмаган дәрәҗәдә хурланды. Дөньяда ул күп яшәде, күпне күрде, юк-бар өчен сугышкан, талашкан чаклары да булгалады, кыйналган, кимсетелгән чаклары да булды, озак вакытлар берәрсенә бик нык хәтере калып, ачу тотып йөргән чаклары да булды. Ләкин ул ачулар һәм һәртөрле хәтер калулар, күңел төбенә тирән төшмичә, әкренләп-әкренләп онытылып бетте. Чөнки ул вакытларда ул яшь иде, ваемсыз иде; тормыштагы күңелсез нәрсәләргә караганда күбрәк аның күңелле, матур нәрсәләргә игътибар итә торган чагы иде. Өй эчендә пыраннап алуларны исәпкә алмаганда, аның инде бик күптәннән бирле беркем белән телгә-тешкә килгәне юк иде.

Ә менә бүген аны сүгеп, төрткәләп чыгардылар. Төрткәләп кенә дә түгел, кыйнап, тукмап чыгардылар! Картлык көнендә аның чал башын хур иттеләр. Ничек җаның әрнемәс тә, ничек күңелең тыныч калыр моңа?!

Байболат карт, алдын-артын карамыйча, ярсуына, хурлыгына түзә алмыйча, бертуктаусыз атын юырттыруында булды. Ул ашыкты, Иртыш буендагы үзенең тыныч куышына ашыкты, беркайчан да үзен кимсетмәгән-хурламаган киң күңелле, күндәм көтүләре янына ашыкты.

Ат өстендә тирбәлеп бара торгач һәм каршы искән салкынча җил тәэсиреннән ул әкренләп йомшый төште, тынычлана төште. Инде Көктугай да, «кодай орган адамдар» да бик еракта калды. Каршыда тик зәңгәрләнеп Иртыш буе урманнары күренде дә, як-якта тик яшькелт болын уртасында, анда-санда ялтыр-йолтыр итеп, вак-вак күлләр торып калды. Юл читеннән, куе үлән арасыннан көтмәгәндә берәр кошчык очып чыкты, чыкты да, искәрмәстән ат түшенә бәрелә язып, шундук читкә томырылды. Юл буенча алдан сикергәләп каяндыр соры куян йөгереп китте. Анысы югалуга, камышлыктан озын аяклы челән күтәрелде, һәм кайдадыр бик якында гына, үлән арасында көчәнеп-көчәнеп, бытбылдык кычкырды.

«Бытбылдык, анда барып хур булдык!»— диде ул, картны үчекләгән сыман.

Байболат атын туктаткандай итте. «Кая дип болай ашыгам соң әле мин?»— дип уйлады ул, үз-үзенә сорау биреп. Әле яңа төш вакыты җитеп килә. Көтү янында кеше бар, сыер саварга иртә. Чынлап та, кая ашыга соң әле ул? Өйдә бер чеметем чәй юк, бер тешләрлек шикәр юк. Нәрсә дип җавап бирергә андагыларга? Кибет ачык түгел, дияргәме, әллә чәй-шикәр булмады, дияргәме? Хатыныңны, бәлки, алдарга да булыр, ләкин үз-үзеңне ничек алдарсың да, түшәктәге карт анаңны ничек алдарсың? Чәй-шикәрсез ул тора да алмый. Аннары, кибеткә барам дип, көн дә эштән аерылып, шулкадәр җиргә ат азаплап йөреп тә булмый. Кызы әйтте бит, көтеп тор, бабай, диде, хәзер килермен, диде.

Һәм ул атын кирегә борды. Өйгә таба бик теләп, бик җиңел кайткан ат, иясенең мондый кыланышына гаҗәпләнеп, колагын шомартты, башын боргалады. Үзенең ризасызлыгын болай да аңлата алмагач, пошкыра-пошкыра, әкрен генә, теләр-теләмәс кенә лыстырдый башлады.

## IV

Көктугайга килеп кергәндә, Байболат карт сыңар чиләк тотып яр астындагы коега суга төшеп килүче Әзизәне очратты. «Юлым булмас, ахрысы: кире дә борылдым, монысы тагын буш чиләк белән каршыма килә»,— дип уйлады ул, тагын да ныграк күңеле кырылып.

Әзизә Тәкен карт килене иде. Тәкен картлар әле шушы көннәрдә генә Камыскүлдән кире Көктугайга, үз йортларына күченеп кайтканнар иде. Хәер, Тәкеннең улы Мырзабек Камыскүлгә бөтенләй үк күченеп тә китмәгән иде бугай. Көктугайда совхоз оешкач, ул шунда ниндидер складкамы, мастерскойгамы эшкә кергән иде. Күрәсең, анысы үзсүзлерәк булып чыкты — яңадан барысын да үз янына тарттырды да алды. Бөтен авылга каршы килеп, үзенчә мөгез чыгарып азапланган җилкуар Мырзабекка картлар болай да кырын күз беләнрәк карыйлар иде. Атасын да үз ягына аударгач, бер дә җүнлегә түгел инде бу...

Мырзабек хатыны Әзизәне Байболат күрмәмешкә салынып узып китмәкче булды, ләкин Әзизә беренче булып үзе эндәште.

— Нәрсә син, Байболат әкә, бер киләсең, бер китәсең, әллә берәр нәрсәңне югалттыңмы?— диде Әзизә, көлеп.

— Югалтканны табарлык түгел инде, килен,— диде карт, аның көлүенә әз генә дә исе китмичә.

— Кереп чык, Байболат әкә,— диде Әзизә.— Син безне гел читләтеп йөрисең.

— Рәхмәт сүзеңә,— диде Байболат, атын куалап.

Ул шулай гына узып китмәкче булды, ләкин авылдашына, кордашына сугылмый узуны ул хәзер шулай да яхшысынмады. «Туктале, нишләп ята икән Тәкен карт?»— дип уйлады ул үзалдына һәм бара торган юлыннан кырт кына сулга борылды.

Хуҗалар Байболатны ачык йөз белән каршыладылар, аманмысың, диделәр; каян килеп чыктың болай, диделәр; әйдүк, түргә уз, мактап кына йөрисең икән — хәзер чәй эчәрбез, диделәр. Өйдә хуҗалардан башка тагын Камыскүлдән килгән бер-ике кунак та бар иде. Алар, җир идәнгә җәелгән киез өстендәге тәбәнәк өстәл тирәсен әйләндереп алып, ашап-эчеп утыралар иде. Кунак дигән бу кешеләр элекке авылдашлар, Көктугайныкылар иде. Байболат картның алар белән очрашмаганына инде бик күптән иде.

Күрешкәч, исәнлек-саулык сорашкач, хуҗалар Байболат картны да киезгә, үзләре янына утырттылар. Табын янында сүз баштарак хәл-әхвәл, саулык-сәламәтлек турында барды, аннары дөнья хәлләренә, дала хәлләренә күчте.

Байболат башта тыңлап кына утырды. Камыскүлдән килгән Өтембай белән Әдилбектән ул нинди дә булса яңа хәбәр ишетүне өмет итте. Иртыш буена күченеп килгәннән бирле, аның әле Камыскүлгә бер генә мәртәбә дә кайтып әйләнгәне юк иде.

— Дөресме, җырталармы?— диде ул сүз арасында, ниндидер әһәмиятсез нәрсә турында сөйләнгән сыман.

— Җырталар, җырталар, Байболат әкә,— диде Өтембай.— Авылдан бер-ике чакрым алыста, Куйҗатырга бара торган юл буеннан тотындылар. Җире кап-кара, әйләндерә дә бара! Караҗардан илебатырдан безнең адамдар орлык ташыйлар. Инде өченче көн чәчәләр. Җырталар, Байболат әкә, җырталар.

Өтембай ашыкмыйча гына сөйләде, кайгырып-пошынып сөйләде. Өтембайның мондый кайгырулы-пошынулы әкренлеге тәэсиренә бирелеп, үзалдына уйга калган кебек, һәркем аны җитди, олы кыяфәттә тыныч кына тыңлап утырды.

Чәй эчеп туйганчы Байболат карт авыз ачып бүтән бер сорау да бирмәде, һаман шул җитдилеген, олылыгын саклап, караңгы чырай белән тын гына утыруында булды. Дала турында, даланың харап булуы турында сүз куерту түгел, хәтта уйлый да алмады. Аруы-алҗуы һәм

тамак кибүе беркадәр басылса да, аның күңеленә әз генә дә ял булмады, киресенчә, авыр яра гына кузгалды.

— Синең хәлләр ничек соң, Байболат кордас?— диде Тәкен, авылдашына эндәшеп.— Синең бер дә тавыс-тының чыкпайды, үлеме-тереме син анда — киттең дә җок булдың.

— Хәлләр элеккечә,— диде Байболат карт, саран гына сүзгә керешеп.— Менә чай, кант дип килгәнием дә, җолым оңбады.

— Ничек алай?— диде хуҗа, кызыксынып. Байболат карт теләр-теләмәс кенә үзенең бүген хур булуы турында, бер «мас керген» белән бәрелешүе турында сөйләп бирде. Аның сөйләгәне тыңлаучыларга Өтембай сөйләгән хәлләргә караганда да күңелсезрәк тәэсир итте. Байболатның хәтере калуын һәркем үзенеке итеп кабул итте, һәркемнең күкрәгендә, каты таш булып, ачу хисе йомарланды. Ләкин беркем бер сүз әйтмәде, беркем берни белдермәде, бары тик чырайлар гына кырыслана төште дә, кысылган күзләрдә очкыннар гына күбәйде.

Тәкен картның учак тирәсендә булашкан карчыгы сорап куйды:

— Нугай баласы дисеңбе?— диде.

— Нугай баласы,— диде Байболат. Тагын тынлык урнашты.

— Ярый, рәхмәт, китим. Әллә тагын дөкәнен[1] дә җабып куяр,— диде Байболат карт бераздан, урыныннан кузгалып.— Аягым да тартпайды.

— Үзем генә барып килим, Байболат әкә?— диде Әзизә.— Мәрьям белән без таныш. Ул күрше йортта гына тора, Сапарлар йортында. Акчаңны бир дә, күпме кирәк, әйт,— хәзер алып кайтырмын.

— Рәхмәт, балам,— диде Байболат карт.— Сүзең өчен рәхмәт. Шулкадәр җирдән азапланып килгәч, бер-ике атлам җир өчен ялкауланып тору килешмәс. Чайдың да бит төрлесе була... карап алырга кирәкте.

## V

Аның бу баруында кибеттә ул-бу булмады. Исламның баягы тупаслыгы өчен гафу үтенгән сыман, Байболат белән Мәрьям аеруча ягымлы сөйләште, аның һәрбер соравына бик теләп, әйбәтләп җаваплар бирде һәм «тагын нәрсә кирәк» дигән шикелле, әледән-әле тутырып аның

---

[1] Дөкән — кибет.

күзләренә карап алды. Байболат картның күңеле эреп китте. Гаҗәп хәл, баягы хурлануын да онытты. Камыскүлдә даланы сөрә башлаулары турындагы хәбәрне дә, Әзизәнең теләгенә каршы килеп, әле генә өйдәгеләр каршында уңайсыз хәлдә кала язуын да — барысын да, барысын да исеннән чыгарды. Нишләптер аның шундук теле чишелеп китте, «бер бите ай, бер бите кояш» булган бу чибәр кыз белән бертуктаусыз сөйләшәсе, шаяртып, көлдереп сөйләнәсе килә башлады. Гөнаһ шомлыгына каршы, кибетендә аннан башка бүтән кеше дә юк иде.

— Бигрәк җагымлы икәнсең, кызым,— диде Байболат, елмайгандай итеп.— Улым менә иртәрәк өйләнеп ташлады шул, килендеккә алган булыр идем үзеңде!

Килгән-киткән казакъларның сөйләшүенә игътибар итеп, Мәрьям казакъчаны ярыйсы гына аңлый башлаган иде. Байболат картның сүзләрен ул бик яхшы төшенде. Шикәрдәй тешләрен күрсәтте дә, үзенең яшьлеген, матурлыгын аңлаудан туган бер канәгать елмаю белән елмаеп:

— Үзеңдең кимпереӊ[1] үлмәдеме соң?— дип куйды. Байболат карт, мондый шаяртуга бик тә кәефе килеп, шырк-шырк кеткелдәргә тотынды.

— Кимпер кимпер болады... Яшь хатын булып килерсең, балам!

— Дүрт кисәк чәй. Тагын нәрсә? Шикәр... кант? Кант эре шакмаклы гына. Каты. Тешең үтәрме, бабай?

— Шикәр имәс, тасты да омырып тастайтын чамам бар, балам!— диде карт, сер сынатасы килмичә.

— Күпме үлчим: бер кило, ярты кило?— диде Мәрьям, көлеп.

— Ой-бой, бик аздау болыр, балам. Көбрәк үлчә. Бис кило, алты кило... Атым таза, күтәрер.

— Кесәң ничек соң?— дигән булды Мәрьям.

— Кантка да җитәрлек, сиңа да җитәрлек, балам,— диде Байболат карт, кеткелдәп.

— Ул кадәр күп ярамый бит, бабай,— диде Мәрьям, җитди итеп.— Ат күтәрә дип, син бер капчык та сорарсың!

— Мин алыстан килгән, балам. Көн саен чәй-кант дип йөреп болмайды,— диде карт, куеныннан бәләкәй капчык чыгарып.

---

[1] Кимпер — карчык.

— Ярый инде, сиңа гына үлчим, булмаса...— диде Мәрьям, килешеп, һәм, тиз генә биш кило шикәр үлчәп бәләкәй капчыкка тутырды да, капчыкның авызын бәйләп куйды.

— Менә рәхмәт, кызым!— диде Байболат карт, чын күңелдән куанып.

Өенә ул бик канәгать булып, бик кәефләнеп кайтып китте.

«Нинди чибәр! Нинди сылу!» — дип уйлады ул, әледән-әле Мәрьямнең ягымлы, көләч кыяфәтен күз алдына китереп.

Аның Гөлбибие дә матур матурын, ихтимал, бөтен Көктугайда беренче матурдыр. Әмма шулай да ул икенче төрле шул. Үз балаң. Ә моның белән, ай-һай, кем генә тиңләшә алыр икән! Ул күзләр! Ул кашлар! Ул иреннәр! Ул тешләр! Ой-бой! Син картлачны түгел, әллә кемеңне җилкендерер ул шайтан кызы!

## VI

...Кайчандыр бик күптән казакъ далаларына бәхет эзләп, Ырымбур якларыннан Зәйнолла дигән шәкерт килеп чыккан. Үзе ярлы булган, ләкин бик чибәр булган. Кыш көне мәдрәсәдә укуын дәвам итү өчен, монда беркадәр акча эшләп китәргә уйлаган. Шул ният белән Зәйнолла Бәйсембек байның балаларына сабак укытырга ялланган. Җәй көне укыткан да көзгә тагын үз якларына кайтып киткән. Икенче җәйне бу тагын килгән, тагын шунда ялланган. Бәйсембекнең өч хатыны булган, өч хатынның унбишләп баласы булган. Зәйнолла шәкертне балалар һәр килүендә шатланып каршы алганнар. Бәйсембекнең кече хатыны Айсолу Зәйнолланы балаларга караганда да куаныбрак каршылаган. Айсолу бик яшь булган, таза булган, үзенең иреннән егерме биш яшькә яшьрәк булган. Шулай итеп, яшь егет белән яшь хатын бер-берсенә гашыйк та булганнар.

Көз җиткәч, кар төшкәч, нугай егете, очар кошлар сыман, янә дә үз якларына юл тоткан. Айсолу ул киткәч айлар буе боегып, моңаеп йөргән. Зәйнолла шәкерт өченче елны да Иртыш буйларына килеп чыккан. Килүен килгән, ләкин бу килүендә аның юлы уңмаган. Көктугайда аны мөгаллимлеккә алырга теләмәгәннәр. Бәйсембек карт үлгән булган, яшь хатыны Айсолуны исә, йола буенча, картның энесе Сәрсенбайга көчләп хатынлыкка биргән булганнар. Бәйсембек үләр алдыннан Айсолу бер матур кыз бала тапкан. Озын телләр аны нугай затына,

нугайның[1] да Ырымбур якларыннан килеп йөрүчеләр затына охшаган, дип сөйләгәннәр. Ләкин Сәрсенбай, агасының исеменә тап төшерәсе килмичә, бу турыдагы имеш-мимешләрне бик тиз туктаткан. Зәйнолла шәкерт яңадан да Көктугайга килеп чыккач, ул аңа бер көн тормый бу тирәдән китәргә һәм беркайчан да бу якларга аяк басмаска дип әйттергән.

Айсолудан туган ул кыз бала Гөлбибинең мәрхүм әбисе булган.

Ата-баба турындагы бу риваятьләрне исенә төшергәч, Байболат картның уй җепләре үзеннән-үзе шул Айсолулар, Зәйноллалар заты Гөлбибигә барып тоташты. Аның кинәт үз кызын күрәсе килеп китте. «Минем Гөлбиби дә чибәр, бик чибәр!»— дип уйлады ул, горурланып.

Әйе, Гөлбиби дә чибәр... Төсе-бите белән ул үзенең мәрхүм әнисе Гөлҗанны хәтерләтә. Үлгәненә инде ун елдан артып китте, ә Гөлбиби шикелле яшь-яшь булган вакытларына инде, күрәсең, өч-дүрт уннар узып киткәндер. Эх, заманалар! Гөлҗан да бар иде, бөтен тирә-якка данлы гүзәл Гөлҗан да бар иде...

Үз кызын күрергә ул чын-чынлап ашкынып кайтты. Кайтып керсә, Гөлбиби өйдә юк иде. Картка ифрат дәрәҗәдә авыр, күңелсез булып китте.

— Кая китте?— диде ул хатынына.

— Камыскүлгә, Сәлим янына,— диде хатыны. Гадәттә булганча, үги кызын Җәмилә бик үк яратып җиткерми иде. Байболат моны бик яхшы белә иде. Аның ачуы килде.

— Нәрсә калган аңа анда?— диде ул, кырыс кына, шулай да яшь хатыны белән даулашырга базмыйча.

— Монда аңа нәрсә калган?— диде Җәмилә.— Көтү көтәсе килми, сыер савасы килми. Өйдә тик ятсынмыни? Үзем җибәрдем, бар, күңел ачып кайт, дидем, Сәлимнәрнең дә хәлен белерсең, дидем.

— Аларның хәлен белүнең кирәге юк!— диде Байболат, тупас кына.

Шулай диде дә, бүтән бер сүз әйтмичә, тышка малтуар арасына чыгып китте.

«Дөмегеп бетмиләрме тагын!»— диде ул үз-үзенә, әлерәк кенә юк-бар нәрсә турында хыялланып кайтуына һәм кинәт кенә өметенең юкка чыгуына кәефе кырылып. Аннары күңеленнән ул үз-үзен сүгеп ташлады: карт алаша, кызларга күзе төшкән, дивана, диде; нугай кыз-

---

[1] Нугай — казакъча «нугай» сүзе «татар» дигәнне белдерә.

лары турында уйлау түгел, тәмуг турында уйларга кирәк сиңа, диде. «Кайтыр әле, әллә кая китмәс!»— диде ул, төкеренеп.

Ләкин Гөлбиби кайтмады. Икенче көнне дә, өченче көнне дә кайтмады.

— Сәлим янында аңа күңеллерәктер,— диде Җәмилә, аның кайтмавын үзенчә аңлатып.

Ата кеше тынычсызлана башлады. Шулай итеп, бер атна чамасы вакыт үтте. Ахырда Байболат карт түзә алмады, атына атланды да Камыскүлгә китте.

Гөлбиби югалып торган бу бер атна чамасы вакыт эчендә исә кайбер әһәмиятле вакыйгалар булып алды.

## VII

Соңгы көннәрдә «Татарстан» совхозының икенче бригада басулары өстеннән бер-бер артлы җылы яңгырлар явып үтте. Яңгырдан соң исә көнне кинәт җылытып җибәрде, һаваның үзгәрүе Барыйның икенче бригадага килеп эшли башлавының беренче көннәренә туры килде. Кайберәүләр моңа бик тиз игътибар иттеләр. Көннәрнең җылынуы бары тик яңа бригадирга гына бәйле булырга тиешлеген сиздереп, гомумән, элекке солдат кешенең ничек тә күңелен табарга, мөмкин булса,— хәтта күңелен яуларга тырышып, кызлар аңа турыдан-туры әйттеләр, и, Барый абый, диделәр, күптән безнең бригадага киләсегез калган икән — сез юкта никадәр туңып азапландык, диделәр; әллә үзегез белән кояшны да ияртеп алып килдегез инде,— күрдегезме, нинди елмаеп карый, диделәр. Шаян сүзләргә ул шаян сүзләр белән җавап бирде, кызларның чибәрлекләре турында мактау сүзләре әйткәләп куйды, бераз ияләшә төшкәч исә, үзенең баш кеше икәнлеген онытып, хәтта берәр чаярагын кочаклап та алды.

Егетләр белән дә ул үзен бик иркен тотты, дусларча, иптәшләрчә тотты, һәм әлегә беркем белән дә бозылышу дәрәҗәсенә барып җитмәде.

Ни генә булмасын, бригадада эшләр җайлы гына барды. Шуның өстәвенә көтмәгәндә станциядән яңа чәчкечләр кайтты — чәчүгә шундук икенче агрегат көйләп җибәрделәр. Шул ук вакытта сөрү дә тукталып тормады. Сөрә-сөрә тракторлар юлның икенче ягына чыктылар, бераздан бригаданың көньяк чигенәчә барып җиттеләр. Сөрүчеләр артыннан кызулап чәчүчеләр барды, чәчүчеләр артыннан исә вагоннар, чатырлар кузгалды — бригада «авылы» икенче урынга күченде.

Шулай итеп, дала һаман артка чигенде. Вак-вак буразналар, киңәеп, бергә кушыла тордылар, дулкын-дулкын булып як-якка җәелә тордылар. Дала үзгәрде, көннән-көн үзгәрде, күзгә күренеп үзгәрде. Чынында инде ул дала түгел, озакламый яшел хәтфә белән капланачак иксез-чиксез иген кыры иде.

Күбрәк вакытын Барый чәчүчеләр янында уздырды. Шуңа күрә дә сөрүчеләрне ничектер онытып җибәргәндәй булды, онытып ук җибәрмәсә дә, аларга карата игътибары кими төште.

Беркөнне ул, шушы арада гына сатып алынган мотоциклына атланып, ерак басуда сөрүче тракторчылар янына барып чыкты.

Еракта, буразна уртасында ул бер туктап, бер кузгалып азапланган трактор күрде. Трактор йә авыр җиргә юлыккан булырга тиеш иде, яисә анда аңа бер-бер хәл булган булырга тиеш иде. Тиз арада ул әлеге трактор янына барып та җитте. Кабинадан яланөс, яланбаш Белугин килеп чыкты.

— Ни булды?— диде Барый, аның сүз башлавын да көтмичә.

— Туктый. Бармый, бригадир,— диде Белугин.— Ике мәртәбә сүнде. Нидер булган, бригадир.

Аның тавышы чак-чак кына калтыранып чыкты, йөзендәге кызыллыгы куера төште һәм үзенең ни өчендер гаепле икәнлеген сизгәнгә күрә, бригадирның сынаучан, усал күз карашыннан уңайсызланып, ул тонык-зәңгәр күзләрен шундук читкә борды.

Бригадир берни әйтмәде, сабан янына барып буразнаның тирәнлегенә күз төшерде — буразнаның тирәнлеге таман гына иде, шулай ук җир өсте дә бу төштә тигез, туфрак та йомшак иде. Шуннан соң ул яңадан трактор янына килде һәм, аның «чире» нидән гыйбарәт икәнлеген белмәкче булган кебек, тирә-яктан аны җентекләп карап чыкты. Аның тәҗрибәле күзе ялгышмады — тракторның «авыруы» йөзенә бәреп чыккан иде.

Мондый тракторны ул әйтерсең беренче кат күрде. Трактор, әле яңа гына эшли башлавына да карамастан, бер атна-ун көн эчендә!— инде тузарга да, картаерга да өлгергән иде. Ул ифрат дәрәҗәдә пычрак, шапшак иде.

Техник карау вакытында Белугин беркайчан да бригадирдан ярдәм-киңәш сорамады. Алмашчысы белән бергәләп ул бөтен эшне үзе башкарды. Эше беткәч тә, ул тизрәк кабинага менеп утырды да беренче булып кузгалып та китте. Еш кына ул мактанып, белдекләләнеп: «Техниканың барлык көчен сыгып ала белергә кирәк!»—

дип сөйләнде. Шуңа күрә ул мөмкин кадәр күбрәк бу-разнада булырга тырышты.

Мондый ашыгучанлык анда бигрәк тә Таран белән Ислам арасындагы соңгы бозылышудан соң, ягъни кызыл тактада кинәт кенә түбән тәгәрәгәннән соң, үзен бик нык сиздерә башлады. Кырык сигез гектар мәсьәләсендә гайбәткә урын калдырмас өчен, үзенең электән үк нормасын гел арттырып үтәгәнлеген аклау һәм яңадан да алдынгылар сафына басу өчен, ул алдын-артын карамый тырышырга мәҗбүр булды. Бу турыда аңа Ислам әйтте, шулай итсәк, безгә беркем пычрак яга алмаячак, диде. Белугин чыннан да соңгы көннәрдә ярый-сы гына алга китте.

Аның шулай яхшы эшләвенә Барый чын күңелдән сөенгән иде. Ләкин шул ук вакытта ул аны үзенең астыр-тын дошманы дип тә исәпли иде. Шунлыктан ул әле һич тә аңа карата күңеленнән ныклап торып эреп китә алмый иде. Күрәсең, менә шушы сәбәпләр аркасында, ул моңар-чы аның тракторыннан ничектер читтәрәк йөргән иде.

Баксаң, менә ничек тырыша икән ул!

## VIII

Мондый шапшак, мескен тракторнымы, әллә аның бичара хуҗасынмы кызганырга белмичә, бригадир ап-тырап сызгырып җибәрде. Аның болай үчекләшкән ши-келле сызгырынып торуы Белугинга һич тә ошамады. Ул тагын да ныграк үртәлә, тынычсызлана башлады, тик шулай да, әдәп сакларга мәҗбүр булып, беренче сүзне бригадирдан көтте.

— Чүпрәгең бармы соң синең?— диде Барый, Белу-гинга борылып.

Бу сорауны ул гади генә итеп, тартырга бармы? яисә, акчаң бармы? дип сорагандагы шикеллерәк кенә итеп бирде, әмма бу гадилектә Белугинга шелтә авазы яңгы-рап китте.

— Чүпрәк?— диде ул, мәсьәләгә тиз генә төшенеп җитмичә.

— Чүпрәк шул, чүпрәк!— диде Барый, кычкырып.— Ничек оялмый утырып йөрисең син монда? Трактор түгел бу, эт белсен, әллә нәрсә шунда! Юри тузанга, пычракка аунатканнар диярсең. Менә ул идән себерә белмәүнең бәласе!

Бригадир авызыннан чыккан һәрбер сүзне йотып алырга әзер булып, Белугин берни эндәшмичә карап то-руында булды.

— Тракторың шапшак малай-шалай төсле,— диде Барый.— Пычранып, авызы-борыны җимерелеп беткән. Менә шуңа күрә туктаган. Син аңа утырып йөрергә оялмасаң да, ул сине тартып йөрергә оялган. Булдымы?

Белугин, әлбәттә, аннан берәр төпле сүз,төпле киңәш көтте, ярдәм көтте. Ләкин бригадирның ныклап торып карамыйча-тикшермичә мәсьәләне шулай җиңел генә аңлатырга тырышуы аның ачуын китереп куйды.

— Шаяртмавыгызны үтенәм, иптәш бригадир!— диде ул, чәйнәлгән папиросын җиргә төкереп.— Мин эш кешесе. Минем сездән ярдәм сорарга хакым бардыр бит?

— Нинди шаярту ул!— диде Барый, кырыс кына.— Яле, эшкә тотын тизрәк... алай эш кешесе булгач... Хәзер үк кулыңа чүпрәк ал: сөрт, чистарт, ялт итеп торсын! Мондый трактор янына мин якын килергә дә җирәнәм. Аңлашылдымы?

— Бик үк аңлашылып җитмәде шул,— диде Белугин.

— Аңлашылмаса, тагын шул,— диде бригадир.— Ягулыкка тузан керү аркасында, радиатор пычрану аркасында... балдаклар, шатуннар тузган; блок кызган, двигательнең көче кимегән. Кара әнә, тракторыңның янына барырлык та түгел, утлы мич кебек.

— Аңлашылды!— диде кинәт Белугин.

— Шуңа күрә,— дип дәвам итте бригадир,— балдакларны, шатуннарны карарга; фильтрларны, ягулык багын...

— Аңлашылды, аңлашылды!— дип кычкырды Белугин.

Ул, урыннан кубып, тракторына ташланды, кабина ишегенә кыстырып куйган сырмасын тартып алды да, ласт, иттереп, аны җиргә атып бәрде һәм, ашыгып-кабаланып, күзенә ак-кара күренмичә, авыр күн итекләре белән сырма итәгенә баскан килеш, өр-яңа җиңне шытырдатып умырып та чыгарды. Шуннан соң ул җилләнеп, тузан туздырып, сырма җиңе белән тракторын сөртергә тотынды.

Бөтенләй диярлек киелмәгән сырманы аның шулай әрәм итүенә Барыйның эче пошып куйды, шулай да ул хуҗа кешегә шелтә ясаудан тыелып калды. Эш инде шелтә ясаудан узган иде.

Тракторны, һичшиксез, бригада «авылына» алып кайтырга туры киләчәк әле, алып кайткач исә сүтеп ташларга кирәк булачак иде. Никадәр тырышсаң да, бүген кичке сменага аны өлгертеп булмаячак иде. Әле иртәгә өлгерәме, юкмы! Кыскасы, трактор кимендә бер смена эшләмәячәк, кимендә бер биш-алты гектар җир сөрелми

калачак. Ә бу вакытта биш-алты гектар җир бәләкәй нәрсә түгел.

— Ярар, туздырма тузан!— диде ул кинәт Белугинга.— Кайткач чистартырсың. Сабаныңны ычкындыр да хәзер үк бригадага элдерт. Сүт, кара, тикшер... Озакламый артыңнан кайтып җитәрмен.

Шулай диде дә, мотоциклына атланып, кызулап китеп тә барды. «Кем белә, бәлки, бүтәннәр дә шулай тузанга батып яталардыр»,— дип уйлады ул, ачынып, сыкранып.

...Барый төн урталарына кадәр Белугин тракторы белән азапланды. Чистартасы җирен чистарткач, алыштырасы җирен алыштыргач, мотор бөтенләй икенче тавыш белән, шат, көр тавыш белән эшли башлады. Бригадир, тракторны басуга озатты да, эттәй арып-алҗып, әмма үз-үзеннән бик тә канәгать булып, вагонга кереп китте. Ул рәтләп чишенеп тә тормады, кергәч тә шул көе сәкегә ауды — соңгы көннәрдә аңа йокы бик аз эләгә иде.

Иртән аны көчкә уяттылар. Үзенең шулай вакытында тора алмавына ул шаккатты. Торып тышка чыккач, бригада хәлләре белән танышкач, аңа тагын да ныграк гаҗәпләнергә, тагын да ныграк шаккатырга туры килде.

Ул басудан кайткан тракторлар янына килеп җитәргә дә өлгермәде, егетләр аны яңа хәбәр белән «куандырдылар». «С-80» тракторы туктады, диделәр, төне буе тик торды, ни булгандыр, хәзергә әле берни белмибез, диделәр. Барыйның эче жу итеп китте.

Озакламый җәяүләп басудан Илгиз кайтып килде.

Соңгы җыелыштан соң ул Андронов урынында эшли башлаган иде, Андронов исә аның тракторына күчкән иде. «С-80» тракторында Илгизнең әле икенчеме-өченчеме смена гына эшләве иде. Бригадада ул урта кул тракторчылардан исәпләнелә, һәм шуңа күрә Исламның аны үзе белән бергә эшләргә алуы, шулай ук бригадирның моңа риза булуы кайберәүләргә бик үк аңлашылып та җитмәгән иде. Хәер, бригадир әле кешеләрне белеп тә җиткерми иде. Ләкин Ислам турында: кемнең ничек эшләгәнлеген белми дип әйтеп булмый иде. «С-80» тракторы, ни әйтсәң дә, «ДТ»га караганда катлаулырак та, дәрәҗәлерәк тә иде, һәм, язылмаган бер кагыйдә буенча, гадәттә анда тәҗрибәлерәк, көчлерәк һәм тешлерәк кешеләр эшли иде.

Тракторның Илгиз сменасында кырылуын белгәч, күпчелек моңа әллә ни гаҗәпләнмәде. Бу ничектер үзеннән-үзе шулай булырга тиеш шикелле тоелды.

— Ни булды? Кай җире ватылды?— диделәр аңа, курку белән.

Илгизнең беркем белән сөйләшәсе килмәде. Аның, гомумән, сөйләшер рәте калмаган иде. Берничә сәгать эчендә ул танымаслык булып үзгәргән иде. Аның мәетнеке төсле агарынган йөзенә, каралай көйгән иреннәренә һәм нурсызланып, мескенләнеп калган күзләренә карап кына да хәлләрнең бик үк шәптән түгеллеген аңларга була иде. Ләкин бүтән вакытта шундый усал, чая булган, хәтта явыз булган кешенең кисәк кенә бөгелеп төшүе, шулкадәр кайгы-хәсрәткә бирелүе, әлбәттә, сәеррәк иде.

Трактор ватылу шикелле нәрсә болай сер булып исәпләнелмәсә дә, нәрсә булганлыгын Илгиз бары бригадирга гына сөйләде. Бу исә кызыксынуны тагын да арттыра төште. «Сер» чыннан да бик хикмәтле булып чыкты: тракторның уң як табаны — гусеницасы ычкынган иде.

Тракторның, гадәттә, тиз таушала, туза торган берәр нечкә детале бозылып эштән чыга, яисә, Белугин тракторындагы сыман, ягулыкка тузан үтеп керә, мотор кыза, яисә, бөкеләр ныгытып борылмау аркасында, май ага, яисә... беткәнмени шуның ише нәрсәләр! Май агулар, радиатор тишелүләр, клапан янулар, подшипник кырылулар һәм һәртөрле шундый көтелмәгән хәлләр бер булмаса бер булып куя, үз тракторыңда булмаса— кешенекендә, үз бригадаңда булмаса — бүтән бригадада булгалап тора. Мондый кырылу-ватылулар тракторчы өчен әллә ни искитәрлек нәрсә түгел.

Әмма гусеница ычкыну!.. Дөнья булгач, әнә андый хәлләр дә булгалый икән.

## IX

Трактор, бара торган җиреннән уңга каерылып, буразнага аркылы туктап калган иде. Бөтен авыр гәүдәсе белән ул уң якка кыйшаеп, янтаеп тора иде, сыгылмалы авыр чылбыр каерылган һәм бушап, салынып төшкән иде. Шундый зур, куәтле машина хәзер бик көчсез булып, зәгыйфь һәм кызганыч булып күренә иде.

Барый мотоциклдан төште дә якынрак килде һәм, кулларын бөеренә таянган килеш, ике-өч адым читтәрәк туктап калды. Ватылган, көйсезләнгән машиналарны аның шулай иң элек читтән, тышкы яктан күзәтә торган бер гадәте бар иде.

Илгиз дә аның янына килеп басты һәм, мондый хәлне беренче мәртәбә күргән шикелле, кыйшайган тракторга карап тора башлады.

Барый үз фикерен әйтергә ашыкмады. Бу инде Белугин тракторы гына түгел иде, хикмәт монда пычрануда-

нидә генә түгел. Шапшаклык, пычраклык монда бөтенләй юк. Хикмәт монда катлаулырак. Белугинга кычкырган кебек монда, шулай ит, болай ит, дип кенә котылып булмаячак. Монда чын-чынлап җиң сызганып эшләргә, тир түгәргә туры киләчәк.

«Диагноз» мәсьәләсендә ул артык баш ватып тормады, беренче караштан ук бөтенесен аңлап алды. Сырлы, киң буыннардан җыелган авыр чылбырны — гусеницаны хәрәкәткә китерүче арткы тәгәрмәч, яисә, техник термин белән әйткәндә, ияртүче йолдызча, үз урыныннан ычкынып, читкәрәк күченгән булырга тиеш. Ләкин йолдызча ни өчен үз урыныннан ычкынган, ни өчен читкәрәк күченгән? Нәрсәсе ычкынган, нәрсәсе бушаган? Шулай ук бу да аның өчен әллә ни катлаулы табышмак түгел иде. Монда роликлы подшипник бушаган булырга тиеш. Ә роликлы подшипник... Кыскасы, көйләү гайкасы сүтелгән.

Әйе, моны аңлавы авыр түгел. Теория буенча бу шулай булырга тиеш. Башкача булуы мөмкин түгел. Ләкин гайка нилектән сүтелгән? Үзлегеннән сүтелгәнме, әллә берәрсе сүтеп куйганмы, ягъни сүтеп караганнан соң тиешенчә борып җиткермәгән булганмы? Анда, капкач эчендә, ниләр кырылган, ниләр исән калган? Төзәтерлекме, рәтләрлекме, әллә соң барлык нәрсә ватылып-кырылып он булганмы?

Барый, трактор янына якын килергә батырчылык итмәгәндәй, шактый вакыт бер урында басып торды. Ниһаять, урыныннан кузгалып куйды, Илгиздән кирәкле ачкычлар сорап алды да эшкә дә кereште. Йолдызча капкачын ачып карагач, аның коты алынды: конуссыман роликлы ике подшипник һәм олы шестерня бернәрсәгә яраксыз хәлгә килгән иде.

Әйтәсе дә түгел, бик яман, бик хәтәр авария иде бу!

Барый, бернәрсәгә кагылмыйча, капкачны кире ябып, гайкаларны борып куйды. Билен турайтты да, кузгалып китә алмыйча, тагын бер үк ноктага карап тора башлады.

— Смена алышыныр алдыннанмы, элегрәкме стопор гайкасын бормадыгызмы?— диде ул Илгизгә.

— Юк, белмим,— диде Илгиз.— Мин эшли башлаганнан бирле без бернәрсәне дә ачып карамадык.

— Бәлки, Ислам ачкандыр? Сиңа кадәр? Сөйләнмәдеме?— диде бригадир, төпченеп.

— Белмим,— диде тагын Илгиз.

— Гаҗәп, ничек сүтелде икән соң ул?— диде Барый үзалдына.

Шуннан башка ул бүтән бер сүз дә әйтмәде. Алар мотоциклга утырдылар да бригадага кайтып киттеләр.

## X

Илгиз белән Барый бригада «авылына» кайтып төшкәндә, смена алышыну инде беткән иде, тракторлар далага китеп барганнар иде.

Пычранган кулларын ашык-пошык кына юыштырып, алар икесе дә өстәл янына килеп утырдылар. Фәридә, җитез генә кыланып, калай коштабакларга җылы аш бүлеп китерде. Бригадирның да, Илгизнең дә йөзләре кырыс, сүзләре, хәрәкәтләре авыр, салмак иде. Аларның ни өчен шулай кәефсез икәнлекләрен Фәридә, әлбәттә, бик яхшы белде, һәм шуңа күрә ул берни сораштырып тормады, казаны янына килде дә бүленгән эшенә тотынды.

Бераз тамак ялгап алгандай иткәч, Барый авыр башын күтәрде, Фәридәнең әледән-әле казан өстенә иелгән сылу, җитез гәүдәсеннән, сызганылган юеш кулларыннан күзен алмыйча, беравык карап торды һәм күңеле белән бөтенләй икенче нәрсә турында уйланып:

— Ислам күренмәдеме?— дип сорады.

— Нәрсә, нәрсә?— диде Фәридә.

Барый соравын тагын кабатлады. Фәридә аңлап алды да кызарынып китте һәм, уңайсызлануын яшерү өчен, кулын маңгай турысына күтәреп, чәчен сыпырып куйган булды.

— Ул сезнең янга китте,— диде ул, көттеребрәк.— Атка атланды да сезнең янга китте. Турыдан гына...

Барый, үзенең соравын да онытткан, кызның җавабын да ишетмәгән шикелле, каядыр үзалдына караган килеш, әкрен генә ашавында булды.

— Тотарсың инде аның койрыгын!— диде Илгиз. Бераздан бригадир янә сорап куйды:

— Димка өйдә микән?— диде.

— Димка басуга китте,— диде Фәридә.

— Хәле ничек икән? Рәтләнмәгәнме?— диде бригадир.

— Белмим. Юктыр. Кәефсез күренде,— диде Фәридә, һәм шуннан соң тагын өчесе дә тынып калдылар.

Кичәгенәк кич Димка басудан күңелсезләнеп кайтты. Кайткач берни ашамады, эчмәде, баш авырта, эч авырта, диде һәм минут саен дала ягына — ак киндер белән корамалап куелган куыш ягына йөгерде. Көндәлек язусызу эшен ул бик авырлык белән башкарды һәм эше беткәч шундук урынга ятты. Ул үзенә нәрсә булганлыгын ачык кына аңлый да алмады. Аңа кайдадыр салкын да тигән кебек булып, әллә тозлы балык ашагач, әллә шунда консерва ашагач кинәт кенә эче авырта башлаган шикелле дә булды. Башта ул моңа бөтенләй игътибар итмәде, бетәр

әле, диде. Кичәгенәк йокларга ятканда ул тәмам айнып, хәлләнеп киту нияте белән яткан иде, ләкин бүген иртән ул үзен әз генә дә хәлләнгән итеп сизмәде, киресенчә, аңа ул тагын да ныграк начарланган шикелле тоелды. Шулай да ул шыңшымаска тырышты һәм теләр-теләмәс кенә ашагач, теләр-теләмәс кенә басуга китте.

«Монда складта булмас»,— дип уйлады Барый, Димка турында онытып.

Әллә бар микән соң? Юк, булмас. Районга китәргә туры килер. Ярый ла анда булса. Булмаса, калага... Ә бригада? Үзең китсәң, әллә нәрсәләр эшләп ятарлар болар... астын өскә әйләндерерләр. Менә башланды! Башланды... Димка тагын ныклап чирләп китсә... аяктан егылса... Бер килсә килә бит ул шулай. Бер килмәгәндә генә берни сизелми — үзеннән-үзе эшләнелә, рәхәт, җиңел... Нишләп сүтелде икән ул? Үзлегеннәнме? Алай да булырга мөмкин. Бик мөмкин. Завод гаебедер.

— Барый абый,— диде Фәридә, аны уйларыннан бүлдереп.— Галимулла абзый чирләп киткән бит әле. Барый җәһәт кенә башын күтәрде.

— Кайчан? Ни булган?— диде ул.

— Эч авырта, хәл юк, ди. Әнә теге утыннарны яргалап ташларга кирәк, дигәнием дә, хәзергә булмый әле, сеңелем, ди, бераз ятып алыйм, ди. Хәзер менә су алып кайтырга кирәк коедан. Ә мин ул үгезләрнең янына барырга да куркам.

«Башланды! Менә ул кайчан башланды!»— дип уйлады яшь бригадир һәм алдына килгән чәйне тиз-тиз генә эчте дә ашыгып урыныннан торды.

## XI

Галимуллаларның ике кешелек яшел чатырлары бригада «авылыннан» бер читтәрәк утыра иде. Тәбәнәк чатыр эче кысан иде, бөркү иде. Галимулла чишенеп урынга яткан, Фәрханә апа, капкачы ачылган кечкенә чемоданы алдына чүгәләгән көе, иске-москылар арасыннан нәрсәдер эзләп азаплана иде. Ишек хезмәтен үти торган киндер кисәге ачылып китүгә, ул ашыкмыйча гына башын күтәреп карады һәм кем кергәнен күреп алды да урыныннан кузгалгандай итеп куйды.

— Галимулла абзыйга ни булган?— диде Барый, исәнлек-саулык сорашкач.

Галимулла, күрәсең, йоклап китәргә өлгермәгән иде әле — бригадир тавышын ишетеп, ул күзләрен ачып җибәрде, башын калкытты да торып утырмакчы булды.

— Торма, торма,— диде Барый, аның янынарак узып.— Ни булды, кай җиреңавырта? Бик ныкмы?

— Бик үк нык түгел дә, хәл юк, Барый туган,— диде Галимулла, күңелсез генә.— Ашагач, чәй эчкәч рәтләнерменме дигәнием дә, юк... баш авырта, эч авырта — үтерә инде...

— Эч китү түгел монда, ачуым килмәгәе, агуланып бетәрсең әле шул кансирвалар белән!— диде Фәрханә апа, тузынып.— Ашарына бер рәтле нәрсәсе юк... Казакъстан, диләр, көтү-көтү мал-туар, диләр... Нинди Казакъстан бу?! Җылап эзләсәң бер кило ит табалмассың. Монда инде әйтәсе дә түгел, районында, базарында шул бит әле! Җитмәсә тагын, монысы анда булыр-булмас көенә көн-төн азапланып йөргән була, хәсрәт капчыгы. Эшләсен әнә яшьләр! Ачка койрык чәнчеп монда!.. Сиңа шул үгезләрне куалап йөрсәң дә җиткән, үләмәт.

— Их, Барый, искә төшердең!— диде кинәт Галимулла һәм тиз-тиз генә урыныннан торды да, эчен тотып, кабаланып тышка чыгып китте.

— Сугыш елында да мин мондый кытлык күрмәдем,— диде Фәрханә апа, зарланып.— Ирләр урынына заводта эшләдем, төнә-куна яткан чакларым да булды, иллә-мәгәр мондый кытлыкны күрмәдем. Әз булса да итен дә бирделәр, маен да бирделәр, бәрәңгесе дә булды. Дала да дала, диләр, оҗмах, диләр. Оҗмах булмый ни, оҗмах, тот капчыгыңны! Шайтан төкергән җир — менә ул нәрсә селина! Кем көчләп алып килгәндер, эшләгән җиреңдә эшләп тик ят икән. Болай булса, бөтен бригатың белән кырылып бетәрсең әле.

Әле һаман үз уйларыннан арына алмаган бригадир Фәрханә апаның сүзләренә бөтенләй диярлек колак салмады. Бу минутта ул, Галимулла чынлап торып аяктан егылса, аның урынына кемне куярга туры килер икән дип, нишләргә, ни кылырга кирәк булыр икән дип баш ватты. Бит әле монда Галимулла гына да түгел, монда әле Димка да бар! Икесенең дә эче китә, башы авырта, хәлләре юк — икесендә дә бер үк чир. Димка элегрәк чирләгән. Берьюлы ике кеше эштән чыкса, шуның өстәвенә тагын трактор... Ай-һай, артыграк түгел микән бу бер көнгә?

Бер биш-алты минуттан Галимулла кайтып керде.

— Эшләр хөрт, Барый туган,— диде ул, баягыдан да төшенкерәк тавыш белән.— Кан китә. Гомергә мондый нәрсә күргәнем юк. Әллә ялгыш сөяк-фәлән йотканмын инде... эчәге тишелгәндер... баш белән уйлап караганда...

— Сөяк йоткансыңдыр!— диде Фәрханә апа, тагын да ныграк үртәлеп.— Сыер итенең сөяге шулай тамакка кадалучан була ул. Иртән дә ит, кичтән дә ит... гел ит ашап монда!

— Беләсеңме, Галимулла абзый,— диде Барый,— әйдә, хәзер үк Көктугайга! Врачка күренми ярамас. Мотоциклда баралырсың ич?

— Бармый... барырмын инде...— диде Галимулла, шыңшыгандай итеп.— Теге малай да инде өченче көн эч авырта, дип йөри.

— Тикмәгә түгел бу, күренмичә ярамас,— диде Барый, пошынып.

— Ул гына түгел, үзең дә өч-дүрт көн инде,— диде. Фәрханә апа, тагын ирен ачуланырга тотынып.— Мин дә әйттем сиңа, бырачка күрен, дип. Бүлетин алырыең, ичмасам... Кеше кебек тынычлап чирләриең, күз көеге... Кырык төрле эшкә тотынмасаң...

Барый Галимуллага киенеп-әзерләнеп торырга кушты да тиз генә чыгып китте. Аның күңелен кинәт бер шомлы нәрсә биләп алды. Кыска гына вакытка ул кырылган трактор турында да, дала турында да, сөрү-чәчү планнары турында да оныткандай булды. «Әгәр бригадага берәр яман чир йоккан булса?!» — дип уйлады ул, коты алынып. Әгәр, чыннан да, ул консервалар — бүтән җирдә үтми яткан һәм шуңа күрә монда китереп тутырылган тәмсез балык консервалары бозык булып чыкса?! Бүген Галимулла чирләде, Димка чирләде, иртәгә Һарун чирләр, Вәгыйзь, Мансур чирләр... Өч-дүрт көн үтмәс «бөтен бригат» аяктан егылыр, «бөтен бригат» кырылып бетәр! Анда инде трактор кайгысы да, чәчү-сөрү кайгысы да калмас. Сорап-тикшереп тә тормаслар — алырлар да китәрләр! Ник вакытында чара күрмәдең, диярләр, кеше кырдырырга синең ни хакың бар, диярләр.

Аның бит ишеткәне бар ниндидер үләт, ваба чирләре турында. Берни белән дәвалый алмыйлар, ди... Кайчандыр алар авылында булган бит. Кешеләр чебен урынына кырылган, үлгәннәрне күмәргә кеше җитмәгән. Кайбер авылларда беркем калмаган, кырган да салган. Шулай ук эч киткән, хәл булмаган... Бәлки, аның үзенә дә эләккәндер ул яман чир... ваба чире... үләт...

Бәлки, ул бруцеллездыр? Дүртенче бригададан ике егет кайдадыр сөт эчеп кайтып аяктан егылдылар бит. Әле булса, больницада яталар. Аны да дәвалап булмый, ди, имеш.

Дала ят, дала мәкерле. Аяк атлаган саен монда нинди дә булса тозакка килеп эләгүең мөмкин.

Шулай уйланган саен, бригадирның куркуы арта төште. Аны хәзер бу шик-шөбһәдән беркем дә, берни дә арындыра алмас шикелле тоелды. Аңа бары белгеч кенә дөрес җавап бирә алачак иде, бары ул гына аның буталган уйларын тәртипкә китерә алачак иде.

Һәм күз ачып йомганчы ул мотоциклын кабызды да Галимуллалар чатыры каршысына килеп тә туктады.

Алар кузгалып киткәч кенә, каршыга Фәридә йөгереп килде.

— Нишләрбез икән, Барый абый?— диде ул, үпкәләгән сымаграк итеп.

— Нәрсә булды тагын?— диде Барый. Фәридә тагын аңа үзенең үгезләр янына барырга куркуы турында сөйләргә кереште.

— Ә!— диде Барый, аңлап.— Илгиз өйдәме? Юк, ул йоклыйдыр. Ял итсен. Ислам кайтыр. Аның бүген барыбер эше юк. Әйт: Галимулла урынына бүген ул кала. Булдымы?

— Булды, Барый абый...— диде Фәридә, тыелып кына.

## XII

Өстенә ап-ак халат, башына шулай ук өр-яңа ап-ак башлык киеп куйган, бөтен өсте-башы белән, бөтен кыяфәте белән тынычлыкның, сабырлыкның җанлы гәүдәләнеше булып тоелган Рәйханә апаны күргәч, Барыйның күңелендә нәрсәгәдер өмет һәм ышаныч шикелле бернәрсә уянды. «Юк, алай ук түгелдер әле, әнә ул нинди тыныч... Врач кеше шул дәрәҗәдә тыныч булганда, нинди яман чир таралмак кирәк!»— дип уйлады ул, үз-үзен юатып.

— Сезгә чыгып торырга була,— диде аңа Рәйханә апа.

Барый такта стеналарына аркылы-торкылы чыра кагылган кечкенә бүлмәгә чыкты да шундагы бер артсыз урындыкка утырды. Врач хатынның шулай тыныч кына, ашыкмыйча гына сөйләшүе, мондагы сәер тынлык, дару исе һәм күзгә ташланып торган һәртөрле медицина әйберләре аңа бары уңай яктан гына тәэсир итте. Ул бик тиз арада тынычланып өлгерде һәм, ябылып бетмичә калган ишектән күрше бүлмә ягына караштыргалап, сабыр гына көтә башлады.

Врач хатын авыруга сораулар бирде, аннары башын иеп озаклап нәрсәдер язды, тагын сораулар бирде, тагын язды. Галимулла, зур керле кулларын тез башына куйган килеш, кых-кых тамак кыргалап, аның шулай шыгырдатып зәңгәр кәгазьгә нидер язып беткәнен түземлек белән генә көтеп утырды.

— Ни... нәрсә соң инде бу... нинди авыру була?— дип куйды ул бераздан.

— Ныгытып тикшерергә кирәк. Дизентерия булуы мөмкин,— диде Рәйханә апа, башын калкытмыйча гына.

Чирләр-авырулар мәсьәләсендә Барыйның әллә ни мәгълүматы юк иде. Ак халатлы хатын авызыннан «дизентерия» сүзен ишеткәч, шундук аның күңеле күтәрелеп китте. Димәк, бернинди агулану юк, бернинди ваба, үләт юк! Ә дизентерия... Нәрсә ул дизентерия?! Яшь балаларда була торган эч китү түгелме соң? Шулай бугай. Күрәсең, кайчакта олыларда да була торгандыр. Менә курыкканга куш күренә дигәндәй... шуның өчен уткасуга төшеп, мәшәкатьләнеп тә йөрисе калмаган. Бер йөз грамм салды исә, барлык эч китүләрен юар да төшерер иде.

Ул урыныннан торды да, шакып-нитеп тормыйча, иплән кенә ишекне ачты һәм, Рәйханә апаның язып бетергәнен дә көтмәстән:

— Ярый, алайса, Галимулла абзый, мин киттем,— диде.— Мин конторада булырмын. Шунда бар. Миннән башка кайтып китә күрмә.

Рәйханә апа, җитди, тыныч йөзенә бераз гына катгыйлык төсе чыгарып:

— Авыру беркая китмәячәк,— диде.

— Ничек ул алай?— диде Барый, гаҗәпкә калып.

— Шулай,— диде ак халатлы хатын,— районга анализга җибәрергә туры киләчәк.

— Районга-а?! Ә сезне монда ни өчен утыртып куйганнар?

— Карагыз әле, ябыгыз әле ишекне!— диде кинәт Рәйханә апа, каты гына итеп.

— Бер кешене биш итәргә торган вакытта... Сезнең хакыгыз юк!— диде Барый, үзе дә сизмәстән кызып китеп.

— Мин сездән хак сорамыйм,— диде врач хатын.— Мин сезнең эшегезгә кысылмыйм, шулай булгач, минем эшкә дә кысылмаска киңәш итәм.

— Мин аны монда калдырмыйм!— диде бригадир кеше, нык итеп.

Бер кызудан ул тагын әллә нәрсәләр әйтеп ташлады: бригада кешеләре өчен мин җавап бирәм, диде, бөтен бригада Галимулла абзыйга карап тора, аннан башка бригада кулсыз-аяксыз калачак, диде. Мондый сүзләрнең бик үк ышандыргыч түгел икәнлеген ул үзе дә аңлагандай булды, ләкин ачыну, пошыну һәм аптырау тойгысы шундый көчле иде — хәтта ышандыргысыз сүзләр дә аңа хәзер дөрес булып тоелды.

— Дизентерия — бик яман чир, йогышлы чир,— диде Рәйханә апа, йомшаргандай итеп.— Бөтен совхозда бу беренче авыру. Мин хәзер үк районга шалтыратачакмын, моны болай гына калдырырга ярамый.

Аның соңгы сүзләре Барыйга янау булып, үз өстеннән районгагы кемнәргәдер әйтергә-җиткерергә теләү шикеллерәк булып яңгырады.

— Шалтыратыгыз! Миңа димәгәе!— диде ул, дорфа гына һәм дулап-тузынып чыгып та китте.

Иң куәтле тракторың кырылып ятсын, сөрелмәгән, чәчелмәгән ун мең гектар, йөз мең гектар җирең булсын — тузынасың килмәсә дә тузынырсың! Тузыну түгел, акылыңнан язарсың монда!

Запчастьлар складының ачык икәнлеген күреп, юл уңаенда ул шунда сугылып узмакчы булды. Складта аңа кирәкле подшипниклар да, шестерня да юк иде. Моның шулай буласын алдан ук белгән булса да, аның тагын да ныграк кәефе кырылды.

Дизентерия, имеш! Ак халатлар киеп кенә... рәхәт аларга. Тузан юк, ни юк, чиста, тыныч. Вакытында ашыйлар, вакытында йоклыйлар, ике кулларына бер эш. Аларга синең кайгың ни дә, сөрүең, чәчүең ни!

Менә ничек килеп тыгылды барысы да! Тракторын кузгатып җибәреп булса, Галимулла ничек тә рәтләнер иде әле. Аңа подшипник та кирәкми, шестерня да... кештер-мештер тик йөри. Менә аларын каян табарга?

«Мәрьям дә ак халат киеп эшли!»— дип уйлады ул кинәт, үзенең ак халатлар турындагы фикеренә үзе үк каршы төшеп. Бәлки, ул да кайберәүләргә шулай булып күренәдер... эшлексез булып, кыланчык булып... Юк, ул алай күренмәс. Аның эшчән, булдыклы икәнлеге йөзенә чыккан. Шулай да әйбәт булмады әле бу талашып чыгып китү. Бала-чагачарак килеп чыкты. Туктале, йогышлы диде түгелме соң ул? Әйе, дизентерия йогышлы бугай шул. Башта бит Димка чирләгән, аннары Галимулла. Алар гел бергәрәк булалар. Димәк, чыннан да, йоккан булырга тиеш. Әгәр бөтен бригадага йокса?

Ул әле склад яныннан кузгалып китмәгән иде. Күп уйлап тормыйча, ул кире больница ягына борылды. Ак халатлы хатын аңа хәзер баягыча шәфкатьсез булып, эшлексез булып тоелмады, киресенчә, ул аңа хәзер арыган, йончылган кыяфәттә күренде.

— Беләсезме нәрсә...— диде ул, Рәйханә апаның күзләре белән очрашмаска тырышып,— әле генә мин бер ахмаклык эшләп ташладым.

Рәйханә апаның күз карашында чак-чак кына гаҗәп-

сенү чаткысы күренеп китте. Барый исә, сүзне чамадан тыш турыдан башлавын шәйләп, кинәт тотлыгып калды — шул яшенә җитеп ул әле булса ялган сөйләргә күнегә алмаган иде.

— Гафу итегез,— дип мыгырданды ул.— Уйламыйча әллә нәрсәләр әйтеп ташладым... Минем бригадада тагын шундый бер авыру бар. Бәлки, анысын да алып килергәдер?

— Менә монысы егетләрчә!— диде Рәйханә апа, саран гына елмаеп.

«Егетләрчә!»— дип уйлады Барый, мондый мактау сүзен һич тә ошатмыйча. Чынлап та малай-шалайга санаган икән. Юк инде! Алай түгел ул!

Нәрсәнең «алай түгел» икәнлеген бу минутта ул үзе дә аңлый алмады һәм аңларга да теләмәде. Сумка каешын ныграк кысып тотты да, шулай да үзенә җиңелрәк була башлаганлыгын тойган хәлдә:

— Вакытыгыз булса, бәлки, бригадага барып чыгарсыз?— диде.— Кем белә аны, әллә бөтен бригада белән... Мотоциклга утыртам да алып китәм. Нәрсә ул дизентерия — сөйләрсез, аңлатырсыз. Без бит бөтенләй томана ул яктан.

— Мондый сүзләрегез өчен рәхмәт,— диде Рәйханә апа, җитди итеп.— Дизентерияме, түгелме икәнлеге хәзергә анык түгел. Дөресен лаборатория әйтәчәк. Дизентерия булган очракта, без сезгә болай да тынгылык бирмәячәкбез. Ә Галимулла абзыйны... Галимулла абзыйны ничек тә тизрәк дәваларга тырышырбыз.

— Ә Димка?

— Нинди Димка? Теге авыруыгызмы? Аны инде, иптәш Рамазанов, сорап та торасы юк, авыру булгач — авыру, барыбер китерергә кирәк.

## XIII

Директор янына Барый җилләнеп, кызарынып килеп керде.

— Теләсәгез нишләтегез, Игорь Андреич!— диде ул, туры өстәл янына узып.

Йодрыкланган ике кулы белән өстәл читенә таянган килеш, Горшков аны тыныч кына тыңлап утырды.

— Шулай...— диде ул, бригадир сөйләп бетергәч.— Бүген үк районга машина җибәртербез. Анда синең барып йөрүең кирәкми. Галимулланы да шунда алып китәрләр. Кем сменасында — Мусинныкындамы?

— Бөтен хикмәт тә шунда шул — анықында түгел!

— Анықында булса — нәрсә?

— Никтер мин аннан шикләнәм, Игорь Андреич,— диде Барый, тыелыбрак.— Билгеле, заводтан да шулай чыгарылган булуы мөмкин, тиешенчә борылмыйча...

— Шикләнеп кенә хәзер бернәрсә дә эшләп булмый,— диде Горшков, тавышын күтәрә төшеп.— Мусин мәсьәләсендә мин күптән шикләнәм, ләкин шикләнү генә әле ул берни түгел. Безнең монда суд-тикшерү органнарыбыз да юк, әллә нинди экспертизаларыбыз да юк. Алай нечкәләп тора торган вакыт та түгел. Бүгеннән милициягә тотып бирергә дә хакыбыз юк. Эштә ул алдынгы, тырыш. Аннары бары тик яратып җиткермәгән өчен генә...

— Юк, алай түгел, Игорь Андреич,— диде Барый, сүзнең икенче якка китүенә пошынып.

— Алаймы, түгелме — чынында шулай килеп чыга. Кыскасы шул: завод гаебеме анда, кемнең дә булса күреп җиткермәвеме — тракторчыларның икесе дә гаепле! Шулай ук син дә, иптәш бригадир!

Горшков кыза башлавын үзе дә сизенде бугай — урыныннан торып, идән буенча бер-ике мәртәбә йөренеп килде дә, ике йодрыклап өстәлгә барабан кагып алды һәм шуннан соң бөтенләй тыныч, салмак бер тонга күчеп:

— Менә шул, иптәш бригадир,— диде.— Ә йолдызча капкачын юкка ачкансың... Ярый, ул турыда бетте. Нәрсә, дизентерия? Сөйләштеңме врач белән?

— Сөйләштем.

— Ярый, яхшы булган,— диде директор һәм беразвакыт эндәшми торды да: — Мин сиңа кайбер яңалыклар әзерләп тордым,— дип куйды.

«Кыздырды-кыздырды да, хәзер инде күңелне күтәрмәкче була»,— дип уйлап алды Барый үзалдына.

— Өлкә каласыннан хәбәр бар,— диде Горшков.— Безнең совхозга өстәмә рәвештә тагылма инвентарь кайткан. Вагоннар «Аксу» станциясендә. Чәчкечләр дә бар.

— Чәчкечләр дә?!— диде Барый, кинәт йокысыннан айнып киткәндәй.

Чәчкеч мәсьәләсе әле булса совхозның иң нечкә җире иде. Бер генә бригаданың да чәчкечләре җитәрлек түгел иде. Булган барлык чәчкечләрне көн-төн файдаланганда да, совхоз чәчү планын вакытында үти алмаячак иде, һәм монда бары тырышлыкка гына яисә нинди дә булса берәр могҗизага исәп тоту мөмкин дә түгел иде.

— Әйе, чәчкечләр дә!— диде Горшков.— Хәзер инде бөтен эш үзебездә. Хәзер инде бернинди сылтау була алмый. Шушы калган өч-дүрт көн эчендә иң соңгы көчне

куеп тырышырга кирәк булачак. Иң соңгы көчне! Аксуга машиналар китте. Кичкә таба кайтып җитәргә тиешләр. Кайткач та бер машина туп-туры сиңа китәчәк. Бер минут туктап тормыйча, чәчкечләрне җыясыз, төнләме, көндезме — кайчан өлгерәсез, шундук чәчәргә дә тотынасыз!

— Аңлашылды, Игорь Андреич!— диде Барый, җәһәт кенә урыныннан торып.

— Тукта, бераз гына сабыр ит,— диде директор.

Горшков ачык ишектән икенче як бүлмәгә күз төшереп алды да, бар әле дигән сыман, үзенең секретарена ым какты.

Яшь кенә бер кыз, биек үкчәле туфлиләрен шакылдатып, Барый яныннан узып китте. Егет кешенең борынына җиңелчә хуш ис килеп бәрелде. Көн-төн басуда,үзе кебек үк тупас, кара киемле кешеләр арасында булып тагын да ныграк тупасланып беткән бригадир күңеленә бу җиңел, татлы ис һәм бу чиста, пөхтә киемле сылу шәһәр кызы әллә ничек тәэсир итте. Кинәт ул кемнедер юксынып куйды, моңаеп-сагышланып куйды.

Секретарь кыз коридордан бер казакъ кызы ияртеп керде. Казакъ кызы, өстәл янына ук килеп җитмичә, стена буендагы бер урындыкка утырды да башта директорга, аннары Барыйга карап алды һәм башын иеп көтә башлады.

Өстенә ул озын, киң итәкле яшькелт ситсы күлмәк һәм киҗе-мамык тукымадан тегелгән иске генә кара бишмәт кигән иде. Түгәрәк нечкә муенының ачык җирендә җемелдәп, күпереп эре гәрәбә сыргасы асылынып тора иде. Кулына ак яулыкка төйнәлгән бәләкәй генә төенчек тоткан иде. Гәүдәгә ул уртадан биегрәк иде, тулы тәнле, зифа сынлы иде. Барлык дала кызларыныкы шикелле аның да бите киң, түгәрәк иде һәм бер-береннән шактый читкә урнашкан күзләре кысылыбрак тора иде. Ләкин, гаҗәп хәл, дала кешеләреннән үзгә буларак, ул чем-кара күзле түгел, бәлки, коңгырт күзле иде. Бу аны ничектер икенче төрле итеп, гадәттәге казакъ кызларыннан башкачарак итеп күрсәтә иде.

— Менә сиңа бер эшче,— диде директор, Барыйга эндәшеп.— Русча «драсти»дан башка берни белми. Сөйләш үзең рәтләп. Синдә аңа яхшырак булыр.

Барый, аңлашылды дигән кебек, баш какты һәм кызга бераз карап торгандай итте дә, сүзләрен мөмкин кадәр казакъчалатырга тырышып:

— Атың кем?— диде.

— Гөлбиби,— диде кыз көттермичә һәм шул ук ва-

кытта каш астыннан тагын җитез генә Барыйга карап алды.

— Кайсы авылдан?— диде бригадир.

Кыз янә башын түбән иде һәм кулындагы төенчеген бөтәргәләргә тотынды. Барый аны аңламады, ахрысы, дип уйлады. Ул соравын яңадан кабатлады.

— Камыскүлдән,— диде кыз, теләр-теләмәс кенә.

Барый аңа тагын берничә сорау бирде, әтиең-әниең бармы, диде; ничә яшьтәсең, диде; укыдыңмы, ничә класс бетердең, диде; бездә эш авыр бит — үкенмәссеңме, диде. Гөлбиби торган саен ныграк ачыла барды, кыюлана барды һәм сорауларга бик теләп җавап бирде. Барыйга ул хәтта кирәгеннән артык кызу сөйләшә шикелле тоелды. Кызның ят сүзләрен аңлар өчен аңа бөтен игътибарын бергә тупларга туры килде.

Кешене эшкә алганда, билгеле, болай сорашып кына алмыйлар — үзе белән сөйләшкәнче иң әүвәл паспортын карыйлар, характеристикасын карыйлар. Көтмәгәндә ниндидер җилләр китереп ташлаган бу кызның паспорты да, бүтән документлары да юк иде. Ләкин шулай булуга да карамастан аңа ышандылар, аның чын күңелдән эшләргә теләвенә, теләсә нинди кыенлыкларга түзәргә риза булуына ышандылар. Шундый япь-яшь кызның монда эш сорап килүе беренче карашка сәеррәк тоелырга мөмкин иде, ләкин шул ук вакытта — аның нәкъ менә шул яшьлеген исәпкә алганда — монда бик үк сәерсенер урын да юк иде.

— Патриот!— диде Барый, кыз белән сөйләшеп бетергәч, елмайгандай итеп.

— Дөрес, патриот. Тик бу әле бердәнбер патриот,— дип куйды Горшков, күңелсез генә.— Яшерен-батырын түгел, җирле халык безне яратып җиткерми. Безгә килеп төшкән беренче карлыгач бу. Безгә ул карлыгачларны күбрәк тартырга, күбрәк чакырырга иде. Хәер, соңга таба менә шулай үзләре дә килә башларлар әле.

## XIV

Барый кызны хәзер үк үзе белән бригадага алып китәргә булды.

— Утырганың бармы моңа?— диде ул, тышка чыккач, мотоциклга күрсәтеп.— Минем ат менә шул. Безгә бик алыс кайтасы.

— Утырганым бар,— диде Гөлбиби, баш кагып.

— Киттек, алайса!— диде Барый.

Икенче бригадага юл турыдан гына китә иде, ләкин

Барый уңгарак борылды һәм бер-ике минуттан азык-төлек кибете каршысына килеп чыкты.

— Туктале, папирос алып чыгыйм,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Менә безнең догкән. Берәр нәрсә алырга кирәкмиме?

— Җок,— диде кыз, башын чайкап.

Барый аның сүзен ишетмәде. Аңа хәзер ул, гомумән, берни күрми, берни ишетми шикелле тоелды. Солдат гадәте буенча, ул бил каешын рәтләде, күлмәк җыерчыкларын артка сыпырып җибәрде, ачык якасын төймәләде дә сумка каешын ныграк кысып тотты, туры басарга тырышып, әмма шулай да чак-чак кына чайкалгандай итеп, ишеккә таба атлады.

Кибеттә, гадәттәгечә, кешеләр бар иде. Бала җитәкләгән бер хатын, төзүчеләрдән бер-ике яшь егет, бер кыз, бер-бер артлы тезелеп, сабыр гына чиратка басып торалар иде. Барыйга алар беренче караштa гына чалынып калдылар да шундук юкка да чыктылар. Аның күз алдында бары тик үлчәү янындагы ак халатлы сатучы гына калды, аның соскы тоткан ак нәфис куллары да нур бөркеп торган ак түгәрәк йөзе генә калды.

Кибеттәге кешеләр никтер аңа сынап, гаҗәпсенеп карыйлардыр шикелле булып, аның монда ни өчен кергәнлеген дә, нәрсә уйлаганлыгын да, нәрсә хис иткәнлеген дә — барысын да беләләрдер шикелле булып тоелды. Аларның шелтәле күз карашларыннан яшеренмәкче булып, ул тиз генә артка, чират койрыгына барып басты. Ләкин, күпмедер вакытлар басып торгач, беркемнең дә үзенә карамавын, беркемнең дә үзе белән кызыксынмавын сизеп, гаҗәпсенеп китте, тирә-якка, кешеләргә җентекләбрәк карый башлады. Әле генә шундый күзнең явын алып, нурлар чәчеп торган ак халатлы сатучы да хәзер аңа яхшырак күренә башлады. Алай гына да түгел, ул аның йөзенә-кыяфәтенә дә игътибар итте. Мәрьям аңа гадәттәгегә караганда боеграк, күңелсезрәк булып күренде. «Ни булган?» — дип уйлады ул, пошынып. Һәм ул, көйсезләнгән трактор белән эш иткәндәге кебек, ни булганлыгын белмәкче булып, сатучы кызга аеруча бер дикъкать белән карап-карап алды.

Үзенә төбәлгән күз карашын тоеп, Мәрьям дә аның ягына карагандай итте.

— Исәнмесез!— диде Барый, авызы колагына җитәр дәрәҗәдә елмаеп.

— Исәнмесез,— диде Мәрьям дә, һәркемгә эндәшә торган гади генә бер тавыш белән.

Чират Барыйга җиткәч, ул яңадан башын калкытып карады һәм шундый ук гадилек белән:

— Сезгә нәрсә?— диде.

— Миңамы?— диде Барый, әле һаман елмаюыннан тыела алмыйча.— Миңамы... миңа... нәрсә бирерсез икән?

Үзенчә, ул кыз белән шаяртып сөйләшәм дип уйлады, ләкин аның бу юкка вакытны ала торган «шаяртуы» Мәрьямнең ачуын китерде.

— Ни кирәклеген үзегез дә белмәгәч, мин каян белермен икән?— диде ул.

— Сез бүген никтер кәефсез күренәсез,— диде Барый.

— Кәефем юк шул. Башым авырта,— диде Мәрьям, күңелсез генә.— Әйтегез, нәрсә кирәк?

— Миңамы... Миңа биш пачка «Беломор» бирегез...

— Тагын?

— Тагынмы?.. Шикәр, ярма...

— Күпме?

— Берәр кило.

Барыйның беркайчан да кибеттән шикәрдер, ярмадыр ише нәрсәләр алганы юк иде. Хәзер дә ул бу кадәр ашамлыкны ни өчен алганлыгын аңлый алмады, ул хәтта алам дип тә уйламады, ул бары болай гына әйтте, шаяртам дип уйлап кына әйтте. Мәрьям исә, артык сорашып тормыйча, тиз-тиз генә үлчәргә дә тотынды. Үлчәде дә, каяндыр кәгазь табып алды, төрде, йомарлады, бер читкә алып куйды, акчасын исәпләде һәм, чак-чак кына көлемсерәгәндәй итеп:

— Тагын?— диде.

— Тагынмы?— диде Барый, шул ук «шаярту» белән шаяртып. Кинәт анда гадәттән тыш бер кыюлык барлыкка килде.— Тагынмы?— диде ул, кабатлап.— Бер генә елмаегызчы.

Якында гына басып торган егетләр көлешеп алдылар. Мәрьям ачуланмакчы булды, ләкин, бүтәннәрнең шат кыяфәтен күрепме, бүтән сәбәптәнме, ачуланудан тыелып калды һәм саран гына булса да елмайгандай итеп куйды.

Куанычы эченә сыймаган бригадирның күңеленә шунда мең төрле уй килде, тел очына мең төрле сүз килде.

— Рәхмәт,— диде ул.

Ул арада Мәрьям нindидер эш тапкан булды да ачык ишектән арткы як бүлмәгә чыгып китте. Барый, сумкасын ачып, үзенә тиешле нәрсәләрне тутыра башлады. Ләкин сумкага бер кило шикәрдән башка әйбер сыймады.

— Әллә монысын сездә генә калдырыйм микән?— дигән булды ул, үлчәү янына килеп баскан Мәрьямгә ярмасын күрсәтеп.

— Сатылган товар кире кайтарып алынмый,— диде Мәрьям, рәсми бер корылык белән.

Шул ук вакытта ул аңа өздереп кенә бер карап алды. «Менә шулай, иптәш бригадир. Җыен тузга язмаган сүз сөйләп, башымны катырма әле»,— диде аның бу кыска күз карашы. Барыйның кыюлыгы шундук юкка чыкты. «Ярар, теге кызга бирермен әле»,— дип уйлады ул, кинәт авыраеп калган ярмасын кулына алып.

## XV

Мәрьямнең бер елмаеп каравына, бер ягымлы сүзенә зар-интизар булып йөрүче егетләр Рамазанов кына түгел иде. Мондагы һәртөрле ир кешеләрнең мактау сүзләренә, мәгънәле күз карашларына Мәрьям инде күптән күнегеп беткән иде, шуңа күрә андый татлы-баллы сүзләргә дә, нәрсәдер өмет иткән, нәрсәдер вәгъдә иткән күз карашларына да аның әз генә дә исе китми иде. Ул моны, гомумән, шулай тиештер дип, аның урынында бөтенләй икенче бер кеше булса да, аңа да шулай карарлар иде дип исәпли иде.

Барыйның да кергән саен сүз кушуларына, шаярткан булуларына ул бөтенләй диярлек әһәмият бирмәде. Кибеткә кергән һәрбер ир кешегә, һәрбер шырпы-папирос алучыга, һәрбер «аракы юкмы?» дип сораучыга ничек караса, аңа да шулай ук карады, аларга ничек җавап бирсә, аңа да шулай ук җавап бирде һәм Барыйның өстендә солдат киеме булган өчен генә һич тә үзен аның белән гадәттәгедән дә ягымлырак булырга мәҗбүр итә алмады.

Моңа кадәр шулай булды. Ләкин Барый икенче бригадага бригадир булгач та, сатучының аңа булган карашы үзгәргәндәй булды. Ул аны күрә башлады, аның сүзенә, кыяфәтенә, кыланышларына игътибар итә башлады. Хәтта аның кайчакларда Барый турында уйлаган вакытлары да булгалады.

Ник, ни өчен? Баштарак ул аның Ислам эшләгән бригадада бригадир булганы өчен кызыксынды, яңа бригадирлары ничек икән, нинди рәк кеше икән, диде. Аның аннан бригада хәлләре турында, Ислам турында сораштырасы килде, ләкин ул, билгеле, берни турында да сораштыра алмады.

Ул көн дә Исламны көтте. Ислам исә ачуланып киткәннән соң бер генә мәртәбә дә килеп әйләнмәде. Ул

борчыла, тынычсызлана башлады. Исламның килмәвенең сәбәбен ул никтер яңа бригадирдан күрде. Аңа Исламны бары ул гына җибәрмидер шикелле булып, аны юри артык эш кушып тоткарлыйдыр шикелле булып тоелды. Аннары күңеленә тагын шундыйрак уй килде: Ислам белән аның арасындагы мөнәсәбәтләрне белгәндер дә, арага кермәкче буладыр шикелле булып, Ислам тегендә тузанда-туфракта аунаганда, ул үзе монда килеп шулай сөйләнгәләп, тәмле телләнеп йөридер шикелле булып тоелды. Соңгы вакытта Барыйның кибеттә еш күренгәләвен ул бары шуңа гына юрады. Аның ачуы килде. Ачуы гына да килеп калмады, ул моңа бөтен күңеле белән нәфрәтләнде.

Барый исә соңгы көннәрдә, эшләр җайга салыныр, ахрысы, дип уйлаштыра башлаган иде. Ләкин Мәрьямнең бүгенге сүзләре, салкын күз карашы аны аптыраште калдырды. Кирәксез ярмасын бер кулыннан икенче кулына күчергәләп, ул бер читтәрәк басып тик торды. Ул кеше чыгып беткәнне, Мәрьям белән икәүдән-икәү генә калуны көтмәкче булды. Ләкин кешеләрнең берсе керде, берсе чыкты, һәм кибет эче бер генә минут та бушап тормады. Мәрьям, аның барлыгын-юклыгын да онытып, һаман үз эшендә булды.

— Ярый инде...— дип куйды Барый, ниһаять, китәргә кирәклеген аңлап.— Кайчан бетәр бу эш?

Бу сүзләрне ул Мәрьямгә карата, аның бертуктаусыз эшләвенә һәм әз генә дә үзенә игътибар итмәвенә карата әйтәм дип уйлады, ләкин тыңлап торучыларга бу, киресенчә, аның үзенә карата әйтелде шикелле тоелды.

— Эшнең аның беткәне юк, энем,— диде чандыр гына бер татар хатыны.— Үлгәч тә әле ул җиде көнлек кала, ди.

— Шулай шул, апа,— дигән булды Барый һәм, үзе дә сизмәстән, көрсенеп куйды.— Кайберәүләр әнә эшлиләр дә эшлиләр, үлгәнче эшләп бетерик диләр микән инде.

Мәрьям, җан өшеткеч бер игътибарсызлык саклап, тагын берни эндәшмәде, бары тик матур иреннәрен генә ныграк кысып куйды да чак-чак кына матур кара кашларын җыерды. Барый авыр гына, теләр-теләмәс кенә атлап чыгып китте.

Гөлбиби аны баскыч төбендә көтеп тора иде. Бригадирның чыгуын күреп, ул мотоцикл янына килде.

— Мәле, төенчегеңә төйнә шуны,— диде Барый, кулындагы ярмасын кызга сузып.— Тапкан! Ач кеше кебек... Утырдыңмы? Нык тотын, егыла күрмә тагын. Бәладән баш-аяк...

## XVI

Юлда кайтканда бригадирны икенче төрле уйлар биләп алды. Күңеле белән ул шундук бригадага кайтып җитте. «С-80» исенә төште, исенә төште дә, бәгырьләрен телгәләп алды. Ничә көн утырыр ул шулай? Чәчүгә җир җиткереп булмаса? Өч агрегат эшләүдән ни файда ул чакта. Кемнәрне куярга өченче агрегатка?

Ул барыбер уйларының очына-кырыена чыга алмады — тузан туздырып, алар бригада «авылына» килеп тә керделәр.

Көктугайда әллә ни озак тормады шикелле тоелган булса да, никадәр күп вакыт үткәнлеге монда кайткач бик тиз сизелде. Төш вакыты инде узган иде. Черки күплектән битен-күзен яулык белән томалап бетергән Фәридә, күрәсең, әле яңа гына басудан кайтып, аш йөртә торган термосларны, табак-савытларны юып ята иде. Бригадирга утырып килгән ят кызны күреп, ул эшеннән туктады һәм, бу кем булыр икән дигән сыман, кызыксынып карап тора башлады.

— Менә бер эшче алып кайттым,— диде Барый, пешекче кыз янына якынлашып.— Танышыгыз. Исеме Гөлбиби. Камыскүлдән. Үзе теләп безгә эшкә килгән.

— Әйбәт булган,— диде Фәридә.— Ләкин мин аңа аш калдырмадым бит әле, Барый абый. Сезгә генә.

— Зарар юк,— диде бригадир.— Бер табактан ашарбыз.

Ул сумкасындагы шикәрен, Гөлбиби төенчегеннән чишеп биргән ярмасын кухня өстәленә куйды һәм, тотлыккандайрак итеп:

— Менә... сиңа...— диде.

— Нәрсә, нәрсә?— диде Фәридә. Өстәл янына килде дә, юеш бармакларын тырпайтып, кәгазь төргәкне ачып карады, карагач елмаеп куйды.— Күчтәнәчме, Барый абый?

— Әйе, күчтәнәч,— диде Барый, аңламыйчарак. Фәридә көләргә тотынды. Бригадирның мондый күчтәнәче дә, сүзләре дә, үз-үзен тотышы да аңа бик сәер булып тоелды.

— Ник алдыгыз моны?— диде ул, ярмага күрсәтеп.— Шикәре инде ярый. Ярмадан үзегезгә ботка пешертергә уйламыйсыздыр ич?

— Алып куй инде, күп сөйләнмә,— диде Барый.

— Карабодай ярмасы кайткан кибеткә,— диде ул бераздан, ялганларга исәпләп.— Пешереп карар, дидем, әйбәт булса, күпләп алырбыз, дидем...

— Алайса, бу карабодай ярмасы була, Барый абый?— диде Фәридә, хәйләкәр елмаеп.— Мин бит бүген нәкъ шундый ярмадан ботка пешердем... Кайда ашыйсыз? Монда утырырлык түгел — черки! Вагоныгызга кертимме?

— Керт,— диде бригадир.

Аның хәзер карабодай ярмасын күрәсе дә килмәде. Ләкин вагонда аш янында Фәридә тагын шул турыда сүз башлады.

— Карабодай боткасы тәмле бит, иеме, Барый абый?— диде ул, өстәлнең икенче башына, Гөлбиби янына урнашып.— Сезнеке дә шундый микән?

— Тәмле...— диде Барый, теләмичә генә. Аннары, сүзне икенчегә борып, өстәп куйды: — Дөге түгел инде шулай да... Пешерүен дә яхшы пешергәнсең.

Мактау сүзләре ишетеп, Фәридәнең бит алмалары алсуланып китте.

— Үзем теләп алгач, шүрләп тә куйганыем булдыралмам дип... Барыбер шул ук дөге, шул ук токмач. Ничек пешерсәң дә бер ботка,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.

— Юк, син әйбәт пешерәсең,— диде бригадир. Аның кинәт кенә Фәридәне ныклап торып мактыйсы килеп китте. Аның үзенә бу мактау пешекче кыз алдында ялагайлану шикеллерәк булып, бөтенләй кирәкмәгәнгә шикәр, ярма ише нәрсәләр алып кайтып ахмаклык эшләгәнлеген кызның тизрәк онытуын үтенү шикеллерәк булып тоелды.

— Уңдык синнән, Фәридә!— диде ул.— Вакытында өлгертәсең, тәмле итеп пешерәсең. Безнең шартларда шунысы да җитеп ашкан инде.

— Егетләр дә зарланмый хәзер, Барый абый!— диде Фәридә, балаларча куанып.

— Ишетелми,— диде бригадир.— Хәлнең шәптән түгел икәнлеген алар бит аңлыйлар. Менә ит тә булса...

— У-у, ул чагында!— диде Фәридә, Барый абыйсыннан күзен алмыйча.

— Бүген дә сорадым,— диде Барый, искәрмәстән бик җиңел генә ялганлап.— Авылларга да барып караганнар. Мал суярга рөхсәт юк, ди. Быел маллар начар кышлаган, күбесе үлгән, шуңа күрә суйдырмыйлар, ди.

— Беләсеңме, Барый абый...— диде кинәт Фәридә, ничектер бик серле итеп.— Беренче бригаданыкылар әнә балык тоталар икән...

Бу турыда Барыйның да ишеткәне бар иде, ишетү генә түгел, бу турыда ул бик яхшы белә иде. Көктугайдагы кайбер кешеләр һәр ял саен җыйнаулашып балык-

ка йөриләр иде. Ләкин аларның эше шундыйрак бит. Мастерскойдамы, складтамы, конторадамы тиешле сәгатьләрен эшлиләр дә — дүрт яклары кыйбла! Аннары беренче бригадага да җиңел. Иртыш аларга якын, күп дигәндә ярты сәгать эчендә җәяүләп тә барып җитәсең. Юк, аның өчен бу бер дә яңалык түгел.

— Мин бернәрсә уйлаганыем әле, Барый абый,— диде Фәридә.

— Нәрсә?

— Без бит Беренче Май көнне Иртыш буенда булдык...

— Ишеттем. Тагын барасыгыз киләме?

— Шунда Иртыш буенда бер маякчы тора. Шуңа әйтсәк, безгә балык тотмасые микән ул, Барый абый?

Бригадир ашавыннан туктап калды.

— Нишләп элегрәк әйтмәдең аны?!— диде ул.

— Үзем дә бүген генә уйладым,— диде Фәридә.

— Уйласаң, менә шул: хәзергә бу турыда беркемгә әйтмә. Сменадан соң кичкә таба үзем тиз генә барып кайтырмын. Мин дә беләм ул маякчы йортын, минем дә Иртыш буенда булганым бар лабаса!

Ашап туйгач, бригадир Гөлбибигә карап алды да, аны әле яңа гына исенә төшергәндәй:

— Тойдыңбы?— дип сорап куйды.

— Тойдым,— диде кыз.

— Туйсаң шул, хәзер сиңа берәр урын табарбыз. Ял итәрсең дә төнге сменага чәчүгә китәрсең.

— Аны безнең янга урнаштырырга туры килер инде, иеме, Барый абый?— диде Фәридә, уйлангандай итеп.— Бераз кысанрак булыр инде...

— Бер дә кысан булмас әле,— диде бригадир.— Беркем дә көне-төне вагонда ятмый: берсе кайта, икенчесе китә.

— Мин бит болай гына, Барый абый!— диде Фәридә, ашыгып.— Аның үзенә кыен булмасын, дим. Без инде өйрәнгән, безгә ничек тә ярый. Ул бит яңа кеше.

— Ул да өйрәнер!

Казакъ кызы, гомумән, үзе турында сөйләгәннәрен аңласа да, татар сүзләренә тулысынча төшенеп җитә алмады, ахрысы, һәм, кысык күзләрен җемелдәтеп, әле бригадирга, әле Фәридәгә карап-карап алды.

— Барый абый, мин аңа үземнең урынны бирермен,— диде Фәридә.

— Үзең нишләрсең? Син бит мондагы кеше.

— Ничек тә җае килер әле.

— Карале, сиңа кухня чатырына урнашу яхшырак

булыр... дисәң дә инде... кыз кеше... Фәридә кызарып китте.

— Миңа кайда да ярый,— диде ул.— Мин болай да төн уртасыннан торам.

— Алайса, шунда күчен,— диде бригадир.

— Мин инде ике төн шунда кундым,— диде Фәридә, үзенең серен чишеп.— Барысы да йоклап беткәч мыштым гына чыгам да ятам шунда. Эчтән икегә бүлдем: бер ягында табак-савыт, бер ягында...

— Эх, белмәгәнмен моңарчы!— дигән булды бригадир, күз кысып.— Син инде беркемгә дә әйтмә, икәү генә белик моны!

— Юк, юк. Барый абый, беркемгә дә әйтмәм!— диде Фәридә, көлеп.

Тышка чыккач, ул Гөлбибине култыклап алды һәм хәзер үк аны үз урынына илтеп урнаштырмакчы булды.

— Синең соң бүтән киемең юкмыни?— диде ул, казакъ кызының бишмәт җиңеннән тоткалап.

— Җок,— диде Гөлбиби.

— Мин дә уйладым инде аны,— диде Барый.— Җиләк җыярга барган кебек кенә чыккан шул.

— Мин аңа үземнең эш киемнәрен бирермен, Барый абый!— диде Фәридә.— Миңа хәзер аларның кирәге юк.

— Шәп кыз син, Фәридә!— диде Барый, чын күңелдән сокланып.

Бу мактаудан Фәридә кабынып киткәндәй булды, куанычыннан хәтта Барый абыйсына җавап кайтарырлык сүз дә таба алмыйча, кискен бер хәрәкәт белән Гөлбибинең беләгеннән кысып тотты да, балкып-елмаеп:

— Әйдә тизрәк, Гөлле Биби!— диде.

Шул ук минутта диярлек Барый Көктугай ягыннан болай таба якынлашып килүче машина күреп алды. Бу, һичшиксез, «Аксу» станциясеннән чәчкечләр алып кайтучы машина булырга тиеш иде.

## XVII

Бригадир чатырга килеп кергәндә, зур өстәл тирәсен әйләндереп, шаулашып егетләр домино уйнап утыралар иде. Уенчылар шундый мавыкканнар иде, якында гына бригадир торганлыгын алар шактый вакыт сизмәделәр һәм бер-берсенә әтәчләнеп кычкырынуларында булдылар.

Барый беравык тавыш-тынсыз басып торды да боеручан төстә:

— Ташлагыз уеныгызны!— диде.— Киенегез, хәзер эшкә чыгабыз.

Аның тавышын ишетеп, өстәл янындагылар барысы да башларын күтәреп карадылар.

— Шушыны гына уйнап бетерик инде,— диде Илгиз.

— Әйттеләрме сиңа!— диде Ислам, урыныннан торып.— Әйдә, киен!.. Ничек, Барый, бармы, юкмы? Нишләрбез икән, ә? Тәмам эштән чыккан бит, малай.

Барый, ишетмәгән сыман, берни җавап кайтармады, иреннәрен кысып, киеренке бер кыяфәттә көтеп торуында булды.

— Чәчкечләр кайтты,— диде ул бераздан, тыныч кына.

— Чәчкечләр?! Чынмы?— диделәр егетләр һәм, бүтән әйтеп торганны да көтмәстән, этешә-төртешә ишеккә ташландылар.

Эчен тотып, алар артыннан сытык чырайлы Димка да иярде.

— Хәлең ничек?— диде бригадир.

— Капкынга эләккән бүренеке төсле,— диде Димка, шыңшып.

— Эш беткәч бүген үзем Көктугайга илтеп куярмын. Беркая китмә,— диде бригадир.

— Мотоциклга утырмыйм,— диде Димка, киреләнеп.— Үзләре килсен.

— Ярый, алайса, үзләре килгәнне көтәрбез,— диде Барый, тыелып кына.— Үлчәдеңме?

— Үлчәдем. Һарун төнлә җитмеш алты гектар чәчкән.

— Җитмеш алты?!

— Үзем дә башта ышанмадым. Ике мәртәбә үлчәдем — җитмеш алты.

— Менә шәп! Бодай китерәләрме?

— Китерәләр,— диде Димка, ыңгырашып, һәм борылды да ашыгып каядыр китеп барды.

Йөк төялгән машина янына килгәч, Барый иңбашындагы сумкасын салып куйды һәм егетләргә чәчкеч тимерләре бушатырга булыша башлады. Берничә минуттан аларга Димка да килеп кушылды.

— Маташма!— диде бригадир, кул селтәп.— Бар, кереп ят, йә булмаса читтәрәк тор.

Димканың, әлбәттә, барлы-юклы хәле белән тимер күтәреп азапланасы килми иде. Бригадир кушкач, ул эшен ташлады да читкә китеп басты.

Шул вакыт Ислам аның селтәнеп черки куып торуын күреп алды һәм, эшем кешесе булып:

— Әй, син, багана, нәрсә каттың анда?— дип кычкырды.

— Ул авыру. Аңа ярамый,— диде Барый.

— Авыру? Эч китә дип шыңшып йөри — шулмы авыру?

— Шул,— диде бригадир.

Ислам сүз көрәштереп тормады. Аның эче пошты. «Бу чәчкечләргә кемне куярлар?»— дип уйлады ул үзалдына.

Әйе, капчык ташырга, тузан эчәргә кемне куярлар? Кемне булсын, әлбәттә, аларны! Үз тракторың кырылып ятканда баш тартырга бернинди сәбәп юк. Сәбәбе табылса да, нигезле булмас. Мөмкин түгел.

Бригадирның авыру Димканы яклап торуы аның күңелендә кинәт бер фикер уятты.

— Галимулла кая соң безнең, ник булышырга килми?— дигән булды ул тагын, үзалдына сукранып. Аннары «исенә төште» дә әйтеп куйды: — Аны бит синең белән Көктугайга китте дигәннәрие түгелме соң, Барый?— диде.

— Аны анда алып калдылар,— диде бригадир.

— Ник?

— Дизентерия таптылар... Районга анализга җибәрделәр.

— Дизентерия?!— диде Ислам, шаккатып.— Алайса, Димканың да дизентерия? Алайса, миңа да йоккан?

— Сиңа да?— диде Барый, ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

Белмим, мин инде беркемгә әйтмәдем. Далага да кеше күрмәгәндә генә йөгердем. Иртәннән бирле баш авырта, хәл юк. Йокы туймагандыр дип йөрим тагын.

Барый эшеннән туктагандай итеп торды да Исламга бер җентекле күз карашы ташлап алды.

— Хәлең булмаса, үзең кара тагын,— диде ул. Исламның кыяфәте бер дә авыруларныкы төсле түгел иде, ләкин кеше үзен авырумын дип торганда, ышанмау да килешеп бетми иде.

— Юк инде,— дигән булды Ислам, көрсенеп.— Мондый вакытта эш ташларга мин теге... Әле дә менә бу җебегән аркасында ике кулсыз, ике аяксыз калдык.— Ачу белән ул Илгиз ягына ымлап алды.— Сораштырдыңмы, Барый, складта бирәр нәрсә бар микән?

Барый тагын ишетмәмешкә салынды. Аның хәзер бу турыда ишетәсе дә, сөйләшәсе дә килмәде.

— Бүген Рәйханә апа килергә тиеш. Шунда күренерсең,— диде ул, бөтенләй икенче нәрсәгә җавап биреп.

— Үзем дә шуны уйлап торам әле, Барый,— диде Ислам, мескенләнеп, тирләгән маңгаен сөрткәләп.— Менә бу машинага утырып киткәндә яхшы булырые да бит... булмый, боларны ничек ташлап китәсең!

«Әһә, шулаймы!— дип уйлады Барый, ачу белән.— Оста, бик оста!»

— Дөрес, шушы машинага утыртып җибәрергә кирәк!— диде ул аннары.— Әй, Дмитрий Иванович, кил

әле монда! Юкка шыңшып йөргәнче, утыр да кит хәзер үк Көктугайга. Врачка күренми кайтасы булма. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Димка, күңелсез генә.

— Моны озатыйк әле башта,— диде ул Исламга, аның үзе кебек үк дусларча булырга тырышып.— Ул киткәч, чир йоктыручы бетәр, синеке әле безгә тиз генә йокмас. Ул арада без әллә никадәр тау-таш актарып ташларбыз.

Ислам эндәшмәде. Ләкин шулай да, үзен авырумын дип белдергәч, хәзер инде шул тондарак дәвам итәргә кирәклеген шәйләп, бераздан әйтеп куйды:

— Әйтсәң дә ышанмыйлар, әйтмәсәң дә...— диде, хәтере калган булып.

— Ышанмаудан түгел,— диде Барый.— Син монда хәзер бик кирәк. Синсез эш бармаячак. Берничә сәгатькә генә түзәргә булыр ич?

— Түзәрмен инде... түзәргә кушкач...— диде Ислам, теләр-теләмәс кенә.

Машина бушатылып беткәч, бригадир егетләрне үз янына җыеп алды да, җирдә аунап яткан чәчкеч тимерләренә күрсәтеп:

— Хәзер инде боларны җыярга кирәк,— диде.— Исламны сезгә баш итеп куям. Хәзер үк, шушы минуттан ук эшкә тотынасыз. Булдымы? Мин үзем хәзер басуга китәм. Берәрсен алып кайтырга кирәк булачак.

— Сөрүдән туктатып?!

— Шулай туры килә. Хәзер иң кирәге менә шушы чәчкечләр. Җыярга да шунда ук тракторга тагарга. Бер минут туктамый җыярга. Төне буе. Таңгача. Директорның боерыгы шундый.

— Аңлашылды! Әйдәгез тизрәк!— диде Ислам, егетләргә кычкырынып.— Анда тагын йоклап ятучылар бардыр — алып чыгарга кирәк барысын да.

— Анысы синең эш,— диде бригадир, аңа тулы ирек биреп.— Миңа басуда бераз тоткарланырга туры килер. Җирләрне үзем үлчәми булмас. Ә сез — хәзер үк!

— Булды, булды!— диештеләр егетләр беравыздан. Фәридәнең эш киемнәрен киеп куйган һәм шуңа күрә бертуктаусыз елмаерга гына торган Гөлбибине Барый мотоциклга утыртты да кызулап басуга китеп барды.

## XVIII

Һарунның «өйгә» кайтмаганына бүген өч көн булды. Бүтәннәр кайткаладылар: йә орлык ташучы машинага, йә арбага утырып, тракторга утырып тегене-бу йомыш белән

кайтып әйләнделәр. Ул кайтмады. Смена беткәч тә, заправкадан, техник караудан соң Вәгыйзьне озатып җибәрде дә, Фәридә китергән ашны ашады да, шундук йокыга ауды. Төне буе эшләп ул шундый арый, шундый йончыла иде, аның инде кая да булса кайтып торасы да килми иде.

Аннары бу ару-алҗудан тыш аны монда тагын икенче бернәрсә тотып торды. Эш барышында ул Вәгыйзьнең кайбер йомшак якларын белеп өлгерде. Авыр, киеренке эш, тузан-туфрак һәм черки — барысы бергә җыелып, Вәгыйзьне бөгә, сыга башлады шикелле тоелды. Ялкаулык дип әйтеп булмаса да, анда ниндидер гамьсезлек, авырлык сизелә башлады.

Һарун моны һич тә килештерә алмады. Эш вакытында тиз-тиз кыланасы урында, үз иптәшенең чамадан тыш әкрен кыймылдавын, кинәт кенә туктап калуын, йә булмаса, теләр-теләмәс кенә сөйләшүен күргәч-ишеткәч, аның үзалдына җене котырып алгалады. Тыштан исә, кайгыртучан булып, ул аңа, әллә чирлисеңме, диде, ни булды, ник кәефең юк, диде. Вәгыйзь бер дә ачык кына җавап бирмәде. Бервакытны ул, радиатордагы суны карарга онытып, моторны эштән чыгара язгач, Һарунга хәтта кызып китәргә дә туры килде. Моңарчы алар бик тату эшләделәр, килешеп эшләделәр. Ләкин монда инде ул үзенең иптәшен чын-чынлап сүгеп ташлады.

Менә шушы вакыйгадан соң, Һарунның күңеленә бер шом төште. Аның өчен яңа борчу артты. Ул тракторын кызгана башлады, трактор өчен генә түгел, гомумән, Вәгыйзьнең эше өчен курка башлады, аның өчен үзен бүтән вакыттагыга караганда да җаваплырак итеп сизде һәм күңеленнән һәрвакыт аңа күз-колак булып торырга кирәк дигән бер карарга килде. Шулай итеп, теләсә дә, теләмәсә дә аңа гел басуда ятарга туры килде.

Ә беркөнне Вәгыйзь сменасы көндезге ашка туктагач, тракторга ул үзе утырды. Вәгыйзьләр иркенләп ашадылар, ял иттеләр һәм төштән соң яңа көч, яңа дәрт белән эшкә тотындылар. Бүтән көннәрне җилгә оча торган вакыт — кимендә ярты сәгать вакыт файдага узды. Шул ук төнне, иптәшенә бурычлы булып каласы килмичә, Вәгыйзь дә кешеләрен уятты да Һарунныкыларга: «Сез бераз ял итеп алыгыз, сезнең өчен без әйләнербез»,— диде. Алар бер сәгать чамасы йоклап алдылар. Бу бер сәгать йокы аларны бөтенләй икенче кешегә әйләндерде.

Менә шул чагында инде Һарун агрегатында үзенә күрә бер яңалык барлыкка килде. Хәер, бу яңалыкны

алар элегрәк тә, Беренче Май көнне дә кулланып караганнар иде, тик ул вакытта алар моңа әллә ни әһәмият кенә бирмәгәннәр иде.

Сменага бүленеп эшләү әйтерсең юкка чыкты. Кешеләр үз сменалары өчен генә түгел, бәлки, бүтәннәр сменасы өчен дә үз-үзләрен җаваплы итеп сизделәр һәм төнләме, көндезме анда — һәрвакыт бер-берсенә ярдәм итәргә әзер тордылар. Баштарак бу булышу, ярдәм итү ирекле рәвештә булса, соңгарак, үзара киңәшеп, килешеп, мондый нәрсәне агрегатта эшләүче һәркем өчен мәҗбүри бер кагыйдәгә әйләндерделәр.

Шулай итеп, унар, унберәр сәгатькә сузылган ялыктыргыч озын сменалар урынына кыска вакытлы сменалар барлыкка килде. Сәгать механизмы кебек төгәл көйләнгән, төгәл идарә ителгән һәм һәрвакыт Һарунның уяу күзәтүе астында булган агрегат берөзлексез көн-төн эшләде дә эшләде. Ул бары тик кирәк вакытларда гына: зарури техник карау һәм бакларга су, май, ягулык салу өчен генә — тәүлегенә ике мәртәбә генә туктатылды. Бүтән төрле ихтыяҗлардан чыгып туктап торулар бөтенләй бетерелде, элек анда-монда әрәм ителә торган секундлар, минутлар тулысынча эш өчен, чәчү өчен файдаланылды.

Дөрес, болай эшләү мәшәкатьлерәк булды, һәрвакыт уяулыкны һәм көндәлек тормышта гадәтләнгән кайбер нәрсәләрдән баш тартуны таләп итте. Ләкин моңа беркем зарланмады, беркем ризасызлык белдермәде. Киресенчә, болай күбрәк тә, яхшырак та эшләргә мөмкин икәнлеген күреп, һәркемнең күңеле күтәрелеп китте, һәркем үзендә бер горурлык хисе, җиңелчә бер өстенлек, мактану хисе тойды.

Димка бүген иртән җитмеш алты гектар дигәч, Һарун башта ышанмыйчарак торды, дөрес түгелдер, диде, яңадан үлчә әле, диде. Ләкин икенче мәртәбә үлчәгәч тә, барыбер җитмеш алты чыкты. Һарунның үзеннән-үзе авызы ерылды, чак-чак кына башы әйләнгәндәй булды, һәм шул чакны ул үзен әллә нинди батыр итеп, ниндидер бик зур эш башкарган гадәттән тыш кеше итеп хис итте. Ни әйтсәң дә, аның әле беркайчан да бу кадәр күп чәчкәне юк иде, шулай ук аңа бүтәннәрнең дә җитмештән, җитмеш биштән уздырганнарын ишетергә туры килмәгән иде.

Ләкин капчыклардан, киндер чыбылдыклардан теркәп тегелгән ясалма чатыр эченә кереп яткач, аның җилкенгән күңелендә, әкренләп-әкренләп, икенче төрле фикерләр туа башлады. Чәчүгә төшкәннән бирле, хәтта сөрә башлаганнан бирле, ул үзләренең хәзергәчә бер-берсенә ярдәм итеп эшләмәүләренә һәм шуның аркасында ни-

кадәр кадерле вакытның бушка әрәм булуына үкенеп куйды. Җитмеш алты хәзер аның өчен бик гадәти сан булып, хәтта бөтенләй әһәмиятсез сан булып калды.

Анда кинәт үз-үзеннән, үзенең эшләгән эшеннән ризасызлык тойгысы барлыкка килде, гадәттә, кешене алга өндәүче, яңадан-яңа югарылыкка рухландыручы күркәм бер ризасызлык барлыкка килде. «Масая да башлады!» — диде ул, әле генә куануы өчен үз-үзен шелтәләп. Нәрсә ул җитмеш алты гектар? Ә чәчәсе никадәр! Аны бит әллә кем килеп чәчмәс, барыбер аларга чәчәргә туры киләчәк.

## XIX

Барый белән Гөлбиби килеп җиткәндә, Һарун инде икенче мәртәбә ял итеп алган иде һәм иртәнге җитмеш алты гектар да, үзенең куанычы да, ризасызлыгы да — барысы да инде онытылып беткән иде. Шуңа күрә бригадирның рәхмәт сүзләре аңа бөтенләй диярлек тәэсир итмәде. Мактау сүзләренә ул, гадәттәгечә, бик тыныч көе калды. Шулай ук бригадирның ниндидер ят кыз белән килүенә дә ул бөтенләй битараф шикелле күренде. Бары тик Мансур, пышылдап: «Кара, нинди матур бу казакъ кызы!» — дигәч кенә, ул кызга күтәрелеп карады да, үзалдына: «Чынлап та!» — дип куйды.

— Бу кызны сездә калдырырга туры килер, — диде бригадир, аларны Гөлбиби белән таныштыргач.

— Шулаймыни? — диде Һарун.

— Яңа чәчкечләр кайтты. Өченче агрегат җибәрәбез, — диде Барый.

— Өченче?! Безгә ярдәмгә?

— Ник ярдәмгә? Бөтенләйгә, үзебезгә!

— Ник соң, алайса, бу кызны шунда куймыйсың? — диде Мансур, тынычсызланып.

— Ярамый, — диде бригадир. — Аның беркайчан да чәчү чәчкәнне күргәне юк...

— Әһә! — диде Мансур. — Тәҗрибәсез кешеләрне өйрәнергә безгә бирәләр, тәҗрибәлеләрне өченче агрегатка җибәрәләр... аларны да безнең кебек эшләргә өйрәтергә! Теләсәгез нишләгез, мин моннан китмим.

Мансур әйтерсең бригадирның күңеленә кереп чыкты. Барый чыннан да өченче агрегатка Мансурны алганда яхшы булыр иде дип уйлап куйган иде, чөнки ул таза, карусыз иде, аннары аны хәзер үк чәчкеч җыярга кайтарып җибәрергә дә була иде, ләкин, шул ук вакытта, бердәм-тату коллективны таркату да килешеп бетми иде. Бу беренче агрегатның үзәгендә Һарун булса, Һарун сме-

насындагы чәчүчеләрнең рәсми булмаган башлыгы Мансур иде, һәм сменаның хәтта бөтен агрегатның яхшы эшләве күбесенчә аның тырышлыгына, аның җитезлегенә, өлгерлегенә бәйләнгән иде.

— Ярый, син калырсың,— диде бригадир Мансурга.— Әйт, кемне бирәсең?— диде ул аннары Һарунга.

— Ал әнә Тәзкирәне,— диде Һарун.

Шул чакны ике басу арасындагы сөрелми калган җир өстеннән болайга таба килүче Тәзкирә күренде. Төтен чыгару өчен ул күп итеп коры үлән, әрем җыйган иде.

Ерактан ук барысы да аны көтеп-каршылап алдылар. Тәзкирә, бригадир белән кычкырып исәнләште дә:

— Менә әрем җыйдым әле, Барыйкаем,— диде.— Теңкәне корытты бу черки. Каян чыгалар алар? Әллә соң американнар җибәрәме? Әллә шунда Иртыш буенда берәр яшерен оясы бармы? Берәрсенең корткычлык эшедер бу, билләһи газим! Син дә йөрисең бригадир булып, Барый җаным, Мәскәүгә шалтыратып бер атом бомбасы гына ташлатасы бар ояларына.

— Телеңә салынма, китер әле тизрәк!— дип кычкырды Мансур.

Ул Тәзкирә кулындагы бер кочак чүп-чарны тартып алды да юл читендәге учакка илтеп салды. Учак, күрәсең, сүнеп бетмәгән иде — бераз вакыттан көчсез генә шыртшырт килгән тавыш ишетелде, һәм күперенке үлән, әрем челтәрен үтә-сүтә тишеп, югарыга әчкелтем-зәңгәрсу төтен күтәрелә башлады. Барысы да, черкидән качып, төтен тирәсенә җыелдылар.

— Әнә таныш бул, безгә яңа кеше килде,— диде Мансур, Тәзкирәгә эндәшеп.

Тәзкирә күз кырые белән генә Гөлбибигә карап алды, коры гына исәнләште, ләкин аның кем булуы турында да, ни өчен килүе турында да төпченеп тормады. Шулай да аны безгә килде дигән сүзләр шиккә төшерде, ахрысы.

— Ник килгән безгә? Кунаккамыни?— диде ул, Барыйга карап.

— Бу вакытта кеше кунакка йөримени? Эшкә килгән,— диде Мансур.— Сине өченче агрегатка җибәрәләр. Ишеттеңме — яңа чәчкечләр кайткан.

— Ишетмәдем шул, Мансуркаем, әрем җыйганда беркемне дә очратмадым,— дигән булды Тәзкирә. Аннары ихахайлап үз-үзенә әйтеп куйды: — Үзем генә әрем арасында йөргәндә, ичмасам, адашып булса да берәрсе килеп чыкмый.

— Әйе,— диде бригадир, аның юк-бар сүзләренә игъ-

тибар итмичә.— Сине өченче агрегатка күчерергә туры килер, Тәзкирә.

Тәзкирә Мансурның сүзләрен бик үк аңлап җитмәгән иде бугай. Хәзер ул аңлады һәм шатлыклы елмаюы аның шундук юкка чыкты, нуры качкан саргылт йөзенә кинәт кан бәрде.

— Ниткән сүз бу?— диде ул, аптырап.— Бер җирдән икенче җиргә куалап йөртергә... Кем дип белдегез мине? Инде әйбәт кенә эшләп яткан җирдән... рәтләп йокламыйбыз, көн-төн аяк өстендә. Ю-ук, беркая китмим мин моннан! Сүзем сүз — китмим. Инде йөзәр гектар чәчә башлагач та ошамаган икән.

Бригадир сүзсез генә аның сүрелүен көтеп торды. «Менә нинди болар! Берсеннән берсенең аерыласы килми. Бөтен бригада шундый булса!»— дип уйлады ул күңеленнән.

— Туктале, аңлатканны көт,— диде ул Тәзкирәгә, җайлап кына.— Сине беркем анда куалап җибәрми. Мин сине анда күчерәм, шулай кирәк булганга күчерәм. Син хәзер монда эшнең рәтенә төшендеңме?

— Төшенмәгән кая ул!— диде Тәзкирә, чак-чак кына масаю белән.

— Шулай булгач, яңа агрегатка тәҗрибәле кешеләр кирәк. Булдымы?

— Син анда тәҗрибәсез яшьләрне өйрәтерсең,— диде Мансур.

Мансурның үзеннән көлгәнлеген Тәзкирә, билгеле, бик яхшы аңлады, шулай да мондый сүздән аның шундук авызы йомылды.

— Шулаен шулайдыр да, Мансуркаем,— диде ул, бирелә башлап.

— Кыскасы шул: хәзер син бригадага кайтырсың,— диде Барый, катгый итеп.— Мансур дөрес әйтә, монда ничек эшләгән булсагыз, анда да шулай ук эшләрсез. Өйрәтергә кирәк икән, өйрәтерсең, күрсәтерсең. Сез монда әнә йөзәр гектар чәчәсез, анда да йөзәрне чәчәрсез!

— Йөз дигәч тә, анысы инде аның болай гына әйтелә, Барыйкаем,— дигән булды Тәзкирә, күңелләләнеп.

— Йөз булмасын, җитмеш-сиксән булсын!— диде бригадир.— Булдымы?

— И, булмаган кая инде ул, Барыйкаем!— диде Тәзкирә, кинәт балкып китеп.— Нәрсә, хәзер үк кайтып китимме, әллә үзең алып китәрсеңме?

— Көтеп тор, сөрүчеләр янына барып әйләнәм дә алып китәрмен.

Бригадир китеп баргач, Тәзкирә учак читендәге әрем-

нәрне уртагарак өеп куйды да кыюсызланып бер кырыйдарак торган Гөлбибигә эндәште:

— Кил, якынрак кил, җолдас,— диде.— Син соң бөтенләйгәме инде дигәндәй. Син инде минем урынгадыр... Өйрәтүен болар өйрәтер, мин инде синең белән азапланып тормам, җолдас.

Гөлбиби бер-берсенә нык сыенып утырган тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды да учак янынарак килде.

— Менә далагызны сөреп-чәчеп бетерәбез, җолдас,— диде Тәзкирә, сөйләнүеннән туктамыйча.— Килеп тә карамыйсыз, ичмасам. Бер дә җан дигән нәрсә юк икән үзегездә, илаһым.

Теленә ни килде шуны сөйләнгәләп утыра торгач, ул ничектер серле генә итеп башта Мансурга, аннары Рәшидә йоклап яткан ясалма чатыр ягына күз ташлап алды, аннары шаулатып «уф!» дип көрсенеп куйды да, уенынчынын бергә кушып:

— Ну мут та соң үзегез дә!— диде.— Беләм мин сезне! Тәзкирә апаларыннан котылмакчы булганнар. Бер күрүдә кызый башларын әйләндереп тә өлгергән мәхәббәтсезләрнең... Берсенә берсе, икенчесенә монысы — пар да килгәнсез инде үзегез дә, илаһым!

Гөлбиби аның сүзләрен аңламады, ләкин Тәзкирәнең үзенә карап-карап алуы буенча, аның үзе турында нindider гайбәт сатканлыгын шәйләми булдыра алмады. Ул, уңайсызлангандай итеп, кысык күзләрен түбән иде.

— Әнә кып-кызыл булды!— диде Тәзкирә, Гөлбибигә күрсәтеп.

Һарун, Тәзкирәнең дөрес әйткәнлеген-әйтмәгәнлеген белмәкче булган кебек, Гөлбибинең йөзенә игътибар беләнрәк карады. Гөлбиби кызармаган иде, ләкин аның яшь сылу йөзендә оялчанлык нуры балкый иде. Мондый нурдан Һарунның кинәт күзе чагылгандай булды. Тиз генә ул күз карашын читкә борды, ләкин шул ук секундта аның тагын ят кызга карыйсы килеп куйды, һәм ул, сынап, җентекләп, яшертен генә янә дә дала кызына күз төшереп алды.

## XX

Барый чәчелгән, сөрелгән җирләрне тиз-тиз генә үлчәде дә ашыгып кирегә борылды. Юл уңаенда ул Һаруннар янына тукталды; озын аяклы таягын җитез атлатып, Вәгыйзь җирен дә үлчәп чыкты, ләкин исәпләп-нитеп тормады — Тәзкирәне утыртты да, пыр туздырып, бригадага чапты.

Бригада «авылына» бер яктан ул килеп керде, икенче яктан ят машина — «ашыгыч медицина ярдәме» машинасы килеп керде.

Ят машинадан ак халатлы кешеләр төште. Алар арасында Рәйханә апа да бар иде.

— Менә килеп тә җиттек,— диде ул.— Галимулла абзыйдан дизентерия табылды. Теге егетегез барып җиткән. Анда да шул ук нәрсә булуы мөмкин.

— Ул дизентерияне монда гына, өйдә генә дәвалап булмыймы соң?— диде Барый, үз кайгысын кайгыртып.

Рәйханә апа көлеп кенә куйды.

Ак халатлы кешеләр бригаданың астын өскә әйләндерделәр: вагоннарны, чатырларны, кешеләрнең урын-җирләрен, кухняны, ашау-эчү, юыну-йөрү урыннарын — бөтен җирне хлорлы известь белән дизенфекцияләп чыктылар. Мондагылар белән эшен бетергәч, санитария фельдшеры, үзләренең машинасына утырып, басуга, төнә-куна ятып эшләүчеләр янына китте.

Рәйханә апа белән санитария врачы «авылда» торып калды. Рәйханә апа Барыйга кешеләрне җыярга кушты, һәм санитария врачы — яшь кенә бер казакъ егете дизентерия турында кыска гына лекция-әңгәмә уздырды.

Шуннан соң Рәйханә апа сөйләде. Идеаль чисталык булдыру өчен сезнең монда тиешле шартларыгыз юк, әлбәттә, диде; ләкин шуңа да карамастан кеше үзен һәркайда кеше итеп сизәргә, нинди генә шартларда булса да, иң гади гигиена кагыйдәләрен сакларга тиеш, диде; моннан соң сезгә бу мәсьәләгә аеруча нык игътибар итәргә туры киләчәк, диде; шундый күңелсез хәлләр булмасын өчен, бригадада санитар пост оештырырга кирәк, диде; ул бригадада чисталык саклауны күзәтеп торыр, кирәк икән, беренче ярдәм күрсәтер, киселгән, яраланган җирләрегезне бәйләр, диде.

Рәйханә апаның мондый тәкъдиме һәркемгә ошады. Эш вакытында төрле хәлләр булгалый, әле кул киселә, әле күзгә чүп керә иде. Шундый чакта нәкъ менә шушындый «санитар пост»ның юклыгы сизелә иде. Ә бригадага бирелгән «аптечка» күптән инде таралып, таланып беткән, һәм аның өчен чынында беркем дә җаваплы түгел иде.

— Фәридәне куярга кирәк,— диделәр егетләр, беравыздан.

Үз исемен ишетеп, Фәридә шундук башын түбән иде. Иптәшләренең үзенә шундый ышаныч күрсәтүләренә аның күңеле җилкенеп куйды. Аның, көттереп-нитеп тормыйча, мин риза, дип әйтәсе килде, ләкин мондый

ашыгычлыкның әдәпсезлек булып исәпләнүе мөмкин булганга, ул тыйнак кына көтеп утырды.

— Үзе аш пешерүче дә булгач, бик яхшы,— диде Рәйханә апа, Фәридә кандидатурасын хуплап.— Ашарга утырганда кулын-битен юмаган кешегә аш бирмәс, бар әле, башта юынып кил, дияр. Медик кеше әйткәнне тыңламый хәлең юк! Медикларның законы үзләре белән! Кем нинди авыру белән авырый — аңа әйтерсез. Ул сезгә бинт, мамык бирер. Мин аны өйрәтермен, кайбер дарулар калдырырмын. Тагын шушындый эч китүләр була икән — шундук миңа хәбәр итәр. Авыр булмас бит, сеңелем?

— Булмас,— диде Фәридә, үзенең ризалыгын белдереп.

Аның мондый күндәмлеген күреп, егетләр тагын да үстереп җибәрделәр.

— Булдыра ул безнең Фәридә!— диделәр.— Хәзер сиңа ак халат кына кирәк инде.

— Дөрес,— диде Рәйханә апа.— Фәридәгә болай да ак халат тиеш. Моны менә иптәш бригадирның колагына киртеп куярга кирәк.

— Ярый, карарбыз,— диде Барый.

— Карарбыз гына түгел, кирәк, тиеш,— диде Рәйханә апа, нык итеп.

— Булды. Карамабыз — эшләрбез!— диде Барый.

— Вакытыгыз сыйдырса көн дә чатырларны, вагоннарны тикшереп чыгарга була,— диде Рәйханә апа, өйрәтүен дәвам итеп.

— Староста белән бергәләп!— диде кемдер.

— Староста ярдәм итсә, тагын да яхшырак булыр,— диде Рәйханә апа, аларның шаяртуын аңламыйча.— Староста гына түгел, барыгыз да ярдәм итәргә тиешсез.

— Итәрбез, итәрбез!— диделәр кешеләр, тизрәк таралышырга ашыгып.

Медицина кешеләрен озаткач, Барый үз бүлмәсенә керде, иңбашындагы сумкасын салып ташлады да лампага ут кабызды. Аның әле үлчәнгән җирләрне исәплисе, бланклар тутырасы бар иде.

Иң элек ул чәчүчеләр җирен исәпләде. Наташаныкы алтмыш гектар чыкты. Вәгыйзьнеке алтмыш биш булды. «Шулай да Һарунга җиткерә алмыйлар»,— дип уйлады бригадир, һәркем шулай эшләсә, һәрбер смена, һәрбер агрегат шулай чәчсә... Ул чагында... Ул чагында бригада чәчүне иң беренче булып тәмамлар иде! Беренче булып! Башкалар аныңча эшли алалармы? Алалар. Һичшиксез, эшләргә тиешләр! Эшләтергә кирәк. Бик кирәк!

Үз бригадасын аның беренче итеп, һәр яктан беренче һәм алдынгы итеп күрәсе килде. Ул шулай уйланып утырганда, әкрен генә ишек шакып, бүлмәгә Фәридә килеп керде.

— Барый абый,— диде ул, ничектер үпкәләгән сыман.— Сез бит бүген бер җиргә барырга тиешсез.

— Кая?— диде Барый.— Ә, балыкка! Ярый әле искә төшердең — мин инде онытып та бетергән идем.

— Шулаймыни, Барый абый?— диде Фәридә һәм бер дә юктан көлеп куйды.

— Ник көләсең?— дигән булды бригадир, юри хәтере калып.

— Болай гына, Барый абый,— диде Фәридә.— Кайчагында минем шулай гел көләсем килә.

— Күңелең күтәренке чактамы? Кызык, нилектән күңелең күтәренке икән синең?

— Минем күңелнең төшенке булганы юк,— диде ул.— Нилектән дип... менә балыкка барасыз...

— Шулай микән?!— дигән булды бригадир. Фәридә чыгып киткәч, ул сумкасын яңадан иңбашына киде, акчасын санап карады һәм, утын сүндереп, ишеген бикләп тышка чыкты. Кузгалып киткәнче ул иң әүвәл чәчкеч җыючыларның хәлен белеште. Бер чәчкеч инде җыелып беткән иде, ләкин әле икенчесенә беркем тотынмаган иде.

— Ислам кая?— диде ул Андроновка.

— Суга китте бугай,— диде Андронов.— Мин хәзер ашап алам да кузгалам.

— Булды. Илгизгә әйт, Ислам кайтканчы икенчесенә тотынсыннар. Мине Көктугайга чакыралар. Хәзер кайтып җитәрмен,— диде бригадир һәм, артык сөйләшеп тормыйча, китеп тә барды.

Бер биш-алты минуттан ул бригаданың иске урынына барып җитте. Ислам коедан су алып ята иде.

— Карале,— диде Барый, тыелып кына,— нәрсә бу, су кытлыгы башландымыни бездә? Иртән дә килгән идең түгелме соң?

— Сорагач, мин нишлим?— диде Ислам, бәндәгә бәндә кеше сыман, юаш кына.— Мин үзем эчеп бетермим инде аны, Барый.

— Ярый, алып кайт та, икенче чәчкечкә тотыныгыз. Мин хәзер кайтып җитәрмен.

— Сөйләштек бит инде, Барый,— диде Ислам, килешүчән тонда.— Син кайтканчы әзер булыр.

Аның шулай күндәм генә сөйләшүе Барыйда никтер шик тудырды. «Эх, юкка барам, ахрысы!»— дип уйлады

ул, күңеленнән. Иң кирәге хәзер нәрсә — балыкмы, чәчкечме? Каян уйлап тапты соң әле бу Фәридә? Ләкин бер юлга чыккач, хәзер инде кире борылу килешмәс шикелле тоелды, һәм тагын ул үзен Көктугайга чакырулары турында, озакламый әйләнеп кайтачагы турында әйтте дә янә кузгалып китте.

## XXI

Маякчы йортының кайдалыгын Барый алдан ук чамалап барды. Иртыш үзәнлегенә төшеп, бер өч-дүрт чакрым чамасы баргач, юлның ике ягында да таллыклар, вак-вак куаклыклар очрый башлады. Куаклыкларны узып киткәч, юл икегә аерылды, һәм Барый, үзенең хәтеренә һәм Фәридәнең әйтүенә ышанып, бернинди икеләнүсез уңга борылды. Бик үк тапталмаган тар гына иске юл аны озакламый Иртыш яры буена алып чыкты.

Яр буеннан әчкелтем төтен исе килде, чит кешене сизенеп, шундук эт өреп җибәрде, һәм күз ачып йомган арада караңгылык эченнән очлаеп бер йорт түбәсе калкып чыкты, ә сул якта, болынлыкта, ниндидер ат кешнәп куйды.

Барый, яр буендагы йорт янына килеп җитәр-җитмәс туктады да, як-ягына карангалап, сукмак буенча сак кына алга атлады. Эт әллә бик карт иде, әллә бик ялкау иде — чит кеше якынаю белән, өрүеннән үк туктап калды һәм, яткан җиреннән дә тормыйча, Барыйны ишеккә кадәр уздырып җибәрде.

Ишек эчтән бикле түгел иде. Барый керосин лампасы белән яктыртылган тәбәнәк кенә, кысан гына бер өй эченә килеп керде. Кечкенә өстәл янында ике ир кеше утыра иде. Аяк астында, идәндә, сузылып, берничә бала белән хатын-кыз затыннан булган бер-ике олы кеше йоклап ята иде.

Ир кешеләрнең берсе яшьрәк, икенчесе картрак иде. Яшьрәге табак битле, зур такыр башлы һәм ике якка салынып төшкән озын нечкә мыеклы казакъ агае, күрәсең, йортның хуҗасы иде. Ул көлмәкчән генә иде һәм, көлмәк изүләрен чишеп җибәргән көе, җәелеп, иркенәеп утыра иде. Аның янындагы картның исә башындагы бүреге дә, кыска сырмасы да салынмаган иде, аннары кулына ул камчы тоткан иде. Шуңа карап аны әле генә атка атланып килгәндер дип уйларга була иде. Гомумән, аның монда чит кеше икәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде.

Бу Байболат карт иде. Гөлбибине очратмыйча, ул күптән түгел генә Камыскүлдән кайтып төшкән һәм менә

хәзер шул кайгысы белән дусты Әлембайга килеп чыккан иде.

Килеп кергәч тә, Барый кычкырып сәлам бирде, аннары үзенең кем икәнлеген әйтте.

— Җаксы, түргә уз, җолдас,— диде хуҗа, урыныннан кузгалгандай итеп.

Барый, хуҗаның сүзләрен туры мәгънәсендә аңлап, бер-ике адым алгарак атлады, кыю гына кыланып, шундагы бер сандык өстенә килеп утырды. Шуннан соң ул үзенең нинди йомыш белән килүен аңлатып бирде. Хуҗа да, Байболат карт та берни эндәшмәделәр.

— Даланы җыртасызбы? Бидай чәчәсезбе?— диде Әлембай, җавап урынына сорау биреп.

Аның шулай сүзне бөтенләй икенче якка каеруы Барыйның эчен тырнап куйды. Шулай да ул, тыелып булса да, җавап бирде, сөрәбез, чәчәбез, диде; йомшармаслармы дигән бер өмет белән, көзгә үзегезне бодай күмәче белән сыйларбыз, дип тә куйды. Ләкин хуҗа, андый вәгъдәгә әз генә дә исе китмичә, авыр, йомры башын чак-чак кына иеп, таш сыңдай һаман тынып утыруында булды.

— Ничек, булырмы?— диде Барый, түземлеген җуеп.

— Асыкпа, җегетем,— диде Әлембай, тыныч кына.

— Ашыкмыйча, минем бит кайтасым да бар. Булса, әйтегез дә, булмаса — хушыгыз!

— Отыр, отыр,— диде хуҗа, җанлану әсәре күрсәтеп.— Балык бар. Канча кирек, сонча табылат. Иртыш үзебездеке. Иртышты җыртып болмайды.

— Шулай булгач?

— Канча сом бирәсең?— диде Әлембай, аягына басып.

«Менә нәрсәдә икән хикмәт»,— дип уйлады Барый һәм, хуҗаның үзе кебегрәк итеп:

— Канча сорыйсың, сонча булыр!— диде.— Акча үзебездеке, орлап алган түгел. Әлембай елмаеп җибәрде.

— Ой-бой, нугай болса да, җаксы болады экән!— диде, мактау белдереп, һәм телен шартлатып куйды.— Балыктың киласы он сом.

— Була. Китер балыкны,— диде Барый, биленә буган капчыгын чишеп.

Хуҗа тәмам ачылып китте. Иртыштан, Иртыш буендагы күлләрдән балык тоту, маякчы хезмәтеннән кала, аның төп кәсебе иде. Моңарчы ул Көктугай халкын яңа тотылган балык белән тәэмин итеп торды. Ләкин Көктугай Камыскүлгә күченеп киткәч, аның бу эше тукталып калды. Яңа совхоз оешу аның өчен менә шушы яктан зыянлы булып чыкты. Совхоз кешеләреннән әле беркем-

нең дә моңа кадәр балык сорап килгәне булмады. Менә беренче адамдары килгән. Бер кило, ике кило да сорамый, күпме булса, шулкадәр алмакчы була. Бәясенә дә сатулашып тормый. Әлембай унике, хәтта унбиш сум сорамавына үкенгәндәй итеп куйды, ләкин әйтеләсе сүз инде әйтелгән иде, һәм ул хатынын уятты да, аңа нидер пышылдагач, Барыйга карап:

— Кумыз эшәсеңбе?— диде.

— Була, эчәм,— диде Барый.

Хатын тавыш-тынсыз гына торды, тавыш-тынсыз гына чыгып китте. Бераздан ул зур гына ак җамаяк белән кымыз алып керде. Салкынча әчкелтем эчемлекне Барый бер күтәрүдә эчеп бетерде.

— Рәхмәт,— диде ул, кәефләнеп.

Ул кымыз белән булашкан арада, хуҗа койрыкларыннан сулары агып торган зур-зур дүрт чуртан алып керде.

— Менә бөген генә тоткан,— диде ул, үз товарын мактап.

Барый балыкларның ничә кило булуын, күпме акча тиешлеген сорады һәм, хуҗа үз сүзен әйткәч тә, кесәсеннән бер йөзлек чыгарып, шундук исәп-хисапны да өзде. Аннары тыпырчынган, елкылдап торган шома, авыр балыкларны бер-бер артлы капчыгына шудырды.

— Ярый, хушыгыз. Рәхмәт,— диде ул, саубуллашып.

— Тагын кил,— диде Әлембай.— Балык күп миндә.

— Килермен,— диде Барый.— Болай булгач, килербез! Ярый, хушыгыз.

— Хош, хош.

## XXII

Совхоз бригадиры Әлембай белән сөйләшкәндә дә, йотлыгып кымыз эчкәндә дә, ниһаять, балык сатулашканда да Байболат берни эндәшмәде — төнге кунак килеп кергәндә нинди кыяфәттә булган булса, һаман шундый ук кыяфәтендә кала бирде. Барыйга ул бары әледән-әле кырын күз карашы гына төшереп алды һәм аның һәрбер сүзен, һәрбер кыланышын аеруча бер киеренкелек белән, ачу, хәтта дошманлык белән тыңлап-күзәтеп утырды. Барый ишеккә таба борылгач кына, ул җан әсәре күрсәтте — әкрен генә башын борып, аның аркасына карады, ләкин шулай да кунакның саубуллашу сүзенә җавап кайтармады.

Хуҗа кунакны озата чыккач, Байболат кинәт тынычсызлана башлагандай булды, кысык күзләрендә ят бер очкын кабынып китте, авызыннан нindидер мыгырдану

авазлары ишетелде. Көтмәгәндә ул урыныннан торды, кулындагы камчысын кырт кына селтәп алды да ишеккә ташланды, ләкин тышка чыкмады, кире уйлап, бусага алдында туктап калды.

Әлембайның хатыны әле ятмаган иде. Байболат, пышылдап, ашыгып, аңа нидер сөйләргә тотынды. Хатын баш какты һәм шундук тышка чыгып китте. Чоланда ул шыпырт кына иренә Байболатның үтенечен белдерде. Әлембай аның әйтеп бетергәнен дә көтеп тормады, ут капкандай ашыгып-кабаланып, каядыр китеп барды.

Барый әле кузгалып китмәгән иде, капчыктагы балыкларын мотоциклының арткы утыргычына бәйләп азаплана иде. Искәрмәстән каршысына Әлембай килеп чыккач, ул сискәнеп китте. Инде сатулашып бетергәч, тиешенчә саубуллашу сүзләре әйтеп аерылышкач, аның яңадан килеп җитүе бригадирга гаҗәбрәк булып тоелды. «Нәрсә кирәк икән инде моңа тагын?» — дип уйлады ул, ошатмыйча.

— Әлдә бәйләп болмайбы?— диде Әлембай, ялагайланган сыман.— Бау кирәкле? Үзеңдеке бармы?

— Бар, рәхмәт,— диде Барый, караңгыда аның кыяфәтен аерырга тырышып.

— Ә, бар болса, ярайт...— диде Әлембай һәм, бүтән әйтер сүз таба алмыйча, тынып калды.— Сапкуз акчаны көп бирә сездең,— дип куйды ул кинәт кенә.

Тик торганда аның шулай сөйләнүе Барыйга тагын да гаҗәбрәк тоелды. «Әллә тиле-миле инде»,— дип уйлады ул үзалдына. Әлембайга ул җавап кайтарып тормады, капчыгын бәйләп бетерде дә кыегаебрак торган мотоциклын турайтып бастырды.

Болай гына сөйләнгән шикелле, Әлембай тагын сорап куйды:

— Бригадада мөселмандар гынабы, әллә орыстар да бармы?— диде.

«Монысы тагын нигә инде?— дип уйлады Барый, әле булса хуҗаның тел төбен сизенә алмыйча.— Бик динле кеше микәнни?— диде аннары үзалдына.— Мин тоткан балыкны мөселманнар гына ашасын, каферга ризык булмасын дип әйтмәкче була микәнни?»

— Төрлесеннән бар,— диде ул Әлембайга.— Мөселманнар да, орыстар да...

— Казакътан җокпы?— диде Әлембай һәм кинәт сагаеп тынып калды.

Барый, аны-моны абайламыйча:

— Бар,— диде.— Бүген генә бер казакъ кызы килде әле. Камыскүлдән диме...

— Җаксы, җаксы,— диде хуҗа, башын селкеп.— Хош. Җолың оң болсын. Тагын кел. Балык миндә күп болады.

Барый соңгы кат саубуллашты да кузгалып китеп барды.

Аның тизрәк бригадага кайтып җитәсе, Фәридәне, Фәрханә апаны сөендерәсе килде. «Нәрсә дип әйтерләр икән?»— дип уйлады ул, шулкадәр күп балык күргәч аларның ничек шатланачакларын күз алдына китереп. Аннары аны иртәнге ашка кыздырырга микән, әллә көндезгегә калдырырга микән дигән мәсьәлә кызыксындырып куйды.

Иртыш үзәнлеген үтеп, Көктугайга килеп менгәнче, ул шундый нәрсәләр белән юанып кайтты. Бераздан балык та, Әлембай да, аның белән булган сәер сөйләшү дә әкренләп онытыла барды.

Бригадага ул төн урталарында кайтып керде. Каршыда таныш вагоннар, чатырлар калкып чыкты, мотоцикл фарасы ярып үткән якты ачыклыкта таныш нәрсәләр: ниндидер тимер-томырлар, солидол мичкәсе һәм ике метр озынлыгындагы юан-юан агачлар күренеп калды. Чәчкечләр җыелып беткән булырга тиеш иде, ул якта берни күренми иде.

Барый үз вагоны каршысына килеп туктады да бәйләнгән капчыгын чишеп алды. Авыр, шома балыкларны яңадан үз кулында тою анда үз-үзеннән канәгать булу тойгысы, сөенеч тойгысы уятты. Ул, капчыгын кул очына гына тотып, кухня чатырына юнәлде. «Хәзер уятырга кирәкмәс, йокласын»,— дип куйды ул Фәридә турында. Иртәгә иртән уянып киткәч күреп алыр әле үзе.

Чатыр янына килеп туктагач, аңа анда кемдер бар шикелле тоелды.

— Кем ул?— диде бригадир, беркадәр тыңлап торгандай иткәч.

Эчтә кемдер куркып ыһ! диде һәм кисәк кенә тынып калды. Барый капчыгын шапылдатып җиргә ташлады, чатыр ишегенең каптырмаларын ычкындырды да соравын кабатлап:

— Кем ул?— диде.

— Мин... Мин бу. Фәридә...— диде җир идәндә яткан кеше, үксеп, тотлыгып.

— Ни булды? Ник җылыйсың?— диде бригадир, аптырап.

Фәридә җавап бирмәде.

— Менә сиңа балык алып кайттым,— диде Барый һәм җирдә яткан капчыкка тибеп алды.

Фәридә тагын җавап кайтармады.

Барый, нишләргә дә белмичә, баскан урынында катып торды да:

— Кара, исләнмәсен!— диде.

Фәридә монысында да эндәшмәде. Караңгыда аның озын итеп көрсенеп-сулкылдап куйганы ишетелде. Бригадирның кинәт дәрте сүнде, кәефе кырылды. Нәрсә булганын төпченеп торырга аның хәзер нишләптер кыюлыгы җитмәде, һәм, башына суккан кебек, ул күңелсез генә китеп барды.

## XXIII

Чәчкеч артына басып йөрү Гөлбибигә бер дә авыр булмады. Беркайчан да мондый эштә эшләмәгәнгә, гомумән, мондый нәрсәне күргәне-белгәне булмаганга, бу аңа бик кызык, бик күңелле булып тоелды. Шундый күңелле булып тоелды, ул моны хәтта эшкә дә исәпләмәде.

Нинди эш булсын инде бу! Бодай болгатып барырга, тегеңә-моңа суккалап алырга кем дә булдыра ала. Тик менә тузаны гына эчне пошыра да, аннары — караңгы. Кап-караңгы. Берни күренми. Бу як дала аңа таныш, бик таныш. Бу бит аларның элекке көтүлекләре. Күрәсе иде хәзер шул көтүлекләрне, күрәсе иде элекке ямь-яшел даланы!

Юк, кирәкми даласы да, көтүләре дә... берсе дә кирәкми. Камыскүлнең дә, берсенең дә кирәге юк. Гомергә күрмәсә дә үкенәсе юк. Әкәсе белеп әйтә. Әкәсе... Ә менә кызының өйгә кайтмый йөрүенә, җитмәсә, дала бозып йөрүенә ул нәрсә әйтер?! Кадалып кит, моннан соң син минем кызым түгел, диярме, күземә күренәсе булма, диярме? Шулай дияр...

Әйтсә әйтер! Камыскүлгә генә түгел, ул хәзер Иртыш буена да кайтмаячак. Теләсә нишләсеннәр. Ул монда кайтырга килмәде. Ул монда бөтенләйгә килде. Нишләп ятсын ул анда урман эчендә, нишләп берүзе көтү көтеп йөрсен? Көтсен әнә Алтынбай... ялганчы Алтынбай...

Камыскүлгә ул чынында аны күрәсе килеп барды. Ул аны сагынып барды. Ләкин Алтынбай аны бөтенләй сагынмаган булып чыкты. Аны күреп, үзенең сөйгән кызын күреп, әз генә дә куаныч белдермәде. Гөлбибинең, билгеле, моңа хәтере калды, шундый нык хәтере калды, үз-үзен кызганып хәтта елыйсы килеп китте. Ләкин еламады, үпкәләргә, ачуланырга тотынды. Ул шунда Алтынбайның бүтән чакта күрсәткән салкынлыкларын исенә төшерде, Иртыш буена күченеп китәр алдыннан Камыскүлдә калырга димләмәвен дә, күченеп килгәч исә

урманга бер генә мәртәбә килеп чыкмавын да исенә төшерде. Бер ачуы ташыгач, бер дә аптырап тормады, сипте генә, сарыклар арасында ятып, син сарыкка әйләнеп беткәнсең, диде, Алтынбай түгел син, Сарыкбай, диде.

Алтынбайның да хәтере калды, ачуы килде. Ничек кенә килде әле!

Икенче көнне аларның көтүеерактагы көтүлеккә күченеп китте. Алтынбай бу турыда Гөлбибигә әйтмәгән иде. Аның шулай сиздермичә китеп баруын ишеткәч, Гөлбиби нәрсә уйларга да белмәде. Ул һич тә моны көтмәгән иде. Күңеленнән ул инде аны күптән гафу иткән иде, күптән инде аның белән татулашырга әзер иде. Ләкин алар, шулай итеп, яңадан күрешмәделәр дә, татулашмадылар да.

Гөлбибинең хәзер Камыскүлдә дә каласы килмәде, Иртыш буена да кайтасы килмәде. Аның инде кыш көне дә бервакытны йөрәге җилкенеп куйган иде. Аның да читтән килеп тулган шул чая, шат кызлар, егетләр кебек буласы килә иде, алар кебек такта вагоннарда торасы, алар кебек машина, трактор тирәсендә кайнашасы килә иде. Бу әле теләк тә, омтылыш та түгел, бу бары кызыгу, көнләшү шикелле бернәрсә генә иде. Аннары үзенең туган йортын ташлап китәргә торганда, моның нинди дә булса теләк-омтылыш булуы да мөмкин түгел иде. Хәзер... хәзер инде эшләр башкачарак. Хәзер инде аның күңелендә икенче төрле давыл котырына.

Артык уйлап тормыйча, ул очраган беренче машинага утырды да таныш юлдан туган авылына китте дә барды. Бу шундый тиз, шундый искәрмәстән булды — ничек итеп үзенең монда килеп төшүен дә, ничек итеп ят, чит эштә эшли башлавын да ул әйтерсең үзе дә сизми калды. Бу аңа төштәге сымаграк булып тоелды. Аннан соң ул үзендә артык читләшү тойгысы да сизмәде, чөнки ул үзен барыбер туган җирендә итеп, туган йортында, туган даласында итеп хис итте.

Баштарак үзен бик җиңел сизсә дә, төн урталарыннан соң Гөлбибинең йокысы килә башлады. Ул инде уйланмады да, хыялланмады да. Ул хәзер бөтен игътибарын икенче нәрсәгә юнәлтте, ул хәзер аяк өсте йоклап китә-нитә күрмим дип, чәчкечтән төшеп калмыйм тагын дип кенә барды. Ә берзаман ул шундый йончылды, шундый хәлсезләнде — нәрсәгә булса да карау, нәрсә булса да эшләү түгел, хәтта тотынып барырга да көченнән килми шикелле тоелды. Беренче көнне үк сер сынатуның үзе өчен нинди хурлык булачагын ул

бик яхшы аңлады һәм ничек кенә булса да бирешмәскә тырышты.

Беркадәр вакыттан соң, аның урынына икенче кыз килеп басты. Аңа капчыкларга төренеп йокларга куштылар, һәм ул шундук җиргә ауды. Күпмедер вакыттан соң аны яңадан уяттылар, яңадан чәчкеч артына басарга куштылар. Хәзер инде ул бөтенесен белеп, аңлап эшләде, күзләрен ачыбрак, игътибар беләнрәк карады.

Төн аңа коточкыч озын булып тоелды. Таң аттыра алмый ул азапланып бетте. Иртән смена бетеп, үз-үзен ирекгә сизгәч, аның өстеннән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Үзенең дә бүтәннәр кебек эшли алуы өчен күңеленнән ул сөенеп бетә алмады. Туган дала, сөрелгән, чәчелгән һәм бигрәк тә үзе чәчкән дала аңа хәзер элекке яшел далага, көтүлек даласына караганда да якынрак, кадерлерәк булып тоелды, һәм юл читендәге ясалма чатыр янына килеп утыргач та, ул әледән-әле бер якка — төнлә үзе чәчеп калдырган «үз җире» ягына карап-карап алды.

Ашаганда иптәшләре аннан, ничегрәк булды дип, ошадымы, авыр булмадымы дип сорадылар; йокың килмәдеме, башың авыртмадымы, диделәр. Бер төн эчендә ул үзенең шушы ят кешеләр белән якынаеп-дуслашып киткәнлеген тойды һәм аларга теләп, иркенләп җаваплар кайтарды, җок, җок, авыртмады, җаксы болады, диде.

Иртәнге аштан соң, алар Рәшидә белән бер чатырга керделәр дә, бөгәрләнеп, бер-беренә терәлеп йокларга яттылар.

Ләкин күп тә үтмәде, якында гына таныш тавыш ишетеп, ул искәрмәстән уянып китте.

Чәчүчеләр янына Гөлбибинең этисе килеп туктаган иде. Атланган атыннан төшмичә, ул әллә Һарун белән, әллә Мансур белән сөйләшеп тора иде. Ул сөйләшми дә иде, ул кычкырына иде.

Йокы качты, тынычлык качты, һәм яшь кызның күңелендә мең төрле сорау калкып чыкты. Нишләргә? Кая барырга? Шушында качып калыргамы? Ләкин ничек итеп үз атаңнан качып калмак кирәк? Иртыш буена кайтып китәргә туры килсә, тагын көтү көтәргәме, тагын Алтынбай турында уйлап гомер уздырыргамы? Монда нинди күңелле булган иде! Бәлки, ул аны алырга да килмәгәндер әле. Яхшылап аңлатып бирсәң, бәлки, ул бер сүз дә әйтмәс, ярый, кал инде шунда, дияр, бер каршылыгым да юк, исәнлегеңне белгәч, тынычландым, балам, дияр.

Ни генә булмасын, атасыннан яшеренеп калырга аның йөрәге җитмәде. Иң элек капчыклар арасыннан чыгып килгән ике күн итек күренде, аннары сырган чалбар күренде. Байболат карт чатыр эченнән шуышып чыгып килгән күн итекләргә дә, сырган чалбарга да бөтенләй игътибар итмәде. Өсте-башы тузанга буялган, чәче тузгыган һәм баштанаяк ирләр киеме, ят кием киенгән Гөлбиби үзенең каршысына килеп баскач исә, чак-чак кына артына авып китмәде.

— Ой-бой!— диде карт, шаккатып.

Шуннан башка ул бүтән бер сүз дә әйтмәде, телен шартлатып җиргә бер төкереп алды да, исен-акылын җыя алмыйча, һаман кызының өс-башына каравында булды. Гөлбиби гаепле кеше сыман елмаеп җибәрде, иптәшләре алдында тавыш-гауга чыгудан куркып һәм әтисе белән тизрәк килешергә исәпләп, шундук аңа таба тартылып куйды.

— Кайда өз киемең?— диде Байболат, тыныч бер дәһшәтлелек белән.

— Вагонда калды, әкәм,— диде Гөлбиби һәм, кайда икәнлеген аңлатып, бригада «авылы» ягына күрсәтте.

— Әйдә!— диде карт, усал гына итеп.

Кыз тынып калды, башын иде һәм каш астыннан гына яңа иптәшләренә — тынсыз-өнсез басып торган Һарун белән Мансур ягына карап алды.

— Мин кызметкә кердем, әкәм... Китүгә җарамайды.— Без бидәй чәчәмез, әкәм,— диде Гөлбиби.

Байболат карт камчысы белән кизәнде һәм, ярсуыннан тыела алмыйча:

— Әйдә!— дип кычкырды.— Җөр! Ат койрыгына тагып алып кайтармын!

— Бабай, кызмале син!— диде Мансур, картка якынаеп.— Ул хәзер безнең кеше. Бригадир белән сөйләш...

Карт аңа кырын күзе белән дә карамады, кызына тагын нидер җикеренде дә атын юлга борды. Гөлбиби аның артыннан кузгалды.

— Гөлбиби, китмә! Гөлбиби!..— диде кинәт Һарун.

Кыз туктагандай итте, әйләнеп Һарунга карады, яңадан алдына борылды да, башын иеп, атасы артыннан атлады.

Юл буенда аларны иярле ат көтеп тора иде. Гөлбиби үзенең атын танып алды, атланды, һәм алар — ата белән кыз — аллы-артлы китеп бардылар.

Һарун белән Мансур, аякларын аерып баскан килеш, моңсуланып карап калдылар.

## Алтынчы баб

### I

Артына чәчкечләр таккан, маңгаенда кечкенә кызыл әләм җилфердәгән трактор җир башына килеп җитте дә басулар арасыннан салынган тузанлы киң юлга борылды. Борылды да, чәчкечләргә аркылы төшеп, туктап калды. Арттан күтәрелгән тузан болыты җил уңае белән очып китте һәм әкрен генә, талгын гына җир өстенә сузылып ятты. Тирә-як тып-тын булып, искиткеч тын булып калды. Ләкин колак төбендә әле һаман таныш гөрелте, таныш шау-шу яңгырап торды, һәм шуңа күрә бу иртәнге тынлык, бу сәер тынлык тагын да ныграк көчәйгән сыман булды.

Бүтән көнне бу вакытта смена алышына торган иде — ял иткән кешеләр төнлә эшләгән кешеләр янына киләләр, исәнлек-саулык сорашалар яисә, сөйләшеп-нитеп тормастан, шундук эшкә тотыналар иде: карыйлар, майлыйлар, чистарталар иде.

Бүген исә боларның берсе дә булмады. Алмашка кешеләр килгәне дә күренмәде, шулай ук мондагылар да бернинди ашыгу билгесе күрсәтмәделәр — барысы да бер тирәгәрәк җыелдылар да, дөньяда инде бер генә кайгы-мәшәкатьләре дә юк сыман, иркенләп гәп сатарга тотындылар. Бераздан алар чәчкечләр янына килделәр, иелеп нәрсәнедер борырга, сүтәргә керештеләр. Янәшә куелган чәчкечләрне ычкындырдылар, шул ук чәчкечләрне, икенче төрле көйләп, бер-бер артлы тактылар. Берсе җир өстендә аунап яткан буш капчыкларны алып килде, икенчесе төенчекләрне, кием-салымнарны алып килде — барысын да чәчкеч әрҗәсенә ташладылар да трактор янына йөгерделәр.

Трактор кузгалып куйды. Тын далада яңадан мотор тавышы ишетелде, тимер чыңы һәм каты юлдан сикергәләп йөгергән корыч тәгәрмәчләр дыңгырдыгы ишетелде. Күперелеп арттан җиңел тузан күтәрелде, сызылып-сырланып юл өстендә тирән эзләр торып калды.

Пыяла аша күзен алга текәп, Һарун тын гына баруында булды. Беркадәр киселә, кырыслана төшкән йөзендә һәм кысылып, җемелдәп барган күзләрендә аның әледән-әле моңсулык нуры чагылып китте.

Менә чәчү бетте. Чәчү белән бергә йокысыз төннәр дә, тузан да, хезмәт киеренкелеге дә һәм... рухи яктан үз-үзеңне тулы итеп сизү тойгысы да бетте. Ул бушап калды, кинәт кенә кечерәеп, әһәмиятсезләнеп калды. Үз-

үзен ул ярсып чабып барган чакта кинәт туктатылган чабыш аты кебек хис итте. Аның өчен нәрсәдер югалды, тәүлекләр буена үзен каядыр омтылдырып, җилкендереп торган иң кирәкле, иң кадерле нәрсәсе югалды. Иң якын кешеңнән, иң кыйммәтле әйбереңнән аерылу ни дәрәҗәдә авыр булса, бу аерылу да, бу югалту да аның өчен шул ук дәрәҗәдә авыр һәм газаплы булды. Бу турыда ул уйланмады да, фәлсәфә дә сатмады. Ул моны тойды, бөтен күңеле белән, бөтен йөрәге белән тойды.

Ул түзмәде — тракторын туктатты да, кабина ишеген ачып, гусеница өстенә чыгып басты. Чак-чак кына елмайгандай итте, моңаеп, әле генә калдырып киткән кара җир ягына карады. Анда күзгә ташланырдай берни юк иде, анда да шул ук киңлек-тигезлек, офык читенә барып тоташкан һәм ерактан караганда кайбер җирләре карарак, дымлырак булып, кайбер җирләре аксылрак булып күренгән шул ук басу җәелеп ята иде. Чәчелгән җиргә терәлеп бер якта сөрелмәгән, чәчелмәгән ямь-яшел дала, кыргый дала күренә иде. Һарун авыр гына көрсенеп куйды да:

— Ташлап китәсе килми бит, малай,— диде.

— Валлаһи менә, миңа да шулай!— диде Мансур,— аның җилкәсе аша алга үрелеп.— Нишләрбез икән инде хәзер, ә?

Алар тагын кузгалып киттеләр. Бераздан юлның уң ягында яңа гына шытып-калкып килгән бодай җире башланды. Үрентеләр әле бик кечкенә, бик зәгыйфь иде һәм, бу урында кайчан да булса нык, озын сабаклы, эре башаклы алтын-кызгылт бодай диңгезе чайкалып утырыр дип, әлегә күз алдына китерүе дә кыен иде. Ләкин шулай булуга да карамастан чәчкеч дисклары сызып калдырган эзләрдәге бу зәгыйфь үрентеләр инде бөтен басуны каплап алганнар иде; хәзер инде монда әрем, сарут, кылган түгел, бәлки, алар хуҗа иде, һәм тигез булып җәелгән киң, кара җиргә, шәрә җиргә алар инде үзенә бер төс биреп, ямь биреп утыралар иде.

Кыска үрентеле басу беткәч, алда икенче төрле басу күренде. Ул басуга да бодай чәчелгән иде, ләкин үрентеләр монда озынрак, куерак һәм юка, нечкә сабак очларында инде яшел чырай күренә башлаган иде.

Барган саен юлның ике ягында да шакмак-шакмак итеп бүлгәләнгән киң басулар күренде, барган саен басуларның төсләре үзгәрә торды. Монда әйтерсең кемдер илаһи бер кодрәт белән төрле төстәге, төрле тондагы зурзур, озын-озын паласлар — соргылт, көрәнсу, аксыл-яшькелт һәм куе яшел уҗым җепләре белән чигелгән гаҗә-

еп паласлар җәеп чыккан иде. Бер-берсе белән аралашкан, берсе фонында икенчесе аермачык булып ярылып яткан шул паласлар өстенә иртәнге кояш нуры төшкән иде; яшел җепләр, күзнең явын алып, иртәнге якты һавада елкылдап, җемелдәп торалар иде.

Яшьләр бу гаҗәеп яшеллеккә хәзер исләре китеп карап бардылар. Бу кайчандыр алар сөреп, алар чәчеп киткән таныш җирләр иде, ләкин шул ук вакытта бу бик үк таныш та түгел кебек иде. Аларның күптән инде бу басуларга шулай җентекләп, озаклап караганнары юк иде. Җентекләп, озаклап караганда да, һәр көн саен түгел, хәтта сәгать саен, минут саен үзгәрештә булган, сәгать саен, минут саен яңа күркәмлеген ача барган җанлы табигатьне карап туярга да мөмкин түгел иде, шул көенчә бөтенләйгә истә-хәтердә калдырырга да мөмкин түгел иде. Диңгез кебек беркайчан да ялыктырмый торган киңлек вә хозурлык иде бу.

Шулай бара торгач, кемдер шаккатып:

— Карагыз әле, нәрсә ул?— диде. Һарун үзалдына игътибар беләнрәк карый башлады, ләкин ике якта да җәелеп яткан әлеге уҗым басуларыннан башка бүтән берни күрмәде.

— Ә-ә-әнә, ә-әнә!— диде Мансур, каядыр еракка, бушлыкка төртеп күрсәтеп.

— Ә-ә!— диде кинәт Һарун һәм тын да алмый карап бара башлады.

Юлдан беркадәр уң як юнәлештә, еракта, бик еракта, иртәнге алсу нурлар белән яктыртылган күксел офык читендә искиткеч күренеш барлыкка килгән иде. Анда нindидер яңа уҗым басуы калкып чыккан иде! Ул уҗым басуы шул тирәдәге басулардан да, гомумән, күз күреме җиткән барлык басулардан да бик нык аерылып тора иде. Ул ямь-яшел иде, иң яшел басуларга караганда да яшелрәк иде.

Бик гаҗәп иде бу, бик сәер иде, әмма аннан да гаҗәбрәк тагын икенче нәрсә бар иде әле. Гадәттән тыш яшел басу белән күксел офык тоташкан турыда чүмәлә-чүмәлә булып нindидер каралҗым таплар тезелеп киткән иде. Бер караганда, ул тапларны ерактагы болыт кисәкләре дип, икенче караганда, саман йорт шәүләләре дип уйларга мөмкин иде. Тик шулай да каян килгән анда саман йортлар, каян килгән анда чүмәләдәй вак-вак болытлар һәм нилектән ул болытлар, ул шәүләләр көтмәгәндә кыймылдашып куялар да торган саен зураялар, күбәяләр? Һәм тагын да: каян килгән анда нindидер атлар, сыерлар, озын муенлы зур-зур дөяләр? Әллә соң ул турыдан

берәр көтү-фәлән узып барамы? Ләкин ник соң алар шундый җансыз булып, кинодагы кебек яссы булып, өрәк булып тоелалар?

Һәркемнең күңеленә шундыйрак сораулар килде, ләкин беркем дә дөрес җавап таба алмады.

— Кичә үлгән булсам, бүген күрмәгән булырыем,— диде Һарун, исе китеп.— Ниләр генә юк бу далада!

Нәкъ шул чакны аның күзе тагын икенче бернәрсәгә төште. Юлның сул ягында, уҗым өстендә, имчәкле зур корсагы буш капчыктай салынып торган, аксыл-саргылт туны ерткаланып-теткәләнеп беткән очлы башлы бер ана бүре күренде. Якынлашып килгән тимер тавышын ишетеп, ул, күрәсең, каяндыр шушы тирәдән генә калкып чыккан иде һәм хәзер менә, койрыгын бот арасына кыстырып, куркып-үртәлеп, кешеләрдән, машинадан качып бара иде.

— Мираж ич ул, мираж!— дип кычкырды кинәт Мансур.

— Нинди мираж?— диде Һарун, аңламыйча.— Күзеңне ачып кара — бүре!

Рәшидә пырхылдап көлеп җибәрде.

— Мансурның танышыдыр... Мираж дигән бүре!

Мәсьәләгә төшенеп, барысы да көләргә тотындылар. Өтәләнгән ана бүре исә, мотор тавышы, тимер дөбердеге аша ишетелгән кеше авазларын тотып алды да, тешләрен ыржайтып, чак-чак кына артына борылып карагандай итте, аннары кушаяклап чаба башлады.

## II

Чәчү бетте. Биш мең биш йөз гектар җиргә — моңа кадәр кысыр яткан җиргә гәрәбәдәй бодай чәчелде. Икенче бригада, берничә көнгә соңлап булса да, бирелгән планны тулысынча үтәп чыкты. Совхоз буенча бригада икенче урынга күтәрелде. Икенче бригада буенча... икенче бригада буенча гына түгел, хәтта бөтен совхоз буенча Һарун беренче урынны алды.

Үзенең алдан барганлыгын ул инде күптән белә иде. Бу турыда аңа гектар исәбе генә түгел, процентлар һәм һәрвакыт тракторда җилфердәп йөргән кызыл әләм генә түгел, бәлки, бүтән нәрсәләр дә белдереп торды. Бригадирның үзенә карата булган ягымлы, җылы карашы һәм ни теләсәң, шуны үтәргә әзер торуы да; Вәгыйзьләрнең, Мансурларның, орлык ташучыларның, шоферларның аның һәрбер сүзенә, һәрбер теләгенә каршылыксыз риза булулары да; аш китергәч, Фәридәнең үзе янында гадәт-

тәгедән дә өлгеррәк-җитезрәк кылануы да — барысы да, барысы да шул турыда сиздереп торды.

Кешеләрнең үзенә икенче күз белән карауларына аның, билгеле, күңеле үсеп китте. «Әһә, диде ул, күрдегезме инде Һарунны! Шулай булыр әле ул, иптәшкәйләрем!» Ләкин шулай да аның мин-минлеге шуннан ары узмады. Беренче куаныч, беренче күтәренкелек тиз арада узып китте һәм тора-бара ул һәртөрле мактау сүзләренә дә, үзенең алдынгылыгына да бөтенләй диярлек әһәмият бирми башлады.

Аннары үзе белән, үзенең алдынгылыгы белән мавыгырга аның вакыты да булмады. Бертуктаусыз аның миен, ниндидер яман бер чир булып, эш кайгысы тынгысызлап торды. Ятса да, торса да аның күңелендә бары чәчелгән һәм чәчелмәгән гектарлар булды, тракторның яисә чәчкечләрнең теге-бу кыланышлары, теге-бу кисәкләре булды.

Бары тик бер генә көнне кемдер килеп: «Синең турыда гәзиткә язганнар бит әле, малай»,— дигәч кенә, аның йөрәге кинәт әллә ничек кыбырсып тибәргә тотынды. Аның тизрәк шул газетаны күрәсе килде, үзе турында язылган сүзләрне укып карыйсы килде. Газетаны китерделәр. «Татарстан» совхозы турындагы бер мәкаләдә аның исем-фамилиясе телгә алынган иде, иптәш Фәлән Фәләнов көнлек нормасын фәлән процентка арттырып үти, диелгән иде. Ләкин шуннан башка анда бүтән берни юк иде. Ул бик тиз тынычланды — аның турында инде тегендә — авылда чакта да яза торганнар иде, һәм мондый Фәлән Фәләновлар, фәлән процентлар аңа инде таныш нәрсә иде. Шулай да ул күңеленнән, әллә кисеп алып өйгә җибәрергә микән, дип тә уйлап куйды. Өенә җибәрде исә, газетаны бөтен авыл укыр шикелле булып, үзе турындагы хәбәр бөтен тирә-якка таралыр һәм, һичшиксез, Хәлимәгә дә барып ирешер шикелле булып тоелды. Ул хәтта бераз гына хыялланып та алды. Ләкин бу да озакка бармады.

Чәчүне бетереп кайткан әлеге иртәне дә ул андыймондый нәрсә турында уйланмады һәм кайчан да булса бер исерткеч дан-шөһрәт коткысына бирелермен дип башына да китереп карамады.

Бригадага алар бүтәннәргә караганда соңгарак калып кайттылар. Алар кайтып төшкәндә, чәчүчеләр дә, сөрүчеләр дә — барысы да өйдә иде.

Өсләренә соргылт тузан кунган, кайбер җирләренә үлән катыш балчык сыланып калган, табаннары шомарып, ялтырап беткән һәм кешеләр сыман эшчән, кырыс тракторлар, тигез сафка басып, чатырлардан бер читтәрәк

туктап торалар иде. Монда бары кечерәк «ДТ» тракторлары гына иде, баһадир «С-80» әле булса яраланган көе кырда, буразнада утыра иде. Кичәгенәк кенә өлкә шәһәреннән кирәкле частьлар кайтарылган, ләкин ремонт әле төгәлләнмәгән иде.

Бригада «авылында» гадәттән тыш күтәренкелек, җанлылык хөкем сөрә иде. Басуда инде беркем калмаганга, бөтен халык кайтып җыелганга, «урамда», кухня өстәле, буфет тирәсендә әрле-бирле кешеләр кайнаша иде. Һәркемнең йөзе тыныч-шат, беркем беркая ашыкмый, беркем кабаланмый. Кайберәүләр, эш киемнәрен салып ташлап, көндәлек чиста киемнәрен генә түгел, хәтта бәйрәм киемнәрен дә киеп куйганнар. Бригадир вагонының тышкы ягына махсус шүрлеккә утыртып куелган радиоалгыч ягыннан иртәнге музыка моңнары тарала. Кухнядан кыздырылган балык исе килә иде.

Чәчкечләрен юл читендә ычкындырып калдыргач, Һарун тракторын бүтән тракторлар янына — сафның бер як читенә китереп туктатты. Мотор, бүлеп бирелгән соңгы газ исәбенә шәбәеп, кызулап бераз үкереп алды да тынып, бөтенләй туктап калды. Кабинадан, тупырдашып, кешеләр төште.

Аларның кайтып җитүләрен, күрәсең, дүрт күз белән көтеп торганнар иде — шундук алар янына кешеләр җыела башлады. Килгән берсе елмаеп әле Һарунның, әле Мансурның кулын кысарга, котларга, мактау сүзләре әйтергә тотынды.

Һарун аптырап калды. Бөтенләй уйламаган чакта, көпә-көндез кешеләрнең шулай кул кысуын, елмаюын, мактавын ул чынга да, юригә дә алырга белмәде һәм күңеленнән хәтта: «Әллә тилергәннәрме болар чәчү беткәч тә?»— дип тә уйлап куйды. Котлаучылар арасында Исламнарның, Белугиннарның булуы аны чын-чынлап шиккә төшерде. Ләкин шул чакны җилләнеп бригадир килеп җитте. Килеп җитте дә сул кулы белән аның учын җыеп тотты, ерактан селтәп, уң кулы белән шакылдатып сугып алды.

— Булдырдың, Һарун, рәхмәт!— диде ул.

— Нәрсә булдырдым соң мин?— диде Һарун, мәсьәләгә төшенмәкче булып.

— Кыланма инде!— дип кычкырды Ислам, дусларча шелтә белән.

— Кара, әллә чынлап та белми?!— диде Барый.

— Социалистик ярышта син беренче урынны яулап алдың!— диде Белугин, трибунадан кычкыргандай, кулларын бутап.

Әйе, үзенең беренче урынга чыгуын ул инде моңарчы да белә иде, ләкин хәзер аңа кинәт әллә нәрсә булды. Үз-үзен ул хәзер бөтенләй икенче кеше итеп күргәндәй булды; моңарчы үзенә шундый таныш булган гап-гади бер авыл малае итеп түгел, бәлки, искәрмәстән үсеп, куәтләнеп киткән һәм башкалардан кайдадыр өстәрәк — җир белән күк арасындарак асылынып торган батыр итеп күргәндәй булды. Тыштан караганда ул һаман шул ук тупас, беркатлы Һарун булып калды, әмма эчтән инде ул әллә кемгә әйләнде. Ул сукырайды, миңгерәүләнде, акылдан язды! Шундый көтмәгәндә һәм шундый кыска вакыт эчендә ул дан-шөһрәтнең, мин-минлекнең, масаю һәм өстенлек хисенең бер-ике тамчысын татып карады. Татып карады, һәм чыныкмаган яшь йөрәккә шул җитә калды.

— Һарун безнең флагман!— диде Белугин, трактор маңгаендагы кызыл материя кисәгенә күрсәтеп.

«Флагман» сүзенең нәрсә икәнлеген Һарун аңлап җитмәде, шулай да ул аның бик зур олылау сүзе булырга тиешлеген чамалый алды. Шундый сүз әйткән Белугинны ул элекке начарлыклары өчен шундук күңеленнән гафу итте. Аны гына түгел, хәтта үзенең явыз дошманы Исламны да, икейөзле Илгизне дә, чәрелдек Кәрамны да, Тәзкирәне дә — барысын да, барысын да гафу итте. Гафу иткәч, алар аңа хәзер бүтәннәргә караганда да якынрак булып тоела башладылар.

— Һарун булмаса, белмим, бу чәчүне җырып чыга алган булырыек микән,— диде Ислам, башы әйләнгән егет күңеленә соңгы тамчыны өстәп.

Әмма монысы инде чамадан тыш булды. Моның шулай икәнлеген Һарун үзе сизмичәрәк калды, ләкин бүтәннәрнең бу шундук тешенә тиде.

— Ярый, котладык, мактадык — җитте!— диде бригадир, җитди генә.— Ул кадәр теге... Бөтен бригада җиңеп чыкты, без бөтенебез дә... Булдымы!

## III

Чәчү беткәч тә кешеләргә өч көн ял бирелергә тиеш иде. Узып китә язган беренче көнне исәпләмәгәндә, ул өч көннең бер генә көне ял булачак иде, чөнки өченче көнне профилактик ремонт булырга, шуннан соң исә каты сука башланырга тиеш иде.

Кешеләр иркенләп тын алгач та, бригадирның иң беренче эше шул булды: иртәнге аштан соң ул «чисталык сәгате» игълан итте, ягъни һәркемгә вагоннарны, чатыр-

ларны тәртипкә китерергә, ятак урыннарын җилләтергә, юрган, мендәр ише нәрсәләрне каккаларга-суккаларга һәм күмәк көч белән «урамны» һәм һәртөрле «тыкрыкларны» себерергә кушты. Бу эшкә ул турыдан-туры үзе җитәкчелек итте.

Бер сәгать чамасы вакыт үтмәде, бөтен җир чистарып, ялт итеп калды. Ыгы-зыгы инде басыла төшкән бер вакытта, чатырлар, вагоннар арасына түбәсе ябулы машина килеп керде.

— Әзерсезме? Әйдәгез тизрәк!— диде шофер.

— Кая? Нәрсәгә?— диделәр кешеләр, берни аңламыйча.

— Мунчага. Мунчага алырга килдем.

Кемдер бригадирны эзләп йөгерде, кемдер чатырга кереп китте, шундук «мунча» сүзен элеп алдылар, һәм бер-ике минут эчендә бөтен бригаданы күңелле шау-шу биләп алды.

— Мунчага, мунчага!

— Яшәсен мунча! Ура!— дип кычкырдылар егетләр, тилереп-юләрләнеп.

Мунча кереп кайткач та, кешеләр үзара төркем-төркем җыела башладылар һәм, кызып-шаулашып, бер үк нәрсә турында — иртәгәге ял көнен ничек үткәрү турында бәхәсләшергә тотындылар.

Кызларның бер өлеше, машинага төялеп район үзәгенә кино карарга барырга кирәк, диде; икенче өлеше исә беркая бармаска, кер юарга, хат-фәлән язарга, кыскасы, вакытны күңелле генә итеп өйдә үткәрергә кирәк, диде. Егетләр ду китереп бер «мәҗлес ясап» алу ягына басым ясадылар.

Бригадир беркемгә дә ачык кына җавап кайтармады. Үзен аптыраткан кешеләргә ул йә берәр шаян сүз әйтеп куйды, йә көлемсерәп куйды, яисә берни вәгъдә итми торган бер килешүчәнлек белән, карарбыз, уйлашырбыз, диде.

Төзәнгән-бизәнгән көяз кызлар, иртәгәге көн турында артык баш ватмыйча, күңел ачуны хәзер үк башлап җибәрергә булдылар. Гармунчы Коляны өстерәп диярлек тышка алып чыктылар да бригадир вагоны янындагы такта әрҗәгә утырттылар, алдына елкылдап торган эре ак басмаклы аккордеон китереп куйдылар, һәм шундук «мәйдан» уртасында — як-ягында чатырлар, вагоннар түгәрәкләнеп утырган такыр җир өстендә шәһәрчә бию — вальс башланып китте. Музыка тавышын ишетеп, бүтәннәр дә чыкты, биючеләргә яңа парлар кушылды, тузан күтәрелде.

Күңелле шау-шу, музыка кызып кына барганда, Кәрам кинәт:

— Директор килә!— дип кычкырып җибәрде. Түгәрәк читендәгеләр кыймылдашып куйдылар, башларын борып, як-якка карандылар; аккордеон ялгышкандай итте, биюләр әкренли төште. Көктугай ягыннан чыннан да бригадага таныш машина якынлашып килә иде.

Машина бер-ике минуттан яшьләр янына килеп тә туктады. Аягына яхшы күн итек, өстенә зәңгәрсу галифе чалбар белән яңа кара пинжәк киеп куйган, галстук таккан, кырынган-чистарынган һәм бөтен кыяфәтеннән, бөтен килеш-килбәтеннән бәйрәмчә җанлылык, тантаналык сизелеп торган Игорь Андреич кабинадан чыкты. Елмаеп, ул яшьләргә сәлам бирде. Ләкин нишләптер аның сәламенә беркем дә җавап кайтармады. Тик шулай да бу ике-өч секунд кына дәвам итте. Көтмәгәндә каршылау маршы яңгырап китте, төрле яктан бер үк вакытта диярлек сәлам авазлары ишетелде.

— О, сездә башланган да икән!— диде директор, тагын да ныграк елмаеп.— Без, ахрысы, соңгарак калганбыз.

Директор артыннан кабинадан чыгып килүче парторг белән совхоз комсоргы күренде. Алар да елмаеп куйдылар, нидер әйткән булдылар, ләкин күңелле ыгы-зыгы арасында аларның нәрсә әйткәнлекләре ишетелми калды.

Машинада тагын бер кеше бар иде. Кемдер аны күреп алды, тамак ярып шундук «ура» кычкырды, һәм күңелле шау-шу искәрмәстән җил-давылга, күк күкрәүгә әйләнде. Барысы да, шаулашып, көлешеп, әлеге кеше янына агылдылар, аны уратып алдылар да, кулларына күтәреп диярлек, бригадир вагонына алып киттеләр. Мондый кадер-хөрмәткә лаек булган кеше совхоз кассиры Айсылу апа иде. Май аеның беренче яртысы өчен ул хәзер эш хакы алып килгән иде.

— Беләм мин сезне!— дигән булды Горшков, бармак янап.— Безне марш белән генә каршыладылар... Кассирны әнә күтәреп йөртәсез!

— Игорь Андреич, сезгә дә кассир буласы калган,— диде Белугин, аның каршысына чыгып. Директор күңелләнеп көлеп куйды.

## IV

Акча бирү тәмамлангач, Барый кешеләргә кухня өстәле тирәсенә җыелырга кушты.

Берничә минуттан бригаданың язгы кыр эшләре

тәмамлануга багышланган җыелышы башланып китте. Бригадир, андый-мондый рәсмилекне саклап тормыйча, кулындагы кәгазьгә карап, турыдан-туры сүзгә күчте. Кыска гына итеп ул бригаданың кайчан, нинди шартларда сөрә башлавы, чәчә башлавы турында, эш барышындагы җитешсезлекләр турында әйтте; бригаданың ничә гектар җире булуы, шуларның күпмесе ничә көндә сөрелеп-чәчелеп бетүе турында әйтте. Аннары бернинди керешсез-нисез, кемнең ничек эшләве мәсьәләсенә күчте.

Халык алдында сөйли белмәгән һәммә кеше кебек, ул бик күңелсез итеп, эч пошыргыч итеп сөйләде. Ләкин кемнең ничек эшләвенә килеп җиткәч кызыксыну арта төште. Бригадир монда да бары коры саннар гына әйтте дә исем-фамилияләрне генә әйтте. Фәлән Фәләнов яхшы эшләде, диде, көнлек нормасын фәлән процентка үтәде, ә Фәлән Фәләнов иптәш нормасын фәлән процентка гына үтәде, диде.

Һарун агрегаты турында сөйләргә тотынгач, ул коры саннар белән генә дә чикләнмәде — каяндыр матур сүзләр дә тапты, чагыштырулар да тапты, тавышын да күтәребрәк җибәргәндәй булды. Аның һәрбер сүзеннән соң барысы да, менә кемнәр икән алар! менә нинди кешеләр икән! дигән сыман, кызыгып, исләре китеп, әле Һарун ягына, әле Вәгыйзь, Мансур ягына карап-карап алдылар.

Бригадирдан соң парторг сүз алды, чирәм җирләрне үзләштерүнең әһәмияте турында, «яшь патриотларның» фидакарь хезмәте турында сөйләде, ахырда, гадәттәгечә, мактауга күчте, тәҗрибәсе аз булуына да карамастан, бригадага дөрес җитәкчелек иткән яшь коммунист «иптәш Рамазановны» мактады, тегесен-монысын мактады һәм, аерым басым ясап, янә дә Һарун агрегатына тукталды, Һарунның үзенә тукталды.

Парторгтан соң совхоз комсоргы Саша Кауфман сөйләде, бик кызып, кайнарланып сөйләде. Аннан соң сүзне директор алды. Ул күп сөйләп тормады. Кыска гына, үтемле генә итеп, дирекция исеменнән бөтен бригадага рәхмәт белдерде. «Беренче сынауда сынатмадыгыз, киләчәктә дә сынатмассыз дип ышанам»,— диде.

Башлыклар сөйләгәндә, Һарун шатлык һәм оялу тойгысыннан нишләргә белмичә, кызарынып, уңайсызланып тик торды. Директор сөйли башлагач, ул үзе дә сизмәстән: «Минем турыда әйтер микән?»— дип уйлады. Аның хәзер һәркем авызыннан бары үзе турында гына ишетәсе килде, бары мактау сүзләре генә ишетәсе килде. Әгәр директор аның турында берни әйтми калса, ниндидер га-

делсезлек эшләнер шикелле тоелды. Ә директор нишләптер аны мактарга бик үк ашыкмады.

Менә ул әкрен генә, салмак кына кыланып, эчке кесәсеннән бөкләнгән бер кәгазь кисәге чыгарды, кәгазьне җәйде дә, гадәттәгегә караганда тавышын күтәрә төшеп, укырга керешге. Бу гади генә сүзләр түгел иде, бу кәгазьгә язылган, боерык рәвешендә белдерелгән мактау һәм рәхмәт сүзләре иде.

Директорның укып бетерүе булды, барысы да шаулашып кул чабарга тотындылар.

— Чөяргә, чөяргә!— дип кычкырды Ислам, беренче булып.

— Тотып селкергә!— диде Кәрам.

Күп сөйләшеп тормыйча, каты, нык куллар Һарунны эләктереп тә алдылар. Эләктереп алдылар да җиңел генә югары күтәрделәр һәм, ул исенә-акылына килеп өлгергәнче, чөеп тә җибәрделәр, «һап-һоп!»— дигән, көлешкән тавышлар ишетелде, куллар, башлар чайкалды. Куллар, башлар гына түгел, бөтен тирә-як чайкала-тирбәлә шикелле тоелды.

Аннары тагын Барый сүз алды һәм иртәгә ял көнне «бригада буенча» сабан туе ясалачагын әйтте. Бу хәбәрне дә яшьләр ду килеп каршыладылар.

Тиз арада башлыкларны уратып алдылар, сораштылар, үзләренең тәкъдимнәрен әйттеләр. Кызлар аш-су мәсьәләсен кузгаттылар. Илгиз былтыр үзенең сабан туен кайда, ничек каршылавы турында борчак чәчәргә тотынды.

Шау-шулы төркемнән Һарун ничектер читтәрәк торып калды. Үзе дәрәҗәсендә макталмаган, күккә чөелмәгән кешеләр арасында ул үзен кинәт ялгыз итеп тойгандай булды. Нишләптер аңа хәзер һәркем аннан көнләшәдер шикелле булып, шуңа күрә юри аның белән сөйләшмәскә, хәтта аның ягына әйләнеп тә карамаска тырышадыр шикелле булып тоелды.

Бүген ул акчаны шактый күп алды. Шул да аны масайтып, үстереп җибәрде. Бригадада ул үзенә-үзе иң бай кеше булып күренде. Анда кинәт шуның белән мактанасы килү теләге туды. Кесә тулы акчаң була торып, тып-тын гына, мыштым гына йөрү килешмәгән эш булып тоелды. «Әллә иртәгә бөтен бригаданы үз исәбемә сыйлыйм микән соң?»— дип уйлады ул, чамадан тыш юмартланып. Менә ярар иде бу, ичмасам! Белсеннәр, күрсеннәр Һарунның кем икәнлеген! Әйттеме ул аларга: күрсәтермен әле дип! И күрсәтте дә! Ул әле тагын күрсәтер аларга...

Колак төбендә кемдер аңа шундый нәрсәләр пышыл-

дады. Ашыгып, ул Вәгыйзь белән Мансур янына килде. Алар белән бергә эшләү дәверендә ул үзенең барлык эч серләрен уртаклашырга гадәтләнеп киткән иде. Ләкин ул үзенең бөтен бригаданы сыйлау нияте турында әйткәч, Вәгыйзь дә, Мансур да моңа әллә ни куаныч белдермәделәр.

— Белугин белән Исламны дамы?— диде Мансур, шаккатып.

— Ю-ук, кирәкми,— диде Вәгыйзь, ипләп кенә, каты бәрелмичә генә.

— Ник, ник кирәкми?— диде Һарун, кыза башлап.— Минем хәзер акча җитәрлек!

— Эчмәгәнсеңдер бит син?— диде Мансур, дусларча елмаеп. Аннары кисәк кенә аның җиңеннән тотып алды.— Алай бик бай булгач, чыгар әле акчаңны!

— Нәрсә?

— Взнос. Комсомол взносы. Вәгыйзь, син дә!.. Әнә Саша миңа карап-карап ала: кыздырырга җыенадыр. Стена газетасын чыгарып өлгермәдек, взнос җыелмаган... Хәзер әләгә миңа!

— Кайгырма, үзем якламмын!— диде Һарун, эре генә, дәрәҗәле генә.

## V

Иртыш буена бүген теге вакыттагы кебек берничә кеше генә түгел, бәлки, бөтен бригада бара иде. Авыручылар да, шулай ук үзе теләп монда калучылар да юк иде. Ләкин бригадада кемне дә булса каравылчы итеп калдырырга кирәк иде, штатта исә андый кеше юк иде.

Сабан туена әзерләнеп, тыз-быз килеп йөргән арада, Барый шул турыда исенә төшерде. Бу нәрсә аңа шактый катлаулы булып тоелды. Ул егетләр вагонына керде дә мәсьәләне аңлатып бирде.

— Кемнең башы авырта, кемнең эче авырта?— диде.

— Калсын шул көе! Йомраннардан, төлкеләрдән башка монда кем килеп йөрсен?— диде Белугин, кулын селтәп.

— Шобага тотарга кирәк, җегетләр,— диде Ислам.

— Юк, Галимуллага әйтергә кирәк,— диде Илгиз.— Аның эше шул.

— Дөрес, Галимуллага әйт, Галимуллага әйт!— дип кычкырдылар төрле яктан.— Бәлки, ул бүген авырып та киткәндер әле.

Бригадир артык сатулашып тормады, тиз генә кузгалды да «авыл» читендә утырган ялгыз чатырга китте.

Ишек хезмәтен үтәгән чаршауның бер кырыен күтәреп, ул чатыр эченә күз төшереп алды. Галимулла, җир идәндәге палас өстенә аякларын бөкләп утырган көе, консерва савытына терәп куелган көзгегә карана-карана, барлы-юклы сакал-мыегын кырып азаплана иде. Иренә аркасы белән утырган Фәрханә апа тирләп-пешеп чәй эчә иде.

— Исәнмесез!— диде Барый, яртылаш чатыр эченә сузылып.

Бер як чигәсе ялтыратып кырылган, икенче як чигәсендә сабын күбеге булган Галимулла ипләп кенә муенын борды да, иреннәрен чак-чак кыймылдатып:

— Бик исән...— диде.

— Барый икән,— диде Фәрханә апа.— Кер әйдә, нишләп ишек төбендә генә торасың? Кортны качырырсың! Ишек төбендә керми торсаң, элек безгә шулай диләрие.

— Галимулла абзый кирәк иде,— диде Барый, түргәрәк узып.

— Менә бу мин булам инде, Барый туган,— дигән булды Галимулла.— Сабан туена әзерләнеп ятам әле менә.

Барый аның кырынып беткәнен тавыш-тынсыз гына көтеп торды. Аннары серле генә итеп, әйдәле, Галимулла абзый, диде дә аны тышка алып чыкты һәм, йомышын әйтеп тә тормыйча, үз вагонына ияртеп китте.

— Сабан туе дигәч тә, әллә ни булмас инде ул, Галимулла абзый,— диде бригадир, үзалдына сөйләнеп.— Бу көнне анда черки талап үтерер! Елга буенда бигрәк тә. Мин әле үзем дә ике аягымның берсен дә атламас идем.

Аның тәртәне кайсы якка каерганлыгын Галимулла әз генә дә сизенмәде. Ул аны чын күңелдән сөйли дип уйлады һәм аның һәрбер сүзен җөпләп, әйе, әйе, диештереп барды. Бүлмәгә килеп кергәч, Барый сәке астыннан бер яртыны тартып чыгарды да Галимуллага тоттырды.

— Ал әле менә шуны, Галимулла абзый,— диде ул.

— Каян алдың?— диде Галимулла, исе китеп.

— Кичәгенәк итәк астыннан гына алдым,— дигән булды бригадир.— Бүген әле аның булмавы да мөмкин тегеләргә. Аңлыйсыңмы? Беркемгә сиздермә!

Галимулланың авызы ерылып китте. Аннары ул аптырагандай итте, тамагын кыргалады, үз-үзенә урын таба алмагандай, бер аягыннан икенче аягына баскалады, ничек була соң әле бу, Барый, диде; рәхмәт инде, диде; кайчакта бит, Барый туган, тамак чылатып алу да зыян итми, диде.

— Олы кешегә ансыз буламы соң!— дигән булды Барый.

Шулай да, шешә Галимулла кулына күчкәч, ул артык нечкәләп тормады, син бит, Галимулла абзый, бригадада каласы кеше, болай булгач күңелсез булмас үзеңә генә, диде. Галимулла, ниһаять, аңлап алды. Аңлап алды да ыңгырашкандай итеп куйды. Шуннан соң бөтенләй тынсыз-өнсез калды, күзләрен челт-мелт йомгалап торды, ләкин бригадирга каршы сүз әйтергә нишләптер теле бармады. Бераздан аның йөзе янә яктырып китте, һәм ул үзенчә хәйләкәр генә бер елмайды да:

— Баш белән уйлап караганда...— диде.

— Бер дә уйлап торасы юк, Галимулла абзый,— диде Барый.— Үзең уйлап кара, шулкадәр техниканы ташлап китикмени? Синнән дә ышанычлырак кем бар безнең?

— Менә мин хәзер каравылчы да!— диде Галимулла.

— Шулай булып чыга инде, Галимулла абзый,— диде бригадир.

Галимулла чалбар кесәсен кабартып торган шешәне кулы белән капшап карады, ишеккә төртеп җибәрде.

— Ярар, хафаланма, Барый туган,— диде ул, тыныч кына.— Кирәк булгач кирәк. Шуның өчен күршегә кереп тормабыз лабаса!

## VI

Билгеләнгән сәгатькә Көктугайдан машина килеп җитте. Яшьләр, чыр-чу килеп, машинаны уратып алдылар, тәгәрмәчләргә, арткы тимерләргә басып югары менделәр, кулларын сузып иптәшләренә ярдәм иттеләр, әйберләрне күтәреп алдылар һәм биш-алты минут эчендә төялешеп тә беттеләр. Кыска аякларын аерып баскан көе, такыр мәйдан уртасында аларны Галимулла озатып калды.

Тигез юлдан машина очты гына. Каршыга ыргылып җил исте, аяк астында җиңелчә калтырап, дерелдәп сиртмәле идән тирбәлде. Юл читендәге яшел уҗым басуы, ниндидер конвейер тасмасы шикелле, коточкыч тизлек белән артка шуышты.

Бер ярты сәгатьтән еракта Көктугай күренде.

Бар тавышларына кычкырып җырлап килгән яшьләр шифер түбәле яңа йортлар яныннан, төзүчеләрнең яшел чатырлары яныннан, таудай итеп өеп ташланган җыелма йорт детальләре, агач-таш яныннан выжлап узып киттеләр дә иске Көктугайга килеп керделәр.

Автомашина кибет каршысында туктап калды.

Барый кабинадан чыкты да, өстә утырганнарга төшмәскә, беркая таралышмаска кушып, кибеткә кереп китте. Үзенең тынычсызланганлыгын, күңеле җилкенгәнлеген сиздермәс өчен, ул бик нык ашыккан, кабаланган кеше кебек кыланды. Хәер, кылану гына түгел, чыннан да, аны нидер кыстап, котыртып тора шикелле тоелды.

Кибеткә килеп керер-кермәс борын ук:

— Исәнмесез!— дип кычкырды ул, саңгырау кеше сыман.

Гөлбибине бригадага алып барган чакта туктап, сатучы кызга сүз кушып азапланган теге көннән соң ул монда тагын бер-ике мәртәбә кереп чыккан иде. Ләкин бер керүендә дә Мәрьям аңа ачылып китмәде. Хәзер ул элеккегә караганда да тәкәбберрәк күренде. Шулай булуга да карамастан аның белән барыбер сөйләшергә кирәк иде, ничек тә сөйләшергә кирәк иде, бары тик аулакта гына, икәүдән-икәү генә сөйләшергә кирәк иде.

Ләкин менә ничек итеп аның белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсең? Бөтен бригада алдында!

«Эш белән лә мин аңа!»— диде ул аннары, үз-үзен юатып. Бер дә юктан түгел. Серләшү генә иммени... Болай сөйләшергә дә була ич әле!

Күңелендә шундый каршылыклы уйлар булганга, бүген дә ул аның салкын күз карашын очратырмын дип уйлады, ләкин — гаҗәп хәл!— Мәрьям бүген аңа бөтенләй икенче кеше булып күренде. Кибеткә бригадир килеп кергәч тә, ул, алсу иреннәрен суза төшеп, хәтта елмайгандай итеп куйды һәм сәламгә каршы сәлам белән җавап бирде дә, тәрәзәгә үрелеп тышка карады.

— Килеп тә җиттегезме?— диде ул, үзе сүз башлап.

Бригадирның күңел кошы кинәт тибрәнеп куйды. Тар, кысан кибет эче кисәк кенә киңәеп китте. Ясалма кабалануга, ясалма кутәренкелеккә икенче бер җиңеллек өстәлде, һәм үзенең ни сөйләгәнлеген үзе дә рәтләп аңламыйча, ул кызның соравына каршы әллә никадәр сүз сөйләп ташлады.

— Сез инде сабан туен башлагансыз да икән,— дигән булды Мәрьям, сәйлән тешләрен елтыратып.

— Без инде кичәдән бирле бәйрәм итәбез!— диде Барый, бөтен кибет эченә шаулап.— Сабан туе гынамы соң! Беләсеңме, Мәрьям, әйдә безнең белән! Ташла кибетеңне. Бер көнгә берни булмас. Кем тияр дисең? Төлкеләрдән, йомраннардан башка монда беркем юк,— диде ул, иртән кемдер әйткән сүзләрне хәтерләп.— Хәзерге төлкеләр, йомраннар, үзең беләсең, аңлы халык.

Мәрьям тагын тәрәзәгә карап алды да көлеп куйган булды.

— Валлаһи, хәзер менә Галимовка барам, рөхсәт алам. Чынлап! Булдымы?

— Бер машина кызлар алып барасыз — миңа инде анда урын да калмагандыр,— дигән булды Мәрьям, назландырып.

— Мин сине бер машина кызларга да алыштырмыйм, Мәрьям!— диде бригадир, чамадан тыш кыюланып.

Мәрьям тагын көлеп куйды. Монысында инде көчлерәк, озаграк көлде, үзе һаман ишеккә, тәрәзәгә карап-карап алды.

Чибәр кызны күреп кинәт диваналанып киткән бригадир егет гыйшык-гашрәт сүзләре сөйләп азапланган арада, кибеткә тагын икенче бер дивана килеп керде.

— Барый абый, аракы өчен акчаны үзем түлим!— дип кычкырды ул, адашкан кеше сыман.

Бригадир тиз генә артына борылып карады.

— Нәрсә?— диде ул, Һарунны ашардай булып.

— Аракы өчен акчаны үзем түлим,— диде Һарун.— Шулкадәр акча була торып, иптәшләрне бер сыйламый ярамый.

— Бар әле... йөрмә!— диде бригадир, сөекле тракторчысын тупас кына читкә этәреп.

Һарун каушап калды. Ул һич тә мондый нәрсә көтмәгән иде. Ләкин Барый абыйсы белән даулашырга, аның алдында үз фикерен яклап маташырга шулай да аның йөрәге җитмәде.

— Мин бит... Барый абый...— диде ул, буталып, мыгырданып.

Аның артыннан ук кибеткә Белугиннар, Илгиз, Кәрамнар килеп керде.

— Кая, буламы инде анда, иптәш бригадир?— диде Белугин.

— Нәрсә әйттем мин сезгә — таралышырга куштыммы?— дип кычкырды Барый, кәефе кырылып.

Мәрьям исә үзенә бирелгән акчаны санады да, үз ягына үтәргә кушып, кечкенә ишекне ачты.

— Керегез, менә бу ящикны алыгыз,— диде ул.

Ялт итеп Белугин эчкә, Мәрьям янына кереп китте, күрсәтелгән әрҗәне ике куллап тотып алды да, баш өстенә күтәргән көе, шаулап, кычкырынып ишеккә таба атлады.

Акча түләнде, товар алынды, ләкин Барыйның әле һаман чыгып китәсе килмәде. Шул ук вакытта яңадан сүз башлап җибәрергә дә бернинди сәбәп юк шикелле тоелды.

Шул чакны шау-шу арасында Исламның тыелып кына: «Исәнмесез»,— дигән тавышы ишетелде. Мәрьям кинәт балкып китте, аннары кинәт кенә сүнде һәм, күзләрен түбән игән көе, кабаланып-калтыранып, бер мәртәбә санаган акчасын яңадан санарга кереште.

Андагы бу үзгәрешне Барый бик яхшы күреп торды. Эчке бер сизенү аны тетрәндереп җибәрде. Ирексездән ул артына борылды, күз кырые белән генә Мәрьямгә карап торган Исламны күреп алды, һәм шунда аңа бөтенесе дә аңлашылган төсле булды.

— Әйдәгез, әйдә!— диде ул, кешеләрен кибеттән куалап.

## VII

Юл дәвам итте. Машина саман йортлар яныннан ук башланып киткән сөзәк ярдан аска төште дә тигез үзәнлек буенча алга чапты. Юл читендә каты ботаклы кәрлә куаклар очрады, яшел куе үлән арасыннан пырылдап кошлар очып китте; арт аякларына басып, өннәре янында йомраннар торып калды.

Күп тә үтмәде, машина Иртыш буена килеп җитте һәм ачык бер урында — яр буенда туктап калды. Кешеләр шыбырдашып җиргә коелдылар. Барысы да яр кырыена килделәр, җәелеп, ялтырап яткан су өстенә текәлделәр. Болай да аяз, кояшлы көн, киң дәрьяга күз карашы ташлагач та, тагын да ачылып, яктырып киткән төсле булды. Бу кадәр яктылыкка тиз генә күнегә алмыйча, кешеләр ирексездән күзләрен кыстылар, кулларын маңгайларына куйдылар.

Иртыш безнең Иделгә дә, Чулманга да охшамаган иде. Аның суы Иделнеке төсле каралҗым да, Чулманныкы төсле кызгылт-комлы да түгел иде. Шулай ук ул безнең якның киң колачлы батыр дәрьялары кебек салмак, тыныч канлы да түгел иде. Пыяладай яшькелт, чиста сулы Иртыш ашыгып-ашкынып ага иде. Ул кайсыдыр ягы белән безнең гүзәл Агыйделне хәтерләтә иде.

Кешеләр, комлы ярлар, яшел тал-тирәкләр арасыннан уйнаклап, кызулап аккан, кояш нурларында ялт-йолт килеп, шаян дулкыннарын кагып аккан суга төбәлгән көе, бу кадәр гүзәллек, бу кадәр хозурлык алдында телсез-өнсез калган сыман, бераз вакыт тын гына басып тордылар.

Кемдер шунда гармун сыздырып җибәрде. Яңгыравык моңлы авазлар, Иртыш дулкыннарына бәрелеп, шундук кире киттеләр, күккә аштылар, киң болынга җәел-

деләр. Барысы да, көчле бер тәэсиргә бирелеп, гармунчы ягына борылып карадылар.

Сабан туе башланды.

Чынында бу бөтен рәвешен китереп ясалган сабан туе да булмады — бергәләшеп иркендә, яланда бер күңел ачу гына, киеренке, тынгысыз көннәрдән-төннәрдән соң, бер тынычлап ял итү генә булды. Бер төркем кызлар, егетләр, Мансурга ияреп, шундук яр астына төшеп киттеләр, чишенеп, чыр-чу килеп, бер-бер артлы суга сикерделәр. Кармак алып килгән һәвәскәрләр тизрәк балык каптырырга ашыктылар. Барый учак урыны әзерләргә керешге.

Күп тә үтмәде, аның янына Белугин килеп җитте.

— Бригадир, ә, бригадир, кайчан тотынабыз инде моңа?— диде ул, киндер белән каплап куелган әрҗәгә күрсәтеп.

— Бар әле, йөрмәле монда иснәнеп!— диде Барый, коры гына.

Кибеттә булган очрашудан соң, аның әле күңеле тынычланып җитмәгән иде. Белугин, үз сүзен сүз итмәкче булып, аның белән бәхәсләшергә чамалап карады, ләкин Барый аны чын-чынлап куалап җибәрде. Белугин үзенең әшнәләре янына килде дә «каты куллы» «котырган» бригадирны сүгәргә керешеп китте.

— Бар әле син! Сезнең өчен мин генә йөрергә тиеш түгел,— диде ул, Исламны кыстап.

Ләкин Исламның барасы килмәде. Беренчедән, бригадир ачулы чакта, ул аның күзенә күренүдән тыелырга мәҗбүр булды. Аннары кибеттә аның Мәрьям алдында ярарга тырышып сөйләнгәләвен дә, үз-үзен бик тыныч тотмаганлыгын да ул, әлбәттә, сизми-күрми калмады. Күз ачып йомган арада, Мәрьямнең үзгәргән кыяфәтенә карап, мәсьәләгә кинәт кенә төшенеп алган Барый кебек, ул да, бригадирга күз карашы ташлау белән, бөтен нәрсәне аңлап алгандай булды. Аның күңелендә шул чакны көнчелек тойгысы кузгалып куйды.

Мәрьямне ул бөтенләйгә онытмакчы булды. Ләкин, гаҗәп хәл, Фәридә Мәрьямнән яшьрәк, чибәррәк булса да, соңгы көннәрдә ул аңа тулы юаныч һәм күңел канәгатьлеге бирми башлады. Яңадан аның күз алдына Мәрьям килде, аның ягымлы иркәләүләре исенә төште. Үзе ул хатын-кызны иркәли белми иде, киресенчә, үзе генә иркәләнергә ярата иде. Фәридә исә аны тиешенчә иркәли дә, юата да алмады, алай гына да түгел — кинәт кенә үпкәләргә тотынды, елады, шелтә белдерде. Андый елакларның потьы бер тиен! «Тагын берәр мәртәбә сөйләшеп карарга кирәк,— дип уйлады ул Мәрьям турында.— Бо-

лай кырт кына өзәргә ярамый... югыйсә әнә тилгәннәр сагалап кына йөриләр».

— Һарун барсын менә,— диде ул Белугинга.— Һарунны ул ярата. Бар әле син, Һарун, бар!

— Ник бармаска, барам шул!— диде Һарун, батыраеп.

Аңа башта ук бригадир белән Белугин түгел, бәлки ул үзе барып сөйләшергә тиеш иде шикелле тоелды. Үзен ул хәзер алдынгы тракторчы итеп кенә түгел, бәлки бригадада ниндидер җитәкче рольгә лаек кеше итеп, «начальство» тирәсендә чуалырга хаклы кеше итеп тә сизә башлады. Шуңа күрә сүзе үтәчәгенә ул әз генә дә шикләнмәде. Ул хәтта баягынак кибеттә булган нәрсәне дә исеннән чыгарып ташлады һәм, көдрәеп, эре-эре атлап, бригадир янына китеп барды.

— Карале, Барый абый,— диде ул аңа үз итеп, пышылдап.

— Нәрсә, аракымы?— диде Барый, юри кычкырып. Һарун сагаеп Фәридә белән Фәрханә апа ягына карап алды.

— Берәр ярты гына, ә, Барый абый?— диде ул, үтенү дә, бәйләнчекләнү дә сизелеп торган бер әдәпсезлек белән.

Әле кайчан гына шундый тыйнак булган яшь егетнең бер-ике көн эчендә үзгәреп китүе, бер дә юктан кылтаеп китүе бригадирның чын-чынлап эчен пошырып куйды. Аның аны дусларча гына шелтәләп, кыздырып аласы килде, масайма, энем, юкка-барга башың әйләнеп харап булуың бар дип әйтәсе килде, ләкин шул ук вакытта алай дип әйтергә, аны кыздырырга-шелтәләргә нигезе дә юк шикелле тоелды. Кешенең сөйләшү тоны үзгәргән өчен генә яисә аның гадәттәгегә караганда күбрәк көлгәне-елмайганы өчен генә аны сүгәргә, аңа акыл өйрәтергә кемнең нинди хакы бар? Андый нәрсә турында йөзгә карап әйтмиләр, ул турыда бары эчтән генә сыкраналар да эчтән тыналар.

Һарунның соравына бригадир җавап бирергә дә өлгермәде, һәркемнең игътибарын бүлеп, яр астында кинәт ниндидер тавышлар ишетелде.

## VIII

Бу турыда елга шактый тирән иде. Агым да кызу булганга, су керүчеләр артык кыюлык күрсәтә алмадылар — яр буенда гына йөзеп йөрделәр. Ләкин Мансур яр буенда йөзү белән генә канәгатьләнмәде. Аның, гадәттәгечә, һәркемнән уздырып җибәрәсе килде. Әледән-әле кызлар ягына караштыргалап һәм бер тирәдәрәк кай-

нашкан «куркакларга» тәнкыйть сүзләре әйткәләп, ул читкәрәк йөзеп китте, йөзеп китте дә кире килде, аннары ярга чыкты, текә җирдән суга сикерде, чумды, калкып чыкты... Беркадәр вакыт ул шулай үзенең һәртөрле һөнәрләрен күрсәтте дә, яр читенә чыгып, кинәт үргә таба йөгерде. Иптәшләреннән бер ике йөз адымнар ераклашкач, ул янә Иртыш кочагына ташланды.

Мондагылар аның нишләргә исәпләвен абайламыйчарак калдылар. Бераз вакытка ул хәтта югалып та торган сыман булды. Кинәт аны күреп алдылар: кызу агым белән ул болай таба агып килә иде һәм шул ук вакытта ярдан ераклаша бара иде.

— Мансур, боры-ыл!— дип кычкырды Рәшидә, кулларын авыз турысына куеп.

Бүтәннәр дә куркып кычкырырга, кул болгарга тотындылар. Су өстеннән аларга беркем җавап кайтармады. Тирбәлгән, чайкалган дулкыннар арасында, агызып җибәрелгән туптай булып, Мансурның әледән-әле кара чәчле башы гына күренеп-күренеп китте.

Күз ачып йомган арада ул үзенең иптәшләре турысына җитте, аларны узып китте һәм котылгысыз рәвештә ярдан һаман ераклаша барды. Тиздән аның йөзе бөтенләй аермаслык булды. Шул чакны яр буенда чыр-чу купты.

Барый эшен ташлады да тавыш килгән җиргә ашыкты. Иртыш уртасына җитә язган Мансурны ул бик тиз күреп алды. Яр астындагылар аның каян килеп чыкканлыгын сизми дә калдылар — кинәт кенә ул күктән сикереп төшкән сыман булды. Бары тик ниндидер авыр нәрсәнең шапылдап суга төшкәне ишетелде дә яшькелт дулкыннар арасында шәрә тәннең ялтырап киткәне генә күренде. Аннары ул төшкән турыдан чайкалып як-якка түгәрәк дулкыннар йөгерде; бераз вакытка су өсте бызырдап-ургылып торды да, кинәт еракта, Иртыш җәймәсендә бригадирның киң аркасы, яртылаш суга чумган башы калкып чыкты. Көчле беләкләрен алмаштилмәш селтәп ишә-ишә, ул бар көченә алга ыргылды.

Яр буендагылар хәзер бары аны гына күзәттеләр, һәм күпмедер вакытка Мансур истән чыкты.

— Мансур кая?— диде кинәт Зәкия. Барысы да Иртышның менә хәзер Мансур йөзеп барырга тиешле турысына текәлделәр.

— Кая ул?

— Юк бит, юк!— диештеләр кызлар.

Мансурны Барый бер генә минутка да күзеннән ычкындырмаска тырышты. Бары тик бермәлне генә Мансур күренми торды да, тагын өскә калкып чыкты.

«Бата!» — дип уйлады бригадир һәм соңгы көчен бергә җыеп, тагын да кызурак йөзәргә тотынды.

Бик озак тоелган берничә секундтан соң, ул, ниһаять, Мансурга якыная төште.

— Борыл! Ярга борыл!— дип кычкырды ул. Якында гына боеручан тавыш ишетеп, Мансур әйләнеп карады, ләкин, берни булмагандай, һаман үз юнәлеше белән йөзүендә булды.

— Борыл!— дип кычкырды Барый тагын да.

— Мине... коткарырга килдегезме?— диде егет, елмаерга тырышып.— Моның іше... Иртышны гына...

— Әйдә минем арттан!— диде бригадир.

— Моның іше генә... Иртышны гына...— диде Мансур, һаман бер үк сүзне кабатлап.

Бригадир кире йөзә башлады. Мансурның үзе артыннан иярүен һәм шактый тигез, җиңел йөзүен күреп, аның күңеле үз урынына утыргандай булды. Аңа ул үзе яныннан гына барырга кушты. Ләкин Мансур, бераз гына янәшә барды да, көчле бер омтылыш ясап, көтмәгәндә алга чыкты һәм, күрдеңме инде! дигән сыман елмаеп, артына борылып карады.

«Кара син аны!» — дип уйлады Барый.

Ярга җиткәнче алар шулай алды-артлы йөзеп бардылар. Вак таллыкка килеп чыктылар да, аяк асларында каты җирне тойган хәлдә, икесе дә еш-еш тын алып, беркадәр вакыт хәл җыеп тордылар. Өсләреннән шабырдап су акты, җиргә сеңдерердәй булып, иңбашларына ниндидер коточкыч авырлык басты, юеш тәннәрендә исә, рәхәт кытыклап, кояш нурлары уйнады.

— Соңгысы булсын, кара аны, комсорг!— диде Барый, кисәтеп.— Нинди башбаштаклык ул!

— Минем әле Иделне дә йөзеп чыккан бар,— диде Мансур, мактанып.— Иртышны гына...

— Әнә нинди котырынып ага! Белмәгән-күрмәгән... беренче мәртәбә... Тот та ташлан, имеш! Кыюлык түгел, ахмаклык бу!

Монысында Мансур эндәшмәүне яхшырак тапты. Күңеленнән ул чыннан да кыюлык, батырлык күрсәттем дип уйлады. Бригадирның шелтә сүзләреннән соң, шундук аның кикриге шиңде.

— Әйдә, көтеп торалардыр,— диде Барый, кузгалып. Юан, таза аяк балтырлары кара төк белән капланган бригадир, башын чак-чак кына алга таба иеп һәм шәрә беләкләрен әкрен генә селтәштерә-селтәштерә, таллыкка таба атлады. Иренгән сыман шулай ук әкрен генә атлап аның артыннан Мансур иярде. Аяк астында сайлап салынган-

дай чиста, шома вак ташлар кыштырдады, баш өстендә яңгыравык, шат тавыш белән кычкырып, акчарлаклар очып йөрде, артта, беркемгә, бернәрсәгә колак салмыйча, мәңге хәрәкәттә яткан ташкын дәрья шаулап калды.

— Менә кыш кына җитсен,— диде бригадир, килешүчән бер йомшаклык белән.— Ныгытып төпләник тә, спорт секцияләре оештырып җибәрербез. Бокска тотынырбыз. Мин синнән менә дигән боксер ясыйм!

— Ник кыш җиткәнне көтәргә?— диде Мансур.

— Көтәргә туры килә шул. Аны бит болай гына булмый... коры кул белән генә. Вакыты да андый түгел. Каян өлгермәк кирәк барысына да! Тормыш бит әле яңа гына җайланып бара. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Мансур, теләмичә генә.

Яр буендагы иптәшләре аларны шаулашып каршы алдылар. Берсе хәлләрен сорашты, икенчесе мактау, соклану белдерде, өченчесе шелтәләп алган булды. Ләкин Мансур беркемгә берни эндәшмәде һәм караңгы чырай белән күлмәк-ыштанын кияргә тотынды.

Аның киенеп бетүе булды, ничектер бик мут елмаеп, җиңнәрен сызганып, аның янына Һарун килеп җитте.

— Әйдә көрәшәбез!— диде ул аңа.

— Арытты. Нинди көрәш әле ул монда!— диде Мансур.

— Бик әйбәт — көчләр тигез булыр. Синдә бит арыган чакта да биш кешене борып салырлык көч-куәт бар!— диде Һарун, яшь егетнең мин-минлеген уятырга исәпләп.

Аның Мансур белән көрәшергә ниятләвен күреп, кызлар шундук моңа каршы төштеләр. Белугин әйтте, йөз грамм кирәк, йөз граммсыз чирләп китүе бар, диде. Илгиз белән Кәрам, күрәсең, Мансурның җиңелүен, хурга калуын күрәселәре килеп, аны төрлечә кыздырырга, котыртырга тотындылар. Аларга башкалар кушылды. Төрле яктан үзен эткәли-төрткәли торгач, кыстый-үчекли торгач, Мансур түзмәде, ни булса булыр дигәндәй, кулын селтәде дә:

— Әйдә!— диде.

## IX

Аларны чабылмаган болын уртасынарак алып киттеләр, биек үләнне таптап тигезләделәр дә көрәш мәйданы әзерләделәр һәм икесен дә төрле яктан уратып алдылар. Белугин каяндыр тиз генә ике сөлге алып килде, сөлгенең берсен Мансурга, икенчесен Һарунга тоттырды да, кулларын югары чөеп:

— Башлыйбыз! Татарча көрәш!— дип белдерде.— Җиңүчегә — йөз грамм! Юк, ике йөз грамм!

Һарун белән Мансур бер-берсенә якынрак килделәр, бау шикелле бөтәрләнгән сөлгеләре белән бер-берсенең билләреннән уратып алдылар. Көрәшчеләр, аякларын җиргә терәп бастылар да, иңбашлары белән бер-берсенең иңбашына тиеп торган хәлдә, нык тартылган сөлгеләре белән бер-берсенең билләрен сынап карагандай иттеләр. Икесе дә әз генә дә кымшанмады. Беравык шулай сагаеп, сакланып торгач, икесе дә кинәт кенә селкенеп куйдылар һәм арка сөякләрен шытырдатып кыскан сөлгегә бирешмәскә, киресенчә, үз дошманын кысып алып, җиргә атып бәрергә чамалаган хәлдә, кызарынып, көчәнеп тартышырга, түгәрәк мәйданчык уртасында таптанырга тотындылар.

Шул чакны Мансурга нидер булды: әллә кулы тирләде, әллә бүтән нәрсә килеп чыкты — сөлгесен рәтләмәкче булып, ул бераз гына кулларын ычкындырып җибәргәндәй итте. Шул ук секундта бөтен тәне, баштагы ныклыгын югалткандай, искәрмәстән сыгылып китте. Һарун аны шундук күкрәгенә кысып алды, кысып алды да, җилтерәтеп күккә дә күтәрде.

Халык гөж килде. Тик шулай да халык иртәрәк гөжләде. Ул арада Мансур аякларын тиз генә ике якка аерып җибәрде, башта сул аягын җиргә тидерде, аннары уң аягына басты да, үзен кыршау сыман кысып торткан көчле куллардан тартылгандай итте дә ярсып шунда Һарунның үзенә ташланды.

Нәрсә булганлыгын Һарун искәреп тә өлгермәде — ул бары үзенең җирдән аерылганлыгын гына тойды, һәм шул ук секундта диярлек бөтен җир өсте гөрес итеп китте. Аның күзләреннән яшелле-зәңгәрле очкыннар чәчрәде, әллә арка сөяге, әллә калак сөяге чатнап киткәндәй булды. Күпмедер вакыт ул, ныклап аңына килә алмыйча, чытык, кызганыч йөз белән җир өстендә сузылып ята бирде.

Бераздан аның колагына дөнья бетереп шаулашкан, кул чапкан тавышлар ишетелде. Шундук аның башына кан йөгерде. Аны кинәт ярсу биләп алды, аның торып үзен шулай хур иткән кешенең якасына барып ябышасы килде, әмма чатнап торган каты авырту, җиргә кагып куйган сыман, әз генә дә аңа кузгалырга ирек бирмәде.

Батыр чыккан Мансур, бөтәрләнеп беткән сөлгесен күтәрде дә, цирк көрәшчеләре кебек, әле бер якка, әле икенче якка карап баш иде, елмаеп җибәрде. Кемдер аның аяк астына ике-өч конфет ыргытты, икенче берсе бер пачка печенье ташлады.

Бригадир, уртага чыгып, Мансурның кулына өр-яңа шахмат тоттырды. Шаулатып тагын кул чаптылар.

— Батырга кем чыга?— диде Барый, Мансурның кулын күтәреп.

Җиңнәрен сызганып чандыр Кәрам килеп чыкты, җирдә аунап яткан конфет белән печеньене алды да батыр кулындагы шахматка үрелде.

— Буләкләреңне җыеп барам — уртак булыр!— диде ул.

— Кем чыга, кем?— диде Барый, соравын кабатлап. Шунда Һарун көч-хәл белән аягына басты. Көлешү, шаулашу көчәя төште.

— Җиңдеңме?!

— Гел син генә булмассың!— диештеләр берәүләр.

— Биле сынган! Ашыгыч ярдәм кирәк!— диештеләр икенчеләре, үчекләшеп.

Һарун, җир тишегенә керердәй булып оялса да, ачы сүзләр колак итен көйдереп-көйдереп алса да, бүтәннәргә ияреп, берни булмагандай елмайган булды, көлгән булды. Халык ныграк көлсен өчен әле бер як янбашын тотып карады, әле икенче як янбашын тотып карады һәм, юри аксаклап, түгәрәк уртасыннан чыгып китте.

— Ягез, батырга беркем дә юкмыни?— диде Барый, янә соравын кабатлап.

Өстендәге яхшы күлмәген салып ташлап, уртага Илгиз килеп керде.

— Мин батырга!— диде.

Аңа Һарунның сөлгесен бирделәр, ләкин Илгиз аннан баш тартты.

— Җиңелгән кеше сөлгесе белән көрәшмим мин!— диде ул, эре генә.

— Мә, алайса, минекен,— диде Мансур. Алар шундук алыша башладылар. Көрәш бер-ике минут чамасы гына дәвам итте. Мансур Илгизне дә күтәреп бәрде. Тагын дер селкетеп көләргә, шаулашырга тотындылар.

Илгизнең дә егылуын күреп, егетләр кызып киттеләр. Һәркемнең батыр чыгасы килде, һәркем инде Мансурның, ниһаять, арыган булуы ихтималына исәп тотты, ләкин, кем генә чыкмасын, барысы да бер-бер артлы җиңелә торды. Өч-дүрт кешедән соң бүтән бер генә кыю кеше дә табылмады.

— Барый абый, Барый абый, әйдә син!

— Бригадир, чык батырга!— дип кычкырдылар төрле яктан.

— Куркам,— дигән булды Барый.— Сезне күтәреп бәргәнне... мине генә инде ул!..

Ул моны шаярыбрак әйтте, шулай да күңеленнән чын-чынлап шүрләп куйды. «Каян беләсең аны, алыр да орыр!»— диде ул үз-үзенә.

— Теләүчеләр юкмы?— диде ул, төркемгә карап.— Булмаса, быелгы сезон чемпионы Мансур...

— ...белән мин!— дип ялгап алды Кәрам һәм шундук Мансур янына барып басты.

— Көрәш тәмам!— дип белдерде бригадир.— Хәзер — күз бәйләп чүлмәк вату.

## X

Төш җитүгә, аш өлгерде. Үлән исләре, чәчкә исләре белән аралашып болынга тәмле, кайнар исләр таралды. Ачыккан кешеләр казан тирәсенә җыелдылар, табын булып утырдылар һәм көтә башладылар. Бригадир әрҗә өстендәге япманы ачып җибәрде, берәрсе чәлдермәде микән дигәндәй, оядагы шешәләрне күздән кичерде, әрҗәне үз янына утыртып куйды да бергә җыйналган стаканнарга, кружкаларга тигез итеп сала башлады.

Мәҗлес башланды. Беренче тостны «яңа җирдә үткәргән беренче яз өчен, язгы чәчүне уңышлы тәмамлаган өчен» эчтеләр. Аш алдыннан беркадәр тынып торган тавышлар яңадан көчәеп китте. Түгәрәкләнеп утырган табын аша бер-берсенә эндәшеп сүз кушкан, табак-савыт шалтыраткан тавышлар ишетелде. Кемдер җыр башлап җибәрергә азапланды, кемдер чыркылдап көләргә кереште.

Беренче стакан Һарунга бик әз булып тоелды. «Янган йөрәген» басу өчен аңа бер шешә эчеп бетерсә дә җитмәс шикелле иде. Әмма эчкәннән соң биш минут вакыт үтмәде, тәнендә ул гаҗәеп җиңеллек тойгандай булды. Кинәт аңа бик тә күңелле булып китте, әле генә эчен пошырган хурлыклы нәрсә бик вак булып, бик әһәмиятсез булып калды. Баштарак аның күңеленә, Мансур белән икенче дуслашмыйм, аның урынына бүтән кеше алам, дигән бер тәкәббер уй да килеп киткән иде. Үзен күңелле хис итә башлагач та, ул мондый уеннан кире кайтырга мәҗбүр булды. Чөнки ни әйтсәң дә, Мансур ярыйсы гына егет, аның белән алай тиз генә аерылышу да мөмкин түгел. Кеше алдында шулай егып салган икән — нишлисең — ул бит батыр! Ул бит аны гына түгел, бүтәннәрне дә егып салды! Уен әшмени ул, иптәшкәем, батыр бит ул! Батырга ник үпкә тотарга? Юк, шәп егет ул. Әгәр ул булмаса, алар шулай алдынгы да булып чыкмаслар иде, юк, валлаһи, чыкмаслар иде. Ул бит кап-

чыкларны туп урынына гына күтәреп йөртте. Беркайчан да карышмады, беркайчан бер каршы сүз әйтмәде. Алтын егет бит ул! Ничек итеп аның белән ачуланышасың?

Икенче стаканнан соң Һарун үзен тагын да җиңелрәк, тагын да күңеллерәк хис итә башлады. Барлык дөнья кайгылары каядыр юкка чыкты. Үзендә ул моңарчы булмаган бер иркенлек тойды, нишләргә, кая барырга теләсә дә, нинди сүз сөйлисе килсә дә — барысын да, барысын да булдыра алыр шикелле тоелды.

Өченче стаканны күтәрер алдыннан, алпан-тилпән атлап, алар янына Ислам килеп җитте, стаканын башта Һарунныкы белән, аннары Вәгыйзьнеке, Мансурныкы белән чәкештерде дә, элекке явызлыкларыннан тәүбә иткән бер кыяфәттә:

— Их, җегетләр!— диде.— Эш вакытында төрлесе була, үпкәләштән булмасын, и бетте-китте! Яшь гомерләр үтәкитә, татулыкка ни җитә!

— Ыщту син, Ислам абый! Узган эшкә салават!— диделәр егетләр.

Исламнан соң алар янына кызарынып, кулларын бутап Белугин килде. Ул да шул ук сүзләрне кабатлады, Һарунны мактады, Вәгыйзьне, Мансурны мактады, авызына китергән йомрысын кире алды да, сул кулын югары күтәреп:

— Иптәшләр! Иптәшләр!— дип кычкырды.— Тыңлагыз әле мине, бер сүз әйтәм. Бу тостны мин Һарун өчен күтәрергә тәкъдим итәм!

— Дөрес, күтәрәбез!— диештеләр төрле яктан. Ашагач-эчкәч, болында — табыннан читтәрәк — күмәк уен башланып китте. Илгиз гармунда уйнады, кызлар биеде. Җыелган кешеләр, биючеләрне дәртләндереп, кул чабып тордылар.

Уен башланганда, Һарун табын янында утырып калды. Ләкин күп тә үтмәде, көлеп-елмаеп, хушбуй исләре аңкытып, аның каршысына Зәкия килеп басты; җиңел генә аның кулыннан алды да, шелтә дә, үпкә дә белдергән бер кыюлык белән:

— Тумас борын картайгансың икән, Һарун!— диде.— Нишләп утырасың — әйдә биергә!

Һарун шундук урыныннан сикереп торды.

— Биергә? Киттек! Биергә!

Аларга барысы да юл бирделәр, уртага чакырдылар. Һарун ялындырып тормады — Зәкиядән кулын ычкындырды да, өйрәнмәгән аю кебек, алпан-тилпән килеп, биергә дә керешеп китте.

Биеп туктагач, бөтенесе аңа бердәм булып кул чабарга тотындылар, шәп, шәп, диделәр, тагын, тагын, диделәр. Ачык изүле күлмәген ике куллап тоткан көе, җилләнә-җилләнә ул читкә китеп барды.

Шул чакны ул уенчылардан беркадәр читтәрәк, сирәк куаклар арасында ниндидер сыерлар күреп алды. Сыерлар, ашана-ашана, әрәмәлектән ачык җиргә чыгып киләләр иде. Алар берничә генә дә түгел иде, алар бөтен бер көтү иде, ахрысы. Ләкин нинди көтү булыр бу? Бит совхозның үз маллары юк.

Көтүдән бигрәк, Һарун атка атланган яшь кенә көтүчегә игътибар итте. Казакъ егете туп-туры аңа таба килә иде, дөресрәге, башкалардан узып киткән зур ала сыерның алдына төшмәкче була иде.

Менә ул якынайды һәм киреләнеп һаман читкә каерган сыерга кычкырып җибәрде. Аның яңгыравык тавышы бөтен болынга таралды. Тик шулай да уен белән мавыккан яшьләр аның тавышын ишетми калдылар. Һарун исә кинәт айнып киткәндәй булды. Бу тавыш аңа бик тә таныш тоелды, һәм ул, беравык урынында карап торды да, куе үлән ярып, көтүче каршысына йөгерде.

Алга чыккан сыер, Һарунны күреп, туктагандай итте һәм шундук көтү ягына борылды. Аны шулай ук башка сыерлар да күреп алдылар, башларын күтәреп, калын, юеш иреннәрен турсайтып, үпкәләгән сыман, аның килеп җитүен көтеп тордылар. Көтү белән бергә көтүче дә туктап калды.

— Гөлбиби!— дип кычкырды Һарун, кулларын бутап.

Гөлбиби дә аны танып алды, елмайгандай итеп куйды.

— Гөлбиби, Гөлбиби, синме бу?!— диде Һарун. Ул күрешү өчен кызның янына ук бармакчы булды, ләкин сагаеп, күзләрен уйнатып торган яшь ат өркеп кисәк кенә башын югары күтәрде, авызлыгын чәйнәп читкә тайпылды.

— Аманмы, Гөлбиби!— дип кычкырды Һарун.

— Аман, Һарун,— диде кыз, елмаеп, куанып. Ул атын тыя төште, тезгенен тартыбрак тотты.

— Бездә сабан туе. Әйдә безнең янга!— диде Һарун, уенчыларга күрсәтеп.

Гөлбиби бригада кешеләре ягына күз төшереп алды да башын чайкап:

— Җок. Ярамайды,— диде.

— Әйдә, әйдә! Нәрсә куркып торасың?— диде Һарун.— Мансур да анда, Фәридә дә, Рәшидә дә... синең иптәшләрең. Әйдә, хәлне белеп китәрсең.

Ул яңадан ат янына килмәкче булды, әрсезләнеп

Гөлбибине атыннан ук тартып төшермәкче булды. Ләкин аның урыныннан кузгалуы булды, казакъ кызы тезгенне бушайтып җибәрде дә өзәңге тимере белән атның корсагына җиңелчә генә төртеп алды. Көлә-көлә, ул Һарунга нәрсәдер әйтте һәм атын юыртып китеп тә барды. Яңадан Иртыш буенда аның шат, яшь тавышы яңгырады.

Шул ук вакытта диярлек «нугай» егете әле генә көтү чыккан куаклар арасында икенче бер атлы кешене күреп алды. Монысы Байболат карт иде.

«Карт шайтан!»— дип уйлады Һарун, кызга ачуланасы урында аның атасына ачуланып. Аның Байболат белән очрашасы килмәде, һәм ул, ераклаша барган яшь көтүче ягына карана-карана, үзенекеләр янына китеп барды.

Болында әле булса җыр-бию, уен-көлке дәвам итә иде...

## XI

Сабан туенда егетләрнең кайберсенә исерткеч җитми калды, дөресрәге, тулысынча аларның нәфесен канәгатьләндерерлек, аларны чын-чынлап аяктан егарлык булмады, һәм алар, бер-ике сәгатьтән үк айный башлаулары белән килешә алмыйча, бригадирдан тагын булмаган нәрсәне таптыра башладылар.

— Бетте,— диде Барый,— ышанмасагыз әнә ящикны барып карагыз.

— Син әле үзеңә дә калдырмагансыңдыр, бригадир?— диде Белугин.

— Синең өше туймас тамаклар барында калдырырсың!— диде Барый.— Кайтканда тагын кибеткә тукталмый булмас, ахрысы,— диде ул аннары, үзалдына сөйләнеп.

Аның бу сүзләрен ишетеп алдылар, хуп күрделәр һәм тизрәк кайтып китү ягын чамалый башладылар. Ләкин кибеттә эш сәгате беткәнче барыбер кайтып өлгерә алмадылар. Кибет ябык иде, ишеккә аркылы төшеп, озын, яссы тимер сузылган иде, тимернең бер башында исә зур, авыр йозак асылынып тора иде.

Кызмача егетләр үзара киңәштеләр дә, болай гына кайтып китмәскә, ничек тә кибетне ачтырырга дигән фикергә килделәр. Аларга бригадир да кушылды. Алай гына да түгел, бөтенесен ул үзе башкарып чыгарга булды һәм, үзенә берәрсе иярә-нитә күрмәсен дигән сыман, ашыгып:

— Шушында гына торып торыгыз, таралышмагыз,— диде.

Кая барырга ниятләве турында ул берни әйтмәде. Әйтмәсә дә аны бик яхшы аңладылар. Кая барырга мөмкин ул? Әлбәттә, иң әүвәл Мәрьям янына. Исламның йөзенә кинәт тынычсызлану билгесе чыкты. Ул бригадирга бер сөзеп карады да иреннәрен тешләп куйды.

Барый Мәрьямнең кайсы йортта торганлыгын белә иде. Ләкин аңа әле бер генә мәртәбә дә анда булырга туры килмәгән иде. Кибетнең бикле булуына ул чын күңелдән сөенде. Моннан да уңай вакытның булуы да мөмкин түгел. Хәзер ул аны күрергә тиеш, сөйләшергә тиеш. Ачыктан-ачык. Бернинди тартынусыз. Ни булса да булыр.

Үзалдына шулай уйланып барганда, аның күңеленә: «Кем белә, бәлки, инде мин соңга да калганмындыр!» — дигән бер уй килде. «Юк, йөрмәскә!» — диде ул аннары, йодрыкларын кысып. Үзе һаман алга атлавында булды. Мондый чакта еш кына булганча, ул үзен юатмакчы булып карады, ник болай башымны катырам әле, диде; Ислам бит Фәридә белән чуала, диде. Фәридәне исенә төшергәч, уйлары тагын буталды. Ул аның соңгы көннәрдә бик күңелсез йөрүе турында уйлады, аның бу күңелсезлеге белән теге вакытта чатырда елап ятуы арасында бәйләнеш табарга тырышты, һәм искәрмәстән Мәрьям бөтенләй артка чигенде.

Сатучы тора торган йорт янына килеп җиткәндә, аның инде кыюлыгы да, кыюсызлыгы да юкка чыккан иде. Аның күңелендә хәзер бер генә ачык уй-фикер дә, бер генә билгеле теләк-омтылыш та юк иде. Шуңа күрә Мәрьям бүлмәсенең ишеге каршысына килеп туктагач, ул үзендә әз генә дә тынычсызлану шикелле нәрсә тоймады. Ишекне ул бик тыныч шакыды һәм бүлмәгә дә тыныч кына барып керде, күптәнге таныш кешесенә, көн дә күреп күнеккән кешесенә барган кебек барып керде.

Мәрьям кечкенә өстәл янында нәрсәдер тегепме, чигепме утыра иде. Барый килеп кергәч, ул кызарынып китте, тегүен-чигүен тиз генә йомарлап, каядыр читкә яшереп куйды һәм, Барый һич тә көтмәгәнчә, балкып урыныннан торды, шундук аңа урын тәкъдим итте, изүе ачык халатының якаларын каплаштырып, уңайсызланып беравык урынында басып торды да, көтмәгәндә:

— Барый... сез... чыгып торыгыз...— диде.— Мин хәзер... Хәзер киенәм.

Аның мондый тәкъдиме Барыйга бик сәер тоелды, шулай да ул тоткарланып тормады — күндәм генә кыланып кире тышка чыкты. Мәрьямнең үзен ягымлы йөз белән каршылавы, килеп кергәч тә кызарынып китүе,

гомумән, үз-үзен серле-уңайсыз тотуы, йомшак, ягымлы тавышы — барысы да аның күңелендә өмет чаткылары кабызып җибәрде.

Ниһаять, Мәрьям киенеп бетте һәм елмаеп килеп тә чыкты.

— Гафу ит инде, куалап чыгаргандай булды,— диде ул караңгыда.

— Басып кергән шикелле булгач...— диде аңа каршы Барый.

Мәрьям, аның ни өчен килгәнлеген аңлаган сыман, берни эндәшмичә, тышкы ишеккә таба атлады. Алар сүзсез генә кибеткә таба юл тоттылар.

Мәрьям бернәрсә турында да сораштырмады. Хәзер аны бер генә нәрсә дә кызыксындырмады. Ул бары Исламнарның Иртыш буеннан кайтуларын гына белде, үзенең менә хәзер аны күрергә, мөмкин булса, аның белән сөйләшергә тиешлеген генә белде. Ихтимал, бүген ул монда да калыр. Ул калырга тиеш. Ул калмый булдыра алмас. Аларга сөйләшергә кирәк, бик күп нәрсә турында сөйләшергә кирәк. Шулкадәр вакыт үпкәләшеп яшәргә, бер-береңнән аерым яшәргә мөмкин түгел. Моңа хәзер чик куелырга тиеш. Ул хәзер качып-посып яшәмәячәк, качып-посып яшәргә инде мөмкин дә булмаячак. Ул аңа ачыктан-ачык әйтәчәк. Тагын үзсүзләнә икән, бөтен халык алдында әйтәчәк! Җитәр, күп йөрде алданып, ышанып... Моннан соң болай булмаячак, моннан соң бөтенесе үзгәрәчәк. Тагын киреләнә икән, ул чагында... ул чагында... Ул барыбер көрәшәчәк, теше-тырнагы белән тартышачак!

Ислам киреләнсә, үзсүзләнсә нәрсә эшләячәген әле ул үзе дә анык кына белмәде, тик шулай да ниндидер зур эш, бөтенесен шаккатырырдай коточкыч эш эшләячәген бик яхшы аңлады. Ул үзендә хәзер бөтен дөньясын пыран-заран китерердәй бер көч сизде. Ул үзенең кая басканын да белмәде. Аннан калышмас өчен Барыйга хәтта ашыгырга ук туры килде.

## XII

Бригадир кибетчене эзләп киткәч, Ислам үзенең дусларын читкәрәк чакырып алды да башкалар ишетмәсен өчен пышылдап кына аларга үзенең «бер планын» сөйләп бирде.

— Мин,— диде,— мондагы кибет күселәренең иң олысы белән таныш.

— Беләбез инде, беләбез!— диде Кәрам.

— Нәрсә беләсең?!— диде Ислам.

— Юк, юк, белмибез!— диде Кәрам.

— Кыскасы, чыгарыгыз акчаларыгызны!— диде Белугин, Исламның аңлатып бетергәнен дә көтмәстән.

Хәер, егетләргә аңлатып торуның кирәге дә юк иде. Исламның башка вакытлардагы шикелле тагын төп башына утыртып калдыруы бик мөмкин булса да, кесәләрендә бер кочак акча булганда һәм, бигрәк тә, тамаклары күптән инде кыткылдап торганга, беркем дә саранланып маташмады: кайсы егерме бишне, кайсы иллене сузды.

— Белеп торыгыз, мин сезгә ящигы белән алып кайтам!— дип мактанды Ислам, болай да кызмача күңелләрне кыздырып.— Тик, карагыз аны, бригадирга ләм-мим! Үзебез генә беләбез, үзебез генә бәйрәм итәбез.

— Әгәр кибеттән бирсәләр?— диде Димка, икеләнгәндәй итеп.

— Бирерләр, тоттырырлар!— диде Ислам.— Бригадаларга бүлеп куйганнар икән, кибетче үз белдеге белән ничек сатсын? Ә күселәр җитәрлеген алып куйган булырга тиешләр. Шуның өчен дә күсе алар!

— Кайгырма, Димка, син алмасаң үзебезгә генә булыр.

— Артыгын коега салырбыз,— диделәр дуслар, остарып.

Шул чакны якынаеп килүче бригадир белән Мәрьям күренде.

Килеп җиткәч, Мәрьям сабан туеның ничек узуы турында, Иртыш буйларының ямьлелеге турында бер-ике сүз сорашты да, зур ачкычын тотып, күтәрмәгә менде.

— Кемгә нәрсә?— диде ул, кибеткә керешли.

— Аракы, аракы!— дип кычкырдылар егетләр төрле яктан.

— Аракы?— диде Мәрьям, гаҗәпләнеп.

Ул бары шунда гына мәсьәләгә төшенеп алгандай булды. Башка берни әйтмичә, ул кибетнең товар саклана торган икенче як бүлмәсенә чыгып китте. Пычкы чүбенә буялган дүрт шешә алып чыкты да шешәләрне Барый алдына китереп куйды.

— Артыгы булмый,— диде ул.— Ярамый. Сезгә инде алдынгы бригада булган өчен генә... Ул Барыйга елмайгандай итеп куйды.

— Булды, булды! Монысына да рәхмәт!— диештеләр егетләр, күңелле шаулашып.

Аласы нәрсә алынып, кибеттә йомышлар беткәч, бригадир машинага утырырга кушты. Ул үзе арткарак калды. Мәрьямгә тагын рәхмәт әйтте, үзенчә кызның күңе-

ленә шом салып карады, әллә безгә кунакка барасызмы соң, диде, мотоцикл белән китереп куяр идем, диде.

Мәрьям дә рәхмәт әйтте, сез бик еракта торасыз шул, дигән булды. Ул тизрәк тышка чыгарга, кирәкле кешесен күрергә ашыкты. Әрсез бригадир исә, ачу китереп, юлына аркылы төште һәм әйдәләп чыгармасаң, үзе белеп һич тә чыгар төсле күренмәде.

Ул тышка чыкканда инде кибет алдында беркем калмаган иде, барысы да машинага төялешеп беткәннәр һәм кузгалып киту өчен бары бригадирларын гына көтеп торалар иде. Барый кабинага кереп утыргач та, машина гүелдәп, газ исе таратып китеп тә барды.

Мәрьям хәлсезләнеп калгандай булды. Кулындагы тимер йозак, ике потлы гер кебек, коточкыч авыр тоелды. Ул ишекне бикләде дә җиргә төште, әле, һаман аны күрмәкче булып, артына борылып карады, кибет тирәсенә, йортлар арасына күз йөртеп чыкты. Тирә-як бупбуш иде.

## XIII

Аның һич тә өенә кайтасы килмәде. Аның күңеле һаман дала ягына, машина китеп барган якка тартылды. Аның ачуланасы килде, рәнҗисе килде. Ләкин шулай да ачулану гына, рәнҗү генә монда бик аз булыр шикелле тоелды.

Онытылып ул дала ягына карап торды-торды да, теләр-теләмәс кенә өенә борылды. Бүтән вакытта дүрт-биш минут чамасы йөри торган араны ул хәзер икеләтә-өчләтә озаграк кайтты.

Черегән салам, тирес һәм мал-туар исе аңкытып торган саман йорт алдына кайтып җиткәч тә, ул, буш, ялгыз бүлмәсенә керәсе килмичә, бераз вакыт ишек төбендә тукталып торды. Тирә-як, шәрә табигать аңа бик тә котсыз булып, ят һәм ямьсез булып тоелды. Аның күңеле тагын сыкрап-сызлап куйды, һәм ул, елап җибәрүдән куркып, тизрәк түбә астына керде. Бүлмә ишеген тартып җибәрсә, ишек биксез булып чыкты. Ә бүлмәдә... бүлмәдә балкып ут яна иде. Тәртәдәй озын аякларын карават янындагы урындыкка сузып салган килеш, ап-ак җәймә, мендәрләр өстендә Ислам ята иде.

Мәрьям, ни әйтергә белмичә, беравык аңа карап торды да, бугазына килеп тыгылган төер сыман нәрсәдән кытыкланып, елмаеп җибәрде, кулындагы ачкычын өстәлгә ташлады, үзе шундук тәртә аяклы кешегә таба омтылды.

— Менә кайдасың икән син!— диде ул, тыелып кына.

— Озакладың,— диде Ислам.

— Мин инде сине китте дип торам,— диде Мәрьям, аның сүзен тыңламыйча.

Караватка утырды да, шаяртып Исламның каты чәчләрен маңгаена төшерде.

— Мине шулай бик күрәсең килдемени?— диде Ислам.

— Кем әйтте әле алай диеп?

— Алайса, минем сиңа бөтенләй кирәгем дә юк? Ислам, аякларын урындыктан алды да, торып утырмакчы булды. Мәрьям аны кире урынына екты, торгызмыйм дип, аның күкрәгенә капланды, артка кайтарылган озын чәчләрен яңадан тузгытып ташлады, ләкин ир кешенең кырыс йөзендә әз генә дә эрү билгесе күренмәде.

— Җә инде, бер генә елмай!— диде Мәрьям.

Ислам, бик ачулы кеше сыман кашларын җыерып, тын гына, авыр гына аны күзәтеп утырды. Мондый шомлы тынлык хатын кешенең эчен пошыра башлады.

— Тагын минем белән ачуланышыр өчен килмәгәнсеңдер бит?— диде ул.

— Әйе, ачуланышыр өчен.

— Булмас инде, аппагым, минем андый көнем түгел!— дигән булды Мәрьям.

Ислам эндәшмәде. Аннары тып-тыныч бер гадәти тавыш белән әйтеп куйды:

— Бригадир белән эшләр шәп барамы?— диде.

Аның бу сүзләре Мәрьямгә «кибеттә сатулар ничегрәк бара?» сымаграк тәэсир итте. Шулай да ул аның нәрсәгә ишарәләп әйтүен бик яхшы аңлады һәм, бала-чаганың берәр көтелмәгән мәзәк сүзеннән көлгән кебек, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Көлмә!— диде Ислам.

— Әллә җылыйм микән, Ислам?— диде Мәрьям, елмаеп, аның каршысына килеп.— Шул гынамы сүзең?

— Шул гына.

— Әллә мине көнлисең, Ислам?— диде Мәрьям, кыланган булып.— Әллә мин генә көнләшә беләм микән дигәнием, син дә көнләшә беләсең икән. Исең китәр!

— Син турысын гына әйт...— диде Ислам һәм кинәт төртелеп калды: нәрсәнең турысын гына әйттерергә теләгәнлеген ул үзе дә белмәде.

Мәрьямнең елмаюы шундук юкка чыкты. Җитди, боек йөз белән ул аш-су әзерләргә тотынды.

— Аның белән минем арада нәрсә килеп чыкканлыгын үзең күреп торасың,— диде Ислам, яңадан сүзгә башлап.— Ул булмаса, күптән инде без бергә булырыек.

— Анның безгә бер зыяны да тигәне юк,— диде Мәрьям.— Безнең бергә булу-булмауга беркем гаепле түгел, аппагым! Бары син генә. Үзең гаепле. Мин бөтенесенә риза: телисең икән, бүгеннән синең янга күченеп китәм. Кибете дә кирәкми, Көктугае да... Теләмисең икән, иртәгә үк директорга барам, парторгка барам, машина бирегез аңа, димен, бозмагыз безнең тормышны, димен!

— Барып кара!

— Болай булса, бармый да булмас! Җитәр, күп түздем! Көнләшәсең икән, минем ят ирләр белән сөйләшкәнне теләмисең икән...

— Төкерәм мин синең сөйләшүеңә!

— Алайса, ник дулыйсың соң?— диде Мәрьям, исе китеп.

— Мин сиңа теләсә нинди ирләр турында әйтмим. Мин сиңа бер генә кеше турында әйтәм. Бер мәртәбә инде ул минем юлны бүлде, тагын икебезнең арага керә икән... белеп тор!

— Икебезнең арага?!— диде Мәрьям, шаккатып.— Миндә синең балаң була торыпмы?! Акылың кая синең?

«Бала» сүзе Исламны тилертеп җибәрде.

— Бала! Әллә ул бөтенләй минеке дә түгелдер!— диде ул, ажгырып.

Мәрьям кисәк кенә башын калкытты, караватъ ягына борылып карады да, теле тотлыккан кеше сыман, нәрсә дә булса әйтергә теләп тә әйтә алмаган шикелле тынып калды. Ул хәтта моны тиз генә аңлап та җитә алмады. Аңа ул ялгыш ишетте шикелле тоелды.

— Телең корыр... Ислам...— диде ул, әрнеп, әкрен генә.

Аннары кечкенә өстәлгә арты белән терәлгән көе, тыела алмыйча елап җибәрде.

Кирәгеннән артыгын ычкындыруын Ислам үзе дә шәйләп алды, ләкин инде эш узган иде.

Шулай итеп, алар тагын ачуланыштылар, моңарчы булган барлык ачуланышулардан да ныграк ачуланыштылар. Бер-берсенә каты-каты сүзләр әйттеләр, янадылар, үпкә-шелтә белдерделәр. Берсенең әзерләнгән ашы онытылды, икенчесенең йомышы онытылды.

Инде тәмам бозылышкач һәм бер-берсен гаепләрдәй нәрсә бетте шикелле тоела башлагач кына, Ислам үзенең монда нинди максат белән килгәнлеген исенә төшерде; исенә төшерде дә, кырт кына борылып, кире чабарга тотынды; шулай, диде, болай, диде, гафу ит, диде; бары сине генә ярatkанга шулай көнләшәмдер, диде; менә бергә тора башласак, берни булмас, диде; күпкә түзгәнне әзгә түзәрбез, диде.

Мәрьям эреде дә китте. Күз яшьләре дә кипте, дәрте дә кузгалды, йөзенә хәтта елмаю билгесе дә чыкты. Аш янында алар тыныч кына, тату гына утырдылар.

Ашау-эчү тәэсирендә алар тагын шул ук нәрсә турында — әле генә үзләрен талаштырган төп нәрсә турында сүз башлап җибәрделәр. Монысында инде алар бөтенләй икенче төрле итеп, үртәлмичә, кычкырышмыйча сөйләштеләр һәм озакламый уртак тел тапкан сыман да булдылар. Ләкин һәркем үз фикерендә калды, һәм үз фикерен һәркем ераграк, тирәнрәк яшерде.

Тамагын туйдыргач, бераз ял итеп алгач, Ислам җайлап кына кайту турында сүз кузгатты. Аның шулай буласын Мәрьям алдан ук сизенгән иде. Ул бары көрсенеп кенә куйды. Ислам, үзенең ни өчен кайтырга тиешлеген аңлатып, үзалдына нидер сөйләнергә тотынды. Иртәгә эш башларга кирәк, диде, миңа хәзер бригадир белән бозылышырга ярамый, диде. Мәрьям, башын иеп, теләр-теләмәс кенә өстәл җыештырды.

Ислам торды, җыена башлады һәм инде кузгалып китәргә генә торганда, карават астына ымлап:

— Бармы анда?— диде.

— Ал, ал!— диде Мәрьям, ашыгып.— Нәрсә сорап торасың... күпме кирәк, шулкадәр ал.

Авыр гына мышнап, Ислам иелгәндәй итте дә карават астыннан берничә шешә тартып чыгарды. Шешәләрне кулына алу белән аның йөзе балкып китте, тавышы йомшарды, күз карашы, беркайчан да булмаганча, нурланып, ягымлыланып калды. Шешәләрне кесәләренә салгач, ул беравык икеләнгәндәй итеп торды, аннары мышнап, тамак кыргалап, куен кесәсеннән бер уч унлыклар, бишлекләр чыгарды.

— Мәле, алып куй әле шуларны,— диде ул, йомарланган акчаларны өстәлгә ташлап.

Һәрбер шешәнең фәлән сум, фәлән тиен торганлыгын һәм шул шешәләр өчен кайчан да булса бер исәп-хисап ясарга тиешлеген бик яхшы белсә дә, Мәрьям, аның кулында акча күргәч, кинәт үзгәреп китте. Ул аңа аптырау катыш куркып, хәтта нәфрәтләнеп карады.

— Син нәрсә?!— диде ул, күзләрен зур ачып.— Болай рәнҗеткәнең җитмәгән...

— Мин бит үземнекен бирмим,— диде Ислам, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.— Җегетләр өчен алам. Бушлай килми лә ул сиңа!

— Алар алмый бит, син аласың!

— Шулай да...

— Ничек оялмыйсың, Ислам!— диде хатын әрнү, сык-

рау белән.— Сатып алмакчы буласыңмы мине? Син бит минем ирем!

Үксеп, ул аның күкрәгенә ташланды. Ислам аны кочаклап алды, тук, тыныч бер тавыш белән:

— Шулай, шулай, ирең,— диде, аркасыннан сөеп.

## XIV

Бүген инде вакыт та соң иде, Фәридә белән Фәрханә апалар да арыганнар иде, шуңа күрә, һәркемнең ризалыгы белән, кичке ашны пешереп азапланмаска булганнар иде. Ләкин Фәридә, иптәшләренең андый ризалыгына да карамастан, титанда чәй кайнатмакчы булды. Шул ният белән ул учакка ут ягып җибәрде дә гадәтенчә кухня тирәсендә кайнашырга тотынды. Көтмәгәндә аның башы авырта башлады, хәле бетте. Чәен кайнатып чыгара алмады, вагонга кереп ятарга мәҗбүр булды. Иптәш кызлары чыш-пыш сөйләшергә, вагон белән кухня арасында тыз-быз чабышырга тотындылар. Ни булды?— дигән сораугa беркем дә ачык кына җавап бирмәде.

Чәйне Зәкия белән Рәшидә җитештерде. Кичке табынны да алар әзерләделәр. Чатыр эчендәге озын өстәлгә берничә газет җәйделәр дә табак-савытларны, кашыкларны, консерва һәм май, шикәр ише нәрсәләрнең барысын да шунда таратып ташладылар.

Табын әзерләнеп беткәч, Белугин бригадир вагонына кереп китте. Арып йокыга талган Барыйны ул ишек шакып уятты һәм өстерәп диярлек зур чатырга алып керде.

Барый, әле һаман йокылы күзләрен ачалмыйча, өстәл башына килеп утырды. Аның инде хәзер ашыйсы да, эчәсе дә килми иде. Татлы йокыдан аеруларына аның бераз гына ачуы да килеп тора иде, тирә-яктагы тавыш һәм каршыдагы утлы лампа бер дә юктан җанын үрти иде. Ләкин, алдан килешенгән булганга һәм шуңа күрә күпчелек теләгенә каршы килмичә, ул барысына да түзәргә булды. Күп тә үтмәде, көндезге сабан туеның дәвамы булып, кичке мәҗлес башланып китте.

Исламның Көктугайда торып калуын Барый әле бөтенләй белми иде. Гадәттәге тавыш, шау-шуга, ут яктысына ияләшә төшкәч, ул чатыр эченә игътибар беләнрәк күз йөртеп чыкты, әмма, никадәр генә каранса да, Исламны күрә алмады. Бүген ул нишләптер гел аның турында гына уйланды, гел аны гына күрергә тырышты. Ни өчен моның шулай икәнлеген ул аңлап та җитм-

әде, ләкин аңа, әгәр дә ул Исламны күрмәсә, аның тавышын ишетмәсә, нәрсәдер үз урынында булмас шикелле тоелды.

— Ислам кая?— диде ул үз янындагы Димкага.

Димка Исламның кайда икәнлеген, әлбәттә, белә иде. Ләкин ул туры җавап бирмәде, ы-мы итәргә тотынды.

— Сезнең белән кайттымы соң ул?— диде Барый.

Аның кем турында сораганлыгын ишетеп, сүзгә Ира катышты.

— Юк, кайтмады,— диде ул, кеше аша Барый утырган якка кычкырып.

— Көктугайда калдымыни?

— Бүтән кайда калсын? Анда бит аның сөяркәсе бар диләр...— диде Андронов, хатыны өчен җавап биреп.

Барыйга әллә ничек булып китте. Аның башына кан бәрде, һәм күпмедер вакыт эчендә ул үзенең кайда утырганлыгын да, нишләп утырганлыгын да онытып җибәргәндәй булды.

«Димәк, сөяркәсе?»— диде ул үз-үзенә, мондый нәрсәгә һич тә ышанасы килмичә. Димәк, чынга чыкты, моңа кадәр колакка чалынгалап калган төрле имеш-мимешләр дә, бүген көндез кибеттәге очрашудан соң туган сизенүләр дә — барысы да чынга чыкты?

Юк ла, булмас ла! Ә ник булмасын? Бәлки, ул бүген төнлә шунда калыр... аның янында... кечкенә, җыйнак кына шул бүлмәдә... Әгәр кайтса?.. Ух, кайтсын гына! Сөяген он итеп, авызын җимереп... типкәләп... бер минут торгызмыйча...

Ә Фәридә?! Әйе шул, Фәридә... Бүген ул шундый күңелсез йөрде. Ник? Димәк, чын! Димәк, сөяркәсе...

— Фәридә кая?— диде ул, як-ягына каранып. Үз эшләре белән мавыккан, кычкырып сөйләшкән, көлешкән кешеләр аның сүзен ишетмәделәр. Шуңа күрә аңа җавап кайтаручы булмады. Аның шундук, шушы секундта ук үз соравына төгәл җавап ишетәсе килде. Кисәк кенә ул урыныннан сикереп торды, кызларга эндәшеп:

— Фәридә кая?— диде тагын да.

Егетләр бер-берсенә мәгънәле генә күз кысышып алдылар. Берсе әйтте, Барый абый исерде, диде, икенчесе әйтте, юк, ул Фәридәгә гашыйк, диде. Кызлар да шулай ук бер-берсенә каш сикертеп алдылар, пышылдарга тотындылар.

— Авырып торале ул. Ята,— диде Зәкия, көттереп.

— Ни булган аңа?— дип кычкырды бригадир.

Һәм, Зәкиянең аңлатып торганын да көтмәстән, җилләнеп чатырдан ук чыгып китте.

## XV

Юрганына төренеп, Фәридә үзалдына үксеп ята иде. Барый, каршы як сәкедәге урын-җирне кайтарып куйды да, авыру янына килгән доктор сыман, кыз янына килеп утырды. Артык нечкәләнеп, әдәп-фәлән саклап тормыйча, ул Фәридәнең башына капланган юрганын аскарак тартты. Бүлмә эче бик үк караңгы да, бик үк якты да түгел иде, шулай да кеше йөзен аерырга була иде. Фәридә кызарынган, чыланган яшьле күзләрен шундук читкә борды һәм зәгыйфь бер хәрәкәт белән юрганын кире кайтарып куймакчы булды.

— Япма!— диде Барый, боеручан һәм шул ук вакытта йомшак бер тавыш белән.— Әйт дөресен генә... яшермичә генә... Ни булды сиңа?

— Сорамагыз, сорамагыз, Барый абый!— диде кыз, үксеп һәм шундук икенче ягына әйләнеп ятты.

— Курыкма. Оялма,— диде бригадир.— Мин барысын да беләм... Дөресме?

Нәрсәнең дөресме, түгелме икәнлеген ул әйтмәде, ләкин аның нәрсә турында әйткәнлеген Фәридә, әлбәттә, бик яхшы аңлады. Ул яңадан тыела алмыйча үксергә тотынды.

Барыйга бу баштарак бик җиңел тоелган иде, ләкин, кыз тарафыннан мондый каршылык күреп, ул аптырабрак калды.

— Алай булмый бит инде...— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Үз кешеләремне мин белергә тиешмен.

— Мин авырыйм, Барый абый,— диде Фәридә.

— Ярый, алайса, мин хәзер Рәйханә апаны чакыртам,— диде Барый, тиз генә урыныннан торып.

— Юк, юк!— диде Фәридә, кабаланып.— Чакыртмагыз, беркем кирәкми.

Аның шулай ялганлап ятуы бригадир кешенең ачуын китереп куйды.

— Нәрсә, авырмыйсыңмыни инде?— диде ул, кырыс кына.— Мин сиңа малай-шалай түгел. Әйтмисең икән, үзеңә үпкәлә. Сабый бала түгелсең, үзеңне үзең беләсеңдер. Ә Исламны җыелышта тикшерәчәкбез. Булдымы!

Шулай диде дә тузынып чыгып та китмәкче булды. Фәридә ашкынып башын күтәрде, бригадирны тотып калырга теләгән сыман, ялварып:

— Барый абый, Барый абый!— диде.— Тикшермәгез! Барый абыкаем!.. Үзем гаепле, барысына да үзем гаепле!..

Барый кире урынына утырды һәм бөтен күкрәгән дер

селкетеп авыр-авыр тын алган хәлдә, әйтер сүз таба алмыйча, Фәридәнең тартышкан кызганыч йөзенә текәлеп калды.

— Курыкма,— диде ул.— Мин үзем белермен. Тынычлан.

Үз хәле дә кайсыдыр ягы белән анықына охшаш булганга, бу сүзләрне ул шундый ышандыргыч итеп әйтте, Фәридәнең үксүе күз алдында басыла төште. Аңа кинәт кенә җиңел булып киткәндәй булды, үз әнисе янындагыча, иң якын сердәше янындагыча рәхәт һәм җиңел булгандай булды.

## XVI

Барыйның ашаучылар-эчүчеләр янына керәсе килмәде. Аның хәзер, гомумән, беркем белән дә очрашасы килмәде. Хәзер ул гаҗәеп бер тойгы кичерде: күзенә чалынган, кытыгына кагылган теләсә нинди чүп нәрсәгә каршы ташкын булып, давыл булып ыргылырга торган ярсулы бер тойгы кичерде.

Юк, бу хәтта ярсу гына да, нәфрәт кенә дә түгел иде, бер үк вакытта бу ачыну да иде, әрнү һәм сыкрану да иде — күңел түрендә йөрткән кешеңнең шундый булып чыгуы өчен, куктә йөзгән хыялыңның кинәт җиргә төшеп челпәрәмә килүе өчен әрнү һәм ачыну иде.

Юк, бу шулай ук әрнү һәм ачыну гына да түгел иде, бу тагын да үкенү дә, оялу һәм хурлану да иде — үзеңнең шул дәрәҗәдә беркатлы һәм бик тиз ышанучан булуың өчен, сукыр һәм томана булуың өчен оялу һәм хурлану иде.

Ләкин бу бары үкенү, хурлану гына да, әрнү һәм ачыну гына да түгел иде, монда тагын кызгану да бар иде — җиләк чәчкәседәй шундый япь-яшь кызның, фәрештәдәй саф һәм гүзәл кызның шундый ахмакларча алдануы өчен чын күңелдән кызгану бар иде.

Караңгы төшкән иде инде, түбә өстендә укмашып-укмашып кара болытлар капланып тора иде, түбәндә исә шашынып, котырынып черки өерләре кайнаша иде. Мондый вакытта далада йөрү түгел, вагоннан башыңны тыгып карарлык та түгел иде.

Юл буенча ул Көктугай ягына карап китте. Ул, билгеле, кая да булса барам дип бармады. Ул болай гына барды, йөрәге янган өчен генә, бер урында туктап тору мөмкин булмаган өчен генә барды.

Күпмедер киткәч, ул адымын әкренәйтә төште, бераздан бөтенләй үк туктап калды. Салкынча һава, чик-

сез-кырыйсыз бушлык, шул бушлык эчендә үз-үзеңне япа-ялгыз итеп тою һәм бигрәк тә утлы черкиләр аның кузгатылган, ташкын булып урыныннан купкан күңелен беркадәр дәрәҗәдә баса төшкәндәй булды.

Баягынак бригадир тышка юнәлгәч тә, аның артыннан ук кемдер ияреп чыккан иде. Барый кызлар вагонына кереп киткәч, ул «кемдер» тышта торып калды. Бригадир юл буенча китеп баргач исә, ул янә аның артыннан иярде. Барый аны күрмәде дә, сизмәде дә, чөнки ул бер генә мәртәбә дә артына әйләнеп карамады. Ләкин каршысына икенче бер карачкы — озын буйлы таныш карачкы калкып чыккач, ул аны күрми кала алмады.

Алар бөтенләй көтмәгәндә, бөтенләй искәрмәстән очраштылар. Исламны китерә килгән машина, бригадага килеп җитмичә, Барый вагоннан чыкканчы ук борылып киткән иде. Шуңа күрә бригадир аның утын да күрә алмады, тавышын да ишетмәде.

Ислам, бригадирга бер-ике адым каларак туктап калды да, дусларча бер гаҗәпләнү белән:

— Барый?!— диде.— Нишләп торасың монда берүзең?

Барый эндәшмәде. Ул, аякларын аерып баскан хәлдә, дошманына ыргылырга җайлы вакыт көткән юлбарыстай, тынын кысып, тешен кысып бер урында кымшанмыйча тик торды.

Караңгыда Ислам аның йөзен күрмәде һәм шуңа күрә аның монда нинди уй белән басып торуын да шәйли алмады. Аның күңеле бик күтәренке иде. Бригадирны ул үз вагонында гырлап ятадыр дип уйлаган иде. Ләкин әнә ул да йокламаган. Нишләп йөри ул монда? Исергәнме, әллә соң... Җитмәгәндер дә, аның менә кайтып җиткәнен түземсезлек белән көтеп йөридер... Таран кебек... Берәр тишек авызы ычкындыргандыр. Үзе тагын күңеленнән газапланадыр, алып кайтырмы, юкмы ди торгандыр. Аракы ул, иптәш бригадир, теләсә кемне үз кубызына биетә. Бер авызыңа эләксә, әллә нинди изге булсаң да, әллә нинди чыкылдап торган патриот булсаң да, иптәш бригадир, аяктан егып сала! Аракыда иблис көче бар анда, туганкаем, иптәш бригадир!

Ислам Барый белән мөмкин кадәр әшнәләрчә, куштаннарча булырга тырышты, аның күңеленә хәтта бригадирның иңбашына дусларча берне сугып алу теләге дә килде. Әмма шулай да аны ниндидер бер сагаю тойгысы тыеп калды. Кесәсеннән папирос, шырпы алып ул ут кабызып җибәрде. Шул эше белән мавыккан арада, үзе һаман сөйләнүендә булды.

— Син сорама, мин әйтмим дигәндәй... бер җирдә мин бер-ике шешә таптым әле. Тартмыйсыңмы? Әйдә кирәбез, нәрсә монда...

Барый һаман кымшанмады. Ләкин бу барысы ярты минут чамасы гына дәвам итте. Кинәт ул теленә килде. Бөтенләй ят, карлыккан бер тавыш белән, һәрбер сүзен теш арасыннан сыгып:

— Синең белән сөйләшәсе бар,— диде.

— Сөйләшик соң!— диде Ислам, тагын да ныграк сагая төшеп.— Нәрсә турында?

— Фәридә турында.

— Фәридә турында?!

— Бүген үк... хәзер үк... син аңа өйләнергә тиешсең!— диде бригадир, янаулы тонын әз генә дә үзгәртмичә.

Ислам шундук төшенеп алды. Ләкин берни аңламаган һәм чиктән тыш гаҗәпкә калган кебек, кинәт көләргә кереште.

— Син нәрсә... сорамаган җиргә кысылмакчы буласыңмыни?— диде ул, мыскыллы көлемсерәү белән.

Җавап урынына шул чакны караңгыда чатнап-шапылдап киткән тавыш ишетелде.

— Аы-ы, шула-аймы-ы!— диде озын карачкы, тамак төбе белән чинап.

Барый башын иеп калды — селтәнгән йодрык якында гына һава ярып үтте. Күптән инде ыргылырга торган ташкын көчкә ирек биреп, ул карачкының шешә тулы күкрәгенә тимер йодрыклары белән бер-бер артлы дөпдөп орып алды.

— Монда берсе белән, тегендә икенчесе белән... Хәшәрәт!

Ләкин Ислам тиз арада исен-акылын җыеп өлгерде, куенындагы бер шешәне тартып чыгарды да бар көченә кизәнеп җибәрде. Шул ук секундта шартлап пыяла ватылды, һаваны спирт исе белән бозып, күзләрне ачыттырып, як-ягына аракы чәчрәде. Барый чайкалып китте, ыңгырашып куйды һәм шундук кулы белән башына тотынды.

Шул чакны арттан килеп кемдер Исламга ябышты, аның бугазыннан кысып алды да каядыр аны аска, упкынга өстерәде.

## XVII

Якында гына тавыш-кычкырыш ишетеп, «авыл» ягыннан тагын кешеләр йөгереп килде.

Барыйга ни булганлыгын караңгыда рәтләп беркем дә күрә алмады. Аны култыклап аягына бастырмакчы булдылар, ләкин ул бик авыр булып чыкты. Кемдер шырпы сызып җибәрде һәм шундук коты алынып аһылдап куйды. Бригадирның сул як чигәсе кып-кызыл кан иде. Кызыл кан арасыннан яраланган биттә елтырап пыяла кисәкләре күренә иде. Кан шулай ук аның иягенә, муенына агып төшкән иде. Башындагы кепкасы да канга буялган иде.

Җыйнаулашып аны үз вагонына алып кerделәр, урынга салдылар. Кызларның берсе тиз генә Фәридә янына кереп китте. Бер-ике минуттан, кулына санитар сумкасы тотып, коты алынып Фәридә килеп керде. Керде дә сумкасындагы барлык бинтларын, йод, мамыкларын өстәлгә чыгарып салды һәм пыскып янган ут яктысында, куркып-кабаланып, эшкә дә тотынды. Иң элек ул күренеп торган пыяла кисәкләрен алды, аннары мамык белән кан тапларын сөрткәләде.

Фәридә үзе белгәнчә, җәрәхәтне җентекләп карады, чистартты да, мамык белән йод сөртте һәм, яралы башны тубалдай итеп, бинт белән урап бетерде. Ул арада бригадир исенә килде. Ярасы бәйләнгәч, ул сыңар күзен ачты да әкрен генә:

— Рәхмәт,— диде.

— Авыртмыймы, авыртмыймы, Барый абый?— диде санитар кыз.

— Юк,— диде бригадир.— Бетәр әле. Була инде ул.

— Ни булды соң, ни булды, Барый абый?— диде Фәридә, бригадирның күзенә керердәй булып.

— Аракы... беләсең инде...— дигән булды Барый. Бригадирның үз авызыннан мондый сүз ишеткәч, бүлмәдәге кешеләр өчен мәсьәлә тиешенчә ачыкланган кебек булды. Төпчену, кызыксыну кими төште. Моңа хәзер бик гади бер нәрсә итеп карадылар. Тик менә аек чакта шундый яхшы кешенең эчкәч бозылуы һәм бер дә юкка сугыша башлавы гына ничектер сәеррәк тоелды. Хәер, эчкәч кем дә шулай инде...

Барый, билгеле, бәрелешнең төп сәбәбен әйтә алмады. Әлегә ул моңа ничегрәк карарга кирәклеген ачык кына белеп тә җиткермәде. Ул бары үзенең төзәтеп булмаслык хата ясаганлыгын гына аңлады да, моннан соң Ислам белән икесенә бер җирдә эшләү дә, яшәү дә мөмкин түгел икәнлеген генә аңлады. Иртәгә үк ул директорга барырга, берничә карамый Исламны бригададан куаларга, бригададан гына түгел, совхоздан ук сөрдертергә дигән карарга килде.

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, кемдер, аның ишеген шакыды. Барый, күбеп чыккан яңагының, маңгаеның бик нык авырткалыгын тойган хәлдә, авырлык белән генә сыңар күзен ачты, шаку тавышына колак салып торгандай итте дә:

— Ишек ачык!— диде.

Бүлмәгә Ислам килеп керде. Барыйның шундук йокысы качты, тамырлары буйлап кан шәбрәк, кызурак йөрергә тотынды, һәм ул, башының авырлыгын да, авыртуын да онытып, кискен бер хәрәкәт белән урыныннан торып утырды.

Ислам якынрак килде, өстәл астыннан артсыз урындыкны тартып алды да, кайгыртучан, кызганучан бер төс белән:

— Хәлең ничек, Барый?— диде. Барый, берни эндәшмичә, аның агарынган нурсыз йөзенә текәлеп калды.

— Һич тә сине шундый булырсың дип уйламаганыем, малай,— дип дәвам итте Ислам.— Үзең башламасаң, мин сиңа кул күтәрә торган кешеме? Харап була яздык бит, малай!

— Ник кердең?— диде бригадир.

— Ник дип... ышту син, Барый!

— Кыскасы, сиңа миннән нәрсә кирәк?

— Кыскасы, миңа торыр урын кирәк, иптәш бригадир! Аерым бүлмә кирәк... чүпрәк сарай булса да ярый.

Барый урыныннан кузгалып куйды, сыңар күзен тагын да киеребрәк ачты.

— Алайса?..— диде ул.

— Алайса... без бүген өйләнештек!— диде Ислам, ярым тантана, ярым мыскыл белән.

— Ярый. Булыр,— диде бригадир, коры гына.— Хәзер... күтәр үкчәңне! Йөрмә йокы бүлеп.

— Ну усал да кеше син, Барый!— диде Ислам, уфтанган булып.

Урыныннан торды да, мыскыллы ирония белән авызын кыйшайтып, ишеккә борылды.

## Җиденче баб

### I

Алдан уйланылган исәп буенча, профилактик ремонтны тәмамлагач, бригада бүген яңа урынга — сөреләсе яңа басу ягына күченергә тиеш иде. Яңа басуның чикләре, сөреләсе җирнең гектар исәбе, авыл булып утырасы урын — һәммәсе дә инде билгеле иде.

Иртәнге аштан соң бригада шундук эшкә тотынды. Төшкә кадәр кешеләр баш калкытмый эшләделәр. Төшке аштан соң да бер минут ял итми эшкә керештеләр. Бригадир әледән-әле ризасызлык белдерде, бертуктаусыз ашыктырып, кызулап йөрде. Аның җаны түзмәде, тизрәк моннан, бу урыннан кузгалып китәсе килде, күңелендә таплы эз булып, яра булып торган кайбер нәрсәләрне оныту өчен бөтенләе белән чын эшкә, зур эшкә чумасы килде. Ни генә булмасын, монда тагын бушка бер төн уздыруда мәгънә юк иде. Бүтәннәр дә шулайрак уйладылар һәм караңгы төшкәнче тиешле урынга барып җитеп урнашу, хәтта төнге сменага чыгу өчен барлык көчләрен куеп тырыштылар.

Эшнең очы-кырые күренгәндәй булгач, бригадир берничә кешегә чатырларны сүтә башларга кушты. Галимулла белән Илгиз, Ислам бауларны чишәргә, казыкларны суырырга тотындылар. Шул вакыт бригадир янына Димка килеп җитте.

— Рациягә чакыралар,— диде ул.

Ни булган инде анда тагын дигән сыман шомланып һәм ризасыз бер тойгы белән, Барый вагонга кереп китте.

Аны Көктугайга чакыралар иде. Аның йөзе караңгыланып китте, шикләнүе арта төште. Нәрсәгә чакырганлыкларын белмәкче булып, ул төпченеп карады, ләкин аңа аңлатып тормадылар, тизрәк килеп җитәргә кушылды дип кенә җавап бирделәр.

— Мин кайтканчы юлга әзер булыгыз,— диде Барый кешеләргә.

Ул мотоциклына атланды да Көктугайга чапты.

Аның чорналган-бәйләнгән башын күреп директор шаккатты.

— Нәрсә, тагын сугыштыгызмыни?— диде ул, шактый кырыс кына.

— Тагын дип... безнең беркайчан да сугышкан юк, Игорь Андреич,— диде Барый, елмаерга тырышып.

— Нәрсә, караваттан егылып төштеңмени?

— Шулайрак булды инде, Игорь Андреич. Сабан туе бит! Сезне дә көттек, килмәдегез. Өегезгә барырга кыймадым.

— Мине дә тукмарга исәпләгән идегезме?

— Анысы менә башка килмәде!

Горшков, эх, син, бригадир! дигән сымаграк итеп башын чайкап торды да, берни эндәшмичә, караңгы чырай белән кузгалып китте. Алар конторага керделәр.

Монда ниндидер җыелыш булырга тиешлеге әллә каян сизелеп тора иде. Бүлмә уртасына рәт-рәт урындыклар, озын утыргычлар тезеп куелган иде. Берничә кеше, бер тирәгәрәк өелеп, нәрсә турындадыр үзара гәп алып баралар иде. Җыелган кешеләр арасында совхоз җитәкчеләре дә, бригадирлар да бар иде. Шунда ук Таран да күренә иде. Бригадирлыктан төшерелгәч, ул механика мастерскоена урнашкан иде. Киләсе кешеләр, күрәсең, барысы да килеп җитмәгән иде, шуңа күрә барысы да киеренке бер түземлек белән кемнәрнедер көтәләр һәм ишек ачылган саен, сүзләреннән бүленеп, күз кырыйлары белән генә шул якка карап алалар иде.

Директор белән яңа бригадир килеп кергәч, барысы да аларга игътибар иттеләр. Берсе әйтте, күренмиләрме әле, диде, икенчесе әйтте, бик озак көттерделәр, диде. Барый аларның кемне көткәнлекләрен дә, бүген монда нинди җыелыш булачагын да белмәде. Монда килгәндә ул, күрәсең, бригададагы хәлләрне директорга җиткергәннәрдер, дип уйлаган иде. Ләкин директор әнә берни белми булып чыкты. Хәер, кичә төнлә булган хәлне аның әле белүе дә мөмкин түгел.

Ул үзенең чорналган башыннан, җимерелгән йөзеннән уңайсызланып, иң арткы рәткә барып утырды.

Күп тә үтмәде, контора бүлмәсенә райком секретаре Нурсәетов белән бер-ике казакъ агае килеп керде. Райком секретарен күргәч, Барый кинәт кенә шүрләп куйды. Никтер аңа хәзер кичәге талаш-сугыш турында райкомга ук барып җиткәндер шикелле булып, директор бу турыда юри әйтмәгәндер, һәм җыелыш та нәкъ шул нәрсәне тикшерү өчен, ягъни үзен кыздыру өчен җыелгандыр шикелле булып тоелды. Ул тынычсызлана башлады, әледән-әле ят кешеләргә, совхоз җитәкчеләренә күтәрелеп карады, аларның йөзләренә карап, үз уйларының дөресме, түгелме икәнлеген белергә тырышты.

## II

Барыйның бәхетенә каршы, бу бөтенләй икенче төрле җыелыш булып чыкты. Бу совхоз җыелышы гына түгел, бәлки, совхоз белән төзелеш участогының берләштерелгән җыелышы иде, һәм каралачак мәсьәлә дә, язгы кыр эшл-

әре йомгаклары яисә, гомумән, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре булмыйча, бөтенләй икенче мәсьәлә — төзелеш эшләренең барышы мәсьәләсе иде.

Иң элек төзелеш участогы башлыгы Куракинның белдерүе тыңланылды. Кыска гына буйлы, зур башлы, көлтә сыман күперенке саргылт чәчле һәм ифрат дәрәҗәдә рәсми-тыныч йөзле, хәтта бераз гына таштай салкын кыяфәтле Куракин машинкада басылган әзер кәгазьгә карап сөйләде.

Эшчеләр өчен торак йортлар, аннан да бигрәк, яңа ашлык өчен таш амбар салу эше чиктән тыш начар бара иде. Бу исә монда утыручыларның берсе өчен дә сер түгел иде. Совхоз парторгының алдан әйтеп китүенә караганда, бу җыелыш нәкъ менә шул «өзеклекне» бетерү һәм яңа төзелешне «киңрәк җәеп җибәрү» нияте белән җыелган иде. Шуңа күрә җыелыштагы һәркем Куракинны үз-үзенә, үз карамагындагы кешеләрнең эшләренә карата беркадәр тәнкыйть белән сөйләр дип, һич булмаса, тегебу нәрсәдә җитешмәүчәнлеккә зарланыр дип көткән иде. Әмма Куракин һич тә алай сөйләмәде. Аның сүзләренә ышансаң, төзелеш мәйданында эшләр алай артык борчылырлык түгел иде, «кайбер совхозлар белән чагыштырганда», хәтта шактый әйбәт бара иде.

Шулай да ул сүзенең соңында тәнкыйтькә дә урын бирергә булды.

— Дөрес,— диде, пумаладай зур башын чайкап,— дөрес, без әле барлык көчебез белән эшләмибез, иптәшләр, эчке резервлардан тулысынча файдалана алмыйбыз, бездә кимчелекләр дә юк түгел... Бүгенге көндә безгә агач-таш җитми, механизация җитми...

Тәнкыйтендә ул шуннан ары узмады, нинди «эчке резервлардан» файдалана алмауларын да, нинди «кимчелекләр» булуын да аңлатып тормады. Көтмәгәндә һич тә бу җыелыш рухына туры килми торган бер тантаналы күтәренкелеккә күчте дә, лозунглар кычкыргандай, «Татарстан» совхозының киләчәге турында, «совет төзүчеләре» башкарачак «зур эшләр» турында, тиз көннәрдә салыначак икешәр катлы мәктәпләр, клублар, больницалар һәм тагын әллә ниләр турында сөйләргә керешеп китте. Бу кадәр эшне башкарып чыгуны, диде, партия һәм хөкүмәтебез безгә тапшырды, диде, моның өчен дәүләт безгә җитәрлек акча җибәрде, диде, ләкин монда, иптәшләр, сезнең ярдәмегез кирәк, шунсыз безнең комга утыруыбыз бар, диде.

Куракинның белдерүен ниндидер бер уңайсызлану белән, канәгатьсезлек белән тыңлап утырган кешеләр аның соңгы сүзләреннән көләргә тотындылар.

— Безгә сафсата сатып, кадерле вакытны алып торганчы, башта ук сүзне шуннан башларга иде!— дип кычкырды арттан бер эшче.

Куракин, үз эшен тиешенчә башкарып чыгуына бик тә канәгать бер кыяфәттә, чигә чәчләрен сыпыргалап алды, урынына утырды. Ачуыннан нечкә бармакларын шартлаткалап утырган Нурсәетов мәһабәт гәүдәсен турайтты да беркадәр казакъчалык акценты сизелеп торган русча белән:

— Иптәш, бик дөрес әйттегез,— диде, арттан кычкырган эшчегә ишарәләп. Аннары Куракинга борылды: — Сез безгә киләчәк план турында сөйләмәгез, иптәш Куракин. «Татарстан» совхозының үзәк поселогы киләчәктә ничек буласын без сездән башка да беләбез. Сез, бәлки, бүгенге эшләр турында сөйләрсез, ә? Ни өчен план үтәлмәгән? Ни өчен сигез йорт урынына ике йорт та тулысынча салынып бетмәгән? Менә нәрсәләр турында сөйләгез сез безгә! План, имеш, перспектива, имеш! Булачак, төзиячәкбез!

Нурсәетовның бу сүзләре төзелеш участогы эшчеләренә очкын кебек тәэсир итте.

Шунда япь-яшь кенә бер егет чәчрәп чыкты.

— Иптәшләр!— диде ул, кызларныкына охшаш нечкә тавыш белән бик яман кычкырып.— Менә мин ташчы. Таш ватарга безнең хәтта махсус чүкеч тә юк. Киндер бияләй дә юк. Ташны югарыга носилкалар белән ташыйбыз, ә электр краны тик тора! Кем гаепле моңа — сезме, әллә безме, иптәш Куракин? Сез гаепле, иптәш Куракин!

Яшь егеттән соң икенче бер эшче — башы түшәмгә тия язган таза бер украин торып басты.

— Мин — маляр,— диде ул,— миңа эш юк. Эш бар — тыңламыйлар. Өй эче шкатурланган, буйый башларга да була. Тыңламыйлар. Мин нинди эшкә дә риза — җир казырга да, таш ватарга да. Ләкин минем яраткан эшем бар. Иптәш Куракин безнең сүзгә колак салырга тиеш. Ул безнең белән рәтләп сөйләшми дә. Шулай булгач, ничек эш барсын?

Җыелышта күпчелек төзүчеләр иде. Алар, күрәсең, барысын да ачыктан-ачык сөйләргә дип, алдан ук кызып, әзерләнеп килгәннәр иде. Аннары «игенчеләргә» караганда алар кыюрак та, усалрак та шикелле иде.

Малярдан соң икенчеләр, өченчеләр сөйләде. Ярсыпярсып алар эштә бернинди тәртип, бернинди оешканлык булмавы турында, шуның аркасында бернәрсәнең дә алга китә алмавы турында сөйләделәр.

«Боларның эше чын-чынлап хөрт икән»,— дип уйла-

ды Барый, төзүчеләр өчен борчыла башлагандай булып. Болар белән чагыштырганда, бригада эшләре әнә нинди! Сигез йорт урынына ике йорт! Ягъни биш мең гектар урынына бер мең гектар чәчү кебегрәк була инде ул. Бер мең дә түгел әле... алты йөз, җиде йөз... Яисә трактор белән сөрү урынына ат белән сукалау сымаграк... Ярсырга урын бар монда! Ләкин шулай да аларның эшенә «игенчеләрнең» ни катнашы бар соң? Бригадалардан кешеләр алмакчы булалар микәнни? Менә тагын кайгы! Хәер, прицепщикларны бирергә була. Чәчү вакытында тракторчылар үзләре генә сөрделәр.

Төзүче эшчеләрдән сөйләргә теләүчеләр күренмәгәч, Нурсәетов үзе торып басты. Җыелыш башланганга күп вакыт үтмәгән иде әле, һәм шулай ук тикшерелә торган мәсьәлә дә очланмаган иде. Ләкин Нурсәетов җыелыш барышында бер генә сүз дә эндәшмичә, бары тик азактан гына академик чыгыш ясаучы һәм бүтәннәрнең үзенә кадәр әйткәннәрен үзенең авторитетлы «соңгы сүзе» белән каплап куючы кайбер партсекретарьлар шикелле түгел иде, ахрысы. Ул ниндидер тиктормас, тынгысыз һәм дәртле кеше иде. Җыелышта ул башта ук гади тыңлаучы булып кына утырмады — чыгып сөйләүчеләргә кыска-кыска гына сораулар биреп куйды яисә берәр сүз кыстырып җибәрде һәм шуның белән сөйләүче кешеләрнең фикерләрен — кирәк икән — тиешле юнәлешкә борып җибәрә белде. Ләкин ул моны бик оста эшләде һәм аның мондый сораулары, мондый сүз кыстырулары һич тә кеше сүзенә кысылу булып аңлашылмады. Киресенчә, җыелышка бу үзенә күрә бер җанлылык, иркенлек кертеп җибәрде, җыелышның кайчагында тыңлаучыны җәлеп итә алмый торган гадәти рәсмилеген, формаль рухын таратып җибәрде.

— Минемчә, яшьләр монда бик дөрес сөйләделәр, ихлас күңелдән сөйләделәр,— диде ул, гади генә итеп.— Иптәш Куракин турында мин өстәп бер генә сүз дә әйтмим, тулысынча эшчеләр сүзенә кушылам. Вениамин Степанович, әгәр бүтән вакытта сез аларның сүзләренә колак салмаган булсагыз, монда сөйләгәннәренә һичшиксез колак салырсыздыр дип ышанам. Хәзер мин сезгә икенче нәрсә турында әйтмәкче булам. Торак йортлар төзүгә килгәндә, бүгеннән башлап безгә бөтен көчне саманга бирергә кирәк. Безне бары саман гына коткара ала. Мондагы кебек салкыннарны, мондагы кебек карбураннарны кайберләрегезнең, бәлки, төшендә дә күргәне юктыр. Саман йортка бернинди салкын да, бернинди карбуран да куркыныч түгел. Җәй көннәрендә — тышта

эсселектән тыннар куырылганда, җиргә бассаң, табаннар янганда, саман өйдә хәтта салкынча була. Саман йортның уңай яклары менә шунда. Аннан да бигрәк, саман йорт бик арзанга төшә. Саман кирпече — дала шартларында мөмкин булган иң арзанлы төзү материалы...

— ...«Татарстан» совхозы язгы чәчүне уңышлы тәмамлады,— диде ул, сүзен дәвам итеп.— Беренче сынауда сез... ягъни без барыбыз да җиңеп чыктык. Бу безнең бик зур җиңүебез. Ләкин, иптәшләр, эш моның белән генә бетми. Сез монда шуның өчен генә килмәдегез. Чәчкән игенне җыеп аласы бар. Аннан соң көз җитәр, кыш җитәр. Хәзер безнең өчен беренче көн тәртибе шундый: уракка төшкәнче кешеләргә кышкы торак җитештерергә кирәк. Кешеләрне без кышка киндер чатырларда, такта вагоннарда калдыра алмыйбыз. Бу хакта төптәнрәк уйларга кирәк. Уен эш түгел. Яз башыннан ук саманга тотынырга кирәклеге турында без сезгә әйтә килдек, Вениамин Степанович. Ә сез нишләдегез? Бернәрсә дә эшләмәдегез! Ник сез бары такта йортларга гына исәп тотасыз? Саманга ышанып җитмәү бәласе түгелмени бу? Саманга кул селтәп карау, саманга борын җыерып карау читтән килгән кайбер иптәшләр арасында әле булса бетеп җитмәгән. Шундый иптәшләрнең берсе сез — Вениамин Степанович. О-о, саман, имеш! Балчык йорт, имеш! Сыер абзары, мал фермасы, имеш! Без яңа совхозлар төзибез, шулай булгач, безгә бөтенесе дә өр-яңадан булсын, завод-фабрикадан чыккан гына булсын! Әлбәттә, алай җиңелрәк тә, уңайлырак та — китереп биргәннәрен генә көтеп ятасың. Ләкин, иптәшләр, белегез, ул такта йортлар безгә алтын бәясенә төшә. Үзара гына әйткәндә, ул җыелма йортларның шуннан башка кыйммәте дә юк... алтын бәясеннән башка...

— Кабатлап әйтәм,— диде ул, бераз тын алып торгандай иткәч,— бөтен көчне хәзер саманга җигәргә кирәк. Ләкин төзү оешмасы бары саман белән генә шөгыльләнә алмый. Уракка төшкәнче без, бернигә карамый, таш амбарны өлгертергә тиешбез. Өлгертмәскә безнең хакыбыз юк. Шуның өчен... «эчке резервлардан» «тулырак файдалану» өчен, ягъни төзелеш эшчеләрен тулысынча амбар салуга туплау, шул ук вакытта торак төзелешен дә ныклап торып кузгатып җибәрү өчен безгә хөрмәтле Игорь Андреичка мөрәҗәгать итәргә туры килер. Иптәш Куракин дөрес әйтте, ярдәм итмәсәң, чыннан да, аның көймәсе комга терәлергә мөмкин. Шул ярдәмне без сездән көтәбез, Игорь Андреич.

Нурсәетов сөйләп туктады да Горшковка борылып

карады. Директор, рөхсәт сорагандай, парторгка күз төшереп алды һәм, ашыкмыйча гына, урыныннан торды.

Барый сагая калды.

— Салыначак яңа йортларда төзүчеләр түгел, без торачакбыз,— диде директор, салмак кына сүзгә башлап.— Шулай булгач, үзебезнең йортлар турында үзебезгә кайгыртырга кирәк булачак. Ныклап, чынлап торып. Моңарчы без төзүчеләргә ышанып килдек. Шундый ышандык, аларның ничегрәк эшләүләре белән дә, планнарының үтәлүе-үтәлмәве белән дә кызыксынмадык. Моннан соң без кызыксыначакбыз. Төзү участогы үзенә башка, совхоз үзенә башка яшәүдән туктарга тиеш. Язгы чәчү беткәч, безнең хәзер төзү мәсьәләсендә конкрет ярдәм күрсәтерлек мөмкинлекләребез бар. Парткомда үзара киңәшкәч-сөйләшкәч, без саман кирпеч сугуны бөтенләе белән үз өстебезгә алырга булдык.

«Оһо!»— дип куйды Барый үзалдына.

— ...кирпеч сугу — бездән, матур итеп, яхшы итеп йортлар салу — сездән, Вениамин Степанович,— диде Горшков, башын иебрәк утырган Куракин ягына борылып.— Шулай иткәндә, безнең эшебез бермә-бер алга китәчәк. Амбарлы да булырбыз, торак йортлар да салырбыз.

— Конкретрак итеп әйткәндә, нишләргә уйлыйсыз?— диде Нурсәетов.

— Конкретрак итеп әйткәндә, иптәшләр, ике бригаданы без кирпеч сугу эшенә куймакчы булабыз. Үзегез аңлыйсыз, сөрүне бөтенләй үк туктатып булмый. Саманга без алдынгы бригадаларны: дүртенче белән икенче бригаданы билгеләдек.

## III

Яңа хәбәрне бригадада начар каршыладылар. Өйрәнелгән, гадәтләнгән эштән, өйрәнелгән, гадәтләнгән киң, иркен табигатьтән аерылып беркемнең дә каядыр «чит» җиргә — Көктугайга күченеп китәсе килмәде, анда китеп ниндидер ят, авыр эшкә барып тотынасы килмәде. Бригадир кайтып төшкәндә, инде чатырлар җыеп алынган, төяләсе әйберләр вагоннарга төялгән иде, һәм вагоннар да, сабаннар, тырмалар да, чәчкечләр дә — барлык тагылма инвентарь тракторларга тагылып куелган иде. Хәзер инде, бер минут көтеп тормыйча, бөтен бригада белән кузгалып китәргә дә була иде.

Ләкин күпчелек китү турында ишетергә дә теләмәде. Беркая бармыйбыз, яңа басуга китәбез, безгә саман йорт кирәкми, безгә чатырда да күңелле, диделәр.

Кешеләрнең шаулашканын Барый караңгы чырай белән тыңлап, көтеп торды да, авыр гына:

— Юк, булмый,— диде.

Билгеле, ниндидер белмәгән-күрмәгән саманга аның үзенең дә бик үк тотынасы килеп тормады. Ләкин бу турыда ул хәзер берни сиздермәде.

— Булмый, иптәшләр,— диде ул тагын да.— Ярамый! Үзегез беләсез: без монда бөтенесе әзер булыр дигән өмет белән килмәдек. Без монда шәп-шәрә дала икәнлеген бик яхшы белеп килдек. Без хәзер шәрә даланы иген басуына әйләндердек. Инде безгә үзебез өчен оя кора башларга вакыт.

— Ислам белән Фәридә кебекме?— диде Кәрам.

— Андый оя кору да кирәк,— диде бригадир.

— Мин дә оя корам!— дип кычкырды Белугин.— Кызлар, әйтегез тизрәк, кем миңа кияүгә чыгарга әзер? Ашыкмыйча гына... берәмләп кенә сөйләгез... Иртәгәдән үземә саман йорт сала башлыйм!

— Төлкеләргә өйлән! Син диванага кем барсын,— дип куйды Тәзкирә, бер дә юктан тузынып.

— Карале, Барый туган, баш белән уйлап караганда...— диде Галимулла, бригадирга якынрак килеп.— Белугин Ваня шаяртып сөйли дип уйлыйсыңдыр да син... шулай да, Барый туган, начар сүз сөйләми ул. Башка шундый уй килде әле минем: менә без, мәсәлән, Фәрханә апаң белән үзебезгә саман йорт салып чыксак, ничегрәк булырые икән, ә?

— Ничек була инде ул?— диде Барый.— Һәркем үзенә йорт сала башласа, кая китә ул?

— Юк, алай түгел ул!— диде Галимулла.— Менә безнең кебек, Ислам белән Фәридә кебек кешеләргә яхшы булырые ул, Барый туган.

— Берни әйтә алмыйм,— диде бригадир, икеләнеп.— Әйтеп торам бит, йортны без салмаячакбыз, без бары кирпеч кенә сугачакбыз. Йортларны төзүчеләр салачак, проект буенча.

— Шәһәрдәге сыман!— дип кычкырды Белугин.— Тирестән, балчыктан сылап икешәр, өчәр катлы сарайлар, асфальт юллар, трамвай-троллейбуслар! Мин риза, теләсәгез ни әйтегез!

— Шулай да киңәшеп караганда ярарые ул, Барый туган,— диде Галимулла, тиз генә бирешергә теләмичә.— Менә Андроновлар да...

— Миңа бер бүлмә дә җиткән!— диде Андронов, кулын селтәп.— Өйләр турында хыялланырга иртәрәк әле. Карале, иптәш бригадир, нәрсә монда сүз куертып то-

рырга? Әйтелгән икән — күченәбез! Кая куялар — шунда эшлибез!

Аның мондый катгый төстә әйткән сүзләре бригадирга тәэсир иткән сыман булды. Ул, сумка каешын кысыбрак тотты да, шаулашкан кешеләргә карап:

— Аңлашылдымы?— диде.— Аңлашылса шул: кайчан күченәбез — хәзер үкме, әллә иртәгә иртәнме?

Бригада төнне далада уздырырга булды. Чатырларны ашык-пошык яңадан корыштырдылар да, урын-җирләрен, төйнәлгән әйберләрен чишеп ташлап, йокларга яттылар.

Иртән, кояш чыгып шактый кыздыра башлагач һәм кешеләр тамак ялгап алгач, артына ике вагон таккан беренче трактор кузгалып китте. Аның артыннан сабаннар, чәчкечләр, тырма-культиваторлар кузгалды, мичкәләр төялгән арбалар кузгалды. Дала яңадан көчле моторлар гөрләве белән, корыч-тимер шыгырдавы һәм яшьләр шау-шуы белән яңгырап торды.

Әле генә алар торган, әле генә алар йөргән, алар утырган җир өстендә, тапталган, казылган-сырланган һәм трактор майлары белән тапланып беткән җир өстендә, иркенләп җил исте. Берәр нәрсә төшеп-тамып калмады микән дигәндәй, чыркылдашып шундук чыпчыклар килеп җитте. Вак-төяк икмәк катылары, коелган ярма, токмач ише нәрсәләр таптылар, үзара талашып, куанып чүпләргә дә тотындылар. Чыпчыклардан беркадәр соңлап, тилгән килеп җитте, түбәннән генә очып әйләнде дә, эләктерер нәрсә күренмәгәч, тукталып тормыйча, ары очты. Чыпчыктан да, тилгәннән дә соңгарак калып, иснәнә-иснәнә очлы борынлы төлке килеп чыкты. Ул да шулай ук үзенә кирәкле нәрсәләр эзләде, тапты, ашады һәм, тамак ялгап, үлән арасына кереп посты.

Дала бушап калды. Моннан соң бу урынга, бәлки, беркайчан да беркем килеп йөрмәс, беркем авыл кормас. Монда шулай чыпчык, тилгәннәр, йомраннар, төлкеләр тулысынча хуҗа булып калыр. Тик шулай да монда хәзер бик якында гына кеше барлыгы сизелеп торыр, тын даланы шау-шу белән күмеп киткән, тып-тын яткан җир йокысын бозып, куенына бөртек ташлап киткән чын хуҗаның якынлыгы сизелеп торыр.

## IV

Көктугай халкы суны яр астындагы коедан ала иде. Тирәнлеге ике метрдан артмаган һәм бер мичкә тутырып алдың исә, шундук суы болгана башлый торган бердәнбер кое совхоз кешеләрен тулысынча тәэмин итә ал-

мады. Совхозның әлегә көтү-көтү сарыклары да, сыерлары да юк иде, ләкин аның су күп сорый торган машиналары, ашханәсе бар иде, төзүчеләре бар иде. Шуны истә тотып, Көктугайда төпләнүнең беренче көннәреннән үк өстә, авыл читендә тирән кое казылды. Шуңа күрә Көктугай халкы әлегә су кытлыгы күрмәде.

Саман кирпеч сугу мәсьәләсе кузгатылгач, су мәсьәләсе яңадан калкып чыкты. Саман өчен су күп кирәк булачак иде. Монда инде бер-ике кое белән генә котылып булмаячак иде. Шулай ук суны алты-җиде километр ераклыктагы Иртыштан ташу да бик үк күңелле эш түгел иде. Шуларның барысын да исәпкә алып, кирпеч сугуны су буендарак оештырырга кирәк дигән фикергә килделәр һәм дүртенче бригаданы турыдан-туры Иртыш буена күчерергә булдылар.

Икенче бригадага килгәндә, мәсьәлә алай җиңел генә хәл ителмәде. Көктугай турысында Иртыш янына ук барып утырырга мөмкин түгел иде, чөнки елга үзәнендә саман кирпеч өчен яраклы кызыл балчык юк иде. Кирпечне кичек тә шушында, төзелешкә якынрак җирдә сугарга кирәк иде.

Уйлашкач-киңәшкәч, шулай да җае табылды. Көктугайдан бер-ике чакрым төньякка таба, Иртыш үзәнендә бер кечкенә тирән күл бар иде. Күлдән калку ярга кадәр булган ара шулай ук бер-ике чакрым чамасы иде. Икенче бригаданы нәкъ шул турыга — үзәнлектәге күл турысына, калкулык буена урнаштырырга булдылар. Күлдән су ташу өчен бригадага бер бензовоз, тирес, салам ташу өчен бер йөк машинасы беркетелде.

Күченү көне буена сузылды. Тракторлар билгеләнгән җиргә килеп җиттеләр дә бер-бер артлы туктап калдылар. Монда Иртыш буйлары да, елга аръягындагы авыл да, яшел урманнар да, Көктугайдагы ап-ак цистерналар гына түгел, хәтта барлык йортлар да яп-якын булып, апачык булып күренеп тора иде. Якыннан гына, бер ярты чакрым чамасы читтәнрәк, дала ягында — шәһәргә китүче олы юл сузылып ята иде.

Барый Һарун тракторына утырды да калкулык буен— бригада авыл булып урнашачак җирне түгәрәкләп сөреп чыкты.

— Бу безнең дәүләт чигебез булыр. Шушы чиктән бригада эченә бер генә ят кыз да, бер генә ят егет тә үтеп керергә тиеш түгел,— дигән булды ул, борыннарын салындырган кешеләрнең күңелләрен күтәрмәкче булып.— Монда килгәч, азып-тузып бетмәсәгез ярый инде. Югыйсә Көктугайда кызлар-егетләр җитәрлек.

Ләкин мондый шаяртуга гына беркемнең дә күңеле күтәрелмәде. Бер-берсенә кычкырынгалап, теләр-теләмәс кенә бушатына башладылар. Далада утырган тәртип буенча, вагоннарны тиешле урынга борып, турылап куйдылар, чатырлар өчен урын җайладылар, тракторларны, тагылма инвентарьны шулай ук тиешенчә саф-саф итеп тезделәр.

Кешеләр яңа җирдә урнашу белән булашкан арада, Фәридә поход кухнясына ягып җибәрде. Морҗадан күңелле бөркелеп тирә-якка зәңгәр төтен чыга башлады.

## V

Яңа җирдә беренче көн тыныч кына, басынкы гына үтте.

Икенче көнне кешеләр, ашап алгач та, чатыр тирәсендә, тракторлар тирәсендә кайбер соңгы эшләрен башкардылар да, берәм-берәм генә яисә төркем-төркем булып, Көктугайга агыла башладылар. Күзне кызыктырып, күңелләрне кытыклап якында гына ап-ак цистерналар ялтырап торганда, ниндидер серле, яшерен бер гүзәллеккә ия булган шикелле булып, Көктугай «шәһәре» күренеп торганда, беркемнең дә монда ятасы килмәде. Аннары әле монда эшлисе эш тә юк иде, ә саман дигән нәрсәгә кайчан һәм ничек тотынырга кирәклеген әлегә беркем дә белми иде.

Озак та үтмәде, алар артыннан бригадир да кузгалды. Килешү буенча, кирпеч сугу эшенә төзүчеләр өйрәтергә тиеш иде. Шуны истә тотып, ул туп-туры төзелеш участогына юнәлде.

— Беренчедән, сезгә, иптәш Рамазанов, күп итеп, ягъни һәркемгә җитәрлек санда, такта калыплар ясатырга кирәк булачак,— диде Куракин, аны үз вагонына алып кереп.— Ике бригадага да калыплар ясар өчен безнең тактабыз юк. Моны инде сез үзегез эшләргә тиешсез, үз көчегез белән. Икенчедән, нәрсә кирәк? Икенчедән, кызыл балчык, су, тирес-салам катнашмасыннан кирпеч өчен яраклы балчык изәргә өйрәнергә кирәк. Монысы артык катлаулы түгел, шулай да баштарак кыенга туры килер. Шуңа күрә мин сезгә якындагы берәр казакъ авылына барып, анда аларның кирпеч сукканнарын карап кайтырга киңәш итәм. Аннары тагын нәрсә? Аннары, билгеле, тимер көрәк, сәнәк һәм башкалар кирәк. Аларын инде болай да беләсез булыр.

«Һу-у, артыннан үзең йөрмәсәң, берни барып чыгачак түгел икән әле монда!» — дип уйлады Барый, кашла-

рын җыерып һәм Куракинның сүзен бүлдерде дә, түземсезләнеп:

— Хәзер үк, бүген үк эшкә тотынуда сез безгә нинди ярдәм күрсәтә аласыз?— диде.

— Бүген үк?! Хәзер үк?! Алай тиз булмый ул, иптәш Рамазанов,— диде Куракин, башындагы чәч көлтәсен селеккәләп.— Мин сезгә нинди ярдәм күрсәтә алам? Мин сезгә балчык измәсенең рецептурасын бирә алам, шуннан башка, иптәш Рамазанов, берничек тә ярдәм итә алмыйм. Киресенчә, сез безгә ярдәм итәргә тиешсез!

— Аңлашылды!— диде Барый, ачу белән.— Миңа сезнең рецептурагызның кирәге юк! Төзүчеләр, имеш. Әрәмтамаклар!

Ул шулай кинәт кенә дулады да начальниктан кулын селтәп чыгып китте. Ул Горшков янына юнәлде. Директор үз бүлмәсендә иде. Бер кызудан Барый аның белән дә ачулы гына сөйләште. Безне эштән аердылар, диде; саман кирәк, саман кирәк диделәр, баксаң, берни әзер түгел, беркем берни белми, диде. Директор аны сабыр гына тыңлап торды да, кызма, кайнарланма, диде; әгәр бик җиңел генә эшләнелә торган эш булса, иң яхшы бригадаларыбызны без төп эштән аермаган да булыр идек, диде.

Сөйләшкәч-аңлашкач, алар совхозның столярлык мастерскоена бардылар, калып ясарга такта бармы, юкмы икәнлеге белән кызыксындылар. Мастерской мөдире әйтте, ул турыда мин ишеткән идем инде, ләкин әлегә кадәр беркем килеп заказ бирмәде, шуңа күрә ныклап уйлаган юк, диде. Аннары өстәп куйды, анлык кына такта табылыр, бүгеннән эшкә тотынырга була, диде.

Бригадирның күңеле беркадәр тынычлангандай булды. Шулай да ул Куракинның якындагы берәр авылга барып кайту турындагы киңәшен дә исенә төшерде.

— Яхшы, барып кайтыгыз,— диде директор да, килешеп.— Ләкин үзегез генә бармагыз, бөтен бригада белән барыгыз.

— Әлбәттә!

## VI

Барый, Димканы очратып, аңа Көктугайда теләсә кайда йөргән үз кешеләрен бергә җыярга кушты. Берничә минуттан яшьләр контора алдына җыелдылар да, машинага төялеп, бригада авылына кайтып киттеләр. Төшке ашны ашагач, алар Камыскүлгә сәфәр чыктылар.

Моннан өч-дүрт ай элек алар Көктугайга нәкъ шушы

юлдан килгәннәр иде. Ул вакытта дала да икенче, юл да икенче иде. Һәм машина бригададан ераклашып өлгермәде, тирә-якта бөтенләй яңа, ят җирләр башланды.

Хәер, бу һаман да шул ук дала иде, тигез, япан, ялыктыргыч дала иде. Тик әлегә кадәр күреп гадәтләнгән даладан үзгә буларак, уң якта Иртыш буе урманнары, ала-кола текә калкулык сузыла иде дә, юл читеннән генә ике чыбыклы телефон баганалары ияреп бара иде. Ләкин ул баганаларның берсе дә һәркем күреп гадәтләнгән шәмдәй төз, юан баганалар түгел иде. Ул баганалар, күрәсең, Иртыш буеннан кисеп алынган, ботаклары боталып, каерылары каезланган һәм көянтә сыман бөгелеп-сыгылып беткән кәкре-бөкре агачлар гына иде. Һәм аларның бөтен күрке дә гадәттәге телефон баганаларына охшамауларында иде, ахрысы. Игътибарын нәрсәгә юнәлтергә белми аптырап барган кеше өчен алар чыннан да бик кызыклы, бик хикмәтле булып күренергә мөмкин иде. Аларның кайберләре уң якка, кайберләре сул якка башларын иеп утыралар иде. Кайберләре исә, эче авырткан кеше сыман, урталай бөгелеп, бөкрәеп калганнар, ә кайберсе шундый нечкә иде, аларны телефон баганалары дип түгел, бәлки, тимерчыбыкларны җирдән күтәртеп куйган вакытлыча таяклардыр дип уйларга була иде. Әмма никадәр генә гарип-гораба, никадәр генә нечкә, зәгыйфь булмасыннар, шулай да алар телефон баганалары иде, күз күреме җитмәслек киң далага, кешесез, йортсыз-нисез буш далага бөтенләй икенче бер төс бирүче, җан кертүче чыбыклы, тылсымлы баганалар иде.

Далада барганда күпме җир үткәнлекне беркайчан да төгәл генә белә алмыйсың. Барасың да барасың, барасың да барасың... Алдан синең каршыңа тигез, туры юл чаба, дала чаба һәм арттан да шундый ук тигез, туры юл кала, дала кала. Алдыңа — тирә-ягыңа карый-карый, күзләрең талып бетә. Менә әллә кайда еракта, каршыдагы офык читендә, ниндидер кара нәрсә күренә. Биш минут барасың, ун минут барасың. Кара нәрсә әкренләп ачыклана башлый, зурая башлый. Бу кара нәрсә дигәнең йә каршыга килүче машина була, йә берәр атлы кеше була, яисә җигүле дөя булып чыга. Бу япа-ялгыз далада күңел хәтта шул җигүле дөягә дә, билгесез җайдакка да, йә булмаса, берәр калкулык өстендә моңаеп утырган берәр кабер калдыгына да шат. Яныңнан гына кәкре-бөкре телефон баганалары тезелеп бара икән, бу инде үзе бер куаныч!

Менә дөя яныннан да, башына очлы бүрек кигән, бите кояшта янган киң яңаклы, кысык күзле җайдак яныннан да выжт итеп узып китәсең; җайдак та, дөя дә һаман

артта кала бара, кечерәя бара, тагын кара тапка әйләнә һәм шул рәвешчә озак кына күренеп тора да янә күздән югала, һәм тагын да гарип-гораба баганалар белән, ыжгырып барган машина һәм машинадагы иптәшләрең белән, үз уйларың белән иксез-чиксез дала уртасында, шыр ялангач дала уртасында торып каласың.

Шулай озак кына селкенгәләп, тирбәлеп бара торгач, алдагы бер калкулык өстендә нинди дер зур гына авыл караеп күренде. Барысы да башларын борып, шул якка карарга тотындылар.

— Камыскүл, Камыскүл!— диде кемдер.

— Камыскүлгә ерак әле,— диде икенчесе.

— Нинди авыл соң ул — никтер хәтерләмим,— диде өченчесе.

Калкулык өстендәге бу авыл гадәттәге дала авылларына бик әз охшаган иде. Андагы йортларның барысы да ничектер бик тәзек һәм гадәттәгегә караганда бик еш утырганнар иде. Шулай ук анда йорт тирәсендә була торган каралты-куралар да, тирес, салам өемнәре дә күренми иде. Ул гына да түгел — анда, гомумән, бернинди тормыш әсәре сизелми иде.

— Авыл түгел ич ул — зиярат!— диде юлчылардан кемдер.

— Нинди зур!— диде икенче берәү.

— Урта гасыр шәһәре кебек,— диде өченчесе, остарып.

— Урта гасыр кешесе!— диделәр аңа, көлешеп. Олы юл зияратка барган юнәлешеннән кырт кына сулга борылды һәм калкулык итәге буеннан йөгерә башлады. Зиярат, нинди дер шомлы, серле кала булып, бик күптөрле истәлекләр саклый торган борынгының җансыз бер шаһите булып, тиз арада артта калды. Бераздан алда, калкулыктан беркадәр читтәрәк — чит-читләре куе камышлык белән уратып алынган зәңгәрсу-каралҗым күл буенда яссы түбәле тарау бер авыл барлыкка килде.

Ап-ак болытлары-ниләре белән бөтен күк йөзен чагылдырып, тыныч кына тулып-артылып яткан шул тирән күл; күлдәге казлар, үрдәкләр; яр читендәге яшел камышлык; камыш арасындагы буш көймә һәм күл буендагы зур авыл — чын авыл тирә-якка кинәт тереклек гүзәллеге, тормыш һәм шигърият гүзәллеге бөркеп җибәрде. Бөтен нәрсә балкып китте. Җансыз коры дала кырык чакрым артта калды. Күл ягыннан, кешеләр яшәгән авыл ягыннан искән рәхәт дымсу җил үзе белән тәтен исен, салкын су исен алып килгәндәй булды.

Машина, олы юлдан уңга каерылып, туп-туры Камыскүлгә чапты.

## VII

Бу яктагы казакъ авылларының күбесе кебек, Камыскүл дә тәртипсез утырган иде. Монда чын мәгънәсендә урам дигән нәрсә дә юк иде. Камыскүл беркадәр дәрәҗәдә Көктугайны хәтерләтә иде. Ләкин ул үзенең саман йортлары белән генә, йорт араларындагы тирес өемнәре, мал абзарлары белән генә Көктугайга охшаган иде. Көктугайга караганда Камыскүл икенчерәк тормыш белән яши иде. Монда, барыннан да элек, йорт араларында яисә «урамнар»да бала-чаганың күплеге, мал-туарның, кош-кортның һәм этләрнең күплеге күзгә ташлана иде. Аннары кая карама, тау-тау итеп кирпечләп сугылган тизәк өеп куелган иде. Монысы дала халкының кышлык утыны иде. Авыл читендә исә бөтен җирне тезеп куелган, өеп куелган саман кирпеч каплап алган иде.

Машина, авылга кереп тормыйча, күл буена, саманчылар янына борылды һәм шунда кирпеч өемнәренә якынрак бер җирдә туктап калды. Бригадир кешеләрнең барысын да бер төркемгә туплады да саманчылар янына алып китте.

Монда күл буенда кызу эш кайный иде. Өй урыны кадәр түгәрәк чокырлар тирәсендә чалбар балакларын күтәргән ирләр һәм итәкләрен югары кыстырып куйган хатын-кызлар мәш килеп кирпеч сугалар иде. Кешеләрнең өс-башлары чыланып, пычранып беткән, аяк-куллары ләпеккә баткан иде, йөзләре җитди, эшчән һәм кырыс иде.

Яшьләр бер чокыр янына килделәр, эшчеләр белән исәнләштеләр дә тавыш-тынсыз гына карап тора башладылар. Җир казу, балчык изү, үзләнгән, тапталган балчыкны калыпка тутырып тигез җиргә илтеп каплау — боларның берсе дә баш җитмәслек катлаулы нәрсә түгел иде. Бик гади, бик аңлаешлы нәрсә иде бу.

Ләкин никадәр гади, никадәр аңлаешлы булып күренмәсен, шулай да бу беркемгә дә ошамады. Яшьләргә генә түгел, Галимуллага да — күптән инде күңеленнән үзенә саман йорт салып куйган Галимуллага да ошамады, борынын тартып, тамагын кыргалап ул әле бер агай янына барды, әле икенче агай янына барды, чатнатып казакъча сөйләште, тегесен-монысын сорашты һәм, авызын ачып, әлегә бер генә мактау сүзе дә ычкындырмады.

— Бу бит феодализм калдыгы!— диде Белугин, нәфрәтләнеп һәм шунда яткан бер чи кирпечкә аягы белән тибеп җибәрде.

Ялтырап торган ак туфли яртылаш кирпечкә батып

керде. Кирпечкә берни булмады — ярылмады, чатнамады, уртасында бары чокыр булып туфли эзе генә торып калды. Пычранган аяк киемен күреп, Белугин сүгенергә тотынды, аның янындагылар көләргә керештеләр, кызлар исә, эшчеләрдән берәрсе күрмәде микән дигән шикелле, як-якка карандылар да әдәпсез егетләрне шелтәләп алдылар.

Күл буендагы саман сугучыларның барысы да диярлек Көктугайдан күченеп килгән кешеләр иде. Кирпечне алар үзләре өчен сугалар иде. Камыскүлнең аргы башында инде яңа бер урам — тигез, туры, чын урам төзелеп ята иде. Урамның ике ягында да яртылаш өелгән яисә инде өелеп беткән дүртәр, бишәр тәрәзәле җыйнак, матур йортлар тезелеп киткән иде. Кайбер урыннарда әле яңа гына нигез салып яталар, кайберсендә инде сырлы шифердан кыеклап түбә ябалар иде. Әле анда, әле монда балта, чүкеч тавышы ишетелеп китә иде.

Авыл кешеләре баштарак совхозныкылар белән бик үк теләмичә генә сөйләштеләр, ләкин тора-бара телләр дә чишелде, йөзләр дә яктырып киткәндәй булды. Очлы озын мыегы салынып төшкән карсак кына, юан гына бер агай, сорауларга җавап бирү белән генә дә канәгатьләнмәде — иркенләп сөйләргә-аңлатырга ук керешеп китте. Үз эшеннән бүленеп, ул бригада кешеләрен челтәрләп штабельләргә өелгән кирпечләр янына алып килде; саманның ни дәрәҗәдә нык булуын күрсәтмәкче булып, кулына бер кипкән кирпечне алды да бар көченә аны җирдәге икенче кирпечкә орды. Ташны ташка бәргәндәге кебегрәк тавыш чыкты. Кирпечләрнең берсе дә ватылмады. Шунда кемдер берәү:

— У-у!— дип куйды.

Мыеклы агай саргылт тешләрен күрсәтеп елмайды да ашыкмыйча гына сүзен дәвам итте.

Хәзер инде кунаклар сыек ләпек тулы чокырларга, баш калкытмый үз эшләре белән мәшгуль булган кешеләргә һәм корсак аслары, тезләре, койрыклары пычранып беткән, йончылган үгезләргә икенчерәк күз белән карый башладылар. Саман кирпечтән салынган йортларга якынрак килгәч, монда аларга тагын да ныграк ошый төште. Алар яңа урам уртасыннан бардылар, кайбер йортлар янында туктап-туктап тордылар, эшчеләр белән, хуҗалар белән исәнләштеләр, сөйләштеләр, сораштылар.

Беренче булып Галимулла үзгәрде.

— Эх, менә шундый йортың булса!— диде ул, кызыгып.

— Шәп булырые ул.

— Вагон ише булмасые,— диештеләр бүтәннәр дә.

— Шуның өчен килдек тә инде,— диде Барый, аларның сүзен куәтләп.— Карарга, өйрәнергә килдек. Күреп торасыз, бер дә мулла кирәкми — теттереп кирпечен дә сугалар, йортын да салалар. Карагыз — начармыни? Таштан коеп куйган кебек. Шәһәрдәгечә бүлмәләр дә бүлеп җибәрсәң... үлә дә китә! Булдымы!

— Ни... баш белән уйлап караганда, Барый туган, күңелгә ятты бу минем,— диде Галимулла.— Фәрханә апаң белән икебезгә шушындый йорт салып чыкмасам, исемем Галимулла булмасын!

— Салабыз, салабыз, Галимулла абзый!— диде Барый, аны тагын да ныграк дәртләндереп.

— Ә без?— диде Ира, иренә карап.— Миңа да йорт кирәк, йорт!

— Карарбыз, карарбыз!— диде Андронов, үчекләшеп.

Карыйсы нәрсәне карап, сорыйсы нәрсәне сорап бетергәч, яшьләр кире борылдылар. Егетләрдән кемдер кымыз эчәргә тәкъдим итте. Шуннан соң өй борынча кымыз сорап киттеләр. Таптылар да чиратлашып кымыз эчәргә керештеләр. Кычкырып мактадылар, бер сүз эндәшмичә карап торган хуҗа хатынга акча бирделәр, рәхмәт әйттеләр; тагын килербез, кымызны әзерләп торыгыз, диделәр.

Егетләр кымыз белән булашкан арада, кызларның берсе килеп:

— Әйдәгез, сезне көтәбез!— дип кычкырды.

Шуннан, дәррәү кубып, машинага таба йөгерделәр. Бөтен тирә-якны томалап көнбатыштан яңгыр болыты килә иде. Яңгыр килеп җиткәнче тизрәк кайтып җитү нияте белән, машина ашыгып чабарга тотынды. Ләкин болыт җитезрәк булып чыкты. Күп тә үтмәде, килеп тә басты. Кызлар, чыркылдашып, бер-берсенә сыендылар,— чәчләрен-башларын капладылар.

Тигез юл буенча бар көченә чапкан машина озакламый яңгыр астыннан чыгып китте. Болыт чаршавы, дала өстеннән киң итәген өстерәтә-өстерәтә, Иртыш аръягына юл тотты. Бераздан ул ерагайды, кечерәйде, Камыскүл ягын томалап алган карасу-зәңгәр күк фонында аксылсоргылт бер тастымал гына булып калды. Тиздән тастымал да, усал бер зәңгәрлек белән, бер-берсенә каш җыерган ачулы, мыгырдавык болытлар арасына кереп буталды. Иртыш аръягындагы караңгы күк кисәге хәзер коточкыч биек бер стена булып күренде, ә шул стенага астан яшькелт дала-үзән барып тоташты. Карасу-зәңгәр күк стенасы белән җир кушылган турыда бик кечкенә булып Иртыш буе урманнары күренде, тасма булып ак-

сыл-кызгылт яр күренде, яр өстендә шакмак-шакмак йортлар күренде.

Алда исә, ерактагы караңгылыкка капма-каршы буларак, якты кояш балкып чыкты. Юл читендәге чокырлы урыннарда табак-табак сулар ятып калды, олы юлны аркылы кисеп үткән һәм дала үләне арасында боргаланып-сыргаланып узган аксыл юеш сукмаклар ялтырап калды. Алда тәгәрмәч эзенә җыелган яңгыр суын эчеп торган кызыл сыер, машина тавышын ишетеп, иренеп кенә башын-күтәрде; горурлыгын саклап, бер дә исе китмичә, ашыкмыйча читкә тайпылды, ләкин автомашина килеп җитеп, кинәт бөтен киң корсагына пычрак салкын су сибелгәч, башын чайкап сикереп җибәрде дә, арт аякларын күтәреп, койрык чәнчеп чабарга ук тотынды. Машина артыннан әкрен генә башын бора-бора юл читендә атлы көтүче торып калды, һавада җиңел ис — яңгыр һәм чыланган җир исе аңкыды.

## VIII

Һарун юл буена күңелсез булды, бүтәннәр кебек авыз күтәреп җырлый да алмады, юк-бар сәбәп табып көлә дә алмады, хәтта кызларның үзенә атап әйткән шаян сүзләренә дә колак салмады. Читтән караганда аны авыру дип уйларга мөмкин иде. Ләкин бу тыштан гына шулай иде. Күңелендә аның бер минут тынгы белмичә, өермәдәй булып уйлар бутала иде.

Бу «буталыш» анда бүген генә башланмады, бу «буталыш», бу үзгәреш анда кичә кичтән үк башланды. Саманга күчү турындагы хәбәр әйтерсең аны аяктан екты. Аның өчен бу көтелмәгән кайгы-хәсрәт кенә булмады, аның өчен бу күз алдына китереп тә, аңлап-төшенеп тә булмый торган мәгънәсез һәм кирәксез үзгәреш булды. Аның өчен дөньяның асты өскә килде. Аның кулыннан яраткан эшен тартып алдылар, яраткан коралын сугып төшерделәр, киләчәк көнгә билгеләп куйган барлык уйларын-өметләрен челпәрәмә китерделәр. Ул сөйгән ярыннан аерылды, туган авылыннан, туган анасыннан, сеңелләреннән аерылды, ләкин моңарчы әле аны беркем дә сөйгән эшеннән аера алмады.

Менә хәзер аердылар! Дөрес, аны гына түгел, бөтенесен дә аердылар. Ләкин аларга ул нәрсә! Беләме соң алар Һарун белгәнне, тоямы соң алар Һарун тойганны?! Кая ул аларга! Аларга кайда да бер: басуда да пычрак, саманда да пычрак. Юк, моны беркем дә белми... аңламый һәм аңлатып та булмый.

Саманга ул муенына муенчак салсалар да тотынмаячак! Аның эше түгел ул. Кемгә йорт кирәк, эшләсен шулар. Аның бер башы кайда да сыяр әле. Аннары Һарун кебек тракторчыларының кадерен белсәләр, йортын да салырлар, торыр җирен дә табарлар. Кирәк икән, кыш буена киндер чатырда торырга да риза, әмма пычрак таптарга, дуңгыз кебек ләпектә аунарга якын да килмәячәк. Ул игенче, ул механизатор. Аның башы кайда да кадерле, аңа кайда да эш табылыр...

«Чынлап та, әллә башка бригадага китәргәме?» — диде ул, үз-үзен дәртләндереп. Әйе шул, сөрә торган бригадага... Юк, совхозыннан ук китәргә! Берәр күрше совхозга яисә Камыскүлгә... колхозга... бит анда да сөрәләр... Белерләр шуннан соң Һарунның кем икәнлеген!

Уйлана-уйлана ул шундый фикергә килде. Ләкин күңеленнән никадәр дуламасын, никадәр бетеренмәсен, шулай да бу аны тулысынча канәгатьләндерә алмады. Мондый уй-фикерләр, нигезләнгән ныклы бер теләк булып түгел, бәлки үз-үзеңне, үзеңнең кузгатылган күңелеңне бер юату гына булып калды. Чынында аның бригададан беркая да китәсе килмәде.

«Нишләргә соң алайса?» — диде ул бераздан, баштагы уйларына каршы килеп. Ул тиз генә җавап тапмады. Үзалдына көрсенеп куйды. Үз янында утырып барган кешеләр аңа беренче мәртәбә чит-ят булып күренде, аларның сүзләре, көлешүләре аның җенен котыртты. Ул табак-табак җыелып яткан суларга да, су эчеп торучы сыерга да, юл буендагы атлы көтүчегә дә — берсенә дә хәзер сокланып, яратып карый алмады.

Бригадага кайткач, ул Барыйның үзен генә туры китерде дә, аңа үзенең эч серләрен ачып салды. Шулай-шулай, диде, ул эш бер дә күңелемә ятмый, Барый абый, диде, директор белән сөйләшеп, мине башка бригадага җир сөрергә җибәрттер әле, диде.

Бригадир аның сүзләрен караңгы чырай белән тыңлап торды. Аңа бу һич тә ошамады. «Бозылды егет, бозылды!» — дип уйлады ул, ачынып. Кирәгеннән артык мактау кайчагында менә нишләтә! Таранны да заманында шәп тракторчы булган диләр, мактала-мактала шулай эчкечегә әйләнгән диләр. Син алдынгы дип, син оста, син уңган, нәрсә теләсәң, шуңа хакың бар дип азындыра башласаң, нишләр бу киләчәктә?!

— Эх, син, Һарун! — диде ул, башын селкеп. — Мин тагын сиңа ышанып йөрим! Булмады бу болай булгач. Мин үзем дә атлыгып тормыйм ул саманга. Кушкач... кирәк булгач, нишлисең! Үзебез өчен бит.

— Миңа аның кирәге юк,— диде Һарун.

— Нәрсә, әллә минем өчен генә кирәкме?— диде бригадир.

— Мин җир сөрүче,— диде егет, аның сүзен тыңламыйча.— Мин кайда кирәгрәк — сөрүдәме, самандамы?

— Без барыбыз да сөрүчеләр!— диде Барый, кыза башлап.— Нәрсә син «мин» дә «мин» киләсең әле? Нинди «мин» ул?

— Үзем өчен сөйләгәч, «мин» булмый, кем булсын?— диде Һарун, үртәлеп.

— Беләсеңме нәрсә,— диде бригадир кинәт, нык кына итеп,— йөрмәле син булмас нәрсә белән баш катырып... кеше котыртып!

Һарун кызарынып китте: Барый абыйсыннан ул, билгеле, мондый җавап көтмәгән иде.

— Мин директорга барам!— диде ул, усалланып, киреләнеп.

— Бар, бар,— диде бригадир, салкын гына. Егетнең тәмам кәефе кырылды. Ул монда бөтен гаепне бригадирдан күрде. «Көн-төн басуда ятып чәчү чәчкәндә, Һарун кирәк булды, чәчү беткәч кирәге юк!— дип уйлады ул, хәтере калып.— Ул чагында син тегеләй дә, син болай. Ни телисең, шуны үтиләр, ни сорыйсың, шуны бирәләр, өрмәгән җиргә генә утыртмыйлар. Бер кирәгең беттеме — әнә әйләнеп тә карамыйлар!»

## IX

Кичке аштан соң ул, өстен дә чишенеп тормыйча, урынына ауды. Ул беркемгә, бернигә катышмады — чирле кеше сыман тын гына, боек кына ята бирде.

Ул шулай ятып торганда, чатырга Зәкия килеп керде. Кулына ул хат тоткан иде. Аны күреп алдылар да, кемгә дә кемгә, дип кычкырырга тотындылар. Зәкия, елмаеп, туп-туры Һарун янына килде. Килде дә, хатны баш очында күтәреп:

— Һарун, бие!— диде.

— Аяк авырта,— диде Һарун, дәртсез генә.

— Авыртса да бие!— диде Зәкия, кыстап.

— Мин инде сабан туенда биедем,— диде Һарун һәм күңеленнән уйлап куйды: «Сеңелләрдән микәнни?»— диде.

Монда килгәч, ул алардан инде әллә ничә хат алган иде. Сеңелләре аңа хатны бер-берсеннән уздырырга тырышып, бер-берсеннән көнләшеп язалар иде һәм язган саен бер үк хәбәрләрне, хәтта бер үк сүзләрне кабатлый-

лар иде. Өйдәге хәлләрне ул инде болай да белә иде, соңгы бер атна эчендә генә анда әллә нинди үзгәреш булуы мөмкин түгел иде.

— Бие инде, бие!— диде Зәкия, хатны һаман кулыннан ычкындырмыйча.

— Биемичә дә таманга килер әле,— диде Һарун.

— Алай ярамый инде, Һарун,— диде Зәкия, үпкәләгәндәй итеп.

— Ярар. Икенче мәртәбә биермен,— диде Һарун, иренеп кенә.

Зәкия, күрәсең, сүз тыңлата алмаячагын аңлап, хатны караватка ташлады да, башын иеп, кызу-кызу атлап чыгып та китте. Беркадәр вакыттан соң, Һарун ул ташлап калдырган хатны кулына алды. Алды да аның кемнән икәнлеген дә карап тормыйча, яткан килеш укырга тотынды.

Хат Хәлимәдән иде, күптән инде үлгәнгә исәпләнелгән, тик шулай да кайчагында эчне тырнап, үткәннәрне искә төшереп торган Ташкичү Хәлимәдән иде.

Хәлимә үз авылдашларының исәнлеге турында язган иде, аннары болай гына, сүз арасында гына, ник бер дә хат язмыйсың дип, киттең дә югалдың, безне бөтенләй оныттың дип, шелтә белдергән иде. Хатның азагына исә, чәчү беткәч кайт, җибәрәләрдер ич?— дип тә куйган иде.

Хат Һарунга әллә ни тәэсир итмәде, тик шулай да Хәлимәнең соңгы сүзләре аның дәртсез күңелен кузгатып җибәрде. Бу сүзләрдә ул үзенең «котылгысыз» хәленнән котылу юлы күргәндәй булды. «Дөрес, кайтып китәргә була!— диде ул үз-үзенә, күңеле күтәрелеп.— Кайтасың да бераз ял итәсең. Кире әйләнеп килгәндә инде, бәлки, саманы да бетәр. Бетми икән... авылда торып калырга да була. МТС директорына барсаң, дүрт куллап каршы алыр!»

Һәм ул, ашыгып, яңадан бригадир вагонына юнәлде.

Барый, кечкенә өстәлгә иелеп, шәм яктысында китап укып утыра иде. Һарунны күреп ул теләмичә генә башын калкытты.

— Ни булды тагын?— диде ул, коры гына.

— Барый абый...— диде Һарун, бераз тотлыгып. Хәзер ул бригадир белән җайлабрак сөйләшергә булды.— Барый абый, син миңа ачуланмадыңмы?

— Нинди ачулану ул тагын?— дигән булды бригадир.— Сезгә ачулана китсәң, бик тиз картаерсың монда.

— Карале, Барый абый,— диде Һарун.— Сиңа бер үтенеч бар: берәр атнага ял бир әле?.. Авылга кайтып киләм.

— Авылга?— диде бригадир, кашларын җыерып.— Ни булды?

— Булды дип... булмады да... Менә хат алдым,— диде Һарун, кулындагы хатны күрсәтеп.— Мә, укып чык. Барый укып тормады.

— Нәрсә, чакырып язганнармыни?— диде ул.— Ник? Нәрсә булган?

— Ни... минем йөргән кыз... Киткәндә бозылышканыек... Шуның белән эшне җайларга...— дип мыгырданды Һарун.

— Кызың язганмыни?— диде Барый, урыныннан торып.

— Ыы шул, Барый абый,— диде Һарун, юаш кына, мескен генә.— Хәлимә язган... чакырып... Берәр атнага...

Бригадир, идән уртасына баскан килеш, уйлангандай итеп торды.

— Ярар,— диде ул, ниһаять.— Кызың янына булгач... кайтырсың. Карале, бәлки, син аны үзең белән алып килерсең?

— Хәлимәнеме?— диде Һарун, никтер кызарынып.

— Хәлимәне инде, Хәлимәне!— диде Барый, көлемсерәп.— Эшләреңне җайла да, ал да кил. Син булдырырсың дип уйлыйм. Нинди егет ул кызлар белән эшен дә җайлый алмагач!..

Шулай диде дә, тотлыгып, туктап калды, эче тырналып куйды. «Акыл сата!»— диде ул үз-үзенә, мыскыл белән.

— Карармын әле,— диде Һарун.— Әйтеп булмый, килсә...

— Син инде үзең беләсең — бу вакытта бернинди ял бирелми,— диде бригадир.— Бер атнада син әйләнеп килә алмассың. Бер ярты айга сорарбыз. Алдынгы эшче дип, фәлән-төгән дип... Тик, кара аны, үзеңә генә әйткәндә, аның өчен түгел, кызың өчен! Булдымы?

— Булды, Барый абый!— диде Һарун.

## X

Директор рөхсәт бирде. Һарун, юллык әйберләрен тиз-тиз генә җыештырып чемоданына тутырды да, иптәшләре белән саубуллашып, олы юлга чыкты. Күп тә үтмәде, шәһәргә баручы бер машинаны туктатты, чемоданын өскә ташлады, үзе кабинага кереп утырды. Бөтен бригада аны ерактан кул болгап, шаулашып озатып калды.

Самолет Казанга төнлә очты. Икенче көнне иртән ул

Казан аэродромына килеп төште. Үзләре авылына кайту, ерак Казакъстаннан Казанга кайтуга караганда, мәшәкатьлерәк булып чыкты. Алар ягына йөрүче автобус инде китеп барган иде. Аңа тагын юл буенда машина көтеп утырырга туры килде. Шулай да аның бәхете җиңде: Уракчыга ул төн урталарында кайтып керде.

Ишек шакыган тавышка өйдәгеләр аптырап калдылар, бер-берсенә пышылдашып, куркышып, кем дә кем, диделәр. Сания әйтте, Зиннур абыем кайткандыр, диде. Равилә әйтте, Һарун абыйдыр, диде. «Йөриләр шунда йокы бүлеп!»— диде әниләре, мыгырданып. Килеп ишекне ачкан иде, артына әйләнеп китә язды: караңгыда бөтен ишекне каплап, Һарун басып тора! Әнисе, улын танып алды да, «әстәгъфирулла!» диде, шундук бисмилла укырга тотынды.

— Кем ул, кем, әни?— дип кычкырдылар кызлар, яткан урыннарыннан торырга иренеп.

— Әллә танымадың, әни?— диде Һарун, басынкы бер тавыш белән, эчкәрәк узып.

Шуннан алар күрештеләр. Күрешкән чакта әнисе чакчак кына балавыз сыккандай итте. Җылы урыннарыннан сикерешеп кызлар тордылар, кайнар beләкләре белән, тузгыган чәчләре белән абыйларының муенына килеп сарылдылар. Һарун абый кайткан, Һарун абый,— диделәр, үзара тәтелдәп. Икәүләшеп авыр чемоданына тотындылар да өстерәп өй эченә алып кереп киттеләр. Әнисе лампа яндырды, шалтыр-шолтыр килеп самавырга ут үрләтеп җибәрде. Кызлар, абыйларының кесәсеннән ачкычын актарып алдылар да, бүлтәеп торган серле чемоданны ачып та җибәрделәр.

Һарун, әле кичә генә кайдадыр Каф тау артында, бүген менә туган йортында, әнисе, сеңелләре янында булуына ышанырга да, ышанмаска да белмичә, исе-акылы китеп, кызыйларның чемодан тирәсендә кылбырдакка килүләренә күңеле булып, елмаеп тик утырды.

Бүләкләрне карарга әнисе дә килде. Әле анысын, әле монысын алды, кулына тотты, рәхмәт, диде; болай баеп кайтырсың дип төшемә дә кермәгәние, кулың-аягың сызлаусыз булсын, диде. Кызлар үзләренең яңа яулыкларын шундук башларына бәйләп куйдылар, көязләнеп көзгегә каранырга тотындылар, күлмәклек материяләрен чандыр тәннәренә урап бетерделәр.

Бүләкләрне карап бетерүгә, чәй кайнап чыкты. Вакыт инде таңга таба авышкан булуга да карамастан, бөтен өстәл өстен тәм-төмнәр белән күмеп ташладылар да гөрләшеп чәй эчәргә утырдылар. Бераз тынычлангач,

очрашу шатлыгы беркадәр басыла төшкәч, Һарунга сораулар ява башлады. Ник кайттың, күпмегә кайттың, диделәр. Алдынгы булып эшләгән өчен унбиш көнгә ял бирделәр, диде Һарун.

— Кайтырга кайчан чыктың?— диде әнисе. Бу турыда инде Һарун кайтып төшкәч тә әйткән иде.

— Кичәгенәк иртән чыгып киттем бригададан,— диде ул тагын да.— Мин бит самолет белән кайттым, әни!

— Күпме түләдең?— диде әнисе.

— Биш йөз чамасы...

— О-о, биш йөз!— диделәр кызлар, шаккатып. Әнисе эндәшмәде һәм бүтән берни төпченмәде.

## XI

Һарунның кайтып төшүе турында икенче көнне бөтен күрше-тирә белде. Авыл гадәте буенча, хәл белешергә иң элек бала-чага керде, аннары хатын-кызлар керде. Әнисе кергән бер кешегә улы исеменнән бүләкләр бирде, һәркемнең күңеле булды, һәркем рәхмәт әйтте, һәм барысы да сокланып, исләре китеп, үзгәргән, чыныккан Һарунга, аның яхшы өс-башына карадылар, чит җирләр турында сораштылар, акча күп төшәме, эш авырмы, диделәр; ачлыкмы, туклыкмы анда, диделәр.

Самолет белән Казанга очар алдыннан Һарун өлкә шәһәрендә, бүләкләр белән беррәттән, үзенә өр-яңадан кием-салым да алган иде. Иртәнге чәйдән соң ул беренче мәртәбә шул яңа киемнәрен киде дә, авызына хуш исле папирос капты да урамга чыгып китте. Гомуми шатлык-куанычтан, үзенең шәп кеше икәнлеген аңлап уңайсызлану тойгысыннан аның бертуктаусыз авызы ерылды, әледән-әле аяклары ялгышып куйды яисә кинәт кенә куллары кирәксез булып, авыр булып тоелды, ул да булмаса, ялт итеп торган ботинка борыны юл катысына төртелеп-төртелеп китте.

Тип-тигез даладан соң, монда аңа бөтен нәрсә бераз гына сәер булып, ят булып тоелды. Шулай да бу озакка бармады. Авыл читендәге калкулыкларга, урамга, йортларга күзе ияләшә төшкәч, аның аяк атлавы да ныгыды, кыенсыну тойгысы да кими төште.

Шулай як-якка карангалап, әкрен генә урам уртасыннан барганда, аңа яшьтәше Гата очрады. Аның белән күрешеп хәл-әхвәл сорашырга өлгермәделәр, таякларын шакылдатып, кара сакал-мыек баскан йөзен балкытып, чаттан аксак Әхәт килеп чыкты.

— Дыраствуем,— диде Әхәт, Һарун белән исәнләшеп.

Ул, солдатта йөргән кеше буларак, үзенең тегенди-мондый гына түгел икәнлеген күрсәтү өчен, кайчагында шулай русча гына сиптерә иде, ләкин аның русчасын аңлау еш кына очракта табышмак чишү белән бер була торган иде.

— Муладис, энекәем!— диде Әхәт, Һарунның иңбашыннан кагып.— Муладис, кеше булып кайткансың. Синең турыда вчә диревнә шаулый, энекәем. Баеп кайткан, диләр, күпич булып кайткан, диләр.

— Алай ук түгел лә инде, Әхәт абый,— диде Һарун, тыйнаклык күрсәтеп.— Нинди шаулау ул! Бүген төнлә генә кайтып төштем бит әле мин.

— Каяле, энекәем, бездә тартып җибәрик әле селинни папирусларны!— диде Әхәт, учын учка сугып.

Һарун кесәсеннән «Казбек» чыгарды, башта Әхәт абыйсына сузды, аннары Гатага сузды. Алар өчәүләшеп идарә ягына атладылар.

— Ни бит, энекәем, апмивайт итәргә кирәк бит моны,— диде аксак Әхәт.

Һарун аңламады. Ләкин алар алдында үзенең шуны да аңламавын күрсәтү ничектер оят булып тоелды, шуңа күрә ул дәрәҗәле генә эндәшми калды. Аның эндәшмәвен күреп, Әхәт бәйләнергә үк тотынды.

— Юк, энекәем, алай жатничайт итмә,— диде.— Бер шешә синнән. Атаң урынына калган абзаңны абижайт итәргә как нимейш права!

Һарун аңлап алды һәм, артык сүз озайтып тормыйча, шундук кибет ягына борылды.

Ул бер ярты белән бер тозлы балык алды, аннары өч стакан алды, барысы өчен дә акча түләде дә, авылдашларына ым кагып, тышка чыкты. Кибет артындагы буш әрҗәләр арасында алар яртының «муенын сындырдылар».

— Муладис, энекәем! Синнән акыллы кеше бөтен Уракчыда юк,— диде аксак Әхәт, Һарунны мактап. Аның сүзләрен Һарун ишетмәде дә.

— Ташкичү Шамилне белмисеңме — хаты-хәбәре юк микән?— диде ул бераздан яшьтәшенә.

— Өйләнгән инде,— диде Гата, кулын селтәп.

— Өйләнгән?!

— Дөмеккән. Шунда, шахтасында... Үзенең Мәрүсәсенә.

— Муладис, энекәем, эх, муладис син, Һарунка!— диде күңеле күтәрелеп киткән Әхәт, кычкырып.

— Сыйларга булгач, сыйларга!— диде Һарун, тиз генә урыныннан кубып.— Тагын бер ярты! Миннән тагын бер ярты!

Чамадан тыш кызу атлап, ул яңадан кибеткә кереп китте. Әхәт елмаеп Гатага күз кысып куйды.— Яшәсен байлар! Муладис, Гата!

Икенче шешәне ачканда, алар янына тагын бер-ике агай-эне килеп туктады. Юмартланып Һарун аларны да сыйлады. Икенче шешәдән соң өченчегә дә кермәкче булды, ләкин шунда Гата аның җиңеннән тартып куйды. Ул тукталып калды. Аның үзенең дә, билгеле, монда әрҗәләр арасында вакыт уздырасы килеп тормый иде, аның тизрәк кузгалып китәсе, яшьтәше белән Шамил турында, Хәлимә турында сөйләшәсе килә иде. Һәм агай-эненең таралышканын да көтмичә, алар саубуллаштылар да Гата белән икәүләп китеп тә бардылар.

— Эх, Гата малай!— диде Һарун, күңеле тулып, көрсенеп.

Яшьтәшенә аның ниндидер бик кирәкле, бик кызганыч сүз әйтәсе килде, ләкин андый кирәкле сүз нишләптер тиз генә күңеленә килмәде, һәм ул тагын бер көрсенеп куйды да: «Эх, Гата малай!»— диде.

— Беләсеңме, Гата, әйдә Ташкичүгә!— диде ул кинәт, чишелеп.

— Хәлимә янынамы?

— Хәлимә янына!

Гата тиз генә җавап кайтармады. Хәлимәнең күптән инде ятлар белән чуалуын, җитмәсә, әле һаман Шамил белән хат алышуын ул ишетеп белә иде. Бу турыда ул Һарунга берни әйтмәде, ләкин күңеленнән уйлап куйды, икәүләшеп анда бару килешеп бетәрме, диде. Хәлимәнең егетләре, Һарунга үч итеп, аңа да эләктереп алмасллармы? Һарун китәр дә барыр, ә ул монда торып каласы кеше. Кеше өчен үз башыңа үзең бәла алудан ни файда?

Бик үк кыюлардан булмаган һәм һәрвакыт итәген җыеп йөри торган Гата шулайрак дип уйлады. Яшьтәше кыстый торгач, шулай да ул риза булды.

Ташкичүгә, билгеле, җәяү барып булмый иде. Шуңа күрә Һарун колхоз идарәсеннән ат сорамакчы булды. Ләкин идарәдә беркем юк иде. Шуннан соң алар ат фермасына китеп бардылар. Ат караучы Мирзахан кырт кисте, ат юк, булса да рөхсәтсез бирелми, диде.

Мондый тәртипләрне Һарун, әлбәттә, белә иде. Шулай да аның ачуы килде. Ат караучы белән ул чак-чак кына әйткәләшеп китмәде.

— Кызма алай, җүләр!— диде Гата, аның колагына пышылдап.— Карап кына тор, хәзер үзем җайлыйм!

Һәм чыннан да күз алдында җайлады да куйды. Ат караучыны читкәрәк алып китте дә, әкрен генә:

— Мирзахан абзый, Һарун кыз алырга кайткан. Ташкичүгә шуңа барабыз,— диде.— Кайгырма, буш итмәбез!

Һарун аның «кыз алырга кайткан» дигән сүзләреннән башкасын ишетмәде дә. «Иште ишәк чумарын!»— дип уйлады ул, Гатага ачуы килеп. Гатага ул шелтәле бер күз карашы ташлап алды, ләкин Гата аны бөтенләй күрмәмешкә салынды. Аның урынына, басса бакыр өзәрлек, типсә тимер өзәрлек баһадир Мирзахан агай шундук йомшап китте; аерым аранда улак чите кимереп, маена чыдый алмыйча ажгырып торган һәм кайчагында бары тик бригадир да ат караучылар гына җигеп йөри торган нәсел айгырын җитәкләп алып та чыкты.

— Күптән шулай диләр аны,— диде, үзалдына сөйләнеп.— Ату башымны катырып азапланасыз. Шундый эшкә ат җәлләп торалармы соң!

Шулай сөйләнгәләп һәм ерак җирдән кайткан Һаруннан дөнья хәлләрен, юл хәлләрен сораштыргалап, ул сөлектәй айгырны канатлы арбага җикте. Егетләр җайлап яңа чабылган печән өстенә утырдылар, агай ат башына утырды һәм бер генә сызгырып җибәрде дә дилбегәне бушайткандай итте. Күкрәк кагып, айгыр урамга ыргылды.

Олы урамга чыккач Гата, яшьтәшенең колагына иелеп:

— Сыйламый булмас, малай,— диде.

— Ярар,— диде Һарун.

Кибеттән ул тагын бер ярты алып чыкты. Алар тагын буш әрҗәләр арасына керделәр. Авызын югары күтәртеп, тезгененнән телефон баганасына бәйләп куелган нәсел айгыры хуҗалар эчкәндә бертуктаусыз биеп торды, чалтыр-чолтыр китереп авызлыкларын чәйнәп торды. Мирзахан агай күздәй тулы стаканны, эһ, тә итми авызына каплады да күзләрен йомгалап алды, тозлы балык капты һәм саргаеп беткән мыек очларын бөтергәләп куйды. Шуннан соң ул рәхмәт әйтте, Һарунны мактады, Гатаны, айгырны мактады һәм, җиңел-җиңел атлап, арба янына килде дә атның елкылдап торган симез муенына шапылдатып алды.

Бер ярты сәгатьтән ул егетләрне Ташкичүгә илтеп тә куйды.

## XII

Үзләре авылына Һарун җәяү кайтты. Инде кояш чыгып килә иде, авылда көтүче тавышы, сыерлар мөгрәгән, әтәч кычкырган тавышлар ишетелә иде. Кеше күзенә

күренмәс өчен, ул ындыр артлап кына кайтты. Бары ишек тоткасына тотынгач кына, ул үзенең йорты турында, энисе, сеңелләре турында һәм кичәгенәк аларга берни әйтми чыгып китүе турында исенә төшерде. Төне буе йокламаганга, аның төсе качкан, күзләре кызарып тора иде, өстендәге өр-яңа киемнәре исә әвәләнеп беткән иде. Мондый хәлдә энисе күзенә күренү бик үк яхшы булмаячагын чамалап, ул чалбар балакларының тузанын каккалап алды. Шулай өстен-башын чистартып яткан арада, эчтә өй ишеге ачылып китте.

— Кайттыңмы?— диде энисе, ничектер шомлы итеп.— Рәхмәт, улым, куандырдың... Әйтү юк, сөйләү юк — чык та кит, имеш. Син монда аның өчен ут йотып ятасың.

Һарун берни эндәшмәде, караңгы чырай белән тиз генә чоланга узды. Энисе алдында ул үзен бик-бик гаепле итеп сизде һәм аңа тагын да ныграк тузынырга мөмкинлек бирмәс өчен, ничек тә күндәм, юаш булып күренергә тырышты. Ләкин аңа карап кына энисе әз генә дә йомшарырга исәпләмәде.

— Баеп кайткач ни... шулай булыр инде,— диде ул, сукранып.— Өяз яхшы чапмага, өй караңгы кайтмага... Кайтып күзгә-башка да күренмәсен, каядыр чыгып та китсен! Әзрәк акылың бармы, улым, әллә читтә сатып эчтеңме? Әнә бөтен авыл көлеп сөйли, Әсманың улы акча туздырырга кайткан, диләр. Син менә монда бер тиенен каян табарга белми кырыкка өзгәләнеп ятасың, ул анда очраган теләсә кемне эчереп, адәм рисвае булып йөрсен! Син соң нәрсә, аксак Әхәт белән Торна Харис малае ялкау Гатаны эчерергә кайттыңмыни? Әллә тагын шул Хәлимәң өченме?

— Ярар инде!— диде Һарун, сабырлыгын җуеп.

— Әһә, ярармы? Ошамыймы энинең сүзләре?— диде энисе, кызганнан-кыза барып.— Яраплан белән кайткан шәп җегеп, баеп кайткан! Кеше кебек җыллар буе йөрсәң, көрәп акча алсаң, нишләрсең син... Тегендә дә рәтләп эшләмәгәндер ул, качып кайткандыр, йә берәрсенең акчасын урлап кайткандыр, эстәгъфирулла-тәүбә!

— Качкан! Урлаган!— дип кычкырды Һарун, тыела алмыйча.

Энисенең кайбер нәрсәдә бөтенләй хаксыз икәнлеген һәм малай-шалай кебек аның тарафыннан тиргәлеп торуның бер дә килешкән эш түгеллеген бик яхшы аңласа да, энисенең хаксызлыгы алдында үзенең гаебе, үзенең «диваналыгы» чамадан тыш зур булганга, үз-үзен яклап ул шуннан башка берни әйтә алмады. Үкенү, ачыну тойгысы аның барлык горурлыгын, барлык күтәренке

уй-фикерләрен — барысын берьюлы юкка чыгарды, һәм ул, идәнгә, стена буенарак бер мендәр ташлады да, астына иске тунын җәйде дә, юрганга баштанаяк төренеп, урынга ауды. «Эх, бар икән күрәселәрем!— дип уйлады ул, уфтанып.— Ник кайттым мин монда? Ни өчен? Нәрсә өчен?»

Әнисенең тавышы ишетелмәсен өчен, ул колагын ныграк томалады, ләкин ана кешенең әрнүле сүзләре, мамык аша үтеп, туп-туры йөрәгенә тиде, чәнечте, өтеп-өтеп алды.

— Эш ташлап кайтыр булгач, йөрмиләр аны,— диде әнисе, һаман тынычлана алмыйча.— Бер дә куалап җибәрмәдем, үзең киттең. Качып кайткандыр, бер дә бүтән булмас. Бу вакытта нинди ял ди ул? Ике-өч ай эшләмә, сукыр бер тиен кебек кайт та кил ялтырап! Гата сыңары, җык җилкә...

Әнисе Һарунның бик тыныч холыклы иде. Балаларына ул беркайчан да юкка-барга кычкырынмый иде, шулай ук аларны төрле яман сүзләр белән дә атамый иде. Ул бары үзәгенә үткән чакларда гына, күңеле тулган-ташыган чакларда гына чыгырыннан чыгып китә торган иде. Ләкин андый чакларда да аның әле үз улына ялкау дип, җык җилкә дип әйткәне юк иде бугай.

Мондый сүзне Һарун беренче мәртәбә ишеткәндәй булды. Аның өчен бу иң яман, иң хурлыклы нәрсә иде. Беркайчан да аның әле үз-үзен ялкау дип, эшлексез дип исәпләгәне юк иде, киресенчә, аның булган бөтен байлыгы, бөтен мактанычы шул ялкау һәм эшлексез булмау иде.

«Эх, бар икән күрәселәрем!»— диде тагын да бәхетсез егет, үзалдына көрсенеп.

## XIII

Ул бары өч-дүрт сәгать кенә тынычлап йоклый алды. Кемдер кинәт: «Әй, ялкау! Җык җилкә!»— дип кычкырып җибәрде. Коты алынудан ул шундук уянып китте, тегендәгечә тиз генә сикереп торды һәм урындыкка куйган киемнәрен ашык-пошык киенде дә аягына торып басты. Әнисе дә, олы сеңелесе Сания дә өйдә юк иде, бары тик Равилә генә ике куллап чүпрәк белән өстәл өстен ышкып маташа иде. Өйгә тәмле ис — коймак исе чыккан иде.

— Абый, тордыңмы?— диде Равилә.

Абый кеше эндәшмәде. Равилә өстәл өстенә ашъяулык җәйде, йөгергәләп абыйсына ашарга әзерли башлады.

— Коймак пешердек. Әни яшелчә бакчасына утауга китте. Апа мәктәптә, аларны да бакча утарга кушканнар. Әни төшкә кайтмый,— дип сөйләнде кызый.

— Кайтмаса әллә...

Һарун тышка чыгып юынып керде, сеңелесенең бертуктаусыз сөйләнүен тыңлап, коймак ашады, катык ашады. Равилә, ух-вах килеп, өстәлгә кайнар самавыр китереп утыртты.

— Икәүләп кенә чәй эчик әле, иеме, абыкаем!— дигән булды, кеткелдәп.

— Укуың беттеме әле?— дип сорап куйды абыйсы ашаган арада.

— Әйттем ич инде — бер дә тыңламыйсың икән син!— диде Равилә, исе китеп.— Бишенчегә күчтем. Бер «өчлем» бар, калганнары «биш» тә «дүрт»!

— «Бишле»се дә бер генәме?

— Булыр! Нишләп бер генә булсын! Ике. Ике «бишле»!

— Булдыргансың,— дигән булды Һарун, сеңелесен мактап.

Равилә күңеле булып көлеп куйды. Аның бу көлүе абый кешегә ошап җитмәде. Сеңелесе аңа, менә мин синең шикелле ялкау түгел шул, дигән төсле булды. Аның йөзе караңгыланып китте, һәм бу турыда ул сүз озайтып тормады.

Шулай эндәшми-тынмый гына ашап утырганда, Равилә, бик белдекле булып:

— Бер дә яратмыйм шул Хәлимә апаны,— дип куйды.

— Нәрсә?— диде Һарун, кашларын җыерып.

— Һи, шул Хәлимә апаны әйтәм лә!— диде кызый.— Беркөнне безнең Хәсән абый янына килгән. Төскә дисәң, төсе юк, кеше белән җүнләп хушлаша да белми, Ходаем! Әллә нинди мөжеле шунда!

— Бик күпне белә башлагансың әле син,— диде Һарун.— Күпне белсәң, тиз картаерсың!

— Картайды, пычагым!— диде Равилә, көлеп.— Син дә инде, Һарун абыкаем, Хәлимә дигәч тә дуларга тотынган буласың.

«Юри үчекләшә,— дип уйлады Һарун, ярсып.— Күрәсең, Саниясе котыртып киткәндер».

— Бар әле, утырма монда!— диде ул, сеңелесен өстәл яныннан төрткәләп.

Шат күңелле кызның моңа чын-чынлап сөмсере коелды. Йөзен чытты да, битен кулы белән каплап, үпкәләп читкә китеп барды.

— Әни кайтсын әле, күр дә тор, барыбер әйтәм!— диде

ул, яшь аралаш.— Баеп кайткан да әллә кем булган. Күрерсең әле менә, әни кайтсын әле!

— Сөйләнә әле яме!— диде Һарун, кычкырып. Кызый куркып чоланга ук чыгып китте һәм үзен куркынычсыз урында итеп сизгәч, кыюланып, үчекләшергә үк тотынды.

— Баеп кайткан да тилергән була,— диде, әнисенең сүзләрен кабатлап.— Зиннур абый кайтсын әле менә, күрсәтер әле күрмәгәнеңне, җык җилкә!

Һарун урыныннан сикереп торды, өй ишеген япты да, иреннәрен чәйнәп, яңадан өстәл янына килеп утырды. «Китәм! Бер көн тормыйм!»— дип уйлады ул, ярсып, усалланып.

Китәргә булгач китәргә! Әни кайтканчы ук китәргә. Хәзер үк! Теләсә нинди нахак сүз ишетеп... Бу елаклар күрмәгән, ишетмәгән булсалар да ярар иде... Киткәч, анда теләсә нәрсә сөйләсеннәр.

Чәй яныннан кузгалгач, Һарун тышка чыкты. Чыкса, тезенә башын салындырып, баскыч төбендә Равилә елап утыра.

— Нәрсә балавыз сыгасың монда?— диде ул, бик үк каты орынмыйча гына.

— Сыгам менә...— диде кызый, үксергә тотынып.— Мин сине сагынып көтеп тордым, Һарун абыкаем кайта дип... Атасыз бала дигәч тә...

Аның шулай сөйләнгәләп утыруы абый кешегә кызык булып китте.

— Ярар инде, җылама,— диде ул, йомшарып.— Үзең дә усалсың бит.

— Усал шул!— диде кызый, каш астыннан гына абыйсына карап.

— Әйдәле икәүләп бакчага чыгып керик,— диде Һарун.— Быел тагын кәбестәләр, кишерләр утырттыгыз микән...

— Син булмагач та... әллә теге... кәбестәсез калырлар дип белдеңме!— диде Равилә, күз яшьләрен сөрткәләп.

Алар икәүләшеп бәрәңге бакчасына керделәр, куакланып килгән бәрәңге төпләрен карап уздылар, ямь-яшел булып утырган суган түтәле янына тукталдылар да,— суган кыягы өзеп ашадылар, аннары кишер-кәбестәише нәрсәләрне карарга тотындылар.

— Бер дә утамагансыз,— диде Һарун, кишер арасындагы чүпләрне өзгәләп.

— Барысына да каян җитешәсең!— диде Равилә, олыларча.— Калхузныкын утаргамы, үзеңнекенме? Безнең бит монда биш кулыбыз юк.

— Бигрәк телең озайган,— диде Һарун.— Шунда җылап утырганчы, менә бу чүпләрне утасаң, әнигә файда булырые ичмасам.

— Кайсына-берсенә җитешергә дә белмәссең инде!— диде кызый, яңадан күңеле күтәрелеп.

— Сөйләнә але!— диде абыйсы, каты гына.— Тотын хәзер үк. Башта менә бу чөгендер түтәлләрен ута, чөгендерләрен йолка күрмә.

— Беләм инде, беләм, өйрәтмәсәң дә бик...

— Кешене җык җилкә дигән була,— диде Һарун, килешүчән тонда.— Үзләре монда ялкауланып беткәннәр мин юкта.

— Бер дә харап инде!— диде Равилә, чөгендер түтәле өстенә иелеп.— Син әйтмәсәң белмидериек. Колак итләремне ашадың инде, Һарун абыкаем.

— Телбистәсе!— диде абыйсы, көлемсерәп.— Бозылып беткәннәр мин юкта, ялкаулар!

«Ялкаулар» сүзен, «җык җилкә» сүзен кычкырып әйткәч, үзенә карата түгел, бәлки бүтән кешегә карата әйткәч, әнисе әйткән сүзләрнең тәэсире, дөресрәге, шул тәэсирнең күңел төбендәге калдыгы юкка чыккандай булды. Аның күңеле күтәрелә төште, һәм ул бәрәңге төпләре арасыннан йомшак туфрак таптап, бакча читәненә таба атлады. Былтыр тотылган читән инде кайбер урыннарында басылгандай булган, кайбер урында — иске баганасы черепме, мал-туар ышкылыпмы — кыегая башлаган иде, ә бер төштә бөтенләй тотрыксызланып калган иде. Һарун баганаларны тоткалап, селеккәләп карады. Шулай тикшереп карый-карый ул бөтен читәнне әйләнеп чыкты. Шуннан соң өйгә кереп, үзенең үткер балтасын эзләп тапты. Ләкин балтаның инде исеме генә үткер иде, үзе юк чакта аны тупасландырып бетергәннәр иде. «Хатын-кызга калса дөньяң, хәзер җыкка терәлә инде ул»,— дип уйланды ул үзалдына. Балтасын үткерләгәч, ул утынлыктан баганалар эзләп алды да шуларның барысын да читән буена өстерәп алып китте.

Берничә сәгать буена ул читән белән булашты, аннары абзар тирәсен караштырды. Абзар эченә, сыер яткан җиргә шактый тирес өелгән иде — сәнәк алып шуны түгәргә кереште. Тирес түгү аңа кичкә кадәр җитте. Ул мавыгып китте. Үзе әледән-әле көрсенеп-уфтанып куйды, «дөньяны рәтләп алып бара белмәгән» хатын-кызны тиргәде, шулкадәр тирес калдырган сыерны тиргәде. Тирес белән булашкан чагында, тегендәге саманчыларны исенә төшерде, аларның да шулай тирес белән, салам белән эш итүләре турында уйлады. Бер дә юктан аның күңелендә үз-

үзеннән ризасызлык тойгысы калкып чыкты. Туган йорт та, бакча да, абзардан чыгарып өйгән тирес өеме дә — берсе дә күзенә күренмәс булды, һәм ниндидер зәһәр корт кебек шундук аны үкенү ачысы газаплый башлады.

Ә бит аның әнисе чыннан да хаклы! Бит ул чыннан да эш ташлап кайтты!

Күрәсең, кичәгәчә эчке өмет итеп, караңгы төшәр алдыннан Гата килеп керде. Керде дә, кич чыгабызмы, диде, башың ничек, диде; кичә кайчан кайттың, эшләр уңдымы, диде. Һарун теләр-теләмәс кенә сөйләште, кәефем юк, беркая чыкмыйм бүген, диде.

— Әйдә киттек Ташкичүгә!— диде Гата, суынган Һарунны яңадан кыздырмакчы булып.— Хәзер айгырны җиктерәм!

— Булмый, малай,— диде Һарун, иренеп кенә.— Әнинең дә ачуы килгән. Кайтып төшү белән ярамый бит алай.

Ташкичүгә бару турындагы тәкъдимне ул бөтенләй җавапсыз калдырды. Гата исә бу турыда үзенчә уйлады. «Егетләр тукмап кайтарганнар!— диде ул.— Синнән буламы соң! Кыз алырга кайткан, имеш! Тоттырдылар ди сиңа кызны!..»

## XIV

Икенче көнне Һарун көне буе лапас түбәсен рәтләде, урам як капкаdebug селкенеп торган баганасын ныгытты, утынлыкта теләсә ничек аунап яткан чыбык-чабыкларны, утыннарны бер җиргәрәк өеп куйды, утын кисте һәм күзгә ташланып торган шундый эшләр эшләнеп беткәч, баскыч тирәләрен, абзар алдын — бөтен җирне ялт итеп себереп куйды. Моңарчы ташландык хәлдә булган ишегалды ямьләнеп, күңеллеләнеп китте.

— Кулың-аягың сызлаусыз булсын инде, Һарун абыкаем,— диде телмәт Равилә.— Ялап алгандай иткәнсең. Мин түгел, әни дә шулай себерә алмасые.

Соңгы сүзләрен ул, ахрысы, чынлап әйтте. Аның шулай олылар сүзен үзенеке итеп сөйләвенә Һарун тагын көлемсерәп куйды.

— Чөгендерне утадыңмы соң әле? Менә хәзер кереп карыйм — бетмәгән булса, кирәгеңне бирәм!

— Утамаса, уталыр әле!— диде кызый, аптырап тормыйча.— Минем монда биш кулым юк. Хәзер менә суга барасым бар. Көтү кайтыр вакыт җитә... монда теге...

— Карап-карап торам да, бигрәк остаргансың әле син,— диде абый кеше.

— Сиңа кушмаслар әле, Һарун абыкаем,— диде Равилә, кеткелдәп.— Бигрәк тагын... Хатын-кыз эшенә кысылмасаң әллә...

Үзеннән зур чиләкләрен шалтыр-шолтыр китереп, шаярып, көлә-көлә ул суга китеп барды. «Кара, ничек үзгәргән!»— дип уйлады Һарун үзалдына.

Кичкелекне ашаганда, Һарун карасына орынып, бер дә юктан көрсенеп утырды.

— Нәрсә уфтанасың?— диде әнисе.— Тирес түгәр өчен шулкадәр җирдән кайтып йөрмиләр аны. Ярапланга, эчкегә тоткан акчаңны йортка бирсәң, үзем дә түгеп куярыем тиресне генә.

Равилә пырхылдап көлеп җибәрде. Абыйсы белән әнисенең мөнәсәбәтләрен яхшырак аңлаган Сания, әдәп саклап, эндәшми калды һәм ачуланып астан гына сеңелесен чеметеп алды. Равилә, чыраен сытып, йодрыкларын йомарлап апасына ташланды.

— Сезгә тагын ни җитми?— диде әниләре, үртәлеп. Ул әле улы белән тавышланудан соң тыныбрак торган иде. Ләкин әнә бөтенләй үк тынычланып җитмәгән икән, йөрәгендә әле һаман төен торып калган икән, һәм менә ул хәзер яңадан да дуларга чамалый иде, ахрысы. Һарун, башын иеп, әкрен генә ашавында булды.

— Чаңгакүл ягыннан бура ташыйлар кешеләр. Барып кайт, ичмасам, бер файдаң тияр,— диде әнисе, улына карамыйча гына.— Миңа инде күп калмаган, шунысы да җитәр миңа. Сез торасы, сезгә кирәк... Сине бит әнә ун мең белән кайткан диләр.

— Кайткан!— диде Һарун.— Ун меңне әллә анда аяк астында аунап ята дип белдеңме!

— Аяк астында аунап ятмагач, ниеңне күреп акча туздырып йөрисең?

Һарун җавап кайтарып тормады, ашык-пошык кына ашады да, колагым тынмасмы, дип, тышка, баскычка чыгып утырды. Кич чыгу турында ул хәзер уйлый да алмады. Башына авыр кайгы төшкән кеше сыман, ул шулай кичке шәфәкъка, караңгылана барган җир өстенә карап утырды-утырды да чоланда үзенә-үзе урын җәеп йокларга ятты.

Иртән ул иртүк торды, коры-сары капкалап җылы сөт эчте дә, әнисенә бер сүз әйтмичә, Чаңгакүлгә китеп барды. Анда аның бөтен көне узды. Ләкин юлы уңмады. Яңа бурага аның көче җитәрлек түгел иде. Аннары, ул мәсьәләнең икенче ягын да уйлады. Бура сатып алу белән генә әле эш бетмәячәк иде. Аны әле ташытырга, ташу өчен исә машина ялларга, машина эзләргә туры киләчәк иде.

Боларның барысы да бик озакка сузылырга мөмкин иде. Хәзер аның һич тә вакытын андый нәрсәләргә әрәм итәсе килмәде. Аның моңа чын-чынлап күңеле тартмады. Әледән-әле ул еракта калган дала турында уйлады. Андагы эшкә, тормышка, андагы кешеләргә ул шундый нык береккән иде, шундый нык бәйләнгән иде, хәтта монда да ул үзен алардан тулысынча азат итеп сизә алмады, һәм анда булып узган һәртөрле кайгы-шатлыклар әле булса аңа тәэсир итә шикелле тоелды. Ләкин шул ук вакытта ул монда, даладан бик еракта булганда, үзенең үткән тормышына икенчерәк күз белән карый башлагандай булды: тәэсирләр йомшарды, кайбер томанлы нәрсәләр ачыклана төште, кайберсе, киресенчә, онытылып юкка чыкты.

Чаңгакүлдән кайтышлый, үзләре авылында ул үзенең икенче бер яшьтәшен очратты.

— Әллә сине өченче көн Ташкичүләр тукмап кайтарды?— диде аңа яшьтәше.— Әллә кайда йөрисең үзең дә! Әйдә, бүген җыйнаулашып китәбез үзләрен тукмарга!

— Мине беркем дә кыйнамады,— диде Һарун, сүзнең нәрсә турында барганлыгын бик үк аңламыйча.

— Кыйнамаган! Җилсез агач шауламый. Хәлимәне алырга дип барган икән дә, Ташкичү егетләре дөмбәсләп кайтарган икән үзен, диләр.

«Хәлимә» сүзен ишеткәч, Һарунның чырае сытылып китте.

— Кем сөйли?— диде ул.

— Бөтен авыл сөйли,— диде яшьтәше.— Әйдә, Мирзаханның айгырын җигәбез дә төялешеп китәбез бүген!

«Китми торыгыз!»— дип уйлады Һарун, ачуы килеп.

— Менә йорт мәшәкате артыннан йөрим әле,— диде ул яшьтәшенә.— Көн дә бәлеш, көн дә туй булмый бит. Булды, җитәр...

«Әйе, булды! Җитәр!»— диде ул яшьтәшеннән аерылгач та, ныклы бер фикергә килеп.

Бирелгән унбиш көнлек ялның әле башланмаган ун көне булса да, өенә кайткач та ул ерак юлга әзерләнә башлады.

## Сигезенче баб

### I

Икенче бригаданың Көктугай ягына күченеп килүенә барыннан да бигрәк Мәрьям сөенде. Исламның бригададагы тормышы турында ул Ислам үзе сөйләгәннән башка берни белми иде һәм бик үк белергә дә тырышмый иде. Кайбер хатын-кызга хас булган шымчылык белән, сүз йөртү, юкка-барга шикләнү, көнләшү ише нәрсәләр белән ул бөтенләй диярлек таныш түгел иде. Исламның соңгы вакытларда бөтенләй күзгә-башка күренмәвенә дә, килгән чакларда үз-үзен бик сәер тотуына да, хәтта булачак бала турында әллә нинди тузга язмаган сүзләр сөйләвенә дә карамастан, ул әле һаман аңа карата ышанычын югалтмаган иде.

Ул аның бүген кич килеренә әз генә дә шикләнмәде. Ул үзендә гаҗәеп бер күтәренкелек тойды. Эштән соң ул үз бүлмәсенә ашыгып-кабаланып кайтты. Ислам аны күптән инде көтеп торадыр шикелле тоелды. Ишектә йозак эленеп торуына да ул артык кәефсезләнмәде. Ярым караңгы бүлмәгә килеп кергәч тә, балкытып ут яндырып җибәрде дә, өстен-башын чишенеп ташлады да, плитәгә якты, чәй утыртты һәм чәй кайнаганчы тиз-тиз генә идәнен сөртеп ташлады. Шуннан соң ул ике кешелек итеп ашарга әзерли башлады.

Ул әледән-әле сәгатькә күз төшереп алды, ишеккә колак салды, чоланда ниндидер аяк тавышлары, кыштырдаган тавышлар ишетеп, хәтта бер-ике мәртәбә ишеген дә ачып карады. Вакыт һаман үтә торды, ләкин килүче-китүче булмады. Чәй дә кайнады, күкәй тәбәсе дә куырылды, табын да әзерләнде...

Мәрьям, авызына берни капмыйча, борчылып, дертмерт килеп һаман көтеп утыруында булды. Вакыт үтте дә үтте, чәй дә суынды, күкәй тәбәсе дә суынды, ул әле һаман ашарга тотынмады. Хәзер инде ашыйсы да килми башлады.

Шулай боегып утырганда, ишек ачылып китте. Мәрьям сискәнеп шундук урыныннан торды. Ләкин керүче кеше аның күршесе Рәйханә апа булып чыкты.

Рәйханә апа белән алар тату гына яшиләр иде, берберсенә йомышка-нигә кергәлиләр, кайчагында серләшеп-сөйләшеп тә алгалыйлар иде. Рәйханә апа Мәрьямнең кайбер серләрен дә белештерә иде, һәм өстәлдәге ашамлыкларга карап, хуҗа кешенең кыяфәтенә карап, ул хәзер дә мәсьәләне бик тиз төшенеп алды һәм үзе дә сизмәстән:

— Көтәсеңме?— диде.

Мәрьям, әйе дигән сыман, елмайгандай итеп куйды. Күрше хатын исә, үзенең кирәкмәгәнне ычкындыруын шәйләп алып, тизрәк йомышын әйтергә ашыкты.

— Оятын оят та инде, Мәрьям җаным, чәй эчәргә шикәребез калмаган,— диде ул.— Бераз гына биреп тор инде син, Мәрьям җаным.

Мәрьям, иелеп, өстәл астын караштырды да, тапмагач, өстәл өстендәге шикәр савытын күршесенә тоттырды. Үзенә ул ике-өч шакмак кына алып калды.

— Болай күп булыр бит, Мәрьям җаным,— диде Рәйханә апа.— Оят булса да...

— Ал, ал, Рәйханә апа! Ни сөйлисең, без бит инде... Рәйханә апа, һаман да «оят булса да» дип сөйләнә-сөйләнә, шикәрне савыты белән күтәреп чыгып китте. Аның керүе Мәрьямне газаплы уйлардан арындырган кебек булды. Аның ашыйсы килеп китте, һәм ул, иренеп кенә, теләр-теләмәс кенә ашарга кереште.

Исламны ул төн уртасына кадәр көтте. Килүче кеше булмагач, өстенә киенеп тышка чыкты, калку яр читенә килде дә икенче бригада ягына — үзенә тартып, кызыктырып кызгылт утлар җемелдәшкән якка озак кына карап торды. «Ярар, бүген килмәсә, иртәгә килер. Эше бардыр»,— диде ул, үз-үзен юатып.

Икенче көнне ул аны иртүк көтә башлады. Кибетен ачып эшкә тотынгач та, һәрбер керүчене игътибар белән күздән кичерде. Икенче бригада кешеләре күренгәли башлагач, аңа күңеллерәк булып китте. Алар белән ул бик теләп, иркенләп сөйләште, ник кайттыгыз монда, дигән булды, саман сугаргамыни, дигән булды, ярый инде, әллә кайда далада ятканчы, якынайдыгыз, дигән булды. Кыюланып, шаярткалап, хәтта, бригадирыгызниндирәк кеше соң сезнең — усал түгелме дип тә ычкындыргалады. Үзенең шуклыгыннан ул үзе дә көлеп куйган булды һәм тагын да ныграк кыюланып:

— Бик чибәр күренә ул, каһәр,— диде.

— Чибәрен чибәр дә, без аны ятларга бирмибез шул!— диделәр кызлар, шаулашып.

— Әйдәгез безгә! Бригадага берсүзсез алырбыз,— диделәр егетләр.

Яшьләр белән шулай көлешеп-сөйләшеп торганда, кибеткә ышкылып беткән кара портфель тотып, күзлекле бер кеше килеп керде. Аның янында рабкооп председателе Галимов һәм тагын бер ят кеше бар иде. Мәрьям күзлекле кешене шундук танып алды. Бу— районнан килгән ревизор иде.

## II

Кибеттәге кешеләргә чыгарга куштылар. Кибет ябылды һәм ишеккә «учет» дигән язулы ак кәгазь ябыштырылды.

Ябык ишек артында ревизия башланды. Ревизия кичкә кадәр дәвам итте һәм икенче көнгә дә калды.

Мәрьям үз бүлмәсенә бик төшенке күңел белән кайтты. Аның исәп-хисап эшләре бик үк шәптән түгел иде. Бу турыда ул үзе дә белә иде һәм вакыты-вакыты белән шактый пошаманга да төшеп куйгалый иде. Ләкин күңелендә бүтән төрле борчулар өстенлек иткәнгә, бу мәсьәләгә ул тиешенчә игътибар итеп җиткерә алмаган иде. Аннары аның сәүдә кешесе өчен иң хәтәр, иң начар бер гадәте бар иде: көндәлек исәп-хисапны бик үк яратып җиткерми һәм тиеннәрнең, граммнарның көндәлек хисабын алып баруны вак эш, ялыктыргыч эш дип исәпли иде. Шуңа күрә үз өстендә күпмелек товар барлыгын ул чама белән генә белә, ләкин, чама белән исәпләгәндә дә, күпмедер аның өстенә чыгарга тиеш иде. Акчасын соңыннан китерерсез дип, ул кайберәүләргә шикәрдер, ярмадыр биреп җибәргән иде.

Алары әле аның берни түгел. Ә менә бәясе түләнмәгән аракылар, балыклар, папирослар!.. Алары инде җитәрлек. Эш хакы алгач түләрмен әле, диде, качмас әле, үз кулымда, диде. Менә түләде! Хәтта Ислам өчен дә шулкадәр юмарт булырга ярамаганлыгын ул нишләптер исеннән чыгарып ташлады.

Мәрьям төнне тагын ут-газап эчендә уздырды. Икенче көнне кичкә таба ревизия тәмам булды. Сатылмаган барлык товарларны үлчәп-санап чыкканнан соң һәм бухгалтериягә кергән мәгълүматларны тикшереп-чагыштырып караганнан соң, барлыгы өч мең дә бер йөз кырык өч сум сиксән тиен җитмәүчелек чыкты. Ревизор акт төзеде, тиешле кешеләрдән кул куйдырды да район үзәгенә кайтып та китте.

Мәрьямнең әле сатучы булып эшләү дәверендә беркайчан да мондый хәлгә юлыкканы юк иде. Аның коты алынды. Ул үзен беткәнгә исәпләде һәм алда бернинди котылу юлы күрмәде. Моңарчы аның өскә чыгулар турында, суд, төрмә турында күп кенә сүзләр ишеткәне бар иде. Ләкин боларның барысы да аңа чит нәрсә булып, үзенә һич тә катнашы булмаган һәм булуы да мөмкин булмаган нәрсә булып тоела торган иде. Хәзер ул үзе ишеткән шул куркыныч хикәяләрне исенә төшерде, һәм аның түбә чәчләре үрә торды. «Минем турыда да шулай

кызганып, куркып сөйләрләр микән?»— дип уйлады ул. Шуннан соң аның күңеленә икенче төрле уйлар килде, икенче төрле уйлар артыннан өченчеләре килде, һәм кинәт үз-үзенә ул: «Бала нишләр?— диде.— Төрмәдә туар микәнни? Атасыз булып? Нинди хурлык, нинди мәсхәрә!»

Үз-үзен түгел, бәлки, булачак баласының булачак язмышын кызганып, ул чак-чак кына елап җибәрмәде. Ләкин аның хәле хәзер елаудан узган иде. Елап кына монда берни дә эшләп булмаячак иде. Ялынычлы, кызганыч күзләрен тутырып, ул Галимовка карады.

Маңгай чәче коелып беткән зур такыр башлы, зур калку маңгайлы һәм челпи зәңгәр күзле Галимов, ревизор калдырып киткән акт кәгазен нишләтергә белмәгәндәй кулына алды да, Мәрьямгә ничектер кыеклатыбрак, яны белән рәк караган көе, салкын гына:

— Да, сеңелем,— диде,— эшең харап. Ярый ла берике ел белән генә котыла алсаң...

Мәрьям агарынып китте һәм керфекләрен чылаткан күз яшьләрен күрсәтмәс өчен тиз генә читкә борылды. Үз хәленең бик үк шәптән түгеллеген аңласа да, шулай да ул Галимов авызыннан берәр җылырак сүз көткән иде. Ни әйтсәң дә, ул баш кеше, сәүдә эшендә шактый тәҗрибәле, шактый шомарган кеше иде һәм, әлбәттә, ул инде мондый гына хәлләрне башыннан кичергән булырга тиеш иде.

Галимов исә аны бераз гына шүрләтмәкче булды. Монда аның үз исәбе бар иде. Ул инде ир уртасы кеше иде. Казанда аның бик шәп фатиры, хатыны, ике баласы калды. Хатыны белән ул аерылышып китмәде, онытканда бер аңа хат язып, акча салгалап торды. Ләкин Казанда хатыны булган өчен генә ул һич тә монда әүлия булып яшәргә исәп тотмады һәм кайда гына җай чыкмасын, ничек тә форсаттан файдаланып калырга тырышты. Бергә эшли башлаган көннән үк аның челпи күзе Мәрьямгә төште. Ул бик озак сызланып, нурсыз күзләрен майландырып йөрде. Ләкин үзенең аннан бик олы булганлыгын, яшь, чибәр кыз тирәсендә яшь, чибәр егетләр бөтерелеп йөргәнлеген белгәнгә күрә, аннары, билгеле, Мәрьям шактый кырыс торганга күрә, баштарак ул аңа якын килергә бик үк батырчылык итә алмады. Шулай да аның белән бергә булган чакларда, ул аңа шаяртып сүз кушкан булды, кочакларга, йә булмаса сыларга-сыйпарга, иркәләргә азапланган булды, беркөнне кызмача баш белән хәтта аның бүлмәсенә үк барып керде. Андый-мондый нәрсә турында ачыктан-ачык сүз кузгатмаса да, Мәрьямнең эчен пошырып, саруын кайнатып, Ка-

занда калган хатынын, бала-чагаларын хурлап утырды, мин инде анда кайтмыйм, диде; шушында тормыш корып җибәрергә кирәк, диде. Мәрьям көлә-көлә аны чәй белән сыйлады.

Аның янына ул икенче мәртәбә дә килде. Монысында инде хатынын, бала-чагаларын гына хурлап калмады, күңелендә булган барлык нәрсәсен чыгарды да салды. Мин сине май эчендә генә йөздерермен, диде; атласка, ефәккә төрендерермен, диде. Мәрьям әйтеп тә карады, ачуланып та карады, алай да аңлата алмагач, өеннән үк куалый башлады. Галимов чыкмады. Шуннан соң хуҗа кеше күршесенә шакырга тотынды. Куркып, ни булды дип, Рәйханә апа килеп керде. Кызарынган, уңайсыз хәлдә калган Галимов, исереккә салынып, гафу үтенә-үтенә, тизрәк чыгып таю ягын карады.

Шуннан соң аларның аралары бозылып китте. Галимов, ачыктан-ачык аяк чалмаса да, аңа карата үзен эре тотты, хәтта беркадәр дәрәҗәдә хәтере калган, нахакка рәнҗетелгән кеше кебек тотты.

Менә хәзер җай чыкты. «Әһә, асыл кош аягыннан эләгә!»— дип уйлады ул, куанып. Караңгы төшкәнне генә көтте дә өченче мәртәбә аның янына китеп барды.

## III

Галимов килеп кергәндә, бүлмәдә беркем юк иде, түшәмдә ут янып тора иде, димәк, хуҗа кеше кайда да булса шушы тирәдә генә булырга тиеш иде.

Мәрьям бу вакытта Рәйханә апаларда иде. Үз бүлмәсенә кеше кергәнен ишетеп, ул тиз генә урыныннан кузгалды. Керүчене ул Исламдыр дип уйлады, ләкин Ислам урынына Галимовны күргәч, йөзендәге шатлык нуры шундук юкка чыкты һәм үз бүлмәсенә керергәме, кермәскәме дигән төсле, бусагада туктап калгандай итте.

— Ник килдегез?— диде ул, коры гына.

Үзенең шушы такыр башлы кешегә буйсынган икәнлеген һәм киләчәк язмышы да, ихтимал, аның кулында булуын яхшы белсә дә, аңа карата ул хәзер әз генә дә ягымлы һәм ачык йөзле була алмады. Ул әле генә үзенең нинди хәлгә таруы турында Рәйханә апа белән сөйләшеп утырды. Аның белән сөйләшкәч, аның күңелендә беркадәр ышаныч һәм өмет чаткылары туган сыман булды.

— Гафу ит, өйдә юк икәнсең, сеңелем...— диде Галимов, үзен гаҗәеп дәрәҗәдә тыныч тотып.

— Галимов абый,— диде Мәрьям, эчке бер әрнү

белән,— тагын күршеләр сизенгәнче... чыгып китегез тизрәк! Үзегез дә оятлы буласыз, мине дә...

— Туктале, кызма, сеңелем,— диде Галимов, кайгыртучан бер йомшаклык белән.— Мин менә сине оятлы итмәс өчен дип килдем дә. Кер, утыр, тыңла.

Мәрьям эчкә керде, ишекне япты һәм ишек яңагына сөялеп калды.

— Алай булмый инде ул, сеңелем,— диде Галимов, аның басып торуыннан риза булмыйча.— Аяк өсте генә сөйләшә торган сүз түгел бу.

— Мин болай да ишетәм,— диде Мәрьям.— Сөйләгез, тыңлыйм.

Галимов, башларгамы, юкмы дигән сыман, беравык ы-мы итеп утырды, аннары күзгә төртелеп, сөзелеп торган киң елтыр маңгаен калкытты да:

— Үземә авырлык китереп булса да...— диде, әкрен генә сүзгә башлап,— мин сиңа булышырга уйлыйм, сеңелем.

Ул сүзеннән туктады да, ни әйтерсең моңа дигән сыман, зур маңгаен тагын югарырак күтәрә төште. Мәрьям һаман эндәшмәде.

— Иртәгә районга барам,— диде Галимов.— Түләтергә генә ясармын...

Шул чакны Мәрьямнең йөзендә җанлану әсәре күренде. Каш астыннан гына ул Галимовка карап алды, ләкин баягыча, конторадагыча аның алдында җебеп калырга, ялынырга, ялварырга аңа нидер комачаулап торды. Ул аңа хәтта рәхмәт тә әйтә алмады. Аның сүзсезлеге исә Галимовның эчен пошырды. Сабырсызланып, ул утырган урынында кыймылдап алды, өстәлгә барабан каккандай итте. Тиз генә ачылып китүе өчен ул күңеленнән үкенеп куйды. Шулай шактый тынып утырды да кинәт икенче яктан һөҗүм итеп карамакчы булды.

— Миндә бер мең чамасы бар,— диде ул, аның кайгысын уртаклашкан булып.— Мин сиңа биреп торырмын. Башкасын каян табарсың... менә анысы мәсьәлә. Бу турыда бик шауларга да ярамый. Баш китә торган эш бу, сеңелем. Но... җайларга да булыр кебек... Анда әле аларга бераз төртергә дә кирәкмәгәе — шундый халык инде алар... ягъни без...

— Мин ничек тә акча табарга тырышырмын, Галимов абый!— диде Мәрьям, тиз генә.

— Син инде, сеңелем, аңлыйсың, судка бирмәгән очракта да, эшеңнән алынырга тиешсең... закуны шундый аның,— дип дәвам итте баш кеше, өстәлгә барабан каккалап.— Үзеңә генә әйткәндә, минем сине бер дә эш-

тән чыгарасым килми. Өйрәнгән яу сугышмакка яхшы, ди...

— Рәхмәт инде, Галимов абый,— диде Мәрьям, күңелсез генә.— Казанда да өч-дүрт ай гына эшләдем, монда тагын... Минем бит тәҗрибә юк сезнеке кебек.

— Шул шул! Әнә шулай килеп кабасың инде аны, сеңелем, итәгеңне җыеп йөрмәсәң. Ярый әле мин булдым... Син минем кадерне белмисең белүен... Бүтән кеше булса, күз дә йоммый төрмәгә илтеп тыгарые.

— Рәхмәт инде, Галимов абый,— диде Мәрьям, кабатлап.

Кыска гына вакыт эчендә гөлт итеп кабынып киткән шатлык хисе шундук юк булды. Аның хәзер такыр башлы бу кешегә — әрсезләнеп, үзен-үзе түбәнсетеп, үзен-үзе мактап утырган бу кешегә тагын ачуы кабара башлады.

— Мин, алайса, Рәйханә апага кереп карыйм әле,— диде ул, ишек тоткасына тотынып.

— Теге врач хатынгамы?— диде Галимов, сагаеп.

— Әйе, шуңа.

— Ярый, сеңелем, мин китим. Акча табалмасаң, үземә кил. Ничек тә җайларбыз. Монда халык бай, безнең эше генә түгел.

Чыгып киткәндә, ул шулай да никтер икеләнгәндәй итте, елмайган булды да кисәк кенә Мәрьямне кочып алды.

— Хәйләкәр дә соң үзең дә,— диде.— Хәзер инде күршесе белән генә куркыта!

Мәрьям, боргаланып, шуышып тиз генә аның кочагыннан ычкынды, елмайган булып, шаярткан булып, аны ишеккә таба этеп җибәрде.

Галимов фуражкасын басыбрак киде дә тиз генә чыгып китте.

## IV

Ул киткәч, Мәрьям тагын күршесенә керде. Рәйханә апа аңа биш йөз, алты йөз чамасы биреп торырга мөмкинлеге барлыгын әйтте.

Мәрьямнең үзенең дә кассада өч йөздән артыграк акчасы бар иде. Бу барысы сигез йөз, тугыз йөз чамасы булды. Галимовныкын да истә тотсаң, бу барысы ике мең чамасы булачак иде. Ләкин аның Галимовтан аласы килмәде. Шулай булгач, аңа тагын ике меңнән артыграк кирәк иде. Каян, кемнән алырга?

Аның алдына котылгысыз булып шундый сорау ки-

леп басты. Ул уйланырга тотынды. Хәер, уйланып та тормады. Аның уйлары шундук Исламга юнәлде.

Аның монда аннан да якын, аннан да үз кешесе юк иде. Монда аны бары ул гына коткарып калачак иде, монда бары аңа гына ялынырга, аңа гына егылырга мөмкин иде. Ник ялынырга? Монда алай ялынып, егылып торасы да юк. Аңа бары мәсьәләне генә аңлатып бирәсе бар. Калганын инде алар икәүләшеп хәл итәчәкләр.

Шулай да ул килмәде. Күрәсең, чынлап та бер-бер хәл булгандыр. Бармыйча ярамый. Ачуланса ачуланыр, бармыйча ярамый. Мөмкин түгел. Җитәр болай яшәргә! Ара якын, күп булса, унбиш-егерме минутлык юл. Ул анда ятырга тиеш түгел... Ул монда күченергә тиеш...

Һәм ул яхшылабрак, томаланыбрак киенде дә, бизгәк тоткан кеше сыман, ашыгып-кабаланып тышка чыкты. Ул инде моңарчы да, әгәр дә мәгәр Ислам бүген дә килмәсә, бернигә карамый аның янына барырга кирәк дип уйлап куйган иде. Галимов белән булган сөйләшүдән соң аның хәле ачыклана төште, үз-үзенә ышанычы арта төште. Ул хәзер Ислам белән хәтта чит кешеләр алдында очрашудан да, Исламның моның өчен ачулануы мөмкинлегеннән дә курыкмады. Алай гына да түгел, моңа кадәр аннан аерым яшәве, кешеләрдән качып-посып яшәве аңа хәзер шундый мәгънәсез булып, шундый көлке булып тоелды — үзенең шулкадәр йомшак була алуына ул гаҗәпләнеп бетә алмады.

«Үз ирең белән, үз балаңның атасы белән бергә булмыйча... кешедән куркып... оялып яшә, имеш!» — диде ул үз-үзенә.

Юк, моннан соң болай булмаячак. Аның анда бригадир белән талашуында, кемнәргәдер икенче төрле булып күренергә тырышуында аның эше юк. Кешеләр өйләнешәләр дә, ни булса да бергә торалар, ни күрсәләр дә бергә күрәләр. Әгәр ул аның янында булса, аңа шулай газапланырга, ут йотарга туры килер идемени? Әллә нинди кабахәт Галимовларның оятсызлыгына түзеп торырга туры килер идемени?! Теләсә нишләсен, йә муенына сарылырга, йә үзен өстерәп алып кайтырга. Икенең берсе. Исән генә булсын, өйдә генә булсын. Хәзер инде юк-бар сәбәпләр табып тора алмас. Кибеттән дә чыгарачаклар. Бик шәп булачак. Ике арадагы киртә җимерелер һич югы. Ислам кайда, ул анда. Башкалар нәрсә эшләсә, ул да шуны эшләр. Кеше эшләмәстәй эш түгелдер әле саманнары.

Юлда аңа беркем очрамады, бары тик каршыдан авыр гыжылдап, дәһшәтле дию күзләре сыман ике утын балкытып, ниндидер машина гына узып китте. Бригада «авы-

лы» якынайганнан-якынайды. Төн карасында аермачык булып очлы башлы чатырлар, озынча вагоннар һәм трактор шәүләләре күренә башлады.

Чатырларга якыная барган саен, аның әллә нишләп хәле бетә, тыны кысыла шикелле тоелды. Ул туктап калды. Тынычланмакчы булып, бераз хәл җыеп торды, үзүзен юатырга, дәртләндерергә тырышты. Ләкин ниндидер көтелмәгән шомлы нәрсә, хәтәр нәрсә буласын сизенгән йөрәк, бернинди акылга, ихтыярга буйсынмыйча, ярсып, шашынып тибүендә булды.

Бераз җир барды да тагын туктап калды, тагын ике куллап күкрәгенә тотынды. Аңа кинәт бик күңелсез булып, бик куркыныч булып китте. Хәзер инде ул бернәрсә дә уйлый да алмады, нинди дә булса билгеле бер карарга да килә алмады. Ул бары менә хәзер Ислам белән, ике көн инде никтер килми яткан, үзе турында бернинди хәбәр-хәтер белгертмәгән Ислам белән очрашасын гына белде.

Нишләгән, ни булган аңа? Һәм нинди йөз белән каршылар ул аны?

Аның өчен хәзер бөтен дөнья, бөтен тормыш, бөтен мәгънә менә шушы бер-ике сорауга кайтып калды.

Бригада «авылына» бөтенләй үк якынлашкач, гармун тавышлары, кеше тавышлары аермачык булып ишетелә башлагач, әлеге шул бер-ике сорау, таркалып, берничә сорауга әйләнде, һәм аларның барысы да, баштагы шул бер-ике сорау кебек, бик мөһим, бик катлаулы булып тоелды. Каян табарга Исламны? Иң әүвәл кайсы вагонга, кайсы чатырга барып керергә? Керергәме, әллә берәрсенең чыкканын көтеп торыргамы?

Ул, карак шикелле як-ягына карангалап һәм тирәяктагы тавышларга бик нык колак салып, читтәрәк торган бер вагонга якын килде. Килде дә сагаеп тыңларга кереште. Вагон эчендә бернинди тавыш-фәлән ишетелмәде. Гармун кычкырту зур чатыр ягыннан ишетелә иде. «Андадыр»,— дип уйлады ул. Урыныннан кузгалды да, ниндидер тимер-томырларга абына-сөртенә, шунда таба атлады.

Аның чатырга якынлашуы булды, киндер ишек ачылып китте. Ачык ишектән кара җир өстенә көчсез генә яктылык бөркелде һәм «күсәкләр» дип сөйләнеп, Белугин килеп чыкты. Аны Мәрьям белә иде.

— Белугин!— диде ул, кычкырып.

Ләкин аның кычкыруы чынында бары пышылдау булып кына, карлыккан бер ыңгырашу булып кына чыкты. Белугин, бик якында гына булса да, күрәсең, аны

бөтенләй ишетмәде һәм черкиләрдән селтәнгәләп, каядыр китеп барды. Мәрьям тамак кырды һәм тагын да:

— Белугин!— дип кычкырды.

Монысында Белугин ишетте, туктады, үзенә кем эндәшкәнлеген аңлый алмыйча, артына борылып карады. Шул ук секундта аның беләгенә кайнар куллы ниндидер хатын-кыз килеп сарылды.

— Саша!— диде Мәрьям.— Әллә ишетмисең? Таныйсыңмы? Мин сине таныдым.

— Ә-ә!— диде Белугин.— Таныйм! Тик мин Саша түгел, Ваня.

— Ул кадәр кычкырма, Саша!— диде Мәрьям.

— Әһә, Ислам кирәкме?— диде Белугин, тавышын әкренәйтә төшеп.

— Әйе...

Белугин аны култыклап алды, нидер уйлангандай итеп торды да, бер сүз эндәшмичә, тракторлар ягына юнәлде. Шунда ул аңа көтеп торырга кушты, үзе кире чатырга йөгерде.

Берничә минуттан караңгыда таныш кеше шәүләсе күренде.

— Кем ул анда?— диде Ислам, тракторларга якынлашып.

Мәрьям урыныннан купты, тимер кебек авыр аякларын өстерәп, аңа таба атлады.

— Бу мин...— диде ул, калтыранган, карлыккан бер тавыш белән.

## V

Белугинның ничек эндәшүе буенча, Ислам үзен кем чакырганлыгын шундук сизенеп алды. Соңгы көннәрдә аның кәефе болай да шәптән түгел иде, бу сизенү исә аның күңелендә җыелып, йомылып ятарга мәҗбүр булган нәрсәләрне кузгатып җибәрде.

Үзе өчен ул бернинди алга китеш күрмәде. Ул әле бер генә теләгенә дә ирешә алмады. Теләкләр, янаулар, ачу-нәфрәтләр арткannан-арта барды, берсе өстенә берсе өелә барды. Хәзер инде андый теләкләрне, янауларны коры кул белән генә башкарып чыгып булмас шикелле тоелды. Күрәсең, гомер буена аңа шулай нәгъләт камыты киеп яшәргә туры киләчәктер. Аек акылы аның шулай диде, ләкин комсыз күңел һич тә моның белән килешә алмады. Үзенең хәле начарлана барган саен, аның бары ярсуы гына артты.

«Ник килгән ул монда?— дип уйлады ул Мәрьям ту-

рында.— Нинди йомыш белән килгән? Аның өйләнүе турында белеп, тавыш-гауга чыгарыр өчен килгәнме...— янган йөрәгенә түзә алмыйча?..»

Мәрьямнең үксүен, үксегән арада бәйләнешсез сүзләр сөйләнүен ул тешен кысып тыңлап торды. Үксү-зарлану аңа шулай да озаккарак сузылган шикелле тоелды. Ниһаять, аның түземлеге бетте, һәм ул аны тупас кына тотып алды да читкәрәк алып китте. Калкулык астына төшкәч, ул аны җиргә утыртты, тезләрен чәнчеп үзе дә аның янына утырды һәм куллары белән черки куалаган арада:

— Ник килдең?— диде.

Мәрьям җавап кайтармады, аннан гафу үтенгән сыман, йомшак кына итеп аның битеннән, башыннан сыйпалады, аннары бер кат яулыгын чишеп, аның ачык муенына бәйләде; аңа табарак елышты да, сабый бала сыман, башын аның күкрәгенә куйды.

— Ачуланма, Ислам,— диде ул, күрәләтә бер ялыныч белән.— Син миңа гел ачуланырга гына торасың. Минем бит сиңа бер сүз әйткәнем юк.

— Сөйлә, ник килдең?— диде Ислам, йомшый төшеп.

Мәрьям сөйләп бирде. Бу көннәрдә үзенең бик сагынуы турында, ревизия турында, өстенә чыгуы турында сөйләде.

«Өйләнү турында ишетмәгән икән әле»,— дип уйлады Ислам, сөенү шикелле бернәрсә тоеп. Ләкин ул уйга калгандай булды. Акчаны ул, мулла кебек, бары ала гына белә иде — аның шундый бер наданлыгы бар иде.

— Нәрсә, түләргә кушалармыни?— диде ул.

— Ыы, түләргә кушалар...— диде хатын, көттереп. Бу мәсьәлә үзе өчен никадәр әһәмиятле булмасын, бу яктан үзенең хәле никадәр мөшкел булмасын, шулай да Мәрьям аннан иң элек бүтән нәрсә ишетүне өмет иткән иде. Иң элек ул аның үзе турында, үзенең ни өчен күзгә-башка күренмәве турында сөйләвен көткән иде, һәм Исламның, шундый зур, катлаулы һәм серле сорауга җавап бирмичә, сүзне бөтенләй икенче яктан башлавы аңа шактый гаҗәп тоелды.

— Акчаң бармы соң?— диде Ислам, салкын гына, ниндидер чит кеше белән сөйләшкән шикелле.

Мәрьям башын күтәрде, әле генә ишеткән сүзләрне яңадан ишетмәкче булып, кинәт тынып калды. Караңгы һавада күзгә күренмәгән черкиләр безелдәде, якында гына һава ярып ниндидер кошлар очып китте һәм калкулык өстендәге чатырлар ягында әүвәлгечә өзек-өзек тавышлар ишетелеп торды.

Җан өшеткеч сүзләр башка әйтелмәде. Бу турыда бу рәвешчә сөйләшермен дип, Мәрьям башына да китереп карамаган иде. Бу, аныңча, үзеннән-үзе аңлашылачак иде һәм Ислам да ул турыда төпченеп, сүз озайтып тормас шикелле тоелган иде. Ул бары аны юатыр шикелле булып, бернәрсә турында да кайгырма, барын да үзем җайлармын дип әйтер шикелле булып тоелган иде.

Ләкин менә бер дә алай булмады. Ул әнә сорады. Бар нәрсәдән элек шул турыда сорады. Ул шундый куркыныч итеп сорады! Курка икән, кирәкми, бер тиене кирәкми. Әллә ул шуның өчен килгәнме? Шуның өчен генә килгәнме әллә ул? Нәрсә булды соң әле бу? Ник әйтте ул аңа?!

Әле генә әйтелгән сүзләрне һәм шул сүзләрнең авыр тәэсирен онытмакчы булып, ул, кисәк кенә:

— Кара, нишләп монда утырабыз соң әле без, Ислам?— диде.— Әйдә безгә! Әйдә, җаным! Нинди эш соң бу? Син бөтенләй үзгәргәнсең, Ислам. Нинди эш соң бу, Ходаем? Мин курка башладым, Ислам, мин шикләнә башладым! Ни булды сиңа? Әйдә хәзер үк үзебезгә!

Ислам эндәшмәде. Мәрьям аны әле һаман акча турында борчыла дип уйлады һәм аның күңелсез уйларын таратмакчы булып, ялганлап:

— Миңа акча кирәкми, Ислам!— диде.— Мин инде барысын да җайладым. Рәйханә апа бирә. Кассада аның биш мең акчасы бар.

Исламга бу чыннан да тәэсир иткәндәй булды. Аның йөзгә бәреп торган салкынлыгы күз алдында кими төште.

— Кирәк булса да бирә алмасыем,— диде ул бераздан.— Биргән чакта үзең алмадың. Булган бар акчаны бригадирга бирдем. Мотоцикл алганда бурычка баткан булган.

— Әйтәм бит, кирәкми миңа!— диде Мәрьям, бөтен тәне белән калтыранып.— Мин бит аның өчен килмәдем. Мин сине алырга килдем, Ислам!

Ислам тагын эндәшмәде. Аның хәзер тавыш-тынсыз гына Мәрьямне озатып җибәрәсе килде. Шул ук вакытта Мәрьямне исән-имин генә озату да бик үк җиңел булмаячак иде. Ләкин аны барыбер озатырга кирәк иде, аның белән араны тәмам өзәргә кирәк иде.

Ул тәмәке төпчеген читкә ташлады да ике кулына таянып, аякларына басты һәм һәрбер сүзен аермачык итеп, чүкеч белән сандалга суккан сыман нык итеп:

— Менә нәрсә,— диде,— мин сиңа әйтә килдем, тыңламадың. Хәзер инде соң. Үзеңә үпкәлә. И бел: моннан соң минем янга килеп йөрисе булма. Безнең арада алышбиреш тәмам. Бөтенләйгә! Мәңгегә!

Соңгы сүз итеп ул, хуш, диде һәм, артына борылып та карамыйча, калкулык өстенә менеп китте.

Мәрьям берни аңламады, аңлый да алмады.

Исенә килеп ул кинәт урыныннан торды, күкрәктән, йөрәк түреннән чыккан иң ачы, иң әрнүле бер тавыш белән:

— Ислам!— дип кычкырып җибәрде.

Ул кычкырып кына да калмады, ул чабарга тотынды, куарга тотынды. Ләкин бу аның үзенә генә шулай тоелды, чынында ул аякларын да күтәрә алмады. Ике-өч адым атлагач та, ул сөрлегеп китте, кулы белән җиргә таянды. Кулына ниндидер каты үлән сабагы кадалгандай булды. Ул торды, аякларына басты һәм тыны бетеп, еламсырап:

— Ислам... Ислам!— диде һәм яңадан хәлсезләнеп җиргә егылды.

## VI

Кайчагында шулай куркыныч төшләр күрәсең: ниндидер текә, биек ярдан егылып төшәсең, суга батасың, йә булмаса, караңгы базда, тау-таш арасында торып каласың. Кот алынудан йөрәгең кысыла, чәчләрең үрә тора, үз-үзеңне кызганып, үз язмышыңны каһәрләп синең елыйсың килә, бөтен дөньяны тетрәндерерлек итеп кычкырасың килә. Әмма син кычкыра да алмыйсың, кымшана да алмыйсың.

Кайчагында аннан да куркынычрак нәрсәләр күренергә мөмкин. Ләкин, ни генә булмасын, кайчан да булса син барыбер уянып китәсең, үзеңнең исәнлегеңне аңлыйсың, һәм шул чагында син, чын-чынлап үлемнән котылган кебек, искиткеч бер шатлык-куаныч кичерәсең.

Нәкъ шундый куркыныч төшләрдәге кебек, Мәрьям дә ниндидер упкын төбенә ташлангандай булды. Җир өсте, караңгы күк гөмбәзе, бөтен тирә-як кинәт гадәттәге урыныннан купты, баш-аяк килде. Ләкин җирнең, күкнең буталуы да, шул буталчык эчендә аның каядыр ыргытылуы да бик әз вакыт дәвам итте. Шуннан соң ул каядыр юк булды. Ул үзенең кая төшкәнлеген дә, төшкәнме, әллә төшеп кенә барамы икәнлеген дә, хәтта үзенең исәнме, түгелме икәнлеген дә аера алмады. Тик шулай да кайдадыр еракта нәрсәдер өздереп, ачыттырып сызлаган шикелле булды.

Бу сызлау-авырту бераздан якыная башлады, көчәя башлады, һәм ул, исе китеп, аның — бу сызлау-авыртуның — бер дә әллә кайда булмыйча, үзендә, үз тәнендә, үз күкрәгендә булуын аңлады. Шуны аңлау белән бер үк

вакытта зиһенендә, ярый әле төш кенә икән! дигән бер кыргый шатлык чаткысы ялтырап китте.

Авырту көчәйгәннән-көчәйде. Әкренләп-әкренләп ул үзенең кулларын, гәүдәсен, аякларын тоя башлады, үзенең кайда, ничек ятканлыгын шәйләп алды. Ул, терсәгенә таянып, башын күтәрде, җайлап җиргә утыргандай итте. Шул чакны ул югарыда эленеп торган кара болытларны, болытлар арасындагы аксыл күк китеген күрде, чекрәешеп җемелдәшкән йолдызларны күрде һәм күкнең дә, җирнең дә урыннарыннан купмауларына, күк гөмбәзенең исә шундый нык булып, зур булып баш өстендә капланып торуына шаккатты.

Ул сикереп торды, аякларына басты һәм исерек кеше кебек чайкала-чайкала, шулай да усал, тәвәккәл адымнар белән кузгалып китте.

Ул калкулык астыннан китте, биек үләннәр белән, чәнечкеле вак-вак куаклар һәм түмгәкләр белән, чокыр-чакырлар белән капланган үзән буенча китте. Көктугайга ул турыдан гына кайтмакчы булды. Ул өскә, тигез юлга менмәде, менә алмады. Аның өчен хәзер юл бикле иде, юл хәзер сөзәк калкулык өстендә генә түгел, юл хәзер күкләргә терәлгән биек, текә кыя өстенә күтәрелгән иде. Анда икенче дөнья иде; дингә ышанучы кешеләр вәгъдә иткән тәмуглы, оҗмахлы теге дөньяга шушы килеш, тере килеш күчеп булмаган кебек, ул текә кыя артына да инде болай гына күчеп булмый иде, кыя өстендәге юлдан да инде җиңел генә китеп булмый иде.

Ул астан китте, үз юлы белән китте. Аның өчен хәзер ни булса да барыбер иде, аның өчен хәзер бөтен нәрсә болганчык бер томан, караңгылык иде, һәм күкрәктәге ниндидер бик газиз, бик якын бернәрсәне кысып, әрнетеп торган җәрәхәттән башка аермачык бернәрсә дә юк иде. Итәккә эләгә торган, оекларны ертып, балтыр итен тырный торган каты куаклар да, атлаган саен абындыра торган түмгәкләр дә, чокыр-чакырлар да юк иде; колакка, күзләргә тула торган агулы черкиләр дә, кулны кисә торган үткер камышлар да юк иде; якынлашып килгән кеше исен сизеп, Иртыш ягына качып барганерткыч бүре дә, түмгәк арасында посып калган усал-куркак төлкеләр дә юк иде.

Ул барды да барды. Аны аяклары түгел, бәлки, әлеге шул әрнү-сызлау тойгысы, җәрәхәт тойгысы һәм беренче мәртәбә баш калкыткан ярсулы горурлык тойгысы алып барды. Егылуы, упкынга тәгәрәп төшүе аркасында ул югары күтәрелде, беркем буе җитмәслек, беркем кагыла алмаслык болытларга кадәр күтәрелде. Ләкин аның

әле моның белән генә дә канәгатьләнәсе килмәде, ул һаман биеккә, югарыга качты. Аның йолдызларга җитәсе килде, аннан да арырак күтәреләсе килде. Ул аннан качты, андагы түбәнлектән һәм үзенең үткәненнән качты. Ул курыкмады, үкенмәде, әрнемәде. Ул үзен хәтта җиңүче итеп сизде, бәхетле итеп сизде, бернинди вакчыллык, бернинди пычраклык җитә алмаслык илаһи бер биеклектә итеп сизде һәм кайчандыр үзен җәберсетә алган вак, пычрак нәрсәләрдән каһкаһә берлән көлеп, якты, чиста биеклектән бар дөньяга, дөньядагы барлык ыбыр-чыбырларга мыскыл һәм җирәнү уклары тондырды.

## VII

Ул кая барганлыгын да, ни өчен барганлыгын да исәпләп тормады. Ул үзенең бары тик каядыр барып җитәргә тиешлелеген генә шәйли алды. Аның күңеленә мең төрле, миллион төрле уйлар килде, ләкин ул уйларның берсе дә үсмәде, зураймады һәм бары тик очкын булып, чаткы булып елтырап-елтырап кына киттеләр дә, бер-берсенә орынып, бер-берсен яндырып шундук юкка да чыктылар. Меңәрләгән уй чаткылары арасында акылдан шашаммы әллә? дигән берсе кинәт гөлт итеп кабынып китте, аның бөтен зиһенен балкытты. Шашасың! Шашасың, диделәр чаткылар, шатланып, күз алдында биешеп.

Ул әйтерсең чыннан да акылдан шашты. Ул тагын кисәк кенә ниндидер чокырга, ниндидер караңгы базга төшеп китте. Бу тагын да нәкъ төштәге кебек булды. Төштәге кебек ул кычкыра да алмады, ни дә булса уйлый да алмады. Сул аягы искәрмәстән ниндидер бушлыкка туры килде, уң аягы исә, бот төбеннән каерылып, нәрсәгәдер эләгеп тоткарланган кебек булды.

Шул ук вакытта уттай янган бите, маңгае ниндидер каты, салкын нәрсәгә, ниндидер очлы-кырлы нәрсәгә бәрелде.

Далада ташландык коелар гадәти нәрсә. Алар бигрәк тә кипкән күл буйларында, үзәнлекләрдә очрыйлар. Аларның кайберләрен хуҗалары тирес, чүп-чар белән күмеп китәләр яисә, вакыт узу белән, ул үзеннән-үзе саега, күмелеп бетә. Ләкин аларның күмелми калганнары да булырга мөмкин. Караңгыда Мәрьям әнә шундый ташландык коега барып төште.

Озак кына онытылып ятканнан соң, ул айнып китте. «Өнемме, төшемме?»— дип уйлады ул, коты алынып. Кулын кыймылдаткан иде, кулы каты, салкын ташка

бәрелде. Аркасына да шундый ук каты, салкын ташлар тиеп тора шикелле тоелды. «Нәрсә бу?»— диде ул үзүзенә. Аның бөтен тәне буенча чиркәнчек йөгерде, маңгаена салкын тир бәреп чыкты, һәм ул, тыела алмыйча, дер-дер калтыранырга тотынды.

Билгеле бер тәртипкә килә башлаган зиһенен утлы кылыч белән ярып, тирәнме бу кое? дигән бер уй ялтырап китте. Авыр башын күтәреп ул югары карады. Читчитләре үлән сабаклары белән капланган түгәрәк ачыклыкта ул тагын да баягы кебек кара болытлар күрде, кара болытлар арасындагы аксыл күк китеген һәм күк китегендә чекрәеп җемелдәшкән бөртек-бөртек йолдызлар күрде. Кое бик үк тирән түгел сыман иде. Ул әле бүген төш вакытында гына су алырга барган коены исенә төшерде. Ул коеның тирәнлеге, күп булса, ике-өч метр чамасы булырга тиеш иде. Суны аннан чыгыр белән яисә сиртмә белән тартып алмыйсың, кырыйдан чыгып торган эре ташларга басасың да аска төшәсең, елгадагы шикелле, чүмечеңне чумдырып аласың.

Ул шундук сикереп тормакчы булды. Ләкин урыныннан әз генә кузгалгандай иткәч тә, башы әйләнеп, кире егылырга мәҗбүр булды. Уң аягын кыймылдатырлык та түгел иде. Аннары аякларында ул ниндидер юешлек тойды. «Әллә суы да бармы соң моның?»— дип уйлады ул һәм куллары белән тирә-ягын капшап карагандай итте. Ләкин куллары коры чүп-чардан башка, каты ташлардан башка бүтән бернигә дә тимәде. «Тирләгәнгә күрә шулай микәнни?»— диде ул аннары, гаҗәпләнеп.

Аны кинәт үз-үзеннән, үзе утырган ниндидер чүпчардан, шакшы тирес-тизәктән җирәнү һәм акылдан язар дәрәҗәдә чиркәнү тойгысы биләп алды. Бу җирәнүчиркәнү тойгысы андагы өскә-югарыга омтылу, чиста, саф җиргә омтылу теләген һәм күкрәктәге, беләктәге көчкуәтне кисәк кенә арттырып җибәргәндәй булды.

Баш өстендәге түгәрәк ачыклыкны гына, саф һаваны гына күз алдында тотып, көчәнеп, киерелеп, ул яңадан кузгалып карады. Монысында инде ул сул аягына гына басты. Башы тагын әйләнеп китте. Ул чак-чак кына артына авып төшмәде, ләкин куллары белән таш стенага тотынып калды. Ташлы стенага күкрәге белән сөялеп, ул беркадәр вакыт хәл җыеп торды. Шуннан соң бер кулы белән як-ягын капшап карады. Стена текә иде, ташлар тигез өелгән иде.

Ничек чыгарга моннан? Ничек?! Ике аягы да исән булса, аякларын аерып баса-баса, куллары белән тотынатотына, ул бик җиңел генә чыккан булыр иде. Ләкин ул

бер генә аяклы. Җитмәсә, кое да киң. Бер як стенасыннан икенче як стенасына кулыңны сузсаң, кул җитәрлек түгел. Нишләргә, ничек чыгарга? Кычкырыргамы әллә? Ләкин кем ишетсен аны монда? Бүреләр, төлкеләр?.. Нәрсә, мәңгегә шушында торып калыргамыни?

Юк, чыгарга, чыгарга! Ничек кенә булса да чыгарга... чыгарга...

Колак төбендә әллә һаман черкиләр безелдәде, әллә шулай бертуктаусыз колагы шаулады... Өстә, югарыда, ирекле җил исеп китте, кое авызына капланып утырган куе үләннәр кызганыч, бик кызганыч итеп шыштырдап алдылар. Кара болытлар арасыннан кызганыч, бик кызганыч итеп, энҗедәй күз яшьләрен түгеп, йолдызлар җемелдәште. Күз алдына бала вакыты килде, ваемсыз, шат бала вакыты килде. Йолдызлы төннәр, шау-шулы Казан урамнары, кояш нурында балкыган комлы Идел буйлары килде. Аннары күбәләктәй кыз чаклары... Ислам...

Ул аны исенә төшерде, яратып, кызганып түгел, бәлки, моңарчы булган яратуы дәрәҗәсеннән йөз мәртәбә, мең мәртәбә көчлерәк җирәнү белән, ярсу-нәфрәт белән исенә төшерде. Үзенең барлык газапларын, үзенең шушында, әзер кабергә килеп эләгүен, үзенең менә озакламый тынсыз-өнсез, хәрәкәтсез калачагын ул бары аннан гына күрде; монда бары аны гына гаепләде һәм күңеленнән аны хәзер үз куллары белән буып, ботарлап ташлардай булды.

Ул яңадан аягына басты. Нишләптер хәзер аңа уң аягы баягыча ук авыртмый шикелле тоелды. Аякларын аерып баскан килеш, бөтен авырлыгы белән кое стенасына терәлеп азапланган арада, аның сул ягына, кое төбенә өстән авыр гына бер таш килеп төште. Чак-чак кына таш аның аягына тиеп китте, ләкин авырттырмады. Үләргә һәм дөньядагы барлык нәрсә белән хушлашырга ниятләгән адәм күңелендә кинәт өмет чаткысы балкып китте. Кулын сузып ул таш кубып төшкән урынны капшап карады.

Шул чакны ул кое читенә өелгән ташларның үзе уйлаганча бер-берсенә бик үк берекмәгәнлекләрен һәм бераз гына көч куйганда, аларны урыннарыннан куптарып төшерергә мөмкин икәнлеген аңлап алды. Ул әле генә кубып төшкән таш янындагы икенче ташны кузгатып карады — таш җиңел генә кубып чыкты һәм дөпелдәп янә кое төбенә тәгәрәде.

Кое ташын ул бер-бер артлы куптара торды, ташлар, шакылдап-шапылдап, төпкә төшә тордылар. Кое төбе

шактый югары күтәрелде. Ул, ташлар өстенә басып, киңәеп калган түгәрәк ачыклыкка якынлашты һәм берзаман, бөтенләй көтмәгәндә диярлек, өстәге каты үләннәргә тотынып алды. Күкрәге белән шуышып, көчәнеп, тартышып җир өстенә килеп чыкты да шундук чыклы үлән арасына ауды.

Ул шәһәр кызы иде. Хәлле генә ата-ана кызы иде. Тормышта әле аның телгә алырлык кайгы-хәсрәт тә, мохтаҗлык та татыганы юк иде, һәм шулай ук күңелендә тирән эз булып калырлык нинди дә булса фаҗига дә кичергәне юк иде. Ул бик йомшак табигатьле, килешүчән, күндәм холыклы иде. Үз гомерендә аның беркемгә дә каты орынганы да, беркемгә дә кул күтәргәне дә юк иде, һәм үзендә ул ихтыяр көченең барлыгын-юклыгын да белми иде.

Аның өчен бу беренче сынау булды, һич тә уйламаган, һич тә башка китермәгән авыр сынау булды, үлем белән тиңдәшсез бер тартыш-сугыш булды. Ул җиңеп чыкты. Ул искиткеч батырлык эшләде, адәм баласының көндәлек тормышында бик еш булып тора торган, ләкин беркайчан да металл тәңкә бәясенә бәяләнми торган, данлы исем алмый торган батырлык эшләде. Ул үлемне җиңде. Ә дөньяда тагын шуннан башка, шуннан бөек нинди каһарманлык була ала?

Салкын үлән арасында ята торгач, саф һаваны сулый торгач, аңа хәл кергәндәй булды. Ул күзләрен ачты, якягына каранды. Бик үк ерак булмаган бер җирдә караеп сөзәк яр күренде, яр өстендә йортлар һәм тоныкк кына җемелдәшкән утлар күренде. Якында гына Көктугай утыра иде.

...Бер ярты сәгатьтән, таң алдында, ярым үлек Мәрьямне машина белән район больницасына алып киттеләр.

## VIII

Икенче бригадада саман сугу эше тиз генә җайланып китә алмады. Баштарак һәркемгә кирәк, калып ише нәрсәләр җитмәде. Эш кораллары булмаган кешеләр карап тору белән генә канәгатьләнергә мәҗбүр булдылар. Менә көрәге дә җитте, калыбы да җитте. Ләкин көтмәгәндә икенче төрле каршылыклар килеп чыкты. Барыннан да бигрәк, су җиткереп булмады. Бензовоз алып килгән су, чокырга агызгач та, коры туфракка сеңде дә бетте. Бензовоз ашыгып яңадан күлгә чапты. Кешеләрнең күңелләре төште, һәркем үртәлә, тынычсызлана башлады.

— Кирәге юк саманның! Бетсен саман!— дип кычкырды Белугин, көрәген җиргә атып.

Бензовоз тагын килде, тагын чокырга су агызырга керештеләр. Егетләр, ашыгып-кызулап, балчык изәргә керештеләр, балчыкны су белән, тирес белән буташтыра башладылар. Монысында су тиз генә агып бетмәде. Ләкин кирпеч өчен яраклы балчык ясарга барыбер өлгерми калдылар. Эш яңадан тукталды.

Кирпеч сугу өчен яраклы балчык бары кичкә таба гына өлгерде. Барысы да, дәррәү кубып, калыпларына тотындылар, сыек-үзле балчыкны тишекле калыпларына тутырдылар да читкә алып китеп каплый башладылар. Такыр җир өстендә беренче кирпечләр ятып калды. Ләкин, кызганычка каршы, кирпечләрнең берсе дә рәтле булмады: кайберләре калыптан төшкәч тә як-якка таралып, җәелеп китте, кайберсенең йә чите китек булды, йә урта бер җире куышланып калды, һәм барысы да диярлек начар булып, гарип-гораба булып чыкты.

Бөтен бригада өчен әзерләнгән бик зур чокырдагы балчыкны караңгы төшкәндә генә ташып бетерделәр. Барысы да арып-алҗып һәм соң дәрәҗәдә үртәлеп йокыга яттылар.

Икенче көнне тагын шуңа тотындылар. Монысында инде бөтен бригада бер булып түгел, бәлки ике төркемгә бүленеп эшләргә булдылар. Икегә бүленгәч, чокырны кечерәк, җыйнаграк итеп ясадылар. Беренче көндәгегә караганда эш бүген яхшырак барды. Шулай да су мәсьәләсе тулысынча хәл ителмәде, киресенчә, беренчелек өчен хәтта бераз тарткалаш та булып алды. Берәүләр әйтте, суны иң әүвәл без агызабыз, без иртәрәк тотындык, диделәр; икенчеләре әйтте, безнең чокыр тизрәк өлгерде — су безгә тиеш, диделәр. Суны бензовоз юл өстендәге беренче чокырга агызды да яңадан күлгә чапты һәм, ике төркемне дә канәгатьләндерә алмыйча, күл белән ике арада тыз-быз чабып тик йөрде.

Көн дә болай эшләргә туры килсә, әлбәттә, әллә ни алга китеп булмаячак иде. Монда нәрсәдер уйларга, нәрсәнедер яңача корып җибәрергә кирәк иде.

Һәм Барый уйлады, баш ватты, анысын-монысын исәпләп, чамалап карады. Төштән соң ул кулына көрәк тотты да күл буена китеп барды. Саманны суга тагын да якынрак китерергә кирәк иде, нәкъ Камыскүлдәге кебек эшләргә кирәк иде. Эшләр бары шул чагында гына җайланып китәргә мөмкин иде.

Бензовоз су ала торган күл тирәсен камышлык каплап алганга, ярга якын җирдә бернинди калкулык та,

кызыл балчыклы урын да юк иде. Ләкин күлдән беркадәр читтәрәк, ниндидер коры елга ярында түмгәксезнисез тигез җир бар иде. Барый шул тигез җирне казып карады. Кызыл балчык монда бик якында ята иде.

Саман сугуны бригадир шунда күчерергә дигән карарга килде. Ләкин шул турыда бригадага кайтып әйткәч, күпчелек моңа риза булмады. Анда черки талап үтерер, диделәр; монда инде ияләштек, күченмик, диделәр. Барый үзе бөтенләй күчену мәсьәләсен куймады, торуын шушында торырбыз, кирпеч сугарга көн дә барып йөрербез, диде.

— Нәрсә, этме әллә без шулкадәр җиргә сөйрәлеп йөрергә!— диде Ислам, бригадирга кычкырып.

Бу әле аның саманга күчкәннән бирле беренче мәртәбә тавыш күтәрүе иде. Фәридәгә өйләнгәч, ул кисәк кенә басылып калган иде.

— Ярый, алайса,— диде Барый, аның кычкыруына игътибар итмичә,— кемнәр күл буена барып эшләргә риза, шулар күл буена китәр, кемнәр монда калырга тели — монда эшләр. Үзегез күреп торасыз, бер җирдә өелешеп ятып без берни кыра алмыйбыз.

— Шулай, Барый туган,— диде Галимулла, аның белән килешеп.— Кеше китмәсә китмәс, үзем китәм. Эшмени бу? Бер чокырга унлап кеше тыгылып ят, имеш! Эшләгәне эшли, эшләмәгәне тик тора. Баш белән уйлап караганда, Барый туган, һәркем үзенә аерым чокыр казырга тиеш, һәркем үзенә балчык ясарга, үзенә кирпеч сугарга тиеш. Үгез дә кирәкми, чурт та! Балчык измәгән кешеме әллә без!

— Сүзең дөрес, Галимулла абзый,— диде Барый.— Насос бар, эчәк бар, хәзер үк складтан алып киләбез дә көйләп җибәрәбез.

— Теләсәгез нишләгез, мин беркая бармыйм,— диде Ислам, киреләнеп.

— Мин әйттем: теләгән кеше монда кала!— диде бригадир.

— Без дә күл буена китәбез,— диде Андронов.

— Мин дә!

— Без дә!— диештеләр тагын берничә кеше.

Шулай итеп, бригада икегә бүленде. Мондый бүленү соңыннан бригадирның эчен тырнап куйды. Болай да җаена төшенмәгән эш, болай да буталчык, таркау эш аңа аерылгач тагын да ныграк буталыр, тагын да ныграк таркалыр шикелле тоелды. Күчену турында сүз кузгатуы өчен ул хәтта үкенеп куйды.

Әмма бүленеп эшләү көткәнгә караганда да яхшырак

нәтиҗә бирде. Бернинди таркалу, башбаштаклык сизелмәде, тик хәзер эшкә бер үк вакытта чыгу, бер үк вакытта эштән туктау тәртибе генә үзгәрде. Эшкә кем кайчан өлгерә, шунда чыкты һәм кайчан үз нормасын үти, кайчан хәлдән таеп арый, шул чагында гына «өйгә» кайтты. Болай караганда бу тәртипсезлек булды, ләкин яңа эш шартларында бу бик яхшы тәртип булды. Аннары кешеләр хәзер икешәр, өчәр кешелек кечкенә төркемнәргә бүленделәр; һәрбер төркем үзенә кечерәк кенә аерым чокыр казыды, аерым балчык ясады һәм кирпечне дә аерым сукты, һәркем үзе өчен эшләде. Иптәше белән эшләде. Эш күзгә күренеп алга китте.

## IX

Барыйның бөтен вакыты әле алай итеп, әле болай итеп узды, тегесен-монысын җайлап, анда чабып, монда чабып узды. Берникадәр кеше күл буенда эшли башлагач, ул ике араны таптарга тотынды. Киңәште, орышты, кулыннан килгәнчә ярдәм итте яисә, теге-бу нәрсә кирәк булып, шундук Көктугайга китеп барды. Шушы дүртбиш көн эчендә ул саманнан башка, су, тирес, балчыктан башка берни турында да уйлый алмады.

Шулай бер матур иртәне, киенеп тышка чыгарга торганда, аның бүлмәсенә Тәзкирә килеп керде. Үз-үзен гадәттәгечә иркен-кыю тотарга тырышып, шулай да эчке бер каушау һәм киеренкелек белән, тотлыгыбрак, ул:

— Карале, Барый җаным... иптәш бригадир,— диде.— Сиңа әйтәсе сүзем барые әле минем...

— Әйтеп кара,— диде Барый.

— Бригаттан китәргә җөрим бит әле мин, Барый җаным.

— Китәргә? Кая?

— Кая дип... Җырак түгел инде ул түгелен, Көктугайга гына.

Аның «бригаттан» китүенә Барый һич тә каршы түгел иде, киресенчә, ул моңа сөенеп кенә калачак иде. Ләкин аның китүенен күреп, бүтәннәр дә шул турыда уйлый башламаслармы? Бит әле Һарун кайтып киткәч тә шактый ризасызлык булып алды. Шулай ук Вәгыйзь белән Илгизнең комбайнчылар курсына китүләре дә күпләрнең күңелен кузгатып куйды. Нәрсә, шулай таралышып бетәргәмени?

— Ник?— диде ул.— Саман туйдырдымыни? Булмый, беркая китмисең!

— Кибеткә сатучы итеп алырга итәләр, Барый җа-

ным,— диде Тәзкирә, никтер ихахайлап.— Галимов абый белән сөйләштем, Игер Әндрич белән дә...

— Кайсы кибеткә? Кем урынына?— диде Барый, гаҗәпләнеп.

— Мәрьям урынына. Аның бит бик күп өстенә чыккан. Кайгысыннан, бичара, авыруга сабышкан, ди...

— Авыруга сабышкан?! Нәрсә юкны лыгырдыйсың?

— Ыы, авыруга сабышкан, бүлнискә салганнар, Барый җаным,— диде Тәзкирә, артына чигенә-чигенә.

— Кайчан, күптәнме?

— Ике-өч көн бар инде. Хәле бик авыр, ди, бичараның. Үлмә хәлдә ята, ди.

— Ни булган, ни булган?!— диде Барый, ашыгып, агарынып.

— Белмәссең инде, Барый җаным,— диде Тәзкирә, кайгырган, пошынган булып.— Берсе әйтә, коега ташланган икән, ди... Өч мең тәңкә өчен коега ташланып торырга да инде! Икенчесе әйтә, йөрәге начар икән, ди... Монда әле аның ташланырлык рәтле-башлы коесы да юк, Барый җаным.

— Кайда ята — районнамы, шәһәрдәме?

— Раюн бүлнисендә, ди. Бигрәк инде төпченгән буласың да төпченгән буласың. Әллә бер-бер хәл бармы соң арагызда?— дигән булды Тәзкирә, янә хихылдап.

— Төпченмичә! Кеше анда үләргә ятсын!

— Ничегрәк соң, Барый җаным? Галимов абый бүген үк килергә кушканые...— диде Тәзкирә, үз мәсьәләсенә кире кайтып.

— Бүген беркая китмисең. Кирпеч сук, норманы тутыр,— диде Барый.— Соңыннан сөйләшербез.

Ул бүген үзе дә бүтәннәр кебек кирпеч сугарга чыкмакчы булган иде. Ләкин Тәзкирәнең шомлы хәбәре аның бу ниятен онытырга мәҗбүр итте. Ревизия булу сәбәпле, кибетнең ябылып торуын белсә дә, ул әле Мәрьям турында берни белми иде.

Тәзкирә белән ул артык сөйләшеп тормады, өстеннән эш киемнәрен салып ташлады да, икенче киемнәрен киде, вагон янында торган мотоциклына атланып, район үзәгенә чапты.

## X

«Үлмә хәлендә ята, үлмә хәлендә ята!»— диде ул, Тәзкирәнең сүзләрен кабатлап. Тәзкирә сөйләгәннәрдән бары шулар гына аның хәтеренә сеңеп калды һәм бөтен уйфикере, бөтен хис-тойгылары бары шул тирәдә генә чуал-

ды. Мәрьям хәзер аңа үлгәндер шикелле булып, яисә үлеп ятадыр шикелле булып тоелды. Ул бөтен күңеле белән шунда — аның янына омтылды. Ул соңга калудан, аны күрмичә, аның белән сөйләшмичә калудан курыкты.

Сул яктан Иртыш буе урманнары йөгереп барды, уң яктан иксез-чиксез дала шуышты, һәм каршыда берән-сәрән сыер, сарык көтүләре, атлылар, машиналар күренеп-күренеп калды.

Илле-алтмыш чакрым араны ул әллә утыз минутта, әллә егерме минутта узды. Бу егерме-утыз минут вакыт аңа бөтен бер гомер булып тоелды. Менә, ниһаять, алда кара күмер төтене ургытып утырган озын морҗа күренде, морҗадан соң очлы башлы агач йортлар күренде. Кара, озын морҗа тиз арада якынлашты, зурайды, һәм морҗадан чыгып җир өстенә таралган сасы төтен исе Барыйның борынына килеп бәрелде.

Район үзәге булып исәпләнгән зур гына авылга килеп кергәч, ул тизлекне әкренәйтә төште. Больницаның кайда урнашканын ул белә иде, шуңа күрә, бер җирдә дә тукталып тормастан, олы урам уртасыннан узып китте дә авылның икенче башына барып чыкты һәм Иртыш буендарак, читтәрәк утырган иске генә озынча бер агач йорт каршысына килеп туктады.

Тышкы ягы сыланган, агартылган бу иске йорт урам яктан коймалап алынган иде. Койма такталарына, баганаларга, һәрбер район больницасы алдында булганча, авылдан килүчеләр атларын бәйләп куйганнар иде.

Барый маңгаендагы күзлеген күтәреп куйды һәм, еракtан ук дару исе аңкытып торган, бөтен тәрәзәләренә ак марля эленгән йортка керергә һич тә ашыкмыйча, өстен-башын кагынырга тотынды. Аның кинәт тәвәккәллеге дә кимеде, дәрте дә сүнгәндәй булды. «Нәрсә әйтергә соң аңа? Ник килдем дияргә?»— диде ул үз-үзенә, аптырап.

Шулай да хәзер инде баш ватып торыр вакыт түгел иде. «Ярар, ни булса да булыр»,— диде дә, нык кына басып, ишегалга кереп китте — больницага керә торган ишек шул яктан иде.

Көтмәгәндә ул Рәйханә апа белән очрашты. Рәйханә апа аксыл клеенка белән тышланган ишектән чыгып килә иде. Барый туктап калды. Рәйханә апа да туктады. Бер-берсенә карашып алдылар да, бер-берсен танып, икесе дә берьюлы диярлек, исәнмесез, диделәр.

— Ни булды, иптәш Рамазанов, әллә чирләп киттегез?— диде Рәйханә апа.

— Юк, үзем түгел,— диде Барый.

— Кем? Сезнекеләрдән монда беркем дә юк шикел-

ле...— диде Рәйханә апа, исенә төшерергә тырышып.— Таран янынамыни?

— Таран?— диде Барый, кашларын җыерып.— Безнең бригадада Таран юк. Булган... хәзер юк.

— Чыннан да!— диде Рәйханә апа, үзенең хәтерсезлегеннән көлеп.— Монда ята бит ул... Эчке аркасында...

— Миңа икенче кеше кирәк иде,— диде Барый.

— Ә-ә!— диде Рәйханә апа.— Мәрьямме әллә?

— Ул мондамы? Күрдегезме?— диде Барый, кызарынып.— Хәле ничек? Кертәләрме?

Рәйханә апа аңа Мәрьям турында сөйләп бирде, хәле начар түгел, диде, ләкин хәзергә әле беркемне дә кертмиләр, диде. Аңа хәзер, барыннан да бигрәк, тынычлык кирәк, диде.

Барыйга болай кисәк кенә борылып китү ничектер килешмәс шикелле тоелды. Ул, ни әйтергә белмичә, урынында таптанып торгандай итте дә, Рәйханә апа кузгалып киткәч, аның артыннан ияреrгә мәҗбүр булды. Бер чишелгәч, Мәрьям турында аның күбрәк, ныграк сораштырасы килде. Ни булган аңа, нишләгән, диде, өстенә чыгуы дөресме, диде. Рәйханә апа әйтте, дөрес, диде, өч мең дә ничә йөз өстенә чыккан, диде, шуны түләргә кушканнар икән дә, акчасы булмаган икән, диде.

— Бөтенләй түләмәгәнмени әле?— диде Барый.

— Кем түләсен аны?— диде Рәйханә апа.— Ревизия беткән көнне үк әнә бәлагә юлыккан. Караңгыда суга баргач, аягы таеп коега егылып төшкән. Бер килсә килә бит ул. Борчылган чагы булгандыр, карап җиткермәгәндер. Башы бәрелгән, кан киткән. Галимовка әйттем, ашыгыч булса, акча миндә дә бар, биреп торырмын, дидем.

— Акча миндә бар!— диде Барый, ашыгып.— Күпме? Өч мең? Мин сезгә бирермен... үзегезнең исемнән түләрсез. Булдымы?!

— Алай килешер микән?— дигән булды Рәйханә апа, көттеребрәк.

— Нинди килешмәгән инде ул тагын! Беркемгә дә әйтмәбез... үзенә бигрәк тә!

— Ярар, карап карарбыз,— диде Рәйханә апа.— Өч меңне каян алсын инде ул хәзер генә... шулай булышмагач та... Сату эшендә эшләгәне юк, тәҗрибә аз. Таяк янына нуль куярга оныттыңмы, менә шуннан китә эшләр! Өстеңә чыга, ялгышасың. Акча эше шундыйрак бит инде ул.

«Ник өстенә чыкканлыгын беләбез инде!»— дип уйлады Барый үзалдына. Шулай да ул Рәйханә апа белән сүз көрәштереп тормады, әйе, шулайрак шул, диде.

— Сез нәрсә белән килдегез?— диде ул аннары Рәйханә апага.— Әйдәгез, утыртып алып кайтам.

— Рәхмәт, минем әле монда йомышларым бар,— диде Рәйханә апа.

— Мин көтеп торырга да риза,— диде Барый.

— Юк, рәхмәт,— диде Рәйханә апа, көлеп.— Әллә төшеп калырмын кайтканда. Рәхмәт.

— Алайса, сау булыгыз,— диде Барый, мотоциклына атланып.— Бүген кич мин сезгә килермен.

## XI

Мотоцикл бик кызу чапты. Ул бригадага кайтып җиткәндә, кашлакта да, күл буенда да инде эш кызып киткән иде. Чокырлар су белән, изелгән балчык белән тулган, кайберәүләр баш калкытмый кирпеч сугалар, иртәрәк кузгалучылар исә балчыкны икенче мәртәбә изәргә тотынганнар иде.

Бригадирның каяндыр кайтып килүен күреп, елан Тәзкирә Ислам янына килде һәм әледән-әле Барый ягына караштыргалап, Исламга нәрсәдер пышылдарга тотынды. Ислам да кырын күзе белән бригадирга карап-карап алды, төкереп куйды һәм ашыгып шундук җир казырга кереште.

Мәрьямнең авырып больницага керүенә ул башта әз генә дә борчылмады да, вөҗдан газабы да кичермәде. Аның коега ташлануы турындагы сүзләргә ул һич тә шикләнеп карамады. Бригадирның мотоциклга атланып район үзәгенә барып кайтуы анда бер-берсенә капма-каршы уйлар тудырды. Көне буе ул күл ягыннан күзен алмады, уйланды, тәмәке тартты, янә күзәтергә тотынды.

Барый исә аның турында исенә дә кертеп чыгармады. Ул бер як читтә үзе генә азапланып яткан Мансур янына килде дә аңа сәлам бирде һәм бүтәннәр шикелле өстен-башын чишенеп ташлады.

— Үз әртиленә аласыңмы мине дә?— диде ул Мансурга.

— Соңга калып йөрисең, иптәш бригадир!— дигән булды Мансур, шелтәләп.

Алар шулай сөйләнгәләп, икесе дә чокыр эченә керделәр, әрле-бирле таптанып, балчык изделәр. Мансур, тәҗрибәлерәк саманчы буларак, Барыйга кайсы төшне ныграк таптарга, ничек таптарга кирәклеген әйтте, сыек ләпеккә әледән-әле тирес ташлады һәм кулындагы көрәге белән балчыкны бутап, аралаштырып алды.

Барый баш калкытмый эшләде. Төшкә хәтле алар

Мансур белән балчыкны ясап бетерделәр, төштән соң кирпеч суктылар. Ике таза кешегә бер чокыр балчык күпкә бармады, һәм озакламый чокыр төбе тап-такыр булып калды.

— Йөз җитмешәр булды!— диде Мансур, ак тешләрен елтыратып.

Кичкә кадәр әле вакыт бар иде. Алар тагын чокыр казыдылар, балчык изделәр. Шулай да икенче чокыр авыргарак туры килде. Кич караңгы төшәр алдыннан, алар күл буеннан иң соңгы кеше булып кузгалдылар.

Эшләми эшләгәнгә һәм беренче көнне үк бар көчен биреп эшләгәнгә, Барый ярыйсы гына арыды. Бөтен тәнендә ул рәхәт бер авырлык, изелгәнлек тойды. Шул ук вакытта үтереп тә ашыйсы килде. Бригада авылына кайтып кичке ашны ашагач исә шундук күзен йокы басты. Вакытның әле иртә булуына да карамастан, ул инде ятып йокларга да исәпләгән иде, ләкин шул чакны Рәйханә апага биргән вәгъдәсен хәтерләде. Район үзәгеннән кайтканда, ул бүген кассадан кереп өч мең ярым акча алган иде. Шул акчаның өч мең ике йөзен кесәсенә салды да җәяүләп кенә Көктугайга китеп барды.

Рәйханә апа өйдә иде. Барый биргән акчаны ул төргәге белән чемоданына салып куйды; рәхмәт, диде, беренче мәртәбә күргәч, мин сине бик алама кеше икән бу дип уйлаган идем, алай ук түгелсең икән әле, дип шаяртып та алган булды; аннары аны повидло белән чәй эчәргә чакырды. Барый кыстатып-нитеп тормады, ашар-эчәр рәте булмаса да, берсүзсез өстәл янына утырды. Чәй эчкән арада, ул иплән кенә, сакланып кына Мәрьям турында сүз кузгатып җибәрде. Рәйханә апа, шулай ук иплән кенә, сакланып кына, үзе белгән кайбер нәрсәләр турында сөйләде.

Алар шулай сөйләшеп чәй эчтеләр. Барый өстәлдәге сәгатькә күз төшереп алды да, рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалды.

Урамда ул Горшков белән очрашты. Игорь Андреич контордан чыгып килә иде. «Төнлә дә тынгы юк кешегә»,— дип уйлады ул директор турында.

— Каян болай?— диде Горшков, гаҗәпләнеп.

— Ни... монда бер танышым янында булдым,— диде Барый.

— Мин әле генә синең турыда уйладым,— диде Горшков, аның йөзенә, тавышына бөтенләй игътибар итмичә.— Әле генә Нурсәетов шалтыратты — Алма-Атага киңәшмәгә чакыралар.

— Алма-Атага? Кайчан?

— Иртәгә көндезге икедә анда булырга.

— Икедә!— диде Барый, сызгырып.

— Икедә шул менә!— диде директор, беркадәр ачыну белән.— Килеп кысылгач кына... вакыты җиткәч кенә...Ниндидер зур кешеләр булырга тиеш шикелле. Бер-ике бригадирны да алырга кушалар. Менә шул.

— Ә бригада?— диде Барый, аның тел төбен сизенеп.

— Вакытлыча берәрсен калдырып торырга туры килер,— диде Горшков.— Мәсәлән, Ислам Мусинны... Сездә бит эшләр җайланды?.. Ике-өч көнгә берни булмас.

— Җайлануын җайланды да...— диде Барый, икеләнеп.— Шулай да... Ярый, алайса! Була, Игорь Андреич!— диде ул аннары, хәрбиләрчә бер җитезлек белән.— Кайчан чыгабыз?

— Хәзер үк. Бер-ике сәгатьтән дә соңга калмыйча. Таң атканчы өлкә шәһәренә барып җитәргә кирәк. Алма-Атага самолет иртән оча. Сез хәзер әзерләнә торыгыз, юл уңаенда сугылып үтәрбез.

— Булды! Аңлашылды!— диде Барый. Бригадага кайткач, ул Исламны үз янына чакырып алды, мәсьәләне аңлатып бирде һәм, мөмкин кадәр дусларча булырга тырышып:

— Сиңа монда минем урынга калырга туры килер,— диде.

Аның кытыгына кагылмас өчен, ул «бригадир булып» димәде, ләкин шулай да Ислам җавап кайтарырга ашыкмады.

— Берни булмас бригадаңа,— диде ул, караңгы чырай белән.

— Булуын булмас, шулай да малай-шалайга күз-колак булып торган яхшы,— дигән булды Барый.

— Ярар, булырмын,— диде Ислам, көттереп, киң күңеллелек күрсәтеп.

Икенче көнне бригадада эш гадәттәге тәртип белән башланды, һәркем үз вакытында торды, үз вакытында эш урынына китте. Бригадирны беркем кирәксенмәде. Бары тик Мансур гына аның турында уйлаштырып алды һәм әледән-әле вагон ягына карап-карап куйды. Ул аны йоклап калгандыр дип уйлады. «Үз вакыты белән чыгар әле чыгасы килсә»,— диде үз-үзенә.

Төш вакытында шулай да кемдер «Барый абыйсын» юксынып куйды.

— Төнлә ул шәһәргә китте директор белән,— диде Ислам.— Типтерергә, күңел ачарга...

Үзенең вакытлыча баш булып калуы турында ул бер-

ни әйтмәде. Ул әйткән хәбәргә беркем дә артык гаҗәпләнү белдермәде, моңа барысы да гадәти бернәрсә итеп карадылар.

Ләкин шулай да бригадада баш кешенең юклыгын белү яшьләрдә үзеннән-үзе чишелү тойгысы тудырды. Төштән соң алар бераз гына селкенгәләп алдылар да, бер җиргә җыелып, юк-бар нәрсә турында гәп сатарга керешеп киттеләр. Алардан күрмәкче кызлар да эшләрен ташладылар. Тәзкирә бөтенләй күзгә-башка да күренмәде — бригадир юклыгын белгәч тә, шундук Көктугайга чапты. Бераздан кызулап, кызарынып ул кире кайтты, вагонда бераз гына югалып торды да тагын чыгып йөгерде. Төшке ашка кайткач исә, барысына да белдереп:

— Мин хәзер сезнең бригат кешесе түгел,— диде.— Хушыгыз, җанкисәкләрем! Апагыз хәзер сатучы булды.

— Болай булгач, аракыга кытлык бетә икән,— диде Белугин.

— Бетә, бетә!— диде Тәзкирә, куанычыннан уттай дөрләп.— Моннан соң инде миңа гына килерсез, җанкисәкләрем.

— Алдыңнан артың!

— Күптән кирәгие!— диештеләр башкалар.

## XII

Төштән соң Исламның никтер эче пошты. Бернәрсәгә күңеле ятмады, бернәрсәгә кулы бармады. Ул яртылаш тулы калыбын чокырга батырды да пычрак кулларын, аякларын юды. Аннары тынычланмакчы булып, тартырга кереште. Ләкин алай да йөрәгенә ял була алмады. Шуннан соң ул «кызык итеп» күл буена китеп барды. Аның әле анда бер генә мәртәбә дә булганы юк иде.

Ул китеп күп тә үтмәде, олы юлда шәһәр ягыннан кайтып килүче бер машина күренде. Машина, икенче бригада чатырлары турысына җитеп кырт кына борылды да, дала уртасыннан туп-туры «авылга» таба килә башлады. Буразнага килеп терәлгәч, ул, чик аша үтәргә кыймыйча, «ындыр артта» туктап калды. Кабинаның бер як ишегеннән шофер чыкты, икенче як ишегеннән кулына яшь бала күтәргән бер хатын чыкты.

Хатын аягын сузып җиргә басты, кулында йоклаган баласының битендәге яулыгын ачып карады, аннары башын күтәреп тирә-ягына: җир өстендәге чокыр-чакырларга, саман кирпеч өемнәренә һәм чокыр тирәсендә кайнашкан ярым шәрә егетләргә, кызларга күз йөртеп алды.

Өстенә ул тузанланып беткән искерәк кенә көрән сар-

жа плащ кигән иде. Төймәләре каптырылмаганга, плащ итәкләре як-якка кайтарылып, салынып тора иде. Ул бик чандыр иде. Аның нык кысылган ирен читләрендә, озак юл килгәнгә арыган, йончылган һәм эчкәрәк баткан сыман шикелле тоелган зәңгәр күзләрендә әчке бер сагыш һәм моңсулык сизелә иде.

Шофер, тәгәрмәчкә басып, кузовтан бер кечерәк кенә чемодан кисәге белән бер төргәк алды; әйберләрнең икесен дә җиргә — хатынның аягы янына куйды да кабинасына кереп утырды, шартлатып кабина ишеген япты һәм кузгалып та китте. Ят хатын, баласын күтәргән килеш, әйберләре янында торып калды.

— Безгә килгән ич бу!

— Кем икән?— диештеләр саманчылар. Хатын, буш кулына чемодан белән төргәген тотты да, әкрен генә, аватүнә генә атлап, сөрелгән җир аша чыкты, якындагы беренче чокыр янында туктап, әйберләрен җиргә куйды һәм сытык бер чырай белән:

— Шушымыни инде силина?— диде.

— Шушы инде, шушы!— диде күрше чокырдагы Кәрам, барысына караганда да җитезлек күрсәтеп.

— Бу икенче бригадамы?— диде хатын, Рәшидә белән Зәкиянең пычранып беткән аяк-кулларын күзәтештереп.

— Икенче бригада,— диде Зәкия.— Сезгә кем кирәк соң?

— Миңа Мусин Ислам кирәк. Шушындамы ул?

— Шушында!— диде Кәрам, хатын янына килеп. Эшләреннән туктап калган яшьләр, берни әйтмичә, аптырашып бер-берсенә карашып алдылар, якынрак килделәр һәм, кәмит күргән сыман, исләре китеп, ят хатынга карап тора башладылар. Хатын, күрәсең, алар арасында Исламны күрмәкче булып, тынгысыз күзләре белән андамонда каранды да йоклап яткан баласын тирбәтеп алган булды.

— Сез Исламның кеме буласыз соң, гражданка?— диде шул чакны Белугин.

— Ярар, кеме булса да булыр, кайда ул... күрсәтегез дә...— диде хатын, тупас кына.

— Була ул!— диде Кәрам һәм җитез генә аның чемоданына килеп тотынды.

Хатын, үзенчә бик тәкәббер кыяфәт белән, эндәшмичә Кәрам артыннан кузгалды.

Кәрам аны Ислам белән Фәридәнең ялгыз чатырына алып килде.

— Өйдәләрме? Кунак килә!— дип кычкырды ул, чатыр итәген күтәргәндәй итеп.

Чатырдагы бердәнбер караватта тирә-ягына ниндидер чүпрәк-чапраклар, төрле төстәге җепләр, төймәләр таратып ташлаган Фәридә Исламның кыска җиңле ефәк күлмәген мәреп утыра иде. Башын калкытмыйча гына ул Кәрамга, өйдә, диде. Ул, күрәсең, «кунаклар» сүзенә игътибар итеп җиткермәде. Ул арада Кәрам кулындагы әйберләрне чатыр эченә кертеп куйды да шундук тышка килеп чыкты. Балалы хатын эчкә узды.

Кәрам тизрәк иптәшләре янына йөгерде һәм ниндидер бик кызык эш башкарган кебек, көлә-көлә:

— Ну шәп булды!— диде.— Хатыныдыр әле ул аның. Эзләп килгән... Ну шәп булды! Барды да керде!

Ләкин аның көлүенә беркем кушылмады. Бу минутта һәркемнең йөзе җитди, борчулы иде.

— Булдырдың!— диде Зәкия.— Йөрисең шунда маймулланып. Без дә инде каттык та калдык.

— Кем икәнлеге күренеп тора инде... Харап иттек!— диде Рәшидә.— Нишләр инде алар?

Барысы да пошынып сабырсызланып көтә башладылар.

## XIII

Исламныкы булырга тиешле чатырда яманып утырган япь-яшь кызны күреп, ят кунак башта аптырап калгандай булды. «Мине алдап китерде микәнни теге ут күз?»— дип уйлады ул Кәрам турында. Шулай да ул чыгып китәргә ашыкмады һәм, Фәридәдән күзен алмыйча:

— Исәнмесез,— диде.— Ялгыш кердем бугай... Миңа Ислам Мусин кирәгие.

— Ислам?! Ислам монда тора. Мин аның хатыны. Ят хатынның йөзе кинәт үзгәреп китте.

— Хатыны?!— диде ул әкрен генә, ысылдап чыккан бер пышылдавык тавыш белән.

Ләкин Дания тиз арада исенә килде. Эчкә баткан күзләре шундук атылып чыгардай булды, әле генә агарынган йөзенә зәһәрле кызыллык йөгерде, һәм Исламга карата айлар буе җыелып килгән барлык каһәрләре, юл азаплары, барлык кайгы-хәсрәте берьюлы тышка бәреп чыкты.

— Шулаймыни?!— диде ул, яшелле-зәңгәрле тавышлар белән.— Сез монда шулай хатынлы ирләрне аздырып-туздырып ятасызмыни әле?!

Елый башлаган баласын ул Фәридә янына караватка ыргытты, аннары ишек төбендәге әйберләрен түргәрәк тартып китерде.

— Күрсәтермен мин сиңа Исламның хатынын!— дип кычкырды ул, ярсып, сөякчел күкрәгенә сугып.— Мин аның хатыны! Мин! Менә баласы, менә закунный хатыны!

Фәридә коелды да төште; урыныннан торды, нидер әйтмәкче булды, ләкин Дания аңа авыз ачарга да ирек бирмәде — борып куйган автомат кебек бертуктаусыз чәрелдәвендә булды. Фәридә, колакларын каплап, кызарынып, ут капкандай шундук ишеккә ташланды.

Нәкъ шул чакны күл ягыннан Ислам кайтып җитте. Үз чатыры янында халык җыелганын күреп ул шомлана калды. Дания тавышын ишеткәч исә, эсселе-суыклы булып китте.

— Исәнме, качкан җегет!— диде Дания, ирен каршылап.

Ислам, кемнәргәдер бәрелеп-сугылып, уртагарак узды, ачык ишектән эчкә ташланды. Күп тә үтмәде, дулаптузынып алар яңадан тышка килеп чыктылар. Кешеләр һылдап куйдылар.

— Оят түгелме әзрәк!— диде шунда Фәрханә апа, Ислам белән Дания арасына кереп.

Шулай диде дә нык кына итеп Данияне култыклап алды. Аңа ярдәмгә кызлар килеп җитте. Усал хатын, ике яктан култыкланган килеш, алпан-тилпән атлап бераз җир барды да хәлсезләнеп шундагы бер түмәргә утырды һәм, авызын бик ямьсез кыйшайтып, күз яшьсез генә, тавышсыз гына еларга тотынды.

Хатын-кыз Дания белән булашкан арада, Ислам кызлар вагонына йөгерде. Фәридә янына кереп калган Рәшидә вагонны эчтән бикләп куйган иде. Аңа ишек ачмадылар. Шул вакытта шаулашып вагон тирәсенә яшьләр җыела башлады.

— Якын килмә!

— Бирмибез Фәридәне!

— Ычкын моннан!— диештеләр ачулы кызлар, Исламны куалап.

## XIV

Ислам, берүзе бер караватка сузылып яткан килеш, берөзлексез тәмәке тартты. Тышта җил чыккан иде. Әледән-әле чатыр киндере чайкалып, суккаланып алды, кайдадыр якында гына җил сызгырды.

Төн урталарына кадәр ул һаман шул бер үк хәлендә ята бирде. Тышта аяк тавышлары басылгач, һәм далада тик кара төн дә йөгәнсез җил генә хуҗа булып калгач,

ул, озын аякларын караватбашыннан алып, җир идәнгә басты, иелеп, бер читтәрәк буш әрҗә өстендә утырган лампаны кабызды, ишекне элдереп куйды да эшкә тотынды.

Караватастыннан ул иң элек үз чемоданын тартып чыгарды, аннан үзенең яхшы кием-салымнарын алды, билгеле бер урынга яшерелгән акчасын алды. Өстендәге эш киемнәрен салып ташлап, яхшы киемнәрен киде. Үзенең барлык нәрсәсен әвеш-түеш китергәч, Фәридә чемоданын ачты һәм пөхтәләп, яхшылап өеп куелган затлы әйберләр арасыннан кабаланып нидер эзләргә кереште. Чемодан төбеннән ачык конвертка салынган беркадәр акча килеп чыкты. Конвертлы акчаны ул кесәсенә салып куйды, аннары ачык чемоданнарга, кием-салымнарга карап, янә тукталып торды.

Әлбәттә, бар нәрсәне дә алып булмаячак иде, иң кирәклеләрен генә, иң кыйммәтлеләрен генә алырга кирәк иде. Ул Фәридәнең күлмәкләрен, кофта-юбка ише нәрсәләрен сайлап актарырга кереште. Аерып алган кыйммәтлерәк әйберләрнең барысын да рәтләп, тыгызлап солдат капчыгына тутырды да чемоданнарны ябып кире караватастына этәрде. Капчык авызын бәйләп, каеш бауларын каптыргач, тагын нәрсә кала икән дигән сыман, чатыр эченә игътибар белән күз йөртеп чыкты.

Шуннан соң ул капчыгын кулына алды, аркасына киде, тышта андый-мондый тавыш ишетелмиме дип, беравык тыңлап торды да ишек элмәкләрен ычкындырды.

Тышта күзгә төртсәң күренмәслек караңгы иде, якынтирәдә бернинди җан иясе барлыгы сизелми иде, вагоннарда, чатырларда күптән инде утлар сүнгән иде. Төнге каравыл булып исәпләнелгән һәм көне буе саман сугып арыган Галимулла, күрәсең, «С-80» кабинасында йокы симертә иде.

Ислам, песи кебек сак кына атлап, бригадир вагоны янына килде. Тагын тирә-якка колак салып тыңлап торды. Шуннан соң вагон тәгәрмәченә сөяп куелган мотоциклны ипләп кенә урыныннан кузгатты. Ул аны олы юлга кадәр этеп алып барды. Юлга чыккач, җиңү-котылу шатлыгы белән, мыскыллы бер тантана белән бригада ягына соңгы мәртәбә карап алды да мотоциклны кабызды.

Ул станция ягына юл тотты. Ике йөз чакрым җирне ул таң атканчы үтәргә исәпләде.

Бик озак аның уйлары бригададан, көндезге гаугадан, Даниядән, Барыйдан аерыла алмады. Соңгы көннәрдә булган бөтен нәрсәне ул яңадан бер мәртәбә хәтере аша

уздырды. Бер-берсенә өелешеп, бер-берсен кысрыклап күз алдына килгән күренешләр арасында ул кинәт чатыр эчендә торып калган утлы лампаны, ачык ишекне исенә төшерде. Баягынак, юлга чыгып артына борылып карагач та, аңа анда ниндидер кызыл нәрсә күренгән шикелле тоелган иде. Димәк, ул аны сүндерергә оныткан!

Бу бик хәтәр иде. Чатыр яна башласа — эш харап! Шундук күреп алырлар, бөтен бригада уяныр, эшне сизеп алырлар да эзләргә тотынырлар!

Аның эче жу итеп китте. Кире борылып аның шул утны сүндерәсе килде, ләкин шул ук вакытта, бер котылгач, кире анда кайту чамадан тыш куркыныч булып тоелды. Мотоцикл бертуктамый алга чапты, ә күңеле аның һаман артка өстерәде. Шактый вакыт ул, урталай өзелгән елан кебек, нишләргә белми барды. Тик шулай да, Көктугай яклары ерагая барган саен, бригада белән бәйләнешле шомлы уйлар артта кала барган саен, аның куркуы да кими барды. Бераздан моның өчен ул сөенеп тә куйды. «Шәп булды! Янып бетсеннәр шунда бөтенесе өелешеп!» — дип уйлады ул, зәһәрле шатлык белән.

## XV

«Аксу» станциясе янында гына ниндидер күлләр, сазлар бар иде. Мотоциклны Ислам шундагы берәр күлгә батырмакчы булды, чөнки поездга утырганда аны кеше күзенә калдырып китү ярамый иде.

Ул инде үзен яртылаш котылган дип исәпләде. Инде таң атты, караңгылык артта калды, алда Аксу йортлары, каралты-куралар күренде, тимер юлда пошкырып торган паровоз һәм паровоз артыннан озын койрык булып сузылган вагоннар күренде. Тагын бераз гына сабыр итәсе дә, тагын бераз гына барасы да, ниһаять, ул бушап, иркенәеп калачак...

Ләкин станциягә бөтенләй үк якынлашкач, аның күңелен икенче бер уй кытыкларга тотынды. Мотоцикл аңа хәзер ниндидер Барыйныкы булып түгел, бәлки, үзенеке булып, үз акчасына сатып алынган үз әйберсе булып тоела башлады. Аны ташлап калдыру, суга батырып калдыру, әлбәттә, бик кызганыч иде. «Туктале, нигә әрәм итәргә әле аны?— диде ул үз-үзенә.— Акча бит әле бу... ярты бәясенә җибәрсәң дә акча...»

Иртыш аръягындагы өлкә шәһәреннән ун километр чамасы көнбатыштарак урнашкан «Аксу» станциясе элекке елларны гадәттәге кечкенә станцияләрдән берние белән дә аерылмый иде. Монда турыдан-туры станциягә кара-

ган берничә агач ызбадан һәм читтәрәк утырган унлап саман йорттан башка бүтән берни юк иде. Ләкин далага яңа кешеләр килеп, яңа совхозлар төзелә башлагач, Аксу кинәт кенә үсеп, үзенә күрә бер үзәккә әйләнеп китте. Яңа совхозларның беренче эшчеләре, беренче тракторлары, күчмә вагоннар, җыелма йортлар һәм һәртөрле техника җиһазлары төялгән эшелоннар шушында тукталды. Йөзәр, икешәр йөз километр ераклыктагы яңа совхозларга юлның башы шушыннан башланды. Хәзер дә монда утызлап яңа совхоз өчен көн-төн товар һәм машина, агач-таш, күмер һәм һәртөрле кирәк-ярак килеп тора иде. Шуларның барысын да вагоннардан бушату өчен, автомашиналарга төяп озату өчен, тимер юл буенда чатырлар корып бик күп эшчеләр тора иде. Монда һәрвакыт ыгы-зыгы, һәрвакыт базар иде.

Ислам мотоциклны нәкъ менә шул ыгы-зыгыда, нәкъ менә шул базарда сатып булмасмы дигән карарга килде. Дала җирендә мотоцикл бик кадерле бит. Кулдан сатканда аны җиңел генә ике бәясенә җибәрергә мөмкин. Ислам алып качкан мотоцикл «Иж» маркалы, өр-яңа иде. Моңа, әлбәттә, кызыгучылар табылырга тиеш иде. Ул аңа әллә ни күп тә өмет итмәде, ике-өч мең бирсәләр, миңа шул җиткән дип уйлады.

Һәм ул, әрәмәлек артындагы күл ягына борылып тормыйча, туры юлдан элдерде генә.

Станциядә халык инде уяна башлаган иде. Бер җирдә берничә кеше, ашыкмыйча гына, иренеп кенә вагоннан такта бушатып яталар иде. Икенче бер җирдә, тимер юл буенда, автомашинага ниндидер тимер-томырлар төйиләр иде.

Ислам алар яныннан җилдәй узып китте, станция читендәге шлагбаум аша тимер юлның икенче ягына чыкты да, артыннан тузан туздырып, вокзал йорты каршысына килеп туктады. Аңа хәзер барыннан да элек расписание белергә кирәк иде.

Капчыгын аркасыннан салып тормыйча, ул көтеп тору залы дип аталган зур гына бүлмәгә килеп керде; зур-зур утыргычларда башларын салындырып, яисә бер-берсенә сөялеп, йокымсырап утырган кешеләр яныннан узды да билет кассасы янындагы бердәнбер расписание тактасы алдына килеп басты. Поездлар тиз генә булмаячак иде. Төньякка таба китәчәк бер пассажир поезды бары өч сәгатьтән соң гына килергә тиеш иде. Ләкин аңа өч сәгать түгел, ярты сәгать тә, чирек сәгать тә көтәргә ярамый, аңа моннан тизрәк, мөмкин кадәр тизрәк ычкынырга кирәк иде.

Ул ашыгып кире чыкты һәм, мотоциклдан котылмакчы булып, кибет, ашханә урнашкан йортлар ягына юнәлде.

Кибетләр, ашханәләр ачылырга әле иртәрәк булса да, анда инде кешеләр кузгалган иде.

Бер машина янында ике-өч кеше күренде. Алар, иртәнге салкыннан бөрешеп, юыныргамы, ашаргамы әзерләнеп торалар иде. Урыныннан куптарып алынган сиртмәле утыргыч өстенә ерткаланып беткән гәзит кисәге җәелгән иде, гәзит кисәгенә ярты кирпеч ак икмәк, колбаса куелган иде. Саргылт чәчләре тузгып беткән һәм шешкән муенына калын итеп марля ураган алыптай юан, таза бер егет кулына ачылмаган консерва банкасы тоткан иде. Шунда ук икенче берсе, башын иеп, битен-күзен юып азаплана, өченчесе исә аңа шешәдән су салып тора иде.

Ислам аларга якын гына килеп туктады һәм, ашыкмыйча гына кыланган булып, капчыгын аркасыннан салды.

— Пәке бирегез әле, пәке?— диде муены бәйләнгән егет, юынучыларга эндәшеп.

Ул, ахрысы, консерва банкасы ачмакчы була иде. Шешәдән су агызып торучы малай сыман яшь кенә егет кесәсен актарып карады да иптәшенә нәрсәдер алып бирде.

— Моның белән ничек ачасың?— диде алыптай егет.— Теш казырга да ярамый бит бу!

Ислам аларның сүзләрен ишетеп торды. Чалбар кесәсеннән ул алты чатлы пәке алды, егетләргә якынрак килде дә:

— Менә миндә бар,— диде.

Егетләр барысы берьюлы борылып аңа карадылар. Пәке сораганы, берни әйтмичә, аның кулына үрелде, пәкесен алды һәм шытырдатып банка калаен кисеп чыгарды.

— Рәхмәт,— диде ул, пәкене кире сузып.

— Тамак ялгарга җыенабызмы?— диде Ислам, сүзгә башлап.

— Исәп шулайрак,— диде алыптай егет.

Ул арада аның иптәшләре юынып, әзерләнеп беттеләр. Өчесе дә бер тирәгәрәк җыелдылар да, бердәнбер стаканга аракы агызып, чиратлашып эчеп чыктылар һәм, Исламның барлыгына-юклыгына әз генә дә игътибар итмичә, зур-зур кабып, икмәк белән колбаса умырырга тотындылар.

— Кая, калдымы анда?— диде бераздан өлкәнрәк егет, шешә төбенә күз төшереп.

Бушаган стаканга ул яртыга якын итеп аракы салды һәм, теге-бу турында сөйләнгәләп, һаман үзләре янында басып торган Исламга сузды. Ислам ялындырып торма-

ды, эчеп җибәрде, тамагын кырып куйды, тыйнак кына кыланып икмәккә үрелде. Аңа колбаса суздылар, һәм биш-алты минут вакыт узмады, ике арада танышлык барлыкка килде. Ислам әйтте, ял алдым әле, диде, туган якларга кайтып килергә исәп, диде, әти-әниләр бәла-казага юлыкканнар — йортлары янган, диде. Шулай сөйләнде-сөйләнде дә егетләр белән шактый үз булып киткәч:

— Менә мотоциклны сатам,— диде.— Кирәк кеше юк микән, белмисезме?

Яңа танышлар лач-лоч чәйнәүләреннән туктап калдылар, кыегаеп эре генә басып торган мотоциклга борылып карадылар, якынрак килделәр һәм сатылачак малны кызыксынып карарга тотындылар.

## XVI

— Ашыгам, егетләр, әйтер сүзегез булса әйтегез дә...— диде Ислам, китәргә җыенып.

— Ашыкма!— диде муены бәйләнгән егет.— Кая ашыгасың? Әле поезд юк.

— Миңа самолетка өлгерергә кирәк,— диде Ислам, җавапка аптырап тормыйча.— Мин монда килеп тә тормасыем. Буран! Буран эшли башлаганчы чыгарга кирәк шәһәргә.

Аның сүзләренә бик үк колак салмыйча, яңа танышлар төпченеп мотоциклны карауларында булдылар.

— Карыйсы да юк, кичәгенәк кенә заводтан чыккан,— диде Ислам.

— Тияре генә күпме?— диде алыптай егет, башын калкытып.

— Сыйлап биргән йөз граммыңны да исәпләсәк, күп булмас,— дигән булды хуҗа кеше.

— Чын, күпме?

— Йөз граммга тагын ике йөз грамм өстә дә, беттекитте!

— Сатмый ич ул, шаярта!— диде малай сымак яшь егет. Ләкин сатулашкан кеше тәҗрибәлерәк күренә иде. Исламның тел төбен ул бик тиз аңлап алды. Йөз граммга кушкач ике йөз граммны була өч йөз грамм, димәк, өч мең! Никтер бик очсыз бу. Хәтта үз бәясенә караганда да очсызрак. Нинди ахмак бу?

— Чынмы?— диде ул, Исламның кулына тотынып.

Ислам да аның ниятен сизенеп алды һәм, оста сатучылар кебек, тимерне тагын да ныграк кыздырмакчы булып:

— Мин киттем,— диде.— Әйтеп торам бит, вакытым юк, егетләр.

— Кил әле!— диде кинәт алыптай шофер, Исламның беләгеннән тотып.

Ул аны үз иптәшләреннән читкәрәк алып китте.

— Ике йөз грамм!— диде ул, сатучының күзләренә туры карап.

Ислам, хәтере калган кеше сыман кырт кына борылды да, эндәшмичә китеп тә барды. Ике меңнең шактый акча икәнлеген ул бик яхшы аңлады, ләкин мондый эштә алай тиз генә бирелү дә ярамый иде.

— Үзең беләсең тагын...— диде шофер, сүрелгәндәй булып.

— Мин киттем,— диде Ислам, рульгә тотынып.

— Соңгы мәртәбә әйтәм!— диде сатулашкан егет.

Ислам, иелеп, нидер чокчынырга тотынган булды. Шофер түзмәде, әкрен генә атлап аның янына килде.

— Акылың барда биреп кал!— диде ул, пышылдап.

Исламның чын-чынлап ачуы килеп куйды, ләкин — берни эшләп булмый!— Ул күнәргә булды һәм, шулай ук пышылдап, боеручан төстә:

— Чыгар акчаңны!— диде.

Алып егет ашыгып кесәсенә тыгылды, бөтәрләнеп беткән берничә йөзәрлек, иллелек һәм вак-төяк акчалар чыгарды. Тиз-тиз генә санады да, мәгънәле генә итеп авыз читен суырып алды: «Эх, җитми!»— диде, кызулап иптәшләре янына китеп барды — иптәшләре теләр-теләмәс кенә кесәләренә тыгылдылар.

— Син соң нәрсә, ир кешеме, әллә хатын-кызмы?!— диде Ислам, үртәлә башлап.

— Җитми бит, җитми!— диде егет, өзгәләнеп.— Тукта, әнә тегендә генә безнекеләр тора. Барып кына килим.

Ул ашыгып читтә, дала ягында күренгән чатырларга таба йөгерде. Ислам сүгенеп алды, китәм, диде, ләкин үзе нишләптер китми калды һәм, нидер рәтләгән булып, яңадан мотоциклга иелде.

Чатырлар ягына киткән кешене күрү нияте белән ул бер-ике минуттан башын калкытып карады, ләкин шофер егет урынына каршысында Һарунны күреп, катты да калды. «Әллә күземә күренәме?!»— дип уйлады, сәерсенеп.

Ләкин бу чыннан да Һарун иде. Постау сыман тупас трикодан тегелгән яңа костюм кигән; керле ак күлмәгенең изүен яка турысыннан ук каптырып куйган; чалбар балакларын җыеп оекбашына кыстырган; кулында — чемодан, йөзендә — ахмакларча елмаю. Каян килеп чык-

кан бу, нишләп йөри? Әллә аның артыннан килгәнме, карап-күзәтеп торганмы? Үзе генәме, әллә иптәшләре дә бармы?

Ислам билен турайтты, як-ягына карангалап алды һәм, һөҗүм була-нитә калса сакланырга әзер булып, тынып калды.

— Исәнме,— диде Һарун, һаман шул ук ахмакларча елмаю белән елмаеп.

— Исәнме,— диде Ислам, ашыгып.

— Әлерәк кенә килеп төштем,— диде Һарун, иснәнеп.— Нәрсә, Барый абый белән килдегезмени? Сагындырды, малай... Безнекеләр нишләп яталар — исәннәрмесаулармы дигәндәй? Тагын кемнәр килде? Машина бармы бездән?

— Бик тиз әйләнгәнсең син,— диде Ислам, телгә килеп.— Менә бригадир белән килгәниек тә, аракы эзләп китте әле.

— Кая җыендың болай капчыклар белән?— диде Һарун.

Ислам җавап кайтарып тормады. Артына әйләнеп ул тагын ерактагы чатырлар ягына карап алды. Ниһаять, көткән кешенең кызу-кызу атлап болай таба килгәне күренде.

— Хәзер!— диде Ислам, көтеп тор дигән мәгънә аңлатып.

Капчык бауларын ике куллап тоткан килеш, ул алыптай егет каршына йөгерде.

«Нәрсә булган соң моңа?— дип уйлады Һарун, аның артыннан карап калып.— Нигә шулай тыз-быз чабып йөри соң әле бу? Ә тегесе кем? Барый абый, диде. Нишләп Барый абый булсын ул?! Кызык... Аркасына капчык кигән...»

Барыннан да бигрәк аны шул аркадагы капчык аптыраашта калдырды. Йокымсыраган миендә аның сәер бер сизену барлыкка килде. Шуннан соң ул кызулап машина тирәсендәге егетләр янына килде.

— Әллә сата?— диде ул, мотоциклга ымлап.

— Сатты инде,— диде егетләрнең берсе.

— Сатты?! Күпмегә?

— Кем белсен аларны!

Һарун кинәт телсез-өнсез калган сыман булды. Ләкин тиз арада ул исенә дә килде: йокысы качты, гәүдәсе турайды һәм әле генә гамьсез караган күзләрендә ихтыяр һәм тәвәккәллек очкыннары чагылып китте.

— Бу урланган мотоцикл!— диде ул, шомлы һәм янаулы итеп.— Кем алды? Бу безнең бригадирның мото-

циклы. Без аның белән бер бригададан. Карак!.. Бандит!..

Егетләр ашауларыннан туктап калдылар, күзләрен зур ачып, аптырап Һарунга текәлделәр, якынрак килделәр.

— Урланган?!— диде малай сымак егет, коты алынып.

— Никтер шикле күренгәние лә!— диде икенчесе. Ул арада Ислам шофер белән эшне җайларга да өлгерде. Акчаны ул санап та тормады, төргәге белән кесәсенә тыкты да:

— Ярый, мин киттем,— диде. Ләкин алыптай шофер, монда нindидер хәйлә булуы мөмкинлеген сизенеп, кисәк кенә аның җиңеннән тотып алды.

— Ю-ук!— диде ул, усал пышылдап.— Алай батмый!

— Батмаса, мә акчаңны!— диде Ислам сүгенеп һәм тиз генә кесәсенә тыгылды.— Син нәрсә, бала-чага кебек...

— Ю-ук, бергә барабыз!— диде егет, кызарынып, ешеш тын алып.

— Тотма, качмам!— дип ыжгырды Ислам. Шофер җиңне ычкындырды, һәм алар, бер-берсен узарга тырышкандай тиз-тиз атлап, егетләр янына килделәр.

— Туктале!— диде кинәт алыптай егет, никтер икеләнеп.

— Фу!— диде Ислам.

Ул туктап тормады, Һарунны култыклап алды да, көтмәгәндә бөтенләй ачылып китеп, нindидер яңа хәбәр әйткән төсле:

— И, син әле белмисеңдер...— диде.— Әйдәле, мин сиңа бер нәрсә әйтәм...

Ислам Һарунны каядыр тимер юл ягына әйдәде. Ул аның йөзенә бөтенләй игътибар итмәде. Аның белән Һарун бераз гына барды да, беләген тартып алды һәм, күзенә ак-кара күренмәгән хәлдә, каядыр ашыккан, ашкынган дошманына кинәт аяк чалды. Озын, авыр кеше, баганадай гөрселдәп, искәрмәстән җиргә капланды. Шундук Һарун юлбарыстай ярсып аның өстенә ыргылды, һәм шул ук вакытта ярдәмгә килеп җиткән кешеләр тавышы ишетелде.

— Аягын бәйлә... кулын! Тизрәк!— дип кычкырды Һарун.

— У-у, боза-ау!— диде Ислам, тешләрен шакырдатып.

— Качмый тор! Эләктең инде!— дип сөйләнде Һарун, эчке бер тантана белән.

Күз ачып йомган арада егетләр качкынның кул-аягын бәйләп ташладылар. Кызарынган, еш-еш тын алган шофер, аягына басты да, муенындагы марлясын тоткалап карады.

— Бар әле, Миша, вокзалга йөгер — милиционер юкмы анда...— диде ул, яшь кенә егеткә эндәшеп.— Шешне сытты, хәшәрәт! Бар инде, бар, йөгер тизрәк!

## Соңгы баб

### I

Мәрьямгә больницада шактый озак ятарга туры килде. Күп кан китү белән бергә, аның аягы да тайган иде. Аны гипска салдылар, һәм беренче көннәрне ул урыныннан да кузгала алмады.

Аның янына көн саен диярлек Рәйханә апа килде. Ул аңа ят ризыклар алып килде, күңелен күтәрде һәм ара-тирә совхоз яңалыкларын сөйләп алды. Билгеле, ул аңа үзе белгән бар нәрсәсен берьюлы чыгарып салмады. Иң элек ул аңа өч мең дә фәлән сум фәлән тиен бурычның тулысынча түләнүе турында әйтте, барысын да үзем җайладым, ул яктан тыныч бул, диде. Мондый хәбәр Мәрьямгә хәл кертеп җибәргәндәй булды.

Соңга табарак, авыруның хәле яхшыра башлагач, Рәйханә апа аңа җайлап кына, әкренләп-әкренләп кенә бүтән төрле яңалыкларын да чишә башлады. Ул аңа Исламның Фәридәгә өйләнгән булуын да сөйләде, көтмәгәндә бригадага Дания килеп төшүен дә, Исламның мотоцикл урлап качуын һәм, Аксуда тотылып, кулга алынуын да, хөкем ителүен дә — барысын да сөйләде. Мәрьям аны тыныч кына тыңлады, үзенә бөтенләй кагылышы булмаган чит нәрсәләр, чит кешеләр турында тыңлаган кебек тыңлады. Дания турында сүз чыккач, аның агарынган йөзенә шулай да сыек кына булып кызыллык йөгерде.

— Бичара, каян кая азапланып килгән!— диде ул, Данияне кызганып.

— Баласы белән бит әле!— диде Рәйханә апа.

— Баласы белән?!— диде Мәрьям.

Ул моны кисәк кенә әйтте, курку катыш гаҗәпләнү белән әйтте, ләкин аның бу кисәк кенә кабынып китүе шулай ук кисәк кенә юкка да чыкты.

— Килүен килгән дә, кайтырга бер тиен дә акчасы калмаган булган шул,— диде Рәйханә апа.

— Кайтып киткәнмени?— диде Мәрьям, гамьсез генә.

— Киткән. Дирекция юллык акча биргән,— диде Рәйханә апа.

Дания мәсьәләсендә сүз шуның белән тәмам булды һәм шуннан соң беркайчан да бүтән кабатланмады. Хәер, Ислам турында да башка сүз булмады. Аның турында Рәйханә апа яңалыкларын сөйләп бетергән иде инде, Мәрьямнең яңадан да төпченәсе килмәде. Төпченү түгел, аның, гомумән, Ислам турында да, Дания турында да

ишетәсе дә килмәде. Ләкин аның бу ишетәсе килмәве һич тә үз-үзен мәҗбүр итү түгел иде. Рәйханә апа үз теләге белән шул хакта яңадан сүз башласа, ул моңа каршы да килмәс иде һәм шулай ук куанмас та иде. Ул битараф иде, тулысынча битараф иде.

Ул хәзер, андый нәрсәләрдән бигрәк, үз хәле, үз язмышы турында уйланды. Ята-ята ул үзенең үткән көннәрен, үткән юлларын күз алдына китерде. Ләкин ул «юллар» Исламга килеп терәлгәч тә, һәрвакыт тукталып калдылар, өзелделәр һәм ниндидер могҗиза ярдәмендә тар, караңгы коега барып ялгандылар. Тар, караңгы коега кадәр булган күпмедер вакытны ул ничектер сикереп кенә үтте. Ислам кайдадыр аста, бушлыкта торып калды, бернинди мәшәкатьсез, бернинди әрнүсез, үкенүсез торып калды, һәм шуңа күрә Ислам турында нәрсә генә сөйләсәләр дә, аның өчен инде барыбер иде.

Караңгы коеда, таш һәм чүп-чар өеме астында Ислам гына түгел, аның каны белән яратылган икенче бер истәлек тә күмелеп калды. Аны хәзер элеккеләр белән берни бәйләп тота алмады һәм шунлыктан ул үзен хәзер яңа туган кеше кебегрәк хис итте, шунлыктан ул караңгы бушлыкны шулай җиңел генә сикереп үтеп, узган гомер җебен турыдан-туры бүгенгә ялгап җибәрергә азапланды. Тик шулай да әлегә ул моны берничек тә ялгый алмады. Коедан соң аның юлы беркая да китмәде. Ул шунда тукталып калды, югалып калды.

Икенче юл башларга аның әлегә кыюлыгы җитмәде, дөресрәге, ул әле кайсы юлдан ничек, кайчан китәчәген төгәл генә күз алдына китерә дә алмады.

## II

Көннәрдән бер көнне ул аягына басты, аннары торып утырды, беркадәр вакыттан соң исә йөри дә башлады.

Җилле, кояшлы беркөнне ул ипләп кенә, мыштырдап кына тышка ук чыгып китте. Айдан артык ябылуда ятканнан соң бу әле аның беренче мәртәбә чыгуы иде. Җиргә басу белән, ул үзендә искиткеч шатлык һәм җиңеллек хисе тойды. Дала ягыннан җил үлән исе һәм ниндидер көйгән исләр алып килде. Бу татлы исләрдән, саф һавадан ул исереп киткәндәй булды — кинәт кенә аның башы әйләнеп куйды, күз аллары томаланды. Берничә адым атлагач та, ул сукмакта туктап калды, бераз хәл җыеп торды да, үзалдына елмаеп, әкрен генә Иртыш яры буена таба юнәлде.

Больница ишегалды яр кырыена барып терәлә иде.

Биек, текә яр буена тәбәнәк кенә текмә тотылган, текмәдән болайрак авыруларга утырып ял итү өчен озынча утыргычлар ясап куелган иде. Бернинди агач-фәлән үсмәгән, ышыкланырга бернинди күләгәле урын булмаган «больница бакчасы» менә шуннан гыйбарәт иде. Ләкин бу «бакчаның» шулай да бер яхшы ягы бар иде: текмәгә сөялеп яисә такта утыргычларга утырган көе, аста җәелеп яткан киң Иртыш дәрьясын, Иртыш аръягындагы юлларны, болыннарны күзәтергә була иде. Әгәр инде көтмәгәндә еракта, күк белән Иртыш бергә тоташкан турыда, кара төтен ургытып кыймылдаган берәр каек күренсә, ул чагында инде тирә-як тагын да ямьләнеп, киңәеп китә иде. Яр буендагы балыкчыларга, су керүчеләргә карап тору да үзе бер хозур иде. Һәм үзләре йөри алган авырулар еш кына шушы «бакчага» чыгып, күңелләрендәге авыр тойгыларны, киемнәрендәге авыр исләрне таратып керәләр иде.

Мәрьям утыргычлардагы бер-ике авыру яныннан үтеп китте дә текмәгә килеп сөялде. Үзе алдында ачылган киңлекне, гүзәллекне күреп ул гаҗәпләнеп китте. Аның әле беркайчан да Иртыш буенда булганы юк иде. Никтер аңа дала бары тик Көктугай тирәсендәге шикелле генәдер сыман тоелган иде. Монда ул бөтенләй икенче төрле табигать күрде, бөтенләй икенче төрле киңлекләр, ераклыклар күрде, бөтенләй икенче төрле зәңгәрләнеп, томанланып торган серле офык һәм төпсез күк йөзен күрде. Бу яңалыкны, бу гүзәллекне ул кисәк кенә аңлый да, тоя да алмады. Ул әйтерсең искәрмәстән сихерләнеп калды.

Аның кинәт күңеле җирсеп куйды, борын очы кытыкланып алды һәм ирекә сусаган, зарыккан йөрәге сулкылдап-сызланып тибәргә тотынды. Аның каядыр шул зәңгәрсу томан артына яшеренгән серле җирләргә, яшел болыннарга, әрәмәләргә барып җитәсе килде, юл буенча каядыр нindидер бәхетле якларга ашыгып чабучы машиналарга утырып китәсе килде, һич югы, аның үз иркендәге балыкчылар кебек, су керүче малайлар, кызлар кебек яр буенда йөгергәләп йөрисе килде.

Шулай үзалдына уйланып-хыялланып торганда, ул урам якта мотоцикл тавышы ишеткәндәй булды. Хәер, мотоцикл тавышы аңа ерактан ук ишетелде. Колак тондыргыч каты тавыш бик тиз якынлашты һәм, больница янында томаланган кебек, сүнеп калды. Аның менә шул кисәк кенә сүнеп калуы Мәрьямне уйларыннан бүлде. Ул хәзер зәңгәрсу офыкны да, Иртыш буйларын да күрмәс булды. Бер дә юктан ул халат изүен, төймәләрен сый-

паштыргалады, хәлсез куллары белән чәчләренә орынып алды һәм тынычлыгын җуйган, уттай янган күзләре белән тиз генә артына әйләнеп карады.

Мотоцикл тавышын ул бик яхшы таныды. Ул инде аны күптән үк таный башлады. Әлегечә шул тавыш больница янына туктап калдымы, бераздан көлеп-елмаеп Рәйханә апа килеп керәчәген ул инде электән үк белеп ята иде. Рәйханә апа аңа мотоцикл хуҗасы турында беркайчан берни сиздермәде. Ләкин ул барыбер сизде һәм шуңа күрә аңына килүенең беренче көннәреннән үк үз янына Көктугай докторыннан башка бүтән беркемне дә кертмәскә кушты. Бер-ике мәртәбә ул хәтта **аның** коридор ягыннан ишетелгән тавышын да тотып алды, ә бер мәртәбә **аны** тәрәзәдән күреп калды. Шуннан соң аның тәмам тынычлыгы югалды. Шуннан соң ул шактый вакыт үз-үзенә урын таба алмады.

Ул аңа ачуланмады, ләкин аның бу эшен яклый да алмады. Аның әле ныклап торып тынычланасы килде, чәчелгән, таркалган уйларын, хис-тойгыларын барлыйсы, тәртипкә саласы килде. Ләкин әнә, күрәсең, бу дөньяда күңелгә беркайчан да тулы тынычлану да, тиешенчә акыллы, әдәпле булу да мөмкин түгел икән!

Ул тагын артына әйләнеп карады һәм шул чакны ишегалды аша сузылган озын баудагы ап-ак керләр арасыннан бу якка — «бакча» ягына чыгып килүче Барыйны күреп алды. Ул, ахрысы, бүген үзе генә килгән иде — аның янында Рәйханә апа да, бүтән беркем дә юк иде.

Мәрьямгә ул үсеп, озынаеп киткән шикелле тоелды. Аның өстендә шул ук солдат гимнастеркасы, солдат чалбары иде. Билендә дә шул ук каеш иде. Тик аягындагы күн итекләре генә яңа иде, ахрысы. Әйе, күн итеге тар, озын кунычлы иде, таза балтырларын кысып, бераз гына сырланып тора иде.

Мәрьям аны шулай бер карауда баштанаяк күздән кичерде дә, каядыр китеп барырга җыенган сыман, берике адым атлап куйды. Ләкин ул үзенең аксаклаганлыгын шәйләп алды һәм, бөтен тәне кинәт хәлсезләнгән килеш, текмә тактасына тотынырга мәҗбүр булды. Шул ук секундта диярлек якында гына кысылып чыккан басынкы таныш тавыш ишетелде.

— Исәнме... Мәрьям,— диде Барый, бер читтәрәк туктап.

Мәрьям, кабаланып, артына борылды, кабаланып «исәнмесез» диде, кызарынды, тирләде һәм тиз генә яңадан Иртыш ягына борылды. Аның уңайсызлануын Барый бөтенләй күрмәде дә, сизмәде дә. Кыюсыз гына ул тагын

аңа таба тартылып куйды, текмә янына ук килде дә ике куллап Мәрьям кебек такта башларына тотынды.

— Карыйбызмы?— диде ул, ни өчендер елмаерга тырышып.

Мәрьям, җавап биргәнлекне аңлатып, авыз эченнән генә нидер сөйләнеп куйды.

— Хәлең ничек, Мәрьям?— диде Барый, янә сүзгә башлап.

— Ярый... рәтләнеп киләм...— диде Мәрьям. Шулай да ул Барыйга әйләнеп карамады. Барыйның йөзендәге елмаюы шундук юкка чыкты, һәм үзенең әрсезлегенә, кирәксез кыюлыгына эче пошып, ул читкәрәк тайпылды. Мәрьям шундый ябыккан, шундый үзгәргән иде — аның бөтен кыяфәте, бөтен торышы үзеннән-үзе күңелдә бары кызгану һәм ярату гына тудыра ала иде. Һәм шуңа күрә ул аның күңелен кырудан, аны рәнҗетүдән курыкты, аның янында ничек тә сак һәм игътибарлы булырга тырышты. Ә ул хәзер шундый киң күңелле, шундый игътибарлы иде, әгәр Мәрьям ачуланып берәр тупас сүз әйтсә дә, хәтта яныннан ук куалап җибәрсә дә, әз генә дә аңа хәтере калмас шикелле иде.

Ләкин Мәрьям аны куалап та җибәрмәде, аңа бернинди тупас сүз дә әйтмәде. Киресенчә, үзенең бала-чага кебек качышлы уйнавын ул, ниһаять, сизенеп алды, Барыйга борылды да, гади генә итеп:

— Әйдәгез, утырып торыйк,— диде. Ул, гадәттәгегә караганда ныграк аксаклап, якындагы буш утыргычка килеп утырды.

— Менә... аксыйм әле,— дигән булды ул, гаепле бер төс белән елмаеп.

Барый да аның янына килеп утырды һәм бераз тынып торгандай итте дә:

— Авыртамыни әле?— диде.

— Авырта шул,— диде Мәрьям.— Менә бүген беренче мәртәбә чыктым. Туйдырды яту... чыгасы килә, йөрисе килә...

— Килмини! Беләм, минем дә ятканым бар,— диде Барый.— Минем дә аяк тайды. Армиядә. Биш-алты ай буе авыртып, сызлап йөрде.

— Шулай озакка бара микәнни ул?— диде Мәрьям, курыккандай итеп.

— Ничек тайган бит!— диде Барый.— Дәваламасаң, билгеле, озакка бара. Сине бит дәвалыйлар... дыр?

— Дәвалыйлар инде,— диде Мәрьям.

Алар шулай җиңел генә, иркен генә сөйләшеп утырдылар; бик күптәнге танышлар кебек, дөнья күргән карт-

лар кебек сөйләштеләр, ләкин шул ук вакытта алар әле яңа гына очрашкан, әле яңа гына танышкан кешеләр кебек сөйләштеләр. Үзләрендә алар хәзер бернинди киеренкелек, бернинди уңайсызлык тоймадылар, ләкин шул ук вакытта алар бер-берсен бик яхшы сизеп-тоеп утырдылар. Четерекле нәрсәләр турында алар ләм-мим эндәшмәделәр. Алар андый нәрсәләрдән читтә, еракта булдылар, ләкин шул ук вакытта алар андый «нәрсәләр» белән янәшә генә утырдылар: икесе дә бер үк һаваны суладылар, икесе дә бер үк киңлекләрне, бер үк Иртышны күрделәр, бер үк кояш җылысын тойдылар, һәм аларга бу бераз гына гаҗәп тоелды, ләкин шул ук вакытта монда бернинди гаҗәпләнер нәрсә дә юк шикелле иде.

Аяк таю, аяк сызлау турында сүз беткәч, Мәрьям урыныннан кузгалгандай итте.

— Бүгенгә җитәр. Алҗытты,— диде ул.

— Ярый, мин китим,— диде Барый, ашыгып.— Күп йөрмә. Өзлегерсең.

— Шулай шул,— диде Мәрьям, күндәм генә. Барый артык сөйләнеп тормады,— саубуллашты да кызу-кызу атлап китеп тә барды. Ул киткәч тә, Мәрьям кире урынына утырды. Аның хәзер һич тә бөркү палатага керәсе килмәде. Аңа монда рәхәт иде, бик тә рәхәт иде. Монда киңлек, монда иркенлек иде, монда якты һәм җиләс иде. Һәм монда Иртыш аръягындагы зәңгәр бушлыкка таба үрмәләүче юллар гына түгел, бәлки, Көктугайга илтә торган таныш юл да, шул юлдан тырылдап чапкан якын кеше дә күренә шикелле иде.

## III

Авылдан иркен далага чыккач, Барый очты гына. Юл таныш булса да, хәзер аңа ул моннан беренче мәртәбә баргандай тоелды. Каршыга томырылып чапкан юлны гына түгел, талгын җилдә дулкынланып яткан соргылт даланы да, яр буена сыенып утырган саман авылларны да, көтүләрне дә — барысын да ул әле яңа гына күргән кебек булды. Ул хәзер бөтен тирә-якка, бөтен җиһанга икенче күз белән, икенче төрле күңел күзе белән карады. Җилгә каршы киерелгән таза күкрәгендә ул бернинди көенеч белән, бернинди шик-шөбһә белән тапланмаган тулы бер шатлык хисе тойды. Як-ягында бернинди киртәләр белән чикләнмәгән төпсез киңлек тойды; алдында бернинди таулар-ташлар белән капланмаган тигезлек һәм бер болытсыз күк табагын күрде; артында үзе өчен бу дөньяда иң кадерле булган, иң сөйкемле, гүзәл

булган кешесе барлыгын белде. Ул үзе генә чапмады, ул аның белән бергәләп чапты, ул дала белән, көтүләр белән, Иртыш буендагы әрәмәләр белән бергә чапты. Алар аны озата бардылар, алар аңа канат бирделәр. Шуңа да ул үзен хәзер шундый бәхетле сизде, көчле һәм гайрәтле сизде. Үзендә ул хәзер бөтен җирне — далалы, Иртышлы иксез-чиксез җирне колачлардай киңлек сизде.

Көктугайга ул күз ачып йомган арада кайтып җитте.

Бүген ял көне иде, кешеләрнең күбесе Иртыш буена китеп беткәннәр иде. Бары тик күл буенда гына берничә кеше саман белән булашып ята иде — кирпечне алар үзләре өчен сугалар иде. «Миңа да, күрәсең, шуларга кушылырга кирәк булыр»,— дип уйлады Барый. «Юк, әлегә ярамый»,— диде ул аннары, үзенә-үзе каршы килеп. Әлегә иртәрәк. Вакыты җиткәч тә өлгерергә булыр. Көзгә кадәр әле вакыт бар.

Ул үзенең бүлмәсенә керде, күн итекләрен, гимнастеркасын салып ташлады һәм, кулларын баш астына куйган килеш, рәхәтләнеп сәкегә сузылып ятты. «Шулай да чамалый башлаганда ярый,— диде ул тагын да, баштагы фикерен дәвам итеп.— Чынлап та, нәрсәсе бар инде аның? Әнә ич кешеләр өйләнәләр дә үзләренә оя да коралар. Нәрсәсе бар аның? Киндер сугуның ние бар — атасы да кагасы! Өй салуның ние бар — мүклисе дә чутлыйсы! дигән ди түгелме соң бер оста. Саман йортның ние бар — өясе дә куясы!»

Шул вакыт кемдер тышта кыюсыз гына ишек шакыды.

— Кем ул? Кер әйдә, кер!— диде Барый һәм урыныннан торып утырды.

Бүлмәгә Фәридә килеп керде.

— Менә сезгә аш керттем, Барый абый,— диде ул, кулындагы тәлинкәсен өстәлгә куеп.

Барый аптырагандайрак итеп калды һәм, берни эндәшмичә, беравык пешекченең моңсу йөзенә, кара янган матур беләкләренә карап торгандай итте. Фәридә элеккегә караганда бераз гына тартылып, ябыгып калгандай күренә иде, ләкин шулай да ул һаман матур иде, сылу иде. Аның үз-үзен тотышыннан, бөтен кыяфәтеннән тыныч бер җитдилек һәм әчке сагыш бөркелеп тора иде.

— Аш керттең?— диде Барый, кабатлап.

Бүтән чакта ул кешеләр белән бергә ашый иде, һәм аның әле бер генә мәртәбә дә болай иркәләнгәне юк иде.

— Әйе, аш керттем, Барый абый,— диде Фәридә, башын түбән иеп.— Төш җиткән, ашарга вакыт.

— Карале, Фәридә, синең белән бер ныклап торып

сөйләшәсе килә әле минем,— диде Барый, аш турындагы сүзне җавапсыз калдырып.

— Сөйләшик, Барый абый,— диде Фәридә, урындык читенә утырып.

— Әйт әле турысын гына: нишләргә уйлыйсың син киләчәктә?— диде бригадир.

— Күз күрер әле, Барый абый,— диде Фәридә.— Алдагысын Алла белә.

— Карап-карап торам да, тагын бер карап куям,— диде Барый, бераз гына вәгазь тонына бирелеп.— Иптәшләрең анда — Иртыш буенда күңел ачалар, син монда берүзең боегып йөрисең! Берүзең! Нәрсә, дөнья җимерелгәнме әллә шулкадәр? Бер мәртәбә абынып егылгансың икән, гомер буена шулай караңа көенеп йөрерсеңмени?!

— Минем эшем бар. Эшемне ташлап мин беркая китәлмим, Барый абый,— диде Фәридә, тагын да ныграк башын иеп һәм бөтенләй көтмәгәндә борынын тарткалый башлады.

«Каты бәрелдем, ахрысы»,— дип уйлады бригадир һәм беркадәр вакыт тынып утыргандай итте дә, йомшак кына итеп:

— Беләсеңме нәрсә, бар, Казанга кайтып кил!— диде.— Әтиең-әниең янына. Ял итәрсең, онытылырсың. Теләсәң — ярты айга, теләсәң — бер айга... Ничек тә җаен табарбыз.

— Юк, мин беркая китмим, Барый абый,— диде Фәридә, нык итеп.— Миңа монда да күңелле.

— Күңелле?!— диде Барый.

— Күңелле,— диде Фәридә, көттеребрәк. Бригадир шактый вакыт тын гына утырды.

— Нәрсә, миңа аш пешерер өчен калдыңмыни?— диде ул бераздан, ясалма бер кырыслык белән.

— Әйе, Барый абый,— диде Фәридә, юаш кына һәм, иелгән башын чайкап күтәрде дә, кызарынып чыгып та китте.

Барый үзалдына уйланып утырды-утырды да аягына басты, күн итеген киде, гимнастеркасын киде. Аның хәзер ашап торасы килмәде, һәм ул җилләнеп вагоннан чыкты да күл буена китеп барды.

Чалбар балагын тезенә тикле кайтарып куйган, күлмәген исә бөтенләй салып ташлаган һәм, көне буе дала коя шында янганга, бакыр төсенә кергән Галимулла аны беренче булып күрде. Күрде дә ерактан ук аңа сәлам бирде һәм:

— Иптәш генерал килә!— дип кычкырды. Әле булса, хәрби киемнәрен салып ташламаганга, кайберәүләр, ша-

яртып, бригадирга йә «генерал» дип, йә «капитан» дип эндәшкәлиләр иде. Галимулланың шат-көләч йөзен күргәч, «генерал»га күңелле булып китте.

— Рота, смирно!— дигән булды ул, чокыр кырыенда туктап.

Саманчылар башларын калкыттылар, билләрен яздылар.

— Барамы эшләр?— диде Барый.

— Барганы бара, бармаганы тик тора,— диде Галимулла.

— Эссе. Яндыра гына. Әллә мотоциклыңа утыртып Иртышка су керергә алып барасыңмы, иптәш бригадир?— диде Ира, тирләгән маңгаен сөрткәләп.

— Ник, була!— диде Барый, шундук риза булган булып.— Ирең рөхсәт итсә, көн дә барып кайтырбыз.

— Болай бик кыздырса, рөхсәт тә сорап тормам әле мин,— диде Ира, батыраеп.

Галимулла белән Андронов чокырларыннан чыктылар да, кулларын юып, Барый янына килделәр, һәм ирләр өчесе дә, коры җиргә утырып, тәмәке көйрәтеп җибәрделәр. Фәрханә апа белән Ира кирпеч өеме артына күләгәгә китеп бардылар.

— Үзең соң нишләп йөреш, Барый туган?— диде Галимулла.— Ни җомга, ни шимбә дигәндәй, бүген бит сезнең эш көне түгел.

Ул, күрәсең, тапкыр сүз әйттем дип уйлады һәм, үз-үзеннән канәгать булып, кеткелдәп куйды.

— Йөрим әле, Галимулла абзый,— диде Барый.— Бер уй белән йөрим әле мин. Әллә миңа да сезнең кебек эшкә тотынысыргамы, дим.

— Ни... баш белән уйлап караганда...— диде Галимулла, тамагын кыргалап.— Ничегрәк соң, үзең өченме дигәндәй?

— Билгеле, үзе өчен!— диде Андронов, Галимулланың шуны да аңламавына исе китеп.— Җитәр, генералга да башлы-күзле булырга вакыт!

Галимулланың авызы җәелеп китте.

— Чынлапмы, Барый туган?— диде ул, күзләрен елтыратып.

— Чынлап, Галимулла абзый!— диде Барый.— Үзем өчен! Үземә йорт салу өчен.

— Ә килен? Килен кем булачак соң?— диде түземсез Галимулла.

Килен турында кычкырып әйткәч, үзе түгел, бәлки, бүтән кеше әйткәч, бу мәсьәлә Барый өчен тагын да ачыклана төшкәндәй булды. Килен аңа ерактагы хыял булып

түгел, бәлки чын булып, якын булып тоелды һәм үзенең озакламый киленле булырына ышанычы булганга һәм бу турыда бүтәннәр дә инде сизенгәнгә күрә, аны кинәт тыелгысыз шатлык, горурлык хисе биләп алды. Ул көлеп җибәрде. Ул куанып, рәхәтләнеп көлде. Шулай да ул тиз генә чишелеп тә китмәде.

— Күз күрер әле, Галимулла абзый,— дигән булды ул.— Башта йорт турында уйларга кирәк, аннары килен турында...

— Юк, алай түгел ул, Барый туган!— диде Галимулла.— Икәүләп җиткергән йорт кадерлерәк була ул.

— Анысы да дөрес!— диде Барый, килешеп.

— Синнән күрмәкче башкалар да тотыныр,— диде Андронов, бераз гына хыялга бирелеп.— Бөтен бригада бер урам булып утырырбыз!

— Мин дә шуны уйлаштырам шул,— диде Барый.— Төпләнергә икән, төпләнергә! Нәрсә монда килде-китте йөрергә...

— Сиңа ул күптән кирәгие дә...— диде Галимулла.— Ярый, әле дә соң түгел. Менә без Фәрханә апаң белән киләсе атнага өмә ясарга дип торабыз әле. Безнең кирпеч инде шактый...

Барый аның соңгы сүзләрен тыңламады — каядыр Иртыш ягына караган килеш, ул үзалдына уйланып утыра иде.

Аның күз алдына биш тәрәзәле яңа йорт килде, тәрәзә төпләрендә үсеп утырган гөлләр килде. Ул үзенең булачак йортының сырлы шифер түбәсен күрде, тырпаеп утырган кызыл морҗасын күрде, бакча эчендә алмалар, карлыганнар күрде... Эх, киләчәк турында хыяллану нинди күңелле!

## IV

Һәр якшәмбе көнне бригада кешеләре, машинага төяләп, Иртыш буена ял итәргә баралар иде. Аларның бөтен көннәре диярлек шунда уза иде. Бүген дә шулай булды. Машина кешеләрне иртән-иртүк елга ярына китереп бушатты да кире кайтып китте. Ял итүчеләр яр буенда торып калдылар, чыр-чу килеп су керделәр, кайнар комда кызындылар, ут ягып ашарга пешерделәр, төрле уеннар уйнадылар.

Мансур җитәкчелегендәге берничә балыкчы, гомуми төркемнән аерылып, балык тотарга китте. Алар аулаграк урын сайларга булдылар һәм, таллык ярып, түбәнгәрәк китеп бардылар.

Алар балыкны шактый күп тоттылар. Балык тотып арыгач, су керделәр, кояшта кызындылар. Төш вакытларында балыкларын пешереп ашадылар да рәхәтләнеп йоклап алдылар. Вакыт шулай бернинди борчылусыз, эч пошусыз үтте.

Көннең кызуы сүрелеп, черкиләр күбәя башлагач, егетләр кайту ягына борылдылар.

Балыкчылар Көктугай юлы өстенә чыктылар да берәр машина туры килмәсме дип көтә башладылар. Ун минут көттеләр, унбиш минут көттеләр, ләкин Көктугай ягына кайтучы бер генә машина да күренмәде. Машиналар бүген Иртыш буеннан ком-фәлән ташымыйлар иде, болай гына килгән яисә ял итүчеләрне алып килгән машиналар инде, күрәсең, барысы да кайтып киткәннәр иде.

Көтеп-көтеп тә рәт чыкмагач, Мансур:

— Әйдәгез, җәяү генә кайтабыз!— диде. Егетләр тузанлы киң юлның як-ягына таралдылар да сүзсез генә кузгалып киттеләр.

Алар Иртыш буендагы сирәк әрәмәлектән чыгарга да өлгермәделәр, көнне кисәк кенә караңгылатып җибәрде. Төньяктан дымсу, салкын җил исә башлады, һәм, күп тә үтмәде, еракта, дала өстендә корымланган чүпрәк төсле кара болыт калкып чыкты.

Егетләр кызурак атларга тотындылар.

Кичке кояшның хәлсезләнгән кызгылт нурлары болыт артында калды. Тирә-як һаман саен караңгылана барды. Үз алдында бернинди каршылыкка очрамаган җитез җил отыры ныграк көчәя барды, отыры ныграк ярсый барды. Юл читендәге үләннәр җиргә егылды. Юл өстеннән бөтерелеп тузан күтәрелде. Биткә, муенга каяндыр җил китергән вак ком бөртекләре бәрелде. Колак төбендә бертуктаусыз җил сызгырып торды.

— Йөгерергә кирәк, йөгерергә!— дип кычкырды Мансур иптәшләренә.

Алар инде болай да йөгереп баралар иде. Мансурның тавышы башкаларга боерык сыман булып ишетелде. Алар тагын да кызулый төштеләр.

Юл ниндидер иске күл эзенә килеп керде. Сул якта ярсулы шыбырдашкан һәм нишләргә белмичә өзгәләнеп-йолкынып утырган биек камышлар күренеп калды. Яшен яктысында, көянтәгә эләктерелгән чиләктәге су шикелле булып, тар гына ярлары эчендә бәләкәй түгәрәк күл чайкалып калды. Иске күлнең икенче яры өстенә килеп менгәч, җилнең шашынуы арта төште. Ертылыр дәрәҗәгә җиткән киемнәр тарткаланды, аяклар буталды, һәм җил ихтыярына бирелеп каядыр юлдан читкә китеп бармас

өчен, шактый көч куярга туры килде, тыгыз һава дулкынын чын-чынлап күкрәк белән ерып барырга туры килде.

Томалап яңгыр килгәндә, гарасат килгәндә, табигать төрле кыяфәтләргә керә. Күк белән җир өсте арасында ниндидер явыз бердәмлек барлыкка килә, һәм бөтен тирә-як җирдәге барлык җанлы-җансызга тетрәндергеч тәэсир итә. Әле генә бик якын булып, гади булып тоелган һәрбер нәрсә кинәт серле, явыз төс ала, адым саен сине нидер өркетә, куркыта; шундый иттереп өркетә,— хәтта үз-үзеңнән дә шүрләргә мәҗбүр буласың.

Балыкчы егетләрне дә шундыйрак аңлаешсыз бер курку-өркү биләп алды. Аларны хәзер кемгә дә булса алдан әйдәп яисә артта кызулап барасы да булмады. Алар иң соңгы тизлектә йөгерделәр, бертуктаусыз йөгерделәр.

## V

Бераз вакыт Һарун Мансур артыннан ук барды. Ләкин корыган күлне чыгып, беркадәр җир киткәч тә, нишләптер аның тын алуы авырлаша башлады. Бугазыннан аскарак, күкрәк өстенә ниндидер бөке килеп кысылды да, эчтәге һаваны тышка чыгармыйча, тыштагысын эчкә үткәрмичә, бөтен күкрәген авырттырып-кысып тик торды. Күкрәктәге авырту озакламый касыкка төште. Аның эченә кату керде.

Иң элек аны бәләкәй Кәрам узып китте, аннары Димка куып җитте.

— Һарун, тизрәк!— дип кычкырды Димка.

— Уз әйдә, уз,— диде Һарун.

Чыннан да, аны Димка да узып китте, һәм бервакыт ул барысыннан да артка калды. Ул, ышыкланыр өчен берәр куак-фәлән юкмы дигән сыман, як-ягына карангалап алды. Ләкин далада ышыкланырлык куак эзләү ком чүлендә челтерәп аккан чишмә эзләү белән бер иде.

Аның аяклары хәлсезләнгәннән-хәлсезләнде. Аңа тын җитмәде. Ул туктарга мәҗбүр булды. Туктады да беркадәр вакыт хәл җыйгандай итте.

Яңадан кузгалып киткәч, юл нишләптер аңа тараеп калгандай булды, аннары җил дә кисәк кенә икенче яктан исә башлады. Бу ничектер аңа гаҗәбрәк тоелды, шулай да ул моңа артык игътибар итмәде — ничек тә иптәшләреннән калмаска, ничек тә кайтып җитәргә тырышып, һаман йөгерүендә булды.

Бөтен тирә-якны көндезгедәй яктыртып, кисәк кенә көчле яшен яшьнәде. Шул ук секундта чатырдап күк

күкрәде һәм сибәләп вак кына яңгыр яварга тотынды. Яшен яктысында Һарун алда беркемне дә күрмәде. Ул, ахрысы, иптәшләреннән бик нык артка калган иде. «Шул арада!» — дип уйлады ул, исе китеп. Ул кычкырырга тотынды, ләкин аның тавышы кайдадыр алда йөгереп барган кешеләргә түгел, хәтта үзенә дә көчкә ишетелде.

Ул үзенең кайчаннан бирле йөгерүен дә, күпме йөгерүен дә онытты. Сибәләп яуган яңгырны ул бөтенләй диярлек сизмәде. Ул шулай битеннән, колак очларыннан салкын тир тамчысы тамадыр дип уйлады.

Менә берзаман аның тын алуы җиңеләеп киткәндәй булды, касыктагы каты авырту юкка чыкты. Ул, ниндидер газаптан котылган кебек, бушаныпирке нәеп, ике кулын да селти-селти, адымнарын тагын да кызулый башлады.

Каршыда гына, якында гына ул ниндидер куаклар күреп алды. Юл өстендә бит Көктугайга кайтып җиткәнче берниндИ куак-фәлән булмаска тиеш иде. Каян килгән бу куаклар? Әллә адаштымы соң ул? Гаҗәп, олы юлда нишләп адашып торыр икән? Туктале, олы юлмы соң бу?

Ул туктап калды, иелеп, күзләрен зур ачып, юлны, юл читләрен караштырырга тотынды. Бу олы юл түгел иде, бу ниндидер ят юл, машиналар бик әз йөргән каты, такыр юл иде. Димәк, ул чыннан да адашкан! Юк, адашмаган, икенче юлга кереп киткән!

Ярый, шулай да булсын, нишләргә хәзер? Кире борылыргамы, әллә һаман алга барыргамы?

Ул кире борылмаска булды. Ул бары алга йөгерүен генә белде. «Берәр зуррак агач астында яшеренеп торырмын да, давыл тынгач, кайтып китәрмен», — дип уйлады ул.

Бөтен җир, бөтен тирә-як көтмәгәндә серле бер төс белән тынып калды. Бу шундый кисәк кенә булды — табигать тагын нинди дә булса көтелмәгән мәкер эшләргә җыенамы әллә дигән сыман, Һарун адымнарын әкренәйтә төште, күзләрен күккә текәп, сагаеп тыңларга тотынды. Бөтен нәрсәне үзенә бертөрле шыбырдауга, тигез бер шауга күмеп, ерактан, әрәмә артыннан эре яңгыр явып килгәне ишетелде. Серле тынлыкта бу шомлы тавышны, яңа гына барлыкка килгән бу тере тавышны ишетү белән Һарун үзен шундый көчсез итеп, шундый мескен итеп сизде, әйтерсең бу һич тә гап-гади яңгыр — йөз мәртәбә, мең мәртәбә күргән-тойган яңгыр түгел иде, әйтерсең бу — вак тояклы ниндидер җанварларның сансыз гаскәрләре иде, һәм алар, каяндыр караңгылык эченнән чыгып, бөтен тигез җирне, бөтен агач яфракларын дәһшәт

белән дөпелдәтеп, ялгыз торып калган кешегә каршы шулай ябырылып киләләр иде.

Тоташ бер стена булып, агарып, томалап килгән көчле салкын яңгыр Һарунның юлын кисте һәм, аның үз иптәшләреннән аерылып калуы өчен, шундый куркыныч чакта, шундый җен туе барган чакта бу далада берүзе калырга батырчылык иткән өчен аннан үч алырга теләгәндәй, ярсып-ярсып өстенә коярга тотынды; барлык тишек-тошыкларын, барлык арыкларын, капкачларын ачып коярга, түгәргә тотынды.

Мондый яңгыр астында юлны дәвам итү һич тә мөмкин түгел иде. Һарун юл читендәге зәгыйфь кенә, сирәк кенә бер зелпе куагы янына йөгерде. Ләкин аңа нибарысы ярты минут чамасы гына ышыкта, корыда утырырга туры килде. Вак яфраклы кәрлә куак аны берничек тә саклап кала алмады. Ул манма су булды, елгада манчып алгандай булды.

Һарун туңа башлады. Куак астына кереп бик зур хата ясаганлыгын ул бары шунда гына аңлый алды. Яңгыр туктаганын көтеп тору һич тә ярамый иде, ничек тә кузгалырга, ничек тә хәрәкәтләнергә кирәк иде.

Ул кыенлык белән генә урыныннан торды, дер-дер калтыранып, сикергәләп юлга чыкты. Яңгыр тынып торган арада, ул кайдадыр урман ягында эт өргән тавышлар ишеткәндәй булган иде. Ни булса да булыр дип, ул әлеге шул эт өргән якка йөгерде.

## VI

Юл аны урман эчендәге ниндидер саман йортлар янына китереп чыгарды. Аның бу якта булганы юк иде, һәм бу йортларның нинди йорт, кем йорты булуын да ул, билгеле, белми иде, ләкин шулай да моны белү дә кыен эш түгел иде. Урман эчендә нинди йорт булырга мөмкин? Йә урманчыларныкыдыр, йә көтүчеләрнекедер. Чыннан да, яңгыр пәрдәсе аша ул арыдарак фермага охшаш каралты-куралар һәм киртәләп алынган түбәле утар эчендә өелешеп мөгердәшеп торган сыерлар күреп алды. Шунда ук көтүчеләр тавышы ишетелеп китте.

Ул якындагы саман йорт янына барып җитте дә, ешеш тын алып, ашыгып, йортның корырак ягына барып сөялде.

Бераз тын алгач, үз-үзен, ниһаять, ышанычлы җирдә итеп сизгәч, ул йортка, каралты-кураларга игътибар беләнрәк карана башлады. «Боларның кайсында кеше тора икән соң?» — дип уйлады ул һәм, тикшереп карамакчы булып, йортның икенче ягына чыкты; стена буеннан

узганда, тәбәнәк тәрәзәдән өй эченә карап алды. Анда кеше-кара күренмәде. Шуннан соң ул чолан сыман бер җиргә килеп чыкты. Бу чолан сыман куыш бер яктан бөтенләй ачык иде, ләкин шулай булуга да карамастан түрдә караңгы иде һәм өйгә керә торган ишекнең кайдалыгын да, гомумән, анда нәрсә барлыгын да тиз генә чамалап булырлык түгел иде.

Һарун берничә адым алгарак атлады да караңгыга карап тора башлады. Каршыда ишек сыман бер нәрсә шәйләгәндәй булгач, ул сакланып кына, капшанып кына тагын кузгалгандай итте.

Ул инде ишек янына килеп тә җиткән иде, тоткага да үрелгән иде — шул чакны яңгырдан качып кемдер түбә астына килеп керде. Килеп керде дә, ишек төбендә таптанып торган кешегә бәрелеп, чак кына кычкырып җибәрде. Һарун кинәт кире чигенде һәм, күзләрен зур ачып, керүчегә текәлде. Ярым караңгыда ул ниндидер кыз кешене күреп алды.

— Кем болады бо?— диде кыз, куркып, шикләнеп. Һарун аны тавышыннан танып алды һәм, куанып:

— Гөлбиби!— дип кычкырып җибәрде. Үз исемен ишетеп, кыз тагын да ныграк аптырап калды.

— Сәлим ага?— диде ул, ни әйтергә дә белмичә.

— Һарун мин! Һарун... Әллә танымыйсың?

— Һарун?!

Шуннан соң кыз ишекне тиз генә ачып җибәрде. Алар өйгә керделәр. Гөлбиби Һарунның өс-башына күз төшереп алды, әүвәлгегә караганда да ныграк каушап, сорау һәм гаҗәпләнү белән аның күзләренә бер тутырып карады да, нәрсәдәндер кыенсынып, тиз генә икенче як бүлмәгә чыгып китте.

— Менә яңгырга эләктем әле... адаштым...— дип сөйләнде Һарун, өйдәгеләр ишетсен өчен юри кычкырып. Өй эчендә ут алынмаган иде, караңгы иде, икенче як бүлмәдә бала-чага, хатын-кыз тавышы ишетелә иде. Гөлбиби ул якка чыгып нәрсәдер әйткәч, үзара сөйләшү тынып калды. Бераздан чәче тузгып торган яланаяклы бер кыз бала, аннары, аның артыннан ук диярлек, кулына янган лампа тоткан бер хатын-кыз килеп чыкты.

— Исәнмесез,— диде Һарун, елмаерга тырышып. Гөлбибинең әнисе аңа баштанаяк күз йөртеп алды да аның сәламенә каршы сәлам белән җавап бирде, лампаны җир идәнгә утыртып куйды һәм ят кунакны түргәрәк, учак янынарак чакырды.

— Менә... балыкка килгәниек тә... яңгырга туры килдем,— дип сөйләнде Һарун, учакка таба атлап.

Хуҗа хатынның үзенә җылы тыныш күрсәтүенә һәм, бигрәк тә, таныш кешеләргә, бер көн булса да үзе белән бергә эшләгән кешеләргә килеп керүенә ул күңеленнән сөенеп куйды. Моңарчы үзләрендә гел чит авылда эшләп, чит кешеләрдә торып өйрәнгәнгә, ул инде үзен теләсә кайда үз өендәге кебек хис итәргә гадәтләнгән иде. Монда да ул үзен нәкъ шулай хис итте һәм хуҗаларның үзе хакында нәрсә уйлаулары турында артык пошынмыйча, утлы учак алдында кулларын угалап, хуҗа хатын белән шундук сүзгә дә керешеп китте.

— Гөлбиби белән без бергә эшләдек,— диде ул.— Әйттеме? Аптырап калдым...

Хатын, күрәсең, аның нәрсә турында сөйләгәнен бераз гына чамалый иде. Әйе дигән сыман, ул аңа баш кагып алды.

— Кая булды соң әле үзе? Керде дә качты,— диде Һарун, чамадан тыш кыюланып һәм, Гөлбибине күрергә иткән кебек, муенын сузып, икенче як бүлмә ягына карап алды.

Ишек ачылып китте, һәм Гөлбиби урынына тыштан, чыланып, Байболат карт килеп керде.

— Исәнме, бабай?— диде Һарун, урыныннан кузгалып.

Үз өендә ят кеше күреп, Байболат карт сагаеп калды. Ят кешенең «нугай» икәнлеген, совхоз «нугае» икәнлеген танып алгач, төсе чак-чак кына үзгәргәндәй булды. Һарунга ул теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды һәм ашыкмыйча гына юеш киемнәрен чишенә башлады.

Һарунның күңел күтәренкелеге шундук юкка чыкты. Учакка бик якын утырса да, ул дерелдәп, чиркәнеп куйды.

— Менә Гөлбибидең танысы экен,— диде хатын, Һарунны карты белән таныштырып.

— Сулайбы...— диде Байболат карт.

Такыр башына дүрт кырлы түбәтәен киеп, ашыкмыйча гына ул учак янына килде дә Һарун каршындагы буш урынга чүгәләде. Чүгәләгәч, һаман берни эндәшмичә, күшеккән кулларын учакка таба сузгалап алды.

Өйдә бик үк күңелле булмаган тынлык урнашты.

— Сапкузданбы?— диде карт, кунакка күтәрелеп карамыйча гына.

— Совхоздан, бабай, совхоздан!— диде Һарун, хуҗа кешенең теле ачылуына күңеле булып.— Мин сине таныдым: син бит безгә килгәниең.

Карт бүтән сүз эндәшмәде. Аның күңелен болай да кузгата алмагач, Һарун, уртак тел тапмакчы булып, яңгырны сүгәргә тотынды, мондый яңгырда көтү белән бик

кыендыр, диде; дала уртасында калсаң менә минем кебек, бик тиз салкын тидерүең мөмкин, диде һәм үзенә ничек салкын икәнлеген аңлатмакчы булган шикелле, бөрешеп-калтыранып алды.

Байболат карт барыбер ачылмады, кунакның сүзләренә бөтенләй колак салмаган кебек, үз уйларына бирелеп, караңгы чырай белән тын гына утыруында булды.

— Балыкка дип килгәниек тә иптәшләр белән...— диде Һарун, инде берничә мәртәбә әйтелгән сүзләрен кабатлап.— Ял көне бит... Кибенәм дә, җылынам да, кайтып китәм турыга гына. Яңгыр туктады түгелме соң?..

Беркадәр дәрәҗәдә үз-үзен кызгандыру өчен, «кайтма» дигән сүз ишетү өчен әйтелгән бу сүзләр дә хуҗа кешегә әз генә дә тәэсир итмәде. Ачу китергеч, күңел шомландыргыч тынлыгын саклап, ул урыныннан кузгалды һәм икенче як бүлмәгә чыгып китте.

Ул арада хатын-кызлар идән уртасына — киез өстенә табын әзерли башладылар. Өстенә коры киемнәрен, хәтта яхшы киемнәрен киеп, юеш чәчләрен тарап, үреп, Гөлбиби чыкты. Учак янында берүзе боегып утырган егеткә ялт кына бер карап алды да, шундый шат, шундый яңгыравык тавыш белән көлеп:

— Гүр суыгы кергенбе сиңа?— диде.— Ни гылып ут яныннан китпәйсең?

Һарун күтәрелеп карады, һәм аңа тагын бик күңелле булып, бик җылы булып китте. «Кусалар да китмим бүген!»— дип уйлады ул, эчке бер кирелек белән.

— Сездә яңгыр бик салкын була икән,— дигән булды ул.— Әйдә, тагын киттекме безгә?

Гөлбиби йөзенә курку билгесе чыгарды, тсс, ишетә күрмәсеннәр тагын! дигән сыман, авызын очлайтып, әтисе кереп киткән бүлмә ягына ымлады да, бер дә юктан мысмылдап көлеп куйды. «Аңлашыла!»— диде Һарун, күз карашы белән елмаеп.

Шул вакыт кулына юылган ап-ак эчке күлмәк-ыштан тоткан Байболат карт күренде.

— Киен,— диде ул, күлмәк-ыштанны егет алдына ташлап.— Киемеңде алыстыр.

Һарун, аптырап, бер картка, бер киемнәргә карап алды.

— Киен, киен!— диде карт, аның икеләнүен күреп.— Бар, анау өйгә барып киен.

Кунак киемнәрне берсүзсез кулына алды да тышка чыгып китте.

Яңгыр әле һаман ява иде, тик ул баягыча салкын да, дәһшәтле дә түгел иде. Ниндидер җылы яңгыр иде ул, иркенләп, җебетеп ява торган яңгыр иде.

Һарун юеш киемнәрен салып борды да, шундагы чыбык очына кибәргә элде, аннары коры, чиста киемнәр киде. Картның күлмәк-ыштаны аңа таман гына булды. Бу киемдә аңа ничектер сәер дә, рәхәт тә булып китте, һәм ул оялып, елмаеп өйгә керде.

Гөлбиби пырхылдап көлеп җибәрде, аңа ияреп балалар да көләргә тотындылар, хәтта Гөлбибинең әнисе дә көлемсерәп куйды — тоташ ак киемнән ул бөтенләй икенче кешегә әйләнеп калган иде.

Байболат карт чөйдән озын гына бер тун алды, тунны янә егеткә сузып:

— Киен,— диде.— Җылырак болыр.

Һарун, рәхмәт әйтеп, тунны да өстенә каплады. Аңа хәзер учак янындагыга караганда да җылырак булып китте.

Табын әзер иде. Киез өстендәге җәймә уртасына итле аш килеп утырган, табак-савыт тезеп куелган иде.

— Отыр, отыр,— диде Гөлбибинең әнисе, Һарунга урын күрсәтеп.

## VII

Ашап туйгач, Байболат картның боз күңеле тәмам эрегәндәй булды. Шырпы белән теш араларын казыштырып, кикергәләп, ул Һарунга сораулар биргәләде, кайсы якнықысың, диде; Казанның үзеннәнме, әллә бүтән җирдәнме, диде. Һарун, Казаннан түгел, дигәч, җанлану билгесе күрсәтеп:

— Әллә Урымбурданмы?— диде.

— Юк, Ырымбурдан да түгел,— диде Һарун һәм үзенең кайсы авылдан икәнлеген әйтеп бирде.

Шуннан соң карт аның йорты-җире белән, ата-анасы, туган-тумачалары белән кызыксынды, сезнең якта ничек, безнең яктагы шикелле даламы, әллә урманлы җирме, диде. Һарун, хуҗа кеше белән сөйләшергә мөмкинлек чыгуына сөенеп, бик теләп, иркенләп җаваплар бирде, үзләре ягы турында, йортлары-җирләре, әнисе, сеңелләре турында сөйләде.

Сүзне шулай бик ерактан урап, хәйләкәр карт совхозга китереп ялгады, сакланып кына, ашыкмыйча гына бригада хәлләре турында, саман сугу турында сораштырды, акча төшәме, диде; эш авыр түгелме, диде һәм тел төбендә әйтелеп бетелмәгән нindидер нәрсәсе бар сыман, янә тынып калды. Аны, билгеле, Һарунның әтисе-әнисе булуы-булмавы да, саман да, ни дә кызыксындырмады. Барыннан да бигрәк аны дала кызыксындырды, туган даласы кызыксындырды.

— Бидай үсәме?— диде ул, ниһаять, үзендәге кирелекне җиңеп.

— Үсә!— диде Һарун, күңеле күтәрелеп.— Ямь-яшел! Үзе куе... менә дигән! Барып карасаң, исең китәр! Мин бит инде иген иккән кеше, бабай, шулай да менә андый бодайны күргәнем югые. Җир җаксы сездә.

— Җаксы!— диде карт, уң кулының баш бармагын тырпайтып.

— Синең әле безнең бодай җирен күргәнең дә юкмыни?— диде Һарун, гаҗәпләнеп.— Синең бит атың бар, атлан да килеп чык бер. Әйләнеп чыгалмассың... Нишләттек менә сезнең буш даланы!

Кунак егетнең мактаныбрак әйтелгән сүзләренә Байболат картның кашлары җыерылып куйды. Ул яңадан тынып калды. Шулай беравык тын гына утыргач, хатынына нидер әйтеп, урыныннан торды. Аның артыннан хатыны да торды һәм почмактагы сандык өстенә өеп куелган ястык-мендәрләрне әвеш-тәвеш китерергә тотынды.

Гөлбиби табын җыештыра башлады. Янында олылардан беркем юклыгыннан файдаланып, ул тунга төренгән килеш стенага сөялебрәк утырган Һарунга утлы күзләрен тутырып бер карап алды да, аның белән үзе арасында ниндидер уртак серләре бар кеше сыман, хәйләкәр генә елмаеп куйды.

— Тагын бер тун кирәкпәйме? Каты тонгансың гой!— диде.

Кинәт тәне авыраеп, йокымсырап киткән Һарунның күзләре ачылды. Кызның елмаюына ул елмаю белән җавап бирде һәм, аның белән генә дә канәгатьләнмичә, шаяртып, бөтенләй үз итеп аңа күз кысып алды. Ят кешегә читтән генә исләре китеп карап утырган кара чәчле бәләкәй малай белән бәләкәй кызый апалары шикелле пырхылдап көлеп җибәрделәр. Һарун, елмаеп, аларга да күз кысып алды, туңган, бөрешкән булып кыланды. Балалар шырык-шырык көлделәр дә көлделәр.

Өстендәге тунны ябынып, йомшак ястыкка сузылып яткач, Һарун бик озак йокыга китә алмый азапланды. Күз алдына елмаеп Гөлбиби килде, нидер вәгъдә итеп аңа күз кысты, көлде һәм матур беләкләрен җитез хәрәкәтләндереп, табын янында нәрсәнедер әвеш-тәвеш китерде. Тышта чуп-чуп итеп юеш җиргә авыр тамчылар тамды, бертуктаусыз дөпелдәп яңгыр яуды, сирәк-мирәк этләр өреп куйды, өй эчендә, ичмасам, кыштырдаган тавыш та ишетелмәде, бары тик теге якта кайсыдыр баланың ара-тирә сулкылдап-сулкылдап куюы гына тынлыкны бозды.

Күңелендә төрле уйлар буталышкан, йөрәге җилкенгән егеткә никтер менә хәзер аның янына шыпырт кына кемдер килеп җитәр шикелле булып, яратып колагына нидер пышылдар һәм кыюланып аның кочагына керер шикелле булып тоелды. Ул көтте, тыңлады, колак салды. Караңгы тынлыкта ул хәтта шул серле кешене, күңеле хәзер шундый нык теләгән, күңеле хәзер шундый нык омтылган кешене күргән шикелле, тойган, сизгән шикелле булды.

Ләкин бу бары хыял гына иде. Чынында исә күрше бүлмәдә беркем дә кузгалмады, беркем дә шыпырт кына бу якка да чыкмады һәм шыпырт кына аңа ул теләгән сүзләрне дә әйтмәде. «Барысы да йоклап беткәч, әллә үзем барыйммы?» — дип уйлады ул, тиеләнеп. Һәм әгәр дә мәгәр сак кына, иплэп кенә барып уятса, берсүзсез ул аны тыңлар шикелле булып, берсүзсез аның янына килер шикелле булып тоелды.

Кинәт кемдер урынында кыймылдап куйды. Егетнең колагы үрә торды, йөрәге тынып, сагаеп калгандай булды, һәм ул чак-чак кына башын калкыта төште. Кеше аягына басты, алпан-тилпән атлап ишеккә юнәлде, тимер келәне ычкындырып тышка чыкты да тамак кырып алды һәм каядыр абзарлар ягына таба китеп барды.

Байболат карт чыгып киткәч, өй эче иркенләп калгандай булды. Хәзер инде Гөлбиби килер, һичшиксез, килер, йөгереп, качып-посып аның янына килер шикелле булып тоелды.

Теге якта чыннан да кемдер кыштырдап куйды, йокы аралаш нидер сөйләнеп, саташып алды. Һарун аның кем икәнлеген аера алмады, шул чакны тышта йөткерә-йөткерә ишеккә таба якынлашып килүче Байболат карт тавышы ишетелде. Кайнар уйлар, хыялый, тиле уйлар, тишелгән куык сыман, кинәт шиңеп калды. Арыган егетнең арыган күзләренә сыек кургаш булып искәрмәстән йокы тулды.

## VIII

Иртән ул уянып киткәндә, өй эчендә беркем юк иде. Өстендәге тунын әллә кая читкә атып орып, ул как киездә бөгәрләнеп ята иде. Ул тиз генә сикереп торды. Торса, чөйдә эленеп торган үзенең киемнәренә күзе төште. Кемдер аны тыштан алып кергән, киптереп, уалап куйган иде.

Ул өс киемен алыштырып киде дә, саубуллашу нияте белән, икенче як бүлмәгә күз төшерде. Анда корышып

беткән куллары белән йон язып утыручы карчыктан башка бүтән беркем юк иде.

— Сау бул инде, әби, китәм. Рәхмәт, бик рәхмәт,— диде Һарун, карчыкка эндәшеп.

— Ой-бой! Уяндыңбы? Кайда җугалды өйдең адамдары?— диде карчык, кузгалгандай итеп.

Ул, ишарәләп, Һарунга сабыр итәргә кушты, мыштырдап, аякларын көчкә хәрәкәтләндереп, тышка чыгып китте. Уң кулы белән зур гына чүлмәк кочаклаган көе бераздан ул кире өйгә керде, чүлмәкне сүзсез генә Һарунга сузды. Һарун, чүлмәкне авызына каплап, аяк өсте генә кымыз эчте. Эчкәч, кесәсеннән бөтәрләнеп беткән бер бишлек чыгарды да рәхмәт әйтеп, карчыкка сузды. Карчык акчаны алып учына йомды, бөрешеп беткән иреннәрен кыймылдатып, пышын-пышын дога кылып куйды. Ул акчаны, күрәсең, хәергә бирделәр, дип уйлады. Бөтен тәнендә сәер бер җиңеллек, күтәренкелек тойган хәлдә, үзалдына елмаеп, Һарун тышка чыкты.

Тышта каты яңгырдан соң гына була торган бер тынлык хөкем сөрә иде. Һава искиткеч саф, чиста иде, бөтен җир, юып алган төсле, ялтырап, җемелдәп тора иде. Табигатьнең ямен җибәрә торган чебен-черкиләр булмаганга, бу көн тагын да матуррак, тагын да гүзәлрәк булып күренә иде.

Көтүләр инде күптән чыгып киткән иде, кайдадыр әрәмә арасында сыер мөгрәгән, ара-тирә кемнәрнеңдер кычкырып куйган тавышлары ишетелгәли иде. Утар тирәсендә бер генә җан иясе дә күренми иде. Бары тик абзар киртәсе янында тезгеннәреннән бәйләп куелган ике ат кына моңаешып тора иде.

Хуҗаларны күрмичә киту, аларга ныклап торып рәхмәт әйтми киту әйбәт булмаячак иде. Аннан да бигрәк, нишләптер Һарунның күңеле юксынды. Аның «кемнедер» күрәсе килде, ул «кемгәдер» нәрсәдер әйтәсе килде.

Ул, берәр таныш кеше күренмәсме дип, йорт алдында бераз гына басып торды да, йөзләгән, меңләгән сыерлар таптап, изеп, сазга әйләнеп беткән баткак җирдән сакланып атлый-атлый, абзарга, бәйләүдәге атлар янына таба юнәлде.

Һарун атлар янына барып җиткәнче, шундагы бер саман йорттан Байболат карт килеп чыкты. Һарунны күреп, ул аңа беренче булып үзе сәлам бирде, атларны чишеп алды да, егеткә эндәшеп:

— Мынау атка менеп карачы!— диде.— Атта йөри беләсеңбе, нугай баласы, карап караекчы!

Һарун берни аңламады. Ул, картның тәкъдимен

ишетмәгән сыман, аңа рәхмәт әйтергә, аның белән саубуллашырга тотынды, мине инде югалтып яталардыр, диде; хәзер инде адашмам, көн аяз, диде. Соңыннан болай гына, сүз уңаеннан гына өстәп куйды, безгә кунакка бар, бабай, диде.

— Менә сезгә конакка барам, әлдә алып бармайсыңбы?— диде Байболат карт.— Әйдә, аттан, конак җегетен җәяү кайтарыңбы?!

Һарун төшенеп алды, ятсынып, колагын шәмрәйтеп торган яшь тимер-күкнең тезгененә сузылды. Байболат карт алдында ул атка җиңел генә атланмакчы булды, ләкин чынында бик үк җиңел булып чыкмады. Карт исә, аның көчәнүен күреп, үчекләшкән сыман:

— Нугай баласы атта җөрүде оныткан!— диде, көлеп.

Алар кузгалып киттеләр. Алдан Байболат карт барды, аның артыннан бераз калышып, Һарун барды. Аяк астында сазлы җир пычтырдады, ат тояклары баскан саен батып-батып китте. Юлга чыккач та әле, вак-вак кына чокырлар белән, тояк эзләре белән тишкәләнеп беткән сазлы җир дәвам итте. Кичәгенәк шундый каты булган юл бүген бөтенләй йомшап, җебеп калган иде. Кайбер урыннарда күл-күл булып яңгыр суы җыелып ята иде. Агач яфракларыннан әле булса берән-сәрән тамчылар тама иде. Ялгыш кына берәр ботакка кагылып китсәң, өстеңә шыбырдап су коелырга гына тора иде.

— Каты җауган, ай-ай, балам!— диде Байболат карт, телен шартлатып.

— Яусын! Игеннәргә бик шәп булды әле бу,— диде Һарун.

Барган саен әрәмә артындагы көтү тавышы якынайганнан-якынайды. Күп тә үтмәде, алар зур гына бер ачыклыкта ашап йөргән сыер көтүе янына килеп чыктылар. Куаклар арасында Һарун Гөлбибине күреп алды һәм янында гына ата кеше барлыгын да онытып, кинәт:

— Гөлбиби!— дип кычкырып җибәрде.— Сау бул, без киттек!

Атка атланган Гөлбиби алар каршысына чыкты. Байболат карт атын туктата төште, кызын көтеп алды да үзенең Көктугайга баруы турында әйтте, аннары көтү мәсьәләсендә киңәшләр бирде.

— Хуш, сау бул. Аман бул, Гөлбиби,— диде Һарун кузгалып киткәч һәм кичәге шикелле елмаеп күз кысып алды.

— Хош, хош!— диде кыз һәм шулай ук кичәге шикелле чыңлатып көлеп җибәрде.

Байболат карт аларның сөйләшүе белән әллә бөтенләй

кызыксынмады, әллә юри кызыксынмаган булып кыланды — артына борылып карамыйча, атын әкрен генә атлатып тик барды.

Һарун кинәт кире борылды, атын юырттырып, юлдан читтәрәк туктап торган кыз янына килде дә аның күзләренә карап:

— Хуш, Гөлбиби,— диде.

— Хош,— диде кыз, әкрен генә.

— Гөлбиби, киттекме безнең бригадага!— диде Һарун.

Кыз башын чайкады.

— Алайса, үзем килимме... синең янга?

Кыз җавап кайтармады.

— Киләм! Көт!— диде егет, үзсүзләнеп.

— Кайчан?

— Теләсә кайчан. Кайчан вакыт бар, шунда!

— Син мине тапмассың. Мин мал багам.

— Мин сине җир тишегеннән дә табам! Кайда көтү, шунда син!

Кыз елмаеп җибәрде.

— Хош, Һарун!— диде ул, кысык күзләре белән, иренe, бите белән — бөтен йөзе, бөтен кыяфәте белән балкып-елмаеп.

— Хуш, Гөлбиби!— диде егет.

Тезгенен ул кисәк кенә тартып җибәрде, тезген очы белән атын сыдыра-сыдыра, ләпек чәчрәтеп, Байболат карт артыннан чаптырып китте. Карт, берни сизмәгән кебек, һаман шулай атын салмак кына атлатып бара иде. Һарун аны куып җитте, атын тыя төште һәм янәшә атлатып бара башлады.

— Эх, бабай, көне нинди матур бүген!— диде ул, тәэсирләнеп.

Иртыш буе әрәмәлекләрен шактый артта калдырып, ачык җиргә килеп чыккач, еракта болай таба килүче бер мотоцикл күренде.

— Барый абый түгелме соң?— диде Һарун, үзалдына.

Мотоцикл бик тиз якынлашты. Атлылар белән тигезләшкәч, ул туктап калды. Бу чыннан да Барый иде. Аның бөтен өсте-башы ләпеккә буялып беткән иде.

— Һарун!— диде ул курку да, шатлык та һәм шул ук вакытта шелтә дә белдергән бер өн чыгарып.— Син исәнмени?! Без инде сине яшен суккандыр дип уйлаган идек. Төне буе яңгыр яуды, беркем рәтләп йокламады. Кайда булдың?

— Мине яшен сугамы соң!— диде Һарун, масаеп, авызын ерып.— Менә Байболат бабайларга барып чыкканмын адашып.

— Аманмы, ата?— диде Барый, чит кешегә шунда гына игътибар итеп.

— Аман, балам, аман,— диде карт, җитез генә.

— Әйдә, алайса, төш тә утыр артка,— диде Барый Һарунга.— Карт кешене интектереп йөрергә... Бабай сине илтә барадыр ич?

— Җок, җок!— диде Байболат карт, аның ни әйткәнен бик яхшы төшенеп.— Мин үзем барам. Сезгә конакка барам. Далада бидайдың өскәнен көрүгә барам.

— Ә, алай булса гына!..— диде Барый.— Әйдә, әйдә, ата, рәхим итәсең! Синдәй кунакларга без бик шат.

— Кунак түгел — хуҗа!— диде Һарун.

— Ие, ие, конак имәс, кужамын!— диде Байболат, куанып.

*1962, Казан*

# ЭЧТӘЛЕК

*М.Мәһдиев.* Заман турында сөйләшә . . . . . . . . . . 7

**Бала күңеле далада**

Беренче баб . . . . . . . . . . 11
Икенче баб . . . . . . . . . . 58
Өченче баб . . . . . . . . . . 127
Дүртенче баб . . . . . . . . . . 175
Бишенче баб . . . . . . . . . . 230
Алтынчы баб . . . . . . . . . . 290
Җиденче баб . . . . . . . . . . 333
Сигезенче баб . . . . . . . . . . 368
Соңгы баб . . . . . . . . . . 407

Литературно-художественное издание

Фаттахов Нурихан Садрильманович

*(Нурихан Фаттах)*

Избранные произведения
в пяти томах

Том 2

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, Г.Г.Зиннәтуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.09.2002.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 22,68+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 13,82.
Нәшер-хисап табагы 22,97+форз.0,36.
Тиражы 3 000 данә. Заказ Б-454.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.